


*Әдәбият халыктан, халыкның хәятыннан, халыкның күңелендәге мәгънә вә хисләрдән бәхәс итә... Әдәбияттагы реализмның бердәнбер әһәмияте фәкать шул ноктадандыр.*

*Тел – уйлауның коралы, уйның калыбы... Миллият бинасының нигез ташларыннан иң ныклысы – тел... Телнең эчендә халыкның рухы, моңы, уй һәм тойгысы яшеренгән.*

Галимҗан Ибраһимов

Кем ул Галимҗан? Ул әдип кенә түгел. Телче, тарихчы гына да түгел. Ул бер татар, казакъ өчен генәме? Юк. Үзбәк, азәрбайҗаннар, тагы әллә кемнәр арасында гына шөһрәт түгел ул. Бөтен Шәрекъның кояшы ул. Менә кем ул Галимҗан!

*МӘҖИТ ГАФУРИ*

Галимҗан Ибраһимов кыйммәте беркайчан да югалмый торган бай, кадерле әдәби мирас калдырды. Ул кулланган иҗат алымнары, ул баетып калдырган әдәби тел әле хәзер дә, яңа заманда да өлге булып хезмәт итә. Аның әсәрләре безнең заман кешесенә дә туган илгә, туган туфракка тирән мәхәббәт тәрбияли, рухи ярлылыктан арынырга, күңел хәзинәсен гуманистик-инсани сыйфатлар белән баетырга ярдәм итә.

*ГОМӘР БӘШИРОВ*

Г. Ибраһимов әсәрләрен укып, шулар үрнәгендә бик күп татар язучылары әдәби осталыкка өйрәнделәр... Аннан соң килгән һәр язучының иҗатында Г. Ибраһимов иҗатыннан килгән, күчкән ниндидер әдәби алымнар, әдәби чаралар яшәп килә. Хәзерге олы буын татар язучыларына әдәби осталык һәм тел ягыннан аның көчле йогынтысы тиде.

*ӘМИРХАН ЕНИКИ*

Галимҗан Ибраһимов зур язучы буларак та, күпкырлы шәхес буларак та халык күңелендә балкый торган җәүһәрләрнең берсе. Алай гына да түгел. Бу җәүһәр яктысында күп нәрсә аермачык күренә, билгеләнә, үзенең бердәнбер төсен ала.

*ГАБДРАХМАН ӘПСӘЛӘМОВ*

Галимҗан Ибраһимов татар халкының, татар мәдәниятенең иң олы патриотларыннан берсе булды. Шуңа күрә дә ул гомерен, талантын, белемен тулысынча туган халкына, туган әдәбиятка, мәдәнияткә хезмәт итүгә бирде. Галимҗан Ибраһимов язучы гына түгел, чын мәгънәсендә тарихчы да, телче дә, тәнкыйтьче дә, шул ук вакытта дәүләт эшлеклесе дә. Мондый кешеләр дөньяга сирәк туа.

*НУРИХАН ФӘТТАХ*

Такой писатель, как Галимджан Ибрагимов, который нашел дорогу к сердцам многочисленных читателей разных народов, бессмертен. Его имя – вечно живой факел, освещающий души. Галимджан Ибрагимов не только народный писатель Татарстана, он всенародный писатель нашей страны. Потому что он воспел те надежды и чаяния, которые были в душе не только татар, но и всех народов Востока. Я преклоняю голову перед великим сыном татарского народа, замечательным писателем. Честь и слава ему, честь и слава и татарскому народу.

*ФАТИХ НИЯЗОВ, таджикский писатель*

Галимджан Ибрагимов – человек энциклопедических знаний и таланта, человек поистине достойный эпохи возрождения, выдающийся писатель, ученый, общественный деятель. Ибрагимов был не просто писатель, он был основоположник, родоначальник татарской современной литературы.

*МИХАИЛ КОЛОСОВ, русский писатель*

Величие и гений Галимджана Ибрагимова, как мне видится, не только в его произведениях, но и в том, что он, будучи большим патриотом своей нации, глубоко уважал чувства и нравы других народов. Что касается казахов, то он был для них и бескорыстным другом, и верным товарищем, и уважаемым учителем-мугаллимом.

*ШАХРАН МОРТАЗАЕВ, казахский писатель*

Г. Ибрагимов – не только ярко выраженный народный, национальный писатель. Он один из крупнейших представителей многонациональной советской литературы. Как автор замечательных романов «Наши дни», «Дочь степи», «Глубокие корни», других не менее прекрасных повестей, рассказов Г. Ибрагимов выходит далеко за пределы национально-литературной известности, что дается не каждому, даже талантливому, писателю.

*АРИФ ГАДЖИЕВ, азербайджанский ученый*

Только истинный художник будет жить болью и чаяниями своего народа. Он переживает, вбирает в свою душу всю радость народа, всю его боль, все его тревоги, все его надежды… Вот именно таким художником, таким писателем был Галимджан Ибрагимов.

*ФРАНЦ ТАВРИН, русский писатель*

МИНИСТЕРСТВО КУЛЬТУРЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
АКАДЕМИЯ НАУК РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ИНСТИТУТ ЯЗЫКА, ЛИТЕРАТУРЫ И ИСКУССТВА им. Г. ИБРАГИМОВА

# НАСЛЕДИЕ Г. ИБРАГИМОВА И ТЮРКСКИЙ МИР

МАТЕРИАЛЫ
МЕЖДУНАРОДНОЙ НАУЧНО-ПРАКТИЧЕСКОЙ КОНФЕРЕНЦИИ,
ПОСВЯЩЕННОЙ 125-ЛЕТИЮ СО ДНЯ РОЖДЕНИЯ Г. ИБРАГИМОВА

17 апреля 2012 г.

КАЗАНЬ
2012

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘДӘНИЯТ МИНИСТРЛЫГЫ
ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ исем. ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

# Г. ИБРАҺИМОВ МИРАСЫ ҺӘМ ТӨРКИ ДӨНЬЯ

Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ ТУУЫНА 125 ЕЛ ТУЛУГА БАГЫШЛАНГАН
ХАЛЫКАРА ФӘННИ-ГАМӘЛИ КОНФЕРЕНЦИЯ
МАТЕРИАЛЛАРЫ

17 апрель, 2012 ел

КАЗАН
2012

УДК 82.512.145(063)
ББК 83.3Тат
Г18

Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты
Гыйльми советы карарына нигезләнеп басыла

**Редколлегия:**

***К. М. Миңнуллин*** *(рәис),* ***Д. М. Абдуллина*** *(фәнни редактор),*
***М. Х. Вәлиев, Р. Ф. Рахмани, З. З. Рәмиев***

**Төзүчеләр:**

***Л. Ш. Бәдертдинова, Ф. Х. Миңнуллина,***

**Г18 Г. Ибраһимов мирасы һәм төрки дөнья:** Г. Ибраһимовның тууына 125 ел тулуга багышланган Халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары (17 апрель, 2012 ел). – Казан, 2012. – 265 б.

ISBN 978-5-93091-152-7

Җыентыкта күренекле язучы, галим, җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның тууына 125 ел тулуга багышланган Халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары тупланды. Аларда әдипнең тормыш юлы, фәнни һәм иҗтимагый эшчәнлеге, иҗат мирасы, башка әдәбиятлар белән бәйләнеше, төрле телләргә тәрҗемәсе һәм сәнгатьтә чагылышы гәүдәләнеш таба.

**ISBN ISBN 978-5-93091-152-7**

© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм
сәнгать институты, 2012

# ОЛУГ ШӘХЕС, КҮПКЫРЛЫ ТАЛАНТ ИЯСЕ
# ЯРКАЯ ЛИЧНОСТЬ, МНОГОГРАННЫЙ ТАЛАНТ

Татар әдәбияты классигы, энциклопедист-галим, күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, Хезмәт Герое Галимҗан Ибраһимов (1887–1938) – ХХ йөз башы татар дөньясында әһәмиятле урын тоткан, әдәбиятыбыз һәм мәдәниятебез тарихында тирән эз калдырган олпат шәхес. Ул, Ф. Әмирхан, Г. Исхакыйлар кебек үк, ХХ йөз башында татар мәдәни алгарышына хезмәт итте, Г. Сәгъди, Г. Алпаровлар белән тел, әдәбият фәненең нигезләрен салышты, бар тырышлыгын милләтебезнең бәхетле киләчәгенә багышлады.

Әдип калдырган мирас гаять бай һәм киң тармаклы. Ул, гасыр дәвамында төрле милләт укучылары тарафыннан бердәй хуп күреп кабул ителгән әдәби әсәрләреннән (дүрт роман, биш повесть, бер пьеса, егермеләп хикәя) тыш, гуманитар гыйлемнәрнең төрле өлкәләрен яктырткан биш йөзгә якын тәнкыйть һәм публицистик мәкаләләре, унике фәнни хезмәте һәм тел-әдәбият буенча дистәдән артык дәреслекләре белән дә мәдәни үсешебезгә зур өлеш кертә. Төрки халыклар һәм татар тарихын, җәмгыять кануннарын, мәгарифебезнең үткәнен һәм киләчәген күздә тотып язылган хезмәтләре аңа татар зыялылары арасында гына түгел, ил күләмендә танылу китерә.

1920 нче елларда Г. Ибраһимов милли мәдәният, фән һәм мәгариф эшләрен җайга салу максатын күздә тоткан Академик үзәкне оештыруда башлап йөрүчеләрнең берсе, аның әйдәп баручы җитәкчесе була.

Тарихчы, этнограф, профессор, җәмәгать эшлеклесе Л. И. Климович бик хаклы рәвештә билгеләп үткәнчә, «Галимҗан Ибраһимов иҗаты татар әдәбиятында да, тугандаш халыклар – әйтик, башкорт, казакъ һәм төрекмән әдәбиятларында да реалистик прозаның алга китүенә уңай йогынты ясады». Чыннан да, күп кенә төрки халыкларның әдипләре аны үзләренең остазлары итеп күрде һәм күрә.

Үпкә авыруы көчәеп киткәнлектән, гомеренең соңгы ун елын әдип Кырымда яшәп иҗат итә. Ни аяныч, тоталитар режим зур иҗат планнары белән яшәгән олуг галим һәм язучыны каләменнән аера. 1937 елның 29 августында кулга алынып, ул Казанның Пләтән төрмәсенә кайтарыла.Тоткынлык шартларында авыру халәттә озак түзү мөмкин булмый. Г. Ибраһимов 1938 елның 21 гыйнварында вафат була.

Г. Ибраһимов хезмәтләренең тулы басмасын әзерләүгә әле ул үзе исән вакытта ук керешелә. 1929 –1931 елларда җиде томлык итеп планлаштырылган басманың икенче, бишенче һәм алтынчы томнары нәшер ителә, 1933–1934 елларда биш томда «Сайланма әсәрләр»е дөнья күрә. Соңрак, шәхес культы шаукымы узгач, 1956–1957 елларда, өч томлыгы басыла, 1974 –1986 елларда сигез томлык тупланмасы чыгарыла һәм шуңа өстәп әдипнең хатларын, документларын эченә алган 9 нчы том гамәлгә куела (2000).

Классик татарской литературы, ученый-энциклопедист, видный государственный и общественный деятель, Герой Труда Галимджан Ибрагимов (1887–1938) – выдающаяся личность, занимавшая важное место в татарском мире начала ХХ века, оставившая глубокий след в истории нашей литературы и культуры. Он, как Ф. Амирхан и Г. Исхаки, в начале ХХ столетия трудился во благо культурного прогресса татарской нации, вместе с Г. Сагди, Г. Алпаровым заложил основы татарского языкознания и литературоведения, всего себя посвятив светлому будущему нашего народа.

Писатель внес весомый вклад в дело культурного развития татарского народа. Кроме литературных произведений (среди которых четыре романа, пять повестей, одна пьеса, около двадцати рассказов), на протяжении десятилетий с единодушным восхищением принимавшихся представителями разных народов, его перу принадлежат почти пятьсот критических и публицистических статей, посвященных самым разным областям гуманитарного знания, двенадцать научных трудов и более десяти учебников по татарскому языку и литературе. Его работы, освещавшие историю татарского и других тюркских народов, законы общественного развития, прошлое и будущее нашего образования, принесли ему известность не только в среде татарской интеллигенции, но и в масштабах всей страны.

В 1920-х годах Г. Ибрагимов руководил созданным по его инициативе Академическим центром, который должен был координировать деятельность по развитию национальной культуры, науки и образования.

Как справедливо отмечал историк, этнограф, общественный деятель профессор Л. И. Климович, «творчество Галимджана Ибрагимова оказало положительное влияние на развитие реалистической прозы как в татарской литературе, так и в литературах родственных народов – скажем, башкирской, казахской и туркменской». Действительно, литераторы многих тюркских народов видели и видят в Г. Ибрагимове своего учителя.

Подготовка к изданию полного собрания сочинений Галимджана Ибрагимова началась еще при его жизни. В 1929–1931 годах были изданы второй, пятый и шестой тома из запланированных семи, в 1933–1934 годах увидело свет пятитомное собрание избранных сочинений писателя. После ликвидации культа личности, в 1956–1957 годах, вышел из печати трехтомник его произведений, в 1974–1986 годах было выпущено восьмитомное издание, которое было дополнено девятым томом (2000 год), содержащим письма и документы литератора.

Творчество Г. Ибрагимова продолжает оставаться в сфере внимания ученых и исследователей. Защищаются

Г. Ибраһимов хезмәтләрен төрле аспектта өйрәнеп, докторлык, кандидатлык диссертацияләре яклана. Монографияләр, истәлек китаплары басыла, юбилейлары уңаеннан ил күләмендә һәм халыкара фәнни конференцияләр уздырыла.

Тарихи мирасыбызны саклауга ихтыяҗ аеруча арткан дәвердә әдипнең мирасын тулырак барлау һәм тирәнтен өйрәнү тагын да әһәмиятлерәк төс ала. Институтыбыз тарафыннан әдипнең хезмәтләрен 12 томлык яңа басма рәвешендә кабат әзерләүгә керешү бу юнәлештәге эшләрнең иң зурысы һәм иң әһәмиятлесе булыр дип көтелә.

Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Фәннәр академиясе һәм Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты тарафыннан уздырыла торган «Галимҗан Ибраһимов һәм төрки дөнья» исемле Халыкара фәнни-гамәли конференция дә әдип мирасын киң масштабта, мәдәни багланышлар контекстында өйрәнү юнәлешендә мөһим чараларның берсе булып тора.

Бу форум төрки дөньяның һәм илебезнең төрле төбәкләреннән олы галимнәрне, әдәбият, тел, тарих, мәгариф өлкәсендәге белгечләрне туплады. Төркия, Азәрбайҗан, Казакъстан, Каракалпакстан, Кырымнан һәм Россиянең күп төбәкләреннән, аерым алганда, Башкортстаннан һәм Татарстанның үзеннән Г. Ибраһимовның бай иҗатын, эшчәнлеген төрле яклап өйрәнүгә, аның биографиясен яңа фактлар, күзәтүләр белән баетуга өлеш кертә алырлык материаллар белән килгән кунакларыбыз, галимнәребез бар.

Менә аларның кайберләре: «Alimcan İbrahim ve Tatar Medeniyeti» (Mustafa Öner, Izmir), «Г. Ибраһимов – яңа әдәбият тудыручыларның берсе» (Д. Ф. Заһидуллина, Казан), «Г. Ибраһимов мирасында әдәби тәнкыйть» (Т. Н. Галиуллин, Казан), «Г.Ибраһимов – җәмгать һәм дәүләт эшлеклесе» (И. Р. Таһиров, Казан), «Ғалымжан Ибраһимов және XX ғасыр басындағы қазақ әдебиеті» (К. Алпысбаев, Астана, Казакъстан), «Г. Ибраһимов татарларның социалистик хәрәкәт эшлеклесе» (А. Ю. Хабутдинов, Казан), «Егерменчеутызынчы елларда Г. Ибраһимовның эстетик эволюциясе» (Ф. Г. Галимуллин, Казан), «Г. Ибраһимов һәм Азәрбайҗан» (Вагиф Арзуманлы, Баку), «Сугышка кадәрге кырым-татар матбугаты Галимҗан Ибраһимов турында» (И. А. Керимов, Кырым), «Мари әдәбияты прозасында Г. Ибраһимов традицияләре» (И. С. Иванов, Йошкар-Ола), «Үзгәртеп корудан соңгы татар әдәбият белемендә Г. Ибраһимовның иҗади мирасын өйрәнү мәсьәләләре» (Р. Ф. Рахмани, Казан) һ. б.

Г. Ибраһимов шәхесе һәм аның иҗаты еллар дәвамында эзлекле рәвештә, төрле яклап өйрәнелсә дә, гаять мул һәм киң тармаклы бу мирас яңа эзләнүләр һәм табышлар өчен һәрвакыт ачык. Бүгенге конференция әдипне өйрәнүдәге эшчәнлегебезне күздән кичереп бәяләү һәм алдагы максатларны билгеләү юнәлешендә нәтиҗәле адым булыр, дип ышанам.

**К. М. Миңнуллин,**
*Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры, профессор, ТР ФАнең мөхбир әгъзасы*

докторские и кандидатские диссертации, посвященные тем или иным аспектам творчества писателя, издаются монографии и книги воспоминаний, проводятся республиканские, всероссийские и международные конференции, посвященные юбилейным датам, связанным с его именем.

В эпоху, когда особую актуальность приобретает сохранение нашего исторического достояния, сбор и более глубокое изучение наследия писателя становится еще более важным. Ожидается, что подготовка двенадцатитомного собрания сочинений писателя, к которой приступил наш Институт, станет наиболее значимым шагом на этом пути.

Существенным вкладом в дело всеобъемлющего изучения творческого наследия писателя в контексте межкультурных связей является проведение Министерством культуры Республики Татарстан, Институтом языка, литературы и искусства имени Галимджана Ибрагимова Академии наук Республики Татарстан Международной научно-практической конференции «Галимджан Ибрагимов и тюркский мир».

Этот форум собрал выдающихся ученых, специалистов в области литературоведения, языкознания, истории, образования из разных регионов тюркского мира и нашей страны. На конференции присутствуют гости из Турции, Азербайджана, Казахстана, Каракалпакстана, Крыма, многих областей России. Надеемся, что представленные доклады раскроют новые грани творчества Г. Ибрагимова и обогатят его биографию новыми фактами и наблюдениями.

Вот лишь некоторые из них: «Alimcan İbrahim ve Tatar Medeniyeti» (Мустафа Онер, Измир), «Г. Ибрагимов – один из создателей новой литературы» (Д. Ф. Загидуллина, Казань), «Литературная критика в наследии Г. Ибрагимова» (Т. Н. Галиуллин, Казань), «Галимджан Ибрагимов – общественный и государственный деятель» (И. Р. Тагиров, Казань), «Ғалымжан Ибраһимов және XX ғасыр басындағы қазақ әдебиеті» (К. Алпысбаев, Астана, Казакстан), «Галимджан Ибрагимов как деятель социалистического движения у татар: от просвещения к политике» (А. Ю. Хабутдинов, Казань), «Эстетическая эволюция Галимджана Ибрагимова в двадцатые–тридцатые годы» (Ф. Г. Галимуллин, Казань), «Галимджан Ибрагимов и Азербайджан» (Вагиф Арзуманлы, Баку), «Крымско-татарская довоенная пресса о Галимджане Ибрагимове» (И. А. Керимов, Крым), «Художественные традиции Г. Ибрагимова в марийской прозе» (И. С. Иванов, Йошкар-Ола) и др.

Несмотря на то, что личность Г. Ибрагимова и его творчество последовательно и разносторонне изучаются уже на протяжении многих лет, его многогранное наследие всегда открыто для новых изысканий. Верю, что эта конференция станет и своеобразным подведением итогов изучения творческого наследия писателя, и точкой определения новых масштабов и горизонтов наших исследований.

**К. М. Миннуллин,**
*директор Института языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова, профессор, член-корр. АН РТ*

# Г. ИБРАҺИМОВ – ӘДИП, ГАЛИМ, ДӘҮЛӘТ ҺӘМ ҖӘМӘГАТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ

## Г. ИБРАҺИМОВ – ЯҢА ӘДӘБИЯТ ТУДЫРУЧЫЛАРНЫҢ БЕРСЕ

***Д. Ф. Заһидуллина (Казан)***

Статья посвящена определению места и роли прозаических произведений Г. Ибрагимова, написанных в 1909–1912 гг., в формировании новой светской литературы. Констатируется, что в рассказах писателя репрезентован новый герой – «националист», ратующий за развитие своей нации. В романтических произведениях писателя происходит раскол традиционной религиозной картины мира на философские дискурсы.

Г. Ибраһимов (1887–1938) – язучы, әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче, тел белгече һәм җәмәгать эшлеклесе. Без аны XX йөз башында яңа әдәбият тудыручыларның берсе буларак хөрмәтлибез. Бу процесс тизләнеп үсү юлына чыккан татар әдәбиятының хасиятләре белән бәйле була: кыска гына вакыт аралыгында милли әдәбиятта дөнья сурәте тулысынча үзгәрә һәм ул өр-яңа юнәлеш ала.

Г. Ибраһимовның беренче әсәрләрендә татар җәмгыятенең аерым бер яклары тәнкыйтьләнү, мәгърифәтчел караш уздырылу гомумбилгеле. Ләкин башлангыч чор иҗатына караган «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә» (1909) хикәясендә тәкъдим ителгән герой – мәгърифәтчелек чикләрен узган. Ф. Әмирханның «Гарәфә кич төшемдә» (1907), «Бәйрәмнәр» (1909) хикәяләрендәге кебек үк, ул да милләтне гомуммәдәни яктан үстерүне мөһим санаучы, милләтче булып күз алдына баса.

Сюжет Сәлим исемле яшь егетнең Әстерханнан өч тапкыр Казанга килүен колачлый. Беренче килүе 1901 елда була, бу вакытта Сәлим – милләтне яратучы, бөтен барлыгын, тормышын милләт өчен корбан итәргә әзер «ялкынлы милли идеяле яшь бер адәм». Берничә ел үткәч Казанга килгәндә, «*ул, тар «милләтчелек» даирәсеннән чыгып, «инсаният даирәсенә» күчкән, милләтчелекне ташлап, инсаниятче булган, «милләтем… татарым…»ны ташлап, «ватаным – бөтен җир йөзе… милләтем – бөтен бәни бәшәр» нәзариясенә иман китергән иде*» (2, 481). Өченче килүендә герой бу фикерләреннән дә ваз кичкән, шәхси мәнфәгатьләрен («*үзенең генә сәгадәте өчен тырышып, мал, байлык, гаилә вә гүзәл тормыш артыннан йөрүне*» (2, 483) кайгыртучы, үзенең тормышын көйләү өчен, университетка укырга керергә теләүче булып күренә. Ләкин әсәр ахырында Сәлим яңадан үзгәреш кичерә: үзенең милләтче вакытын сагына, яңадан шул чакларын кайтарып алу хакында хыяллана. Автор аның өчен мәхәббәтнең – билгеле бер идеягә, максатка хезмәт итү, яшәү мәгънәсе икәнлеген ассызыклый. Шулай язучы Сәлим образында инкыйлаб һәм аннан соңгы елларда зыялы татар яшьләрендәге фикри үзгәрешләрне сурәтләү объекты ясый, үз заманы кешесен әдәбият мәйданына китерә. Сәлим образы аша әдәбиятның төп максаты – татар милләтен үзгәртү, алдынгы милләтләр сафына чыгару икәнлеге белдерелә.

Г. Ибраһимовның «Уты сүнгән җәһәннәм» (1911) хикәясендәге Гыйльман Каһиров – шундый ук тип. Хикәяләүче Садыйк-философ авызыннан язучы кешеләрне ике төркемгә бүлә: язмышны үзгәртүчеләр һәм аңа буйсынучылар. Гыйльман үз язмышын үз кулына ала. Садыйк та үз алдына зур максат куя: «*…мин бик бай хыяллы, хәяттан бик күп нәрсә өмет итүче адәмнәрнең берсе идем. Төрле мәдрәсәләрдә укыганнан соң, үзеңне үзгәртү, мәдәниләштерү, дөнья фәннәре тәхсиль итеп, иҗтимагый эшләрнең бере артыннан йөри торган бер халык хезмәтчесе булу минем баш теләгем иде*» (2, 128), ләкин аның йомшак характеры «*сәҗдә кыла торган идеалына*» ирешергә мөмкинлек бирми. Шул рәвешле, Ибраһимов тудырган заман герое алга таба XX йөз әдәбиятының лейтмотивы булган фикерне – һәр кешенең милләтне үстерүгә хезмәт итәргә тиешлеге фикерен – формалаштырырга ярдәм итә.

Милли әдәбиятка төп үзгәрешләрне Г. Ибраһимовның романтик әсәрләре алып килә, аларда «шәхеснең югары күтәрелүе милләтнең, халыкның югары күтәрелүен аңлата: геройның көндәлек тормыш вакыйкларыннан өстен хисләре кичерешләрнең яңа бер дөньясын хасил итә, татар милләтенең уянып килүче милли үзаңын гәүдәләндерә» (4, 71).

Г. Ибраһимов иҗатында йөзек кашы булган романтик әсәр – «Яшь йөрәкләр» романы (1912) – XX йөз башында иҗат ителгән олы эпик жанр үрнәкләре арасында фәлсәфи характеры белән аерылып тора. Сюжет бирелеше ягыннан үз чоры тормышын тергезә. Ике гаилә, бигрәк тә Җәләш мулла һәм аның балалары Зыя, Сабир мисалында язучы «аталар» һәм «балалар» каршылыгын тудыра, аталары дөрес дип тапкан яшәү рәвешенең балалар омтылышларына тәңгәл килмәве хакында сөйли. Бу каршылыкны «Әдәбият кануннары» дигән хезмәтендә Г. Ибраһимов үзе үк күрсәтеп уза,

аны «искелек һәм яңалык көрәше» дип билгели. Ләкин бу көрәш нәтиҗәсендә «балаларның» омтылышлары тормышка ашмаган кебек, «аталар» төзегән тәртипле көнитеш тә җимерелә. Шул рәвешле, романда язучы традицион татар тормышы-көнитешенең җимерелүе, югалуы турында сөйли. Алга таба шушы мотив модернизм әдәбияты туу өчен нигез була.

Әсәрдә ерак фон төсендә һәрвакыт Алла – кеше мөнәсәбәте катнаша. Геройлар – мөселманнар, үзәккә куелган Зыяның Алла белән сөйләшүләре әсәр тукымасында әһәмиятле урын били. Зыя үлгәннән соң, әсәрнең финалы төсендә, Кәрим мәхдүмнең зиратта сөйләгән сүзләре кыска гына дин фәлсәфәсен кабатлап уза: яшәү һәрвакыт үлем белән тәгәлләнә – бу илаһи канун; без җир йөзендә мөсафирлар гына – билгесез мәңгелеккә китәбез; тормышың башкалар өчен никадәр кыйммәтле, үлемең шулкадәр хәсрәтле; Алладан киләбез һәм аңа әйләнеп кайтабыз. Соңгысы Коръәннән аллюзия ярдәмендә кабатлана: *«Ялгыз... Ялгыз бер юаныч бар: «Инна лилләһи вә инна иләйһи раҗигун!»* Шулай итеп яшәүнең ахыргы максаты ислам динендәгечә аңлатып узыла.

Ләкин Алланың барлыгы табигый факт буларак беркетелгән хәлдә, әсәрдә башка каршылык үзәккә куела. Ул «кеше – мохит» каршылыгы, нәкъ менә шушы каршылык хаос, тәртипсезлек сәбәбе булып аңлашыла. Романның буеннан-буена «мохит» сүзе кабатланып, кеше мохиттә яши, мохиттән азат була алмый, дигән фәлсәфә әсәрнең башлангыч уйланмасын тәшкил итә. Дөрес, чыгарма төсендә әдип бик сирәк кешеләрнең генә үз язмышларын үзгәртә алуын әйтә, ләкин боларның «гадәттән тыш» кеше икәнлекләрен дә искәртергә онытмый. Әлеге фәлсәфә татар әдәбияты өчен традицион дини күзаллауга тәңгәл түгел, киресенчә, ул аны җимерүгә, башка күптөрле караш-дискурсларга таркатуга хезмәт итә.

Романда сурәтләнгән геройлар язмышы да мохиттән азат булу омтылышы белән бәйләнгән. Бу язмышлар каршылыклы кабул ителә торган фәлсәфи нәтиҗәгә китерә: мохитнең тар кысаларыннан бары тик түбәнгә төшеп кенә котылырга мөмкин. Г. Ибраһимов моның төрле вариантларын берәм-берәм укучы күз алдыннан уздыра. Мохит мәҗбүриятеннән беренче булып котылган герой Сабир крестьянга әйләнә: «*Минем үз малым, үз дөньям булыр. Минем алдар хыялым тараер. Мин үз эшемне эшләп, үземә һәм үземнең ирегемә үзем хуҗа булырмын. Азат булырмын. Миңа шул җитә дә*» (3, 60). Мәдрәсәдә укыган мулла малаеның җир эшкәртеп көн күрүе, укымаган кызга өйләнүе – үз дәрәҗәсеннән, мохитеннән түбән төшү. Ләкин Сабир өчен ул бәхеткә ирешү юлына әверелә. Җәләл муллага мохиттән котылу – югалу, читкә китү, качу булып чыга. Мәрьямнең хөкем ителүе, сөргенгә җибәрелүе аны мохиттән аера. Зыя исә үлеп кенә газаплардан арына. Физик үлем белән чикләнмичә, әдип Сәлим язмышында «рухи үлем» вариантын да күрсәтә. Кайчандыр милләт өчен зур эшләр башкару максаты белән тырышып йөргән егет кире үз мохитенә кайтырга мәҗбүр була. Аның үз-үзенә кул салыр алдыннан язган хатындагы өзектә мохит белән ризалашу, ягъни иманны-идеалны югалту кайберәүләр өчен үлемгә тиңләштерелә.

Госман мисалында мохит белән килешү, ризалашуның башка варианты күрсәтелә: авылга кайтып, дөнья көтә башлау. Ләкин бу Госманга канәгатьлек, тынычлык китерми.

Әсәрдә кешегә каршы куелган мохит кешене әйләндереп алган тирәлеккә дә, җәмгыятькә дә тәңгәл түгел. Мәгънәдәш сүз төсендә язучы *«язмыш»*ны файдалана. Романның иң башында китерелгән ике төш – төш эчендәге төш – шушы мәгънәгә өстенлек бирә. Төштә Мәрьям киләчәктә булачак хәлләрне: Зыяның солдатка алынуын, Фәхринең ире булганын, үзенең аны үтерүен, Зыя белән тиңсез мәхәббәтләрен, шуны югалтуларын күрә. Димәк, болар – язмышка язылган, булырга тиеш хәлләр. Төшнең беренче сәхифәсендә дөньяны караңгылык, «гомуми үлем тарафыннан берьюлы» йотылудан курку каплый – аны азан тавышы юкка чыгара. Яшәүнең чиклелеге китергән газапны ислам өйрәтүе җиңә, ди автор. Бу фикер Зыяны күмү вакыйгасы белән кисешә. Хаосны тәртипкә китерә алган көч – ислам дине, Аллага ышану булып чыга. Роман артыннан ук мәйданга чыккан модернизм әдәбиятында чишелеш бөтенләй башка: хаосны җиңәр көч табылмый.

Төштә китерелгән, Мәрьямнең револьвер алганнан соңгы халәтен тасвирлау тагын бер фикерне ныгыта: язмышны үзгәртү теләге – иң көчле теләк, иң олы омтылыш. Бу алга таба күп геройлар тормышы мисалында кабатлана.

Өченче фикер мәхәббәтнең – олы бәхет, яраткан кешенең Алла дәрәҗәсендәге кадерле зат булуын белдерә. Мәрьям белән Зыя арасындагы мәхәббәтне гайре табигый, олы һәм көчле хис буларак сурәтләп, автор һәрдаим аның кешегә бәхет китерүен ассызыклап килә. Шунысы мөһим, әлеге өч фикер алга таба татар әдәбиятында кабатлана башлый, иң еш очрый торган мотивларга әверелә.

Романтик герой Зыя музыкага гашыйк, көйне нечкә тоемлаучы итеп сурәтләнә. Үз заманында Г. Гобәйдуллин Зыя образын «безнең мохиттә генә формалаша алырлык тип» дип атый, аның фәлсәфәсен руссочыл карашлар белән янәшә куя. Шул ук вакытта Зыяның «зәгыйфь, хатыннар табигатьле мәңгелек трагедия әһеле» булуын да җәмгыятьтән, мохиттән күрә (1, 189). Ягъни татар җәмгыятенең нечкә күңелле, рухи бай, талантлы яшьләр җитештереп тә, аларга үз сәләтләрен милләт файдасына хезмәткә куярлык шартлар тудыра алмавына игътибар итә.

Бер яктан, Г. Ибраһимов татар милләтенең хәлен шулай ук мохит чикләреннән чыга алмаган бердәмлек буларак бәяләп уза. Сәлим авызыннан «татар милләте кояш баешына бара» диелә. Зыя исә – шушы язмышны, мохитне үзгәртү юлын музыкада тапкан кеше: «*Музыкам белән татарның аслы рухын уйгатырмын, күгәргән йөрәген сафлармын һәм аның авыр язмышына бер үзгәреш бирермен, томанлы вә караңгы хәятына бер нур тудырырмын*» (3, 314). Татарда сәнгатьне, мәхәббәтне тыю мохит кысалары, чикләүләре кебек аңлашыла. Зыяның соңгы сүзләре бу фәлсәфәне тагын бер тапкыр кабатлый: үсештән туктаган милләтләрне сәнгать уята, кузгата, алга җибәрә ала.

Дини дөнья сурәтенең кире чагылышы «Мәрхүмнең дәфтәреннән» (1914) хикәясендә дә күзәтелә. Романтик сюжетка корылган бу әсәрендә язучы романтик хикәяләүче герое – карт шагыйрь күңелендә эчке каршылык барлыкка китерә. Ул – фәлсәфи мәсьәлә, тормыш мәгънәсен эзләүдән туа: «*Мин хәят эзләдем, хәятта мәгънә эзләдем, хәятның барлык рәхәтләрен фида кыйлдырырлык мәртәбәдә изге була алырлык бер*

*идеал эзләдем. Моны кем эзләмәгәндер, ләкин табучы булганмы?*» (2, 206) – дип сорый карт шагыйрь.

Яшәү идеалы, җир йөзендәге бәхет – матур кызларда, мәхәббәттә, дип ышанган чагы да була карт шагыйрьнең. Ләкин ул аннан ваз кичә. Яшәү мәгънәсен эзләп дингә дә мөрәҗәгать итә. Ләкин *«дин исеменнән түгелгән кан дәрьяларын»* күреп, гайрәте чигә. «Изге идеал» дип милләткә хезмәт итүне саный. Ләкин бу юлда да төрле ихтыяҗларның бугазга-бугаз килүен аңлый. Ниһаять, игътибары фән, гыйлем һәм мәдәнияткә төбәлә. Герой әдәбият һәм сәнгать алдында «*тук мещаннар һәм бай аристократлар*»га хезмәт итүдән башка максатны эзли, йөрәге белән көтә, ләкин таба алмый. Нәтиҗәдә, рухи газаплана, җәфа чигә. Язучы шундый авыр шөбһәләр эчендәге героен караңгы бакчада тормыш төбендә яшәүче кешеләр – сукбайлар белән очраштыра. Хикәяләүчедән аермалы буларак, болар реалистик планда, натуралистик детальләр ярдәмендә сурәтләнә. Автор карт шагыйрьгә алар авызыннан рәхмәт әйттерә, язган әсәрләренең бу кешеләргә җан азыгы булып хезмәт иткәнлеген хәбәр иттерә. Сукбайлар исеменнән шагыйрьгә әйтелгән рәхмәт «сәнгатьнең төп максаты – тормыш төбендәге кешеләргә хезмәт күрсәтү, аларны хак юлга өндәү» дигән фикерне раслый. Дини дөнья сурәте белән каршылыкка кергән «шагыйрь-пәйгамбәр» образы хасил була. Шәхес өчен газиз кыйммәтләр: ана һәм сөйгән яр, дин, фән, гыйлем, милләт күздән кичерелеп, әдәбият аларның барыннан да югары куела, тормыштагы иң кадерле нәрсә кебек шәрехләнә. Ләкин бәхетнең әдәбиятта – уйлап табылган, иҗат ителгән дөньяда булуы кешенең иллюзия белән яшәвенә дә ишарә ясый.

Шулай итеп, Г. Ибраһимов – чор панорамасын тарихи-мәдәни аспектта гына түгел, психологик, психоаналитик, фәлсәфи яссылыкларда тергезгән язучы. Үз әсәрләре белән ул татар әдәбиятына яңа герой һәм үзгә дөнья сурәте алып килә, фәлсәфи тирәнлек, өстәмә мәгънәләр бирү, күпкатламлы тормыш моделе төзү ярдәмендә заман тудырган тема һәм мотивларны гомумкешелек фәлсәфәсе дәрәҗәсенә күтәрә.

ӘДӘБИЯТ


1. Газиз Г. Яшь әдәбиятыбызда «Яшь йөрәкләр» / Газиз Гобәйдуллин // Аң. – 1913. – № 11. – Б. 189–194.

2. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. I т.: Хикәяләр (1907–1929) / Г. Ибраһимов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. – 509 б.

3. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. II т.: Яшь йөрәкләр. Казакъ кызы / Г. Ибраһимов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. – 604 б.

4. Нигматуллина Ю. Г. Национальное своеобразие эстетического идеала / Ю. Г. Нигматуллина. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1970. – 211 с.


# ALIMCAN İBRAHIM VE TATAR MEDENIYETI


***Mustafa Öner (İzmır)***



В данной статье предпринята попытка раскрыть образ Г. Ибрагимова как преподавателя, ученого, общественного деятеля на фоне культурного прогресса татарского народа. В статье дается подробная биография Г. Ибрагимова в связи с его активным участием в движении джадидизма, анализируется его преподавательская, просветительская и общественная деятельность. Особое внимание уделено анализу работ Г. Ибрагимова, касающихся реформирования и дальнейшего развития татарского литературного языка начала XX века.


## *Tatar Medeniyeti*

Türkiye'de *Kazan Türkleri* başlıklı kitabıyla Tatar tarihini ve kültürünü tanıtan Abdullah Battal Taymas, Alimcan İbrahim'e de genişçe yer vermiştir. Ülkemizdeki diğer Tatar muhacirleri gibi Sovyet rejimine hep uzak duran ve açıkça da eleştiren yazarın, ünlü Tatar edibi A. İbrahim'in 1917 sonrasındaki edebiyatını da "hikaye veya roman kılığındaki siyasî şeyler" diye tenkit etmesini bugün daha iyi anlıyoruz (16, 143). Ancak A. B. Taymas, Alimcan İbrahim'in Sovyet devrinde millî Tatar medeniyetini kurmak için çok çaba gösterdiğini de yazmıştır (16, 208–210).

Türkoloji öğrencisi olarak hakkındaki ilk bilgileri böylece edindiğim Alimcan İbrahim'den bana doğrudan doğruya ilk söz eden Altayist Türkolog Üzbek Bayçura oldu. Sovyetler Birliği'nin son yılında yaz aylarında gittiğim Leningrad'da tanıştığım büyük Tatar bilgini Dr. Üzbek Bayçura A. İbrahimov'un "***Tatar medeniyetĕ nindiy yul bĕlen baraçak***" başlıklı eserinin ilk basımını orada hediye etmişti. Ü. Bayçura ayrıca Sovyet dönemi Tatar dil bilimi üzerine yazdığı İngilizce bir makale de verdi. Türkiye'de o ara basılması için bir yol bulamadığım bu makaleyi, Harvard Üniversitesi yayınları arasında *Türklük Bilgisi Araştırmaları* dergisi çıkaran Prof. Dr. Şinasi Tekin'e göndermesini söyledim. Böylece ABD'de çıkan o makalesinde Ü. Bayçura, Gıybad Alpar, Alimcan Şeref gibi bilginlerin yanı sıra Alimcan İbrahim'in Tatar dil bilimine katkısını da anlatmıştı. Bayçura'nın bu makalesinde yazarın "***Tatar medeniyetĕ nindiy yul bĕlen baraçak***" başlıklı eseriyle özel olarak ilgilendiği görülür (3).

Alimcan İbrahim'in doğumunun 120. yılı dolayısıyla özel olarak yayımlanan Kazan Utları dergisinin 2007/3 sayısında Şerif Bayçura'nın merhum edip hakkındaki hatırasını okuyunca üstadım Üzbek Bayçura'nın bana "***Tatar medeniyetĕ nindiy yul bĕlen baraçak***" başlıklı eserini niye hediye ettiğini daha iyi anlamış oldum: Babası ünlü Tatar gazetecisi Şerif Bayçura, yazarımız Alimcan İbrahim ile daha 1911'de tanışmıştı. Sovyet Devrimi sonrasında *Kızıl Armiya* gazetesinde sekreter olarak çalışan Şerif Bayçura, Alimcan İbrahim ile beraber çalışmış ve yazar 1927'de tedavi için Kırım'a gidinceye kadar komşu olarak yaşamıştı (4, 99–100).

Üzbek Bayçura'nın verdiği "***Tatar medeniyetĕ nindiy yul bĕlen baraçak***" bana Arap harfli eski Tatarca metinler için iyi bir örnek olmuştu, bu metin üzerinde özel olarak çalıştım. Bolşevikler Partisi üyesi Alimcan İbrahim'in millî kültürü savunduğu bu eserini ayrı bir makale ile tanıttım: "*Bir Tatar Bolşeviğinin Ana Dili Mücadelesi*" (12).

Alimcan İbrahim Sovyet Devriminin 10. Yılında Tatarcanın devlet dili, eğitim dili olarak gelişmesine seviniyordu. Yazarın bu eserinden alarak yayınladığım şu görüşleri çok önemliydi:

*“Ruslaşma eğilimi tamamen yenildi. Bu Tatarlaşma esasında şimdi bizim alfabelerimiz, okuma kitaplarımız, dil dersi kitaplarımız, imlalar, Tatar gramerleri, edebiyat kanunları ve edebiyat tarihleri tamamen işlenip yola koyuldu, Tatarcanın tam bir sözlüğü de yapılmaktadır”* (9, 34).

*(…) Bu şartlar içinde, Rus medeniyetinin Tatar medeniyetinden üstünlüğü, onun için de Tatarlar için zayıf medeniyetten yüksek medeniyete geçme gereği hakkındaki konuşmalar, sadece, Rus milletinin eski üstünlüğünü korumak için çıkarılmış bir fikirdir. Tatarlar arasında böyle fikirlerin olması, sadece, eski zamandaki Ruslaştırma siyasetinin Tatar zihninde bıraktığı gölgesi, kendisini düşük ve inançsız görme alışkanlığının bir neticesidir* (9, 38).

Bu makale çıktıktan birkaç yıl sonra Hoca Ahmet Yesevi Uluslararası Türk-Kazak Üniversitesinde, Ankara'da 1 Nisan 2000’de “İdil-Ural Türk Aydınları Sempozyumu” yapıldı. Bu toplantıda Alimcan İbrahim’i anlatmak görevi bana verilmişti. Yazarın bütün hayat hikâyesini ve eserlerini ele aldığım konuşma metnini de makale biçiminde *Türk Yurdu* dergisinde yayımladım: “İdil-Ural’dan Bir Aydın: Alimcan İbrahim” (13).

Alimcan İbrahim’in geniş edebî mirası sonraki yıllarda da hep ilgimi çekti. Ege Üniversitesi Türk Dili ve Edebiyatı Bölümünde Tatarca öğretmeye çalıştığım derslerde bu eserleri kullandığım gibi *Kazak Kızı* romanının Arap harfleriyle basılan ilk metni üzerine ayrıca bir tez de yaptırdım: Özlem Özmen, *Alimcan İbrahim’in “Kazak Kızı” Romanının Söz Varlığı, Giriş-Metin-Dizin*, (Yüksek Lisans Tezi) 2006.

## *Geniş Kültür Biyografisi*

Alimcan İbrahim, eski Ufa Gubernası İsterlitamak ilçesinde Soltanmorat köyünde doğar, babası da muallim ve molladır. Onun köy medresesinin yanı sıra üç sınıflık Rusça okuluna da gitmesi ilgi çekici. 1905 Devrimine kadar devam ettiği Orenburg’daki Veli Mulla medresesinden eski düzeni protesto eden gösterilere katıldığı için arkadaşlarıyla birlikte atılır. Rusya’da 1905 ile birlikte topluma yansıyan yenilik düşünceleri onu da sarmıştır. 1906’da Ufa’ya gelir ve Aliye medresesine girer. 1915–1917 yılları arasında tekrar öğretmen olarak döneceği bu okul onda büyük bir iz bırakacaktır. A. İbrahim’in İsterlitamak’ta başlayan Orenburg ve Ufa’dan geçen hayat çizgisi, bir süre yaşadığı Kazak dalalarına ve Urallarda çalıştığı çeşitli işlere genişlemiştir. 1909’da bölgenin kültür merkezi Kazan’a gelen genç yazar, burada üç yıl boyunca Tatar gazete ve dergilerinde makaleler yayımlayıp *Yaz başı, Diñgězde, Yöz yıl ělěk, Söyü segadet, Utı süngen cehennem, Karak Mulla* gibi ünlü hikâyelerini ve *Yeş Yörekler* romanını yazar (8, 8–9). Yazar 1912’de Kiev’e gider, burada siyasi etkinliği dolayısıyla bir süre tutuklanır. 1913 Nisan ayında Kazan’a dönüp *Añ* dergisi sorumlu sekreteri olarak çalışan yazarın biyografisinde 1914’de tekrar Kiev’e ve oradan da Sovyet Devrimine kadar öğretmenlik yapacağı Ufa’daki Aliye medresesine gittiği görülüyor (5, 194–200).

Köylü bir muallimin çocuğu olan Alimcan’ı o günkü Rusya’nın İdil-Ural bölgesindeki bütün büyük kültür merkezleri kendisine çekmiştir: İsterlitamak – Orenburg – Ufa – Urallar – Kazak stepleri – Kazan – Kiev – Ufa. Sadece bu son yolculuğun bile 2116 kilometrelik mesafeye uzandığını belirtmek isterim. A. İbrahim’in geniş edebiyat mirası, sadece köklü bir medrese eğitimine ve ilaveten aldığı Rusça bilgisine değil, aynı zamanda hayatının ilk otuz yılında biriktirdiği, çok geniş alandaki bu büyük görgü ve insan tecrübesine de dayanıyor.

## *Ceditçi*

XIX. yüzyıl sonları Alimcan İbrahim ve çağdaşlarının doğup yetiştiği bir devir olarak modernizmin doğu toplumlarında gelişmeye başladığı çağdır, okuma ve aydınlanma bu gelişmenin açık kapısıydı. Bu yüzyılın başında açılan Kazan Üniversitesi, özellikle şarkiyat ve Türkoloji çalışmalarının merkezi olarak haklı bir şöhret edinmişti. Bu yüzyılda Rusya içindeki Tatar toplumunun gittikçe seküler hale geldiğini gözlemek mümkündür. Yüzyılın sonlarına doğru İsmail Gaspıralı’nın öncülüğünde yeni bir eğitim ve öğretim usulü olarak başlayan akım, hayatın hemen hemen her alanında kadim usulün, eski anlayışın karşıtı olarak gelişmişti. Burada hiç tereddüt etmeden bu Usul-ı Cedid’in öne çıkan merkezinin Kazan olduğunu söylemek mümkün (7, 272).

Alimcan İbrahim’in şimdi tekrar okuduğumuz biyografisinde bu cedidizmin çok önem taşıdığını görüyoruz: Genç öğretmen 1905 Devriminden sonra özgürlük fırsatı bulan ortamdan etkilenmiş, kendisinde gelişen protest tutumdan ötürü medreseden de atılmıştır. Yazarın bu hayat tecrübesi 1907’de yazdığı “Zeki Şekěrtněn Medreseden Kuvıluvı” eserine yansımıştır. 1906 sonlarında Ufa’ya gelen yazarın okumaya başladığı “Aliye” medresesinden de bu ceditçi ve reformist düşünceleri dolayısıyla üç yıl içinde ayrılmak durumunda kalmıştır (8, 8–9).

Tatar halkını asırların kulluğundan, cehalet ve karanlığından kurtarmak, eğitimli kılmak atılımı ile XIX. yüzyılda başlayan Ceditçilik akımı çok değişir, XX. yüzyıl başında hem ülke dışından, Rusya’dan hem içeriden gelen etkiler sayesinde Tatar toplumunun bütün katmanlarına nüfuz edecek bir güce dönüşür. Çünkü yüzyıl başında artık Ceditçilik yeni zaman kalkınmasının milli ideolojisi haline gelmiştir. C. Velidi ve A. İbrahim bu hareketin, hayatı yeni tarzda, Avrupaî biçimde değiştirmek, Doğu’dan Batı’ya yönelmek olduğunu belirtirler (17). A. İbrahim’de öğrencilik yıllarında başlayan bu reformculuk, öğretmenlik ve yazarlık yıllarında gelişmiş ve 1917’den sonra giderek devrimci bir tutuma dönüşmüştür.

## *Öğretmen*

Rusya’da Çar Hükumetinin Müslüman toplumun okuma, aydınlanma ve medeniyet alanında kalkınma taraftarı olan ceditçileri değil de skolastik gelenekleri korumak isteyen kadimcileri desteklemesini anlamak mümkündür. Dolayısıyla Alimcan İbrahim gibi bir ceditçinin 17 Nisan 1913’te tutuklanması ve 1917 Şubat Devrimine kadar gözetim altında yaşaması da bunun bir parçasıdır. Çarlık zindanlarını tanıyan, sürgünlerde yaşayan Ayaz İshaki (doğ. 1878) gibi büyük Tatar edipleri arasına Alimcan İbrahim’i de katmak gerekir. 1915 sonlarında “Aliye” medresesinde öğretmenliğe başlayan yazarın oradan ayrıldıktan sonra bu kutsal göreve Astırhan’da Nogay Tatarlarının çocuklarını okutarak devam ettiğini görüyoruz (8, 9). Sabit Mukanov ve Muhtar Evezov gibi büyük Kazak yazarları, öğretmenliğindeki şöhreti de Uralların doğusundaki steplere uzanan Alimcan İbrahim’e, bu nedenle saygı bildirmişlerdir (2, 94–97).

Yazarın öğretmen kimliğinin onun ceditçi modernist yönüyle ilişkisi en çok kadınların eğitimi ve özgürleşmesi

konusunda kendisini gösterir. Yazarın *Tatar Hatını Niler Kürmiy* adlı romanı kızların okula gitmesi, eğitim alması sorununu doğrudan gündeme alan bir klasiktir. İlk kez 1910'da basılan ve baş tarafında "*İrler suretĕnde yörgen hatın, İsterlĕtamak öyezĕnde bulgan vakıyga*" ibaresi bulunan bu esere yazarın eklediği şu satırlar ne kadar çarpıcıdır:

"*Bilirsiniz: Bizim Tatar dünyasında, ağır hayatına, cebir ve cefaya dayanamadan kaçıp tabiatın verdiği kadınlık sıfatını gizleyip, erkek görünümünde gezmeye mecbur olan mazlum kadınlara az da olsa rastlanır. Eski devirlerde yedi kız, erkek kıyafetine girip uzun yıllar medresede okumuşlar, sonra da büyük bir faciaya uğramışlar deniyor. Bunlar hakkında epeyce türkü ve hikâye vardır. Bu acı gerçeğe ben de rastladım, biri İsterlĕtamak biri Orenburg'da olup her ikisi de yirminci asırdadır. İsterlĕtamak'taki araştırıldıktan sonra elinizdeki şu sayfalar karalandı*" (10, 502–503).

Edebiyat tarihçisi Daniya Zahidullina XX. yüzyıl başı Tatar edebiyatının en esaslı konularından olan bu eğitim sorununa ilişkin şunları yazıyor: "Tatar edebiyatında aydınlanma (*megrifetçilik*) realizmi, öğretim yöntemleri hakkındaki tartışmadan kaynaklanır. Bu eserlerde eski usulde ders vermeyi, kadim okuma yurtlarını eleştirmek ve yeni usulde bilimin gerekliliğini, önemini göstermek esastır. F. Kerim'in «*Cihangir mehdümnĕñ avıl mektebĕnde ukuvı*» (1898), «*Bĕr şekĕrt bĕlen bĕr student*» (1900), Z. Hadi'nin «*Cihanşa Hezret*» (1906), R. Fehreddin'in «*Esma yeki Gamel ve Ceza*» (1903), A. İbrahim'in «*Zeki Şekĕrtnĕñ Medreseden Kuvıluvı*» (1907), M. Akyigit'in «*Hisametdin Molla*» (1886) eserleri bunlardandır" (17).

### *Bilim Adamı*

Alimcan İbrahim Sovyet Devrimi öncesinde edebiyat ve dil bilimine ait eserler de yayımlamıştır: *Tatar Sarıfı* (1911), *Tatar Nehvĕ* (1911), *Tatar İmlası* (1914), *Yaña Edebiyat* (1914), *Edebiyat Derĕslere* (1914), *Tatar Tĕlĕn Niçĕk Ukıtırga* (1916) başlıklı yayınlar, Tatar filolojisinin ilk ciddi ve metotlu kaynakları olarak değer taşır.

Yazarın 1925–1927 döneminde Tataristan Bilim Merkezi (*İlmi Üzek*) Başkanı olarak bilim adamlığına devam ettiğini biliyoruz: Okullar için düzenli programlar, ders kitapları hazırlamak, ülke tarihini araştırmak, tabiat ve sanat anıtlarını korumak ve Tatarcayı bilim ve edebiyat bakımından işlemek gibi işler onun etkinlikleri arasındadır. A. İbrahim'in başkanlığı altında M. Korbangaliyev, Ş. Ehmediev, G. Segdi, G. Rehim gibi Tatar bilim adamları ve eğitimciler bu merkezde çalışırken, Moskova'dan M. Pavloviç, İ. Borozdin, P. Kogan ve A. Samoyloviç bilim adamları da merkezin işlerine katıldı (8, 15). Burada çağının en önde gelen Türkologlarından olan A. Samoyloviç'in Türkiye'de Mustafa Kemal Atatürk'ün sağlığında yapılan Türk Dili Kurultaylarının da misafiri olduğunu belirtmek gerekir. Otuzlu yıllar sonlarındaki Stalin repressiyası, A. Samoyloviç ile A. İbrahim'i ne acı ki facialı hayat finalinde tekrar buluşturmuştur.

### *Toplumcu*

Yazar kendisinin toplumcu ve devrimci olarak yetişmesini şu satırlarıyla anlatıyor: "Benim Marksist bir edip olmam, proleterya bayrağı altında çalışmayı hayatımın, ömrümün esas maksadı olarak seçmem, bütün geçmiş hayatımın tarihî ve mecburi neticesidir" (8, 8). Alimcan İbrahim'in diğer Tatar aydınları gibi zindanında yattığı Çar'dan kurtulmak anlamına gelen Sovyet Devrimine ve onun önderi Lenin'e samimi olarak inandığı açıktır. Devrime kalemiyle hizmet eden yazarın henüz iç savaş sürerken, Kızıl Ordu'nun en ciddi düşmanı olan Kolçak ordusunun egemenlik alanlarına kıyafet değiştirerek casus gibi geçmesi ise son derece dikkat çekicidir. 1919 yılında Mayıs-Ağustos ayları arasında dört ay süren bu yolculukta kıyafet değiştiren yazar, seyyar satıcı belgesi çıkartıp köylerde orak, tırpan satarak gezer ve bütün Uralları ve Batı Sibirya'ya kadar gider ve sağ salim geri döner. A. İbrahim'in kendi konforunu düşünmeden atıldığı bu büyük macerada da masa başında oturmayan romantik bir toplumcuyu görüyoruz (6, 144).

1917 Şubat Devriminden sonra onun siyasi ve sosyal hayata aktif katıldığını görüyoruz: F. Seyfi Kazanlı ve Ş. Sünçeley ile birlikte *İrĕk* gazetesini çıkarmaktadır. Ayrıca Ekim Devriminden itibaren M. Vahitov ve Ş. Manatov ile birlikte Merkezi Müslüman Komiserliğinin kurulmasında çalışırlar. 1920'de ise Tataristan Halk Maarifi Komiserliğindedir ve *Bĕznĕñ Yul* ve *Megarif* dergilerinin kurucusu ve yazarıdır. Tataristan Cumhuriyeti'nin hiç şüphesiz kurucuları arasında anılması gereken yazarın yürekten inandığı Leninci millî politikayı gerçekleştirmek için yorulmadan çalışıp gazete ve dergi sayfalarında, toplantılara, konferanslara eğitim, kültür, edebiyat ve sanat konularıyla katıldığını görüyoruz (8, 13).

1926'da Bakü'de bilim adamı 131 resmi delegenin katılımıyla toplanan SSCB 1. Türkoloji Kurultayına (*Pervıy vsesoyuznıy tyurkologiçeskiy s'ezd*) Tataristan'dan da bir heyet gitmiştir: Abdrahimov Galey Şakiroviç (Ali Rehim), İbad (Gıybed) Alparov, Salah Sadri oğlı Atnagulov, Sibgat Satdıkoviç Gafurov, Galimcan Girfanoviç İbrahimov, Gayaz Kısımoviç Maksudov, Gabdurrahman Eynan oglı Saadi, Galimcan Şerefoviç Şeref.

Görkemli bir bilim şöleni olmanın yanı sıra kurultayın önceden belirlenen en önemli gündemi, Sovyetlerdeki Türk kökenli topluluklar için Latin alfabesine geçiş kararının kabul edilmesiydi. Türk Dünyasının XX. yüzyıl boyunca en önemli toplantılarından biri olan Bakü Türkoloji Kurultayında Arap esaslı mevcut alfabeyi savunanlar arasında Kazak dil bilgini Ahmet Baytursun'un yanı sıra, Tatar delegeleri Alimcan Şeref ve Alimcan İbrahim dikkat çekmişlerdir. Onlar son dönemde belirli bir reforma tabi tutulan Arap alfabesini bırakarak Latin alfabesine geçilmesine şiddetle karşı çıkıyorlardı.

A. İbrahimov, bu kurultaydaki konuşmasında Türk dilinin ses uyumu ve eklemelilik özelliklerini tespit etmiştir. İmlada fonetiğin esas alınması halinde ağızlar arasından seçme yapıp birine esaslanılması gibi çarpık bir durumun gelişeceğini bildiren İbrahimov, morfolojik prensibin imlada ve dilde birleştirici olacağını vurgulamıştır. SSCB KP'nin buradan çıkarmak için çok uğraştığı Latin alfabesi kararına direnen A. İbrahim ve arkadaşlarının biyografilerini tek tek okumak ilgi çekici sonuçlar vermişti (bk. Öner, 1996). Bakü Türkoloji Kurultayı'nın 70. yıl dönümü için Ankara'da Türk Dil Kurumunda yapılan toplantıya Üzbek Bayçura'nın hediye ettiği steno kayıtları esaslı tutanaklar üzerinde çalışarak katılmıştım. Sonraki yıllarda bu tutanakları Azerbaycanlı Prof. Dr. Kamil Veli Nerimanoğlu ile birlikte Türkçe olarak yayımlamak da nasip oldu (1).

Yazar, 1927'den itibaren ağırlaşan verem hastalığı dolayısıyla Kırım'a yerleşir ve daimi olarak burada yaşar. Hastalığı gittikçe ilerlemesine rağmen ömrünün sonuna kadar yazmaktan uzak durmaz. Bilim ve kültür alanındaki

hizmetleri dolayısıyla 1928'de Devlet Sanat Bilimleri Akademisi üyesi seçilir. 1932'de ise Rusya Merkez İcra Komitesi kararıyla "Hizmet Kahramanı" unvanı verilir.

1937'de repressiyanın yükseldiği yılda, A. İbrahim'i "Sağcı Troçkist milliyetçilerin Sovyet hakimiyetine karşı olan örgütüne katılmakla suçlayıp tutuklarlar. Hasta halinde Kırım'dan Kazan'a getirirler ve kapatıldığı hapishanenin hastanesinde 1938'de ölür, ancak vefatından sonra aklanmıştır. Tataristan Bilimler Akademisine bağlı Dil, Edebiyat ve Sanat Enstitüsü 1967'den beri onun adını taşımakta.

Yazarın hapishane hastanesinde duvara yazdığı satırlar çok çarpıcı: "Otuz yıl boyunca edebiyat yolunda yaptığım işlerin son günlerinin böyle biteceğini düşünmemiştim. Ne yaparsın! Tarih araştırır, doğru değeri verir" (15, 104).

Alimcan İbrahim gibi Çar'ın topraklarında XIX. yüzyılın sonlarında doğan nesillerin, halka hizmet etme, aydınlanma, okuma ve okutma idealleri ile dünya haritasını ve dünya tarihini değiştirmiş olduklarını görüyoruz. İdeolojilerin anlamını yitirdiği bu çağda, büyük Tatar yazarının yüz yıl önce de çok önem verdiği Tatar medeniyeti iddiası hâlâ gündemdedir.

### KAYNAKÇA


*1. 1926 Bakü Türkoloji Kurultayı, Tutanaklar*. Çevirenler: Kamil Veli Nerimanoğlu, Mustafa Öner. – Ankara 2008. – S. 486+44. Türk Dil Kurumu Yayınları: 936.

2. Akyĕgĕt R. Galimcan İbrahimov turında kürĕnĕklĕ edipler // *Kazan Utları.* – 2007. – № 3. – S. 94–97.

3. Baitchura U. S. *An Overview of the Development of Tatar Linguistics in the Soviet Time (Introduction and Part I. Achievements in Linguistic Theory; Part II. Achievements in Lexicography; Part III. Achievements in Grammar, Giybad Alpar and his Grammatic Teaching* // Journal of Turkish Studies vol. 17 "Harvard University" 9–36.

4. Bayçura Ş) *Bĕrge uzgan yıllar // Kazan Utları.* – 2007. – № 3. – S. 98–100.

5. Dautov R. N.-Nurullina, N. B. *Sovyet Tatarstanı Yazuçıları:* biobibliografik bĕlĕşme. – Kazan, 1986. – S. 194–200.

6. Gaynetdin M. Doşmannar Arasında Dürt Ay *// Kazan Utları.* – 2007. – № 3. – S. 144–149.

7. Kurat A. N.) Tanıtmalar (*Bennigsen, Alexandre et Ch. Lemercier-Quelquejay; La Presse et le mouvement national chez les Musulmans de Russie avant 1920*) Cilt: 23, 1965. – Sayı: 3–4, 257–282. (http://dergiler.ankara.edu.tr/dergiler/26/1047/12641.pdf)

8. Hesenov M. *Galimcan İbrahimov Eserler* I. – Kazan: Tatarstan Kitap Neşriyatı, 1974.

9. İbrahimof A. *Tatar Medeniyetĕ Nindiy Yul Bĕlen Baraçak?* – Kazan: Tatarstan Devlet Neşriyatı Basması, 1927.

10. İbrahimov G. Eserler, sigez tomda 1. – Kazan: Tatarstan Kitap Neşriyatı, 1974.

11. Öner M. (1996) *I. Bakü Türkoloji Kongresinde İdil-Ural Türkleri*, 1926 Bakü Türkoloji Kongresinin 70. Yıl Dönümü Toplantısı (29–30 Kasım 1996), TDK: 726. – Ankara, 1999. – S. 13–25.

12. Öner M. "Bir Tatar Bolşeviğinin Ana Dili Mücadelesi" // *Türk Dili*. – Sayı 546, Haziran-1997. – S. 551–557.

13. Öner M. "İdil-Ural'dan Bir Aydın: Alimcan İbrahim (1887–1938)" // *Türk Yurdu,* Eylül-2001, cilt: 21. – Sayı 169. – S. 58–61.

14. Salyahova Z. G. Naturalizm v tvorçestvo Galimvana İbragimova: Dis. Kand. Filol. Nauk: 10.01.02. – Kazan, 2004. – 181 s. (http://www.dslib.net/literatura-rosii/saljahova.html)

15. Şamov A. (2007) *Galimcan İbrahimovnıñ songı könnerĕ turında istelĕkler // Kazan Utları.* – 2007. – № 3. – S. 101–104.

16. Taymas A. B. (1988*) Kazan Türkleri*, (3. Basım). – Ankara: "Türk Kültürünü Araştırma Enstitüsü" yay. 81.

17. Zahidullina D. *Tatar Edebiyatı Tarihi* (Türkçe basılmakta).

18. Zahidullina D. *Modernizm hem XX yöz başı Tatar Prozası.* – Kazan: Tatar Kitap Neşriyatı, 2003.


## ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ – ҖӘМӘГАТЬ ҺӘМ ДӘҮЛӘТ ЭШЛЕКЛЕСЕ


***И. Р. Таһиров (Казан)***



Статья посвящена исследованию деятельности Г. Ибрагимова как общественного и государственного деятеля. На примере многочисленных исторических фактов восстанавливается период борьбы татарского народа за независимость.


Киң җәмәгатьчелек Галимҗан Ибраһимовны татар әдәбиятының классигы, искиткеч гүзәл әсәрләр тудырган язучы рәвешендә кабул итә. Ләкин шул ук вакытта аның революциягә кадәрге җәмәгый, аннан соңгы дәүләти эшчәнлегенә тиешле бәя бирелми һәм ул бик начар яктыртыла.

Галимҗан Ибраһимов үзенең әдәби эшчәнлеге белән бергә тарихыбыз белән дә ныклап шөгыльләнгән, аның тирән тамырларын һәрдаим диярлек тикшерә килгән шәхес. Газиз Гобәйдуллин кебек тарихчылар һәрвакыт диярлек аның фикерләренә колак сала, аның белән киңәшә торган булганнар.

Күбебезгә мәгълүм, 1911 елны Зәки Вәлидинең «Төрек-татар тарихы» китабы дөнья күрә. Китапның кульязмасы тәгаенләнгәннән соң Вәлиди Галимҗан Ибраһимов белән очрашып, аның белән киңәшә. Автор баштарак китапны «Төрек тарихы» дип кенә атаган була. Әдип аңарга китапны «Татар тарихы» дип үзгәртергә киңәш итә. Фикер алышулар нәтиҗәсендә китап «Төрек-татар тарихы» исеме белән дөнья күрә. Китап чыккач та, «Йолдыз» газетасы битләрендә Ибраһимов китапны милли тарихыбызга керткән зур өлеш дип бәяли.

Бу очракта мин Галимҗан Ибраһимовның тоемлау сәләте көчле булганлыгына басым ясар идем. Ул бит китапны төрек тарихы түгел, нәкъ менә «Татар тарихы» дип кенә атарга тәкъдим иткән. Бәлки ул кайбер Вәлиди белмәгән чыганакларны да белгәндер. Аныһы мәгълүм түгел. Тик шунысы ачык, ул төркилекнең башында татарлар торганлыгын нык тоемлаган булып чыга. Моның чыннан да шулай икәнлеген 1875 елда ук инде инглиз галиме Эдвард Паркер үзенең «Тысяча лет из истории татар», «Татары: история возникновения великого народа» исемле әсәрләрендә ныклап дәлилләгән. Аларның русчага тәрҗемәсе тик 2003 һәм 2010 елларда гына дөнья күрде. Ләкин аның инглизчә оригиналын Г. Ибраһимов белгәндер дип уйлау кыен. Ә бәлки ул башка чыганаклар белән дә таныш булгандыр?

Дәүләтчелек тарихы белән кызыксыну Ибраһимов өчен ниндидер мавыгу гына булмый. Ул гомере буе дәүләтчелегебезне аякка бастыру эшенә җаны-тәне белән бирелеп яши.

Ул моның өчен теләк кенә җитмәячәген, аны тормышка ашыру тиешле әзерлек таләп иткәнлеген яхшы аңлый. Шул әзерлекнең бер канаты – теоретик, икенчесе практик әзерлек икәнлегенә инана. Теоретик әзерлек, ул «без кем?» дигән сорауга җавап булырга тиеш була. 1913 елны «Аң» журналында шушы темага үткәрелгән дискуссияләрне оештыруда, аның җаваплы секретаре Ибраһимовның роле зур була. Журнал битләрендәге фикерләр халкыбызны, бу очракта аның укучыларын, татарлыкларында ныгыта. Петербург шәһәрендә татар студентларының «Татар учагы» оешмасы барлыкка килү, анда Ильяс Алкин, Галимҗан Шәрәф кебек, соңрак дәүләтчелегебезне торгызуга зур өлеш керткән шәхесләрнең булуы да әнә шул татарлыкның ныгуына ишарә.

Галимҗан Ибраһимов милли идеяне, яки дәүләтчелек идеясен тормышка ашыруның коралы булырга һәм аның милли партия булырга тиеш икәнлегенә дә инана. Татарларны туплау, аларны оештыру һәм милли фирка төзү идеясе белән яна башлый.

Ул, шушы максаттан чыгып, 1914 елның 13 февралендә журналның редакция коллективы белән дусларча саубуллашып, Киев шәһәренә юл тота. Киев аның өчен ят шәһәр булмый. Ул бирердәге мөселман студентлары белән хат алышып торган була. Ә 1912 елның ахырында анда булып та кайта. Киевта аңа татар студентлары тантаналы очрашу оештыралар. Ибраһимов бик тиз арада студентлар оешмасы белән танышып, аларның кайсы партияләргә тартым икәнлекләрен ачыклый. Шул ук вакытта Украина радасы һәм «Бунд» вәкилләре белән дустанә мөнәсәбәтләр урнаштыра.

Ә инде бу килүе әнә шул эшчәнлекне дәвам итү максатыннан була. Ул украиннарның милли партиясе «Спилка»ны төзү һәм эшләү тәҗрибәсен өйрәнә. Аны татар милли партиясенең өлгесе итеп алмакчы була. Федералистик рухта булган грузин демократларының партия төзү тәҗрибәсен дә өйрәнә.

Милли партия оештыруда ул үзенең якын һәм ышанычлы көрәштәшләре рәвешендә Йосыф Акчура, Гаяз Исхакый, Фатыйх Кәрими кебек кешеләрне күрә. Жандарм документында, Киевкә китәренә 3 көн каларак, Г. Ибраһимовның, булачак партиянең үзәгендә Гаяз Исхакый, Шәһит Әхмәдиевләр торырга тиеш, дип әйткән сүзләре язылган (1). Чыннан да бу кешеләр аның иң якын көрәштәшләре була.

15 февраль көнне ул Киевка килеп җитеп, «Москва» кунакханәсенә урнаша. Күрәсең, монда яшәү кыйммәткә төшәчәген аңлап, икенче көнне үк Львовская урамының 55 йортында бүлмә алып, Одессага киткәнчегә кадәр шунда яши.

Казаннан киткәндә үк аңа «коерык ябыштыралар», «интеллигент» кушаматы тагалар. Шуннан соң әдип турындагы мәгълүмат жандармнарга агыла тора. Киевкә килгәч, аңа тентү оештыралар, кайбер әйберләрен алып та калалар. Аларны китәр алдыннан, үзе жандарм идарәсенә килгәч кенә кайтарып бирәләр.

Г. Ибраһимовның сәяхәте Киев белән генә чикләнми. 17 март көнне Одессага китә. Шул ук көнне «Цесаревич Георгий» пароходы белән Сухуми шәһәренә килә һәм «Венеция» кунакханәсенә урнаша. Аннан, нәкъ Киевтагы кебек үк, Сигаев дигән берәүнең йортында яши башлый. Жандарм агенты доносларында «ничего предосудительного замечено не было», «и ведет замкнутый однообразный образ жизни и общение ни с кем не имеет» дигән сүзләр бар. Көн саен почтага килеп, үзенә җибәрелгән корреспонденцияне алуы, кичке прогулкага чыгуы һәм кичләрен өйдә үткәрүе турындагы хәбәр җиткерелеп тора. Гомумән аның һәрбер адымы күзәтү астында була.

Беренче бөтендөнья сугышы башлану партия төзү эшен туктатуга сәбәп була. Ләкин төрле рәвештәге очрашулар, сөйләшүләр тукталмый. Г. Ибраһимов игътибарын Дәүләт Думасының мөселман фракциясенә дә юнәтә, аларның ярдәменә дә өметләнә. Февраль революциясеннән соң ул Петроградта фракция урнашкан бүлмәгә килеп керә. Керсә, күрә, депутатлар тәмәке төтене арасында карта сугып утыралар. Боларны бүлмәнең тышкы ягындагы вакыйгалар бөтенләй кызыксындырмый кебек тоела аңа. Ул депутатларны халыктан аерылган, аның акчасын бушка ашап ятучылар, дип бәяли. Һәм инде алардан өметен өзә.

Бердәнбер өмете һәм ышанычы булып иске дуслары Шәһит Әхмәдиев, Фуат Туктаров, Гаяз Исхакыйлар калалар. Ул алар белән элемтәсен беркайчан да өзми, милли партия төзү кирәклеген һәрвакыт сеңдереп тора.

Февраль революциясеннән соң бу эш яңадан җайга салына. Казанда Мулланур Вахитов җитәкчелегендә Мөселман социалистлар комитеты, аның органы «Кызыл байрак» газетасы барлыкка килә. Шушы комитетның әгъзалары Шәһит Әхмәдиев «Аваз», Фуат Туктаров «Корылтай» газеталарын чыгара башлыйлар. Аларның теләктәше Галимҗан Ибраһимов Уфада «Ирек» газетасының эшен җайга сала. Газеталар тиз арада халык арасында тарала да башлыйлар. Алар хәтта фронт окопларына кадәр барып җитә торган булалар. «Ирек» газетасы тирәсенә күпләгән солдат массалары туплана. Уфа гарнизоны мөселман комитеты әгъзалары, аның вәкилләре буларак, авылларга таралып, анда зур аңлату эшләре җәелдереп җибәрәләр.

Бу һәм башка гамәлләр бердәм социалистик партия оештыруга юл ачалар. Газеталар коллектив агитатор да, коллектив пропагандист та һәм, аннан да бигрәк, коллектив оештыручыга әвереләләр.

Ниһаять партия барлыкка да килә. «Аваз» үзенең 6 июль санында аның оештыру комитеты утырышы булып үтүе турында хәбәр итә. Татар социалист революционерлар партиясенең оештыру утырышында Уфадан Галимҗан Ибраһимов һәм Фатыйх Сәйфи, Саратовтан Сәгыйтъ Енгалычев, Мәскәүдән Мостафа Тюменев, Петроградтан Әбүзәров, Сембердән Зыя Кадермәтов, Төркестаннан З. Вагизов, Донбасстан Зәйнулла Булышев, Финляндиядән Гайсин, Чистайдан Сәмигулла Салихов һәм Казаннан Шәһит Әхмәдиев катнашалар.

Уфада Учредительный собраниегә делегатлар сайлау өчен 3 исемлек төзелә. № 3 – татар социалист-революционерлар исемлеге. Анда беренче булып Галимҗан Ибраһимов фамилиясе күрсәтелгән. Исемлеккә аннан башка Шәриф Сүнчәләй, укытучы Алишев һәм мулла Мөхетдин Мөхәммәтдинов булалар. Галимҗан Ибраһимов шушы исемлек буенча Учредительный собрание депутаты итеп сайлана.

Петроградка Учредительный собраниегә китәр алдыннан ул Уфа шәһәрендә җыелган Милли мәҗлес эшендә актив катнаша. Мәҗлес үзенең эшен 1917 елның 17 ноябрендә башлап җибәрә. Анда, нигездә, ике зур төркем барлыкка килә. Берсендә татарлар өчен милли мәдәни мохтарият дәгъвалаучылар, икенчесендә, федералистлар, яки илне федератив нигездә үзгәртеп

коруны һәм анда татарлар өчен милли дәүләтчелек булдыруны яклаучылар була.

Галимҗан Ибраһимов – ныклы федералист. Ләкин ул шул ук вакытта унитаристларның да милләт дошманы түгел икәнлекләрен яхшы аңлый. Алар кебек үк сибелеп яшәүче татарларны бер милләт рәвешендә оештыру өчен милли мохтарият кирәклегендә шикләнми. Шунлыктан Мәҗлес эчендәге ике төркемне килештерүне бурычларының берсе итеп билгели. Нәтиҗәдә тулы аңлашу барлыкка килә һәм Идел–Урал штатын төзү турында карар кабул ителә.

Мәҗлес өчен иң катлаулы мәсьәләләрнең берсе – татар-башкорт мөнәсәбәтләре була. Галимҗан Ибраһимов, аларны төптән белә торган кеше буларак, ике бертуган милләтне үзара аңлашу юлына бастыру өчен зур эш башкара. Ул башкорт һәм татарларның уртак дәүләте булырга тиешлеген алга сөрә. Төрле газета битләрендә моны дәлилләгән мәкаләләрен бастыра.

Ләкин Зәки Вәлиди җитәкчелегендәге иҗтимагый хәрәкәт башкорт автономиясен булдыру юлына ныклап баскан була. Штатны булдыру өчен башкортлар белән аңлашу, арадашлык вазифасы Галимҗан Ибраһимовка йөкләнә.

Шул ук 1917 елның декабрь аенда Оренбург шәһәрендә башкорт корылтае җыелып, Башкорт республикасы игълан ителә. Г. Ибраһимов Оренбургка барып, корылтайда тирән эчтәлекле доклад ясый һәм бик күпләрне Штатка кушылу идеясенә күндерә. Ләкин Зәки Вәлиди моңа ризалашмыйча, «татарлар яһүдләр кебек алар», дип, башкортларны Идел–Урал штатына кушылмаска өнди (2).

Ләкин ничек кенә булмасын, Г. Ибраһимов Зәки Вәлидине Мәҗлескә килеп чыгыш ясарга күндерә. З. Вәлиди чыгышында татарларны куркаклыкта гаепли, милли мохтарият һәм территориаль автономия арасында «коерык болгап йөрүчеләр» дип атый. Әмма шулай булса да ул Штатка кушылырга ризалык бирә.

Штат идеясе белән рухланган Галимҗан Ибраһимов Петроградка Учредительный собраниегә килә, һәм илдәге мөселман халыкларының дәүләтчелеген булдыру эшләренә ныклап катнаша.

1918 елның 5 гыйнварында большевиклар һәм сул эсерлар Учредительный собраниене ташлап чыгып китәләр. Галимҗан Ибраһимов та алар белән була. Бу вакыйгалардан соң ул III Бөтенроссия Советлар съездында сайланган Үзәк Башкарма комитетына Мөселман комиссариатын төзү тәкъдиме белән чыга. Милләт Эшләре Комиссариатында (Наркомнац) аның җитәкчесе И. В. Сталин белән күрешеп сөйләшә. Соңрак Учредительный собраниедә төзелгән мөселман фракциясе членнары белән очрашып, аларга Сталин һәм үзе исеменнән булачак комиссариат составына керүләрен сорап мөрәҗәгать итә. Ләкин аларның ризалыкларын ала алмый.

Шушы сөйләшүдән соң бер көн үткәч, Петроградка соңга калып Учредительный собрание членнары Мулланур Вахитов һәм Шәриф Манатов килеп җитәләр. Ибраһимов аларга да шушы тәкъдимне җиткерә. Алар аны кабул итәләр һәм бергәләп Смольныйга Сталин янына киләләр. Аның белән Совнарком каршында Мөселман комиссариаты төзергә кирәклеге турында килешәләр.

Шул ук елның 17 гыйнвары көнне бу комиссариатны төзү турындагы декрет Халык Комиссарлары Советы рәисе В. И. Ленин һәм милли эшләр буенча комиссар И. В. Сталин тарафыннан имзалана. Комиссариатның рәисе – Мулланур Вахитов, аның урынбасары итеп Галимҗан Ибраһимов билгеләнәләр. Комиссариат составына алардан башка Төньяк фронт мөселман комитеты членнары Мәхмүт Дулат-Али, Гади Кильдебәковлар кертеләләр. Г. Ибраһимов комитет урнашкан Псков шәһәренә барып, аларны һәм шушы комитетның актив җитәкчеләре Йосыф Ибраһимов, Дәүләт һәм Минһаҗ Коновларны башкалага алып килә.

Комиссариат составында 10 бүлек төзелеп, аның җир эшләре бүлеген Галимҗан Ибраһимов җитәкли. Нигездә исә ул, Комиссариат председателенең урынбасары гына түгел, аның ныклылыгын һәм бердәмлеген тәэмин итүче төп көч була.

Комиссариатта эш җиңелдән булмый. Чөнки, беренчедән, мөселман халыкларының үз араларында аңлашу һәм берләшү җитәрлек дәрәҗәдә булмый. Икенчедән, Сталин җитәкләгән Наркомнац белән эшләү кыенлашканнан-кыенлаша бара. Сталин барлык эшләрне дә үз кулына алмакчы була, Комиссариатны тулысы белән үзенә буйсындырга омтыла.

Галимҗан Ибраһимов Комиссариатның төп вазифасы итеп милли дәүләтчелекне торгызуны күзаллый. Ул иң беренче булып Татар-Башкорт республикасын төзү мәсьәләсен күтәреп чыга һәм аны Сталин алдында кабыргасы белән куя. Күренекле тарихчы Риф Хәйретдинов Галимҗан Ибраһимовны, 1918 елның 22 мартында игълан ителгән Татар-Башкорт республикасы турындагы положениенең идеясе һәм эчтәлегенең авторы булырга тиеш, дип яза (3). Документларны анализлау галимнең бу фикерен тулысы белән раслый: Татар-Башкорт республикасы турындагы Положениедә И. Сталин һәм М. Вахитов белән бергә Галимҗан Ибраһимов һәм Шәриф Манатовларның да имзалары бар (4).

29 март көнне Эчке Россия мөселманнары комиссариатының баш коллегиясе утырышында комиссариатны Татар-Башкорт комиссариаты итеп үзгәртү турында карар кабул ителә. Комиссариатка татар-башкорт мәсьәләләреннән гайре Кырым, Кавказ, Төркестан эшләре буенча комиссариатлар төзү дә йөкләнә. Билгеләнгән үзгәртүләр нигезендә шул комиссариатларның председательләре составында Мөселман комиссариатлары Советы төзү турындагы карар да кабул ителә (5).

Бу үзгәтүләргә үзәк хакимият, милли эшләр комиссариаты, бигрәк тә аның җитәкчесе Сталин риза булмыйлар. Алар дилбегәне тулысы белән үз кулларында калдырырга тырышалар. Аның эшчәнлеген тик татар-башкорт мөнәсәбәтләре белән генә чикләмәкче, татарлардан Кырым, Кавказ һәм Төркестанны аермак булалар.

Моңа ризасызлык белдереп Мулланур Вахитов, Галимҗан Ибраһимов, Йосыф Ибраһимов, Шәриф Манатов һәм тагын өч кеше шул көнне, ягъни 1918 елның 29 мартында отставкага китүләрен белдерәләр. Бу турыдагы гаризаларында мондый сүзләр бар: «В виду несогласия в вопросе о реорганизации Комиссариата и в виду не нахождения общей линии компромисса весь состав Комиссариата выходит в отставку».

Ләкин Сталин отставканы кабул итми. Гаризаның ахырына ул: «Отставку принять не согласен ни в коем случае. Прошу всех членов Комиссариата остаться на

своих местах и уладить трения совместно со мной», – дип язып куя.

Конфликтны хәл итү җиңел булмагандыр. Бездә ул турыда бернинди мәгълүмат та юк. Тик 31 март көнне генә ниндидер рәвештә аңлашу булган булса кирәк. Чөнки шушы көнне М. Вахитов, М. Алиев, Й. Ибраһимов «отставку свою беру назад» дигән сүзләр астына үз имзаларын куялар. Галимҗан Ибраһимовны күндерү җиңел булмаган булса кирәк. Ул имзасын махсус рәвештә иң соңгы кеше буларак кына куя.

Өздереп әйтеп булмый, бәлки Сталинның Татар-Башкорт республикасына эчке каршылыгы булгандыр. Аңа ризалыкны, тик тактик рәвештә, Идел–Урал штат идеясен юкка чыгару өчен генә биргәндер. Шулай уйлау өчен тулы мөмкинлек бар: республика бит тормышка ашмый кала.

22 апрель көнне Совет хөкүмәте (Ленин имзасы белән) 5 майда Мәскәүдә шушы республикага кирәргә тиешле губерна Советлары вәкилләренең киңәшмәсен үткәрү турында күрсәтмә бирә. Аның алдында булачак республиканың чикләрен һәм вәкаләтләрен билгеләү бурычын куя.

«Алтай» газетасы үзенең 25 апрель санында Татар-Башкорт республикасы турындагы Положениенең штатны тормышка ашыруга киртә икәнлеге турында ачынып яза. Газетаның махсус баш мәкаләсе Мулланур Вахитовка багышлана. Анда аңа карата шелтә, янау һәм куркыту сүзләре белдерелә.

Бу, әлбәттә, Үзәк хакимияткә дә мәгълүм була. Апрель аенда Милләтләр эшләре буенча комиссариаттан М. Вахитов һәм Г. Ибраһимов исеменә Татар-Башкорт республикасының Учредительный съездын үткәрү эшен башлап җибәрергә кирәк дигән хәбәр ирешә, Вахитов һәм Ибраһимовның Сталин янына керүләре сорала.

Сталин юкка гына М. Вахитов һәм Г. Ибраһимовны үз янына керүләрен сорамагандыр. Шушы очрашуның төп темасы итеп Татар-Башкорт республикасының Учредительный съездын чакыру эшен башлап җибәрү турында булуы да очраклы булмагандыр, дип уйларга кирәк. Шул ук вакытта моңа М. Вахитовның үзен Татар-Башкорт комиссариаты вазифаларыннан азат итүне сорап гариза язуы да сәбәп булуы ихтимал. Тик менә гариза Галимҗан Ибраһимов тәкъдиме белән кире кагыла. Мәсьәләне аңлашып хәл итү өчен 11 май көнне Ш. Манатов, М. Вахитов, Ф. Сәйфи-Казанлы, Г. Ибраһимов һәм тагын берничә кеше Ленин һәм Сталин янына керәләр. Ул очрашуда нилә булганлыгы мәгълүм түгел.

Ләкин ничек кенә булмасын, М. Вахитов урынында кала һәм Татар-Башкорт республикасын гамәлләштерү эше дәвам итә. Урыннарда киң пропаганда эше җәелдерелә. Г. Ибраһимов бу көннәрдә Уфада да, Казанда да, башка урыннарда да булырга, җыелышларда төпле чыгышлар ясарга өлгерә. Гомумән, республиканы гамәлгә ашыру юнәлешендә армый-талмый эшли.

1918 елның 30 апрелендә ул Уфада. Анда Шәриф Сүнчәләй рәислегендә үткән татар-башкорт эшчеләре җыелышында Галимҗан Ибраһимов доклад ясый. Шуның нәтиҗәсендә, Уфа эшчеләр Советы республика идеясен тулысы белән яклый, дигән резолюция кабул ителә.

Үзәк мөселман комиссариаты бинасында, Сталин рәислегендә, съездны үткәрү тәртибен тикшерүгә багышланган киңәшмә булып үтә. Монда Галимҗан Ибраһимов Уфа мөселман комиссариаты исеменнән чыгыш ясап, хезмәт ияләренең республика идеясен хуплаулары турында сөйли.

10 майда булып үткән Татар-Башкорт республикасының оештыру (учредительный) съездын чакыру киңәшмәсендә Мулланур Вахитов, Камил Якубов һәм Галимҗан Ибраһимов чыгыш ясыйлар. Шунысы игътибарга лаек, Г. Ибраһимов «штат» һәм «республика» төшенчәсен тәңгәлләштеребрәк сөйли. Күрәсең, Татар-Башкорт республикасын шул ук штат итеп күзалларга тырыша (6).

11 май көнне Үзәк мөселман комиссариатының утырышында Татар-Башкорт республикасының фондын булдыру турында карар кабул ителә. Моңа җаваплы кешеләр итеп Галимҗан Ибраһимов, Фатыйх Сәйфи, Шәриф Манатов һәм Мулланур Вахитов билгеләнәләр.

Мулланур Вахитов һәм Галимҗан Ибраһимов Татар-Башкорт республикасының булачагына ихластан ышаналар, аны киң массалар алдында пропагандалыйлар.

Галимҗан Ибраһимов Казанда 1918 елның 23–31 маенда булып үткән укытучылар съездында шушы республика турындагы докладында Ленин һәм Сталинның Татар-Башкорт республикасын яклап чыкканлыкларын бәян итә һәм республиканың тиздән барлыкка киләчәгенә ышаныч белдерә.

Июль-август айлары – гражданнар сугышының иң авыр чоры. Чехословаклар һәм акгвардиячеләр Казанга якынлашалар. Аның дошман кулына күчү куркынычы туа. Шушы шартларда Комиссариат татар һәм башкортлардан хәрби частьләр төзеп, аларны фронтка җибәрү эшләрен дә җәелдереп җибәрә. Аның каршында Үзәк мөселман хәрби комиссариаты төзелә. Ул тиз арада мөселман хәрби частьләрен төзү эшенә керешә, һәм, озакламастан, шушы эшчәнлек нәтиҗәсендә барлыкка килгән I Мөселман социалистик полкы һәм I Татар-башкорт батальоны фронтка җибәрелә.

1 август көнне Мулланур Вахитов үзе дә берничә кеше белән Мәскәүдән Казанга китә. Анда Көнчыгыш фронты командующие Вацетисның Казанны чехлардан саклау өчен тиешле чаралар күрүен таләп итә. Ләкин, ни кызганыч, шәһәрне саклап калып булмый. Шәһәрдә калган М. Вахитов аклар кулына эләгә һәм 19 августта аны атып үтерәләр.

Г. Ибраһимовны М. Вахитов һәм Казандагы социалистик оешмаларның хәле борчый. Һәм ул берничә ышанычлы кешегә, шәһәр эченә үтеп, аларның язмышын белеп кайту бурычын йөкли. Ләкин инде соң була.

М. Вахитов Казанга киткәч, Комиссариат белән җитәкчелек итү тулысы белән Г. Ибраһимов кулына күчә. М. Вахитовның үтерелүе мәгълүм булгач, аның урынына җитәкче билгеләү мәсьәләсе туа. Ул Наркомнацның 13 сентябрь көнне булып үткән утырышында махсус рәвештә карала. Мәсьәләне хәл итү өчен төзелгән махсус комиссия бу урынга Мирсәет Солтангалиевне билгеләүне тәкъдим итә. Бу кандидатура Наркомнац тарафыннан раслана. Галимҗан Ибраһимовка һәм Мирсәет Солтангалиевкә комиссариатның киләчәктәге сәясәт юнәлешен билгеләү вазифасы йөкләнә (7).

Билгеле ки, РКП(б) Үзәк комитетының Политбюросы Татар-Башкорт республикасын булдырмау һәм аны барлыкка китерү өчен пропаганда алып баруны тыю турындагы карар кабул итә. Моңа төрле сәбәпләр

күрсәтелә. Ләкин, минемчә, Үзәк хакимият аның тормышка ашырылуын теләмәгән, аны тик Гражданнар сугышы елларында татар-башкорт хезмәт ияләрен үз якларына аудару өчен корал итеп кенә кулланган.

Тик менә ничек кенә булмасын, Галимҗан Ибраһимовның Татар-Башкорт республикасын тормышка ашыру өчен көрәше эзсез югалмый. Ул Татарстан республикасын булдыруга юл ача.

Бу вакыйгалардан соң әдип тулысы белән барлык көчен 1920 елның 27 маенда игълан ителгән Татарстан республикасын аякка бастыруга юнәлтә. Һәм үзенең ахыргы сәгатьләренә кадәр халкына турылыклы булып кала.

ӘДӘБИЯТ

1. ЦГА РФ, ф. ДПОО, д. 77, тт. 3, б. 20–21.
2. Тормыш. – 1917. – 19 ноябрь
3. Хайрутдинов Р. Г. Трудное возрождение. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1992. – С. 112.
4. ЦГА ИПД, ф. 36, д. 262, л. 97.
5. ЦГА ИПД, ф. 36, д. 262, 247.
6. Образование Татарской АССР. Сборник документов и материалов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1958. – С. 58.
7. ЦГА ИПД. Ф. 36, оп. 1, д. 262, л. 105–106.

# Г. ИБРАҺИМОВ МИРАСЫНДА ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

***Т. Н. Галиуллин (Казан)***

Статья посвящена рассмотрению литературной критики в наследии Г. Ибрагимова. На примере отдельных статей выявляются основные принципы и приемы анализа произведений критиком, литературные взаимосвязи начала XX века.

Язучының тууына 120 ел тулуга багышланган әтрафлы, тирән эчтәлекле халыкара фәнни-гамәли конференция әле генә булгандай тоелса да, шул арада биш ел узган да киткән икән. Анда ясалган чыгышларны туплаган җыентык фәнни концепциясененең ачыклыгы, методологик яңачалыгы белән, Г. Ибраһимов иҗатын өйрәнүдә җитди алга китеш булуы өстенә, мәгариф йортларында, уку-укыту эшендә җитди чыганак дәрәҗәсендә йөри. Әдипнең киң кырлы, күп яклы иҗаты төрле буын галимнәре тарафыннан аркылыгабуйга тикшерелгән, тыныш билгеләре куелган шикелле күренсә дә, мирасын янәдән күздән кичерә башлагач, өйрәнүне, игътибарны таләп итеп, сорап торган өлкәләрнең, мәсьәләләрнең бездән соң киләчәк галимнәргә дә калачагына ышанасың.

Үткән конференциядә ясаган чыгышымда мин Г. Ибраһимовның әдәбият белеме, нәзарәсе мәсьәләләренә багышланган хезмәтләрен үзәккә алган булсам, ошбу нотыгымда игьтибарны аның турыдан-туры әдәби тәнкыйтькә караган мәкаләләренә юнәлттем. Әдәбият белеменең өч өлеше – тарихы, теориясе, тәнкыйте – бер-берсе белән тыгыз бәйләнгән булсалар да, һәркайсының кабатланмас үзенчәлеге, әдәби киштәдә үз урыны бар. Бу мәүзугъка тукталуга бер вакыйга өстәмә этәргеч бирде: 2011 елның декабрь ахырында «Казан утлары» журналынын редколлегия утырышында тәнкыйтьнең артта калуы, бигрәк тә яңа чыккан әсәрләр эзеннән барган, яхшыны начардан , урта кул китапны вакыйга булырдайдан аерып биргән күзәтү-рецензияләрнең аз язылуы, булганнарының да томанлы атамалар артына яшеренеп, анык бәяне бирмәве турында җитди бәхәс купты. Чыннан да тәнкыйть мәкаләсе нинди максат белән языла һәм ул фәнни тикшеренүдән кайсы ягы белән аерылып торырга тиеш? Бу сөальгә җавап эзләп, без һәр өлкәдә киңәшен бирергә әзер Тукаебыз мирасына, аерым алганда аның «Тәнкыйть – кирәкле шәйдер» дигән, 1907 елда ук язылган мәкаләсенә мөрәҗәгать итәбез. «Кеше бер әсәрне болай өстән генә укып чыккан вакытта, – дип яза шагыйрь, – шул әсәрнең иң яхшы вә мәгънәле сатырлары *(юллары)* вә биһүдә *(мәгънәсез, буш)* сатырларыны тәфрикъ *(аера)* итә алмыйдыр. Әгәр уртадан бер мөнтәкыйд *(тәнкыйтьче )* чыгып, шул ук әсәрне иләктән сөзеп чыгарып, яхшысын бер якка, яманын бер якка аерып бирсә ... гүзәл улыр иде». Тәнкыйтькә таләпләрне моннан да ачыграк итеп куюны күз алдына китерүе дә мөмкин түгелдер .

Татар тәнкыйте, мөстәкыйль жанр буларак, XX гасыр башында гына аякка басса да, аның аерым өлгеләре, күзәнәкләре әдәби әсәрләр тукымасында ук бөреләнә. Аерым алганда , хаҗнамәләрдә, сәяхәтнамәләрдә, Габдеррахим Утыз Имәни, Акмулла һ. б. шагыйрьләрнең мирасында, Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Р.Фәхретдин кебек галимнәрнең фәнни, фәлсәфи, тарихи хезмәтләрендә киләчәктә тәнкыйть таянырдай зәмин-җирлек әзерләнә. XX йөз башында Г. Тукай, Г. Исхакый, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, К. Бәкер һ. б. бу жанрны мөстәкыйль юнәлеш, үз объектын һәм шәкли алымнары булган тармак дәрәҗәсенә күтәрәләр.

Татар җәмгыятьчелеген ошбу фәнни мәҗлескә җыйган шәхесебез әдәби тәнкыйтькә прозада үзен сынап, сәләтен күрсәтеп, «Борынгы ислам мәдәнияте» (1909) кебек фәнни-тарихи хезмәтен язганнан соң килә. Атаклы «Галия» мәдрәсәсендә төпле белем алган егет тәүге тәнкыйди мәкаләләрендә үк зәвыклы, әдәби канУннарны, жанр хасиятләрен сиземли торган әзерлекле белгеч буларак танылa. Г. Ибраһимовның әдәби тәнкыйтькә караган мирасы өч чорга бүлеп өйрәнүне «сорап» тора : 1910–1913, 1914–1917, 1918–1935 еллар. Әдәби тәнкыйть жанрының иң кырыс таләпләренә җавап биргән мәкаләләрен ул 1910–1913 елларда иҗат итә. Бу чорда ул иң абруйлы исемнәр, әсәрләр турында тулаем дөрес, объектив бәясен бирә, кимчелекләрне дә курыкмыйча, туры бәреп әйтә. Шуннан соңгы елларда , төрле субъектив сәбәпләр аркасында, Г. Ибраһимов Тукай иҗатына мөнәсәбәтен, Исхакый әсәрләренә бәясен кискен үзгәртә, җитди хаталар җибәрә. 1918 елдан соңгы язмаларында сәяси берьяклылык өстенлек итә, җитди тәнкыйтьне публицистика, гомуми сүзләр кысрыклый. Соңгы чор иҗатында жанр таләпләренә

тулы җавап биргән мәкаләсе юк, дисәк тә, зур хата булмастыр. Бу чорда ул күбрәк сәнгать, тел, әдәбият һәм тарихка караган фәнни-теоретик хезмәтләр яза, дәреслекләр, программалар төзи, дәүләт, җәмәгать эшләре башкара, әдәби әсәрләр иҗат итә.

Үз чорының талантлы шәхесләрен уртакул һөнәрчеләрдән аера белүе иң беренче тәнкыйди язмасыннан – «Татар матбугаты» (1910) мәкаләсеннән үк күренә. «Хасил: татар шигыре мәйданында Тукаев исә, тасвирымыз мәйданында иң гали ноктада Гаяз әфәндедер.

Аның әсәрләре укырга күңелле, сабак та бирә, алдыңа татар мәгыйшәтенең төрле-төрле җанлы ләүхәләрен *(күренешләрен)* дә китерә».

Әдәби тәнкыйтьнең иң кырыс таләпләренә җавап биргән «Яңа әсәрләр» (1911) мәкаләсе Тукайның «Күңел җимешләре» мәҗмугасы басылып чыгу уңаеннан языла. Иң әүвәл автор шагыйрь иҗатына гомуми бәясен бирә: «Ул мәйданга чыкканнан бирле кайгыра да, елый да, көлә дә, сүгә дә». Аннан соң инде Габди тәхәллүсле тәнкыйтьче ошбу җыентыкка кергән шигырьләрнең яңачалыгын эзли башлый: «... үз хасиятен әүвәлгеләрдән артык тулырак, киңрәк һәм ачыгырак җиткезә», чагыштырулары да шигъри һәм җанлы хасиятләргә байый бара. Тукайның үзе шикелле таләпчән һәм төртмә телле Г. Ибраһимов бал мичкәсенә бер кашык дегет тамызмыйча каламы соң? «Тел хакында исә бик мактап булмый, – ди тәнкыйтьче. – Гарәп, фарсы сүзләреннән, чит тәгъбирләрдән арчылуы матлуб *(тиеш)* иде». Дөрес, Тукайны алынма сүзләр белән мавыгуы өчен чеметеп китсә дә, ике битлек «Яңа әсәрләр»ендә автор үзе дә хәзерге әдәби телебезгә тәрҗемә таләп иткән егерме алынма куллана. Хәлбуки, ул шунда ук лөгатебезнең гаҗәеп нечкә хистойгыларны чагылдырырдай байлыгына, кодрәтенә үрнәк мисал итеп, Тукайның «Өзелгән өмид» шигыреннән моңлы саз белән сүнеп барган гомер арасындагы якынлыкны ачкан экзистенциаль сагышлы юлларын китерә.

«И мөкаддәс моңлы сазым! Уйнадың син ник бик аз?
Син сынасың, мин сүнәмен, аерылабыз ахрысы!»

Тукайның «Мияубикә» (1911) җыентыгын үзәккә алган шул ук исемдәге мәкаләсендә Г. Ибраһимов төп дикъкатен тел хасиятләренә юнәлтә. «Җиңел, ачык, чат татарча һәм аңлаешлы язылган бу әсәрнең бөтен фазыйләте *(матурлыгы)* телендә, тик телендә генәдер (берничә гарәби сүзне исәп белән санамаганда). Аның теле шагыйребезнең "Җуаныч" вә "Балалар күңеле"н искә төшерә – матур, уңай һәм үземезчә генә ... Ана телемезне гамәли белүләре ала-чола булган кайбер язучыларымыз Тукай җыентыкларына күз салсалар, байтак өлге алырлыктыр». Г. Ибраһимовның әсәрләрнең теленә ифрат игътибарлы булуы, еш кына сүзне шуннан башлавы ул чорда телебезнең киләчәге турында барган бәхәсләр, кискен фикер алышулар белән дә аңлатыла. Татар әдәби теле нинди юнәлештә үсеп китәр – халыкның сөйләм теленә, Тукайның саф ана лөгатендә язылган шигырьләренә өстенлек бирелерме, яисә катлаулы, чуар , аңлаешсыз, югары өслүб җиңеп чыгармы кебек альтернатива, халкыбызның киләчәк язмышы турында уйлану кебек үк мөһим иде. Г. Ибраһимов халык сөйләм теле, җитлеккән Тукай өслүбе җиңүе өчен көрәштә һәрдаим алдынгы сафта булды.

«Мияубикә» мәкаләсендә тәнкыйтьче,ноширләрне әтәч, сунарчы, песиләр турындагы арзанлы әсәрләр белән мавыгулары өчен «әрләгәннән» соң, Тукайга җитди дәгъвасын белдерә. «Китапның азагында "Русчадан алынып, шигырьгә әйләндерелде", – диелгән. Бу – ялгыш. Безгә шигырь белән нәзымны *(шигырь белән язылган хикәя)* аера белергә күптән вакыт», – дип, үз фикеренең дөреслегенә шикләнмәгән кеше кебек, гомуми дидактик нәтиҗәсен дә ясап куя.

Үзен шигырь белән нәзымны аера белмәүдә , табигать биргән һәнәренең нигезенә кизәнгән, шик белдергән гаепләүне Тукай җавапсыз калдырамы соң? «Габди» мәкаләсе басылган «Йолдыз» газетасында ул (1911, 30 июнь) «Аз гына төзәтү» дигән аңлатмасын бирә. «Минемчә, соңгы җөмләдән мөхтәрәм укучылар "Мияубикә"не язучы нәзым белән шигырьне саташтыра икән, дигән фикергә заһиб булу *(китү)* ихтималлары бар. Шуның өчен изах итәмен ки *(аңлатып бирәм),* "Мияубикә"не шагыйрь саф поэзия, чын шигырьгә әйләндердем, дип ышанганга күрә, "шигырьгә әйләндерелде" дип куйган.

Габдинең югарыдагы сүзләре ... ялгыз бер интисадчының *(тәнкыйтьченең)* фикере генә дип тәлкыйн ителсен *(кабул ителсен)* ...»

Тулаем алганда Г. Ибраһимов тәнкыйди фикерен җәмәгатьчелек игътибарына лаеклы, киләчәге өметле әсәрләргә һәм исемнәргә генә юнәлтергә тырыша. Шуларның берсе – Ф. Әмирхан һәм аның «Хәят» повесте белән «Урталыкта» романы. Бичара татар хатыннары (Ф. Әмирханның «Татар кызы», үзенең «Татар хатыны ниләр күрми» (1909) әсәрләренә киная), «татар ишаны вә татар хәлфәсенең тәмсез вә кызганыч тормышын укый-укый косасын китерерлек мәртәбәгә җителгән» бер заманда "Хәят"нең килеп чыгуы «бик урынлы булып китте», – дип, мәкалә авторы, әсәрнең яңачалыгын хуплавында эпитетларны кызганмый. «Җиңел вә җитез кулдан, җиңел вә оста каләм белән язылган бу хикәяне мин әдәбият мәйданына чыккан яңа бер хадисә *(вакыйга)* итеп карыйм».

«Хәят»нең хисси дөньяны уятып җибәрә торган, иң тәэсирле өлешләре итеп, Рокыяның дөм караңгы, шомлы төндә экзистенциаль сагыш белән елавын һәм Борһанның, ястү намазын укыганда, үзен күкләр илә кушылгандай экстазга бирелүен саный.

Әсәрнең уңай якларына тукталганнан соң, «Хәят»нең «каләм осталыгы белән язылмаган» җитешсезлекләрен дә күреп ала. «Шулар илә, – дип яза күзәтү авторы, – әсәрнең сай чыккан җирләре дә күп. Аның картиналары бөтен хәяты илә тулып, җанланып күз алдына килми». Ә инде әсәрдә чыгарылган типларның табигый эшләнеп чыгу-чыкмавын дәвамы басылгач ачыкларбыз, дип вәгъдә бирә автор. Кызганычка каршы, диимме инде, «Хәят»нең икенче кисәге безгә мәгълүм түгел. Ф. Әмирхан үз каһарманнары тормышының дәвамын күз алдына китерә алмаганмы, әллә күңелен биләгән матур, садә яшьләрне картайтасы килмәгәнме, хәзер җавапчылыкны өстеңә алып, кистереп әйтүе кыен.

«Хәят» әсәре Г. Ибраһимовны шул чор сүз осталарын һәм җәмәгатьчелекне борчыган нәзари уйланулар юлына алып чыга. Берсе – табигыйлек (реальлек) белән сәнгатьчелек арасындагы ярашу булса, икенчесе – миллилекне ничек аңлау, аның эчтәлеген күзаллау. Әдәби әсәрләрендә романтик юнәлеш тарафдары булса да, «Хәят»тә сәнгатьлелекнең табигыйлектән өстенрәк

торуын тәнкыйтьче хупламый. Аның уенча, язучының «сәнгать вә каләм йөртергә» осталыгы табигый барышны күмеп киткән булып чыга. Г. Халит, И. Нуруллин, Д. Заһидуллина, Н. Вәлиев, В. Әминева кебек төрле буын татар галимнәре «Хәят»не нәкъ сәнгатьчә камиллеге өчен югары бәялиләр, И. Тургеневның «Первая любовь» , «Ася» кебек классик бәяннары белән бер рәткә куялар. Миллилек, татарлык мәсьәләләрендә дә ул Ф. Әмирхан белән бәхәскә керә. «Әсәргә "милли хикәя" диелгән. Мин моның яңлышлыгы хакында кул кисеп бәхәсләшә алам, – ди рецензия авторы. – Әсәр милли дип аталыр өчен татар телендә язылуы, каһарманнар татар булу гына җитми, бәлки аның мәркәзендә *(үзәгендә)* татарлык аңкып торырга, каһарманнар татар рухы илә мөкәммәл рәвештә сугарылган булырга кирәк». Шул таләпләреннән чыгып автор: «"Рәхимевләр" ("Хәят"тә Гыймадовлар) гаиләсендә татар рухы эзләү габәс *(буш)* булган кеби, Борһан абый гаиләсендә дә татарлык ягы аз ялтырый...», ди. Миллилекнең эчтәлеге, чагылыш үзенчәлекләре турында Г. Ибраһимов белән килешмәскә, бәхәсләшергә мөмкиндер. Әмма аның таләпне югары куюы сокландырмый калдыра алмый. Ул алдагы елларда да Ф. Әмирханның иҗади адымнарын һәр даим күз уңында тота һәм, «Урталыкта» әсәре басылып чыгуга, «Зур романнар» исемле мәкалә белән чыга. Бу күзәтүендә Г. Ибраһимов янә бер нәзари мәсьәләне калкытып куя. Аның фикеренчә, һәр әсәрдә, бигрәк тә каһарманның рухи дөньясын, үз урынын эзләп бәргәләнүләрен, тирәлек белән мөнәсәбәтен ачуда психологик анализ алымнары бай һәм төрле булырга тиеш. Ул бу таләбенә Кәбир Бәкернең «Җанлы курчаклар», Р. Фәхретдиннең «Асар», Т. Шевченко иҗатына һәм тормышына багышланган «Каһарман шагыйрь», хәтта М. Гафуриның яңа китабы белән таныштырган соңгы мәкаләләренең берсе – «Карт шагыйрьнең яхшы сайланмасы» (1933) мәкаләсендә дә шул принципларына туры калырга тырыша, бәяләү бизмәнен югары кимәлдә тота. Кызганычка каршы, аның шул чорда ат уйнаткан язучыларга шәхси мөнәсәбәтендә субьектив башлангыч, амбиция белән бәйле берьяклылык елданел көчәя бара. Г. Ибраһимов холкының бу сыйфатына заманында күренекле тәнкыйтьче Фәрваз Миңнуллин да игътибар иткән иде. «"Яшь йөрәкләр" романындагы Җәләш мулла кебек, Галимҗан Ибраһимов үзе дә һәр эштә, һәр җирдә беренче булырга омтылып яши. Ибраһимов язмышы – узаманнар язмышы. Аның бөтен тормыш һәм иҗат юлы шул хакта сөйли». Үзе язучы, тәнкыйтьче, галим буларак күтәрелә, танала барган саен, яшьлек кумирлары, элегрәк табынган сүз осталары, аерым алганда, Тукай белән Исхакый иҗатларына мөнәсәбәте кискен рәвештә үзгәрә. Г. Ибраһимовның «Татар шагыйрьләре» китабында, Тукай иҗатын кимсетү исәбенә, Дәрдемәнд белән С. Рәмиевне күтәреберәк куюын җәмәгатьчелек кабул итмәсә дә, күрелмәгән бер үҗәтлек белән тәнкыйтьче үз фикерендә тора. Укучыларның хатларына аңлатма буларак язылган «Өч җавап» (1923) мәкаләсендә ул болай ди: «Мин рәхимсез тәнкыйть тарафдары һәм шундый тәнкыйтьләрнең файдасына ышанган кешеләрнең берсе». (Мәгәр үз адресына әйтелгән бер тәнкыйтьне дә кабул итми.) «Минем белән килешмәүчеләр, "Тукай "шагыйрьме, түгелме?" дигән мәсьәләдә" бу хактагы фикерне кыл кадәрле үзгәртерлек материал таба алмадылар».

Г. Ибраһимовның Тукай иҗатына биргән ялгыш карашын, бәясен кире каккан чыгышлар матбугатта да күп басыла. «Галимҗан Ибраһимов ... Тукаевны да аңар халык тарафыннан бирелгән "халык шагыйрь"леге урыныннан сөрмәкче булып зур гайрәт күрсәткән иде, – дип яза А. Бикташев, – ләкин укучы халык Тукаевның Тукаевлылыгына шулкадәр ышанганнар ки, бер мәртәбә йөзләрен җыердылар да һичбер тәэсирләнми һаман шул иске фикердә калдылар. Тукаев – шагыйрь» («Тәнкыйть тирәсендә»).

Г. Исхакый шәхесенә һәм иҗатына мөнәсәбәтендә дә Г. Ибраһимов берничә чор кичерә: әүвәл соклану, күкләргә чөю... «Әдәбият мәйданында хәзер иң шәүкәт илә иң бөек урында карт реалист Гаяз әфәнде тора. Без аның хикәяләре кадәр реальный бер әсәргә матбугатыбызда очрый алганыбыз юк әле» («Татар матбугаты», 1910).

«Милли матбугатыбыз» (1911) мәкаләсендә Г. Исхакыйның М. Горький белән хат аша аралашып, «Знание» нәшриятендә «Өч хатын берлән тормыш», «Алдымбирдем» әсәрләренең рус телендә басылып чыгуын олы вакыйга дип бәяли. «"Әдәбият агышы"нда (1911) Гаяз әфәнде Исхаковның барлык әсәрләре эчендә иң мөһим вә иң кадерле булганы, һичшөбһәсез, " Ике йөз елдан соң инкыйраз"дыр». Бу повестьның «сихер вә илһам белән язылганлыгы»н, «мәүзыгысы белә дә, сәнгать әдәбиясе белә дә мөхәррирнең башка әсәрләреннән чагыштырмас мәртәбәдә югары» дигән нәтиҗәгә килә. Шул мәдхияви нотыгыннан соң, тәнкыйтьче укучысын «ачы дару» йотарга әзерли башлый. Ошбу әсәреннән соң «әдипнең куәте ахырысы тәкмил *(тәмам)* итеп була». Соңрак язылган әсәрләрендә «табигый агымлы хыял, фикер назиклеге кебек хасиятләр аны ташлый башлады».

Исхакый иҗаты өстендә кылыч уйнатып алулар «"Мөгаллимә"нең Уфада уйнау мөнәсәбәте белән» (1915) мәкаләсеннән башлана. Сәхнә әсәрен тикшерүгә керешкәнче гомуми бәя килә. «"Теләнче кызы", "Солдат", "Зиндан" кебек әсәрләрендә ... элеккечә җәдит вә кадимнең нисбәтенең эзе дә юк... Борынгы җәдит вә кадимнең урынын боларга бер дә аслан мөнәсәбәте булмаган ике сыйныф – байлар вә ярлылар көрәше ала». Кыскасы, Г. Ибраһимов Исхакыйны элеккеге демократик һәм җәдиди ышанычыннан читләшеп, вак-төяк мәүзугълар тирәсендә әйләнүдә, характерларны ачып бетерә алмауда гаепли. «Мөгаллимә» пьесасы да уңай бәягә лаек булмый: «"Фатыйма" трагедиясе... татар мөгаллимәсенең типичный трагедиясе түгел». Замана тәнкыйте Г. Ибраһимов белән килешми. Шул ук А. Бикташев мондый фикергә килә: «Гаяз әфәнденең әдәби кыйммәтен белер өчен, аның берлә халыкны таныштырыр өчен битараф, чын тәнкыйтьчеләр кирәк. Минемчә, бу урынны Галимҗан Ибраһимов тота алмый».

Берничә ел элек кенә татар әдәбияты күген бизәгән ике йолдызны – Тукай белән Исхакыйны илаһи биеклеккә күтәреп куйган гаярь тәнкыйтьченең кыйбласы, табынып яшәгән шәхесләргә мөнәсәбәте кискен үзгәреп кую әдәбият галимнәре өчен хәзергәчә табышмак, каты тышлы чикләвек булып кала бирә. Тукай инде гүр иясе, аның мирасы шул ук, күз алдында. Исхакый да тәүге әсәрләреннән кайтышрак язмый кебек. Бәяләр үзгәрүне Г. Ибраһимовның үзен олы талант итеп танып, ошбу затларны артыгырак мактап, кирәгеннән артык күтәреп, үзем күләгәдә калам, дип

тәүбәгә килүеме, әллә Тукайның хатларында (мәсәлән С. Рәмиевкә) җибәргәләгән ачы теле ярсыттымы, Исхакыйның Г. Ибраһимов иҗаты турында ләм-мим сүз катмавы, күрмәмешкә салышуы нәтиҗәсендә килеп чыктымы, әллә ул үзен 1917 ел борылышыннан соңгы сәяси үзгәрешкә эчке сиземләве белән әзерли башладымы, дигәнрәк уйлар да килә башка.

1917 ел инкыйлабы алып килгән сәясәт бик күп иҗат әһелләрен, шул исәптән Г. Ибраһимов тәнкыйтен дә, капма-каршы чорларга бүлде дә куйды. Аерым алганда, коммунистлар шигарьләренә ышанган Г. Ибраһимов белән мөһаҗирлек язмышын сайларга мәҗбүр булган Г. Исхакый арасындагы элеккеге милли якынлыкны алып ташлаган тирән упкын хасил була. «Кара маяклар һәм ак әдәбиятлар» (Мәскәү, 1924. – 70 б.) һ. б. мәкаләләрендә Г. Ибраһимовның Г. Исхакый иҗатына, аның совет хакимиятен кабул итмәгән эшчәнлегенә мөнәсәбәте тискәре һәм хәтта агрессив төс ала. Бу хакта шулай ук мөһаҗир галим , тарихчы Габделбари Баттал болай дип яза: «Г. Ибраһимов казанлы Гаяз Исхакый Иделленең Русия тышында бастырган әсәрләрен кулына алып, аларда алга сөрелгән аерым фикер һәм проблемаларны “марксизм күзлегеннән карап” бозарга тырыша» («Миражга алданган язучы», 1975).

Г. Ибраһимовның коммунистлар сәясәтенә табынган чорда язылган әдәбият белеменә, тәнкыйтькә кагылышлы мәкаләләрендә әдәби барышны социологик һәм сыйнфый көрәш яссылыгыннан килеп бәяләү өстенлек итә. Элеккеге кайнар хисне, романтик ялкынны, яшьлек темпераментын як-якка каранып әйтелгән гомуми сүзләр ташкыны, акыл-киңәш бирү алыштыра. Аның бу чорда язылган озын мәкаләләрен («Дүртенче елга кергәндә», 1920; «Пролетариат әдәбияты турында», 1924 һ. б.) укыганда эчке ышаныч пружинасы какшагандай хис кала.

Шул ук вакытта совет чоры язмаларында да ул югары зәвыклы, укымышлы, эрудицияле каләм остасы булып кала, буш һәм талантсыз әсәрләрне мактау дәрәҗәсенә төшмәскә тырыша, вак-төяк тирәсендә фәлсәфә сатуга, телне бозуларга каршы чыга, сүз сәнгатенең мөһим жанры булган әдәби тәнкыйть, аның асылы һәм үзенчәлекләре, талант һәм иҗат процессы, яңа китаплар турында игътибарга лаеклы фикерләр әйтеп калдыра.

Нәтиҗә урынына шуны искәртәсе килә: киң карашлы, күпьяклы талант иясе буларак Г. Ибраһимов әдәби тәнкыйть үсешенә бәяләп бетергесез зур өлеш керткән шәхес. Аның Г. Тукай, Ф. Әмирхан, М. Гафури, Дәрдемәнд, С. Рәмиев, Ф. Бурнаш һ. б. асыл затларыбыз иҗатын, яңа басмаларны тикшергән, бәяләгән мәкаләләре бүген дә яңачалыкларын югалтмыйлар, яңа чор тәнкыйтьчеләре өчен үрнәк-өлге булып калалар.

ӘДӘБИЯТ


1. Ибраһимов Галимҗан. Әсәрләр: сигез томда. V т.: Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр ( 1910–1933). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – 615 б.

2. Исхакый Гаяз. Әсәрләр: унбиш томда. VI т.: Публицистика һәм әдәби тәнкыйть мәкаләләре (1902–1914). – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 447 б.

3. Галимҗан Ибраһимов һәм XXI гасыр: Тууына 120 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. – Казан, 2007. – 331 б.

4. Миңнуллин Фарваз. Узаман (Галимҗан Ибраһимов) // Балта явызлар кулында... – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. – Б. 301–311.

5. Хәсәнов М. Х. Г. Ибраһимов – тәнкыйтьче һәм әдәбият галиме // Ибраһимов Галимҗан. Әсәрләр: сигез томда. V т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – Б. 531–543.

6. Баттал Г. Миражга алданган язучы // Галимҗан Ибраһимов: Мәкаләләр, истәлек-хатирәләр. – Казан. Татар. кит. нәшр., 2007. – Б. 446–457.


## ГАЛИМДЖАН ИБРАГИМОВ И АЗЕРБАЙДЖАН


***В. М. Арзуманлы (Баку)***


По мнению исследователей истории татарской литературы, плеяду зачинателей татарской литературы XX века по праву открывает Галимджан Ибрагимов (1887–1938), занимающий видное место в истории литератур всех тюркских народов.

Основатель татарской литературы начала XX века Г. Ибрагимов был большим ученым-историком, литературоведом, критиком, общественным деятелем.

Галимджан Ибрагимов считается самым видным представителем татарской литературы и общественно-политической мысли Нового периода (1887–1938). Он известен как классик татарской литературы, учёный-энциклопедист, выдающийся государственный и общественный деятель, Герой Труда. Г. Ибрагимов является основателем татарского языка, литературы и науки XX века. Особые заслуги принадлежат ему в области татарской литературно-критической мысли Татарстана XX века.

Татарский народ высоко ценит его творчество и научно-общественную деятельность. В разные годы неоднократно издавались его художественные произведения и научные труды. Начиная с 1957 года торжественно отмечались юбилеи Г. Ибрагимова.

С 1967 года Институт языка, литературы, и искусства Академии наук Республики Татарстан носит имя Галимджана Ибрагимова.

Примечательно, что в этом году торжественно отмечается 125-летие со дня рождения Г. Ибрагимова.

Творчество крупнейшего деятеля литературы и культуры Г. Ибрагимова, его разносторонняя научно-просветительская деятельность завоевали широкую популярность не только у татарского народа, но и у азербайджанского народа.

Не случайно, что народный писатель Азербайджана Мехти Гусейн писал о нём следующее: «Его рассказы, повести и романы имели очень большой успех среди широких читательских масс во всей нашей республике. Многие даже считали, что он родной азербайджанский писатель. В мои юные годы, когда только-только начинал писать свои рассказы, я с восторгом перечитывал

Г. Ибрагимова» (Гусейн М. Родина Низами // Советская Татария. – 1964. – 29 мая.)

А известный классик азербайджанской поэзии Самед Вургун, восхищаясь творчеством выдающегося татарского деятеля, говорил: «Ваш Галимджан – великий писатель не только татарского, но всех восточных народов» («Социалистик Татарстан», 1966, 16 мая.)

В истории азербайджанской и татарской литературно-культурной и научной взаимосвязи жизнь Г. Ибрагимова занимает особое место.

Эти связи можно рассматривать в следующих аспектах:

«Галимджан Ибрагимов и Юсиф Везир Чеменземенли»;

«Участие Г. Ибрагимова в 1926 году на I Тюркологическом съезде города Баку»;

«Художественные произведения Г. Ибрагимова на азербайджанском языке»;

«Типологическое сходство между прозой Г. Ибрагимова и азербайджанской прозой 20–30-х годов XX века»;

«Азербайджанские писатели о Г. Ибрагимове»;

«Г. Ибрагимов о классической азербайджанской литературе»;

«Г. Ибрагимов о Наримане Нариманове»;

«Азербайджанское литературоведение о Г. Ибрагимове».

Дружественные и культурные нити, связывающие Г. Ибрагимова с Азербайджаном, довольно широки и разнообразны. Ещё в годы молодости Г. Ибрагимов интересовался деятельностью Мусульманского студенческого общества Киевского университета, которое в своё время возглавлял известный азербайджанский писатель Юсиф Везир Чеменземенли. Являясь участником съезда мусульманских студентов в Киеве, он познакомился с Ю. В. Чеменземенли, и с того дня они стали близкими друзьями и соратниками. Благодаря этой дружбе Г. Ибрагимов имел возможность близко познакомиться с творчеством видных классиков азербайджанской литературы: Низами Гянджеви, Мухаммеда Физули, Мирзы Фатали Ахундзаде.

Вот что пишет Г. Ибрагимов в 1913 году в письме, адресованном Фатиху Каримли, о классике азербайджанской литературы Мухаммеде Физули: «Литература, в которой есть Физули, для нас, татар, имеет много поучительного, она может явиться исключительным примером, образцом, даже сокровищем».

В последующие годы в Москве Г. Ибрагимов познакомился с видным писателем, драматургом и общественным деятелем Нариманом Наримановым. В 1925 году Г. Ибрагимов написал две статьи о Нариманове. Эти статьи в те годы были напечатаны на страницах газеты «Кызыл Татарстан» (25 февраля 1925 года) и в журнале «Бизим йол» (1925 году, №4).

В 1926 году на I Тюркологическом съезде в городе Баку делегацию Татарстана возглавлял Г.Ибрагимов. Он активно участвовал в работе съезда.

Кроме активных выступлений на разных заседаниях на съезде он выступил и с отдельным докладом.

I Тюркологический съезд 1926 года в столице Азербайджана Баку был выдающимся событием для тюркских народов, он привлёк внимание многих народов и государств мира к тюркским языкам и их носителям.

Главным на I Тюркологическом съезде, как известно, было обсуждение вопросов: 1) письменности, 2) терминологии.

Г. Ибрагимов остался доволен результатами I Тюркологического съезда. Вот что он говорил по этому поводу: «Наш съезд дал результаты, дал то, чего мы ждали.

Поэтому я надеюсь, что выражу общее ваше настроение, если скажу от имени тех тюркских местных работников, которые приехали сюда, и выражу благодарность тем учреждениям и отдельным работникам, которые работали над созданием созыва этого Съезда. Первым долгом над созданием этого съезда работал азербайджанский народ, Азербайджанская Республика в лице её известных руководителей. Товарищи, разрешите от вашего имени благодарить как азербайджанский народ, так и Республику и их руководителей за созыв этого Съезда.

Ныне три тюркские республики (из бывших союзных республик) вернулись к латинизированному письму. Это суверенные государства: Азербайджан, Туркмения, Узбекистан.

Татарстан в составе России борется за возвращение к латинской письменности. Хотя в этом вопросе существуют некоторые трудности, но я уверен, что вы, дорогие татарские коллеги, с помощью дальновидных деятелей вашей республики, сможете осуществить эту проблему.

В этом деле желаю Вам удачи».

На шестом заседании съезда в своем докладе на тему «Об орфографии тюркских языков» отметил, что доклад распадается на 3 части. Первая часть включает критический анализ тех старых систем орфографии, которые существовали до 2-й половины XIX в., анализ уйгурской, орхонской и староарабской орфографии. Во второй части описывается движение: башкирское, узбекское, крымское и т. д. Главное внимание этих движений было обращено на то, чтобы установить, сколько гласных звуков в том или другом наречии, какими буквами их надо изображать, потому что в арабской орфографии из 10-ти гласных изображается только три. Потом, как быть с арабскими словами, которые употребляются много, и пишутся они не татарским, узбекским, казанским правописанием, а чисто арабским, и, таким образом, создаются три орфографии в одном языке: тюркская, арабская, а иногда и персидская. Движение это было также направлено на ликвидацию исключений. В третьей части доклада заключаются те конкретные предложения, которые могут до некоторой степени облегчить, а также покончить с тем разнобоем, разногласием, которое существует между тюркскими народами. И предлагается для уточнения тюркской орфографии принимать во внимание следующие особенности тюркских языков (Первый Всесоюзный тюркологический съезд. 26 февраля – 5 марта 1926 года (Стенографический отчет) Баку – АССР, 1926. стр. 168).

Татарские деятели выступали против латиницы даже в ходе работы Первого тюркского съезда в Баку. Так, Галимджан Шараф на съезде говорил, что если придётся отказаться от арабского письма, то принятие русского шрифта будет лучше. Галимджан Ибрагимов так же настаивал на том, что лучше сразу перейти к кириллице.

Выступление и доклад Г. Ибрагимова на I Тюркологическом съезде в то время были опубликованы на страницах азербайджанской печати (газеты: «Коммунист» и «Ени фикир»).

В 1927 и 1936 годах отдельные рассказы, повести и романы Г. Ибрагимова были переведены на азербайджанский язык и были изданы в виде отдельных книг: «Адамлар» («Люди», Баку 1927), «Годжалыг гюнлериндя» («В дни старости», Баку, 1928 ), «Гызыл чичекляр хекайасы» («Рассказ золотых роз», Баку, 1928), «Бизим гюнляр» («Наши дни», Баку, 1936).

В разные годы о жизни и творчестве Г. Ибрагимова в азербайджанском литературоведении были написаны отдельные статьи.

На филологических факультетах университетов Азербайджана изучается творчество Г. Ибрагимова по материалам очерков профессора Панаха Халилова.

Во многих статьях и выступлениях таких видных представителей литературы Азербайджана, как народный поэт Самед Вургун, народный писатель Мехти Гусейн, не раз говорилось о творчестве Г. Ибрагимова.

В разные годы на страницах азербайджанской печати были опубликованы отдельные статьи профессоров Панаха Халилова и Вагифа Арзуманлы о жизни и творчестве Г. Ибрагимова.

## ЕГЕРМЕНЧЕ-УТЫЗЫНЧЫ ЕЛЛАРДА ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫҢ ЭСТЕТИК ЭВОЛЮЦИЯСЕ

***Ф. Г. Галимуллин (Казан)***

В статье прослеживается эстетическая эволюция классика татарской литературы Г. Ибрагимова в двадцатые-тридцатые годы XX века. Романтическое мировосприятие писателя, проявившееся в раннем творчестве, под воздействием общественно-социальных условий со временем уступает принципам пролетарской литературы. Однако писатель не смог полностью отказаться от романтического начала в своем литературном творчестве.

Ибрагимов не только хорошо знал фольклор родного народа, но был знаком с изданиями фольклора других тюркских народов, опубликованных А. Диваевым, В. Радловым и др. Он писал о взаимопроникновениях, взаимовлияниях фольклора этих народов с народным

творчеством татар. Он проводил аналогии и сравнения позднее в статье «Тел, әдәбият мәсьәләләренең кирәкле бер тармагы» («Одно из нужных направлений проблем языка и литературы», 1926). В ней Ибрагимов воздал должное труду многих татарских ученых, писателей, собиравших и популяризировавших татарский фольклор. Первым он назвал К. Насыри, затем венгерского ученого Д. Мессароша (У Ибрагимова – Масияруш), в 1905–1906 гг. собиравшего, изучавшего в Казани татарский фольклор. Высоко оценил он деятельность Х. Бадиги, Г. Рахима, Г. Исхаки, Ф. Туйкэ, С. Кудаша, А. Тагирова, И. Бабича.

Ибрагимов считал, что необходимо собирать народную литературу и для того, чтобы можно было проводить научные исследования. Здесь он определил четыре этапа работы, рассчитанные на продолжительное время:

1. Собирать народную литературу из уст народа.
2. Объединить все материалы, собранные в разное время, но не изданные.
3. Исследовать их научным методом.
4. Систематизировать, издать эти материалы.

Тут же он подчеркивает, что народная литература является основным источником для изучения народа, создания нового литературного языка и терминов. «Чистый народный язык, – пишет он, – сохранился лишь в народной литературе» (4, 491).

В этих статьях он развил далее свои мысли, высказанные еще в 1910 году.

Несомненно, писать о роли фольклора в эстетике Г. Ибрагимова позволительно лишь исходя из его теоретических положений о роли и значении фольклора. В эстетические взгляды Ибрагимова эстетика фольклора пришла как осознанная им необходимость. Необходимость фольклора для писателя уже в том, что он уверен – произведения писателей только при обращении к фольклору становятся реалистическими, жизненными, народными. Эти три категории стали отправными и фундаментальными для творчества Ибрагимова-писателя.

Взгляды Ибрагимова о фольклоре были еще раз обоснованы им в его статье «Уроки литературы» (1916), переизданной в 1918 году под названием «Каноны литературы». Тут он много места отводит разработке основ теории татарского фольклора, анализу жанров и т. п. Он подчеркивает две стороны фольклора, которые им уже были отмечены в статье «Вопросы литературы»: 1) то, что он служит очищению языка; 2) помогает понять душу народа. Здесь Ибрагимов отметил, что собирание, исследование народного творчества соответствует развитому национальному самосознанию, тесно связано с его ростом. Говоря о значении народного творчества для письменной литературы, он пишет, что ее история начинается с народных песен, сказок. Ибрагимов приводит такое образное сравнение: «Письменная литература – это цветок, проросший из народной литературы. Первую из них можно сравнить с естественным лесом, а вторую – с ухоженным садом» (3).

Татарский писатель высказывал свои взгляды на фольклор и в других своих трудах по литературе, в исследованиях о творчестве тех или иных писателей. Но специальный труд – глава «Народная литература» – явился началом поворота на пути использования народной литературы, и не просто вкраплений, фольклоризмов, лежащих на поверхности, характеризующих тот или иной образ, украшающих то или иное произведение, а как осознанное усвоение эстетических ценностей народа, как краеугольный камень его творчества, эстетического отношения к жизни.

ЛИТЕРАТУРА

1. Вопросы литературы. – 1978. – № 11.
2. Горький М. О литературе. – М.: Изд-во худ. лит-ры, 1961. – С. 427.
3. Ибраһимов Г. Әдәбият кануннары. – Казан: Сабах, 1918. – Б. 52.
4. Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. – Т. 5. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – Б. 10–38, 320, 491.
5. Исхакый Г. Әсәрләр: унбиш томда. – Т. 5. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – Б. 280.
6. Нуруллин И. З. XX йөз башы татар әдәбияты. – Казан, 1982. – Б. 15.
7. Тукай Г. Әсәрләр: дүрт томда. – Т. 4. – Казан, 1977. – Б. 66.
8. Хасанов М. Галимджан Ибрагимов. – Казань, 1969. – С. 60–61.

# ИЗ ИСТОРИИ ТЕКСТОЛОГИЧЕСКОГО ИЗУЧЕНИЯ ПИСЬМЕННОГО НАСЛЕДИЯ Г. ИБРАГИМОВА

***З. З. Рамеев (Казань)***

Письменное наследие Галимджана Ибрагимова включает в себя самые разнообразные тексты, созданные в период с 1908 по 1936 год. Это прежде всего, художественные произведения (рассказы, повести, романы, некоторые имеют и варианты, драма), литературно-критические статьи, публицистика, труды по истории общественного движения среди татар, по языкознанию. При жизни автора все они вышли в виде книг, сборников (хрестоматий), публикаций на страницах ряда татарских газет и журналов. И в текстологическом изучении, и в изучении эволюции художественного мышления, лаборатории творчества того или иного писателя большую роль играет и рукописное наследие. По ряду причин личный архив Г. Ибрагимова не сохранился, не сохранились и рукописи художественных произведений. Так, рукопись романа «Дочь степи» («Казакъ кызы»), сданная в печать в издательство «Вакыт», во время обысков в Оренбурге была изъята жандармами и не возвращена. Благо, что у автора оставались черновики, по которым ему удалось восстановить беловик. Но роману опять не везет. 17 апреля 1913 года в Киеве Г. Ибрагимова арестовывают, забирают книги, письма, разные рукописи, а также беловик указанного романа. Правда, пятнадцать месяцев спустя многое было

возвращено, но 70 страниц романа, к сожалению, отсутствовало. Кроме того, в 1929 году, во время освобождения казанской квартиры Г. Ибрагимова из-за срочного отъезда больного писателя в Крым, все, что там оставалось, было собрано в семь ящиков и по акту сдано в подвал Татарского государственного (ныне: объединенного национального) музея для хранения. Оно бесследно пропало. Как активный общественный деятель, он подолгу бывал в разъездах (Оренбург, Сухуми, Казань, Уфа, Москве, Петроград, родная деревня Султанмурат), что не всегда давало возможность сохранить свои автографы произведений, другие рукописные материалы. Не дошли до нас и рукописи ялтинского периода, над которыми он работал (при каждом случае улучшения здоровья) до последних дней пребывания на свободе. В 1937 году его арестовали и тяжело больного этапировали в Казань.

Пытался ли Г. Ибрагимов, хорошо знавший цену своим художественным произведениям, представить их вниманию читателя не в виде отдельных, разрозненных книг, а как собрание сочинений (а он, как классик, безусловно, был достоин таких изданий)? Но при активном участии в общественной, культурной и литературной жизни молодой Татарской республики, кажется, ему было недосуг заниматься такого рода делами. Такая возможность представилась, лишь когда он серьезно заболел в конце 1920-х годов. Напрашивается своеобразная параллель с Тукаем, который, предчувствуя свою кончину, в основном составил «Собрание сочинений» («Габдулла Тукаев мәҗмугаи асәре»), хотя и не полное. В 1929–1931 годах в издательстве «Яналиф» выходят «Произведения Галимджана Ибрагимова» («Галимҗан Ибраһимов әсәрләре») в семи томах. Видимо, их подготовку ускорило и то обстоятельство, что в эти годы надо было в какой-то степени сгладить неоднозначность перехода с испытанной, многовековой арабографической письменности татарского народа на латиницу. Возможно, издание было задумано в дни празднования двадцатилетия его литературной деятельности. Несмотря на болезнь, писатель немало трудился над текстами. В «Автобиографии» 1936 года он пишет, что ему пришлось много работать над подготовкой к печати своих произведений, редактировать, серьезно перерабатывать отдельные места. По каким-то причинам увидели свет лишь 2, 5, 6-й тома (1). Что интересно, в 7-й том планировалось включить и второй том *(«кисәк»)* трилогии «Наши дни».

В середине 1930-х годов два раза были изданы «Избранные произведения» Г. Ибрагимова: сначала в пяти книгах (3 и 4-я – объединенные), затем в четырех томах (вышли лишь 2 и 3-й тома). В Татгосиздате их ответственным редактором являлся Афзал Шамов. Находясь вдалеке, притом больной, Г. Ибрагимов не имел возможности скрупулезно заниматься подготовкой к печати каждого своего произведения. В эти годы, в связи с деятельностью главлита в издательской подготовке произведений, уделялось внимание выдержанности в них идеологических установок партии в области художественного творчества. А. Шамов пишет, что в процессе редактирования он переписывался с писателем, просил разрешения на вычеркивание некоторых слов, строк, на редактирование отдельных предложений, и писатель во многих случаях давал на это разрешение. Но однажды вышла неприятность. Как пишет А. Шамов, при редактировании 2-го тома он убрал из авторского послесловая к роману «Наши дни» 12 строк и не сообщил об этом писателю (и не успел написать об этом в письме) (2). Получив указанный том в руки, Г. Ибрагимов заметил это и послал телеграмму в Татарский областной комитет партии с выражением своего неудовольствия. Хотя в других случаях его реакция на издания своих произведений нам неизвестна, поэтому категорично не можем утверждать об адекватном отражении в них авторской творческой воли.

Надо сказать и то, что в многотомники Г. Ибрагимова тридцатых годов включены лишь художественные произведения. Об издании его трудов по истории, литературоведению и языкознанию в то время не было и речи.

В связи с арестом и объявлением Г. Ибрагимова врагом народа, после 1937 года не только перестали печатать его новые произведения, но и изъяли и уничтожили имеющиеся многотомники. Потому татарская литература 1905–1936 годов долгое время в литературоведческих исследованиях представлялась читателям в урезанном виде. Лишь почти два десятилетия спустя, после начала реабилитации безвинных жертв сталинского режима, начало возвращаться творческое наследие татарских писателей. Так, в 1956–1957 годах Таткнигоиздат выпустил «Избранные сочинения» Галимджана Ибрагимова в трех томах (3), в составлении и редактировании участвовали Афзал Шамов, Гали Халит, Амирхан Еники и Х. Музагитов. В них представлены большинство прозаических произведений писателя и драма «Новые люди» («Яңа кешеләр»). В начале 1-го тома сообщается, что тексты взяты из последних прижизненных изданий писателя.

Современный же татарский читатель имеет возможность знакомиться с творческим наследием классика татарской литературы, видного ученого-литературоведа, языковеда и историка Г. Ибрагимова в основном благодаря его «Сочинениям» в восьми томах. Они были подготовлены текстологами, языковедами и историками Института языка, литературы и истории (с 1997 года: Институт языка, литературы и искусства), достойно носящего с 1967 года имя Галимджана Ибрагимова, и были изданы в Татарском книжном издательстве в 1974–1987 годах (4). Хотя редакционная коллегия во главе с М. Х. Хасановым и не планировала, в 2000 году в другом издательстве («Фикер») вышел еще один том (с письмами и документами Г. Ибрагимова) под номером 9 (5). В те годы никто из татарских писателей не «имел» такого многотомного издания. В коротенькой статье «От редакции» оно определяется как «самое полное» издание сочинений Г. Ибрагимова. В известной степени это близко к правде. Если сравнить его с вышеуказанными многотомными изданиями, вышедшими в 1930-е годы, безусловно, это наиболее полное издание. Наряду с художественными текстами, в нем размещены литературоведческие, публицистические, исторические, языковедческие труды и статьи. Это издание в то время явилось заметным достижением татарских ученых ИЯЛИ им. Г. Ибрагимова в текстологическом изучении классического литературного наследия татарского народа.

Но, если будем иметь в виду все то, что написано Г. Ибрагимовым почти за тридцать лет творческой жизни, мы вынуждены будем признать недоступность

современному читателю еще целого ряда текстов писателя. Может возникнуть вопрос: почему «Сочинения» в восьми томах были подготовлены именно в таком виде? Причин несколько. Во-первых, к началу подготовки прошло только двадцать лет с того времени, когда было восстановлено доброе имя Г. Ибрагимова и начало возвращаться его богатое письменное наследие. Во-вторых, не было научной библиографии его произведений и литературы о нем (вышедший в Уфе в 1979 году библиографический указатель «Галимҗан Ибраһимов», составленный Ф. Г. Габсалямовой и У. И. Гимадиевым в советское время, далек от полноты). К сожалению, библиография до сих пор так и не составлена. В-третьих, в те времена татарское литературоведение и текстология жили под давлением марксистско-ленинской идеологии, и потому произведения, звучащие как-то по-иному, вниманию читателей не предлагались. Помнится, дирекция ИЯЛИ в начале подготовки издания пыталась увеличить количество томов. Но тщетно, товарищи из руководства АН СССР были против, т. к. не соответствовал статус: Татарская АССР была лишь автономной республикой.

В чем же заключается неполнота восьмитомника? Так, например, из художественных произведений осталась невключенной повесть «Люди» («Адәмнәр», 1923). Правда, историкам татарской литературы, текстологам, составителям томов она была известна. Автор вступительной статьи в духе того времени пишет о ней: «В ней не соблюден принцип показа действительности в революционном развитии – одного из важных принципов эстетики социалистического реализма» (6). Большинство невключенных текстов составляют труды и статьи по истории татарского народа, по татарскому языку, публицистика. Многие их них сохранились лишь на страницах татарских газет и журналов 1908–1917 годов. В конце 60-х – в начале 70-х годов, когда начались подготовительные работы по созданию восьмитомника, в секторе литературы ИЯЛИ были предприняты меры по их сбору и переводу на кириллицу. Но такие материалы по вышеуказанной причине остались невостребованными. В их числе очень значительный труд Г. Ибрагимова «Каким путем пойдет татарская культура?» (1927), в котором довольно четко поставлен вопрос сохранения национальных особенностей в культуре татарского народа в условиях новой действительности. Эволюция художественного мышления писателя наблюдается и в том, что тексты его произведений при повторных изданиях претерпевают весьма заметные изменения. Это особенно видно на примере рассказов «На море» («Диңгездә», 1911, 1920,1922, 1929, 1930), «Пастухи» («Көтүчеләр»,1920, 1929, 1934), «Старый слуга» («Карт ялчы», 1912, 1921, 1925, 1934), повести «Судьба татарки» («Татар хатыныниләр күрми», 1910, 1911, 1929), романа «Наши дни» («Безнең көннәр», 1919, 1934). Что интересно, готовя новое издание своего произведения, автор иногда объясняет и свой подход к тексту. Так на титульном листе сборника рассказов «В дни старости» (1920) он делает примечание о том, что он полностью сохранил содержание, но несколько изменил литературно-художественную сторону. Большие изменения внесены им при подготовке к изданию в 1929 году повести «Судьба татарки». Автор отмечает, что на этот раз (третье издание) сохранил основное звучание, общественную основу, но сызнова переработал литературный материал и композицию. Исследователи творчества Г. Ибрагимова давно высказывают мысль о необходимости тщательного изучения первого варианта романа «Наши дни», изданного в Казани в 1919 году, и о включении его в собрания сочинений писателя. Это обьясняется тем, что Г. Ибрагимов, находясь на излечении в Ялте, заново написал его текст, таким образом создал новый вариант произведения (издан в 1934 году). Но в начальном периоде своего творчества писатель обходился и без переработки ранее написанного. Например, в газете «Эльислах» в течение 1907–1908 годов под редакцией Фатиха Амирхана печатался его первый рассказ «Изгнание Заки-шакирда из медресе» («Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы»). Он был издан отдельной книгой в 1910 году с примечанием о том, что автор ничего не изменил, ни одной буквы не добавил, не убавил, все оставил, как было прежде, лишь слегка поправил графическое написание *(«имля»)*. Из вышесказанного можно делать вывод: Г. Ибрагимов с годами более строже начал относиться к своим творениям. С другой стороны, писатель принял Октябрьскую революцию, положительно относился к строительству социализма, что, в свою очередь, отразилось и в критическом отношении к ранее написанным произведениям. Исходя из ряда других фактов, можно уверенно высказать мысль о том, что ряд текстов Г. Ибрагимова в многотомных изданиях не адекватно отражают творческую волю автора. Еще пятьдесят лет назад М. Хасанов обратил внимание на то, что текст рассказа «Красные цветы» («Кызыл чәчәкләр») издания 1931 года точнее отражает волю автора, а в издании 1936 года части текста под номерами 16, 17, 19 были вычеркнуты (7). Что интересно, в трехтомнике 1957 года указанное произведение опять-таки было приведено в урезанном виде.

Среди ряда неоправданных текстологических решений при подготовке «Сочинений» в восьми томах следует указать на купюры (хорошо, что они отмечены в квадратных скобках). Особенно этим «грешат» тома, где приводятся труды по теории и истории татарской литературы (5-й том), публицистика (6-й т.), исторические исследования (7-й т.), труды по татарскому языкознанию (8-й т.). В 5-м томе таких сокращений – 67, в 6-м томе – 40, столько же в 7-м томе, в 8-м томе – 55. Составители этих томов Р. Гайнанов, С. Алишев, Ф. Фасеев и редакционная коллегия издания вынуждены были идти, в основном учитывая главлитовские установки (правда, иногда приходилось ориентироваться на запланированный объем томов). Ограничимся двумя примерами. В его известном, вызвавшем противоречивые оценки современников труде «Татарские поэты» в разделе о Тукае говорится и о том, что «теперь он, словно почувствовав каждой клеточкой своего сердца то, что в его жилах играет кровь Чингизхана, мысленно погружаясь в хмурые, пасмурные дни своего прошлого, он видит, как со стороны Алтая выдвигаются татарские богатыри, герои истории, которые своими именами потрясли мир». И еще: Тукай «хвалится, что из татар вышли *(җитешкән)* Чингизы, Батыи, Мамаи и Сююмбики». Сокращая эти строки, составитель и редколлегия пытаются скрыть тот факт, что Г. Ибрагимов показывает Тукая отражающим национальные чувства. В текстах Г. Ибрагимова, помещенных в 5-ом томе, везде вычеркивается имя Г. Исхаки и потому

татарская литература начала двадцатого века предстает в искаженном виде.

При текстологическом изучении литературного наследия перед исследователем всегда возникает проблема аттрибуции. Относительно творчества Г. Ибрагимова она также существует. В решение этой проблемы внес определенный вклад Рашат Гайнанов. При подготовке 5-го и 6-го томов он обнаружил 13 псевдонимов Г. Ибрагимова: Галимҗан Ибраһимов, Г. Ибраһимов, Габди, Гыйрфанзадә, Гъҗан, Гъҗан Ибраһим, Джан, Гъ. И., «Әльислах» мөхбире, Мөхбирегез, Идарә, Тыңлаучы. Но и в этом направлении поиски должны продолжаться. Писатель в 1917–1918 годах работал и очень активно печатался в газетах и журналах «Ирек», «Безнең юл», «Чулпан», еще не изучены анонимные материалы. С. Алишев, изучавший газету «Чулпан» пишет, что ибрагимовские материалы имеются в каждом номере (8).

Одной из основных задач текстологического изучения литературного наследия является комментирование. В этом заинтересованы читатели и многие ученые, ведущие исследования в татарской филологии. В последние годы татарские текстологи обращают большое внимание и на это. Отрадно и то, что редакторы издательств, где печатаются многотомные собрания сочинений классиков, сейчас также заинтересованы в строгом, последовательном применении научно-текстологических принципов. Во всех восьми томах «Сочинений» Г. Ибрагимова комментарии занимают довольно заметную площадь. Составители не ограничиваются лишь указанием места и времени написания, библиографическим описанием того или иного текста, при наличии материала приводят и суждения современников, объясняют реалии того времени, чтобы «темные» места текстов были понятны широкому читателю. Впервые 5–8 тома снабжены довольно полными алфавитными указателями собственных имен (личностей, книг, газет, журналов, произведений и т. д.), которые упоминаются в текстах. Их составили Р. Гайнанов, З. Рамеев, С. Алишев, Ф. Фасеев, Л. Гайнанова, Р. Даутов. Конечно, они составлены в перестроечное время, и потому некоторые личности представлены в них в соответствии с идеологическими установками того времени (напр., буржуазный историк, белый эмигрант, буржуазный националист, пантюркист).

Учитывая все вышесказанное, а также пожелания, прозвучавщие во время проведения предыдущего юбилея – 120-летия со дня рождения Галимджана Ибрагимова, руководство Института языка, литературы и искусства поручило отделу текстологии Института начать текстологическую подготовку полного собрания сочинений классика татарской литературы, литературоведа, историка, языковеда, выдающегося татарского общественного деятеля Г. Ибрагимова в двенадцати томах. Планируется, что первые пять томов выйдут с художественными произведениями. В 6-м и 7-м томах будут напечатаны литературоведческие труды и литературно-критические статьи, публицистические выступления войдут в 8-й том, исторические труды – в 9-й том, языковедческие труды и статьи – в 10-й. В 11-м и 12-м томах будут помещены частично языковедческие труды, а также автобиографии, письма и документы. Работа предстоит очень большая. Назову лишь некоторые моменты:

1) надо вести библиографические разыскания, ибо не все тексты Г.Ибрагимова еще выявлены; изучить татарские газеты и журналы 1910–1930-х годов, архивные материалы;

2) необходимо исправить все тексты, напечатанные в восьмитомнике, на основании источников, воостановить все купюры;

3) необходимо провести тщательную текстологическую работу с новыми материалами, которые впервые войдут в многотомник;

4) написать подробные комментарии к каждому тексту, учитывая современное прочтение письменного наследия прошлого.

Хочу сказать, что работа началась. К концу года старший научный сотрудник отдела текстологии Гульнара Зайниева завершить подготовку 1-го тома, куда войдут рассказы Г. Ибрагимова, написанные в 1908–1916 годах, ведущий научный сотрудник Анися Алеева приступила к составлению 2-го тома. Все сотрудники отдела текстологии полностью смогут работать по этой теме только после завершения подготовки к печати сочинений Гаяза Исхаки в пятнадцати томах и четырех томов академического издания сочинений Габдуллы Тукая.

ЛИТЕРАТУРА

1. Галимҗан Ибраһимов әсәрләре: 7 томда. 2 том. – Казан: Яңалиф, 1929. – 474 б.; 5 том. – Казан: Яңалиф, 1931. – 198 б.: 6 том. – Казан: Яңалиф, 1930. – 116 б.

2. Шамов Афзал. Чын хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – Б. 292.

3. Ибраһимов Галимҗан. Сайланма әсәрләр: Өч томда. 1 том. – Казан: Таткнигоиздат, 1957. – 527 б.; 2 том. – Казан: Таткнигоиздат, 1956. – 595 б.: 3 том. – Казан: 1956. – 611 б.

4. Ибраһимов Галимҗан. Әсәрләр: сигез томда. 1 том. Казан: Татар. кит. нәшр.,174. – 510 б. [төзүче Г. К. Камалиев, текст һәм аңлатмаларны Р.Р.Гайнанов әзерләде]; 2 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. – 478 б. [төзүчеләр А. Ш. Шамов һәм Х. Я. Гобәйдуллин; текстларны, искәрмә һәм аңлатмаларны хәзерләүчеләр А. Ш. Шамов һәм Р. Р. Гайнанов]; 3 том. – Казан: Татар. кит. нәшр.,1975. – 454 б. [төзүчеләр А. Ш. Шамов һәм Х. Я. Гобәйдуллин; текстларны, искәрмә һәм аңлатмаларны хәзерләүчеләр А. Ш. Шамов һәм Р. Р. Гайнанов]; 4 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. – 459 б. [төзүче, искәрмә һәм аңлатмаларны язучы А. Ш. Шамов; текстларны А. Ш. Шамов һәм Р. Р. Гайнанов әзерләде]; 5 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – 615 б. [төзүче, текст, искәрмә һәм аңлатмаларны әзерләүчеләр М. Х. Хәсәнов, Р. Р. Гайнанов; текстларны җыйнауда, барлауда М. В. Гайнетдинов катнашты, материалларны текстологик яктан хәзерләүдә Н. И. Садыйкова булышты; алфавит күрсәткечен Р. Р. Гайнанов һәм З. З. Рәмиев төзеде; фәнни редактор Н. Г. Юзиев]; 6 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 606 б. [төзүче, текст, искәрмә һәм аңлатмаларны әзерләүче Р. Р. Гайнанов; фәнни редактор И. Г. Гыйззәтуллин]; 7 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – 539 б. [төзүче, текст, искәрмә һәм аңлатмаларны әзерләүче С. Х. Алишев]; 8 том. – Казан: Татар. кит. нәшр, 1987. – 431 б. [том өчен материалларны туплады Л. Гайнанова; төзүчеләр, текстларны хәзерләделәр Ф. Фәсиев һәм Л. Гайнанова; фәнни редактор, кереш сүз, искәрмә һәм аңлатмалар авторы Ф. Фәсиев].

5. Ибраһимов Галимҗан. Әсәрләр: тугыз томда. 9 том. – Казан: Фикер, 2000. – 464 б. [төзүче, текст һәм аңлатмаларны әзерләүче Ф. И. Ибраһимова; фәнни редакторлар З. З. Рәмиев, И. А. Еникиев].

6. Хәсәнов Мансур. Галимҗан Ибраһимов // Ибраһимов Галимҗан. Әсәрләр: Сигез томда. 1 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. – Б. 24.

7. Хәсәнов М. Г. Ибраһимов әсәрләренең икенче томы // Совет Татарстаны. – 1957. – 18 гыйнвар.

8. Алишев Сәлам. Г. Ибраһимов әсәрләренең яңа томы // Ватаным Татарстан. – 2001. – 13 июль.

# ҮЗГӘРТЕП КОРУДАН СОҢГЫ ТАТАР ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕНДӘ Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ ИҖАДИ МИРАСЫН ӨЙРӘНҮ МӘСЬӘЛӘЛӘРЕ

*Р. Ф. Рахмани (Казан)*

В статье говорится о состоянии изученности творческого наследия Г. Ибрагимова (на материале двух прошедших конференций).

Классик әдибебез Г. Ибраһимовның тууына 125, үлеменә киләсе елның гыйнварында 75 ел тула. Әлеге күпкырлы олы талантның милләтенә җиң сызганып хезмәт итә башлавына исә нәкъ бер гасыр! Аның иҗтимагый-сәяси, мәдәни һәм әдәби иҗат эшчәнлеген без бүген әнә шушы гаҗәеп катлаулы, болгавыр гасыр призмасы аша карап фикер йөртергә тырышабыз. Булып узган вакыйгаларга бүгенге көн күзлегеннән торып бәя бирүе җиңелрәк, әлбәттә. Чөнки ярдәмгә Вакыт үзе килә. Әмма Вакыт та барысына да ачыклык кертеп бетерә алмый, күп кенә четерекле сорау-проблемалар бүгенге һәм киләчәк көн галимнәре алдында чишелмәс башваткыч булып калуын дәвам итә.

Г. Ибраһимов – классик әдип; Г. Ибраһимов – танылган күпкырлы галим; Г. Ибраһимов – күренекле теоретик һәм гамәли сәясәтче, җәмәгать-дәүләт эшлеклесе. Заман югарылыгыннан торып караганда, аның бу төп өч юнәлештә күрсәткән эшчәнлеген, билгеле, бүген бер дәрәҗәгә куеп булмый. Без моны танырга тиешбез. Әлеге өч өлкәдә дә ачыкланып бетмәгән, Тукаебыз әйткәндәй, «энәсеннән җебенә кадәр тикшереләсе» нәрсәләр бихисап. Шунысы хак: Г. Ибраһимов мирасы бер яктан икенче якка ташланып бәя бирүләрдән бүгенге көндә дә һич азат түгел әле. Һәм ул сиксән ел буе инде шулай дәвам итә: әле аңа Хезмәт Герое исеме бирелә, әле иҗаты әдәбият тарихыннан, уку дәреслекләреннән алып ташланып, автор үзе юк ителә; әле аны кабат күтәреп алып, югары чөю, идеаллаштыру чоры башлана һәм, табигый ки, монысы да күңелләрдә ризасызлык-канәгатьсезек тойгысы уятуга сәбәпче була. Кыскасы, без, аның варислары, бу олы юбилярыбызга бүген тарихи объектив бәя бирүдән һаман ерак торабыз шикелле. Бу нәрсәдә күренә соң?

1. Без үзебезне әдипнең рәхмәтле варислары итеп саныйбыз. Әлеге шәхеснең һәр олы юбилее Респубика күләмендә дәүләт дәрәҗәсендә билгеләп үтелүе, үзебезнең Институтта гына да соңгы ун ел эчендә халыкара өч фәнни-гамәли конференция уздырылу, ул материалларның исә саллы җыентыклар булып басылып чыгуы шактый күп нәрсә хакында сөйли. Әмма шуның белән бергә, без әдип өчен иң мөһим, иң кирәкле төп эшне башкарып чыга алганыбыз юк. Үзгәртеп корудан соң гына да чирек гасыр вакыт үтеп китте, ә безнең кулда милли культурабызның үзәк фигурасы саналган Хезмәт Батырының, академик димим инде, бозылмаган, автор алдында безгә оят булмастай адәм рәтле бер сайланмасы да юк бит. Әдибебезне ярату яки хөрмәтләвебезнең ихласлыгына шик тумаслык та түгел. Конференциягә җыелып, ниндидер хак сүз әйтергә тырышу, миңа калса – иске тунга яңа ямаулык ябыштырырга азаплануны хәтерләтә башлый.

Галим-голяма карамагында төп өйрәнү материалы булган тугызтомлыкның нинди сыйфатта чыгуын күзаллар өчен текстолог – фәннәр докторы З. Рәмиев мәкаләсеннән бер өзек китереп узыйм. Сүз монда Г. Ибраһимов китабының кыскартылулар белән телгәләнүе, томнарның главлит тырышлыгы белән һәр умырып алынган җиргә куелган квадрат җәяләрдән чуарлануы турында бара: «Андый очраклар белән без 5 нче томда 67 мәртәбә очрашабыз, 6 нчы томда 40 җирдә киселгән, тарихи хезмәтләр урнаштырылган 7 нче томда – 40, 8 нче томда – тел томында – 55» («Галимҗан Ибраһимов һәм XXI гасыр». Тууына 120 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. – Казан, 2007. – Б. 84).

Мондый мәсхәрәле мөнәсәбәтне мин классик әдипкә түгел, һичбер заманның һичбер уртакул язучысына да теләмәс идем.

Ә авторның күпме хезмәтләре әлегәчә киң катлам укучыга билгесез булып кала килә. Әдип иҗатында мөһим роль уйнаган «Адәмнәр» повесте (1923) да, «Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?» (1927) программ хезмәте дә, «Кызыл чәчәкләр»нең 1931 елгы тулы һәм дөрес варианты да тугыз томлыкта урын тапмаган. Әдипнең Зөфәр абый Рәмиев өмет иткән 12 томлыгы, бәлки, алдагы юбилейларга басылып чыгар?! Бүген исә галимнәребез халыкара фәнни-гамәли конференцияне шул телгәләнгән җәрәхәтле тугыз томлык һәм кисәк-кысак өстәмә материаллар белән үткәрергә мәҗбүр.

2. Тулы һәм дөрес басма булмау – әдип иҗатына фәнни якын килә алмавыбызның бер ягы. Икенче ягы аның – әйтүебезчә, мөнәсәбәтебезне югары пафоска корып, үзен исә идеаллаштырып күрергә теләвебездә. Юбилейлар, бәлки, аларсыз да булмый торгандыр, әмма бит алар берничә көн генә дәвам итә, ә калган көннәрдә дә чын хаклык белән яшәү дөресрәк булыр иде түгелме соң?!

Г. Ибраһимов – зур әдип. Әмма аның фәндә һәм иҗтимагый-сәяси, дәүләт эшлеклесе буларак кылган теоретик-гамәли эшчәнлегендә шактый гына каршылыклы фикерләрнең булуын танымый мөмкин түгел. Әлеге олы шәхеснең киң колачлы энциклопедик белеме, кызганыч ки, ул чорларда конструктив, ныклы нигезгә корылып үскән тоташ бер фәнни агымга әверелеп китә алмый. Бу аерым классик әдипләребез һәм галимнәребез (Г. Тукай, Г. Исхакый, Ф. Кәрими, Ф. Әмирхан, Җ. Вәлиди һ. б.) иҗатын бәяләүгә дә, татар әдәбияты тарихын чорларга бүлү мәсьәләсенә дә бердәй карый. Күренекле фикер иясенең, үзе яшәгән яңа заман идеологиясенә яраклашырга мәҗбүр булып, социалистик ил төзергә алынган яшь белгечләргә яңа төр әдәбиятның нигез таләп-методикасын эшләп бирүе исә («Пролетариат әдәбияты турында», 1924) башкалар иҗатын сыйнфыйлык карашларыннан чыгып бәяләргә кирәклекне генә күрсәтеп калмый, хәтта әдипнең инде элек иҗат ителгән үз әсәрләрен дә яңабаштан төзәтеп – сәяси кыйбласын үзгәртеп язу ихтыяҗын тудыра. Шулай ук бу хезмәте аның үз иҗат мирасына да зур зыян сала.

Талантлы язучыбызның әдәби олы мирасы да, миңа калса, өр-яңадан анализлауны сорый. Әсәрләрен

«романтизм», «реализм үсеше» терминнарына гына кайтарып калдырмыйча, аларның кабатланмас колачлы фәлсәфәсен, психологик тирәнлеген, эстетик кыйммәтен һәм тел-стиль казанышларын укучыларыбызга тиешле фәнни дәрәҗәдә анализлап җиткерү киләчәктәге иң мөһим бурычларның берсе булып кала.

Дөрес, фәнни конференция материлларын үзенә туплаган «Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман» (Казан, ТӘһСИ, 2003), «Галимҗан Ибраһимов һәм XXI гасыр» (Казан, ТӘһСИ, 2007) китапларында инде галимнәребезнең әдип мирасына шактый гына объектив якын килеп бәяләү омтылышын сизми калмыйбыз.

Бу яктан мин бигрәк тә фән докторлары Рим Салиховның «Галимҗан Ибраһимов һәм пролетариат әдәбияты концепциясе», Мәсгут Гайнетдиновның «Г. Ибраһимов һәм Ф. Кәрими», Назыйм Ханзафаровның «Г. Тукай турында Г. Ибраһимов һәм Н. Исәнбәт», Т. Галиуллинның «Галимҗан Ибраһимов мирасында әдәбият белеме мәсьәләләре», Хатыйп Миңнегуловның «Урта гасыр һәм XIX йөз татар әдәбияты турында Г. Ибраһимов», Дамир Исхаковның «Об одном политическом взгляде Г. Ибрагимова» мәкаләләрен башка бик күп язмалардан аерып куяр идем. Аларның хезмәтендә әдип иҗатына олы ихтирам да, аның кимчелекләрен күрсәтү һәм ялгышларына тирән борчылу да бердәй ярылып ята. Әдәбият фәненең чын перспектив үсеш юлы – әнә шулай чәчәкләми-чукламый, ялган пафослардан өстен булган хаклыкка ирешү юлында дөрес адымнар салынуда түгелмени?!. Г. Ибраһимов шәхесе моңа лаек һәм ул бизәкле вак-төяк кәгазь белән төрелгән төрле яклауларга мохтаҗ түгел.

Бу бигрәк тә әдипнең фәнни хезмәтләре һәм өченче төр мирасы – революцион дәүләт эшлеклесе буларак күрсәткән иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге турында сөйләгәндә мөһим.

Тарихчы Д. Исхаков күрсәтеп һәм ассызыклап узганча, Г. Ибраһимов 1922 елда басылган «Зур Башкортостан мәсьәләсе» дигән мәкаләсендә Уфа губернасы һәм Башкорт республикасын кушу юлы белән ясалачак «Олы Башкортостан» төзү проектын яклап чыга. «Татар әдәбиятыннан зур бер өлкәнең аерылып чыгуы олуг бер югалту булса да, тарихның китереп чыгарган фактлары белән исәпләшергә тиешбез», – дип коммунистик идеология файдасына Уфа губернасының көнбатыш өлешендә яшәгән 600 меңнән артык татарның мәнфәгатен битараф калдыруы, әлбәттә, авторның сәяси зирәклеге хакында сөйләми. Бүгенгәчә милли тарткалашу чыганагы булып кала килгән каршылыклы вазгыятьне истә тотып, Д. Исхаковның: «Сложнейший “татарский вопрос” в Башкортостане, во многом была проиграна татарами благодаря недальновидности таких политических деятелей, как Г. Ибраһимов» («Галимҗан Ибраһимов һәм XXI гасыр». – Казан, 2007. – Б. 243) дип язуы да тикмәгә түгел, билгеле. Көрәшне җиңдергән гаскәр башлыкларын күккә чөюнең урынсыз булуы ачык аңлашыладыр. Җиңелүнең тарихи-объектив сәбәпләрен анализлау бүгенге көндә күпкә мөһимрәк.

Сөйләгәннәрдән нәтиҗә ясап шуны әйтергә була: олуг әдибебезнең олы мирасын тиешле фәнни дәрәҗәдә өйрәнү эшенә без, татар җәмгыяте, әле бүген дә әзер түгелбез.

## Г. ИБРАҺИМОВ ШӘХЕСЕН ӨЙРӘНҮГӘ КАЙБЕР ЯҢА ФИКЕРЛӘР

*Л. Х. Хәмидуллин (Казан)*

Исторические события XX века оставили след и в литературном процессе, и в творческой биографии отдельных писателей. Статья выявляет пробелы в жизни и творчестве классика татарской литературы Г. Ибрагимова.

XX гасыр ахыры җиткәндә үткән тормышка яңадан әйләнеп карау мөмкинлеге туды. Элек эшләнгән хезмәтләрнең байтагын хәзер «яңа иләктән иләргә» күнегеп барабыз. Шунда, кызып китеп, киләсе гасырга алып керердәй кайбер уңышларыбызны да юкка чыгарырга теләк белдерүчеләр очраштыргалады. Мондый хәл бигрәк тә әдәбият, сәнгать дөньясына бәйле бәхәсләрдә үзен нык сиздерә. Дөрес, кайберәүләрнең ул бәхәсне «үз хаҗәтләрен» истә тотып башлап җибәргән булуы да ихтимал. Югыйсә берничә буын әдәбият сөючеләрнең якты йолдызы булып янган шәхесләргә кизәнүләрне аңлавы читен.

Классиклар киштәсеннән читләштерелергә тиеш табылган әдипләр исемлегенә Галимҗан Ибраһимовны «теркәргә» теләүчеләр дә булды. Ул, имеш, революциядән соң «үз җырын» җырламаган, яңа заманга җайлашырга тырышкан. Мондый караш бигрәк тә милләтпәрвәр әдип Гаяз Исхакый исеме вә иҗаты халыкка кайтарылган көннәрдән соң көчәя төште шикелле. Бу ике олуг шәхесне капма-каршы кую, соңгысының иҗатын вә көрәш юлын чиксез күтәрү исәбенә, элеккеге «остаз»ны түбәнәйтергә тырышу очраклары күренгәли башлады.

Ә бит аларны бер-берсенә каршы куярга кирәкмәстер. Алар икесе ике шартта бер үк «юнәлештә» хәрәкәт иткәннәр. Галимҗан Ибраһимов Гыйльми Үзәкне җитәкләгән чорында гына да татар халкының үз калыбында калып, киләчәккә барышы өчен күпме хезмәт куйган кеше. Шушы өч елда ул башкарган игелекле эшгамәлләрне башкалар унар, утызар елда да тиешенчә эшли вә күтәрә алмастыр мөгаен. Татар халкының киләчәк язмышын кайгыртып яшәвен, шул юнәлештәге тырышлык-омтылышларын күреп торган, шуңа бик тә эчләре пошкан кайберәүләр Г. Ибраһимовны шул вакытта ук тезгенләргә теләк белдерәләр икән, монда инде нәрсәдер бар димәк. Аның үз милләтенең киләчәге өчен көрәш алып барганлыгын ерак Төркиядә яшәргә мәҗбүр булган элекке каләмдәше һәм фикердәше Габделбари Баттал да сизенгән. Шунда нәшер ителгән «Казан төркиләре» китабында ул: «Рус рево-

люциясе кайгылары аны да бөтереп ала һәм, нәтиҗәдә, большевик була, – дип язды. – Тик Г. Ибраһимов «милли большевик» иде. Ягъни, Русиядә урнаша барган яңа режимга яраклашып, үз халкына, милләтенә файдалы булачагына, үз сүзләре белән әйткәндә, «татар мәдәниятен төзи алачагына» ышана иде... 1926 елда Баку шәһәрендә узган тюркологик конференциядә алфавит алыштыруга каршы торган төркем арасында була. Һәм ул – милли коммунист – Бакуда узган вакыйгалардан соң ук шик астына алына».

Бик дөрес сүзләр. Бу юлларда тик бер генә төгәлсезлек бар: Г. Ибраһимов ул «конференция барышында алфавит алыштыруга каршы торган төркем арасында» түгел, шул абруйлы төркемнең җитәкчесе булган кеше. Әдипнең хатыны, язучы Гөлсем апа Мөхәммәдова 1994 елда Казанда нәшер ителгән «Олы юл» китабында да әдипнең Бакудан бик борчылып кайтуын искә төшерә. Аның сәбәпләрен ачыклап: «Галимҗан Ибраһимовның докладыннан соң күтәрелгән дискуссия шул дәрәҗәдә тәртәдән чыгып китә ки, нотык сөйләүчеләр кызып, ярсып берсе артыннан берсе аны милләтчелектә, пантюркизмда һәм башка төрле гөнаһларда гаепли башлыйлар. Г. Ибраһимовның Татарстан делегациясе җитәкчесе икәнлеген онытырга теләгән иптәшләр дә була. Мәсәлән, утырыштан соң баскычтан төшеп барган делегатларны кинога төшереп алган булалар. Ул лентадан Галимҗанны «кисеп» ташлыйлар, аның аяклары гына лентада кала. Конференциягә багышлап чыгарылган җыентыкка аның докладын да, соңгы сүзе дә кертелми», – дип яза.

Ә менә Казанда шул ук елларда уздырылган бер ябык киңәшмә кәгазьләренә күз салыйк (Альберт Мөслимовның «Рәсми әләк» мәкаләсе // Казан утлары. – 1991. – № 7). Анда, бит саен диярлек, Г. Ибраһимов телгә алына. Менә милли интеллигенциягә «бәя» бирү өлеше. «Казан революциягә кадәр дә милли эшлеклеләргә бай иде... Аларның бер өлеше чит илләргә чыгып китте, бер өлеше үзебезнең илгә таралды. Ә бер өлеше Казанда калды һәм, коммунистлар битлеге киеп, үз эшләрен дәвам итте... Татарстан Республикасында милли зыялылар туплана башлады, бу бигрәк тә 1926 елда сизелде. Г. Ибраһимов, Н. Надиев аеруча активлык күрсәттеләр. Алар “милли азатлык хәрәкәтендә” бай стажлы кешеләрнең зур төркемен Мәгариф халык комиссариаты һәм нәшрият органнарына эшкә урнаштырдылар. Шуннан соң алар үзара берләшә, оеша башладылар».

Шуннан соң «конкрет тәкъдимнәр» бәян ителә. «1. Идеология фронтындагы көрәшне туктату юнәлешендә: а) Академик Үзәктә Г. Ибраһимовның янәдән эшләвенә юл куймаска. (Төрле мәгариф вә мәдәният оешмаларында эшләүче тагын 9 кешенең исемнәре атала һәм: «Актив милләтчеләр буларак, аларны эштән бушатырга», – дип әйтелә.) б) Академик Үзәкнең эш планын... милли караштагы элементларны кысып чыгару максатында яңадан карарга, урыннарына марксистик яктан тотрыклы иптәшләрне җәлеп итәргә. Мондый мәсьәләне 1927 елда куярга мөмкин».

Китерелгән мисаллардан күренә ки, «милли большевик» әдип Г. Ибраһимовның революциядән соңгы фәнни һәм иҗади эшчәнлеге хәзер күзалланган кысаларга гына сыеп бетми икән. Аның эшчәнлегенең асыл максаты большевикларга ярашып, ак күмәч ашап яшәргә омтылулардан бик ерак тора. Үзалдына бөек максат куеп, армый-талмый татар милләтенең киләчәге якты булсынга хезмәт итә ул. Шуңа күрә аның егерменче, утызынчы еллардагы иҗат эшчәнлегенә дә үз чорына якын килеп бәя бирергә тиешбездер. Әдәбият галиме Альберт Яхин бер чыгышында әйтеп үткәнчә, Г. Ибраһимовның революциядән соң тудырылган әсәрләрен бәяләү өчен аларны тирәнтенрәк өйрәнү зарур. Аларны бәяләгәндә элекке еллардагы карашлардан баш тарту да кирәктер бәлкем.

* * *

Г. Ибраһимовның исемен һәм иҗатын караңгы гүр базларыннан халкына кабат кайтарган, мәрткә киткән «җаны»н яңадан терелткән, илленче-алтмышынчы елларда әһәмият биреп җиткерелмәгән, яисә заманасына күрә әһәмият ителергә тиеш булмаган күп кенә фактларга бүген күзне ачыбрак карарга, ул биографик «ак тап»лар өстенә капланган «иске чаршаулар»ны алып ташларга вакыт җиткәндер кебек. Әлегәчә исә безнең алда – күпчелек әдәбият сөючеләр алдында әдип шәхесенең бик үк ачык, тулы булмаган, фән телендә «яссы портрет» дип аталган рәсеме генә калка сыман. Аны хәзер укучы алдына тулы гәүдәсе белән китереп бастыру зарур. Ә моңа ирешү өчен аның биографиясен тирәнтенрәк өйрәнергә, элек «табу салынган темалар»ны, фактларны да тулырак яктыртып, ул шәхесне тулы канлырак иттереп торгызырга кирәктер. Һәр фикер иясенә хас булган ялгышулары, абыну-сөртенүләре, эзләнүләре белән бергә...

Туып-үскән Солтанморат авылын калдырып, олы юлга аяк баскан беренче адымнарыннан ук яшүсмер Галимҗанны ниндидер бер билгесезлек биләп ала сыман. Укуын дәвам итәр өчен ул ни сәбәпле туган йортыннан өч йөз илле чакрымнарда урнашкан Оренбург каласын сайлаган? (Дөресрәге, андый хокук, әлбәттә, Гыйрфан мулла карамагында булган, аны ул сайлаган.) Һәм нишләп үзләреннән илле-алтмыш чакрымдагы Уфа мәдрәсәләренә өстенлек бирелмәгән? Бу чорда бит инде Уфадагы «Госмания» мәдрәсәсе тирә-якта абруй казанган, җәдиди ысуллы уку йортларыннан саналган була. Шунда ук «Хәсәния» мәдрәсәсе дә «эшләп тора». Әнә бит атасы Гыйрфан мулла да үзләреннән ерак тормаган Кыешлы авылы мәдрәсәсендә генә белем алган. Соңрак ул Троицк каласына барып чыга. Якын туганы хәлфәлек иткән мәдрәсәдә бераз белемен яңарткannан соң, шунда укытырга калуы – очраклы хәл диярлек. Әгәр анда әнисенең кардәш-ыруы булмаса, мөгаен, Гыйрфан атналар буе йөк арбасында интегеп, дүрт-биш йөз чакрымдагы ерак шәһәргә юл тотмаган да булыр иде. Бәлки, аларның Оренбург белән электән килгән бәйләнешләре булгандыр? Бәлки, мишәр өммәтеннән булулары сәбәпле һәм кайчандыр «башкорт, мишәр гаскәре»нә кергәнлектән, ул гаскәрнең төп үзәге булган Оренбургта якын туганлык хисләрен саклаучы берәр җан иясе яшәгәндер? Гыйрфан мулланың бабасы Әхмәт шул гаскәрнең бер кантонында ахун булган ич. Аның нәсел тармагына кемнәр кергән? Болар әле һич тә ачыкланмаган. Һәм андый «вак» нәрсәләр белән кызыксынучы да әлегә юк шикелле. (Мишәрлек мәсьәләсенә килгәндә исә – Киев төрмәсенә ябылганда Галимҗан кулыннан нәкъ шундый тамга салынган паспорты алына.)

Шул ук Оренбург юлы өстендә, әмма авылдан нибарысы бер тәүлеклек арада, Солтанмораттан сиксән-

туксан чакрымнарда атаклы Стәрлебаш авылы мәдрәсәсе дә бар әле. XIX гасыр ахырларында анда мәшһүр шәхесләрдән Шәмсетдин Зәки, Гали Чокрый, Мифтахетдин Акмулла кебек, исемнәре мәдрәсәдән мәдрәсәгә таралган сүз осталары белем эстәгәннәр. Ниһаять, шул ук мәдрәсәне тәмамлап, булачак яшь шәкертләрнең бабалары Нурмөхәммәт үз авылына мулла булып кайткан. Һәм шул Нурмөхәммәтнең улы Гыйрфан үз балаларын, никтер, тагын да ераккарак, Оренбург тарафына ук озата. Сәбәбе нәрсәдә? Мөгаен, моңа бүген тәгаен генә җавап биреп булмыйдыр.

* * *

Шәкерт Галимҗан биографиясенә үз эзен салган икенче мәсьәлә: 1901–1902 елларда, «Вәлия» мәдрәсәсендә укыганда аның генерал Бикчуринда кучер вазифасын үтәве. Очраклы гына бер хәлме бу, әллә соң алдагы сорауларга да беркадәр ачыклык кертергә ярдәм итәрдәйме? Мирсалих Бикчурин Оренбург төбәге морзалары токымыннан була. 1838 елда шушы шәһәрдә хәрби уку йортын төгәлләгәннән бирле, патша хөкүмәте вәкилләре белән җирле халык арасында арадашчы-тылмач вазифасын үти. Кырык елга якын үзе укыган кадет корпусында һәм соңрак ачылган махсус рус-казакъ мәктәбендә егерме ел чамасына сузылган укытучылык эшчәнлеген башкара. Бу уку йортларында да аның төп хезмәте – «тылмачлык вазифасын үтәү», дип бәяләргә ярыйдыр. Чөнки аның төп эше яшь офицерларны, ягъни булачак патша чиновникларын татар, башкорт, казакъ, фарсы, гарәп телләренә өйрәтү була. Шушы телләрне өйрәнүдә күренекле урын тоткан мәгълүм дәреслек-хрестоматиясе дә («Начальное руководство к изучению... языков... с приложением русско-персидско-татарских слов». 1859, 1869 елларда нәшер ителгән), мәкалә-очерклары да җирле халыкның зыялы катламы тарафыннан хуплап каршы алына. Ягъни, генерал Бикчурин гадәти бер солдафон гына түгел, үз чорының зыялы бер галиме дә булган. Ул сиксән өч яшендә, 1903 елда Оренбург каласында вафат була. Менә шул төрки, фарсы, гарәп телләре профессоры дәрәҗәсендәге генерал карамагында Галимҗан кучер хезмәтен башкарган имеш. Чынмы бу? Әллә бу сүзләр соңрак аның шул генерал йортына еш-еш барып йөрүләрен аклар өчен генә язылганнармы?

Ул вазифаны кайчан, кай араларда башкарган соң бу шәкерт? Җәйге каникул вакытларындамы? Юк шикелле. Чөнки истәлекләрдә аның, агасы Шакирҗан белән бергәләп, һәр җәйдә атасына кыр эшләрендә булышканлыгы бәян ителә. Укулар тәмамлануга аларны авылда көтеп алганнар. Мәдрәсәгә алар «кара көз» кергәч кенә әйләнеп кайта торган булганнар. Һәрхәлдә, истәлекләрдә шулай тасвирлана. Алайса, Галимҗан ул карт генералны кыш айларында, дәрестән соң, иkende-ахшам тирәләрендә генә атта йөрткәндерме? Ләкин шулай соңлап ул генерал кайларга гына барды икән? Морзалар клубына да, рестораннар тарафына да түгелдер мөгаен. Ара-тирә шул якындагы мәчеткә йөргәләсә генә инде. Шәкерт белән генерал юлда сөйләшкәннәрме? Сөйләшсәләр ни хакында, нәрсәләр турында? Телләр өйрәнүгә, әдәбият укуга кагылышлы әңгәмәләр булганмы? Сораулар күп, ә җавап тотарлык дәлилләр юк әлегә. Мирсалих Бикчуринның бай китапханәсе белән дә кызыксынмыйча булдыра алмагандыр бу зирәк шәкерт. Ләкин ул хакта да истәлеккә язмаганнар. Ә «ике ел генералның кучеры булды» дигән сүзләр бер туганының истәлегендә теркәлгән. Галимҗан белән бер үк елларда Оренбург мәдрәсәсендә укыган Шакирҗан агасы да, туганнан туган агасы һәм якын әшнәсе Мохтар Ибраһимов та, никтер, ул дәверне бик сиран искә алалар. Моның сәбәбе бер генә, минемчә: 1917 елдан соң тормышның һәм шуңа бәйле рәвештә дөньяга карашның кинәт үзгәрүе, кискен борылыш ясавы.

* * *

Һәм шушы үзгәреш әдип биографиясендәге икеле-микеле уйлануларга урын калдырган тагын бер вакыйгада нык чагыла. Гыйрфан мулланың Галимҗанны «Вәлия» мәдрәсәсенә урнаштыру мәсьәләсендә. Истәлекләрдә һәм, хәтта ки, күп кенә сораулар тудырган бер романда да бу вакыйганы «малайның чирләшкә булуы» белән бәйлиләр. Ай-һай, шулаймы икән? Һич кенә дә ышандырмый торган дәлил. Соңыннан, дөньяга карашлар ныk үзгәргәч уйлап чыгарылган сәбәпкә охшап тора бу. Имештер, ике улын да тиз арада дан-шөһрәте тирә-якка таралып өлгергән «Хөсәения» мәдрәсәсендә укытырга дип алып килә дә мулла, кечесен, ул чирләшкә, дигәч, бозыграк һавалы, начаррак тәрбияле икенче бер уку йортына урнаштырып китә. Никтер, моңа бик үк ышанасы килми, һәм ышанмау өчен кайбер сәбәпләр дә юк түгел.

Г. Ибраһимов исеме кабат халыкка кайтарылганнан соң, күрше ике республика матбугатында аңа багышлы бик күп истәлек язмалары дөнья күрде. Алар бигрәк тә туган ягында – Башкортстанда дүрт-биш ел дәвамында чыга тордылар. Истәлек авторларының күпчелеге Галимҗан белән яшьли үк таныш булган, бергә үскән, бергә укыган кешеләр иде. Хәтеремдә, ул истәлекләрнең кайберләрендә Гыйрфан мулланың уртанчы улын аеруча бер ярату белән яратканлыгы һәм кечкенәдән үк аны үзе урынына мулла итәргә өметләнүе дә тасвирланган иде.

XIX гасыр урталарында ук инде зыялырак катлам кешеләре арасында милләтебезнең киләчәк яшәешенә аек бер караш туа. Ул карашның асылы – яшь буынны үз чорлары таләпләренә хас килердәй рәвештә тәрбияләү, заманча белемле итүдән гыйбарәттер. Ул вакытта күңелләрдә йөргән төп фикерне Фатих Кәрими соңрак бер әсәрендә болайрак бәян итә: татарда указлы муллалар ишле генә, указсыз муллаларга кытлык хәзер, ди. Ягъни, татарга хәзер заманча белемле кешеләр күбрәк кирәк, димәкче. Риза Фәхретдиновның «Әхмәт бай» китабында китерелгән мәгълүматка караганда, һәр елны мәдрәсәне уңышлы тәмамлаган унике шәкерткә укуларын башка уку йортларында, шул исәптән төрле илләрдәге институт, университетларда дәвам иттерү өчен унике стипендия билгеләнгән була. Һәм байтак шәкерт, шушы форсаттан файдаланып, Истанбул, Бәйрут, Томск, Петербург институт вә университетларында Европа дәрәҗәсендә белем үзләштерүгә ирешәләр.

Ләкин Хөсәеневләрне бөтенләй диннән язган, дәһри затлар итеп күзаллау да дөрес булмас. Шулай ук алар үз акчаларына, нәселләренең бер вәкиле булган Мөхәммәтвәлигә фәкать дин әһелләрен әзерләүгә йөз тоткан мәгълүм «Вәлия» мәдрәсәсен ачтырганнар. Миңа калса, менә ни өчен Гыйрфан мулла йомшаграк холыклы зур улы Шакирҗанны, мөгаллим итәргә

теләп, дөньяви белем бирүче «Хөсәения»гә илтеп тапшыра да, үзенең ата-бабаларыннан килгән вазифаны дәвам итәргә тиешле Галимҗанны исә «заманнан артта калганрак» «Вәлия» мәдрәсәсенә урнаштыра. Әмма язмыш һәм Галимҗанның зирәк акылы атасының киләчәк хыялларын чәлпәрәмә китереп ташлый. Галимҗан бу мәдрәсәгә аяк баскан елларда ук инде Оренбург төбәге үзенең әдип вә шагыйрьләре белән дан казанган төбәккә әверелгән була. Бу төбәктә яшәп иҗат иткән Утыз Имәни, Һибәтулла Салихов, Шәмсетдин Зәкиләрдән соң татар прозасының башлангыч әсәрләрен биргән Шакир Мөхәммәдев, Фатих Кәрими, Риза Фәхретдинов, Тимерша Соловьев, Ярулла Вәлиевләрнең иҗат җимешләре дөнья күрә. Ул әсәрләр шушы төбәк халкы арасында киң таралган була. Әлбәттә инде, менә шушы үрнәкләр Солтанморат авылының булачак мулласын юлдан яздыралар. «Вәлия»дә уку чорында Галимҗан шушы иҗади шәхесләрнең күпчелеген күреп йөргәндер, алар белән якыннан таныш кешеләр белән дә аралашкандыр. Татар зыялысы Мирсалих Бикчурин да шәһәрдәге милләттәшләре белән аралашмыйча тормагандыр. Ул дәвердә шәһәрдә татар морзаларыннан элекке Укытучылар мәктәбе башлыгы Усман Саинов, «Хөсәения»нең рус теле һәм әдәбияты укытучысы, җырчы Гайса Еникиев, Төркия зыялылары һәм әдипләре белән аралашып кайткан Закир Рәмиевләр була. Шул ук елларда шәһәрдә беренче саф татарча басмаханә дә ачыла. Мөхәммәтвәли мулланың атасы Гани бай һәм бертуган Рәмиев байлар ярдәме белән 1901 елда Гыйльман Кәримов оештырган милли типографиядә дистәләгән татарча китаплар чыга башлый. Димәк ки, булачак күренекле язучы Галимҗан Ибраһимов белән аның каләмдәше вә «Вәлия» мәдрәсәсе буенча шәриктәше Шәһит Әхмәдиев күңелендә тәүге иҗат бөреләре шушы чорда бөреләнә башлаган булырга тиеш.

* * *

Нәшриятта эшләвемнең соңгы (1993) елында, миңа Галимҗан Ибраһимовка бәйле мирасның тугызынчы томын тәшкил итәргә тиешле кульязмалар белән танышырга туры килде. Ул кульязмаларны мәгълүм әдәбият белгече, филология фәннәре кандидаты Фатыйма Ибраһимова әзерләгән һәм бик тәфсилле генә «Соңгы сүз» өлешен дә язган иде. Бу томга Г. Ибраһимовның үз кулы белән егерменче елларда русча язган берничә автобиографиясенең татарчага күчермәләре, хатлары һәм башка төр язма истәлекләре керәчәк иде. (Ул китап «Фикер» нәшрияты тарафыннан 2000 елда нәшер ителде.) Ләкин ул документлар һәм язмалар Г. Ибраһимовның 1915–1920 еллар аралыгындагы тормышын һәм иҗатын бик аз чагылдыралар. Аеруча аның сул эсерлар фиркасындагы эшчәнлегенә бәйле архив материалларының булмавы аяныч. Чөнки бу томга керәсе материаллар әле илдә коммунистлар партиясе җитәкчелек иткән чорда тупланганнар һәм, табигый инде, әдипнең биографиясен шул фирка таләпләреннән чыгып «дөресләргә» тырышу үзен нык сиздерә иде. Мәгълүм ки, 1917 елгы Февраль инкыйлабыннан соңгы бер елда гына да Г. Ибраһимов татар халкының киләчәк язмышын хәл иткән берничә зур корылтайда катнаша, сул эсерлар платформасына бәйле рәвештә анда нотыклар сөйли. Шул ук вакытта ул үз катнашында нәшер ителгән «Ирек», «Безнең юл» газеталарына җыелыш-съездлардан күләмле мәкаләләр җибәреп тора. Димәк ки, шул чор матбугатында һәм беркетмә-документларында аның актив эшчәнлегенең эзләре сакланган булырга тиеш. Һәм алар белән дә бүгенге көн укучысы танышырга хаклыдыр, дип уйлыйм.

Мәрхүм Исмәгыйль ага Рәмиев миңа (һәм Әмирхан ага Еникигә) Галимҗан Ибраһимовны 1917 елның декабрендә Оренбург каласында уздырылган башкорт кардәшләребезнең тарихи корылтаена озата барганлыгын тәфсилләп бер сөйләгән иде. Ул корылтай мөстәкыйль Башкорт автономиясен төзү карарын кабул итә һәм аның чикләрен билгели. Ул корылтайда Г. Ибраһимов кунак буларак кына катнашмый, берничә мәртәбә мөнбәргә күтәрелеп, кайнарланып нотыклар сөйли. Без бүген аның анда нәрсәләр сөйләгәнен белергә тиешме? Шуннан соң гына ул шәхес безнең алда тулырак ачыласы түгелме? Ә бит аның биографиясендә мондый ачыкланмаган, барланмаган фактлар байтак әле.

Мәсәлән, аның 1919 елның җәй башында өч-дүрт айга сузылган «югалып торуы». Хәзерге юрама буенча, бу айларда ул Колчак гаскәрләре биләгән Себер тарафларында разведкада йөри. Ләкин гомерендә солдат киеме кимәгән, мылтык тотып карамаган бу кеше адмирал Колчак армиясенең нинди серләрен ачыклады да, нindiрәк мәгълүматлар туплады икән соң? Әллә инде унсигезенче елның җәендә үзенә карата гаделсез гамәлләр кылынуын тойганнан соң, башка кайбер зыялыларыбыз кебек, шул исәптән Габдулла Кариев үрнәгендә бер тын почмакта яшәп, илдә кайсы көчнең җиңәсен көтеп, әдәби иҗат белән генә шөгыльләндеме икән?

1918–1919 елларда Себер тарафларында яшәп алган башка зыялыларыбыз исемлеге дә бар ич әле. Дөрес, аларның күпчелеге сәяси качкыннар, сәяси көрәшчеләр (ерак Петропавел шәһәрендә төпләнеп, милли мөстәкыйльлек өчен көрәшүче, большевикларга каршы торучы төркем вәкилләре) булган.

Истәлекләрдән күренгәнчә, бу айларда Галимҗан да ерак Кызылъяр (Петропавел) шәһәренә үк барып җиткән. Шул ук шәһәрдә большевиклар тарафыннан Уфадан сөреп чыгарылган Милли Идарәбез эшләп килә. Анда «Идел – Урал штатлары»н төзергә «маташкан» төп көчләрдән Гаяз Исхакый, Фоат Туктаров, Габделбари Баттал, Закир Кадыйри һәм башка шәхесләр тупланган була. Шул шәһәрдә алар берничә ай дәвамында «контрреволюцион» дип бәяләнгән «Маяк» газетасын да нәшер итәләр. Милли Идарәнең ул вакыттагы рәисе, сул эсер Ибнеәмин Әхтәмев белән дә Галимҗан күптәннән таныш була. Әмма әдипнең үз истәлекләрендә дә, башкалар язмаларында да бу кешеләрнең берсе дә телгә алынмый.

Шул ук вакытта диярлек, Петропавел каласында Галимҗанның күптәнге дуслары, фикердәшләре Әхмәт Байторсынов, Мәгъҗан Җомабаев һ. б.лар мөстәкыйль казакъ мохтариятен төзү эшләре белән әвәрә киләләр. Аларның Алаш Урда «хөкүмәте» большевикларны Казакъстанга үткәрмәү өчен канлы көрәш алып бара. Һәм нәкъ шул көннәрдә, имештер, иңенә олаучы чыбыркысын аскан Галимҗан Ибраһимов шушы хәтәр Кызылъяр шәһәренә ни-нәрсә өчендер килеп чыга. Совет хакимиятенең Колчак гаскәре биләгән җирләрдәге шымчысы рәвешендә. Шулай булдымы икән

соң? Ай-һай, бу фараз мине бер дә ышандырмый. Галимҗан Ибраһимов ул дәрәҗәдә йөрерлек беркатлы кеше түгел ләбаса. Классик әдибебезнең «тибешкә калдырылган» әлеге сәясәтчеләр тирәсенәрәк елышыр нияте булмадымы икән дигән «көфер» уйлар да башка килгәли.

* * *

Соңгы сүз итеп шуны гына өстисе кала: олуг әдибебез биографиясенә һәм җәмәгать эшчәнлегенә караган «ак тап»лар бик күп әле. Аның иҗатын барлауга күп көч куйган абруйлы галим Мансур Хәсәнев, күренекле әдип Афзал Шамов, Гөлсем апа Мөхәммәдова Галимҗан Ибраһимов исемен кабат халкыбызга кайтару юнәлешендә зур эш башкардылар. Әдипнең мирасын алар барлаган дәвердә барысын да ачыктан-ачык язарга мөмкинчелек булмады. Яшерен архивлар ишекләре әле хәзер дә теләр-теләмәс ачылалар. Уйлавымча, әлеге архивларда шушы язма каһарманына бәйле күп кенә хәзинә сакланган булырга тиеш. Бүген безнең алда торган төп бурыч – аларны барлау, бастырып чыгару... Классик әдибебезнең тулы йөзен тудыру...

# Г. ИБРАҺИМОВ МИРАСЫ ҺӘМ ӘДӘБИ БАРЫШ

## Г. СӘГЪДИ, Г. НИГЪМӘТИ ХЕЗМӘТЛӘРЕНДӘ Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ ИҖАТ КОНЦЕПЦИЯСЕ

*Э. Р. Галеева (Казан)*

В данной статье на примере трудов известных татарских литературоведов 1920–30-х годов Г. Сагди и Г. Нигмати прослеживается система взглядов татарских ученых относительно романтической творческой концепции Г. Ибрагимова в начале ХХ века, включая 20-е годы. Выявляются ценные научные положения и выводы, высказанные ими в связи с изучением эволюции творчества писателя, основных его этапов, идейно-эстетических особенностей.

Г. Ибраһимов иҗатын фәнни нигездә системалы өйрәнә башлау 1920–30 нчы еллар әдәбият белемендә күзәтелә. Бу чорда ул бай әдәби иҗат җимешләре белән танылган зур язучы, милли иҗтимагый-мәдәни хәрәкәтнең күренекле лидеры-җитәкчесе, татар даирәсендә генә түгел, бәлки төрки дөньяда, Россиякүләм масштабта билгеле шәхес. Татар әдәбият фәнендә бу затлы язучы иҗаты турында төпле сүз әйтү, әдәби тәнкыйтьтә моңа кадәр күренә, бирелә килгән бәяләрне гомумиләштерү, фикер-карашларны туплап-җыйнап билгеле бер фәнни эзлеклелеккә салу ихтыяҗы барлыкка килә. Г. Ибраһимов иҗатын концептуаль өйрәнүгә этәргән фактлар һәм факторлар да җитәрлек булган: язучы иҗаты үзенең пигында, әдип иҗаты буенча фәнни гомумиләштерүләр ясау өчен кирәкле булган вакыт дистанциясе дә инде үтелгән, татар мәдәни-тарихи, әдәбият белеме фәнендә әдәбиятны, язучы иҗатын өйрәнүнең методологик, теоретик, методик нигезләре һәм принциплары ачыкланган. Моңа тагын 1928 елда Г. Ибраһимовның 20 еллык иҗат юбилее туры килү фактын да өстик. Ул зурлап, ил күләмендә билгеләп үтелә: Мәскәүдә Фәннәр академиясендә, Казанда Татар дәүләт академия театры бинасында Г.Ибраһимовның иҗат эшчәнлегенә багышланган тантаналы чаралар, кичәләр уза һәм анда илкүләм билгеле зур-зур фән һәм сәнгать әһелләре катнаша һәм чыгышлар ясый. Юбилеена туры китереп, 1929 елда Казанда «Яңалиф» нәшриятында Г. Ибраһимовның 2 томлык сайланма әсәрләре басылып чыга. Әле шул чорда ук, үзе исән вакытта, җәмәгатьчелек тарафыннан Г. Ибраһимов татар классик матур әдәбиятын тудыручы язучы буларак бәяләнә һәм аңа татар әдәбиятын, мәдәниятен үстерү өлкәсендәге хезмәтләре өчен хөкүмәт тарафыннан «Хезмәт герое» дигән мактаулы исем бирелә. Соңга таба әсәрләре рус, казакъ, башкорт һ. б. телләрдә дөнья күрә башлый. Хезмәт бәйрәме елында үзәк һәм республика матбугаты битләрендә Г. Ибраһимов турында бик күп мәкаләләр дөнья күрә. 20 еллык иҗат бәйрәменә багышлап 1928 елда Казанда Татарстан дәүләт нәшриятында «Галимҗан Ибраһимов» дигән махсус фәнни юбилей җыентыгы басылып чыга. Анда татар (Г. Сәгъди, Г. Нигъмәти, Г. Рәхим, С. Борхан, М. Максуд, Г. Толымбай һ. б.), рус (П. Коган, А. Самойлович, И. Бороздин һ. б.) галимнәре, язучылары, тәнкыйтьчеләре тарафыннан Г. Ибраһимовның күпкырлы эшчәнлегенә бәя биреп язылган фәнни мәкаләләр урнаштырыла. Шул рәвешле Г. Сәгъди, Җ. Вәлиди, Г. Нигъмәти, Г. Гобәйдуллин кебек әдәбият галимнәре һәм тәнкыйтьчеләре хезмәтләрендә, мәкаләләрендә әдип иҗатын анализлау, концептуаль тикшерү юнәлешендә монографик планда тәүге тәҗрибәләр ясала башлый. Аларның бер өлеше әдипнең әдәби, гыйльми, иҗтимагый эшчәнлегенә егерме ел тулу датасына туры китереп махсус язылган һәм бастырылып чыгарылган булса, кайберләре шул чордагы әдәби барышны анализлау белән бәйле рәвештә, әдәби процессның билгеле бер этабында Г. Ибраһимовның әдәби иҗат казанышларына фәнни-тәнкыйди анализ ясау тәҗрибәсе буларак языла һәм дөнья күрә. Монда без Г. Сәгъдинең «Татар әдәбияты тарихы» (1926) дигән хезмәтендәге Г. Ибраһимов иҗатына багышланган монографик бүлекне, аның ук «Галимҗан Ибраһимов һәм аның әдәби иҗатлары» (1928), «Галимҗан Ибраһимов иҗатында типлар эволюциясе» (1928) кебек әдипнең юбилей җыентыгына кергән күләмле мәкаләләрен; Г. Нигъмәтинең Г. Ибраһимов турында язылган тулы бер мәкаләләр циклын («Г. Ибраһимов һәм аның әдәби иҗат юлы турында», 1932; «Галимҗан Ибраһимов әсәрләрендә революция мотивлары», 1928; «Галимҗан Ибраһимовның яңа әсәре», 1929; «Бу томда Галимҗан Ибраһимов безгә ниләр биргән?», 1929, – бу мәкалә язучының егерме еллык иҗат юбилее уңае белән чыгарылган «Галимҗан Ибраһимов әсәрләре»нең II томына (Казан, Яңалиф, 1929) сүз башы итеп бирелгән), шулай ук Җ. Вәлиди, Г. Газиз, Ф. Сәйфи-Казанлы, Г. Толымбай, Х. Вәли һәм башкаларның шул чор татар матбугатында дөнья күргән мәкаләләрен, хезмәтләрен күздә тотабыз. Укучыга тәкъдим ителгән әлеге мәкаләдә, телгә алынган хезмәтләр арасыннан, атаклы әдәбият галимнәре Г. Сәгъди һәм Г. Нигъмәти тарафыннан язылганнарын тикшерү объектына чыгарабыз, чөнки алар турыдан-

туры Г. Ибраһимов иҗатын монографик планда тикшерүгә багышланган һәм аның иҗат концепциясен ачыклау юнәлешендә язылган тәүге җитди фәнни тикшеренүләр булып торалар. Мәкаләбездә әлеге татар галимнәренең хезмәтләрендә, мәкаләләрендә әдипнең әдәби иҗат эволюциясе, иҗат концепциясе хакындагы фәнни карашларын, теоретик фикерләрен күзәтүне максат итеп куябыз.

«Галимҗан Ибраһимов һәм аның әдәби иҗатлары» дигән мәкаләсендә (1) Г. Сәгъди, аның үз сүзләре белән әйтсәк, «әдипнең 20 еллык әдәби-иҗади гомерендәге (ягъни беренче әсәре басылып чыккан 1907 елдан башлап 1928 елга хәтле. – *Э. Г.*) бөтен үсү-камилләшү баскычларын карап, тикшереп чыкты». Хезмәт өч бүлектән тора. Беренче бүлегендә автор Г. Ибраһимовның тәрҗемәи хәлен яктырта, монда Г. Ибраһимовның туган җире һәм чыгышы, уку-белем алу баскычлары, тәрбиясе һәм гыйлеме, әдәби, гыйльми хезмәте, журналистлык, педагоглык, революцион эшчәнлеге хакында мәгълүматлар бирелә. Хезмәтнең икенче бүлегендә Г. Ибраһимов әдәбият мәйданына чыккан замандагы татар дөньясы, андагы әдәби-иҗтимагый хәрәкәтләр, мохит, ягъни XIX гасыр ахыры – XX гасыр башындагы тарихи-иҗтимагый-мәдәни-әдәби барышка этрафлы анализ ясала. Хезмәтнең өченче бүлегендә автор язучының әдәби иҗаты эволюциясен тикшерүгә керешә. Г.Сәгъди Г.Ибраһимовның әдәби иҗатын өч чорга бүлеп өйрәнә: беренче чор: 1907–1910 еллар: икенче чор – 1910–1916 еллар һәм өченче чор – Февраль, Октябрь революциясеннән соңгы заман. Мәгълүм булганча, әлеге бүленеш соңрак Г. Ибраһимов иҗатын өйрәнүче галимнәребез хезмәтләрендә дә (М. Хәсәнов һ. б.) төп нигез итеп алынды. Г. Сәгъди Г. Ибраһимовның һәр чор әдәби иҗатын характерлауга аерым-аерым туктала. Мәкаләсенең башында ук Г. Сәгъди, декларатив рәвештә, романтизмны идеализм күренеше дип кире каккан шул чор идеологиясе шаукымына бирелеп, әдип иҗатын гомумән алганда тулаем реализм юнәлешендә үсеп барды дип белдерергә омтылса да, анализ барышында үзе үк үз тезисына каршы килеп, объектив рәвештә Г. Ибраһимовның XX гасыр башындагы иҗатының романтизм эстетикасы юнәлешендә үсеп баруын күрсәтү һәм дәлилләүгә килеп чыкты. Г. Ибраһимовның «татар нәфис әдәбиятында яңалык, яңа бер максат тудыручы бер әдип икәнен»ен күрсәтү өчен Г. Сәгъди әдипнең иҗат чорларын караганда «реалистлык, көрәшчелек» сыйфатлары белән бергә, романтизмның күбрәк урын ала баруын танырга мәҗбүр булды, Г. Ибраһимов та «реализмның киресе булган романтизм ягына тайпылу хәрәкәте» турында язды. Әдипнең сәнгать концепциясендә романтизм белән янәшә реализм, сентементализм, натурализм, символизм алымнарының, башка модернистик сурәтләүләрнең дә урын тотуын сиземләвен белдерде, әлегә бик тыйнак рәвештә генә булса да аларның әдип иҗатының төрле чорларында төрле нисбәтләрдә үзара үрелеп, бәйләнеп үсеп баруы турындагы кызыклы перспективалы фикер орлыкларын салып калдырды. Г. Сәгъдинең романтизмны сәнгать күренеше буларак тануы, бәяләве һәм аңлавы сизелә иде.Тышкы яктан караганда, романтизмга карата негатив мөнәсәбәттә торган кебек күренсә дә, эчке яктан XX гасыр башы татар әдәбиятының кайбер вәкилләре, аерым алганда, Дәрдемәнд, С. Рәмиев, М. Фәйзи, Ф. Бурнаш, бу очракта Г. Ибраһимов иҗаты турында сүз алып барганда, галим объективлык позициясендә кала алды. Мәкаләсендә Г. Ибраһимов иҗатының романтизм белән бәйле эчке хасиятләре турында язды. Романтизмны, символизмны идеализм фәлсәфи агымы күренешләре дип санаса да, бу аңа Дәрдемәнд, С. Рәмиев, Г. Ибраһимовларны классик югарылыкта торган әдип, шагыйрьләр дип тануга, аларның әсәрләрен «әдәбият энҗеләре» итеп тануга комачаулык итмәде. Шушы ук автор, әйтик, әлеге мәкаләсе басылып чыгудан ике ел элек алда язылган «Татар әдәбияты тарихы» дигән хезмәтенең (1926) Галимҗан Ибраһимов иҗатын анализлауга багышланган бүлегендә (2, 252–267) әдипнең «Яшь йөрәкләр» романын «әдипнең сентименталистлык-романтиклык дәверен кичереп торуының зур бер җимеше иде» дип бәяләде һәм татар әдәбият дөньясының, шуңа да карамастан, бу әсәрне «яратып, хәтта шаулатып каршы алуы» турында язды. «Әсәрнең сентиментализм, романтизм белән сугарылган булуы өчен мөхәррир тәнкыйтькә эләкмәде, – дип билгеләп үтте ул, – бәлки моның өчен ул татар матбугатында тәкъдир ителде» (2, 254). Дәлил өчен Г. Сәгъди тәнкыйтьче Г. Газизнең «Аң» журналының 1913 елгы саныннан алынган мәкаләсендәге түбәндәге өзекне китерде: «Юк! Мин хәзерге реалист булып азаплануны үзен ялган реализм дияр идем. Чөнки безнең хәзер милли хисебез куәтләнгән, милли музыка, халык җыры вә музыкасына әһәмият биргән, үзебезнең үткән көннәребезне артыбызга борылып карый башлаган бер заманыбыз – бездә ник романтизм булмасын? Гаребтә, мәсәлән, Германиядә дә шундый бер заман булган иде бит! Шуңар күрә мин безнең романнарыбызның күбесендә очрый торган, бигрәк тә Галимҗан Ибраһимовның әсәрләрендә табыла торган чын яхшы яклары белән булган романтизмны, чын тарихи бер вакыйга, шулай кирәк иде, шунсыз чарасыз иде, дип ышанам» (2, 254). Ягъни Г. Сәгъди үзенең фикерен Г. Газиз сүзләре белән әйтеп бирде. Ул татарда, татар әдәбиятында романтизмның җирлеге барлыгын (милли хис) таныды. Үзенең анализында Г. Сәгъди «Яшь йөрәкләр»нең «романтизм дулкыннары астында калып, шуның тәэсире белән язылуга карамастан» (2, 254), идея-художество ягыннан шактый югары дәрәҗәдә торган бер әсәр булып чыгуына игътибар итте. Бигрәк тә аны әсәрнең тирән психологизмы, «эчке рухи дулкыннар»ның «бик оста тасвир ителүе» сокландырды. Бу сыйфатлар нәкъ менә аның романтизм әсәре булуыннан килеп чыга иде. «Романда күренгән бу хосусият, – дип язды ул, – татар матур әдәбиятында үзенең тулылыгы белән беренче мәртәбә күренгән бер хәл иде. Әдип бу романы белән үзен чыннан да эчке дулкыннарны тасвирлауда да көчле әдип икәнен күрсәтте» (2, 255). Г. Сәгъди Г. Газиз тәнкыйтенең дә язучы иҗатындагы әнә шул үзенчәлеккә – «рухның дулкынын, аның буранын яисә ялтыравыклы күл өсте кебек тын булган заманын» тасвирлау «муаффәкыяте»нә игътибар иткәнлеген тотып алды. Г. Сәгъди «Татар әдәбияты тарихы» хезмәтендә, шулай ук Җ.Вәлидинең дә әдәби-тәнкыйть, әдәбифәнни хезмәтләрендә («Вакыт» газетасында басылган мәкаләләрендә, «Очерк истории образованности и литературы татар» (М.-СПб., 1923) хезмәтендә) Г. Ибраһимовның бу әсәренең «татар тормышының төрле катлауларыннан алынган типларга бай булуы, тагын да әһәмиятлесе – «анларны бигрәк тә эчке яклары, рухани

халәтләре белән күрсәтү хосусияте»нә игътибар итүе турында әйтеп китүне кирәк тапты. Бу уңайдан тагын шуны да билгеләп үтик, Г. Сәгъди хезмәтендә Г. Ибраһимовның әлеге романына уңай бәя биреп язган Р. Фәхретдинов, Х. Кәримов тәнкыйтьләре дә мисалга китерелә.

Г. Сәгъди Г. Ибраһимовның XX гасыр башларыннан алып, 1920 еллар азагына кадәрге вакыт аралыгындагы әдәби иҗат эволюциясен «әдәби мәсләк ягыннан реализм белән башлап, уртада сентиментализм-романтизм баскычын да атлап алып, ниһаять, үзенең элекке төп ноктасында, төп юнәлешендә – реализм һәм кыйсмән натурализм мәсләгендә нык дәвам итеп барды» диебрәк билгели. Ләкин, икенче яктан, үзе үк «Галимҗан Ибраһимовның 20 еллык әдәби иҗат эшчәнлегендә икенче чорның (ягъни унынчы еллардагы иҗатының. – *Э. Г.*) иң әһәмиятле бер хосусияте аның бу чордагы сәнгать иҗатлары һәр яктан аны татарның бөек әдибе, оста бер сүз сәнгатьчесе итеп танытырлык дәрәҗәдә югары булуындадыр» дигән фикерне дә әйтә («бу чордагы әсәрләре аның чыннан да сәнгатьчәлектә, әдиплектә үсеп, пешеп, өлгергән икәнен ачык күрсәттеләр») (1, 36). «Галимҗан Ибраһимов һәм аның әдәби иҗатлары» дигән мәкаләдә, нәтиҗә буларак бирелгән соңгы җөмләдә Г. Сәгъди үткәргән тагын бер әһәмиятле фикер шул: «Галимҗан Ибраһимов татар сүз сәнгатендә үзенә бөтенләй аерым бер мәктәп тудырды» (1, 47).

Г. Сәгъди Г. Ибраһимовның XX гасыр башындагы иҗатында «әдипнең оста сәнгать каләме аркылы татар тормышының һәр төрле катлавы сәнгатьле сурәт алды» дип, дөрес билгеләп үтте, аның бик хаклы язуынча, «татарның бөтен хезмәт вакыйгалары, төрле катлавының үзара көрәшләре, интригалары, татар гореф-гадәтләре, бәйрәмнәре, туйлары, уеннары – һәммәсе бу әдип иҗатлары аркылы тулы шигъри сурәткә куелдылар» (1, 37). Мәкаләдә язучының бу этапта язылган әсәрләренең тематика-проблематикасы тикшерелә, ул иҗат иткән типлар билгеләнә. Г. Сәгъдинең «Татар әдәбияты тарихы» дигән хезмәтендә «Безнең көннәр», «Казакъ кызы», «Алмачуар», «Адәмнәр», «Кызыл чәчәкләр» әсәрләренә аерым-аерым, тулы, ләкин җыйнак анализлар бирелүе турында да әйтеп китәргә кирәк. Мондый анализлар әсәрләргә карата Г. Гобәйдуллин, Г. Рәхим, Ф. Сәйфи-Казанлы, М. Павлович, С. Җәлал, Ж. Вәлиди һ. б. әдәби тәнкыйть бәяләре белән дә аралаштырылып бирелү нәтиҗәсендә дөрес һәм объектив язылганнар.

Бу мәкаләнең соңгы дүртенче бүлеге үзе бер мөстәкыйль, кыйммәтле фәнни тикшерүдән гыйбарәт. Анда автор Г. Ибраһимов иҗатының психологизмын өйрәнүне максат итеп куйды. Мәкаләнең исеме «Галимҗан иҗатында эчке рухи яклар» дип атала (1, 42–47). Г. Сәгъди Г. Ибраһимов әсәрләрендәге психологизмның – аның үз сүзләре белән әйткәндә – «эчке рухи психологик якларның, процессларның» түбәндәге хосусиятләрен күрсәтте: 1) әдипнең вакыйгаларга тиз керүе; 2) Г. Ибраһимов әсәрләренең халык мәкальләре белән бәйләнешле булган фәлсәфи төшенчәләрне үз эченә алуы, аларда халык әкиятләре, халык легендаларының урын алуы; 3) мәхәббәт кичерешләрен сурәтләү нечкәлеге; 4) психологизм («Әдипнең үзенең төрле төстә бик тирән эчке дулкыннары, бик күп төрле баштан кичерүләре аның иҗатларында тулкынланып җәелеп яталар. Чиксез күп төрле кәеф-зәвекълар, әллә ни чаклы баскычлы тәэсирләр, бик күп нечкә төргәкле психологик моментлар үзләре аның иҗатларында калын катлаулы бер комплекс тудыралар»); 5) күп типларның рухи-психологик планда бирелүе; 6) геройның сөйләм үзенчәлегенең аның характерына туры китереп бирелүе; ... 10) геройның рухи хәлләрен табигать күренешләренә мөнәсәбәтле рәвештә сурәтләү; 11) «Әсәрләренең күбесендә табигать хадисәләреннән берәр төрле охшату алу белән башлануы. Бу хадисәләрнең күбесенең куркынычлы яисә рәмезле – символлы булуы» (Г. Сәгъди «Яшь йөрәкләр» һәм «Безнең көннәр», шулай ук «Кызыл чәчәкләр» әсәрләрен мисал итеп күрсәтә). Г. Сәгъдинең хаклы билгеләп үтүенчә, Г. Ибраһимов әсәрләре «үзләренең эчке-рухи яклары белән шулкадәр киң, тирән һәм күп катлаулылар ки», бу мәсьәлә үзе аерым бер тикшерүне сорый.

Г. Сәгъдидән аермалы буларак, Г. Нигъмәти Г. Ибраһимов турындагы мәкаләләре циклында ачыктан-ачык Г. Ибраһимовның революциягә кадәр романтизм юнәлешендә иҗат итүен әйтеп чыкты. Ә бу әле 1920 еллар өчен көтелмәгән, ләкин перспективасы зур булган мөһим әһәмиятле момент иде. «Галимҗан Ибраһимовның бу ун ел эчендә чыккан әсәрләре, – дип язды ул, – йә азмы-күпме романтизм буявына сугарылып, яки бөтенләй шул юнәлештә (“Яшь йөрәкләр”) язылган. Һәрхәлдә бу заман Галимҗан Ибраһимов әдәби стилендә романтизм элементлары характерлы урын тота» (3, 74). Бу фикерне соңрак татар әдәбият галимнәре Р. Ганиева, А. Әхмәдуллин, Ф. Галимуллин һ. б. алга таба дәвам итеп, тирәнәйтеп, үстереп җибәрделәр. Г. Ибраһимов иҗатын өйрәнгән галимнәрдән Г. Халит, М. Хәсәнов, И. Нуруллин Г. Ибраһимовның бу чор иҗатында романтизмны мәгърифәтчелек реализмы, натурализм, тәнкыйди реализм элементлары белән үзара катлаулы мөнәсәбәттә торучы үзенчәлекле сәнгать күренеше дип бәяләделәр. Г. Халит, бу мөнәсәбәттә хәтта рус галиме Г. Фохт терминын кулланып, Г. Ибраһимов иҗатында «романтик реализм» күренеше хакында сүз алып барды. Г. Фохт рус әдәбиятында А. Чехов, В. Короленко, В. Гаршин кебек язучылар иҗаты мисалында романтизм эчендә социологик агым, психологик романтизм, мәгърифәтчелек романтизмы юнәлешләрен аерып чыгарган иде.

«Г. Ибраһимов һәм аның әдәби иҗат юлы» дигән мәкаләсендә Г. Нигъмәти, беренчеләрдән булып, «Яшь йөрәкләр» романында әдәби образларның романтик гомумиләштерү алымы белән эшләнүен, алардагы индивидуаль, шәхси сыйфатларның романтик типлаштырылып, гомумиләштерелеп, үстерелеп, көчәйтелеп бирелүен күрсәтте. Г. Нигъмәти шулай ук бу әсәр композициясенең геройларның психологиясен чагылдыруга җайлаштырылып, туры китерелеп төзелгән булуына игътибар итте. Романда «ертык дөнья» романтик идеясенең, концепциясенең бирелүе, ягъни дөньяның аерым-аерым төрле дөньялардан торуын, анда матурлык, мәхәббәт, сәнгать, табигать дөньясының да, явызлык, сугыш, үлем, төрле фаҗигаләрнең дә булуын күрсәтү әдип Г. Ибраһимовның романтик дөнья концепциясенә туры килә иде.

Г. Нигъмәти «Яшь йөрәкләр» романындагы тел-стиль чараларының да аерым романтик характерына туры килүен билгеләп үтте. Г. Нигъмәти Г. Ибраһимовның

«Яшь йөрәкләр» романын, андагы романтизмны сәнгать законнары күзлегеннән караганда татар әдәбиятының гүзәл күренеше дип бәяләде. «Безнең көннәр» әсәренең дә романтизм кысаларында язылганлыгы турында онытмаска кирәклекне әйтте ул һәм әлеге әсәргә карата биргән тирән анализында әдипнең романтизм концепциясе күздә тотылуы күренде. Г. Нигъмәти «Безнең көннәр» романында (икенче вариант) романтик-реалистик концепциясенең чагылышын күрсәтергә омтылды.

Нәтиҗә ясап, 1920–30 еллар татар галимнәре Г. Сәгъди, Г. Нигъмәти һ. б. хезмәтләрендә Галимҗан Ибраһимов турындагы фән үзенең башлангычын алды, дип әйтергә мөмкин. Шул чорда әдипнең иҗат эволюциясен өйрәнү, иҗат этапларын билгеләү, аларның идея-эстетик үзенчәлекләрен ачыклау, иҗат концепциясен тикшерү юнәлешендә шактый кызыклы, фәнни перспективалы мөһим фикерләр әйтелде. Ул фикерләр алдагы буын татар галимнәре тарафыннан тагын да үстерелде һәм тирәнәйтелде. Катлаулы һәм каршылыклы булуга карамастан, 1920–30 еллар (беренче яртысы) милли әдәби фәнни фикер мирасы Галимҗан Ибраһимов турындагы фәннең ачыкланып бетмәгән проблемаларын хәл иткәндә әле бүген дә потенциалы ачылып бетмәгән байлык булып кала.

ӘДӘБИЯТ

1. Сәгъди Г. Галимҗан Ибраһимов һәм аның әдәби иҗатлары // Галимҗан Ибраһимов. – Казан: Татарстан дәүләт нәшрияты, 1928. – Б. 13–47.

2. Сәгъди Г. Татар әдәбияты тарихы. – Казан: Татарстан дәүләт нәшрияты басмасы, 1926.

3. Нигъмәти Г. Г. Ибраһимов һәм аның әдәби иҗат юлы турында // Яңалиф. – 1932. – № 6–7. – Б. 105–113; № 8. – Б. 71–88.

4. Нигъмәти Г. Бу томда Галимҗан Ибраһимов безгә ниләр биргән? // Г. Нигъмәти. Сайланма әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1958. – Б. 55–72.

5. Галимҗан Ибраһимов. 20 еллык әдәби, гыйльми-иҗтимагый хезмәт бәйрәменә каратып чыгарылган гыйльми-тәнкыйди җыентык. – Казан: Татарстан дәүләт нәшрияты басмасы, 1928. – 195 б.

# ПРОЗА ҺӘМ СӘХНӘ: РЕЖИССЕР П. ИСӘНБӘТ СӘХНӘЛӘШТЕРҮЕНДӘ Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ «ТАТАР ХАТЫНЫ НИЛӘР КҮРМИ?» ПОВЕСТЕ

***М. Г. Арсланов (Казан)***

В статье анализируется спектакль «Судьба татарской женщины» Театра имени Г. Камала, поставленный режиссером Празатом Исанбетом по одноименной повести Г.Ибрагимова в 1978 году, определяются принципы взаимодействия прозы и сцены, мизансценирования, решения сценического пространства и некоторых образов постановки.

Татар театрлары репертуарында проза әсәрләре артык еш кунак түгел. Үткән егерменче гасырның соңгы яртысын алсак, мәсәлән, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында татар прозасының бары берничә әсәре («Акчарлаклар» – Ш. Камал, «Агыйдел» – М. Әмир, «Чикләвек төше» – Г. Ахунов, «Өч аршин җир», «Яра» – А. Гыйләҗев һ. б.) дөнья күрә. Ә бит рус театрларының шул еллардагы эш тәҗрибәсенә күз салсак, иң уңышлы дип саналган спектакльләрнең күбесе проза әсәрләре нигезендә куелган булуын күрербез. Моңа мисал: «Ат тарихы» Ленинград Зур драма театрында (Л. Н. Толстойның «Холстомер» повесте буенча), «Петербург төшләре» – «Моссовет» театрында (Ф. М. Достоевскийның «Җинаять һәм җәза» романы буенча), «Яр» – Кече театр сәхнәсендә (Ю. Бондарев романы буенча), «Декамерон» – Н. В. Гоголь исемендәге театрда (Бокаччо романы буенча), «Наташа Ростова» – Мәскәү яшь тамашачылар театрында (Л. Н. Толстойның «Сугыш һәм тынычлык» романы буенча), «Балалайкин и К» – «Современник» театрында (М. Е. Салтыков-Щедринның «Заманча идиллия» повесте буенча), «Тын Дон» – Ленинград Зур драма театрында (М. Шолохов романы буенча), «Мценский өязе леди Макбеты» – В. Маяковский исемендәге театрда (Н. С. Лесков әсәре буенча) куелган спектакльләр. Шулар рәтендә тагын бөтен театрларда зур уңыш белән Б. Васильевның «Аккошларга атмагыз», «Ә таңнар монда тыныч...», В. Распутинның «Авылдашлар, акча кирәк», «Соңгы срок», «Яшә һәм хәтерлә» кебек әсәрләрнең инсценировкаларын санарга була. Шулай булгач, нигә соң безнең Республика театрлары сәхнәләрендә проза әсәрләре сирәк куела? Бәлки, андый дәрәҗәгә лаеклылары юктыр? Г. Бәшировның «Җидегән чишмә», А. Расихның «Сынау», Ш. Бикчуринның «Каты токым», Г. Ахуновның «Идел кызы», Х. Сарьянның «Бер ананың биш улы», И. Нуруллинның «Аккан су юлын табар» кебек роман һәм повестьларын, Ә. Баянов, М. Мәһдиев, А. Гыйләҗевның прозасын укыгач, моның алай түгеллеге аңлашыла. Аларның һәркайсы күтәрелгән проблемаларының актуальлеге, вакыйгаларның драматик киеренкелеге, характерларга байлыгы, үзенчәлекле стиле белән сәхнәгә куелуга лаек. Алай булгач, бәлки инсценировкалар буенча куелган спектакльләрне татар тамашачысы бик үк яратып бетермидер? Минзәлә һәм Татар дәүләт драма һәм комедия театрларында Г. Ахуновның «Ардуан батыр» һәм «Хәзинә», Яр Чаллы театрында Г. Исхакыйның «Кәләпүшче кыз» романнары буенча эшләнгән спектакльләрнең уңыш белән бару факты гына да мондый сорауның урынсызлыгын дәлилли.

Сәхнәгә проза әсәрләренең сирәк куелуын бер генә сәбәп белән аңлату дөрес булмас. Бу җәһәттән күп кенә объектив һәм субъектив сәбәпләр табарга булыр иде. Шуларның берсе – Республика театрларында эшләүче режиссерларның әдәбият белән танышлыгы, якынлыгы тиешле югарылыкта түгел. К. Л. Рудницкий үзенең «Сәхнә һәм проза» дигән хезмәтендә проза әсәрләрен сәхнәгә күтәрүдә беренчелекне режиссерларга бирә. Аның фикеренчә, режиссер проза әсәрен үзенчә аңлап, автор биргән материал нигезендә үз сәхнә конструкциясен корганда гына уңышка ирешә ала (1). Башкача булганда, талантлы артистлар коллективы да, уңышлы

табылган сәхнә бизәлеше дә, уен өчен романнан яки повестьтан сайланган отышлы эпизодлар да аны коткара алмый. Бу автор белән тулысынча килешкән хәлдә, аны дәвам итеп бер генә фикер әйтәсе килә. Әгәр режиссер прозаны сәхнәгә чыгаруда беренче җаваплы кеше икән, ул иң элек аның үрнәкләре белән якыннан таныш булырга, аның торышы, казанышлары белән даими кызыксынып барырга тиеш, шул очракта гына ул үз иҗатына аваздаш мотивлар, темалар таба ала. Әгәр сурәтләнгән вакыйгалар, характерлар, кузгатылган проблемалар дулкынландырса, театрның репертуар линиясен билгеләүче буларак, режиссер әлеге әсәрне сәхнәгә күтәрү мөмкинлеген ничек тә таба алыр иде. Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында режиссер П. Исәнбәт тарафыннан Г. Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» повесте буенча эшләнгән спектакль – бу фикернең дөреслеген раслаучы ачык дәлил.

XX гасыр башларында ук язылган бу әсәр замана режиссерын кай яклары белән кызыксындыра алган соң? Нинди сурәтләү чаралары, нинди алымнар повестьның сәхнә тормышына юлдаш булганнар?

Әлеге сорауга җавап йөзеннән, әсәрнең үзәгенә куелган мәңге искерми торган гомумкешелек проблемаларын хәтергә төшерергә кирәк. Театр коллективы повестьның рамкаларын киңәйтеп, үзәккә куелган хатын-кыз язмышы аша масштаблы полотно тудырурга ирешкән. Шул ук вакытта спектакль яхшылык һәм явызлык, кеше күңеленә төзәлмәс яра ясап, аны үлемгә илтеп җиткерергә сәләтле битарафлык, күңел тупаслыгы турында зур сөйләшү буларак та кабул ителә. Режиссер П. Исәнбәт әсәрнең сәхнә варианты өчен шул проблемаларны нигез итеп алган һәм алар соң дәрәҗәдә актуаль булып яңгырый.

Режиссер П. Исәнбәт һәм рәссам Ә. Тумашев спектакльнең тышкы образын гади һәм шул ук вакытта гаҗәеп уңайлы материал-сукно кулланып чишәләр. Чигелгән сөлгеләрне хәтерләткән кулисалар, милли орнамент белән бизәлгән падугалар, сәхнәнең бөтен киңлеген иңләгән чәчәкле чыбылдыклар һәм тормыш-көнкүреш кирәк-яраклары спектакльгә милли колорит бирәләр, чорны билгелиләр – революциягә кадәрге авыл тормышын күрсәтәләр, вакыйга геройлары хәрәкәт итү өчен уңайлы тирәлек булып торалар. Сәхнә бизәлешендә мондый принцип куллану, бердән, декорацияләрне җиңеләйтсә, икенчедән, спектакльнең эчтәлеген образлы итеп чагылдыру өчен бай мөмкинлекләр бирә. Декорацияне бу таләптән чыгып куллануга мисал итеп, икенче пәрдәдән бер өзекне күз алдына китерик. Анда режиссер черек нигезгә корылган буржуаз гаилә җимерелүен сәхнә бизәлешендәге динамик мөмкинлекләр кулланып тормышка ашыра.

Гаилә башлыгы Шибай кантон үлгәч, балалары үз өлешләренә тигән мирасны таләп итеп гауга куптаралар. Һәркем зуррак «кисәк» эләктереп калырга тырыша. Тарткалаша торгач, туганнар кызып китәләр һәм сугыша башлыйлар. Сугышу процессында сәхнәдә, образлы итеп әйткәндә, «таш өстендә таш та калмый». Йортның стеналары булып хезмәт иткән җиңел чыбылдыклар аерым кисәкләргә «ертыла», тәртипсез рәвештә тартыла, штанкетларга урала. Өй эчендәге өстәл-урындыклар идәнгә ыргытыла, тормыш-көнкүреш әйберләре дә алар белән бергә ауный. Бөтен күңелсезлеге белән сәхнәнең буялмаган каршы як стенасы ачыла. Режиссерның күп мәгънәле бу метафорасы сөйләнгән вакыйгаларның масштабын зурайта. Эпизод кеше кешегә бүре булган, байлык өчен хәтта туганнар бер-берсен бугазларга хәзер торган җәмгыятьне фаш итә.

Спектакльнең үзенчәлекле стиле шулай ук төрле театраль юнәлешләрнең, алымнарның кушылмасыннан төзелә. Биредә шартлылык һәм тормыш дөреслеген берләштергән сәхнә бизәлеше, кеше характерын ачудагы психологик тирәнлек, шартлы-символик алым күпмәгънәле метафора белән аралашып килә. Һәм нәтиҗәдә спектакль бүгенге татар режиссурасының гына түгел, гомумән совет режиссурасының магистраль линиясендә урын ала.

Мизансцена режиссерның иң мөһим сурәтләү чараларыннан санала. Шуңа күрә кайчак «мизансцена – режиссерның сөйләм теле» («мизансцена – язык режиссера») дип тә әйтәләр. Бу спектакльдә П. Исәнбәт әнә шул «сөйләм теле»нең образлылыгына, күпмәгънәлелегенә ирешә. Биредә мизансценалар, персонажларның эчке дөньясын ачу белән бергә, гомумиләштерү функциясен дә үтиләр. Шундыйларга мисал итеп беренче пәрдәдән Нури (Ш. Биктимеров, Һ. Солтанов) белән аның хатыны Фәтхия (Г. Ибраһимова, М. Миңлебаева) катнашкан эпизодта туган мизансценаны күрсәтергә була.

...Кызын сөймәгән кешесенә бирәсе килмәгән Фәтхия иренә кыяр-кыймас кына каршы дәшә. Бу исә үзен дөньяның кендеге дип йөргән Нурины чыгырыннан чыгара һәм ул дәлил итеп үз тормышын китерә. Янәсе, алар да яратышып өйләнешмәгәннәр, ләкин бик яхшы торганнар. Аңлашуның бер мизгелендә Нури, сугарга йодрык күтәргән килеш, бергә яшәгән озак еллар, бәхетле тормыш турында сөйли. Ә бу моментта исә Фәтхия, аның сугуын көтеп, йомарланып сәкедә ята. Бу очракта метафораны аңлатып торырга да кирәкми. Һәрбер тамашачы шунда ук аларның моңарчы ничек яшәгәнлекләре турында тулы мәгълүмат ала.

Беренче пәрдәнең финалы да шундый күпмәгънәле мизансцена белән тәмамлана. Туй көнендә Гөлбану (А. Гайнуллина, Ф.Хәйруллина) үз бүлмәсендә булачак ирен көтә. Кинәт чыбылдыкның бер кырыен күтәреп Закир (Р. Шәрәфиев) керә. Кап-карадан киенгән таныш түгел кешенең (элек туйга кадәр татар кызлары күп вакытта булачак кияүләрен күрә дә алмаганнар) күренүе Гөлбануны шулкадәр нык куркыта ки, ул һуштан язып, идәнгә ава. Ә үлем – хәзер инде режиссерның фикерләү юнәлеше аңлашыладыр – акрын гына якынлашып, корбанына иелә. Мизансцена монда ирексезләп кияүгә бирүнең трагик финалына ишарә – күпер буларак хезмәт итә.

Спектакльдә П. Исәнбәт күбрәк сәхнәнең беренче ике планын куллана, вакыйгаларны авансценага чыгара һәм бу алым аңа һәрбер персонажның күңел кичерешләрен зурайтып күрсәтергә ярдәм итә. Уен мәйданчыгын бу рәвешле төзү һәрбер хәрәкәтне эреләндерү һәм бер үк вакытта уендагы кечкенә генә ялганны да күренә торган итү мөмкинлегенә ия, шуңа күрә ул артистлардан сурәтләү чараларын бик җитди сайлауны таләп итә. Спектакльдә катнашучылар режиссерның ышанычын тулысынча аклыйлар. Бигрәк тә Ш. Биктимеров, Һ. Солтанов, Г. Камалова (Сабира), М. Миңлебаева, Г. Фәтхуллин (Шаһвәли), Н. Дунаев (Алтынбай) кебек артистларның уеннары тормышчанлыгы, ышандыру көче белән аерылып тора.

А. Гайнуллина һәм Ф. Хәйруллиналар уенында табигыйлек белән тирән хислелек берләшкән. Р. Шәрәфиев исә иркә, бернигә яраксыз Закирны фаш итү өчен үзенчәлекле буяулар таба.

Спектакльнең Ф. Әбүбәкеров тарафыннан эшләнгән музыкаль бизәлешенә аерым тукталырга кирәк. Музыка биредә күп төрле функция үти һәм драманың бөтен вакыйгаларында диярлек катнаша: геройларның эчке кичерешләре турында сөйли, вакыйгаларга контраст буларак килә, спектакльгә милли колорит өсти.

Спектакльнең финалы аеруча көчле. Дөньяда бар булганын – гаилә бәхетен, хәтта ана була алу сәләтен югалткан Гөлбану кабат туган якларына кайта. Тик кечкенәдән үк таныш һәм якын табигать тә инде аны юата алмый. Тормыш белән бәйли торган барлык җепләр өзелгән. Бары үлем генә җиңеллек китерә алыр. Гөлбануның тормыш белән саубуллашуы һәм үлеме күренешләрен П. Исәнбәт шартлы-символик алым кулланып чишә. Сәхнә яктылыктан, төсләрдән азат ителә. Аның бары бер өлеше, Гөлбану басып торган басма гына яктыртыла. (Автор әсәре буенча, ул суга төшә.) Дөнья белән саубуллашу монологыннан соң югарыдан, сәхнә караңгылыгыннан зур ак материя – үлем билгесе төшерелә. Шул кәфенгә төренеп, Гөлбану үзе өчен соң дәрәҗәдә кырыс булган бу дөньяны ташлап китә. Аның үлеме югары хисләр, хыяллар пычракка салып таптала торган, хәтта саф күңелле, чиста йөрәкле кешеләр дә бәхет таба алмаган җәмгыятькә ләгънәт булып яңгырый.

Югарыда каралган спектакль, әйтелгәнчә, режиссер П. Исәнбәт тарафыннан куелды. Аларда теге яки бу дәрәҗәдә режиссерның иҗат йөзе, мөмкинлекләре, идея-эстетик карашлары белән бергә, 70 нче елларның икенче яртысында бөтен татар режиссурасы өчен дә характерлы тенденцияләр чагылыш тапты.

ӘДӘБИЯТ

1. Рудницкий К. Проза и сцена. – М.: Знание, 1981. – С. 16.

## Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ ТАТАР ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЕН ФОРМАЛАШТЫРУ ҺӘМ ҮСТЕРҮДӘГЕ РОЛЕ
## (1910 еллар тәнкыйте мисалында)

***Т. Ш. Гыйлаҗев (Казан)***

В данной работе рассматривается литературно-критическая деятельность Г. Ибрагимова. Он является одним из основоположников татарской литературной критики, которая начала формироваться в началеXX века, авторитетной и влиятельной личностью, известной в литературных кругах широтой кругозора и глубиной теоретической подготовки. Исследуя в своих научных трудах различные общетеоретические проблемы литературной критики, подвергая анализу творчество отдельных татарских писателей, он создал собственную литературно-эстетическую концепцию, способствующую выявлению критериев и научных основ оценки литературного процесса.

Киңкырлы талант иясе Г. Ибраһимовның татар әдәби тәнкыйте тарихында да кабатланмас үз урыны бар. Ул бу иҗат төре белән әдәби тәнкыйтьнең, эзләнүләр чоры үтеп, камилләшү-җитди сыйфади үзгәрешләр кичерә башлаган 1910 елларында шөгыльләнә башлый һәм тиз арада киң карашлы, теоретик әзерлекле, киң колачлы, талантлы һәм үзенчәлекле тәнкыйтьче буларак танылa. Күренекле галим тәнкыйди эшчәнлеген ике юнәлештә алып бара: 1) әдәби тәнкыйтьнең поэтикасы һәм тарихы мәсьәләләре; 2) әдәбият мәйданында урын алган әдәби әсәрләргә чорның гыйльми-нәзари, әдәби-эстетик, әхлакый-фәлсәфи фикерләре ирешкән казанышлары ноктасыннан бәя бирү, үз заманының әдәби процесс үзенчәлекләрен ачу.

Г. Ибраһимовның татар әдәби тәнкыйте тарихында тоткан урыны, тәнкыйди эшчәнлеге һәм аның хасиятләре әдәбиятчы галимнәр тарафыннан мәгълүм дәрәҗәдә яктыртылган. XX гасыр башында татар дөньясында, ниһаять, әдәби тәнкыйтьнең фән буларак мәйданга килүе Г. Ибраһимовның исеме белән дә бәйләп карала. Аның «Татар шагыйрьләре» китабына язылган рецензиясендә Г. Баттал болай ди: «Галимҗан әфәнденең бу әсәре – чын тәнкыйть. Әдәбиятыбыз мондый тәнкыйтьләргә күптән мохтаҗ иде. Без, мондый әсәрләрне күргәч, әдәбиятыбыз җитди юлга кереп бара, дип шатланабыз һәм Галимҗан әфәнденең тәнкыйть гыйлемендә алга таба бик зур адым атлаганын күрәбез» (1, 154). Татар әдәби тәнкыйте фәненең «остазы» булган профессиональ тәнкыйтьче Җ.Вәлиди тәнкыйть һәм әдәбиятта «мөтәхассыйс (белгеч) исемен алган яки алырга таба юл тоткан кешеләр» (2, 316) – «икенче буын мөхәррирләр» арасында Г. Ибраһимовны атый. Әлбәттә, бу замандашы тарафыннан тәнкыйтьчегә бирелгән югары бәя була.

1917 елгы Октябрь борылышыннан соң Г. Ибраһимовның әдәби тәнкыйть өлкәсендәге хезмәтенә Г. Сәгъди, М. Гайнуллин, М. Хәсәнов, М. Мәһдиев, Р. Мөхәммәдиев, Э. Галиева, Д. Заһидуллина һ. б. галимнәр игътибар итәләр. Дөрес, аерым бер эзләнүләрдә Ибраһимовның тәнкыйди фикерләре белән гыйльми-теоретик күзаллаулары, фәлсәфи-эстетик карашлары, кайбер очракларда публицистик эшчәнлеге тыгыз бәйләнештә карала. Бу хосусият әлеге тармакларның үзара тыгыз мөнәсәбәттә яшәүләреннән килә.

Әдәби тәнкыйть поэтикасына караган төшенчәләр, әсәрне бәяләү кагыйдәләре һәм алымнары, критерийлары, мәгълүм булганча, җанлы әдәби тәнкыйди хәрәкәт белән тыгыз бәйләнештә барлыкка килә һәм үсешүзгәреш кичерә. XX гасыр башында әдәби тәнкыйть яңа әдәбиятны, аның аерым берәмлекләрен аңлаубәяләүнең кануннарын, фәнни нигезләрен ачыклый торган эстетик концепцияләр эзләү юлына чыга, ягъни ул әдәби-мәдәни мәйданга килгән һәрбер яңа фән кебек, иң беренче нәүбәттә, үз предметын, өйрәнү һәм бәяләү объектын ачыклау, үз билгеләнү хокукы, иҗтимагый вазифасы һәм функцияләре, әдәби барыштагы

урыны, тәнкыйть этикасы, жанрлар системасы кебек мәсьәләләрне хәл итәргә алына.

Милли, әдәби-мәдәни күтәрелештә әһәмиятле роль уйнаган Шәрекъ һәм Гареб мәдәниятләренең уңай йогынтысы, хәтта бу ике культурологик ориентирның үзара бәхәсе әдәби тәнкыйтьнең мөһим теоретик мәсьәләләрен хәл иткәндә дә сиземләнә. Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Г. Тукай, Г. Баттал, М. Укмасилар тәнкыйди эшчәнлегендә үзе латин, борынгы грек цивилизациясе тәэсирендә калыплашкан Аурупа-рус әдәбият белеменең тәэсире зур булса, ә Р. Фәхретдин, Г. Сәгъди һ. б. лар төрки-татар дөньясы озак гасырлар тыгыз бәйләнештә яшәгән, әдәп-әхлак, белем алмашкан Шәрекъ мәдәниятенә таяналар. Татар галимнәре тарафыннан, мөмкин булганда, милли әдәбият белеменең, шул исәптән әдәби тәнкыйтьнең аерым терминнарын татарча эшләү телəге белдерелсә дә, ике мәдәниятнең ирешкән фәнни казанышларыннан башка бу мәсьәләне чишү мөмкин түгеллеге таныла. Бу хәрәкәтнең үзәгендә Г. Ибраһимов та кайный.

Г. Ибраһимов әдәби тәнкыйть фәне турындагы нәзари эзләнүләрен «Әдәбият кануннары» (1919) дигән хезмәтендә бер бүлекчәгә туплап урнаштыра. Билгеле булганча, аның беренче басмасы «Әдәбият дәресләре» исеме астында 1916 елда Казанда «Сабах» матбагасында дөнья күрә. Иң беренче нәүбәттә, әлеге методик әсбапта галимнең әдәби тәнкыйтьне фәнни нигезгә утырту омтылышын билгеләргә кирәк. Бу еллар тәнкыйди рухи мирасын актарганда, әдәби иҗатның бу төренә атама булып ике термин: тәнкыйть һәм интикадның фәнни кулланылышта йөрүе күзәтелә. Г. Ибраһимовның аерым мәкалә-язмаларында интикад кулланылса да, тәнкыйть терминына өстенлек бирелә. Галим тәнкыйть сүзенең килеп чыгышы, мәгънәсе, фәнни һәм гамәли әйләнешкә керүе, аның тамырдаш, мәгънәдәш сүзләре турында уйлана: «Тәнкыйть сүзе “нәкыд” матдәсеннән алынган. Лөгать мәгънәсе акчаның чынын сахтәсеннән (ялганыннан) аеру димәктер» (3, 106).

Әдәби тәнкыйтьнең предметы, аның шартлары һ. б. гыйльми-нәзари төшенчәләрне шәрехләүдә Г. Ибраһимов, алда әйтелгәнчә, Аурупа-рус әдәбият белеме ирешкән казанышларга таяна. Мәсәлән, ул тәнкыйтьне мантыйкый дәлилләр белән эш итүне һәм исбатлауны таләп иткән мөхакәмәнең бер төре итеп карый һәм алга таба тәнкыйтьнең теоретик мәсьәләләре аның тарафыннан шушы позициядән чыгып аңлатыла. Әдип моңа кадәр практик кулланылышта булган әдәби тәнкыйтьнең шартлары, таләпләре терминнары урынына кагыйдәләр, кануннар дигән төшенчәләргә мөрәҗәгать итә. Әдәби әсәргә бәя бирүнең үлчәмнәре турында сүз алып барып, «мизан» төшенчәсен фәнни әйләнешкә кертеп җибәрә: «Бер әсәрне яки бер язучының барлык әсәрләрен тикшереп, аларга кыйммәт куйганда, мөнәкъкыйднең шулардагы җитешкән яки җитешмәгән якларны билгеләүдә үзенең рәһбәр (юл күрсәтүче, таяныч) ителгән шул канун вә нәзарияләре “тәнкыйтьнең мизаны” – яки критериум дип атыйлар» (3, 106).

Г. Ибраһимов китапның кайсы өлкәгә, нинди жанрда язылуына карап, аны бәяләү мизаннарының да төрле булуын әйтеп чыга, аларны бер-берсеннән аерып куя. Мәсәлән, дәрес китабы белән әдәби әсәрләрне бәяләүдә бер төрле кануннар һәм нәзарияләргә таянуны кире кага. Автор тарафыннан «тикшерелгән әсәрнең эч йөзен, маһиятен (асылын) ачып бирү, әсәр теле, өслүбе, план вә мөндәриҗәсе (эчтәлеге) төп уйны ачып җитә алуы-алмавы, хәятка мөнәсәбәте» мәгълүм мизаннар ярдәмендә бәяләнергә тиешле яклар буларак аерып чыгарыла. Бәя-шәрехләүнең объективлыгын, берьяклы гына булмавын күздә тотып, тәнкыйтьне «ике йөзле хәнҗәргә тиңли». «Тәнкыйть ике йөзле үткен хәнҗәр булырга тиеш. Бу хәнҗәрнең бер ягы әсәрнең эчендәге җәүһәрләрне казып чыгарса, икенче ягы аның чүбекләрен табып күрсәтү» (3, 107).

«Әдәбият кануннары»нда әдәби тәнкыйтьнең төрләрен аерып чыгару, аларның үзенчәлекләрен билгеләү юнәлешендә дә тәнкыйтьченең карашлары урын алган. Әдәби тәнкыйтьнең әдипкә рекомендация бирү һәм әдәби әсәрнең «уңай» һәм «кире», «җитешкән вә җитешмәгән» якларына бәя бирү вазифасы Г. Ибраһимовка аның ике: **«иҗаби» (уңай)** һәм **«сәлби» (кире)** төрләрен күрсәтүгә юл ача. «Әсәрнең яхшы ягын күрсәткән тәнкыйтьләр иҗаби тәнкыйть дип, җитешмәгәнен күрсәткәннәре сәлби тәнкыйть дип атала» (3, 107). Дөрес, биредә кире тәнкыйтьнең әдипкә ярдәм итү, әсәрнең кимчелекле якларын бетерүдә юл күрсәтү сыйфаты калкытып куела: «Сәлби тәнкыйтьләр әсәрнең җитешмәгән якларын күрсәтү белән язучының үзен дә, башкаларны да шул хатадан, шул кимчелектән сакланырга юл эзләргә, шулай итеп төзәлүгә сәбәп булалар» (3, 107). Г. Ибраһимов иҗаби тәнкыйтьнең ике функциясен калкытып куя: 1) халык тарафыннан илтифат ителми яткан яшь талантларның әсәрләрен тикшереп, шулардагы яхшы якларны күрсәтү, шул юл белән аларны дөньяга таныту; 2) дөньяга чыгып та, халык тарафыннан кирәгенчә тәкъдир ителмичә яткан әдәби әсәрнең «төбенә салынган тирән вә кыйммәтле җәүһәрне» укучыга ачып бирү.

Әдәби тәнкыйтьнең жанр ягыннан үсү, баю чоры XX гасыр башларына туры килә. Г. Ибраһимов – әдәби тәнкыйтьнең жанрларын булдыру, аның сыйфатларын ачыклау юнәлешендә дә кызыклы фикерләр белән чыгыш ясаган галим. Г. Ибраһимов **рецензия**, **рәддия** һәм **мәкаләне** әдәби тәнкыйтьнең жанрлары буларак карый. Ул рецензиягә түбәндәге билгеләмәне бирә: «Мәйданга чыккан бер әсәр, тыңланган концерт, күрелгән спектакль хакында вакытлы матбугатта, дәлилләр белән исбатка керешелмичә, кыска рәвештә тәэсир вә мөляхәзәне (фикер йөртүне) бәяннән гыйбарәт булган мәкаләләр **«рецензия»** дип атала» (3, 108). Ә рәддияне, аның карашынча, «сәлби тәнкыйтьләргә мөхәррирнең үзе яки башка берәү тарафыннан бирелгән җаваплар» барлыкка китерә. Алга таба бу жанрның рус әдәбият белемендә **антикритика** дип аталуы искәртелә. Авторның рәддия язылу сәбәпләре турындагы хөкемнәре кызыклы. Г. Ибраһимов әдипне кимсетү, шәхесенә тию, абруен төшерү максатыннан язылган рецензияләргә рәддияләр языла дип карый. «Сәхнә хакында, әдәби әсәрләр хакында, әгәр дә шәхси намуска тиелмәгән булса, гадәттә рәддия язылмый. Фәнни әсәрләргә җавап бирелә» (3, 108). Хезмәт авторы К. Насыйриның Ш. Мәрҗанигә җавабын рәддиягә мисал итеп китерә. 1910 еллар татар әдәби тәнкыйтендә рецензия жанрының активлыгы кими. Ләкин шул ук вакытта рецензия, мәкаләнең жанр сыйфатларын үзенә алып, аңа тартымлык күрсәтә. Бу тенденция Г. Ибраһимовның тәнкыйть практикасында аеруча калку чагыла.

Г.Ибраһимов тәнкыйди эшчәнлегенең икенче тармагында үз иҗатлары белән милли әдәбиятның яңарышын тәэмин иткән классик әдипләр Г. Тукай, Г. Исхакый, Ф. Әмирхан, Дәрдемәнд, С. Рәмиев, Ш. Камал, М. Фәйзи, Ш. Бабич, Г. Камал, Г. Коләхмәтов һ. б. ларның әсәрләре бәяләнә. Ул «Вакыт», «Йолдыз», «Тормыш», «Идел», «Кояш», «Аң», «Мәктәп», 1917 елгы Октябрь борылышыннан соң «Эшче», «Кызыл Армия», «Татарстан хәбәрләре», «Кызыл Татарстан», «Безнең юл» һ. б. газета-журналларда «Г. Ибраһимов», «Габди», «Галимҗан», «Джан», «Гыйрфанзадә» дигән имзалар һәм «Г. И.», «Г.» инициаллары белән актив язышa.

Тәнкыйтьченең бу төр рухи мирасындагы жанрлар системасын аның фикерләү стиле, язмада күтәрелгән актуаль әдәби, фәлсәфи, әхлакый, иҗтимагый-социаль мәсьәләләр, анализ объектлары һәм принциплары, бәяхөкемнәренең концептуальлеге билгели. «Әдип үзенең тәнкыйть мәкаләләрендә, – дип яза М. Хәсәнов, – татар әдәбиятының ул вакыттагы гомуми хәле, аерым жанрларның үсеше, әдәби процесста теге яки бу язучының тоткан урыны, татарда сынлы сәнгать, профессиональ музыка туу перспективалары, журналистика һ. б. мәсьәләләргә дә даими рәвештә игътибар итеп килә» (4, 532). Аның тәнкыйди мирасында яңа әсәрне әдәбият сөючеләргә тәкъдим итү, аның хакында информация бирүне генә максат иткән кыска, кечкенә күләмле информатив жанрларны табу кыен. Ә теоретик мәсьәләләр, сүз сәнгатенең торышы хакында уйлануларны, әдәби хәрәкәтнең аерым чорын, аның үсешүзгәреш закончалыкларын, тенденцияләрен чагылдырган әдәби күзәтү, проблемалы мәкалә, монографик мәкалә, рецензия-мәкалә, монографик рецензия кебек жанрлар Г. Ибраһимов тарафыннан максатчан һәм отышлы файдаланыла. Галим әдәби әсәрләргә бәяне әдәбият-сәнгатькә һәм тәнкыйтькә үзе куйган таләпләршартлар, үз сүзләре белән әйткәндә, әсәрнең «төбенә салынган тирән вә кыйммәтле җәүһәрне» укучыга ачып бирү яссылыгында оештыра. Г. Ибраһимов тәнкыйди эшчәнлегенең асыл хасиятен билгеләп, галим Г. Сәгъди болай дип яза: «...әдип ул вакытта сәнгать әсәрләренең бигрәк эмоция якларына, сәнгатьчә ничек эшләнеп чыгу мәсьәләләренә ныграк кереп, аларга бигрәк шул яктан бәһа бирүдә киң алымлы, зур куәтле тәнкыйтьче иде» (5, 18). Д.Заһидуллина тәнкыйтьченең матур әдәбиятны бәяләү принциплары һәм кануннары хакындагы гыйльми-нәзари күзаллауларын түбәндәгечә формалаштыра: «Әдәбият рухи дөньяны чагылдыру максаты куя дигән кагыйдәдән чыгып, Ибраһимов сәнгать әсәре булу өчен тормышны күрсәтү генә җитми, шул тормышның рухын, җанын ачарга кирәк, дип җавап бирә» (6, 7).

Г. Ибраһимовның үткән XX гасыр буенча өйрәнелеп, бүген дә бәхәсле булып калган «Татар шагыйрьләре» (1913) хезмәте **әдәби параллель** жанрында язылган. Дөрес, автор анда С. Рәмиев, Дәрдемәнд, Г. Тукай шигъриятләренә анализны чагыштырма планда үреп алып бармый, ә китапның беренче бүлегендә әдәбиятсәнгать әсәрләрен бәяләүнең яңа принциплары һәм кагыйдәләре нигезендә С. Рәмиев рухи дөньясының идея-эстетик үзенчәлекләрен, шагыйрьлек сыйфатларын ассызыклый да шулар яссылыгында калган ике шагыйрьнең әдәбият мәйданында тоткан урынын, шигъриятләренең хасиятләрен билгели. Әдип татар әдәби тәнкыйтендә поэзияне шәрехләүдә яңа фәнни-теоретик юнәлеш булдыра: «Требуя от художников слова мастерства, гармонии между чувством и его словесным выражением, критик выдвигал на первый план чисто эстетический аспект творчества; приоритет он отдавал таланту, считая его главным критерием для критической оценки. Это в целом выделяло его среди современников. ...В ней Г. Ибрагимов в целом верно и во многом первым вскрыл эстетические заблуждения национальной литературной критики в подходе к поэзии, тем самым объективно послужив становлению новой парадигмы в татарском литературоведении» (7, 174).

Г. Ибраһимов «Хәят» (1911) монорецензиясендә Ф.Әмирхан повестенда романтик иҗат тибы сыйфатларының чагылышын күрсәтеп, «“Мөгаллимә”нең Уфада уйналуы мөнәсәбәте белән» (1915) дигән мәкаләсендә әдәби әсәрдә тормыш дөреслеген гәүдәләндерү принцибын яклап, «Яңа әсәрләр, яңа имзалар вә яшь куәтләр» (1915) күзәтү рецензиясендә Ш. Камал хикәяләре мисалында импрессионизм модернистик агымының тасвирый алымнары һәм чараларының сыналышын ассызыклап, 1910 еллар татар әдәбиятында иҗат юнәлешләренең төрлелеген һәм милли сүз сәнгатенең үсеш перспективасын билгели. «Яңа китап мөнәсәбәте илә» (1912) язмасында иҗтимагый-социаль, әхлакый һәм тормыш-яшәеш мәсьәләләрен характерларның холкы һәм психологиясе аша гәүдәләндерү, «Зур романнар» (1912) рецензиясендә роман, аның жанр хасиятләре, шулай ук башка язмаларда урын алган әдәби типлар, әсәрләрнең милли характеры, тема-мәүзугъ яңалыгы, образлар системасы, вакыйгалар үстерелеше, авторның хикәяләү стиле хакындагы бәя-карашлары галим фәнни-теоретик эзләнүләренең киңкырлы булуы турында сөйли.

Г. Ибраһимовның бай эстетик зәвыгы, сизгер табигате матур әдәбияттагы һәр яңа күренешне тиз тотып ала. «“Галиябану” хакында бер-ике сүз» (1922) рецензия-мәкаләсендә пьесаны бәяләү уңаеннан халык поэтик иҗаты белән язма әдәбият арасында бәйланышлар, аларның бер-берсенә йогынтысы, сүз сәнгатенең художестволылыгын камилләштерүдә фольклор казанышларының роле кебек мәсьәләләргә дә игътибар ителә. Мәгълүм булганча, М. Фәйзинең «Галиябану» музыкаль драмасында музыканың идея-эстетик вазифасы үзгәрә, ул очраклы бизәк төсендә генә түгел, ә пьеса эчтәлегенең тукымасын хасил итә. Әсәрнең мәгънәви кисәкләрен бер үзәккә туплаган әдәби деталь буларак кулланыла. Әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Г. Ибраһимов әдәби әсәрнең яңа сыйфаты хакында болай дип яза: «Галиябану»ның бөтенләй яңа хасиятләреннән берсе – аның бездә беренче мәртәбә сәхнәгә музыканы, җырны, бер иттифакый зиннәт ясап кына түгел, бәлки төп матди итеп, асыл мөндәриҗә (эчтәлек. – *Т. Г.*) кыйлып кертүедер. Буны «Галиябану» башлап җибәрде. ... Менә шундый хасиятләре белән «Галиябану» бездә ялгыз урында тора, яңа бер баб яки, зуррак тәгъбир булса да, әйтик, драмалар галәмендә яңа мәктәп ача һәм, шулар аркасында бик хаклы буларак, гаммә алдында иң кадерле урыннарның берсен ала» (8, 303).

Г. Ибраһимовның әдәби-эстетик карашлары 1910 еллар татар әдәби тәнкыйтендә мөстәкыйль, үзенчәлекле, әйтергә кирәк вакыты белән каршылыклы үсеш юлы кичерә. Әдипнең кайбер язмаларында галим үзе форма-

лаштырган фәнни мәктәпнең төп кануннары белән генә аңлатып булмый торган берьяклы бәя-хөкемнәре булса да, ул әдәби тәнкыйтьнең фән буларак үсешен тәэмин итүгә, тәнкыйть поэтикасының һәм тарихының мөһим проблемаларын хәл итүгә, әдәби әсәрләрне анализлау-шәрехләүнең яңа парадигмаларын эшләүгә, иҗатның һәр өлкәсендә яшь талантлар тәрбияләүгә үзеннән зур өлеш кертә.

ӘДӘБИЯТ


1. Баттал Г. Яңа әсәрләр «Татар шагыйрьләре» // Гыйлаҗев Т. Ш. Рецензияләрдән тәгъзияләргә: XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. – Б. 149–154.

2. Вәлиди Җ. Матбугат галәмендә // Җамал Вәлиди: әдәби һәм тарихи-документаль җыентык / төз. Диләрә Абдуллина, Җәүдәт Миңнуллин. – Казан: Җыен, 2010. – Б. 304–323.

3. Ибраһимов Г. Әдәбият кануннары. Теория словесности. Өченче басма. – Казан: Дәүләт типографиясе, «Сабах». 1919. – 126 б.

4. Хәсәнов М. Г. Ибраһимов – тәнкыйтьче һәм әдәбит галиме // Галимҗан Ибраһимов. Әсәрләр: сигез томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – 5 т.: Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). – Б. 531–543.

5. Сәгъди Г. Бездә әдәби тәнкыйть (Үктәбрнең унъеллыгына). – Казан: Татиздат. Безнең юл редакциясе. – 22 б.

6. Заһидуллина Д. Язучы, галим, җәмәгать эшлеклесе // Мәгариф. – 2012. – № 3. – Б. 5–7.

7. Гилазов Т. Ш. Литературная репутация Тукая в эстетической концепции Г. Ибрагимова // Известия ВГПУ. – 2009. – № 10 (44). – С. 172–174.

8. Ибраһимов Г. «Галиябану» хакында бер-ике сүз // Галимҗан Ибраһимов. Әсәрләр: сигез томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – 5 т.: Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). – Б. 301–303.


# ӘДИПНЕҢ «ТАТАР ШАГЫЙРЬЛӘРЕ»НДӘ С. РӘМИЕВ ИҖАТЫНА БӘЙЛЕ КАЙБЕР ӘДӘБИ-ЭСТЕТИК КАРАШЛАР


***Ф. З. Яхин (Казан)***



На основе изучения первой главы работы «Татарские поэты» (1911–12) Г. Ибрагимова рассматриваются его литературно-эстетические взгляды, связанные с оценкой творчества С. Рамиева, раскрываются представления Г. Ибрагимова об экспрессионизме.


Г. Ибраһимов «Татар шагыйрьләре»ндә С. Рәмиевнең шигъриятенә хас үзенчәлекләрне бәян итеп, аларның ике төп билгесен аерып күрсәтә. Аның беренчесе моннан гыйбарәт: «Сәгыйтьнең бу тәэсораты, бу ялкыны артык куәтле таша, күңел чыдамсыз һәм гайре табигый ашкына, шу дәрәҗәдә ки, рухның ул куәтле, хәтта тиле ашкынуын, ниһаятсез куәтле изтирабны икенчеләргә ачык әйтеп бирергә сүз җиткерә алмый, тел аларны матурлап, табигый ясап чыгарырга өлгерә алмый» (1, 78). Болар белән Г. Ибраһимов С.Рәмиев шигырьләренең хисси тәэсир аркасында тууларын, хискә корылган булуларын раслый. Һәм ул хаклы. С. Рәмиев шигырьләре көчле хис ташкынының агышы белән тәэсирле. Хәтта бер хис ташкынын икенчесе алыштырып килә. Ул ташкын киң җәелеп һәм ургылып ага. С. Рәмиевнең шигырьләрен укыганда сулыш кысыла, ә хис агымы һаман көчәя бара. Бу исә экспрессивлык күренеше. Шушы күренешне «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» болай дип төшендерә: «Экспрессивлык – сәнгатьлелек, тәэсирлелек, тәэсир итүчәнлек» (2, 564). Бирелгән төшенчә белән чагыштырганда, Г. Ибраһимов бары тик сәнгатьлелек хакында гына аерым әйтми, калган яктан да аның фикерләре белән сүзлектәге аңлатма үзара туры киләләр. Димәк, С. Рәмиев иҗатына, Г. Ибраһимов бәяләмәсенә нигезләнеп фикер йөртсәк, көчле экспрессия хас икән, дигән нәтиҗәгә килергә тиешбез. Тагын да шунысын искәртик, Г. Ибраһимов үзе дә язучы, әдип, С. Рәмиевкә бәя биргәндә ул үзенең әдәби-эстетик карашларыннан да чыгып фикер йөрткән.

Татар әдәбияты тарихында С. Рәмиев романтизмның башлангыч вәкиле буларак бәяләнә һәм аның әсәрләр тупланмасын барлап, җыйнап, өйрәнеп бастырып чыгарган галим Ш. Г. Садретдинов бу хакта болай дип язган: «Сәгыйть Рәмиев – XX йөз башы татар демократик әдәбияты үсешендә тирән эз калдырган әдипләрнең берсе. Татар әдәбиятында романтизмның башлап мәйданга чыгуы аның иҗаты белән бәйләнгән» (3, 172). Бу фикер белән тулысынча килешергә була, чөнки романтизм ул, «Әдәбият белеме сүзлеге»ндә аңлатылганча, «бигрәк тә матур әдәбият өлкәсендә ачык гәүдәләнде. Романтизм язучылары реаль чынбарлыкны үзләренең таләпләре һәм тойгыларыннан, максатларыннан чыгып сурәтләргә, кеше образларын да тормыштагыча түгел, бәлки үзләре уйлаганча күрсәтергә омтылганнар» (4, 142). Галим А. Г. Әхмәдуллин редакциясендә чыккан «Әдәбият белеме сүзлеге»ндә «татар әдәбиятының барлык чорлары өчен дә романтизм юлдаш» (5, 157) дип белдерелә. Урта буын галимголяма дә шушы ук фикерләргә таяна һәм: «Романтизм әдәбиятны кешеләргә яшәеш нигезләре хакында сөйләүче, белем-мәгълүмат бирүче дип карый. Сәях образы – мәңгелек буйлап сәяхәт итүче, шушы мәңгелектә үз урынын эзләүче герой өчен тарихи-географик чикләр, бу һәм теге дөнья, өн һәм төш, хакыйкать һәм хыял арасында чикләр җуела. Үткәнне – тарихны идеаллаштыру, экзотик материалга мөрәҗәгать итү, авторның субъектив позициясе ачык билгеләнү, фәлсәфи һәм лирик чигенешләр ясау күзәтелә» (6, 165), дип белдерәләр. Әдәбият теоретигы Ф. М. Хатипов романтизмны иҗат методы буларак түгел, бәлки иҗат тибы буларак (әдәби иҗат агымы дисәк тә була) карый һәм: «Романтизм – ул художникның хәятны үзенчә күрү җирлегендә туган үзгә бер дөнья» (7, 243) дип, фикерен тагын да конкретлаштыра. Әдәбият теоретигы В. Е. Хализев исә романтизмны бары тик романтика чикләрендә генә карый, әдәби агым яки әдәби иҗат методы төшенчәләрен кире кага, романтизм, ягъни романтиканы «авторның эмоциональлек тибы» кысаларында тикшерә, идиллия һәм сентиментализм белән бер яссылыкка куя (8, 89–92). Аның фикеренчә, идиллия белән

язылган әсәрләр шатлыклы дулкынлану көче белән сугарылалар, сентиментализмга башкалар хәленә керергә омтылыштан туган хиссилек өстенлек алса, романтикага анысы да, монысы да хас, әмма аңарда төрле каршылыклар, борчылулар, авторның «үз эченә чумуы» күзәтелә (8, 89–92). Шулай итеп, романтизмны бер төрле галимнәр иҗат тибы буларак, икенчеләре иҗат методы дип, өченчеләре «авторның эмоциональлек тибы» кысаларына кертеп карыйлар. Минемчә, әдәбиятта романтизмның реализмнан аермасы шунда, ул геройны һәм вакыйгаларны «тыштан торып» түгел, бәлки «эчтән торып» сурәтли, бу мәгънәдә ул иҗат юнәлеше яки иҗат принцибы булып саналырга тиешле. Реалист әдип исә геройларны һәм вакыйгаларны читтән күзәтүче ролендә сурәтли, эчке дөньяны тышкы сыйфат үзгәреше һәм күренешләр ярдәмендә ача, ә романтик әдип, киресенчә, геройларны һәм вакыйгаларны «эченә кереп» сурәтли, шуның белән хакыйкатьнең чын асылын ачыклавына инанып эш итә. Болар исә төрле стильләрне, эмоциональлек үзенчәлекләрен барлыкка китерәләр. Шулай итеп без романтизмны «эчке дөнья аша тышкы дөньяны ачу» дип атасак, реализмны «тышкы дөнья аша эчке дөньяны төшенү» дип белдерәбез. Шушы фикерләмәдән чыгып, С. Рәмиевне берничек тә романтизм вәкиле дип, бер яклап кына бәяли алмыйбыз. Аның иҗаты асылы белән романтизм кысаларына гына сыеп бетә алмый. Ул – романтик та, реалист та. Әмма Г. Ибраһимов дөрес бәяли, С. Рәмиевнең иҗатына экспрессия хас, бу фикерне читләтеп үтү мөмкин түгел.

«Язгы ташкында су ничек үзенең мәгъруф юлыннан читкә, һәртөрле юлсызлыкларга китә, Сәгыйтьнең шигърияте дә шулай, – дип белдерә Г .Ибраһимов, С. Рәмиевнең иҗатына төп үзенчәлекләреннән булган икенче билгесенә игътибарын юнәлтеп һәм шигырьләрендәге хис ташкынының дәрәҗәсен билгеләп. – Ягъни анлар да, артык тиле куәт белән ашкыну тәэсирендә генә язылганга, юлсызлыкка китәләр» (1, 78). Сүз, әлбәттә, иң беренче чиратта, рифма һәм ритм бозылу хакында бара. Бу урынлы әйтелгән бәя. С Рәмиевнең шигырьләренең төзелеше үз чоры өчен татар укучысына бөтенләй дә таныш булмаган калыпка корылганнар. Шагыйрьнең моңа кадәр укучыга яхшы таныш саналган силлабик һәм гаруз шигырь төзелешләренә каршы килгән, эчке хис ташкынына корылган һәм сулыш кысылырлык дәрәҗәгә җиткерелеп язылган әсәрләре әдәбиятта яңалыкка омтылу белән дә бәйле булган. Г. Ибраһимов моны ясалма омтылыш дип исәпләми, бәлки шигъри табигатенчә әдипнең шушы рәвешле иҗат иткәнлеген төшенә һәм аңлатып бирә. Шул сәбәпле ул чын шагыйрьнең асылын аның әсәрләрендәге хиснең ялкыныннан һәм язгы ташкын кебек булуыннан күрә, хиснең экспрессив формаларда бирелүенә игътибар итә. Хиснең яки хисләрнең көчле дулкын рәвешендә шигырьдә һәм гомумән дә әдәбиятта бирелүенә Г. Ибраһимовның төп игътибарны юнәлтүе, М. Х. Хәсәнов билгеләп үткәнчә, «дидактизмга каршы көрәш белән кирәгеннән артык мавыгып китеп» (3, 345) язуыннан килә. Шигъриятнең дидактик формаларга корылуы урта гасырлардан, бигрәк тә суфичылык әдәбиятына хас хикмәтләрдән татар язучы-шагыйрьләре иҗатында үстерелеп килгәнлектән, XIX йөзнең ахырынача диярлек бернинди үзгәрешсез кала баруы, коры фикер әйтү һәм шул фикерләрнең бер әсәрдән икенчесенә күчеп кабатлануы фикри-әдәби торгынлыкка китергән. Әдәбиятта дидактизмның алга чыгарылуы – ул аның үсештә торгынлык чорына килеп керүе, дигән сүз дә әле. Шушы мантыйк нигезендә фикер йөртсәк, С. Рәмиевнең хискә корылган шигырьләр язуы тулысы белән Г. Ибраһимов тарафыннан яңалык рәвешендә кабул ителгән, шунлыктан әдипнең мондый шигъриятне алдынгы, авангард буларак күзаллаганын төшенүе авыр түгел.

Әмма шигырьнең, әдәби әсәрнең хискә корылуы ул әле аның мәгънәсезлеккә таба юл алуы дигән сүз түгел. Моны Г. Ибраһимов яхшы аңлап эш итә. «Шунлыктан, – дип яза ул, – аның шигырьләре мәгънә, хис һәм шигъриятнең артык голүвияте, артык тирәнлеге ягыннан ничаклы кыйммәтле булсалар, тел вә ләфыз җәһәтеннән караганда шул дәрәҗәдә түбән һәм кимчелекле булалар» (1, 78). Димәк, С. Рәмиевнең шигырьләре тел һәм сүз ягыннан караганда түбән һәм кимчелекле икәннәр. Әмма мәгънәдә, хистә һәм шигърилектә бик тә югары кимәлдә язылганнар.

Шигъри теленең табигый булмавын бәяләп, Г. Ибраһимов бу яктан С. Рәмиевне Дәрдемәнд һәм Г. Тукай белән бөтенләй дә янәшә куярлык түгел икәнлекне аерым басым ясап уза (1, 78). Аның бу бәясенә татар әдәбияты тарихы фәнендә, бөтенләй диярлек игътибар ителми.

Г. Ибраһимов фикере буенча, С. Рәмиевнең шигырьләре «табигый агымлы» түгелләр (1, 79). Шушы бәясен биргәндә әдип «аның нәзымнары» дигән терминны куллана. Билгеле булганча, ул шигырь белән нәзымны үзара капма-каршы куя. «Нәзым» дигәндә, тезмә белән язу күздә тотыла, аны һәрбер белемле кеше төзи, тезеп яза ала, әмма «шигырь» дигәндә, ул йөрәктән, кешенең белемле-белемсез булуына бәйсез рәвештә, хис ялкыны буларак, бары тик чын шагыйрь тарафыннан гына тудырылган әсәр итеп карала.

Тел һәм сүз җәһәтеннән «табигый агымлы» шигырь нинди була соң ул? Моңа Г. Ибраһимов С. Рәмиевнең «Авыл» һәм «Сызла, күңлем!» кебек шигырьләреннән мисаллар китереп җавап бирә: «“Нәкъ көлә, нәкъ елмая, нәкъ юри бәгъреңне өзә” кеби бик гаҗаиб, ят, шуның илә бәрабәр, теләнгән мәгънәне аңлатуда искиткеч муаффәкыятьле булган, яки “Сызла, сызла, сызла, күңлем, сызла бер туктамыйча – сызла айлар, сызла еллар – сызла төн йокламыйча” кеби, рухның чын мәгънәсе илә аңлату өчен әллә никадәрле сәхифәләр кирәк булырлык изтираб вә халәте әләмне бер-ике җөмлә илә гаҗаиб дәрәҗәдә ачык һәм тулы аңлаткан мисрагълар очрый» (1, 79), – ди ул. Димәк, Г. Ибраһимов фикеренчә, тел җәһәтеннән «табигый агымлы» шигырьләр, беренчедән, гаҗәпләндерерлек дәрәҗәдә булырга, ят, ягъни кабатланмаган, беренче тапкыр әйтелгәндәй тоелырга, шулар белән бергә теләнгән мәгънәне отышлы итеп җиткерергә тиешләр; икенчедән исә, рухның-җанның дулкынлануын-сыкрануын бер-ике җөмлә белән ачык һәм тулы сөйләп-аңлатып бирсеннәр. Башка төрле әйткәндә, шигырьгә «табигый агым» кабатланмас сокландыргыч мәгънә һәм хисне ачык һәм тулы чагылдырып бирү өчен хезмәт итә икән. Аңлашылып тора, Г. Ибраһимов мәгънә һәм хис бергәлеген туктаусыз үзара бәйләнештә тота, хис агымының мәгънә бөтенлегенә хилаф китерергә мөмкин икәнлеген С. Рәмиевнең «нәзымнары»на бәйле сөйләп бирә.

«Урманның сикәлтәле юлыннан начар арба өстендә барган адәмнең гәүдәсе ни-нәрсә хис кылса,

Сәгыйтьнең бәгъзе бер шигырьләрен укыганда да чын татар зәвыклы сизгер татар теле шуны тоячак» (1, 79) – Г. Ибраһимовның С. Рәмиев шигырьләренә карата әйтелгән бу фикере зур әһәмияткә ия. Ул аның әсәрләренә хас төп җитешсезлекне төгәл тотып алган һәм аңлатып биргән. Бу юлларны укыганда, Г. Ибраһимовны, С. Рәмиев шигырьләренә мөкиббән киткән, дип әйтеп булмый. Киресенчә, ул аларны шактый каты итеп тәнкыйтьли. Шигырьләренә җитешмәгән шул «табигый агым» С. Рәмиевнең әсәрләрен бары тик хис-тойгы стихиясенә бирелеп иҗат итүеннән килә, күрәсең. Г. Ибраһимов фикерләрне дәлилсез сөйләми, мисалларны мул китерә. Аларны, мисалга алганда, әдип хәтта азмы-күпме тәртипкә китерүләре, төзәтүләре хакында да искәртә һәм, «күрәсез, боларны укып барганда тел “табигый акмый”, әле анда, әле монда барып терәлгәндәй, төртелгәндәй була» (1, 79) дип, С. Рәмиев шигырьләрендә рифма-ритм мәсьәләсенең хәл ителми калдырылуына да уфтана. Әмма «табигый агымлы» шигырьләрен дә әдип күрми үтми, алар исәбенә «Көлсеннәр», «Таң вакыты» (аның да башы белән ахырын гына), «Авыл», «Пәйгамбәр», «Дөньяга» шигырьләрен кертә (1, 79–80).

Г. Ибраһимов фикеренчә, тел җәһәтеннән караганда камил һәм матур тоелган шигырьләр алар асыллары белән нәзымчылыктан, шигырь төзи белү осталыгыннан килә, ә чын шагыйрьдә исә сүзләр камил һәм матур булып та бетмәскә мөмкиннәр, әмма алар шагыйрьнең йөрәгеннән кайнап чыгалар, аның хис-тойгылары белән өртелеп туалар. «Сәгыйть начар назыйм булыр, – ди ул, – мин аңа карышмыйм, хәтта тәсдикъ итәм, әмма аның яздыклары чын вә куәтле шигърият белән тулган» (1, 80). Әдипнең төп тикшерү объекты «зарурәте шигърия», ягъни шигъриятнең асылы ни-нәрсә икәнлеген төшендерү-аңлату мәсьәләсе икәнлеге дә шушы фикерләр белән янәшәдә белдерелә. Укучы алдында «Шагыйрь кем?» «Шигырь нәрсә?» кебек сораулар конкрет куела. Боларга җавап бирү эшенә керешеп, Г. Ибраһимов мондый тезисны алга чыгара: «Бездә шигырь белән нәзымны, шагыйрь белән назыймны һаман бутыйлар» (1, 80), – ди. Шуннан соң гына шигырь нәрсә һәм нинди булырга тиешлекне төгәл аңлатып бирә: «Безнең рух вә хыялымызга тәэсир итәчәк, хиссиятемезне, тәэссоратымызны кузгатачак һәрбер нәрсә – шигырь» (1, 81). Димәк, шигырь ул рухыбызга һәм хыялыбызга тәэсир итә, бу – беренчедән, ә икенчедән, хисләребезне һәм тойгыларбызны кузгата. Бер фикер тирәсенә җыеп әйткәндә, шигырь хис-тойгыларга корылган булырга тиеш, шигырь гомумән дә хисләрне тасвир итүдән тора, дип әйтә алабыз. Әмма онытырга да тиеш түгелбез: сүз Г. Ибраһимовның шагыйрьләр һәм шигърият алдына куйган таләпләре хакында бара. Бу чор – әдәби-эстетик эзләнүләр һәм табышлар дәвере дә әле.

Г. Ибраһимов С. Рәмиевнең шигырьләренең хис ташкынына корылган булуына, аларда әдәби хыялкүзаллау көчле булуга төп игътибарын юнәлтә. Бу исә әдипнең үз әдәби-эстетик карашларын да ачыкларга ярдәм итә. Аның карашында С. Рәмиев идеалист, идиллия шагыйре булып гәүдәләнә. Хис ташкынына килгәндә, алар арасыннан Г. Ибраһимов мәхәббәт хисе һәм тормышка нәфрәт белән өртелгән аһ-зар хисен аерып чыгара. Шушылар белән С. Рәмиев кабатланмас, баш бирмәс фикерче буларак та ачыла. Аның көчле рухлы булуыннан ул гыйсьянчылык һәм романтик омтылышлар күрми, ни сәбәпледер, ул хакта сүз дә алып бармый.

Г. Ибраһимов «Татар шагыйрьләре» мәкаләсендә С. Рәмиевнең шигырьләренә биргән бәяләре һәм ясаган анализлары белән үзенең әдәби-эстетик карашларының формалашып җитүен ачык күрсәтә, һәм, шул ук вакытта, аның, үз әдәби иҗатының төп юнәлеше итеп, экспрессионизмны сайлаганлыгына инанырга мәҗбүр булабыз. Шуның өчен ул үзенең әсәрләрен хис ташкынына кора, аның беренче хикәяләре, хәтта романнары да нәкъ шул юнәлештә иҗат ителгәннәр.

ӘДӘБИЯТ


1. Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда. – V т.: Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933) / Төзүчеләре, искәрмәләрне әзерләүчеләре: М. Х. Хәсәнов, Р. Р. Гайнанов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978.
2. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: Өч томда / Төзүчеләре: Абдуллин И. А., Вахитова С. Б., Газизова Ф. М. һ. б. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981.
3. Татар әдәбияты тарихы: Алты томда. – III т.: XX гасыр башы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986.
4. Әдәбият белеме сүзлеге / Төзүчесе Гыйззәтуллин Н. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1958.
5. Әдәбият белеме сүзлеге / Төзүче-редакторы Әхмәдуллин А. Г. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990.
6. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге / Төзүче-авторлар: Заһидуллина Д. Ф., Әминева В. Р., Ибраһимов М. И. һ. б. – Казан: Мәгариф, 2007.
7. Хатипов Ф. М. Әдәбият теориясе: Югары уку йортлары, педагогия училищелары, колледж студентлары өчен кулланма / Ф. М. Хатипов. – Казан: Мәгариф, 2000.
8. Хализев В. Е. Теория литературы: Учебник. – 3-е изд., испр. и доп. / В. Е. Хализев. – М.: Высш. шк., 2002.


# О ПЕРЕВОДАХ РАННЕЙ ПРОЗЫ Г. ИБРАГИМОВА НА АЗЕРБАЙДЖАНСКИЙ ЯЗЫК


*М. М. Гасанова (Баку)*


Творчество классика татарской литературы, известного ученого-энциклопедиста, видного государственного и общественного деятеля Галимджана Ибрагимова вписало яркие страницы в историю литературы как татарского, так и всех тюркских народов. Велика его роль в политическом пробуждении интеллигенции и прогрессивной молодежи этих народов России в начале XX века.

В Киевском университете им Т. Шевченко, одном из крупнейших учебных, научных и культурных центров страны и очаге освободительного движения, было создано «Мусульманское землячество», среди активных организаторов его были азербайджанцы: Ю. Везир Чеманземинли, А. Талышынский, Шафи бек Рустамбеков, Фирудин бек Ордубадлы, А. Алибеков, курсистка женских курсов естественного факультета Сона ханум

Ахундова, татары: Гюльсум ханум Ахтямова, секретарь мусульманского журнала «Анг» Галимджан Ибрагимов, будущий татарский писатель и его земляк Халид Еникиев (1, 102).

Приобщение к реальной политической борьбе нашло свое отражение в творчестве писателя Г. Ибрагимова. Его роман «Наши дни», написанный в течение нескольких месяцев 1914 г., отразил роль и значение прогрессивной молодежи в революции. Издан он был только в 1920 г.

По свидетельству писателя, обращение к жанру революционного романа было новаторством в татарской литературе. Это было важным и для других народов. Роман Г.Ибрагимова на азербайджанском языке вышел в издательстве «Азернешр» в 1935 году в переводе Расула Гаджизаде, под редакцией Сейида Гусейна.

Роль революции в судьбе тюркских народов стала определяющей и в творчестве азербайджанского писателя Ю. В. Чеменземинли, написавшего в том же 1914 году роман «Грех». В нем отразилась сложная и противоречивая жизнь азербайджанских студентов. Роман был издал под названием «Студенты» лишь в 30-е годы.

Оба писателя, представители двух братских тюркских народов, внесли ценный вклад в развитие тюркоязычной литературы, обогатили её, войдя в литературу со своей специфической тематикой и своей оригинальной художественной манерой письма.

В исследованиях по проблеме переводов художественной литературы значительное место отводится показу исключительной роли перевода как в деле ознакомления с передовыми идеями, популяризации научных достижений литературы и культуры, так и в обогащении родного языка. Художественный перевод стимулирует расцвет культуры каждого народа, содействует появлению новых жанров. Следовательно, он является важнейшим фактором взаимообогащения национальных литератур и культур. Будучи важнейшим средством культурного общения, переводческое искусство имеет свою историю, специфику, которая заключается в умении искусно передать на родном языке своеобразие национальной психологии иноязычной литературы.

История художественного перевода азербайджанской и татарской литератур берет свое начало в первое десятилетие XX столетия, когда сатира со страниц революционно-демократического журнала Дж. Мамедкулизаде «Молла Насреддин» привлекла внимание всей прогрессивной общественности мусульман Российской империи. Впервые под пером видного татарского поэта Габдуллы Тукая зазвучала на татарском языке сатирическая поэзия молланасреддинца, поэта-сатирика М. А. Сабира.

Начиная с 20-х годов XX в. переводы азербайджанской и татарской литератур определяются требованиями нового общественно-политического строя. Несмотря на то, что переводы произведений Галимджана Ибрагимова на азербайджанский язык относятся к началу XX века, его талант во всей полноте раскрылся после 1917 года. Воспитанный на многовековых традициях родной литературы Г. Ибрагимов в своем творчестве отразил достижения передовой общечеловеческой культуры, прогрессивные традиции дореволюционной литературы.

Литературное наследие Г. Ибрагимова необычайно богато. Им созданы десятки рассказов, повести, романы, которые переведены на многие языки и оказали благотворное влияние на развитие башкирской, казахской, туркменской, узбекской художественной прозы.

Эстетическое осмысление героической и сложной жизни той эпохи нашло свое отражение в повести «Сказание о красных цветах». Созданная в 1912–1922 гг. повесть рассказывает о пути простых деревенских парней в революцию, которая сыграла особую роль в судьбе татарского народа. Как утверждает М. Хасанов, исследователь творческого пути писателя, «именно органичность романтического и реалистического способов письма дает право утверждать, что «Сказание о красных цветах» обогатило татарскую литературу новым эстетическим качеством. Эта повесть – показатель постоянно свойственного Г. Ибрагимову поступательного художественно-эстетического развития» (2, 246).

В 1928 году азербайджанская общественность широко отмечала 20-летие литературной деятельности татарского прозаика, видного общественного деятеля Г. Ибрагимова. В издательстве «Азернешр» впервые были изданы его повести и рассказы.

Ученый-литературовед А. Мирахмедов в этой связи писал, что для этого были привлечены лучшие специалисты, редакторы М. Ариф, М. Гусейн, А. Эфендиев, Дж. Мамедов, А. Агаев и др. Несмотря на то, что они не имели специального образования по мастерству перевода, не постигли еще теорию художественного перевода, недостаточно освоили тонкости переводческого искусства, тем не менее хочется говорить с чувством признательности о выполненной ими работе.

Наряду с вышеназванными именами над переводами работали И. Нафиси, А. Сабир, С. Бейлярбеков и Худат Азизбеков, о котором А. Мирахмедов пишет как о пленнике оригинала. Будучи одним из старых переводчиков, прекрасно владевшим русским и азербайджанским языками, Х. Азизбеков не обладал творческой смелостью. И потому осуществленные им переводы не были удачны.

Наше внимание привлек перевод на азербайджанский язык повести Г. Ибрагимова «Сказание о красных цветах», впервые выполненный Гасаном Руфатовым. Мы не располагаем достаточными сведениями о самом переводчике, причине, побудившей его сделать замечательную повесть татарского писателя достоянием широкого круга азербайджанских читателей. Работая с архивными материалами исследуемого периода, мы обнаружили фамилию переводчика в документах научно-исследовательского института им. Низами АН Азербайджана. Но дальнейшая судьба этого переводчика и исследователя неизвестна.

Азербайджанская переводческая школа того времени формировалась в русле переводов с русского на азербайджанский язык и обратно. Перевод же, осуществленный Г. Руфатовым, является «первой ласточкой» среди переводов с татарского на азербайджанский язык. Хочется отметить, что татарскому переводчику Г. Руфатову удалось сохранить основную идею и содержание произведения, глубоко постичь художественные, выразительные особенности оригинала.

Повесть «Сказание о красных цветах» начинается с небольшого вводного авторского слова, озаглавленного «Кызыл тохумлар» (Золотые семена). Подобное традиционное начало настраивает читателя на фольклорный эпос. Писатель, показывая трудное, бедственное

положение татарского народа, пишет: «…мы поднялись со дна жизни. Кто, когда и как нам помог подняться?»

Зачином авторского замысла послужил рассказ некоего старика из этих краев, почувствовавшего близкую смерть. Он дает автору горсть семян (золотые семена), наказав посадить их дважды: весной и осенью. Когда зацветут золотые цветы, сад превратится в цветущий рай. Он наказал еще повсюду распространять эти необыкновенные цветы. Следуя совету старика, посадили семена весной. «После весенних дождей засияло солнце. Вскоре семена проросли и появились зеленые листочки… в летние дни они озарили сад радостью и красотой», а осенью посадить семена автор позабыл. И когда на почве перепаханной истории появилось новое молодое поколение, автор невольно вспомнил этих героев.

Действие в повести происходит в одном из селений Башкирии, прекрасном уголке природы, окруженном высокими горами и густым лесом, среди которых извивается бурная речка, именуемая «Аг Едил» (Белая речка). В честь этой бурной речки и село названо «Зенгер Чешме» (Голубой родник). Посреди села выстроена мечеть изумрудного цвета, минаретами устремившаяся ввысь. Окрашены в зеленый цвет дома. И на этом фоне показана судьба пяти деревенских парней, юность которых совпала с Октябрьской революцией и Гражданской войной .

В повести Г. Ибрагимова внутренний мир героев раскрывается через призму их отношений к главному событию эпохи – революции. Повествовательная форма, стиль изложения от первого лица придают повести эмоционально-лирическую насыщенность. Романтические черты сказались в стремлении писателя к ярким, исключительным ситуациям, к броским высказываниям и поступкам героев. Еще одна черта повести – близость её к сказу, хотя автор использовал реальный живой язык, – делает произведение доступным в хорошем смысле слова для читателя.

В процессе работы над оригиналом переводчик Г. Руфатов порой интуитивно обращался к дословной передаче имеющихся в тексте народных изречений.

Именно на это обращал внимание переводчиков К. Чуковский. Он считал, что пословицы, поговорки следует переводить с одного языка на другой дословно, а не заменяя реалиями другого языка.

Один из пяти героев повести, 14-летний подросток Шахбаз, сирота, живет с мачехой, которая невзлюбила его, считая нахлебником (в переводе это слово представлено как «харамхор»). Автор использовал такое народное изречение: «Сколько сироту ни корми, проку не будет». Правомерно поступил переводчик, сохранив на азербайджанском языке эмоциональность подлинника.

«Etim buzov beslersen ağzın yağ olar»
«Etim uşaq beslersen, ağzın-burnun qan olar» (3, 15).

Ранние рассказы и повести Г. Ибрагимова отличаются романтической направленностью. О роли романтического пейзажа в художественной литературе исследователь Н. Мурадалиева пишет: «...природа занимает в жизни человека, в его философских размышлениях, научных исканиях, в творческих борениях большое место, в том числе и в литературе, а в романтической – особенно. Еще более неисчерпаемым и активно используемым природным источником пейзажной антропоморфизации, создание типа пейзажной образности является растительный и животный мир» (3, 41).

В анализируемой нами повести неоднократно изображена чарующая природа края. Так, например, переводчик дает комментарий к слову «mərgən» – охотник, меткий стрелок (nişana vuran ovçu), что помогает восприятию горы Салават, названной в честь национального героя. Пейзажная образность отражена в воссоздании «Zəngər Çeşmə». Красота её подобна легенде о находящейся под лучами осеннего солнца неведомо откуда-то берущей свое начало «Ağ idel», извивающейся вокруг села … В минуты тягостных раздумий герой повести, озираясь на чарующую природу края, у могилы Салавата клянется, что достигнет поставленной цели. Пейзажная зарисовка повторяется, но уже в другой части повести. «Течет река Волга, вокруг высокие деревья тянутся к небу, и даже друг Салават (мерген) с уральских гор взирает на них…».

Известно, что национальный колорит с предельной отчетливостью проявляется в поэзии, ибо в ней концентрируются все его специфические черты. В стихах и песнях авторская мысль выражается в наиболее эмоциональной, впечатляющей форме. Художественная выразительность здесь достигается посредством ритма, строфики и рифмы.

В повести стихи занимают значительное место, способствуют восприятию чувств изображенных героев. Примечательны стихи, включенные писателем в текст повести:

Bu bülbüllər gəlmiş bizə, gedərlərmi payız yenə?
Yayın saban toylarını dönərmiz əcəb biz də? (4, 20)

В повесть вплетено небольшое двустишие о празднике сабантуй, имеющем огромное значение в жизни трудолюбивого татарского народа. Правомерно поступил переводчик, сохранив на азербайджанском языке идейно-эстетическую ценность стиха. Подобно пейзажу, дважды описанному в тексте произведения в XXI и XXIII частях рассказа, это двустишие под звуки гармони выражает чувства героя как в счастливые минуты жизни, так и в дни печали и грусти. Несомненно, это было обусловлено общностью языков, обычаев и традиций наших народов. Оно было отражением лингвистических особенностей тюркского языка. Наши языки имеют общие истоки, характерные для всех тюркских языков. И в силу этих причин перевод, осуществленный Гасаном Руфатовым, близок и доступен восприятию широкого круга азербайджанского читателя.

В 1928 году в Баку была издана книга «В преклонные годы», состоящая из трех рассказов, написанных на разных этапах творчества Г. Ибрагимова. Они вышли в переводе с татарского Ашии Шамсетдиновой. Редактором книги был А. Бабазаде. В предисловии к рассказам читаем: «Пока это издается в форме книги, т. к. они тематически и идейно дополняют друг друга. Сохранив основную идею и содержание, внесено несколько литературных и орфографических поправок».

Татарский ученый М. Хасанов пишет, что лучшим свидетельством того, насколько весомой была доля романтической эстетики в художественном развитии писателя, служит его творческая практика 10-х годов – рассказы той поры. Так, в 1911 году рассказ «В море» был издан в двух номерах ж. «Шуро» № 6–7.

В рассказе создан образ человека, находящегося в разладе с действительностью, ищущего уединения, покоя в природе. Ему «хочется жить и жить тысячи и миллионы лет, но не той жалкой – телесной жизнью, а другой – прекрасной, возвышенной. Но где она? Где такая жизнь? На небесах ли, среди звезд или на луне та жизнь, которая грезится ему?»

Отличительная черта этого произведения в отрицании, ярком, страстном протесте. Но герой не ведает, как можно изменить эту жизнь, достичь желаемого. В рассказе описана романтика ночного пейзажа, «когда звезды увеличиваются и превращаются в сверкающие алмазы… природа, небо, луна, звезды вроде бы они везде есть, в городе их не так воспринимаешь, как в море…»

При сопоставлении рассказа писателя с переводом на азербайджанский язык можно заметить как мастерство писателя, так и умение переводчика А. Шамсетдиновой при воссоздании ночного романтического пейзажа: «Uzaqda açıq göydə nurlu ulduzlar doğmağa başlayırdı. Gecə yaxınlaşdıqca onlar artır, çokalır və elə bir hala gəlirdilər ki, bütün göy üzü guga parlayan almazlara bəzənmiş olurdu. Bakırsan özünün də dünyanı da unudursan. Xəyalın güya səni ikinci dünyalara, gözəllik, şeyriyyat ilə dolmuş yeni ilahi aləmlərə alıb getməkdə idi. Ürəyini daşa dondurmuş olan ağır əzablar, baş qarışdıran böyük-böyük əzablar, əzəiyyətlər, qüdrət əli ilə götürüb, dərin bir səadət içinə dalırsan…» (6, 30).

Перевод при всех своих неоспоримых художественных достоинствах и огромной силе воздействия может быть не точен, несколько отдален от оригинала. При всём том, переводы способствуют углубленному постижению художественного стиля писателя и культуры народа, язык которого развивает стиль и красоту родного языка, побуждает к творческой работе. Перевод сближает народы, представляя возможность проникнуть во внутреннюю мастерскую другого народа. И в этом его самое главное достоинство.

ЛИТЕРАТУРА


1. Ибрагимова М. В горниле борьбы //Литературный Азербайджан. – 1987. – №5.
2. Хасанов М. Галимджан Ибрагимов. – Казань, 1977.
3. İbrahimov A. Qızıl çiçəklər. – Bakı, 1928.
4. İbrahimov A. Qızıl çiçəklər. – Bakı, 1928.
5. Мурадалиева Н. Романтический пейзаж в литературе. – Баку: Язычы, 1991.
6. İbrahimov A. Qocalıq günlərində. – Bakı, 1928.


# Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ «ЯШЬ ЙӨРӘКЛӘР» РОМАНЫ ТУРЫНДА ЗАМАНДАШЛАРЫ


***Ә. Х. Алиева (Казан)***



В статье исследуются отзывы писателей – современников Г. Ибрагимова о его новом большом романе «Молодые сердца», который был издан в 1913 году. Литературная критика восторженно восприняла данное произведение, отмечалось, что оно является новым этапом в истории татарской литературы, а его автора объявили основателем психологического романа. В печати появилось сразу семь рецензий. В них подчеркивалось философский характер, романтическая направленность книги. Авторы в оценке произведений не одинакового мнения, но все они едины в утверждении, что «Молодые сердца» – это совершенно новый тип жанра романа в татарской литературе.


Күренекле әдип Г. Ибраһимовның 1913 елда дөнья күргән, роман жанрында беренче тәҗрибәсе булган «Яшь йөрәкләр» әсәре әдипнең үз иҗатында гына түгел, гомумән, татар әдәбиятында яңа бер этап булып тора. Әдәбият галиме Д.Заһидуллина билгеләп үткәнчә, бу әсәр «...XX йөз башында иҗат ителгән олы эпик жанр үрнәкләре арасында фәлсәфи характеры белән аерылып тора. Сюжет бирелеше белән ул шулай ук үз чоры тормышын тергезә» (5, 8).

Бу әсәре белән Г. Ибраһимов татар әдәбиятында психологик роман жанрын башлап җибәрә. Әсәр романтик рухы, күтәрелгән проблемалары, автор үзәккә куеп сурәтләгән яңа тип геройлары белән укучыларда зур кызыксыну уята һәм, әйтергә кирәк, замандашлары тарафыннан бертөрле генә кабул ителми, төрлечә бәяләнә. Роман басылып таралу белән үк, татар әдипләре, үз фикерләрен белдереп, вакытлы матбугатта – газета-журнал битләрендә күп санлы рецензияләр язып чыгалар (1; 2; 4; 6; 8; 9; 10).

Нәрсәләргә, нинди проблемаларга игътибар иткәннәр соң әлеге авторлар? Кайбер фикерләргә тукталып үтик. Барысы өчен дә уртак фикер күзгә ташлана: алар бу әсәрнең татар әдәбиятында романтик характердагы беренче тәҗрибә булуын ассызыклыйлар һәм «Яшь йөрәкләр» кебек яңа типтагы зур күләмле милли роман иҗат итүе авторның зур уңышы дип исәплиләр.

Г. Зәбиров «Шура» журналында болай яза: «...китапның бәгъзе кимчелекләренә карамаганда, тулаем алганда, татарга милли идеал бирү өчен язылган. Һәр яшь татарның зиһенендә милли хис, ... милли идея урнашырга тиеш... Татар әдәбиятының кимчелеге дә шунда иде, милли хисләрне бирергә, милли идеаллар артыннан йөгертергә тырышып язылган китаплар юк дип әйтерлек иде. Ниһаять мөхәррирләребездән Г. Ибраһимов әфәнде алга таба зур бер адым ясады» (6, 312–313). Зыя образын да бу автор үзенчә аңлата: «Яшь татарлыкның асыл рухы итеп Зыя күрсәтелгән. Романны язудан да максат бу җәһәт булса кирәк. Зыяның бар фикере татарга җан өрү, йөрәген уятудыр. Ул алгы көннең күгендә ялтыраган өмид йолдызы өчен тырышуны төп фикер итеп тота, хәтта бу фикернең корбаны, шәһиде булып дөньядан китә» (6, 313).

Чынлап та, романда төп каһарманнарның берсе – Зыя образы. Авторның идеалы да Зыя образында гәүдәләнә. Хәтта Зыя образына мөнәсәбәтле авторның милли фәлсәфәсе дә чагылыш таба. Романтик герой Зыя язмышны, мохитне үзгәртү юлын музыкада таба:

«Музыкам белән татарның аслы рухын уйгатырмын, күгәргән йөрәген сафландырырмын һәм аның авыр язмышына бер үзгәреш бирермен, томанлы вә караңгы хәятына бер нур тудырырмын», – ди (7, 314).

Г. Гобәйдуллин, мәсәлән, әсәрне анализлап, романның сюжетына төзеклек һәм төреклек җитеп бетми дип билгели. «“Яшь йөрәкләр”дә... шагыйренә язылган тасвирларга очрыйбыз. Типларның шактый муаффәкыятьле булуларын күрәмез – шуның өчен шагыйрьнең истигъдадының куәтләнүе белән хөкем итә алабыз. Ләкин бу матур тасвирлар, кызык вакыйгаларны, арадагы сузылып, киңәйтелеп җибәрелеп язылган урыннары укучыны ардыралар; романның вакыйгалары берсе артыннан берсе ерак булмый, кирәк вакытта хәрәкәтләрне биреп, тасвирларны куертып, лирикага бирелгән сәтырларны урынында үлчәп кенә тыгып җибәрсәң укырга күңелле була, ләкин монда алар кирәгеннән артык күренә...», – ди (2, 192).

Г. Гобәйдуллин Зыя образын шул чор татар мохитендә «...тормышка муафыйк, тик татар галәмендә, бигрәк тә фанатизм золымы астында тәрбия кылынган халыкта була торган бер типтыр, – дип атый, – ...шагыйранә табигатьне “музыка тилесе”. Ул “урталык” җимеше: 1905 елларның буранлы инкыйлаблары арасыннан чыккан. Ул еллар аны инкыйлабчы итеп ясамыйча, матурлык сөюче, “музыка тилесе” ясаганнар... хәтта Зыяның Мәрьямгә булган гыйшкы да, мөхәррирнең музыка сөюне бик куертуы сәбәпле, зәгыйфь, сыек булып чыккан», – дип билгели (2, 192).

Музыкага гашыйк, хискә бай романтик герой Зыя читтә, башка мохиттә, музыкага мөкиббән китеп гомерен үткәрсә дә, үзенең милли асылын югалтмаган. Шулай да Зыя, тәнкыйтьче галим фикеренчә, «зәгыйфь, хатыннар табигатьле, мәңгелек трагедия әһеле» (2, 192) булып гәүдәләнә. Һәм ул аның шулай булуын җәмгыятькә, мохиткә бәйләп күрсәтә. Чөнки сәләтле яшьләргә милләт файдасына хезмәт итәргә шартларның булмавын чынбарлык белән шәхес каршылыгында күрә. Бәяләмәдән аңлашылганча, тәнкыйтьче Зыяны романтик герой буларак тикшерә. Әмма ул сүлпән шәхес, иҗтимагый, гамәли эшкә сәләтсез, татар дөньясындагы гаделсезлекне күреп газап чигүче генә. Аның ихтыяр көче дә, идеалларының тормышта социаль-сәяси таянычы да юк.

Г. Гобәйдуллин Зыя образын сурәтләгән тагын бер моментны ышандырырлык түгел, дип күрсәтә: «...Зыяның теге картны үтерү кыйссасы бик зәгыйфь чыккан. Фикеремчә, мөхәррир үзе дә ни эшләргә белмәгән булырга кирәк... Кеше үтергәч катыйльдә булган хәләте рухия бик зәгыйфь тасвир ителгән: имеш, бер-ике мәртәбә күзгә күренә, төшкә керә дә бетә. Зыя хисчән, романтик, үзенең рухындагы кечкенә генә селкенүне дә санап тора торган бер адәм... Зыя бер гөнаһсыз адәмне үтергәнгә ничек мөтәэссир булырга кирәк? Мәгәр монда иң зур «мәңгелек трагедия» булырга кирәк иде», – дип образның төгәлләнмәвенә ишарә ясый (2, 193).

Романда Җәлал мулланың олы улы Сабир шулай ук үзгәреш чоры вәкиле. Ул үз мохитеннән тулаем аерыла, башка статуста яшәү рәвешенә күчә. Аның үз стихиясе бәхеткә ирешү юлы буларак тасвирлана. Г. Гобәйдуллинның бу образга карашы түбәндәгечә: «Сабир Зыяның капма-каршысы, ул чын Руссо фикерендә. Эш өчен, чын кул эше өчен туган бер кеше. Ул мәдәниятне яратмый, шәһәрне сөйми, аңа хәтта язу тану да мөһим түгел, ул шундый кызны хатынлыкка ала. Ул җитди кеше, сабыр, гакыллы, уйчан. Зыя хис белән яшәсә, Сабир гакылы белән яши.

Менә бу ике борадәрне һәм башка әллә ничә мулла, үзгәреш күргән кешеләрне (чөнки бу типлар шуның җимеше) тасвир иткәндә, мөхәррир үзгәреш заманын һәм аның кешеләргә ничек тәэсир иткәнен аз яза. Әмма бу бик мөһим мәсьәлә, ... шактый язылырга тиеш иде», – дип ассызыклый (2, 192–193).

Җәлал мулла образы турында тәнкыйтьченең фикере бертөрле: «Бу тип, гомумән әйткәндә, шактый гына муаффәкыятьле чыккан. Җәлал мулла, мулла булса да, гаиләсен рәнҗетергә, җәбер кылырга ярата торган, табигате белән гомуми татар бае... Ул дан, ... шөһрәт яратучан. Мещан һәм бай муллаларында очрый торган бер тип булып чыккан», – дигән нәтиҗә ясый (2, 193).

Романда шактый гына зур урын тоткан Мәрьям образы турында карашлары түбәндәгечә: «Ул кыз вакытында, мөхәррирнең сүзе буенча, “мохитнең колы” акрын, юаш табигатьле бер кыз. Ләкин Фәхригә кияүгә баргач, романнан күренгәнчә, психологик романнар каһарманы булырга лаек була. Ул лампа белән киявен яндыра... Кызлык дәвере хатынлык дәвереннән күпкә яхшы чыккан... Ул – сентименталист, зәгыйфь табигатьле, куркак, әмма азакта бер дә алай булып күренми...» дип бу образның бик үк ышандырырлык түгеллеген әйтеп уза (2, 193).

Билгеле булганча, романга беренче бәяләмә цензура комитеты тарафыннан бирелә. Алар бәяләмәсендә мондый юллар бар: «Авторның Мәрьямгә карата хөрмәте булса да, бездә симпатия уятмый. Зыя дустына язган хатында Мәрьямнең башкалар арасында рухи байлыгы, матурлыгы белән аерылып торуын яза... Ләкин әлеге рухи байлык һәм матурлык нәрсәдә күренә соң? Бу сорауга без җавапны таба алмыйбыз. Киресенчә, Зыя Мәрьямнең тышкы матурлыгын гына тасвирлый. Мәрьямнең әнисе янында буш, мәгънәсез тормыш итүе гаҗәпләндерә... Аны беркем дә көчләп бирергә теләмәсә дә, яратмаган кешесенә кияүгә чыга. Тормышка чыккач, Мәрьям җинаять юлына баса һәм... шуның өчен сөргенгә озатыла. Суд вакытында үкенү урынына гаделсезлектән зарлана. Ләкин аңа карата кем гаделсез булуы аңлашылмый кала» (3, 157–158). Цензор биредә рус мохите күзлегеннән чыгып эш итә. Чынлыкта исә Мәрьямне даирәсе кияүгә чыгарга мәҗбүр итә; аның сайлау мөмкинлеге юк. Тормышыннан риза түгеллеген бердәнбер чара – ирен үтерү юлы белән белдерә, шуңа күрә судта Мәрьям гаделсезлек турында сүз алып бара да.

Г. Ибраһимовның икенче бер замандашы Җамал Вәлиди «Яшь йөрәкләр»гә язган бәяләмәсендә (4) татар җәмгыятенең шул чордагы тормышына анализ бирә, ягъни яшьләргә үзләре теләгәнчә уйларга, тоемларга, барыннан да элек татар тормышының тарлыгы кыса, дип яза. Чөнки бу яшь йөрәкнең күбесе дөньяга әнә күзе аркылы гына карый торган каты куллы хәзрәтнең һәм... бала җанлы абыстайның «әлли-бәлли итәр бу, Бохарага китәр бу» дип үстергән баласы, яки дөньяга әнә күзеннән дә тар бер тишектән караучы бер байның колы, ... хезмәтчесе. Әгәр дә ул дөньяны үз күзләре белән күреп, үз фикере белән танырга, үз башы белән уйларга теләсә, ата-ана, хуҗа, җәмәгать разый түгел, үз юлы белән яши башласа да моңа җан тынычлыгы юк; чөнки тегеләр ... бигрәк тә... ананың рәнҗүе яшь йөрәкне борчый. Ул тормыш чынбарлыгы белән үз идеалы арасында барып җитә алмаслык дәрәҗәдә ераклык икәнен

аңлый. Менә яшь йөрәк газаплана башлый. Аның йөрәгендә трагедия, ди тәнкыйтьче.

«Галимҗан әфәнде Ибраһимовның яңа чыккан “Яшь йөрәкләр” исемле бөек романында шундый яшь йөрәкләр күрәбез. Сабир белән Зыя бертуган ике яшь йөрәк. Алар Җәлал мулланың мәхдүмнәре. Хәзрәтнең угылларында өмиде бик зур. Аларны, үзе ирешә алмаган хыялын тормышка ашырып, ахунд һәм мөдәррис итәсе килә. Ләкин угыллары башка юлдан китә. Заман... тәэсиреннәндерме атаның әмәле белән баланың гамәле капма-каршы килеп бәрелешә...» (4).

Романның үзәгенә искелек белән яңалык көрәше проблемасы куеп сурәтләнгән. Бу көрәш аталар белән балалар арасындагы каршылыкка корылган. Төп каршылыклар исә һәр ике якның тормышындагы омтылышлары, үзләре сайлаган яшәү рәвешләре арасындагы аермадан гыйбарәт. Романда сурәтләнгән геройлар яңача, үзләренең хыялындагыча, үзләре дөрес дип тапкан рәвешчә яшәргә омтылган яшьләр. Аларның кичерешләре, шәхесне чолгап алган мохиткә бәйлелеге мәсьәләсе әсәрнең үзәгендә куелган.

Җамал Вәлиди, «Яшь йөрәкләр»не укыгач, ике төрле төп нәтиҗәгә килүен яза: «Беренчесе: татарның хәзерге тормышы күзле, колаклы, йөрәкле, миле булган, күрү, ишетү, сизү, уйлау кабилияте булган инсан өчен гаять дәрәҗәдә тар, караңгы, яшерен. Ул синең сөекле дустыңны күрсәтми, син ишетергә теләгән тавышны ишеттерми, уйлаганыңны... тышка чыгарырга ирек бирми. Әлбәттә, бу хәлгә үзенең инсаниять кыйммәтен аңлаган яшь йөрәк чыдый алмый... Музыкасыз дөньяда тора алмадыгы хәлдә, шул музыка остазы, ата-анасы каршында кеше үтерү, урлау, эчү илә бер дәрәҗәдә санала. Бу кешегә ни эшләргә кирәк – үләргә!? Ул үлә. Аны тормыш кысып үтерә.

Икенчесе: хисле йөрәкле вә назик кешегә дөньяда тору кыен, тормыш дәрьясында идеал эзләп еракка китүче Зыяларны дулкын алып һәлак итә, әмма бик эчкә китмичә, кырыйдарак кына балык тотучы Сабирлар җилдә дә, дулкында да яши алалар», – дип нәтиҗә чыгара әдип (4).

Җ. Вәлиди романга, нигездә, уңай бәя бирә: «“Яшь йөрәкләр” үзенең зурлыгына карамыйча, Галимҗан әфәнденең башка әсәрләреннән ким түгел... әсәр күркәм һәм камил чыккан. Бигрәк тә сүзгә осталык вә фикергә байлык җәһәтеннән бу әсәр татар әдәбиятында беренче урынны тотарлык», – ди. Аның романтик рухта һәм психологизм белән сугарылган булуына да игътибар итә: «Галимҗан әфәнде монда кирәгеннән артык шәхси һәм лирик (эчке шагыйрь) булып күренә шикелле. Ул тормышның иң ачык күренеп торган ноктадарыннан бигрәк үзенең хыялында ялтыраган образларны күрсәтә» (4).

Тәнкыйтьче әсәрнең кимчелекле яклары итеп түбәндәгеләрне атый: «ачык типлар вә характерлар әсәрнең зурлыгына, киңлегенә караганда азрак. Сюжетта төгәллек җитешми, кайбер күренешләр, эпизодлар бертөрлерәк, кабатлана кебек, шуңа да әсәр кирәгеннән артык озайтылган» дигән фикер әйтә (4).

Г. Ибраһимовның замандашы әдип Ф. Сәйфи-Камалны да бу әсәр битараф калдырмый: «“Яшь йөрәкләр” чын мәгънәсендә роман. Биредә мәхәббәт, хәсрәт, кайгы, үтерешү, катыйле нәфес, кинәт алмашынулар, капма-каршы фикерләр тартылышуы тулып ята, биредә аерылышулар, хыянәт, алданулар һ. б. бар, – дип яза ул. – Мөхәррирнең романда күрсәтергә теләгән төп идеясе – иске тормыш белән сәгадәткә ирешергә ашкынган яшь тормышның көрәшен күрсәтү. Икенчесе, гасырлар буена килгән аксөяк (Фатыйма бикә) сыйныфы белән кара халык (Җәлал мулла – авыл кешесе) сыйныфының көрәшүедер. Бу ике төрле көрәшне мөхәррир күрсәтә алган» (8, 50) дип раслый.

Әмма романда тасвирланган геройларга мөнәсәбәттә аның фикере үзенчәлекле: «Бөтен күрсәтелгән типлар арасында бер генә дә тәмам тулы сурәтләнгән, түгәрәкләнгән, тормышта күрсәтерлек бер тип та юк дисәк дә гөнаһ булмас. ... иң ачык күрсәтелгән, иң мөкәммәл каралган герой бары тик Җәлал мулла тибы, – дип аерып күрсәтә ул. Фикерен дәвам итеп, – әгәр дә мөхәррир Сабир образын тирәнрәк ачса, халык арасында еш очрап торган, әле моңарчы әдәбиятта бер генә мәртәбә дә сурәтләнмәгән мөстәкыйль бер тип иҗат иткән булыр иде», ди. Әмма аңа романда бик аз урын бирелүен әйтә.

Ф. Сәйфидә Зыя образы уңай фикер тудырмый. «Бөтен роман Зыяның аһ-фәганнәре белән тулса да... эч пошу, ялыктырудан башка бер тәэсир дә калдыра алмаганга, бу герой хакында бер фикер дә әйтеп булмый, – ди. – Белмим мондый тип кешене автор каян эзләп тапкандыр» (8, 54) дип, бу образны бөтенләй кабул итмәвен аңлата.

Мәрьям туташ образы турында Ф. Сәйфинең карашлары алда китерелгән авторлар фикеренә якын тора. Аның трагедиясендә мохитнең ролен инкяр итми, «ике сыйныфның көрәшүе нәтиҗәсе» дип тә расларга тырыша.

Автор бу тәнкыйть мәкаләсендә романның җитешмәгән якларыннан берсе итеп техник ягына ишарә итә. Укыганда ялыктыра торган урыннар күп, бер йомгакка җыела килгән җепләрне кинәт чуалтасың. Кайбер фасыллар (мәсәлән, бишенче фасыл) бөтенләй коры сентиментализм белән тулган, дип һ. б. шундый кытыршы якларны санап күрсәтсә дә, роман турында тулаем уңай нәтиҗә ясый.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Г. Ибраһимовның XX йөз башында иҗат ителгән «Яшь йөрәкләр» романында татар милләте язмышы, аның киләчәге мәсьәләсе күтәрелгән. Әсәрнең үзәгендә милләтнең азатлыкка омтылу идеясе ята. Катлаулы иҗтимагый шартларда җәмгыятьтә яңа тип шәхесләр барлыкка килүе сурәтләнә. Романтик рухта язылган, геройның чынбарлык белән мөнәсәбәтен тирән психологизм белән тасвирлаган бу әсәр үз замандашларын битараф калдырмый.

Роман турында матбугат битләрендә шактый төрле бәяләмәләр пәйда була. Авторлар үз язмаларында романны анализлап, төрлечә бәяләсәләр дә, бердәм уртак фикер – Г. Ибраһимовның татар әдәбиятында яңа тип роман тәкъдим итүе бәхәс уятмый.

## ӘДӘБИЯТ

1. Авыргазый. Яңа әсәрләр. «Яшь йөрәкләр» // Йолдыз. – 1913. – 24 янв. – № 935.

2. Газиз Г. Яшь әдәбиятыбызда «Яшь йөрәкләр». Тәнкыйть // Аң. – 1913. – № 11. – Б. 189–194.

3. Гыйләҗев З. З. Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романына цензура бәяләмәсе// Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман: Тууына 115 ел тулуга багышланган фәнни конф. материаллары. – Казан: Фикер, 2002. – 272 б.

4. Җәләй. Әдәби мосахәбәләр. «Яшь йөрәкләр» // Вакыт. – 1913. – 28 февр. – № 1141.

5. Заһидуллина Д. Язучы, галим, җәмәгать эшлеклесе // Мәгариф. – 2012. – № 2. – Б. 6–9.
6. Зәбиров Г. «Яшь йөрәкләр» китабы мөнәсәбәте илә // «Шура». – 1913. – № 10. – Б. 312–313.
7. Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. – Т. 2: «Яшь йөрәкләр», «Казакъ кызы». – 477 б.
8. Сәйфи Фатыйх «Яшь йөрәкләр» (Тәнкыйть) // Хокук вә хәят. – 1913. – № 3. – Б. 49–54.
9. Уйгур. «Яшь йөрәкләр». Роман // Йолдыз. – 1913. – 21 апр. – № 972.
10. Хөсни. Матбугат дөньясыннан «Яшь йөрәкләр» // Идел. – 1913. – 21 февр. – № 530.

# Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ «ЯҢА КЕШЕЛӘР» ДРАМАСЫНДА ЯҢА ЧОР ИҖАТ КОНЦЕПЦИЯСЕ ЧАГЫЛЫШЫ

*Ә. М. Закирҗанов (Казан)*

Драма «Новые люди» – первое произведение Г. Ибрагимова, написанное после Октябрьской революции. В статье, на основе анализа идейно-эстетического содержания драмы, рассматриваются нравственные и философские поиски автора. Как политический и общественный деятель всецело поддерживая новые начинания советской власти, Г. Ибрагимов в своем творчестве все же остается на позициях гуманизма.

Күпсанлы хикәя-романнары белән татар әдәбияты Яңарышының нигез ташларын салышкан, аның әдәби-эстетик эчтәлеген, үсеш-үзгәреш юнәлешен билгеләгән Г. Ибраһимов иҗаты ХХ йөз башы татар сүз сәнгатендә гаять мөһим урын алып тора. Әдипнең киңкырлы иҗатыннан башка бу чор әдәбиятының тема һәм мотивлар төрлелеген дә, проблематика һәм идея эчтәлеген дә, реалистик һәм романтик сурәтлелекнең төс-төсмерләрен дә тулысынча аңлап һәм аңлатып булмый. Бөтен иҗаты милли эчтәлек белән сугарылган әдип 1917 елгы инкыйлабларны шатланып каршы ала һәм иҗтимагый-тарихи, социал-мәдәни вакыйгалар үзәгендә кайнап, милли лидерларның берсе буларак таныла. Октябрь инкыйлабының төп максаты буларак тигезлек, туганлык, ирек идеясенең гасырлар дәвамында изелеп яшәгән халыкка ачык һәм аңлаешлы булуы, гражданнар сугышында халыкның большевикларны яклавына китерә. Шуның белән бергә, инкыйлаблардан соң башланып киткән гражданнар сугышы, һәм аклар, һәм кызыллар ягыннан алып барылган террор, бер милләт кешеләренең генә түгел, ата белән улның, туган белән туганның бер-берсен үтерүгә барып җитүләре, большевиклар урнаштырган пролетариат диктатурасы бик күпләрдә, аеруча зыялылар катлавында каршылык-бәхәсләр уята. Әлеге катлаулы вакыйгалар язучыларны сайлау алдына куя, мөнәсәбәтләрен ачыклауны таләп итә. Гадәттәгечә, бу елларда поэзия алга чыгып, М. Гафури, Ф. Бурнаш, С. Сүнчәләй, Ш. Бабич, Г. Камал, Н. Исәнбәт, Ш. Фидаи һ. б. иҗатында көндәлек хәл-күренешләргә караш чагылдырыла, бәя бирелә. Бер үзенчәлек буларак драматургиянең дә шактый активлашуы күзәтелә һәм гражданнар сугышы елларында Ф. Бурнаш, М. Фәйзи, Г. Ниязбаев, Ф. С.-Казанлы, Ш. Госманов, Г. Ибраһимов һ. б. пьесалары языла, сәхнәләрдә уйнала. Әсәрләр төрле булып, безнең игътибар үзәгендә инкыйлаб һәм гражданнар сугышы вакыйгалары чагылыш тапкан Ф. Сәйфи-Казанлының «Дошманнар» (1919), Ш. Госмановның «Канлы көннәрдә» (1919), Г. Ибраһимовның «Яңа кешеләр» (1920) драмалары тора. Әлеге пьесалар белән «тарихи-революцион» һәм «героик драма» жанрларына нигез салына (3, 89). Әсәрләр әдипләрнең вакыйгаларга мөнәсәбәтен, иҗат юнәлешен, әдәби-эстетик эзләнүләрен, шәхес концепциясен ачу ягыннан төрле һәм бик тә гыйбрәтле. Әгәр Ф. Сәйфи-Казанлы «Дошманнар» драмасында мәхәббәт хисе дә сыйнфый каршылыкларны ачуга, өстен сыйныф вәкиленә булган нәфрәт хисенә буйсындырыла дигән фикер үткәрелсә, Ш. Госмановның «Канлы көннәрдә»сендә сыйнфый каршылыкның зур һәм котылгысыз булуы күрсәтелә, шулай да автор милли бердәмлек идеясен яклау юлына баса. Әлеге әсәрләрдә чор күренешләренә бәя бирү, каршылыкка кергән якларның максатын ачу өстенлек итә.

Г. Ибраһимовның «Яңа кешеләр» драмасы вакыйга-күренешләргә бәя биреп кенә калмый, бәлки яңа җәмгыятьне төзүче яңа кешеләрнең көрәш мәйданына чыгуын, формалашуын һәм моның гаять җитди эчке каршылыклар аша баруын сурәтләве белән аерылып тора. М. Хәсәнов, әдипнең үзе өчен яңа әдәби төр булган драматургиягә килүенең сәбәбе турында уйланып, Г. Ибраһимовның яңа карашларын тизрәк һәм күбрәк укучы-тамашачыга җиткерәсе килү белән аңлата (6, 142). Гомумән, әлеге драма гражданнар сугышы чоры татар әдәбиятында барган эзләнүләрне аңлау-аңлату ягыннан һәм яңа иҗтимагый-тарихи, мәдәни-социаль шартлар тудырган әдәбият үрнәге буларак әһәмиятле. Шуңа да ул үз вакытында да, бүген дә зур кызыксыну уята. М. Мутин тарафыннан сәхнәләштерелгән әсәр шактый бәхәс тудыра. Әлеге мәсьәләне махсус тикшергән М. Арсланов билгеләп үткәнчә, М. Мутин, гражданнар сугышы чорының тормышчан картиналарын тудыру белән бергә, кешеләр аңында революцион гуманизм идеясенең расланууын ачарга омтыла (1, 68). Әсәрнең ХХ гасыр дәвамында бәхәсләр уятуын Р. Салихов та ассызыклый. Ул драмага һәм аның сәхнәгә куелышына мөнәсәбәтле Ш. Хөсәнов, Ф. Бурнаш, Г. Нигъмәти, М. Хәсәнов, Г. Халитларның хезмәтләренә күзәтү ясап, төп мәсьәләнең герой концепциясе белән бәйлелеген күрсәтә (5, 44–48). «Яңа кешеләр»не максатчан өйрәнгән Г. Мөхәммәдова фикеренчә, әсәрдә сыйнфый көрәш сәбәпләрен ачу белән бергә, милләтләр киләчәге турында җитди сүз бара: «Татар өчен милли азатлык мөһим булса, урыс өчен – бүленмәгән бөтен бөек Россия» (4, 132). 1917–1920 еллар татар сүз сәнгатендәге эзләнүләр киң планда бер фокуска туплап бирелгән. Икенче яктан, «Яңа кешеләр» пьесасы 20–30 нчы еллар әдәбиятына гаять көчле йогынты ясый, ягъни анда урын алган мотивлар, караш-фикерләр

байтак әдипләрнең иҗат концепциясендә чагылыш таба.

Г. Ибраһимовның «Яңа кешеләр» драмасы үз чорының канлы вакыйгаларына ияреп язылган һәм анда гражданнар сугышы фаҗигасе, аянычы бөтен тулылыгында күз алдына бастырыла. Беренче күренешләрдә үк каршылыкның ике сыйныф арасында булуы билгеләнә. Әгәр авыл бае Хәйри һәм аның хатыны Зөһрә бүгенгенең ыгы-зыгысыннан, мәхшәреннән туеп («бары да шул кызыл иблисләр шомлыгы»), үткәннең тыныч, рәхәт көннәрен сагынсалар, ярлы халык изелеп, кимсетелеп, кол хәлендә гомер итүдән интизар булып, бәхетле тормышны көтеп яши. «Аклар» хәрәкәте беренчесен яклаcа, «кызыллар» икенчесен – халык мәнфәгатен яклап сугыша. Большевиклар иректә, азат, матур тормышка ирешүнең юлын сыйнфый көрәштә күрәләр һәм халыкны да шуңа ышандырырга тырышалар. Әлеге көрәшнең башында торучыларның берсе булган Батырханның «Алайса, безнең монда халык бер-беренә каршы ике класска нык аерылышып җиткән. Сез алайса нык эшләгәнсез»? – диюенә, Шәнгәрәй болай дип җавап бирә: «Бай белән ярлы бугазга-бугаз килеп сугышалар инде».

«Г. Ибраһимов революция тудырган һәм революцияне ясаган көрәшчеләрне “яңа кешеләр” дип атый, яңа дәвернең үзенчәлеген һәм өстенлеген иң әүвәл шундый каһарманнарда күрә» (2, 170). Якты киләчәк өчен көрәшкә ташланган «яңа кешеләр» булып, беренче чиратта, Батырхан, Камәр, Тимеркәй тора. Әмма алар бертөрле генә түгел, һәрберсе үз максат-теләге белән яши, үз йөзе, характеры белән ачыла.

Кызыл командир булып җитешкән Батырхан 7 ел элек хатыны турында гайбәт сүз сөйләгәне өчен Кәҗә Якуб улы Саткайны балта белән сугып үтерә һәм каторгага сөрелә. Аннан качып, Бөтендөнья сугышы фронтлары аша инкыйлаб хәрәкәтенә килеп кушыла. Автор аны һич тә кансыз командир итеп кенә сурәтләми. Ул үзенең гөнаһлы булуын да аңлый. Акгвардиячеләрнең бер гаепсез кешеләрне үтерүләрен күргәч кенә, канлы үч алу юлына килә: «Безгә дә, безнең эшче-крестьян халкына да контрреволюционерларның башлары өстеннән азатлыкка барырга туры килә... Башка юл юк... <...> Юл бер генә! Менә шушы канлы юл – изге юл!»

Драмада укытучы Камәр гаять үзенчәлекле «яңа кеше» образы булып тора. Романтик табигатьле кыз үзенең хыял дөньясында яши. Көрәш юлына килүенең сәбәбен болай аңлата: «Иске тормышның барлык “хозурларын” үз йөрәгемдә татыдым... <...> Мин беренче сөюемдә тирән бер бәхетсезлек күрдем... <...> Хәзер юлым, кыйблам билгеле, җаным тыныч... Элек сөюләр, матур чүпрәкләр колы булуымны уйласам, хәзер үземнең йөзем кызара...» Бу елларда шактый киң урын алган аскетизм күренеше чагылышы буларак, Камәр үзен инкыйлаб эшенә багышлаган. Халык бәхете өчен көрәшүче Батырхан – аның идеалы. «Сез нинди бәхетле, Батырхан абый! Сезнең яраларыгызны үбәсем килә минем...», – ди ул. Матурлыкка, якты тормышка омтылып, ышанып яшәүче кыз кан түгүне җаны белән кабул итә алмый. «Ни генә эшлик? Башка юл юк, юк, юк шул!» – дип тәкрарлый, көрәштәшләренең эш-гамәлен акларга омтылып. Сыйнфый көрәш утында Камәр һәлак була, әмма аның үлеме юкка түгел. Батырханның Камәр гәүдәсе янында сөйләгән нотыгы – киләчәк көрәш юлын, инкыйлаб юлын, ахыр максатын билгеләү булып тора: «Аны югалту – безнең өчен бик артык авыр. Ләкин, иптәшләр, өметсезләнергә урын юк. Безнең арадан берәүне алсалар, аның урынына мең туачак... Буржуазия үзенең капиталын, җир-суын саклар өченниләр генә эшләмәсен, ахыр барып, һаман да без җиңәчәкбез! Бөтен дөнья контрреволюциясе, башы өзелгән аждаһа кебек, пролетариат кылычы астында өзгәләнәчәк! Миллионнарча шәһитләр канына манчылган кызыл байрак каршында бөтен дөньяны тез чүктерәчәкбез! Иртәгә кояшның чыгуына ышанган кебек, моңа да ышаныгыз, иптәшләр!» Әлеге фикерләрнең М. Гафуриның «Кызыл байрак»шигырендәге юллар белән авааздаш булуын күрми мөмкин түгел:

| | |
|---|---|
| Кара син алга!.. | Көчле эшчеләр |
| Күрәмсең анда | Күтәргән аны, |
| Кызыл байракны: | Буялган аңа |
| Буялган канга. | Шәһидләр каны. |

Үз чиратында, алдагы елларда әлеге канлы байрак символы башка әсәрләргә дә үтеп керә. Һ. Такташ «Гасырлар һәм минутлар»ында киләчәкне түбәндәгечә күзаллый:

Ул, кояш нуры кебек нурлар сибеп,
Төрмәләр, подвал, заводларга керә,
Йә, коточкыч байрагын тоткан килеш,
Ул кинәт килеп чыга зур
Парламентлар өстенә!..

Әсәрдәге «яңа кешеләр» арасында яшь буын вәкиле буларак Тимеркәй шулай ук аерылып тора. Кызу канлы, сабырсыз егет хаксызлыкны кабул итә алмый. Сугышның кырыс шартлары аның характерын шулай формалаштыра. «Куркам мин, җизни, аларны кырып бетермәсәм, яңадан баш күтәрәләр дә безне тагын элекке кебек кол итәләр дип куркам...» – ди ул үзеннән өлкән Батырхан һәм башкалар әйткән фикерне кабатлап. Сыйнфый көрәшне, максатка ирешү юлларын берьяклы гына аңлаган егет Вәли абыйсын да җәлләми. Авылдашы карт ялчы Әптерәшнең: «Акылың бармы? Ул бит синең агаң! Ул синең атаңның туган энесе бит!» – дигәненә болай җавап бирә: «Агайны гына түгел, андый урында туган атайны да кызганмам мин!»

Тимеркәйнең әлеге сүзләре чор тормышында күп тапкырлар күзәтелә. Әдәбиятта да әлеге караш-концепция дәвам иттерелә. Һ. Такташның «Күмелгән кораллар» драмасында Мансур исемле герой әтисенең бертуганы булган Солтанның кулга алынып төрмәгә ябылуына ирешә, ә инде «Камил» исемле драмасында Камил әтисенең кулга алынуына һәм атып үтерелүенә сәбәпче була.

Күргәнебезчә, драмада «яңа кешеләр» матур киләчәккә ирешүдә канлы көрәшкә өстенлек бирә кебек. Әмма геройлары белән автор да икеләнә, газаплана. Татар әдәбияты гасырлар дәвамында дуслык, бердәмлек, тигезлек, азатлык идеясен яклап һәм саклап килде, традиция рәвешендә алдагы буыннарга җиткерде. Г. Ибраһимов сәяси-иҗтимагый эшчәнлегендә сыйнфый көрәшне яклап чыкса да, әсәрләрендә, бигрәк тә субъектив катламда гомумкешелек кыйммәтләренә тугры кала. «Яңа кешеләр» драмасында да күңелләрендәге нәфрәт хисенә өстенлек биргән яшьрәк геройларга каршы өлкәннәрнең сабырлыкка, тормыш тәҗрибәсенә нигезләнгән эш-гамәле куела. Арада Шәйбәк һәм Әптерәш картлар аерылып тора. Алар кан түгүгә кискен каршы чыга. Акгвардиячеләр турында «алар

кан дәрьясы аша барып, карун булырга телиләр… Аллаһ Тәгалә андый усаллыкларга түзмәс, балалар!» дигән Шәйбәк карт Батырханның «зарарлы чүпне утап ташламасаң, ул бөтен җирне каплап, ашлыкны харап итә!..», шуңа да «канлы юл – изге юл» дигәнен кабул итми: «Белмим, балам, белмим, күп кан түгүдән саклан! Чүпне утыйм дип, ашлыкны әрәм итә күрмә». Шул рәвешле вакыйгаларда урын алган рәхимсезлек, нәфрәт күренешләренә каршы рәвештә шәфкатьлелек, татулык, бердәмлек идеясе калкып чыга. Өлкәннәрнең дәлилле, акыллы фикер-карашы Батырханны уйланырга һәм байтак эш-гамәлләренең нәфрәт хисенә баш була алмыйча эшләнүен аңлауга китерә. Үз чиратында, ул яшь егет Тимеркәйне сабырлыкка, хистән бигрәк, акыл белән уйлап эш итәргә чакыра. А. Яхин язганча, «Ш. Госманов, Г. Ибраһимов күпчелек татар язучылары кебек идеологиянең аерылгысыз өлеше булган рәхимсезлеккә, кешеләрдә нәфрәт тәрбияләүгә каршы чыктылар. Алар яңа тормышның яңа кешеләрен үзара тату яшәүче, үз ялгышларын үзләре төзәтә алучы, сабыр сыйфатлы итеп күз алларына китерделәр» (7, 38).

Киләчәк җәмгыятьне төзү юллары турында һәм сәясәтче, һәм милләтче буларак уйланган Г. Ибраһимов икеләнүләреннән тулысынча арына алмый. Драма Фәтхия карчыкның мондый сүзләре белән тәмамлана: «Ходаем, бар икән кодрәтең! Менә ничә атналар инде, көн үтәләр, төн үтәләр! Туплар! Кызыл әләмнәр! Илаһым, хуҗам, кайдан килә, кая бара бу бәндәләрең?!» Автор куйган әлеге ике сорау, билгеле инде, укучы белән диалогка китерә. «Кайдан килә?» дигән сорауга артында дөньяны пыран-заран китергән инкыйлабларның сәбәбе турында, аннан да бигрәк инкыйлаб аша тормышны яхшыртып буламы дигән уйлану ята. Ә инде «кая бара бу бәндәләрең?» дигән сорау белән Г. Ибраһимов канлы байрак күтәреп бәхетле киләчәкне төзү мөмкинлеген шик астына ала. Шулай итеп, Г. Ибраһимовның инкыйлаблардан соң язылган беренче әсәре буларак «Яңа кешеләр» драмасы әдипнең яңа чор иҗатына ачкыч ролен үти һәм алга таба үстереләчәк күп кенә әдәби-эстетик карашларын шактый тулы чагылдыра.

ӘДӘБИЯТ

1. Арсланов М. «Новые люди» в постановке Мухтара Мутина // Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман: Тууына 115 ел тулуга багышланган фәнни конференция материаллары. – Казан: Фикер, 2002. – Б. 67–72.

2. Әхмәдуллин А. Г. Ибраһимов һәм татар драматургиясе // Сәхнә әдәбияты һәм тормыш. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – Б. 165–177.

3. Әхмәдуллин А. Драматургия // Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. 4 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – Б. 68–81.

4. Мөхәммәдова Г. Г. Ибраһимовның «Яңа кешеләр» драмасына карата кайбер фикерләр // Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман: Тууына 115 ел тулуга багышланган фәнни конференция материаллары. – Казан: Фикер, 2002. – Б. 130–132.

5. Салихов Р. Г. Ибраһимов һәм пролетариат әдәбияты концепциясе // Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман: Тууына 115 ел тулуга багышланган фәнни конференция материаллары. – Казан: Фикер, 2002. – Б. 35–52.

6. Хәсәнов М. Галимҗан Ибраһимов. – Казан: Татар. кит. нәшр.,1964.

7. Яхин А. Әдәбият: Унберьеллык мәктәпнең 10 нчы сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия. – Казан: Мәгариф, 1995. – 335 б.

## ФОЛЬКЛОРНО-МИФОЛОГИЧЕСКИЕ МОТИВЫ В ТВОРЧЕСТВЕ Г. ИБРАГИМОВА И М. ПЕТРОВА

***Р. В. Кириллова (Ижевск)***

Взаимные творческие контакты, культурное взаимообогащение между татарскими, удмуртскими писателями, поэтами, педагогами, художниками и композиторами ведут свои корни еще с дореволюционных времен.

Из Казани, как одного из научных, культурных и образовательных центров, расходилась по разным направлениям научная и художественная литература. Жизнь в Казани в начале XX века била ключом: прогрессивно настроенная часть новой интеллигенции стремилась к созданию атмосферы взаимопонимания между народами, отвергая национальные конфликты. В этой атмосфере формировались многие видные деятели народов Урала и Волго-Камья.

В начале XX века на качественно новом уровне был начат процесс обновления национальных литератур народов Поволжья и Урала. Это было связано со сближением литературы с реальной жизнью и историческими судьбами этих народов.

Многие начинающие писатели первые свои произведения, так или иначе, связывают с устной народной традицией, фольклором. Исследователи, проанализировав этот процесс, пришли к выводу, что подобное явление характерно для младописьменных литератур Урала и Поволжья, да и для многих литератур Востока.

У Галимджана Ибрагимова была своя колыбель красоты, в нем навсегда осталась любовь к родным местам. Деревенское детство обогатило его знанием татарского и башкирского фольклора – преданий, легенд и сказаний, а учеба в Оренбурге в медресе в течение восьми лет и далее в медресе «Галия» в Уфе расширили и углубили философско-научное мировоззрение будущего писателя и общественного деятеля.

Роль многогранной личности Галимджана Ибрагимова в духовной истории татарского народа трудно переоценить. Художник, воплотивший в своих произведениях основополагающие принципы социалистического реализма, крупный критик и теоретик литературы, выдающийся учёный, государственный и общественный деятель, он был пионером новой национальной культуры.

Исследователь Э. Нигматуллин отмечает: «…писателя отличала напряженная работа мысли, поиски цельных непротиворечивых убеждений, удивительная пластичность, гибкость мышления. Г. Ибрагимова интересовало творчество Сократа, труды арабских ученых, турецких историков, русских лингвистов и фольклористов, английских эстетиков, немецких романтиков, французских позитивистов и русская литература,

начиная с Пушкина и кончая М. Горьким и Л. Андреевым» (11, 363).

Русскоязычному читателю, в том числе удмуртскому, широко известны его романы «Молодые сердца» (1912), «Наши дни» (1919), «Глубокие корни» (1928) «Дочь степи» (1934). В 1974 –1987 гг. вышел 8-томник произведений писателя. Его творчество оказало влияние на развитие художественной прозы тюркских и финно-угорских народов, пользовалось большой популярностью. Сборник рассказов «Начало весны» («Яз башы»), повести «Судьба татарской женщины» («Татар хатыны нилэр күрми»), «Старый батрак» («Карт ялчы», 1912), «Дети природы» («Табигать балалары», 1914), романы «Молодые сердца» («Яшь йөрәкләр», 1912), «Наши дни» («Безнең көннәр», 1920) и др. вызвали особо значимый резонанс в творческой среде финно-угорских писателей.

Фольклорные мотивы в творчестве Г. Ибрагимова ярко зазвучали уже в ранних рассказах, например в «Начале весны». Сама природа, легенды и сказания, которые услышал будущий писатель в детстве, казалось, послужили почвой для творчества. Описывая природу, обращаясь к фольклорным образцам, легендам и преданиям, писатель уже в первом рассказе выступает как романтик. Сказочная мифология в рассказе представлена достаточно полно: *«День проходит, солнце заходит, небо покрывают темные тучи. Путь лежит через болото, где, по легенде, будто бы живет водяное существо – аждаха».* Автор умело изобразил, используя мотивы сказок и легенд, показал через образ впечатлительного мальчика Сабира, как сказочное и реальное (надвигающая гроза, сумрак, ураганный ветер и путь мимо болота, где всегда присутствует дух темных сил), переплетаясь, доводит его до такого страха, что он теряет сознание и долго болеет (10, 24). Романтическая заостренность и яркость образов дополнились в рассказе Ибрагимова реалистической полнотой характеров.

Ибрагимов пришел к фольклорным истокам, на практике обосновав их необходимость в народной литературе и искусстве. Различные жанры фольклора служили ему как средством передачи накопленного социального опыта в виде культурных стереотипов, так и средством формирования ментального поведения народа.

Тема романа «Дочь степи» подсказана писателю личными впечатлениями. Он работал учителем в казахских аулах и был покорён широтой души, свободолюбием и своеобразием культуры и быта казахского народа. С увлечением записывал казахские пословицы, поговорки, песни. В произведениях Г. Ибрагимова есть традиционные образы влюбленных пар, как и в романтических эпосах, которые ради любви согласны идти на большие испытания.

Повесть Ибрагимова «Судьба татарки» (1910) раскрыла сложную судьбу сельской девушки. Не последнюю роль в полотне произведения сыграли народные песни и другие фольклорные элементы, с помощью которых писатель обрисовал трагизм и тяжесть женской доли. Сюжет повести Ибрагимова довольно традиционен, он близок по содержанию к чувашской поэме К. Иванова «Нарспи» и удмуртской поэме М. Петрова «Италмас», основанных на национальных фольклорных корнях: молодых влюбленных разлучают, девушку насильно выдают замуж за другого, желая породниться с богатой семьей. В национальном фольклоре героини подневольной и суровой жизни предпочитают смерть. Если в первом варианте повести главная героиня Гульбану, переодевшись в мужскую одежду, убегает из дома мужа, то примерно через 20 лет повесть выходит уже в новом переработанном варианте, где героиня, не желая смириться с участью, бросается в реку. Такая концовка непосредственно перекликается с многочисленными баитами и лирическими песнями татарского фольклора, где жалостно оплакивается судьба несчастных девушек, насильно выдаваемых замуж:

*Была я стройной и красивой,*
*Все хорошее – при мне.*
*Работяща и послушна*
*Не угодила я тебе.*
*Завещание оставляю,*
*Не жалею своей жизни.*
*Нет, не ждите, не вернусь к вам,*
*Утопилась я в Кабане.*

(«Печальная Бибигайша») (10, 69).

Во втором варианте Ибрагимов широко использует свадебные и этнографические материалы, сравнения и параллелизмы, взятые из народных песен и баитов. Картина природы в повести дается в гармонии с содержанием сюжета: «*…перед свадьбой Гульбану выпал чистый девственный снег, как сама невеста, радостный труд на лоне природы, словно все подсказывает, что она создана на радость всем…*»

Такой же яркой и самоотверженной личностью был для своего народа удмуртский писатель и поэт М. Петров (1905–1955) – прозаик, драматург, теоретик литературы, собиратель духовного богатства своего народа, знаток его этнографии, психологии, исторических и культурных традиций, выдающийся сын удмуртского народа. Его жизнь и творческий путь, как и у его современника Г. Ибрагимова, пришлись на один из самых сложных и драматичных периодов в истории нашей страны – период революций, гражданской войны, массовых репрессий и т. д. Богатое творческое наследие М. Петрова является уникальным материалом для современных литературоведов и критиков. Во всех сферах художественного творчества он оставил глубокий след: в его литературном наследии – поэмы «*Ортчем вамыш*» («Былое») (1935), *«Бадњым кож»* («Наташа») (1946), «*Италмас»(1945), «Кырњан улоз»* («Песня не умрет») (1947), повесть «*Њардон азьын»* («Перед рассветом») (1952), роман «*Вуж Мултан*» («Старый Мултан») (1954), сборники рассказов и очерков «*Улон понна»* («За жизнь»), «*Вить кышкасьтэмъёс*» («Пятеро бесстрашных») (1947), пьесы, сборники стихов и песен, критические и литературоведческие работы. Впитав опыт своих предшественников (Г. Верещагина, Кузебая Герда, Кедра Митрея, и др.), Петров силой своего разностороннего дарования активно воздействовал на дальнейшее развитие современной литературы, был «настоящим мотором удмуртской литературы» (3, 332).

Оба писателя – и Г. Ибрагимов, и М. Петров активно включились в сбор и изучение фольклора своего народа. Так, обработаны фольклорные записи, собранные М. Петровым в удмуртских деревнях в 1934–1936 гг., и составлено два песенных сборника с одинаковым названием – «*Удмурт калык кырњанъёс*» («Удмуртские народные песни»). В 1937 г. М. Петров выпустил

третий сборник удмуртских народных песен с нотами. И в 1939 г. под его редакцией вышел очередной сборник стихов и песен «*Кылбуръёс но кырњанъёс*» («Стихи и песни»).

В своих публикациях М. Петров не раз подчеркивал, что в песнях изливается гордая, красивая, поэтичная душа народа. Она звучит как молитва, как оберег, как исповедь, как надежда (8, 22–34, 179–182). Они уводят в загадочный мир предков, в мифическую «колыбель» удмуртов, откуда писатель черпал свои образы, характеры, мудрость. Невозможно представить художественное творчество М. Петрова без того мифопоэтического колорита, который так осязаемо (а иногда – подтекстно) присутствует в его очерках, рассказах, в его фольклорных сентенциях и реминисценциях.

Для обоих рассматриваемых писателей характерно обращение к теме родного края, деревенской жизни, национального быта. В их произведениях фигурируют герои, сельские жители, утверждаются национально-нравственные ценности, отстаиваются идеи гармонического единения человека и природы. Для раннего творчества обоих писателей были характерны романтические мотивы. Любовь, жизнь деревни, тяжелая судьба героев, их недовольство своей жизнью – такова тематика рассказов обоих писателей.

В рассказах Г. Ибрагимова «Старый батрак», «Пастухи» показана жизнь татарских крестьян. В этих рассказах речь идет о крестьянах, всю жизнь надрывавшихся в батраках, писатель в них резко определил полосы бедности и богатства, впервые реалистично показал социальные контрасты татарской деревни. В рассказах, очерках и пьесах М. Петрова «Батрак» (1931), «Ваче пинь» («Зуб за зуб», 1931), «Вуж вуко» (Старая мельница», 1929), «Виль улонэ» («В новую жизнь») и других речь также идет о классовой борьбе и жизни удмуртского села, освещаются драматические социальные события конца 20-х годов XX века.

Писатели мастерски перерабатывали элементы устного народного творчества, вплетая сатирические выражения, обороты, фольклорные афоризмы в свои произведения, чем достигали высокой поэтической образности, художественной меткости и эмоциональной окраски. Эти элементы, становясь в центре внимания читателя, приобретают особое смысловое значение и сосредоточивают их на эмоциональную силу. Приведем несколько примеров из произведений М. Петрова: «*Шудез гожтэмын вылымтэ*» (Без счастья рождена), «*Лулзиськод – со порме пилемлы, витемдэ адзиськод уйвотын*» (Твой вздох в тучку обращается, мечты только снятся). Ряд афоризмов М. Петрова показывают силу любви в его художественном творчестве: «*Сюлэме яратон кенжуку, куанер мурт но луэ ук майбыр»* (Когда любовь входит в сердце, и бедняк становится счастливым), «*Яратон – со егит сюлэме чик усьтон курытэк ик пыре»* (Любовь в юное сердце и без ключа проникает), «*Пöсь синву – со курыт бöрдйсьлы*» (Слезы горьки для горемычного), «*Лек кылпум лэчыт пурт кадь ик луэ*» (Злая молва словно острый нож), *«Бай муртлэсь тырмостэм аксымзэ замокен, пе, уг лу пытсаны*» (Жадность богатеев на замок не запрешь).

В повести Г. Ибрагимова «Судьба татарки» внешность героини Гульбану сравнивается словами народных песен: «*Буйга дисәң – Идел камышы кебек зифа, йөзе тулган ай кебек, балкып тора, кузендә ялкын уйный, авызы уймак, йөреше – аккош йөреше*» (Она стройна, как камышинка, лик подобен луне, глаза ее искрятся звездами, ротик как наперсток, а выступает, будто лебедь плывет). Характер героев изображается через яркие частушки: «*Бер егетне карата алмый, буй устермәм кыз булып»* (Если юношу не заставлю заглядеться, незачем было мне девушкой родиться). В этих сравнениях сохранены сжатость, глубина мысли, запечатлены мудрость и жизненная практика народа. Все примеры говорят о том, что писатели широко использовали образные средства и приемы выразительности, почерпнутые из фольклора, дав им новое освещение и содержание.

Фольклорно-мифологические материалы в трудах Г. Ибрагимова и удмуртского писателя М. Петрова отражают такие наиболее характерные проявления мировоззрения татарского и удмуртского народов, как мифологемы, суеверия, культы и т. п., показывают, что в данный период устойчиво сохраняются и признаки язычества, а некоторые традиционные образы и мотивы трансформируются под влиянием ислама.

В биографиях обоих писателей много общего: их творчество расцвело под влиянием бурных событий революционных лет, Г. Ибрагимов и М. Петров хорошо знали устное народное творчество народов Поволжья и Урала. Г. Ибрагимов родился в Башкирии в татарском селе, М. Петров – в Татарстане в удмуртской деревне, владел несколькими языками, так как рядом жили татары, марийцы, русские. Оба написали величайшие произведения о грозных потрясениях XX века, оба добились литературной славы. Исторические романы «Наши дни» Г. Ибрагимова и «Старый Мултан» М. Петрова оказали огромное влияние на всю последующую татарскую и удмуртскую литературы. Оба творили в искусстве с той же широкоохватностью, с преемственностью в традициях, виртуозно используя фольклор, обращаясь к историческим легендам.

Широта и разнообразие человеческих характеров, глубина социально-философского осмысления действительности в богатом творческом наследии Г. Ибрагимова и М. Петрова объясняют долговечность и притягательную силу их произведений.

Таким образом, как отмечает исследовательница В. Х. Хакимова, «при изучении татарских и удмуртских литературных связей в их историческом движении естественно возникает вопрос о сложившейся модели этих взаимосвязей. Исследовав самобытность и общие черты писателей двух соседних народов и двух неродственных национальных литератур, мы пришли к следующим выводам: общие традиции татарской и удмуртской литератур складывались, прежде всего, на базе фольклора, затем – в романтическом и реалистическом изображении явлений действительности (событий, картин природы, характеров, судеб героев). Самобытность литератур проявлялась в вечно кочующем от народа к народу, с места на место фольклоре, но никогда не менялась мировоззренческая и этнокультурная суть» (12, 75).

ЛИТЕРАТУРА

1. Богомолова З. А. Истоки жизни и вдохновения // Река судьбы. Жизнь и творчество Михаила Петрова: Воспоминания, статьи, речи, письма / Сост. З. А. Богомолова. – Ижевск: Удмуртия, 2001а. – С. 6–8

2. Гачев Г. Д. Национальные образы мира: Курс лекций. – М.: Академия, 1998. – 432 с.

3. Домокош П. История удмуртской литературы / Пер. с венг. В. Васовчик. – Ижевск: Удмуртия, 1993. – 448 с.
4. Ермаков Ф. К. Поэзия и проза М. Петрова. – Ижевск: Удм. кн. изд-во, 1960б. – 220 с.
5. Ермаков Ф. К. Творческие связи удмуртской литературы с русскими и другими литературами. – Ижевск: Удмуртия, 1981. – 196 с.
6. История татарской литературы нового времени (XIX – начало XX в.). – Казань: Фикер, 2003. – 472 с.
7. История и культура родного края: Учебное пособие-хрестоматия. – Казань: Магариф, 1974. – 191 с.
8. Исламов Ф. Ф. // Аргамак. – 1998. – № 9–10.
9. Петров М. П. Люкам сочинениос: Быръем статьяос, речьёс, докладъёс но гожтэтъёс: 6 томен. – Ижевск: Удм. кн. изд-во, 1961. – 6 т. – 292 с.
10. Садекова А. Х. Фольклор в эстетике Галимджана Ибрагимова. – Казань, 1995. – 104 с.
11. Нигматуллин Э. Г. Шекспир и Гете а татарской литературе // Сравнительное и сопоставительное литературоведение: Хрестоматия. – Казань: ДАС, 2001. – 390 с.
12. Хакимова В. Х. Кедра Митрей и Гаяз Исхаки: достойные сыновья своих народов. – Ижевск, 2009. – 80 с.

# «ТИРӘН ТАМЫРЛАР» ӘСӘРЕНЕҢ ОБРАЗ ТӨЗҮ ПРИНЦИПЛАРЫ

***Р. Ф. Харрасова (Казан)***

В романе Г. Ибрагимова «Глубокие корни» все персонажи – не только участники криминальной хроники, но и активные борцы за претворение в жизнь своих идеалов, их сюжетная функция – утверждение своей позиции на том или ином уровне, в зависимости от занимаемого положения в обществе. Исторические события начала XX века их разделили на два крупных враждующих между собой лагеря. Система ценностей и осознанная жизненная позиция каждой стороны сформировалась в предыстории основного конфликта. Кроме этого, все герои условно воображаемых лагерей романа между собой крепко связаны кровными, семейными и дружественными узами. Связи и отношения, чувство мести и боязни заставляют даже нейтральных персонажей к концу финала занять ту или иную сторону.

Бер гасыр эчендә татар әдәбияты шактый үзгәрешләр кичерде, әмма аны бәяләүче өлкә элек-электән килгән төп принципларынннан бервакытта да ваз кичмәде. Инкыйлабтан соң башланган әдәбиятны аккакарага бүлү күренеше Үзгәртеп кору елларында инде башка ракурслардан янә зур көч белән җанланды. Идея-тематиканы алга куйган кайбер әдәбиятчылар, әсәрләрнең үз заманы рухын чагылдыруына, һәм инде, кызганыч ки, бигрәк тә сәнгатьчә эшләнешенә игътибар да итмәстән, тагын кирәкле һәм кирәксез әдәбиятлар исемлеген төзи башладылар, күңелләренә хуш килмәгән үрнәкләрне дәреслекләрдән төшереп калдырдылар. Яңа төр әсәрләрнең язылуы яисә әйләнеп кайтуы да моны аклый алмый иде. Хәтта чорыбызның гомум идеологиясенә генә түгел, бүгенге милли максатомтылышларыбызга хезмәт итмәстәй ядкарьләрне дә тарихтан сызып атарга ярамый, чөнки алар язучы аңындагы үзгәрешләрне күрсәтеп тора, аның каләм иясе буларак үсеш этапларын билгеләүдә катнаша.

Соңгы егерме биш елда бигрәк тә коммунистик идеологияне яктырткан, коллектив хезмәт, ватанпәрвәрлек идеяләрен алга сөргән һәм тормышны якты төсләрдә чагылдырган әсәрләр чүплек савытларына ыргытылгандай булды, әмма күпсанлы китап укучылар хәтереннән, әдәби мирасханәдән һәм инде аеруча әдәби барыштан аларны бервакытта да чыгарып ташлап булмый. Икенче яктан, демократик яшәүне бары тик төрле фикерләргә урын барлыгы гына тәэмин итә ала.

Әдәбият корифейларының берсе булган Г. Ибраһимов эшчәнлеге фәнни язмаларда ачыктан-ачык ук тискәре чагылыш тапмаса да, каләм ияләре үзара аралашуларында, мөмкинлек туганда, аны да шулай ук типкәләп үтә башладылар. Гомумән алганда, әдип хезмәтләрендә тискәре бәя алган күренешләргә, беренче чиратта, шәхси мөнәсәбәтләреннән якын килү, аның инануларын, үз фикеренә хаклыгын, гомумәдәбият таләпләрен исәпкә алып бетермәү күзәтелде. Галимнәр, Г. Ибраһимов тарафыннан әсәрләренә карата кискенрәк, шулай да нигезсез үк түгел сүз әйтелгән кайбер талант ияләре бервакытта да тәнкыйть ителергә тиеш түгел, кебек фикер йөрттеләр; үзләре дә субъективлыкка зур урын бирделәр, чор тәэсирен, ышану-инануларының җирлеген игътибарга алмадылар. Шул ук вакытта әдипнең романтик рухтагы һәм хисләр, төрле тип мөнәсәбәтләр матурлыгын эстетик кыйммәтләр дәрәҗәсенә күтәргән нәфис әсәрләренә махсус рәвештә өстенлек бирелә башлады.

Әлбәттә, Г. Ибраһимов – социалистик революция эшенә, аның җиңүе өчен көрәшкә иң бирелгән шәхесләрнең берсе. Үзе дә большевизмның үлем элмәгенә килеп кергәч һәм тарихта канлы битләр калдырганлыгын аңлагач та, коммунистик идеаллардан ваз кичмәде, һәм, бездән аермалы буларак, кыйблалыгы өчен, бәлки, ул мактауга гына лаектыр. Г. Ибраһимовның инкыйлабтан соң татар әдәбиятына биргән прозасы шул кыйбланы ачык күрсәтеп тора. Архитектоникасы тулаем язучының идея карашларына нигезләнгән әсәрләр арасында «Тирән тамырлар» романы да бар. Бөтен төрки әдәбиятларда реалистик прозаны формалаштыруга зур өлеш керткән әлеге әсәр М. Шолоховның шул рухтагы һәм һәр яктан авазд аш дөньякүләм билгеле хикәя, повесть, романнарына тиң каләм көче белән язылган.

Роман 1926 елда фәлсәфи-фикри эчтәлеген ачып бетермәгән, эпика өчен ятышмаган һәм публицистик аһәңле «Тугры сүз» атамасы белән дөнья күрә. Шул ук вакытта вакытлы матбугатта чагылыш тапкан язма өчен аны дөрес сайланган дип карарга кирәк. Ул бигрәк тә газета материалларыннан тугры сүзлелек көткән киң катлам укучының ихтыяҗларына җавап бирә, игътибарын тартып тора. Икенчедән, әсәрнең бик үк поэтик яңгырамаган тәүге мәгънәсенең дә үз тирәнлеге бар. Ул геройларның иманга тугрылыгын, дөресен сөйләүләрен, бер-берсенә объектив характеристика бирүләрен, хөкемнең нәтиҗәсен, әсәрнең тормышта булган хәлләргә нигезләнүен, хөкемнең тугры бер эш икәнлеген, авторның объективлыгын күрсәтә.

З. Бигиевнең прозасын һәм зур күпчелеккә билгесез кайбер гарәп шрифтында сакланган әсәрләрне исәпкә алмыйча, элегрәк «Тирән тамырлар»ны тәүге детектив әдәбият үрнәге кебегрәк тәкъдим итәләр иде. Шул ук вакытта сайланган калып бары тик детектив жанр формасы белән билгеләнсә дә, сюжет сызыкларының традицион түгеллеге автор табышы сыйфатында аңлатылып килende. Белгәнебезчә, һәрбер җинаять эше аны факт буларак констатацияләүдән башлана, һәм әлеге җинаятьне ачу процессы, бернинди уйланмаларсыз да, язылачак әсәренең схемасын әзер рәвештә автор кулына тоттыра.

Г. Ибраһимовның, бәлки чор традицияләреннән, күләменнән, функциональ стиленнән чыгып, «хикәя» буларак билгеләгән әсәре, асылда, романга тарта һәм шул жанр төркеменә кертеп йөртелә дә. Аның кыска яңгырашлы атамасында ук чагылыш тапкан тамырлар төшенчәсе берничә яссылыкта ачыла һәм алга таба аларның тирәнлеге, озак вакыт аралыгында дәвам иткәнлеге ассызыклана барыла. Шуларның беренчесе – ерак тарихтан килгән һәм заман шартларында туган үчлек. Фәхринең үлем хәбәре ишетелгәч, Шәяхмәт юкка гына: «Фәхри абзыйга теш кайрап йөрүчеләр күп иде», – дип әйтеп куймый. Алга таба автор текстка «Фәхрине яраталар иде», – дигән капма-каршы мәгънәдәге җөмлә кертсә дә, алдарак әйтелгәне күңелдән китми.

Дөрес, әсәрдә укучы очрашкан тәүге конфликт яшьләр һәм өлкән буын арасында тоемлана, әмма язучы аның артыннан ук тагын хәлне, карашны үзгәртерлек ачыклык кертә – асылда аларның һәр икесе бер үк иҗтимагый утның ялкыннары белән янган ике буын кешеләре, ди. Ул моның белән персонажларның каршы як төркемнәргә, беренче чиратта, иҗтимагый яссылыкта бүленәчәгенә ишарәли.

Заман үчлекләре унтугыз яшьлек Шәяхмәтнең күргәннәре ярдәмендә ачыла. Бала булса да, канлы көрәш елларында, Казанга чехлар басып кергәч, ул татарларның инкыйлабчы юламаны Мулланур Вахитовны зинданга алып кереп киткәннәрен үз күзләре белән күргән, озак вакыт аның атылуы тәэсиреннән айнымаган. Абыйсы Бирәхмәтнең ат койрыгына тагылып үтерелүенең дә, башкаларның гади халык хакына кан түгеп йөрүләренең дә шаһиты ул. Егет хәтерендә саклаган вакыйгалар аны көрәшче итеп үстергән, әмма үчлек хисен дә онyттырмаган.

Романда көрәш утлары бер генә гаиләне дә читләп үтмәгән, һәм автор күзаллавындагы һәр уңай герой шул инкыйлабка бирә алган корбаннар белән горурлана. Шуларның иң мактанырлыгы – Җиһанша карт. 1905 елда энесе Тимершаның, кое баганасына асып, тәнен кискәләгәннәр, ярасына тоз сибеп, газаплап үтергәннәр. Ике улы инкыйлаб көрәшендә вафат. Язучы тасвирында геройларның инкыйлабка керткән өлеше аны дөньякүләм җәелдерүдәге роле буенча бәяләнә. Бу әсәрдә, әйтерсең, марксизм-ленинизм тәгълиматының бер генә пункты да онытып калдырылмый. Җиһаншаның җиде сугышны кичкән, Кызыл Йолдыз алган зур улы Мөхәммәтшаны гына искә төшерик. Аның башы Перекоп сугышында дошман тубыннан өзелә. Икенчесе Уфада һәлак була. Кызыллар ягыннан көрәшкән төркемне автор даими рәвештә теге яки бу җирне явыз дошманнан коткаручылар дип бәяли.

Җинаятьнең җебе әле тикшерүче килгәнче, авыл халкының бәхәсләре, хәтерләрен алып барулары аша сүтелә башлый. Авыл халкы кем-кемгә дус яисә үчле икәнне ачыкларга тотына. Язучы хәтта үзәктән килгән тикшерүчеләрне дә геройларның үткәне белән тыгыз бәйли. Әйтик, эшне ачыкларга җибәрелгән Петров Шәңгәрәйнең фронтташы булып чыга, Паларусов исә Фәхри белән яхшы таныш: берсе волбашкарма рәисе булган, икенчесе – үзәк агенты, шулай ук бер якта сугышып та йөргәннәр. Димәк, җинаять эше дөрес ачылачак. Г. Ибраһимовка совет оешмаларындагы кешеләрне дә инкыйлабка мөнәсәбәттә төркемләү мөһим.

Авыл эчендәге мөнәсәбәтләрнең гаять тә катлаулылыгын язучы масштаблы һәм детальле картина ярдәмендә күрсәтә, конфликт үзәгендә торган инкыйлаб тирәсенә торган саен күбрәк кеше тартыла. Ниһаять, без Садыйкның Габдулла ишанны аттырганлыгын, ә Гыймади ишанның тугры хезмәтчесе булганлыгын беләбез. Иманга ныклы тугрылык күпчелек очракта геройларны үлемгә илткән булып чыга. Фәхринең атасы да тугрылыгы өчен вафат имеш. Алда аталган гамәлкүренешләр – социаль-сәяси каршылык тамырлары һәм гомум иҗтимагый барыш белән билгеләнә, һәм, әйткәнебезчә, нәкъ менә алар әсәрнең образлар системасы сайланышына беренче чиратта тәэсир итәләр дә. Автор позициясеннән чыгып, ярыша-ярыша үскән тамырларның беренчесе – ак, икенчесе кара төскә буяла. Калган каршылыклар – тамырчыклар әнә шул үзәкләрдән үсеп чыга.

Җинаять эшен ачыклауга иҗтимагый тормыштагы яңа каршылыкларның да киртә коруы бар, дип искәртә автор: бүген-иртәгә шәһәрдә ачылачак партконференциягә әгъза сайлау чоры, каршы якның шулай ук аңа бәйле кампаниясе бара. Автор әсәрдә, җае чыкканда, дошман элементларның хакимияткә үрләү юлларын күрсәтә. Татар коммунистлары арасындагы ызгышларны да алар белән бәйләргә тырыша, яисә, төп дошманны күрмичә, көчләрен кирәкмәс әйберләргә сарыф иткәнлекләрен әйтмәкче.

Шунысы бик кызык: язучы акларның ат кебек кешегә хезмәт иткән җан ияләренә салган зарарын да читләтеп үтми. Мәсәлән, Петров белән Паларусовны Байракка илткән ат сугышта туп ватыгыннан аксаган. Үләргә хөкем ителгән атны чираттагы ачлыктан шешенеп үлгән гади чуваш карты саклап калган. Атка авыл капкасын «муенына кызыл галстук бәйләгән ялан аяклы кескенә кара малай ача». Әсәрнең һәр җөмләсенә әнә шулай авторның үткән һәм киләчәк тормышка бәйле уйлары яшеренгән яисә ачыктан-ачык әйтелгән.

Романның, бер фокуска туплансалар да, бихисап яссылыктагы каршылыклары эчендә фольклорга тартым урыннары бар. Бай һәм ярлы малайлары, гадәттәгечә, бер үк кызны – авылның иң чибәр, иң булган кызын ярата, ә инде кыз, байлыгына карамый-нитми, гомерлек пар итеп яраткан кешесен сайлый. Инкыйлабтан соңгы чорда бу төр күренешләргә әдәбиятта игътибар бермә-бер көчәя. Шул ук «Тирән тамырлар»да да Заһид бай малае Шәмси Нәгыймәне ярата, ә ул Садыйкка чыгуны хуп күрә.

Әсәрдә чагылыш тапкан социаль-сәяси каршылыклар тар тирәлек эчендә көндәлек тормышның вак-төякләре белән көчәйтелә. Аны тасвирлауның да халык авыз иҗатыннан ук килгән тәҗрибәсе бар. Бу – бай һәм ярлы арасында хезмәт һәм аны бәяләүгә мөнәсәбәттә барган каршылык. Г. Ибраһимов йортсыз-җирсез Җамалины бае тарафыннан нык кимсетелгән итеп сурәтли:

Вәли байның таш пулатында гына торган, тырышып эшләгән, хезмәт хакын алып бетерә алмаган, чөнки бае үзен үтә дә вөгъдәсез итеп күрсәткән. Аның гел – түрә, үзенең исә бары тик ялчы булганлыгы өчен, Җамали гомер буе хуҗасына үч саклаган, әмма көрәштә нейтраль позициядә калмакчы, чөнки ике якның да начар сыйфатларын, яманлыкларын күрә, үтә куркак. Җитмәсә, кодасы Кәмали язмышлар хәл ителәчәк бер моментта күңеленә, хакимият алмашыначак, дигән коткы сала. Г. Ибраһимов советка дошманнар тарафыннан һәр кешене үз якларына мобилизацияләү эше барганлыкны бу образлар аша да күрсәтә. Язучы әйтмешли, «хуҗалык, сәяси момент, үлем, – менә бу өчнең беренчесеннән икенчесенә күчү өстендә торалар».

Туганнар арасында мөнәсәбәтләр катлаулы булган кебек, ир-хатын гаиләсе эчендәге каршылыклар да йомшак дип әйтеп булмый. Вәли байның дүртенче хатыны исәбендә йөргән Кәримә бервакытта да ирен яратмаган, араларында ихлас дуслык та булмаган, хатын үзенә якты көн килгәнне көтеп, озак еллар түзеп яшәгән. Романда сурәтләнгән каршылыклар никадәр тармаклы, никадәр тирәнгә киткән булса, ачылырга тиешле җинаять эше дә шундый ук зур, шундый ук тармаклы. Фәхринең үлеме – бер ноктага төйнәлгән каршылыкларның кульминацион ноктасы гына. Аның тамырлары авыл белән генә чикләнми, калага, ил киңлекләренә тарала, әдәбият-сәнгать тирәсенә, вакытлы матбугатка үтеп керә.

Әдипнең бик күп әсәрләрендә, җиргә нинди орлыклар чәчсәң, шундый ук уңыш аласың, фикере ассызыклана, бигрәк тә «Кызыл чәчәкләр»дә ул аермачык күренеп тора. Шушы ук идея «Тирән тамырлар»да да чагылыш таба. Каты кыштан соң язын туфракка сибелгән саф орлыклардан киләчәк тормышның тамырлары үрли, әсәрнең фикри-фәлсәфи асылы өзектә бик тирән ачыла. Бу орлыкларны чәчеп кенә калмыйлар, һәлак тә итәләр, теге яки бу якның тамырлары корысын – урталыктагылар хисабына артмасыннар дип, нейтраль позициядәге кешеләргә дә каршы көрәшәләр. Фетнә вакытында мөгаллим Хәбибне аттан өстерәтеп үтерәләр. Белгәнебезчә, мөгаллимнәр теге яки бу катламга хезмәт итә, аларның зур өлеше бигрәк тә хаким сыйныфлар идеясен массаларга тарата. Бу хәзер дә шулай. Коммунистлар шул хактагы фикерне һәрвакыт кабатлап тора, димәк, ул әсәрдәге вакыйгаларның хәрәкәтенә, персонажларның үзара мөнәсәбәтләренә дә тәэсир итә.

Уңай орлыклар – коммунистик идея чыганаклары турында сүз барганда, шунда ук черек орлыклар, яман үсентеләр, зарарлы уңышлар да күз алдыбызга килә. Язучы мул образ-сурәтләүләр, әйтемнәр ярдәмендә, социаль тамырлар ассоциациясен даими тудырып тора. Ул, әле җинаять эше ачылганчы ук, табигатькә чәчкән изгелек орлыклары турында сөйли, болар – уңай идеалларда тәрбияләнгән яңа буын кешеләре, якты киләчәкнең нигезе, алар күп, аларга каршы көрәшүчеләр дә бихисап. Роман ахырында мәңгелек бер агачның үзе белән тирә-як туфрагын да кубарып егылуы сурәтләнә. Бу инде Вәли бай төркеме белән ассоциацияләнә, язучы тормыштан китәргә тиешле төркемнәрнең ишелелеген тагын бер кат ассызыклый. Тамырларга ябышып яшәгән тузан да, аларны тукландырып торган туфрак та юкка чыгарылырга тиеш, ди ул.

Мондый үтә дә кискен каршылыклы проза үрнәкләре татар әдәбиятында артык күп түгел, алар – нигездә, инкыйлабтан соңгы әсәрләр, шактые Г. Ибраһимов каләменнән чыккан. Күренеш-хәлләр тыгызлыгы, геройларның күплеге, һәрберсенең вакыйгаларда күпмедер, әмма һәрвакыт уңай яисә тискәре борылышларга тәэсир итәрлек өлеше булу, антитезалы тасвирлар көчле конфликт тудыруга хезмәт итә.

Әгәр без персонажлар төркемен ныклап анализласак, аларның бер-берсенә дуслык-туганлык җепләре белән бик тыгыз бәйләнгәннекләрен күрербез. Шушы юл белән, ягъни туганлык һәм кода-кодачалык шәҗәрәсен төзеп, вакыйгаларга теге яки бу күләмдә мөнәсәбәте булган персонажларны, ике зур төркемгә бүлеп бетерә алачакбыз. Авторның, геройларны конфликтка тартканда, туган-тумачалык, кода-кодагыйлык принцибын һич кенә дә күз уңыннан ычкындырмавы, һәр мөнәсәбәтләр тарихын укучы тотып алырлык итеп аерым абзац ярдәмендә тасвирлавы композицияне бик тотрыклы, сюжет схемасын бик нык уйланылган, фикерне логик эзлекле итә.

Без һәм тегеләр, туганнар һәм читләр, дип аеру – ыруглык заманнарыннан, кабиләара мөнәсәбәтләр чорыннан ук килә торган күренеш. Димәк, автор авыл, ил, дөнья эчендә барган социаль һәм башка төр каршылыкларның тарихын, беренче чиратта, җәмгыять тарихы белән бәйләп карый. Моннан да тирәндәрәк яткан тамырлар була алмый, шуңа күрә аның тасвирлаган имәне дә – гасырлар кичкән агач, берьеллык куак та, юк кына зилзиләләрдән егылырга, сыгылырга торган, сынып чыккан өянке, тирәк, каен да түгел.

«Тирән тамырлар»ның сюжеты көрәшнең бөтен катлаулылыгын күзалларга ярдәм итсә, аның төзелеше, шул исәптән образ композициясе бу көрәшнең гаять тә кискенлеген күрсәтеп тора. Роман тетрәндергеч, тәннәрне өшеткеч «Фәхрине үтереп ташладылар» җөмләсе белән башлана, һәм язучы тиз арада укучыны кискен сыйнфый көрәш белән характерланган авыл дөньясына алып керә, бу кискенлекне әсәр дәвамында югалтмаска тырыша. Ә бит «хикәя»не бераз йомшаграк яңгырашлы «Фәхринең үле гәүдәсе табылды», «Авылда уйламаганда-нитмәгәндә Фәхринең үтерелгәнлеге турында хәбәр таралды» дигән сүзләр белән дә башларга булыр иде, әмма сюжет үстерелешендәге иң киеренке нокта публика аңына тәэсир көчен шактый киметәчәк.

Характерларның формалашуын сурәтләгән күренешләр, бик нык чәчеп бирелсә дә, нигездә, әсәрнең үзәгенә урнашкан, бу – геройларның үткәненә игътибарны арттыра. Тикшерү вакытында һәркемнең күңел хатирәләре яңартыла, ә кеше хәтерендә тормышында күргән иң тәэсирле вакыйгалар гына озакка теркәлә, алар күп, эзлекле һәм автор тарафыннан ачык күзалларлык, укучы адашмаслык итеп җиткерелгән.

Әсәр ничек кискен башланса, шулай ук кискен тәмамлана да. Язучы, «Вәли Хәсәнов караңгы төндә урманга чыгарып атылды», ди. Роман иң элек уңай геройларга карата кылынган гамәлне атый, иң ахырдан шул гамәлгә адекват җәзаны ирештерә. Әгәр иң соңда автор суд хөкемен җиткерсә, җөмләгә башка персонаж исемнәрен кертсә, кискенлек, һичшиксез, йомшаячак. Уңай үсентеләргә каршы башланган көрәш зарарлы агачны тамыры белән юкка чыгару рәвешендә тәмамлана. Фәхри үлеменең җеп очларын ачыклау кебек кенә башланган тикшерү эше еректан килгән сыйнфый көрәш картинасын тудыруга хезмәт итә. Әсәрдә капма-каршы социаль көчләрнең туплануы, гавам

хәрәкәте, тәхет өчен көрәш вакытында кеше психологиясендәге үзгәрешләр, карашларның ачыклануы күренә, автор шул юл белән, геройларны ак һәм кара төркемгә бүлә бара.

Кайберәүләр әсәрдәге тәүге пейзажны әсәрнең экспозициясе дип билгелиләр, бу дөрес түгел, анда әсәрнең төп идеясе ачыла, табигать хакындагы өзек лирикфәлсәфи ачкыч ролен башкара. Тамырлар ничек таралган, орлыклар ничек сибелгән, геройлар бирелеше дә шулай ук, без алар белән өзек-өзек, аерым-аерым танышабыз. Романның, димәк ки, гомум композиция идеясе бик көчле, уйланылган, аның һәр элементы төп идеягә хезмәт итә. Әсәрнең кульминациясе итеп канлы бишмәт табылуны күрсәтү дә хакыйкатькә туры килми, бу инде зур конфликтның чишелә башлавы дигән сүз. Фәхринең үтерелеп ташлавы исә, безнеңчә, нәкъ менә сыйнфый көрәшнең иң кискенләшкән вакытына туры килә.

Фәхри үлеме кешеләрне, кайсы лагерьга керүләренә карамастан, бик киеренке хәлгә куя. Ни өчен? кем? ни белән бетәр бу? сораулары аларның миен көйдерә, хәтерләрен яңартып җибәрә. Әлеге сораулар конфликт, аның яклары һәм чишелеше дигән сүзләр ул. Г. Ибраһимов иң башта геройларны бүлү эшенә аларның Фәхригә мөнәсәбәтләре ноктасыннан керешә. Беренче шик, әлбәттә, Садыйкка төшә, чөнки үле гәүдә янында аның кендеге табыла. Аннан вакыйгаларга Җиһанша карт тартыла, бераздан бөтен кешенең уе, Фәхридән күчеп, Садыйк тирәсенә туплана. Язучы, аның Фәхри белән мөнәсәбәте ничек булган, бу җинаятькә катнашы бармы, кебек сораулар куйса да, тиз генә җавап бирергә ашыкмый. Җавапка бик ерактан, Садыйкның яшьлек елларыннан килә, һәм, детектив әсәрләргә хас булганча, безне ялгыш юлдан алып кереп китә кебек, шул ук вакытта бу «ялгышу» бик күп нәрсәләрне ачыкларга булыша.

Көчле мәхәббәт тарихы рәвешендәге Садыйк – Нәгыймә сюжеты романга ниндидер җылылык бөрки, шулай да көрәш килеп керү, аны бераз киметә: егет кызны хатынлыкка кибетче малаеның борын төбеннән тартып ала. Моннан тыш Садыйкның Фәхрине үзенең революция хәлфәсе итеп санавы тикшеренүчене дә уйланырга мәҗбүр итә. Дөрес, язучы, тормышны матур төсләр белән яктыртып җибәрү өчен, әледән-әле табигать тасвирларына мөрәҗәгать итә, аларга зур урын бирергә тырыша, әмма һәрвакыт тасвирланган күренешләреннән әсәр идеясенә хезмәт итәрлек фикерләр чыгара. Җиләкче Җиһан әби, әйтик, яландагы чәчәкләргә, өсләренә кунгалап очкан күбәләкләргә карап, егет-кыз, ата-ана һәм бала мәхәббәте, аның орлыклары турында сөйли. Зөфаф кичәсе кайчандыр Җиһан әбинең сүзләреннән тәэсирләнгән Нәгыймә гомерен икегә бүлгәндәй итә: алар Садыйк белән дөньяга мәхәббәт орлыклары чәчә, әмма аларның гаиләсе дә кайвакыт тормыш каршылыкларына каршы торып бетә алмый, ике араларында конфликтлар да борынлаштыргалый.

Романда тасвирланган Нәгыймә белән Гайшә – шул заман әдәбияты өчен яңа тип геройлар: гаиләләрендә ирләр белән тигез хокукка ирешкәннәр, фикердәшләре дәрәҗәсенә күтәрелгәннәр. Әлеге риясыз һәм туры сүзле хатыннарга Шәңгәрәй җәмәгате Рәгыя капма-каршы куела, социаль чыгышы аңа бу көрәштә ире тоткан кыйбланы аңларга комачаулык итә.

Характеристика бирүне каршы лагерьларга тапшыру персонажларны ныграк, төрле яктан ачуга китерә. Садыйк белән Фәхри үзара, беренче чиратта, Җиһанша образы аша тоташа: ул – Фәхринең абзасы, Садыйкның – Туй атасы. Революция яклы геройлар алга таба бала чагында Хәйдәр мирза Акчулпановның крәстияне булган Җиһанша тирәсендә туплана.

Җиһаншага каршы лагерьның үзәгендә – Вәли Хәсәнов. Аның килеп чыгышыннан, үткәндә кылган эшләреннән инкыйлабка каршы лагерь оештырганлыгын күрәсең. Кайчандыр Колчак гаскәрендә советларга каршы көрәшеп йөргән Вәли бай, дуслары һәм сөяркәләре ярдәмендә, совет хуҗалыгында җитәкче эшкә билгеләнә һәм астыртын гамәлләренә керешә: Фәхрине үтертеп, күмәкләшү хәрәкәтен өзәргә маташа. Бу кешенең тамырларын яшәтерлек су-гамәлләр белән авылда калган элекке ялчылары сугарса, шәһәрдә – совет һәм партия аппаратына кереп оялаган дуслары яшәтә. Язучы тудырган образлар системасына чорның һәр күренеше тәэсир итә – ул һәр җирдән яшеренеп яткан дошман элементлар эзли, таба, хөкем итә.

Динчеләр шулай ук дошман типларны яклап көрәшә. Тиречә Вәли шәҗәрәсен киңәйтеп җибәрүчеләрнең берсе – даменла Фәрид. Гомере рухани катлам тирәсендә узган Гыймади да аның белән бер тарафта, хәйләкәр картның бурычы – җинаять эшен ялгыш юлдан җибәрү.

Г. Ибраһимовка һәр кеше гомерендәге мөһим моментларны атау бик кирәк. Бу үч тамырларын гына түгел, элек һәм хәзер каршылыгын да тудыруга хезмәт итә. Шул ук Фәхрине алыйк. Атасы – ярлы крәстиән генә. Фәхри балачактан авыл байларына ялланып эшләгән, егет булгач та, фон-Киллер дигән алпавытка хезмәт иткән. Җирле булырга өметләр кабызып җибәргән Февраль инкыйлабыннан соң гына ул кеше исәбенә кергән. Аның соңрак язылган «гади» биографиясе – совет иле тарихы: артель, коммун, колхоз. Ул шулкадәр яңаны төзү эшенә бирелгән ки, шәхси йортны да «тарих белән ясалып килгән тормыш көчләре» үзе югында салган. Ә менә руханилар янында йөргән Гыймади кебекләр күтәрелә алмаган, хәтта язу язарга да өйрәнмәгән, авылдашларының да нәфрәтен генә казанган.

Г. Ибраһимов узган гасырның беренче утыз еллыгындагы бер генә иҗтимагый-вакыйга күренешен дә романнан төшереп калдырмаган. Монда сәнәк фетнәләре дә, читкә китеп эшләүләр дә, комсомол ячейкалары тормышы да, тәүге татар театрына бәйле һәм гайбәтләр сыйфатында бәяләнгән хәлләр дә, илнең чит илләр белән мөнәсәбәтләре дә, дөнья масштабындагы сәяси вазгыять тә тасвирланган. Аларны бер докладта санап чыгу, шуларга бәйле сюжетка килеп кергән персонажларга характеристика биреп бетерү дә мөмкин түгел. Чынбарлыктагы детектив материалларга нигезләнсә дә, әсәрдә тасвирланган партия тормышы, аның эчендәге көрәш тарихы, әлбәттә, Г. Ибраһимовка башка чыганаклардан билгеле, ул әсәргә бар укыганын, бар ышанганын, бар күргәнен кертеп бетерергә тырыша. Киң полотнолы эпопеяда бу аклана да. Дөрес, ул һәр аталган вакыйгага артык зур урын бирә алмый, һәм моны максат та итми шикелле, аңа ярлы катлам күтәрелгән бәхет, яңача тормыш өчен көрәшнең масштаблылыгын, дошманнарның һәрвакыт, һәр җирдә очраганлыгын күрсәтү кирәк, чөнки язылган вакытта илебезнең эчке дошманнарны фаш итү юлына баскан инде, һәм большевиклар бу юлда гомер кыюдан да тартынмый.

Сыйнфый көрәшләрне эпик планда тасвирлаган тәүге үрнәкләрдән буларак, «Тирән тамырлар» алга таба язылачак бик күп, әйтик, шул ук Ш. Камалның «Матур

туганда»сы кебек әсәрләрнең идея эчтәлегенә тәэсир итә. З. Бигиевтән соң детектив әсәрләр язу эше тукталыбрак торган була, ул әлеге юнәлешне җанландырып җибәрә. Романның язучы мирасханәсендәге башка әсәрләр, бигрәк тә «Казакъ кызы», «Кызыл чәчәкләр» белән бик күп ноктадан, идея эчтәлегендә, конфликт кору планында, образлар төзүдә уртаклыгы күренеп тора. Монда авторның шул чордагы гомум иҗат принциплары да шактый саклана. Болар: социаль-психологик детерминизм, көчле фикер логикасы, бик нык уйланылган, бөтен һәм төзек композиция һәм башкалар. Татар әдәбиятына гадәттән тыш мәхәббәт тарихлары бирү белән мавыккан Г. Ибраһимов бу очракта инкыйлабка чын күңеленнән бирелгән, аңа мөнәсәбәтләре көчле мәхәббәт дәрәҗәсенә җиткән геройларны тасвирлый.

## ОБРАЗЫ Г. ИБРАГИМОВА И ИХ ИСТОРИЧЕСКАЯ ЖИЗНЬ

*Р. М. Гайсин (Елабуга)*

Мироощущение каждого человека Российской империи начала XX века зримо отражало глубинные исторические изменения, происходившие в гигантской стране. Настроения и чувства творческих людей, всегда чрезвычайно зависимые от окружающей действительности, в еще большей степени свидетельствовали о начавшихся и грядущих эпохальных сдвигах в отечественной жизни. Не стал среди них исключением Галимджан Ибрагимов – впоследствии классик татарской литературы. Будучи личностью масштабной и изумительно одаренной, он чутко реагировал на любые жизненные проявления, пытался запечатлеть их в ярких и запоминающихся образах. Более того, сам активно участвовал в общественной жизни, стал известным ученым и государственным деятелем.

Эта авторская включенность в историческое движение окружающего мира наложила серьезный отпечаток на поэтическое своеобразие и бытование произведений Г. Ибрагимова. Говоря об уникальности художественного мира классика, надо помнить следующее. Конечно, литературное произведение является результатом писательского труда и представляет собой сложное целостное единство. Это естественно вытекает из самой природы искусства, где в художественных образах происходит эстетическая интерпретация картин действительности, объединяющей в себе различные стороны жизни. При этом в творческом процессе созидается новый мир, поэтический, со своей неповторимой и ощутимой предметностью.

Очевидность связи между двумя мирами, обыденным и художественным, не вызывает сомнения. А вот характер этих взаимоотношений зависит от разных факторов, прежде всего – от творческого метода писателя. Галимджан Ибрагимов давно в восприятии исследователей его творчества и в читательских представлениях видится романтиком. И на самом деле, в стиле писателя пересоздающее начало часто преобладает над воссоздающим, а в структуре образа субъективные элементы как бы заслоняют собой его объективную основу. Ибрагимовский герой, занимающий центральное место в типологии образов, устремлен к высокому, становится символом вольнолюбия и свободомыслия, не терпит насилия над собой. В романтическом ореоле предстают и картины природы, животные, образы предметного мира, общественные события.

В то же время автор, Галимджан Ибрагимов, вполне реален и не несет в себе черты трансцендентности, как было совсем недавно в татарской словесности, долго сохранявшей налет средневековья. И окружающий писателя мир наполнен зримой, слышимой и ощутимой конкретностью. В нем на переднем плане дерзновенные герои, способные действовать, бороться за идеалы свободы и справедливости. Романтические мечты их совпадают с содержанием реальной жизни, где поступками смелых молодых людей творится новейшая история страны и родного народа.

Авторский дебют Г. Ибрагимова состоялся в 1907 году публикацией в казанской газете «Эль-ислах» («Реформа») рассказа «Изгнание шакирда Заки из медресе». Уже тот факт, что на начинающего прозаика обратили внимание столь же молодые и ищущие коллеги в Казани («Эль-ислах» издавал Фатых Амирхан), свидетельствует о начале исторической жизни его первого произведения еще до выхода в свет, как и образа главного героя. А если быть более точным, все началось еще раньше. Частная история самого автора обрела в процессе творчества общественное звучание. Дважды он сам изгонялся за вольнодумство из медресе. Сначала юного шакирда исключили из старометодного учебного заведения, возглавляемого Вали муллой в Оренбурге. Во второй раз ему пришлось уйти в Уфе из престижного новометодного медресе «Галия», считавшегося одним из татаро-мусульманских вузов.

Поступок шакирда Заки увлекал, звал к протесту против схоластики существующей системы образования. Не только татарские юноши, но и девушки устремляются за истинно научными знаниями: поступают в гимназии, мечтают учиться в российских университетах и даже уезжают за границу. Часто там получить доступ к просвещению оказывается проще, чем в царской России. Примером для них могли быть Ю. Акчура и С. Максуди. Первый из них еще в «1899–1903 годах… учится в свободной Школе политических наук и одновременно посещает лекции Высшей школы прикладных наук Сорбонского университета» (3, 152). Второй поступает на факультет права в Сорбонне (Парижский университет) и через четыре года (1906) успешно его оканчивает. Важный момент – «во время учебы он не получал регулярной материальной поддержки, поэтому подрабатывал статьями в разных газетах России и уроками русского языка. Несмотря на эти трудности, годы, проведенные во Франции, оставили прекрасные воспоминания в душе романтически настроенного юноши, он находит здесь единомышленников и близких друзей» (1, 148).

Как тут, так и в последующей прозе малой формы Г. Ибрагимов неизменно ориентируется на знакомый

ландшафт жизни, на совокупность ее проявлений. Образные ряды его меняются вместе с изменениями окружающей действительности и характером ее восприятия, с его неустанным стремлением постичь сущность бытия. И все-таки до начала 1910-х годов он был довольно последовательным в предметном показе национальной действительности. Многое угнетает: строения и хозяйственная утварь, одежда и иной скарб, а более всего – узость жизни. Эпично, погруженностью в многовековой закосневший уклад ее, звучит название рассказа «Судьба татарки» (1909). Сам образ героини, не смирившейся с существующим рабским положением женщины-мусульманки, становится знамением времени.

Примечателен выход за три года до этого книги Р. Фахретдинова «Знаменитые женщины». Она раскрывала историческую ретроспективу истинной роли мусульманки в обществе. При объективном взгляде оказалось, что многие из них были блестяще образованы и владели искусствами, принимали деятельное участие в общественных делах. Образ Гульбану становился первым шагом в непростой истории возвращения женщины-мусульманки к ее естественному и достойному социальному статусу. Есть в рассказе мотив перевоплощения (переодевания) героини в мужчину. Только имеет это действие в произведении совсем иной смысл, чем в жизни – фигуральный. Оно указывает на необходимость эмансипации женщины-мусульманки, на реальное уравнение ее в человеческих и, естественно, в гражданских правах с мужчиной.

С выходом рассказа «Начало весны» (1910) в творчестве Г. Ибрагимова особую эстетическую функцию стали играть образы природы, где романтический пейзаж оттеняет несовершенства жизни. Еще совсем молодой автор проявляет себя тонким психологом, умеющим в целостности поэтического мира соединить человеческое и природное, придать фольклору и ландшафту символический и исторический смысл. Ведь на самом деле весна приносит с собой обновление, дает надежду на будущее, наполняет жизнь красотой и чистотой помыслов. С особой прелестью и одухотворенностью показаны в рассказе отношения матери и сына. Их лики светлы, чувства, казалось бы, безмятежны. Только от внимательного взгляда не ускользнут тонкие ассоциативные связи этого гармоничного мира с действительностью, тревога в душе юного героя.

В рассказе «В море» (1911) образная предметность определяется заглавием. Мир предстает цельным и живым, гармоничным и одухотворенным. В нем ничего не упущено, но нет и ничего лишнего. Такое предметное единство становится великолепной предпосылкой для создания сильных романтических творений. Г. Ибрагимов это не только хорошо понимал, но и возвел в ранг одного из главных своих творческих принципов.

Понятно, что без концептуальных оппозиционных функций сами пейзажи бессмысленны. Они и противопоставлены несовершенству современной писателю городской жизни, а сами противоположности сходятся на восприятии действительности романтическим героем. В море ему легче дышится, возвращаются душевные и физические силы. Образ героя, совершающего побег из реальной жизни, на самом деле историчен, имеет временную прописку. Он, порожденный автором и действительностью начала XX века, обретает собственное историческое бытование. Направление же побега героя из затхлого мира может быть разным. В рассказе «Любовь – счастье» (1911), например, герою на излете жизни таким желанным берегом видится любовь.

Культ природы, любви и искусства, их атрибуты «исключительно выпукло и противоречиво воплотились в романе Ибрагимова «Молодые сердца» (1912). Этот роман – первое произведение автора, сконцентрировавшее его идейно-эстетические концепции…» (4, 376). Любовь представлена в романе в универсальном плане. Ее возвышенный вариант дан во взаимоотношениях Зыи и Марьям, а земной – соотнесен с другой парой, Сабиром и Камилей. Принципиально важно, что талантливый юноша Зыя занимается музыкой, а пленительно прекрасная Марьям – чтением любовных романов. И все это происходит на лоне природы, символом которой становится сад.

Хронотопическая система «Молодых сердец» прочно связана с романтической традицией. Сад в ней – место встречи влюбленных. Сами необычные и возвышенные характеры, действия героев, проявление их симпатий требуют соответствующего обрамления. В саду, рожденном сотворчеством природы и человека, особая аура красоты и таинства. Он свидетель любви молодых людей и хранитель страшной тайны, связанной с нечаянным убийством невинного человека.

Роман заканчивается печально: Зыя в финале умирает. Вот как описывает это Г. Ибрагимов: «Доктора признали паралич сердца... Похороны пришлись на пятницу. Отовсюду понаехало много народа» (2, 211). Карим махдум, поэт и друг покойного, произносит прощальную речь: «Он говорил, я живу... Живу для людей... Он видел на небосклоне будущего сияние звезды надежды... Его душа была полна великих стремлений... “Если будут условия, я облегчу жизнь моего народа, освещу его темную жизнь!..” – говорил он» (2, 212). Преобразить жизнь Зыя собирался с помощью своей музыки, великолепной игрой на скрипке.

«Молодые сердца» закономерно стали культовым произведением татарской молодежи. Герои романа обладали громадной притягательной силой, звали в иную жизнь, прекрасную и наполненную благородным высоким смыслом. Вне сомнения, велика их роль в становлении музыкального искусства у татар, в формировании новых отношений между молодыми людьми.

К сожалению, в эти годы не смог увидеть свет другой роман Г. Ибрагимова – «Дочь степи», дважды конфисковывавшийся в десятые годы. Напечатать его удалось лишь в 1924 году, в советское время. Образ красивой, с длинными черными косами и озорными раскосыми глазами, девушки казахских степей Карлыгач-Слу (Ласточки-красавицы) стал подлинной удачей татарского прозаика. Закономерно беспрецедентное историческое бытование этого образа, породившего подражательное поведение в жизни и целую традицию в создании женских образов в литературах родственных народов. Невозможно назвать, кто из нескольких первых поколений казахских, среднеазиатских и татарских писателей остался к ней равнодушен.

С большой силой Галимджан Ибрагимов создает образы простых людей из социальных низов. Таков его старик Шаги из рассказа «Старый батрак» (1912). «Кабы доля, кабы счастье – не был бы человек рабом человека», – говорит он. В них столько горя и скорби, приглушенного отчаяния души, что невольно

задумываешься о том, как исторически устанавливалась вопиющая несправедливость на земле. Еще дальше в возвышении писательского голоса в защиту обездоленных людей идет он в рассказе «Пастухи» (1913). Окончательное развитие эта линия в его творчестве, согласно исторической логике, найдет в произведениях предреволюционного и советского времени (романы «Наши дни» и «Глубокие корни»).

Наконец, нельзя обойти стороной при разговоре об историческом бытовании героев Г. Ибрагимова рассказ «Габдрахман Салихов», опубликованный в 1916 году. Нарастающая протестная волна в российском сообществе была прочно связана с ростом самосознания и самоопределения личности. В начале XX века резко обострились отношения между социальными группами населения, перед каждым человеком встал вопрос: с кем быть? О нелегком нравственном выборе своего героя повествует в указанном произведении Г. Ибрагимов.

Обреченный на полуголодное существование из-за конфликта с родителями, Габдрахман мечтает поступить в университет или, на худой конец, сдать экзамен на учителя. Далее автор устами героя повествует об анекдотической ситуации, сложившейся с Салиховым в городе «…». Его, терпящего жесточайшую нужду и рассчитывающего подработать уроками, обыватели принимают за корреспондента газеты, сотрудничающего в сатирических журналах. Почему-то они решили, что журналистика и учительство несовместимы. Так Габдрахман попал в абсолютно безнадежную ситуацию, оставшись без заработка.

Проблема нравственного самостояния бедной, но гордой личности фокусируется на заглавном герое. Несмотря на лютый холод, Салихов сохраняет достоинство – ни к кому с мольбой не пошел, не стал оправдываться, что он не журналист. В нем кипела праведная злоба против мира сытых и подлых. Еще один мотив заставляет его не опровергать слухи: он знает, как обыватели боятся всего нового, так и разоблачения их убожества и грязных делишек.

И все-таки в кульминационный момент Габдрахман Салихов, измученный голодом и беспросветным нищенством, поддается соблазну получить «отступные» от боящегося разоблачения и огласки в прессе своей распутной жизни бая. В один из самых безнадежных дней в комнату молодого человека явился посыльный с приглашением в гости. Но и тут герой рассказа находит силы отложить поездку на один час. Лишь принципиально выдержав паузу, он завернул в бумагу старые учебники и с самым безразличным видом поехал в присланной бричке к баю.

Тем неожиданнее оказывается развязка рассказа. За уставленным яствами столом распутный бай, точно обвиняемый на суде, оправдывался перед «репортером», говорил о своем благодеянии в отношении юной вдовы умершего муллы. При расставании он предложил Габдрахману сторублевую кредитку, ибо надо «помогать тем, кто ступил на путь просвещения». Даже тогда Салихов находит силы, чтобы сразу не поддаться искушению.

И все-таки гордость была побеждена. Кредитка оказалась в кармане честного юноши и сразу начала отравлять его жизнь. Уже были потрачены двенадцать рублей, покрывшие все долги Габдрахмана, когда к нему приехал близкий друг Хабиб. Понурый взгляд и сумрачный вид Салихова поразили его. Узнав причину, он заявляет: «Ну и что?.. Бай дал – ты взял, что же тут позорного?! Они строят себе хоромы, выжимая соки у тысяч людей. Не будь наивным!» Но в итоге Хабиб доложил свои деньги к сохранившимся у Габдрахмана, чтобы обменять их на сторублевую кредитку и возвратить ее баю. Когда все было проделано, герой почувствовал облегчение. А мы, подводя итоги, можем сказать, что так и только так должен был поступить настоящий интеллигент. И потому в новых исторических условиях образ Габдрахмана Салихова особенно актуален.

ЛИТЕРАТУРА

1. Гаффарова Ф. С. Максуди // Духовная культура и татарская интеллигенция: исторические портреты. – Казань: Магариф, 2000. – С. 130–135.

2. Ибрагимов Галимджан. Молодые сердца. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1980. – 240 с.

3. Мухаметдинов Р. Ю. Акчура // Духовная культура и татарская интеллигенция: исторические портреты. – Казань: Магариф, 2000. – С. 147–154.

4. Хасанов М. Галимджан Ибрагимов (1887–1938) // История татарской литературы нового времени (XIX – начало XX века). – Казань: Фикер, 2003. – С. 374–389.

# Г. ИБРАҺИМОВ МИРАСЫНЫҢ Ә. ЕНИКИНЕҢ ӘДӘБИ ДӨНЬЯСЫНА ЙОГЫНТЫСЫ

***Р. Р. Идрисов (Уфа)***

Классики национальной литературы оказывают огромное воздействие на формирование художественного мира молодых писателей. На примере наставника у молодых складываются идейно-эстетические принципы художественного освоения действительности, особенности художественного видения мира, творческий метод и индивидуальный стиль. В становлении художественного мира выдающего татарского писателя Амирхана Еникеева решающую роль играл творческий пример старшего товарища по писательскому цеху Г. Ибрагимова. Особенно плодотворно было его воздействие в идейно-эстетических поисках художественой индивидуальности, в формировании поэтической картины мира в творчестве писателя.

Татарстанның халык язучысы, Республиканың Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Әмирхан Еникинең иҗат дөньясы формалашуда XX йөз башы татар әдәбияты традицияләре хәлиткеч рольне уйный. Татар ренессансының бәрәкәтле тәэсире әдәби әсәрләр, газета-журнал мәкаләләре һәм язучыларының шәхси үрнәге мисалында күренә. Булачак әдипнең рухи-мәдәни үсеше XX йөз башы татар дөньясының иҗтимагый-тарихи һәм әхлакый-эстетик эзләнүләре яктысында да бара.

Ул чор татар тарихында бик үзенчәлекле дәвер иде. Күп гасырлар буена тупланып килгән рухи потенциал мәгърифәтчелек һәм җәдитчелек идеяләре рәвешендә яшәешнең бар өлкәләренә дә ташкын булып бәреп керде, публицистика, тарих һәм әдәбиятның төп үсеш юнәлешләрен билгеләде. Җәдитчеләр милләтне алга җибәрү, аны һәрьяклап тәрәккый иттерү юлларын эзләделәр (1, 131). Татар тормышында барган катлаулы үзгәрешләр, искелек белән яңалык көрәше, мәйданга яңа заман каһарманы килү матур әдәбиятта да чагылыш тапты. Яңарышны әйдәүче титаннар – талантлы әдипләр сафы пәйда булды. Аларның идеалы алга киткән бәхетле милләт булды. Мәгърифәтчелек идеалларында мәйданга килгән сүз сәнгате әһелләре: «Шәхес милләтне тәрәккый иттерү (чәчәк аттыру) юлы белән генә бәхетле була ала», – дип җавап бирделәр (2, 344). Һәм шуңа да милләткә, халыкка хезмәт итү милли идея дәрәҗәсенә күтәрелде һәм зыялыларның яшәү мәсләгенә әверелде.

Нәселе бик борынгы татар морзаларына барып тоташкан (3, 155), халык мәнфәгатьләрен кайгырту һәм аның өчен фидакарь хезмәт итүне яшәү рәвеше итеп кабул иткән Еникиләрнең бер вәкиле булган яшь Әмирхан өчен бу максатлар бик якын була. Шуңа да ул, бик иртә шул идеяләр белән рухланып яши башлый һәм хаклык, һәм гаделлекне әдәби иҗат белән раслауны иң нәтиҗәле юл итеп таба (4, 498).

Егерменче йөз башы әдәбият титаннарыннан булган Г. Ибраһимовның Ә. Еникинең әдип буларак формалашуына йогынтысы әлегә тиешенчә өйрәнелмәгән. Кайбер хезмәтләрдә бу хакта сүз уңаеннан гына әйтеп узыла (5, 25; 6, 9; 7, 284), яисә бу фикер аксиома буларак кына кабул ителә (8, 190).

Сүз дә юк, Ә. Еникинең остазлары берәү генә булмаган. Әлбәттә, ул, барыннан да элек, Тукайны кыйбла иткән, Ф. Әмирхан, М. Гафури, С. Сүнчәләйләрдән иҗат серләренә өйрәнгән, С. Рәмиев һәм Дәрдемәнднең фикер һәм форма камиллеген үрнәк итеп алган. Ә. Еники «XX гасыр татар әдәбиятының пәйгамбәре» (С. Поварисов) Г. Ибраһимовның да шәхси һәм иҗади йогынтысында булган, әлбәттә. Шунысын да аерып билгеләп үтәргә кирәк: Еники беренче карашка төрле, хәтта бер-берсеннән шактый ерак булган әдипләрнең һәркайсыннан үзенә кирәген алган. Димәк, ул һәр әдипнең милли сүз сәнгате хәзинәсенә кертгән өлешен бик дөрес аңлаган, кирәк чакта шуны яклап та чыккан һәм мөкатдәс әдәбиятны үстерүне кайгырткан. Аның Тукай, К. Мотыйгый, Т. Ченәкәй һәм башкаларның исемен аклап ясаган чыгышлары да шул хакта сөйли. Әдипнең, 1955 елда ук Г. Ибраһимовны әдәбиятка кайтару хакында КПСС Үзәк Комитетына хат язуы аның гражданлык батырлыгы хакында да сөйли. Чыннан да, 60 нчы еллардагы «җепшеклек» – әдәбиятыбыз үсүендә яңа чор – бездә 1953 елда – М. Җәлил һәм 1955 елда Г. Ибраһимовның әдәбиятка кайтуы белән башланды, дип тә әйтергә була.

Еники мирасында Г. Ибраһимовның әдәбият тарихындагы урыны һәм аның яшь авторга тәэсире хакында шактый мәгълүматлар тупланган. Алар мисалында Еникигә Г. Ибраһимов эшчәнлегенең кайсы яклары якын икәнлеген чамаларга була. Барыннан да элек, булачак язучыны әдипнең проза өлкәсендәге осталыгы әсир итә. Нечкә зәвыклы яшь Әмир чын поэтик проза әсәре белән очрашканын бик иртә сизеп ала.

«…Һич онытасым юк Галимҗан Ибраһимовның “Безнең көннәр”ен икәү алмашлап укып чыгуыбызны! Бу Коръәннән дә калынрак роман безне тәмам йотып, әсир итте, без аңардан аерыла алмас булдык, тиз генә бетмәвен, уку рәхәтенең бер дә өзелмичә дәвам итүен теләдек. Моңарчы да мин үзем генә яки икәү бергә укыган матур китаплар аз булмады, әмма “Безнең көннәр” кебек бу хәтле дә ошаганы, безне беткәнче биләп алганы булды микән? Моның сәбәбен без ул чакта, бәлки, аңлап та бетермәгәнбездер… Мондый хәл сирәк була. Ихтимал, шуңа күрәдер, мин бу романның әдип тарафыннан утызынчы елларның башларында төзәтелгән вариантын шушы көнгә кадәр укырга җөрьәт итә алганым юк, ничектер, менә беренче басмасыннан алган тирән тәэссоратны югалтырмын дип куркам… Гомумән, конъюктурага ияреп, әсәр төзәтү ул, минемчә, сәнгать эше түгел» (4, 347). Монда Еникинең остаз әдибе иҗатына мөнәсәбәте күренә. Шулай ук ул үз иҗат кредосының кайбер якларын да сиздереп куя. Ә. Еники бер язылган һәм бигрәк тә басылган әсәрне яңадан эшләү ягында түгел иде. Мәсәлән, 1999 елда Уфада кыскартып басылган «Соңгы китаб»ының бер генә сүзен дә үзгәртмәде, ә кечкенә кереш сүз генә өстәп бастырырга фатыйха бирде (9, 337).

Әдипнең Г. Ибраһимов мирасына, бигрәк тә әсәрнең ике редакциясенә мөнәсәбәте – ул классик язучының идея-эстетик эволюциясенә дә мөнәсәбәте дигән сүз. Билгеле булуынча, совет әдәбияты белемендә Г. Ибраһимовның повесть һәм романнарын яңадан эшләве уңай күренеш, үсеш дип бәяләнеп килде. Ләкин 90 нчы еллардагы яңа әдәбият тарихы концепциясенә ярашлы рәвештә карашлар шактый үзгәреш тә китерде. «Кызганычка каршы, Г. Ибраһимов элек язылган әсәренең байтагын, иҗтимагый карашларының үзгәрүенә туры китереп, яңадан эшләп чыкты. Моңа, бердән, үзенең кыйммәтле вакытын әрәм итсә, икенчедән, табигый таланты белән иҗат ителгән әсәрләрне рәсми сәясәт карашлары белән сугарып, аларның ясалма яңгыраш алуына китерде, сәнгатьлелек дәрәҗәсенә зыян итте», – дип язды Фоат Галимуллин (10, 220).

Шул ук галим, әдәбият тарихында үз урыны булган олы әдипләр мирасы хакында уйланып, болай дигән иде: «Үз иҗат ысулын, фәлсәфи, сәнгатьчә фикерләү рәвешен вакытында тапкан язучы әдәбиятта яңа сүзне күпкә иртәрәк һәм отышлырак әйтә. Аларның аеруча талантлылары үз иҗат мәктәпләрен дә тудыра… Бу – сәнгатьчә фикерләү мәктәбе, кеше рухын ачуның аңа гына хас чаралары системасы», – диде Фоат Галимуллин. Һәм шундый язучылар исәбенә ул Г. Ибраһимовны да кертә (11, 46).

Татар әдәбиятында узган гасырның 60 нчы елларыннан, академик Ә. Тенишев сүзләре белән әйтсәк, яңа чор башлаган (12, 7), кеше рухын ачуның үз системасын булдырган (13, 42) Ә. Еники, әлбәттә, Г. Ибраһимовның әнә шул үзенчәлекләренә төп игътибарын юнәлткән.

1962 елда язылган «Безне ул өйрәтте» исемле мәкаләсендә Ә. Еники: «Мине, язучы кешене, ул иң әүвәл әдип-художник буларак кызыксындыра…

Бишенче елдан соң әдәбиятка бер үк вакытта диярлек Фатих Әмирхан белән Галимҗан Ибраһимов килеп керделәр… Бу ике олы талант аркасында безнең проза әдәбияты яңа биеклеккә күтәрелде, өр-яңа сыйфатларга баеды, ул инде чынлап та рус һәм Европа прозасына

охшаш бер кыяфәткә керде. Без чын мәгънәсендә роман һәм хикәяләр укый башладык» (14, 7–8). Еники әдипнең тел-стильне баетуына игътибарны юнәлтә һәм аның портрет, пейзаж, рухи кичерешләр, деталь, эчке монолог, диалогларны сурәтләүдәге осталыгын, әдәби телне камилләштерүдәге хезмәтен югары бәяли. «Асылда ул безгә проза теленең иң үтемле, саф татарча үрнәген эшләп калдырды. Аның бу үрнәгендә без телебезнең гаҗәп бай эчке мөмкинлеген, фикерне әйтеп бирә алуда һәм сурәтләп күрсәтүендә зур сәләткә ия булуын күрдек…

Шулай итеп, Галимҗан Ибраһимов безнең проза әдәбиятыбызда хикәяләүнең үрнәк булырлык гүзәл бер тел-стилен тудырды» (14, 9). Мәкаләнең йомгаклау өлешендәге сүзләр Ә. Еникинең үзенә дә кагыла кебек: «…аңардан соң әдәбиятка килгән язучылар, барысы да диярлек аның көчле йогынтысына бирелеп, теге яки бу дәрәҗәдә Галимҗан стиле белән яза башладылар… Әлбәттә, алар иярүчеләр генә булып калмадылар, чын талантка ия булганнары телебезне баетуда, әдәби осталыкны үстерүдә үзләреннән дә зур өлеш керттеләр, ләкин барыбер аларның һәркайсы “Галимҗан мәктәбе” аша узды» (14, 9), – дип язды ул.

Г. Ибраһимов шәхесе һәм иҗаты хакындагы әдипнең фикерләре әллә ни үзгәрми үсеш кичерүе аның 1987 елда язылган «Бер сорауга бер җавап» мәкаләсендә дә чагылыш тапты. Анда да Ә. Еники Г. Ибраһимовның тел-стиль осталыгына, аның новаторлыгына төп игътибарны бирә: «Татар әдәбиятын прозаның төрле жанрлары белән баетуда Галимҗан Ибраһимовның роле шөбһәсез бик зур…

Матур әдәбиятыбызның сәнгать булып җитешүендә Галимҗан Ибраһимовның роле шулай ук бик зур», – диде ул (15, 22, 23).

Г. Ибраһимовның язучыга шифалы йогынтысы шәхси мөнәсәбәт, бәяләр белән дә аңлатыла. Китаплары аша гына таныш булган әдипне Ә. Еники күреп тә кала. Һәм бу очрашу булачак әдипкә бик көчле тәэсир итә: «Сүз дә юк, авыру әдип белән бу очрашуның миңа тәэсире бик зур булды. Әгәр мин 1955 елны партия Үзәк Комитетында Галимҗан Ибраһимовның эшен яңадан карауны үтенеп хат язганмын икән, әнә шул 1937 елда әдипне үз күзем белән күрү миңа ул хакта тәвәккәлләп язарга, һичшиксез, ярдәм иткәндер, дип уйлыйм», – диде ул (4, 475).

Күрүебезчә, турыдан-туры иҗади тәэсир-йогынтыдан тыш, әдип шәхесенең үзенчәлекләренә дә игътибар итә Ә. Еники. Онытылмас очрашу, якташлык хисе, туган туфрак тойгысы, гаделсезлек корбаны булган Г. Ибраһимов фаҗигасе белән теләктәшлек хисе дә язучыга якын булган дип әйтергә тулы нигез бар. Әдәбиятчы галимнәр Ү. Гыймадиев (16), М. Мәһдиев (17) һәм С. Сафуанов (18) хезмәтләрендә искә алынган әдип әсәрләренең җирлеге, прототиплар, хронотоп, язылу тарихы, иҗат лабораториясе мәсьәләләре дә Ә. Еникинең игътибарыннан читтә калмаган, билгеле. Бу хакта әдип хакындагы Еникинең төрле хезмәтләрендә сибелеп бирелгән фикерләре сөйли. Г. Ибраһимов әдипнең даими рәвештә игътибар үзәгендә була.

Авыргазы районы Солтанморат авылында янгыннан соң яңадан тергезелгән әдипнең йорт-музеена материаллар җибәрүе, шуларның анда барып җитүҗитмәве белән кызыксынып белешүе дә шул хакта сөйли. «Санаулы көннәр» дип исемләнгән эссесында Ә. Еники үзе өчен мөһим булган бу темага да кагылып китә. «Инде менә янган йорттан бераз читтәрәк, музей өчен кызыл кирпечтән яңача стильдә бик матур бина салып куйганнар. Без менә шул чибәр бинаның шактый иркен эчен, андагы экспонатларны ашыкмыйча гына карап, танышып чыктык. Музейны караучы ханымның тырышлыгы нәтиҗәсендә күп нәрсә җыелган, ләкин бушлык сизелә иде әле. Мәсәлән, мин үзем Г. Ибраһимовның шушы музей өчен җибәргән “Нәхү” исемле китабын һәм әдипнең Газим Касимовка үз кулы белән язган хатын монда күрмәдем. Ахрысы, аларны миннән алып киткән Уфа галиме тапшырырга өлгермәгәндер…» – дип яза ул (15, 385).

Җыеп әйткәндә, Г. Ибраһимовның шәхси үрнәге дә, аның бай әдәби мирасы да икенче күренекле әдип Әмирхан Еникинең иҗтимагый-сәяси, фәлсәфи һәм әдәби-эстетик карашлары формалашуда зур роль уйный. Язучы әдәбиятка олуг якташының бәрәкәтле традицияләрендә дә килә. Туган якка тугрылык, газиз милләт язмышын кайгырту, дөньяны һәм кеше күңелен тирәнтен аңлау, вөҗдан кыйбласы белән яшәү һәм иҗат итүдә өлкән әдип аңа рухи терәк була. Ә. Еникинең соңгы әсәре – «Юбилей сабаклары»нда мондый юллар бар: «Кеше кирәк!.. Яхшымы-начармы, яшәр өчен кеше кирәк. Дөньясы шулай корылган.

Мин үземә фикердәшләр таптым. Бәхетемдер инде, алар һәммәсе дә бик ышанычлы, затлы кешеләр иде» (15, 477). Ныклы инану белән әйтергә була: әдипнең шул фикердәш, мәсләктәш остазларының берсе, һичшиксез, Г. Ибраһимов була.

ӘДӘБИЯТ


1. Очерки истории татарской общественной мысли. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2000. – 407 б.
2. Яхин А. Г. Әдәбият: 9 нчы сыйныф өчен дәреслек-хрестоматия. – Тулыландырган икенче басма / А. Г. Яхин. – Казан: Мәгариф, 2001. – 191 б.
3. Габдуллин И. Р. От служилых татар к татарскому дворянству / И. Р. Габдуллин. – М., 2006. – 320 с.
4. Еники Ә. Соңгы китап: Истәлекләр/ Ә. Еники. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. – 504 б.
5. Хатипов Ф. Мөлкәтебезне барлаганда: Иҗат портретлары, тәнкыйди-теоретик мәкаләләр / Ф. Хатипов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 272 б.
6. Хәсәнов М. Х. Галимҗан Ибраһимов: шәхесе һәм иҗаты, ул яшәгән заман турында уйланулар // Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман: Тууына 115 ел тулуга багышланган фәнни конференция материаллары / М. Х. Хәсәнов. – Казан: Фикер, 2002. – 272 б.
7. Поварисов С. Оҗмахка бер адым. Роман. – 3 том / С. Поварисов. – Казан: Матбугат йорты. – 2001. – 320 б.
8. Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. 4 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 568 б.
9. Еники Ә. Соңгы китап. Истәлекләр / Ә. Еники. – Уфа: Китап, 1999. – 337 б.
10. Галимуллин Ф. Әле без туганчы… / Ф. Галимуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 320 б.
11. Галимуллин Ф. Табигыйлеккә хилафлык / Ф. Галимуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 303 б.
12. Гыймазова В., Идрисов Р. Еники васыятьләре / В. Гыймазова, Р. Идрисов // Өмет. – 2000. – 17 февраль. – 7 б.
13. Идрисов Р. Р. На пути художественного постижения правды войны: Учебное пособие / Р. Р. Идрисов. – Уфа: РИО БашГУ, 2005. – 124 с.
14. Еники Ә. Хәтердәге төеннәр: мәкаләләр, очерклар һәм истәлекләр / Ә. Еники. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. – 224 б.
15. Еники Ә. Әсәрләр: 5 томда. 5 том: Публицистик язмалар, мәкаләләр / Ә. Еники. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 479 б.
16. Гимадиев Ү. И. Талант һәм хезмәт / Ү. Гимадиев. – Өфө: Башкорт. кит. нәшр., – 1982. – 159 б.
17. Мәһдиев М. Реализмга таба / М. Мәһдиев. – Казан: КДУ нәшр., 1989. – 156 б.
18. Сафуанов С. Рухи тамырлар / С. Сафуанов. – Уфа: Китап, 2006. – 376 б.

# ТАНЗИМАТ ЧОРЫ ТӨРЕК ӘДӘБИЯТЫНДА ҺӘМ ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ИҖАТЫНДА АВЫЛ – ШӘҺӘР КАРШЫЛЫГЫ ТЕМАСЫ

***Р. А. Яруллина-Йылдырым (Адыяман)***

Литература периода Танзимат, которая пережила сильное воздействие европейской культуры, является проводником новых идей в татарское общество, в частности, литературу конца XIX – нач. XX в. Как и многие татарские писатели этого периода, Г. Ибрагимов с большим интересом увлекался новыми начинаниями и прогрессивными идеями турецкой литературы. В особенности, на его эстетические взгляды подействовали произведения А. Хамида Тархана, Н. Кемаля, А. Мидхада. В статье на примере пейзажной лирики из книги «Сахра» А. Хамида и рассказа «Счастье» Ахмеда Мидхада в сравнительно-сопоставительном плане выявляется общность с идеями некоторых произведений Г. Ибрагимова с точки зрения романтических особенностей, в частности, влияния руссоистических взглядов.

Европадагы Ренессанс казанышлары тәэсирендә XIX гасырның икенче яртысыннан һәр яктан искергән, черегән һәм хаос хәлендәге Госманлы империясендә Танзимат (яңа тәртип) дәвере башлана. Европалашу йөз ел элек башланган булса да, Танзимат карарының рәсми рәвештә игълан ителүе (1839) төрекләр арасында өр-яңа бер мәдәнияткә омтылуда, Европаның изүче көче, өстенлеге каршысында яңадан формалаша башлауда яңа сәхифә, ныклы бер карар иде (9, 30). Дәүләт күләмендә Танзимат күренеше сәяси һәм хәрби яңарыш кына түгел, бәлки социаль, икътисади һәм әдәби өлкәләрдә дә яңарыш иде. Әдәби мәгънәдә Танзимат яңа эзләнүләр һәм табышлар, яңа тәҗрибәләр чоры буларак аңлашыла. Модернлашуның күренекле лидерларыннан саналган Ибраһим Шинаси, Нәмык Кәмаль, Зыя Паша, Әхмәд Мидхәд әфәнделәрнең кеше акылын зурлаган, шәхес иреген яклаган көчле яңгырашлы, фәлсәфи карашлы, форма һәм эчтәлек ягыннан яңа әсәрләре XIX гасыр ахыры – XX гасыр башы татар әдәбиятына да тәэсир итүе бәхәссездер. Тукай, Дәрдеменд, Г. Камал, Ф. Әмирхан, Г. Исхакыйлар кебек, Галимҗан Ибраһимов та «яңа төрек әдәбиятын яхшы белгән язучылардан иде. Талантлы шагыйрь, драматург, тәрҗемәче, публицист Ибраһим Шинаси иҗаты, гражданлык пафосы белән сугарылган Тәүфикъ Фикрәт романтизмы аңа якынрак булуы күренә. Әхмәд Мидхәднең төрле маҗараларга бай булган новелла, повесть һәм романнарын Ибраһимов төрек телендә укыган», – дип яза Резеда Ганиева (3, 531). Фатих Кәримигә язган хатында төрек әдәбиятын матур һәм нәфис әдәбият дип бәяләгән Г. Ибраһимов: «Габделхак Хәмид, Әкрам, Халид Зыя һәм Тәүфикълары булган бу әдәбиятта безем татар өчен бик күп гыйбарәләр, бик күп нәмүнә *(үрнәк)* вә хәзинә бардыр, – дип белдерә. – Мин бу ел Габделхак Хәмид трагедияләрен укый башладым... Вакыйган, мин ул куәт алдында хәйранмын» (2, 107). Хатта татар язучысының төрек әдипләрен олылавы, төрек әдәбиятын зурлавы һәм аңа сусавы ачык күренә.

Европа культурасына, яшәү тарзына, бигрәк тә француз әдәбияты һәм сәнгатенә йөз тоткан Танзимат язучылары иҗатында француз сентиментализмының күренекле вәкиле Жан-Жак Руссо фикерләре белән көчле мавыгу күзгә ташлана. Руссоның кешене рәхимсез эксплуатацияләгән һәм сыйнфый тигезсезлеккә юл ачкан, әхлакның бозылуына сәбәп булган цивилизацияне тәнкыйтьләүче, «табигый халәт»не аңа капма-каршы куючы фикерләре бу чор төрек әдәбиятында, аерым алганда, Габделхак Хәмид («Сахра» шигырьләр китабы), Режаизаде Мәхмүт Әкрам («Араба севдасы»), Әхмәт Мидхәд («Бахтиярлык») кебек язучылар иҗатында чагылыш таба. Мәсәлән, Р. М. Әкрамның «Машина гыйшыкы» («Араба севдасы») романының баш герое Виһруз бәй, белем алуда, киенүдә, ашау-эчүдә, кыланышларында, күңел ачуда булсынмы – һәр яктан европача яшәү үрнәгенә бирелгән тип итеп тасвирлана. Көнбатыш әдәбиятының мәшһүр мәхәббәт романнарын укый, операларыннан кайбер парчаларны үз эчендә көйләп йөри, француз шагыйре белән төрек шагыйрьләрен чагыштырып, икенчесен түбәнсетә. Ж.-Ж. Руссоның «Яңа Элоиза» романын җентекле өйрәнә һәм яраткан кызына сөю хатларының үрнәгең бу әсәрдән ала (5, 387). Гомумән, бу чор төрек әдәбиятында Европа мәдәниятенең тәэсирендә, заманча булам дип, Биһруз бәй кебек, үз мәдәниятеннән, яшәү рәвешеннән ераклашырга тырышкан типларны тасвирлаган шактый әсәрләр очратырга мөмкин.

Танзимат әдәбиятының эре фигураларыннан саналган һәм татар язучылары, шул исәптән Галимҗан Ибраһимовның эстетик карашларына да көчле тәэсир иткән Габделхак Хәмид Тархан белән Әхмәт Мидхәд әфәнделәрнең кайбер әсәрләренә күзәтү ясап үтмәкче булам. Өч язучы иҗатын да романтизм әдәбиятында яратып эшләнгән темаларның берсе – авыл тормышы белән шәһәр мәдәнияте каршылыгы ноктасыннан анализлау мантыйклы булыр дип саныйм.

Аристократ гаиләсендә тәрбияләнеп, яхшы белем һәм тәрбия алган, гомеренең күп өлешен Париж, Берлин, Лондон кебек шәһәрләрдә илчелекләрдә хезмәттә уздырган Габделхак Хәмидне чордашлары иң бөек шагыйрь – «шаири әгъзам» дип йөртәләр (6,162). Диван әдәбиятының бөтен рухын һәм үзенчәлекләрен яхшы белгән Г. Хәмид яңарыш юлында Көнчыгыш һәм Көнбатыш мәдәниятләренең бай телен һәм мәдәниятен, фәлсәфи һәм эстетик фикерләрен әсәрләрендә уңышлы берләштерә. Аның шигырь сәнгатендәге иң мөһим үзенчәлеге, яңалыгы – фикерне алгы планга чыгаруда һәм бу юлда тойгы белән төшенчәне берләштергән фәлсәфи шигырьләр язуда. Әдипнең әсәрләре төрек шигъриятендә хыял дөньясына иң бай һәм иң тирән иҗат булып санала. Моннан тыш, күркәмлек, фикер һәм рух югарылыгы йөзеннән, аның шигырьләре әдәби сәнгать һәйкәленә тиңләштерелә, шуның өчен аның шигъри каләменә «юҗе шиир», ягъни « бөек шигырь» исеме бирелә (6, 163).

Габделхак Хәмиднең тәүге әсәре булган «Сахра» (1879) исемле шигырь китабы төрек әдәбиятында пейзаж лирикасының беренче үрнәге санала. Шәһәр мәдәнияте белән авыл тормышы арасындагы мөнәсәбәтләрне чагыштыруга багышланган китапта авыл тормышына өстенлек бирүе, Ж.-Ж. Руссо романтизмы тәэсирендә «мәдәният кешегә бәхет китерми» дигән фикерне шигъри юлларда расларга алынуы ягыннан бу

китап төрек сүз сәнгатендә яңа бер башлангыч булып тора. Диван шигыренең форма һәм сәнгатилегеннән ераклашкан һәм экзистенциаль фикерләрне дә үз эченә алган «Сахра» китабында Г. Хәмиднең табигатьне аңлавы, аны яхшы танып-белү сәләте ачык күренә. Китаптагы «Хош нишинан» («Хуш ай яктысы») исемле беренче шигырьнең (8, 63–66) ике строфасында табигать дөньясы белән шәһәр тормышы чагыштырыла, аннан соңгы строфада табигать эчендә көн итүче кешенең яшәү стиле, 4–5 нче строфаларда табигатьтә яшәүчеләрнең дини уй-фикерләре, 6 нчы строфада яз фасылында авыл кешеләре тормышындагы җанлану күренешләре тасвирлана. Янә табигать тасвирын, кырдагы тормыш картиналарын, кыш фасылын аерым бер җанлылык белән сурәтләгәннән соң, 15–18 строфаларда шагыйрь каләме яшь авыл кызын төрле ситуацияләрдә сурәтли. Авыл кешеләренең яшәеше белән якынрак танышу максатыннан Г. Хәмид, берара, Истанбул янындагы дачада һәм Токат авылында яшәп, тәҗрибә туплый. Әсәрләрендә авыл кешесен «табигать парчасы» дип зурлый, аны кешене бәхетсез итүче шәһәр мәдәниятеннән читтә сурәтли. Шагыйрь фикеренчә, авыл кешесе мәдәният тарафыннан йөкләнгән борчулардан еракта, табигать хозурлыгында яши. Табигать кешесе үзе аулаган хайван ите белән тамагын туйдырса, шәһәрлеләр көн итү өчен бер берен ашый. Шәһәрле саз уйнавын тыңлау өчен акча түләсә, авыл кешесе исә бушка кош сайравын тыңлый, ди. Күңел ачу темасын яктырткада Г. Хәмид шәһәр кешесенең күңел ачуын болганчык суга охшата, авыл кешесенекен исә көмеш су белән чагыштыра. Шигырьдә пантеистик идеялар да урын алган. Тәңре һәрвакыт бар, тудыручы һәм иҗат итүче. Үзенә сәҗдә иткән Тәңренең барлыгын авыл кешесе гыйбадәт иткәндә әйләнә-тирәсендә хис итә. Г. Хәмид авыл кешесенең бу шәкелдәге гыйбадәтен дөрес дип саный.

Икенче бер шигырь – «Белде гүзин»дә («Бистә гүзәле») (8, 47–57) дә Руссо идеяләре дәвам иттерелә: авыл тормышының кеше өчен хозурлык, шәһәрнең даими золмәт әсирлеге икәне аңлатыла. Авылдагы кыш матур бер фасыл, гади генә киемле яшь кыз табигатьнең бер парчасы буларак, якты буяуларда бирелә. Чәчләрен җил тараган, иртәләрен әтәч тавышына уянган бу кара чәчле яшь кыз, озын чәчләренә төренеп, сөйгәне белән күрешергә урамга чыга. Болар барысы да «Белде гүзин»дә шәһәрдәге яшәешкә каршы сурәтләнә. Авылда сөю-мәхәббәт чиста һәм яшерен, шәһәрдә исә мәхәббәтнең үз законнары бар. Биредә тышкы күренеш һәм акчага сатылачак һәр нәрсә ир-хатын мөнәсәбәтендә әһәмиятле роль уйный. Шагыйрь бу мөнәсәбәтләрдә акчаның көчен аңлатан хикмәтле сүзен әйтә: «Акча мабуд ве банкалар мабед», ягъни «Акча – Тәңре, банклар исә гыйбадәтханә» (8, 57).

Пантеистик фикерләргә төренгән 8–9 нчы строфаларда янә табигатьнең җанлы картинасы бирелә. Таулар, сулар, яшеллек эчендә җиләк-җимешләре салынып торган агачлар, кошлар һәм чәчәкләр белән капланган табигать, үзләрен туендыручы Тәңрене мактап, үзара сөйләшә, аңа рәхмәтен белдерә.

Гомумән, Габделхак Хәмиднең «Сахра» исемле беренче шигырьләр китабы авыл кешесе белән табигатьне бербөтен итеп җанлы тасвирлауда, яңа шигъри сурәтләре һәм фәлсәфи фикерләре ягыннан, унтугызынчы гасыр төрек поэзиясе өчен бер казаныш булып тора.

Әхмәт Мидхәднең «Бахтиярлык» (1885) исемле озын хикәясендә дә авыл тормышы романтикларча мактала, шәһәр яшәешеннән өстен тасвирлана. Әсәрнең баш геройлары итеп лицей-интернатта бер сыйныфта укучы, әмма матди хәлләре һәм сыйфный үзенчәлекләре төрле булган гаилә уллары Сенай һәм Шинаси исемле үсмер егетләр алына. Хикәядә берсенең авыл тормышы, икенчесенең дә шәһәр тормышы кешене бәхетле итә дигән идеяне чынга ашыру өчен, үзләренә юл картасы сызулары тасвир ителә

Сенай – Бурса өлкәсе тарафында зур мәйданда җирләре булган Ямали Муса агайның улы. Җирне башкаларга арендага биреп, үзе көч тукмичә генә мул тормышта яшәүче Ямали Муса агайның зур хыялы – улын Истанбулда укытып, зур бер дәүләт кешесе яки генерал кебек дәрәҗәле зат итеп җитештерү. Улына еш кына: «Улым! Син ичмасам минем кебек хайван булып калма. Шәһәргә кит, укы! Яз! Тәрбияле бул! Язмышыңда булса, хәтта генерал булырсың. Минем кебек җир эшкәртүче булып яшәү бәхетме соң?» (4, 4) – ди. Шуңа күрә Сенайның яхшы һәм төпле белем алуы өчен кулыннан килгән кадәр тырыша. Галатасарай мәктәбен тәмамлаган Сенай, Европага китеп, укуын хокук юнәлешендә дәвам иттергә һәм, Истанбулга кайтып, яхшы бер адвокат булырга хыяллана.

Шинасига исә атасы, еллар буенча дәүләт эшендә бер хезмәт хакы алып гомерен уздырган кеше буларак, башка юлны тәкъдим итә. «Шәһәрдә кешенең байлыгы, уңышы ни кадәр күп, ни кадәр югары булса, рәхәтсезлеге, бәхетсезлеге дә шул кадәр артыр. Иминлек, муллык һәм бәхет зур җәмгыятьләрдән еракта яшәүдәдер» (4, 4), – дип, Руссоның табигать кочагына качу фикерен телгә ала. Атасының авыл тормышының матурлыгын бәйнә-бәйнә һәм тәэсирле итеп аңлатулары йогынтысында, Шинаси яхшы бер игенче булырга карар бирә. Күргәнебезчә, ике егетнең дә киләчәген билгеләүдә ата феноменының әһәмияте зур. Һәр ата улын үзендә булмаганнарга юнәлдерә, үз хыялларын балалары аша тормышка ашырырга тели.

Моннан соң бу ике атаның бер-беренә каршы булган фикерләренең никадәр дөрес булуы улларының язмышында чагылдырыла. Шинаси, атасының үлеменнән соң, җир эшкәртү эшендә фикер уртаклашу өчен Ямали Муса агайның утарына китә. Сәяхәт өчен килгәндер, дип уйлап, Ямали Муса агай егеткә язын килсә идең, кышын авылда нинди гүзәллек, нәфислек булсын, ди. Шинаси да җавабында хикәянең леймотивы булырлык сүзләрен әйтә: «Юк, әфәндем, мин монда сәяхәт итү өчен килмәдем. Авыл кешесе булырга килдем» (4, 28), – ди. Үзенә кечкенә генә җир сатып алып, Шинаси табигать кочагында хыялларын тормышка ашыра башлый. Тавыклар ала, инкубаторда чеби үрчетә, төрле җиләк-җимеш үстерә башлый. Янына ярдәмче эшчеләр алып, хайванчылык кәсебен дә киңәйтә. Туфракларының уңдырышын арттырып, уңышларын берничә тапкыр артык ала башлый. Биш-алты ел эчендә табышы мул булган фермерлар дәрәҗәсенә күтәрелә һәм шул рәвешле үз идеясенә, максатларына ирешә. Ямали Муса агайның кызы Зөләйхага өйләнеп, бәхетле гаилә тормышы кора.

Синай башта чит илләр бюросына хезмәткәр булып урнаша, атасыннан калган акчаны Истанбулның күңел ачу мәркәзендә туздыра, Европадан килгән артист ханым белән богема тормышы алып бара. Моның

өстенә аля-франка, ягъни французларча яшәү стиленә кызыксынучан булуы да күренә. Мәсәлән, үзенә «Синор де Берракпынар» исеме күркәм булыр иде, ди. Бераздан соң бабасы акчасына Европага белем алырга китә, тиз арада Парижның азарт уеннарында, казиноларында бөтен акчасын югалтып, көч-хәлгә бер тиенсез Төркиягә кайтып егыла. Үзенең таләпләренә туры килгән кызга – француз укытучы мадам Турниедән европа стилендә белем һәм тәрбия алган Нусрәт ханымга өйләнә. Әмма Европаны, андагы яшәү стилен сагыну күңеленә тынычлык бирми. Кайнатасының акчаларын да үзенә үзләштереп, акылының бер почмагында тынгылык бирмәгән шул европача яшәү, мәдәниятле булу хыялын тормышка ашыру өчен, Швейцарияга кача һәм моннан соң һичбер хәбәр алынмый.

Хикәядәге баш геройларның исемнәре дә тирән мәгънәгә, аларның язмышларын билгеләүче үзенчәлеккә ия. Язучының идеалларына туры килгән образ Шинасиның исеме «белгән, аңлаган, таныган» , Сенайныкы исә «икеле, ике кисәктән тору» мәгънәсендә килә. Чыннан да, Сенайның тәне белән төрек, рухы белән Европалы икәне, Шинасиның да ирешкән уңышларыннан үз исемен дәлилләгәне күренә.

Гомумән, бәхет эзләү, бәхет нәрсәдә кебек адәм баласын һәм кешелек җәмгыятен һәрвакыт борчыган сорауга Әхмәт Мидхәд үз чорыннан торып җавап эзли. Бәхет, Шинаси һәм Ж.-Ж. Руссоның «Яңа Элоиза» романындагы кебек, кыр һәм авыл тормышына качудамы? Яки Сенай үрнәгендәге кебек, бөтен начарлыкларына карамастан, яшәүне шәһәр тормышында дәвам иттерүдәме?

Югарыда күзәтү ясалган төрек әдәбияты әсәрләре белән Г. Ибраһимовның Октябрь революциясенә кадәрге прозасы арасында шактый уртаклыклар бар. Татар әдибенә француз романтизмы, бигрәк тә Ж.-Ж. Руссо фикерләренең тәэсире йогынтысында фәнни язмалары булганлыктан, без бу проблемага тирән кермибез. Белгәнебезчә, Г. Ибраһимовның «Яз башы», «Диңгездә», «Табигать балалары» кебек хикәяләрендә табигать культы, бәхеткә һәм хозурлыкка омтылган геройның табигать белән гармониясе романтикларча тасвирлана. «Көтүчеләр»дә Ж.-Ж. Руссоның фән һәм сәнгать хакындагы фикерләре чагыла: әсәр герое Вахит, атасы Әптерәш карт кебек, тормыш төбендә, хәерчелектә гомер уздырган миллионларча адәм баласының бәхете, мәсгудияте өчен гыйлем-әдәбиятның, фәлсәфәнең һәм диннәрнең бернинди файдасы юклыгын ярсулы рәвештә дәлилләргә омтыла. «Яшь йөрәкләр» романындагы Сабир да, Әхмәт Мидхәтнең «Бахтиярлык» хикәясендәге Шинаси кебек, бәхетне тир түгеп, физик хезмәт белән көн итүдә, авылда игенче тормышы белән яшәүдә саный, өйләнгәндә дә авылны һәм туфракны яраткан, укымаган, табигате бозылмаган, тере һәм җанлы кызны сайлый. Шәһәрдәге укуын ташлап, авылга кайтып урнашырга теләвенең сәбәбен Сабир француз романтиклары тәэсиренә бирелеп аңлата: «Мәдәниятегездән дә, театр вә музыкаларыгыздан да туйдым. Гыйлем хәзинәсе булган китапханәләрегезгә дә ихтирамым бик аз; мәдәниятнең бирдеге башка бик күп “сәгадәтләре”нең дә һичберен сагынырмын дип уйлый алмыйм... Мин сүзем, гакылым белән генә түгел, үземнең инстинктым белән үк авыл ягына карыйм. Дөрес, синең санаган нәрсәләреңнең анда бере дә булмас, ләкин минем җанымның теләгәне булыр... Мин үз эшемне эшләп, үземә һәм үземнең ирегемә үзем хуҗа булырмын. Азат булырмын» (1, 74), – ди. Романда Сабирның да үз максатына ирешүен күрәбез, әмма язучының симпатиясе милли сәнгатьне, татар музыкасын үстерергә теләгән Зыя тарафында. Димәк, Г. Ибраһимов сәнгатьнең һәм мәдәниятнең кеше тормышындагы уңай тәэсирен бөтенләй үк кире какмый.

Гомумән, Танзимат чоры сүз сәнгате – бай һәм кызыксыну уятырлык мирас. Киләчәктә ике милләт классикларының да гүзәл үрнәкләрен күбрәк тәрҗемә итү, ике культураны да бер-беренә киңрәк таныту һәм тирән эзләнүләр алып бару эше сорала.

ӘДӘБИЯТ

1. Ибраһимов Г. Сайланма әсәрләр. – Казан: Хәтер, 2002. – 543 б.
2. Ибраһимов Г. Фатих Кәримигә // Совет әдәбияты. – 1963. – № 1. – Б. 107–110.
3. Ганиева Р. Көнчыгыш традицияләрен үстереп // Татар әдәбияты тарихы: Алты томда. III т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – Б. 531–532.
4. Midhat A. Bahtiyarlık / Hzl. N. Sağlam. – Ankara: TDK yayınevi, 2000. – 87 s.
5. Tanziman Edebiyatı / Hzl.: Prof. Dr. İsmail Parlatır, Prof. Dr. İnci Enginün, Prof. Dr. Ahmat Ercilasun vb. – Ankara: Akçağ yayınevi, 2006. – 701 s.
6. Türk Dünyası Edebiyat Tarihi. Cilt 7. – Ankara:Atatürk kültür merkezi başkalığı yayınları, 2006. – 641 s.
7. Tanzimat Edebiyatı II / Hzl.: Prof. Dr. Ali İhsan Kolcu. – Erzurum: Salkısöğüt yayınevi, 2009. – 305 s.
8. Hamit A. Bütün şiirleri 1 Sahra. Divaneliklerim, Bunlar odur / Hzl.: İnci Enginün. – İstanbul: Dergah yayınevi, 1991. –118 s.
9.Yeni Türk Edebiyatı (1839–2000) / Editör: Dr. Ramazan Korkmaz. – Ankara: Grafiker yayınları, 2009. – 640 s.

## ҒӘЛИМЙӘН ИБРАҺИМОВТЫҢ «АЛМАСЫБАР» ХИКӘЙӘҺЕ ҺӘМ ӘҪӘР БУЙЫНСА СПЕКТАКЛЬ: СЮЖЕТ-КОМПОЗИЦИЯ ҮҘЕНСӘЛЕКТӘРЕ

***Р. Х. Фәтҡуллина (Стәрлетамаҡ)***

В статье анализируются сюжетно-композиционные особенности рассказа Галимжана Ибрагимова «Алмачуар». Основой внутреннего сюжетного развития служит душевный мир повествователя – героя рассказа Закира, его отношение к жизни, жеребенку Алмачуар. Автором статьи также дается сопоставительный анализ рассказа с одноименным спектаклем «Алмачуар» по мотивам рассказа Г. Ибрагимова на сцене Татарского государственного театра юных зрителей имени Габдуллы Кариева.

Ғәлимйән Ибраһимов – Башҡортостанда тыуып үҫкән яҡташ яҙыусыбыҙ. Уның һәр әҫәре тыуған төйәк рухы менән һуғарылған, туғандаш ике халыҡтың: башҡорттоң һәм татарҙың күңел яҡынлығын, йәшәйеш ҡиммәттәре берлеген асыуға бағышланған.

Әҙиптең «Алмасыбар» хикәйәһе лә ошо яҡты маҡсатҡа хеҙмәт итә. Балалар өсөн ижад ителгән әҫәр ерлегендә – ябай ауыл халҡы тормошо. Ғәлимйән Ибраһимовтың оҫта ҡәләме хикәйәлә татар-башҡорт мөнәсәбәттәрен бик нескә бирә. Әҫәрҙең инеш өлөшөндә Мөхәммәтхафизға көрәшсе-батыр Әлемғол бурыл бейә бүләк итә. Милли менталитет үҙенсәлектәре шунда сағыла ла инде: тәбиғәте менән бик намыҫсан, алдаша белмәҫ башҡорт Әлемғол һабантуйҙа Оҙон Хафизды хәрәмләшеп еңгән өсөн үҙен-үҙе ғәфү итә алмай сиргә һабыша. Данлыҡлы бәйге аттары әсәһе – бурыл бейәне бүләк итеүе башҡорттоң әйткән нәҙеренә бәйле. Ауыл халҡы был ваҡиғаны ихлас күңел менән аптырап та, шатланып та ҡабул итә, бүләк аттың Хафиз ғаиләһенә ҡот-бәрәкәт килтереүен теләп, доға ҡыла.

Шундай халыҡсан мөхиттә асыла әҫәр. Проза жанрына хас булғанса, яҙыусы Хафиз ғаиләһенең көнкүрешен һүрәтләй, балалары яҙмышына төшкән һынауҙарҙың сәбәптәрен асыҡлай. Өлкән улдары Шәйәхмәт дошманлыҡ арҡаһында нахаҡҡа хөкөм ителгәс, ҡыҙҙары атай фатихаһынан тыш тормошҡа сыҡҡас, Әлемғол бүләге ғаилә өсөн киләсәккә ҙур өмөт булараҡ ҡабул ителә. «Бер мөхәббәттең тарихы» тип билдәләгән Ғ. Ибраһимов хикәйәнең икенсе исемен. Уның сере әҫәрҙә үҙәкләшәсәк төп герой – Хафиздың кинйә улы Закир образына бәйле асыла. Балалар хикәйәһен яҙыусы ошо үсмер исеменән алып бара. Закирҙың күңел донъяһы, уның тормошҡа мөнәсәбәте, юғалтыу-табыштары бар итә әҫәрҙе. Хикәйәнең психологик нигеҙен билдәләүсе эске монологтар, геройҙың уй-тойғолар ағышы әҫәрҙең эске сюжет үҫешен тәьмин итә. Закирҙың өмөт-хыялы булып тыуа бурыл бейәнән Алмасыбар ҡушаматлы ҡолон, уны бәйге аты итеп үҫтереү маҡсаты геройҙы ла көслө итә.

Ғабдулла Кариев исемендәге Татар Дәүләт Йәш тамашасылар театры сәхнәһендә Ғәлимйән Ибраһимовтың «Алмасыбар» хикәйәһе буйынса ҡуйылған спектаклдә (Фәнәвил Ғәлиев сценарийы), драматургия ҡанундарына ярашлы, художестволы әҫәр экспозицияһында һүрәтләнгән бер ваҡиға ла алынмай, Хафиз ғаиләһенең сюжеттың төйөнләнеүенә тиклемге тормошон һүрәтләүгә спектаклдә әһәмиәт бирелмәгән. Тамаша экспозицияһы – геройҙың баласағынан килгән хыялы (малай һәм үсмерҙе ике кеше уйнай) – Закирҙың үҙ ҡолоно булыу хаҡындағы яҡты өмөттәренә бәйле асыла. Спектакль өсөн тағы шуныһы үҙенсәлекле: әгәр ҙә Ғәлимйән Ибраһимов әҫәрҙә кешеләр тормошон һүрәтләүҙе беренсел маҡсат итеп ҡуйһа, спектаклдең режиссеры Ренат Әюпов һәм сценарист Фәнәвил Ғәлиев өс яҫылыҡ: кешеләр, аттар, бүреләр донъяһын йәнәш бирә. Һәр зат үҙ ҡиммәттәре, үҙ тормошо менән йәшәй, спектаклдең драматик асылын ошо өс донъя араһындағы эске бәйләнештәр, ҡаршылыҡтар тыуҙыра. Йәшәү өсөн көрәш, өмөт, мөхәббәт һәм нәфрәт тойғолары ошо художестволы «өсмөйөштә» асыла. Тамашала кешеләр менән бергә, аттар ҙа, бүреләр ҙә «һөйләшә». Алмасыбарҙың да «кешеләшеүе», спектаклдең көсөргәнешле мәлдәрендә «телгә килеүе» хикәйәләге ваҡиғаларҙы нескәрәк сағылдырыуға булышлыҡ итә, әҫәрҙе ҡабул итеүҙе тәрәнәйтә. Шуға ла проза әҫәре – хикәйәлә үҙәктә Закирҙың күңел донъяһын һүрәтләү торһа, спектакль композицияһының арҡа һөйәген Алмасыбар образы билдәләй, сюжетты уның яҙмышы әйҙәй.

Кеше һәм ат араһындағы эске бәйләнеште изге итеп ҡабул итеү борон-борондан аңыбыҙға, йәнебеҙгә һеңгән. Хыялыбыҙ, йәшәү ҡотобоҙ башҡорт халыҡ эпосында Аҡбуҙат образында һынлана, «Ҡайҙа ғына бармай, ниҙәр күрмәй ир-егеткәй менән ат башы» тип йырлана халыҡ йыры «Азамат»та ла. Ошо мәңгелек берлек «Алмасыбар» хикәйәһе нигеҙендә лә ята. Быуаҙ бейәгә донъя ҡото итеп ҡарау, уға һаҡсыл, аяулы мөнәсәбәт, ҡолон тыуғас, халыҡ йолаһына ярашлы, аҡһаҡал ҡарттың – Сафа бабайҙың, доға уҡый-уҡый, уның муйынына ҡыҙыл таҫма менән кескәй ҡыңғырау (ҡот саҡырыу, ҡот һаҡлау билдәһе) тағыуы – туғандаш халыҡтарҙың яҡты күңел донъяһын асыу сараһы. Ҙур тормош тәжрибәле, абруйлы, бәйге аттарын таныу һәм тәрбиәләү серҙәрен белгән Сафа бабай образы Ғ. Ибраһимов хикәйәһендә ҙур әһәмиәткә эйә. Әҫәрҙә был образ характер кимәлендә: уның һүҙе халыҡ аҡылын, ихтыярын сағылдыра, фатиха, кәңәш биреүсе лә, кәрәк икән, һуңғы һүҙҙе әйтеүсе лә, Алмасыбарҙы сабыш аты итеп тәрбиәләргә ярҙам итеүсе лә – Сафа бабай. Спектаклдә был образ, ҡыҙғанысҡа ҡаршы, алынмай, уның рухи көсө хикәйәләгесә тамашаны байытыр, быуындар араһындағы бәйләнештең ни тиклем мөһим булыуына баҫым яһар ине.

Хикәйә сюжетында яҙыусы Хафиз ғаиләһендәге мөнәсәбәттәрҙе һүрәтләүгә ҙур урын бирә: был да төрки халыҡтарының күркәм ғаилә моделе итеп ҡабул ителә. Закир – бик бәхетле бала, ул ҡурсаулы, мөхәббәтле ата-әсә ҡосағында үҫә, был тойғолар ғаиләләге ике бала ҡайғыһынан һуң тағы ла тәрәнәйә. Кинйә улдың хыял-өмөттәрен, Алмасыбарға булған һөйөүен бигерәк тә атай кеше аңлап ҡабул итә. Быуаҙ бурыл бейәне һаҡлау, һуңынан Алмасыбарҙы һабанға екмәү хаҡындағы Закирҙың үтенестәренә лә ул һәр саҡ ризалаша. Иң мөһиме – улының күңелен һүрмәү, рухын үҫтереү маҡсатында эшләй быны атай кеше. Ғаилә, бигерәк тә атай менән ул мөнәсәбәттәре спектаклдә Ғәлимйән Ибраһимов һүрәтләгәнсә сағыла. Үсмерҙәр күңелендә тәүге тойғолар яралғанын күрһәтеү өсөн өҫтәлмә персонаж – Ҡыҙ образы алынған. Тамашаның ҙур табышы итеп шуны билдәләр инем: спектаклдә ғаилә тормошо кешеләргә йәнәшә бүреләр (Ҡарт бүре, Инә бүре, Бала бүре, Йәтим бүре образдары ярҙамында), аттар (Оло ат, Бейә, Йәш тай, Йәш бейә образдары булышлығы менән) донъяһы аша бирелә. Был ғаиләләр ҙә йәшәүгә хоҡуҡты һөйөү һәм берҙәмлек менән яулай. Тамашаға романтик рух өргән тағы бер мөхәббәт тарихы (ярҙамсы сюжет) – Алмасыбар һәм Йәш бейә араһындағы тойғолар үҫеше. Спектаклдең режиссеры Ренат Әюпов һәм бейеүҙәрҙе ҡуйыусы Рөстәм Фәтҡуллин башлыса хореография мөмкинлектәре ярҙамында аса был яҡты идеяны – йәш аттар мөхәббәтен. Алмасыбарҙы тулы ҡанлы образ итеп күҙаллау өсөн был сюжеттың роле бик ҙур. Финалда Алмасыбар фажиғәһенән һуң Йәш бейә тамашасы күңелендә киләсәккә өмөт ҡалдырыуға хеҙмәт итә – уның ҡарынында затлы ат нәҫелен дауам итәсәк йән бар.

Хикәйәнең дә, спектаклдең дә кульминацияһын ойоштороусы художестволы арауыҡ – ул һабантуй майҙаны. Проза өсөн милли байрам картинаһын тасуирлау ҡатмарлы түгел, халыҡ йолалары хикәйәлә сағыштырмаса киңерәк һүрәтләнә, сәхнә өсөн – массалы хәрәкәт биреү, художестволы деталдәргә иғтибар мөһим. Яҙыусы бәйге аты – Алмасыбарҙың халәтен психологик яҡтан тәрән аса, ғүмерендәге һынылышлы мәлде ул ярһып, ашҡынып ҡаршылай. Хикәйәлә бәйгенең һүрәтләнеше Закир тойғолары аша сағыла, тышҡы һәм эске

хәрәкәт тиҙләнешле үҫкән һайын, әҫәр атмосфераһы көсөргәнешлерәк була бара. Ә спектакль өсөн һабантуйҙағы ат сабышы бейеү аша бойомға ашырыла. Рөстәм Фәтҡуллин хикәйәләге көсөргәнеш үҫешен хореография теле менән аса алған. Кульминациялағы һынылыш шул: бәйгеләгә еңеү Алмасыбар өсөн дә, Закир өсөн дә тормоштағы еңелеүгә әйләнә. Затлы ат яныуҙан үлә, ә үҫмерҙең йөрәгендә, Ғәлимйән Ибраһимов әйткәнсә, «ергә, күккә, әҙәмдәргә, бөтә нәмәләргә булған мөхәббәтте Алмасыбар үҙе менән бергә алып китә». Спектаклдә Фәнәвил Ғәлиев һүҙҙәре аша үҫмерҙең ғазаптары шулай асыла: «Нисек донъя бөтмәһен?! Алмасыбар ашайһы үләндәр, сәскәләр, һыу кипте!» Ни генә тимә, ятаҡкан аты Закир (спектаклдә был ролде Рәзил Фәхертдинов башҡара) аҙмышында ҙур роль уйнай, хатта үҙенең үлеме менән дә ул йәш хужаһын үҫтерә. Хафиз ағай улын йыуатып әйткәнсә, Закир өсөн бөтөнләй икенсе, яңы тормош башлана.

Ғөмүмән, Ғәлимйән Ибраһимовтың хикәйәһенең сюжетын әйҙәүсе төп көс – ул Алмасыбар ғүмере ағышы. Әсәһе – бурыл бейә ҡарынынан алып тормош менән хушлашҡанға тиклем йәшәү дәүерендә донъяға ҡот өҫтәргә – кешене яратырға, матурлыҡты танырға, сәмләнеп йәшәргә өйрәтергә килгән изге зат булып хәтерҙә ҡалды был образ (был ролде спектаклдә Илнар Низамиев уйнай). Яҙыусы әҫәрҙе Закирҙың күңел фажиғәһен асҡан юлдар менән тамамлаһа ла («Шунан һуң донъяла һис нәмәнә һөйә алманым»), тормош дауам итә. Спектакль аҙағы шуға ишаралай: йәшәйештең мәңгелек хәрәкәте сәхнәне биҙәүсе тәгәрмәс әйләнешендә, аттар бейеүендә сағыла. Ә мөхәббәт йәшәй… Йәш бейә тойғолары булып, Алмасыбарҙан тыуасаҡ ҡолон ғүмере булып...

## ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ПРОЗАСЫНА ЭПИК ФОЛЬКЛОР ЙОГЫНТЫСЫ

***И. К. Фазлетдинов (Уфа)***

В предлагаемой статье исследуется преемственность фольклорных традиций в прозе Галимзяна Ибрагимова в образах, мотивах, художественных средствах; изучается влияние эпических жанров фольклора – сказок, легенд, преданий, быличек, устных рассказов на его творчество. Особый интерес представляет изучение влияния мифологии на произведения писателя, в которых тесно переплелись как исконно тюркские, так и арабо-мусульманские мифологические воззрения, образы и мотивы, которые обрели современное реалистическое содержание.

Бөек татар язучысы, җәмәгать эшлеклесе, зур галим Галимҗан Ибраһимовның талант тамырлары халык авыз иҗатына барып тоташуы – бәхәссез хакыйкать. Ул үзенең әдәби иҗатында кечкенәдән ишетеп үскән фольклор әсәрләрен – әкиятләрне, легенда-риваятьләрне, сөйләкләрне, мәкаль-әйтемнәрне мул файдалана, шул рәвешле, хикәя-романнарын милли колорит, кабатланмас моң белән баета. Фольклорның эпик төренә караган әсәрләр аның иҗатында аеруча зур урын тота.

Танылган фольклорчы А. Х. Садекова язучының фольклорга нигезләнеп язылган беренче әсәре итеп, «Яз башы» хикәясен (1910) күрсәтә (4, 7). Әдип андагы төп герой – Сабир исемле малайның әйләнә-тирә табигать белән танышкандагы кичерешләрен ачыклар өчен, әсәр тукымасына аждаһа турындагы мифологик хикәятне дә алып керә. Хикәянең кульминациясе дә әлеге персонаж хакындагы халык ышануларының бала күңеленә тәэсире нәтиҗәсендә барлыкка килә: көчле давыл, яшенле яңгырдан куркудан Сабирның күзенә аждаһа күренә һәм малай аңын югалта. Г. Ибраһимов еланның йөз ел яшәп, аждаһага әверелүе, аннары Каф тауларында мең ел гомер кичергәч, юхага әйләнеп, гүзәл кыз кыяфәтендә кешеләрнең канын суырып йөрүе турындагы мифологик хикәят аша борынгы ышануларның бала күңеленә нинди зур зыян ясый алганлыгын бик оста күрсәтә.

А. Х. Садекова билгеләвенчә, «аждаһа – явыз, изүче, җимерүче көч, ә юха мәкер һәм хыянәтне чагылдырып килә. Алар кешенең фантазиясе тарафыннан тудырылганнар һәм кеше аларны һәрвакыт җиңеп чыккан. Сабирның явыз көчләр тылсымыннан котылып, терелеп, якты кояш дөньясына, дусларына, балачак уеннарына кире әйләнеп кайтуы татар әкиятләренең оптимистик тәмамланышы белән туры килә» (4, 25). Ягъни «әкият мотивлары башка – профессиональ нәфис әдәбият дәрәҗәсендә осталарча гәүдәләнеш ала» (4, 25).

Әкиятләргә хас композицион элементлар, башламтәмамланышлар язучының башка әсәрләрендә дә очрап, персонажларның сөйләмен җанландыру, халыкчанлаштыру, сәнгатьчә баету өчен хезмәт итәләр. Мәсәлән, аның «Татар хатыны ниләр күрми» повестенда (1910) Усман исемле бунтарь-солдатның тоткынлыкта яткан урынын сурәтләгәндә, урядник әкиятләргә хас художестволы алым куллана. «Анда, дип әйтә, ди, тау өстендә дүрт почмаклы таш койма бар имеш, моның эчендә тагы койма, тагы дүрт солдат имеш, менә шуның эчендә калын стеналы биек сары таш пулат бар имеш, шуның кечкенә тәрәзәләре бар имеш, болар бары да беләк калынлыгы тимерләр белән коршалган имеш, дип әйтә, ди. Усманны менә шул тимерле тәрәзә эчендә бер бүлмәдә, бер ялгызы тимер богауларда саргаеп кибеп утырганын күргәннәр имеш» (1, 163). Күренүенчә, әлеге тасвирлама тылсымлы әкиятләрдә Каф таулары артында дию пәрие яшәгән җирне сурәтләгәндәге традицион медиаль формула белән тәңгәл килә һәм әсәрдә символик вазифа үти: патша төрмәсендә яткан егет дию пәриенә тоткынлыкка эләккән батыр белән чагыштырыла, ә патша дию пәриенә тиңләштерелә.

1912 елда тәмамланган «Яшь йөрәкләр» романында Кәрим карт «Җирнең чите кайда?» дигән сорауга шулай ук әкиятләргә хас тотрыклы тәгъбир белән җавап

кайтара: «Без җирнең читендә булдык, җирнең читенә барып җитеп, аяк салындырып утырдык; күрсәгез, исеңез китәр менә, шул җир бара-бара да, читенә җиткәч, теп-текә яр шикелле төшә дә китә, аннан ары бернәрсә дә юк. Җитмәсә тагы шул җирләрдә болыт бик түбән була, болытка элеп мундирлар киптерәбез. Кояшны җыйнаулап тартып чыгарабыз» (2, 149–150).

Галимҗан Ибраһимов иҗатында легенда һәм риваятьләр дә еш очрый. Белүебезчә, әлеге ике жанр бер-берсенә бик якын торып, этиологик – теге яки бу табигать күренешенә, урын атамасына һ. б. аңлатма бирү вазифасын башкаралар. Риваятьләр һәм легендалар арасындагы төп аерма – аларның чынбарлыкка мөнәсәбәтендә. Риваять «тарихта булган конкрет вакыйгалар, тормыш хәлләре, фактлар, тарихи шәхесләр, шәһәр, авыл һәм башка урыннар белән бәйле мәгълүматларны һәркем ышанырдай итеп тасвирлауга нигезләнә»сә (8, 174), «легенда сюжеты күбрәк Библия, Коръән фантастикасына корылган» (6, 14).

«Яшь йөрәкләр» романында автор Ярми карт авызыннан аның бабаларының берсе – Хозайдәд турындагы дини легенданы сөйләтә: «Хозайдәд бик дини кеше булган. Бервакыт аның хатыны балага авырып, җирдән яңа гына өзеп алынган яңа җир җиләге тели башлаган. Ә бу хәл үзе кышкы чилләдә, чатлама суык заманда булган.

Ни эшләргә? Мондый вакытта яңа җир җиләген кайдан табарга? Хозайдәд хатынын үзенә чакырган да:

– Серне кешегә әйтмәзсеңме? – дигән.

Хатын әйтмәскә сүз биргән.

– Ярый, бар, әйтмәс булсаң, тәрилкә ал да базга төш. Шунда кирәгеңне табарсың! – дип әмер биргән.

Хатын төшә. Ни күрсен: базда үләннәр, чәчәкләр үскән, шулар арасында җәй көне июль аенда гына була торган эре җиләкләр сабакларын бөгеп утыралар. Үзе бик күп һәм бар да эре, бар да кып-кызыл булып пешкәннәр. Хатын кирәген ала да, ашап теләген тутыра.

Ләкин бу серне саклый алмый, берәүгә сөйли. Шуның җәзасыннан, туган ир баласы тәүфикъсыз булып, гомер буена эчеп, ахырда кабак алдында вафат булган» (2, 27–28).

Әлеге өзек тулаем татар легендалары өчен традицион мотивны – изге кешеләрнең, хатыннары соравы буенча, кышын баздан яңа пешкән җиләк җыеп алып менүләрен кабатлый. Шушы мотивка нигезләнгән «Яхъя хәзрәт», «Уразбәхи», «Ибраһим бабай җиләге» кебек легендалар татарлар яшәгән төрле төбәкләрдә киң таралганнар (6, 257–259). Аларның һәммәсендә дә Коръәннең илаһи көчен дәлилләү чагылыш таба. Догадан соң базда бакча үсеп чыгуы – дини могҗиза. Хатыннар тарафыннан сернең кешегә сөйләнелүе фаҗигагә китерә: изгеләр үлемгә дучар булалар, ягъни биредә борынгы мәҗүси җәмгыять өчен типик булган сүз тыюы (табу сүз) күренеше мөселман җирлегенә күчерелә һәм яңа мәгънә, яңа эчтәлек ала. Галимҗан Ибраһимов изге тыюны бозган өчен җәза алу мотивын реаль тормышка тагын да якынайта: серне чишкән хатынның улы нәкъ XIX гасыр чынбарлыгындагыча эчкечелектән үлә, ә Хозайдәднең киләчәк язмышы ачылмый. Шулай итеп, әлеге легендада борынгы мифологик ышануларның Ислам дине һәм реаль чынбарлык күренешләре белән кушылып, катлаулы синтез хасил итүен күрергә мөмкин.

Әдипнең 1911 елда язылган «Диңгездә» хикәясендә алып-балык турында легенда китерелә. Ул хаҗга баручы Нурый бабай тарафыннан сөйләнелә: «Бер чакны Гаптулла хаҗи хаҗга барырга җыена. Бара бу. Кире кайтыр юлда боларга диңгездә бик зур утрау очрый. Диңгезчеләр аңа төшәләр, җир өстеннән җиде көн буе йөриләр. Берчакны болар ашарга пешерер өчен учак яккач, җир чайкала, үз урыныннан кузгалып китә. Баксаң, бу йоклап уянган бик зур балык булып чыга. Ул диңгезчеләрнең корабларын әсирлеккә ала һәм алардан корбан сорый. Корбан бирер өчен диңгезчеләр шобага тота. Шобага Гаптулла хаҗига чыга. Аны зур балыкка ыргыталар. Шуннан соң гына балык корабны азат итә» (1, 21).

Әлеге легенданың Көнчыгышның урта гасырларда иҗат ителгән мәшһүр кысалы кыйссасы «Мең дә бер кичә»дәге «Синдбад Дәрьяви» (3, 312–331) хикәяте тәэсирендә туганлыгын ачыклау авыр түгел. Бу хикәяттә дә диңгезчеләр, ял итәр өчен, утрау дип уйлап, йоклаган алып–балык өстенә тукталалар һәм үлемнән чак котылалар. Күрәсең, бу сюжет безгә Ислам динен таратучы гарәп миссионерлары аша кергәндер. Легенда тукымасында дин юлыннан китүче Гаптулла хаҗи образы очравы да әлеге фикернең дөреслеген дәлилләп тора.

Башкортстанда яшәүче татарлар арасында алыпбалыклар турындагы легендалар шулай ук очрый. Ләкин аларда дини мотивлар бөтенләй юк. Мәсәлән, Илеш районы Карабаш авылында безнең тарафтан язып алынган «Иш тавы» легендасының беренче вариантында аның барлыкка килүе гаять зур, ләкин аңгыра балыкның ике тау арасына кысылып калып, катып, үзе дә тауга әверелүе белән аңлатыла (9, 197–198). Бу инде «Диңгездә» хикәясендәге легендадан күпкә борынгырак, тамырлары белән алыпларга бәйле ышануларга килеп тоташучы мотив.

Риваятьләргә килгәндә, алар бөек әдибебез иҗатында легендалардан зуррак урын тота. Монда авыл тарихлары да, җир-су атамаларына бәйле топонимик риваятьләр дә, күренекле шәхесләр хакында, җырбәетләрнең тууы турында бәян иткән әсәрләр дә очрый. Әдәбият галиме С. Г. Сафуанов билгеләвенчә, «язучы үзенең әсәрләренә еш кына үз төбәгендәге ялан, тау, елга, күл, авыл исемнәрен (Исәнбикә болыны, Яманташ тавы, Үзән елгасы, Кондызлы күл, Таштамак, Карамалы авыллары һ. б.) нәкъ булганынча, үз атамалары белән үк кертеп-кертеп җибәрә, кайберләре әсәрдән-әсәргә күчә. Ә еш кына бу атамаларны бераз үзгәртеп тә куллана, әмма соңгылары да күп вакыт танылып тора. Шулар бөтенесе Агыйдел буйларының, Авыргазы якларының, гомумән Башкортстанның җанлы образын тудыралар» (5, 193).

«Яшь йөрәкләр» туган ягыбыз тарихына бәйле риваятьләргә аеруча бай. Мәсәлән, үзәк герой Зыяның туган төяге булган Кара авылы хакында хикәяләгәндә, автор аның исеменең килеп чыгышын да халык риваятенә нигезләнеп аңлатып үтә. Бу авылга башлап Бөре ягыннан күчеп килгән Әлемгол исемле карт нигез сала. Ул чакта авыл тирәсен балта-пычкы күрмәгән кара урманнар чолгап алган була, шуңа күрә дә авыл Кара Урман дип атала башлый (2, 26–27).

Шушы ук әсәрдә «Моңлы Гайшә көе» һәм «Шәкерт солдат бәет»ләренең барлыкка килү тарихларын тасвирлаган ике тарихи-көнкүреш риваять тә китерелә

(2, 167–169, 198–199). Алардагы вакыйгалар тарихи җирлеккә нигезләнә, ягъни риваятьләрдә сурәтләнгән шәхесләрнең икесе дә реаль, Госман исемле персонажның авылдашлары итеп күрсәтелә.

1923 елда тәмамланган «Казакъ кызы» романына әдип татар, башкорт, казакъ халыкларының уртак мәгърифәтче шагыйре Акмулла турындагы тарихи риваятьне алып керә. Ул казакъ бәге Сарсымбайның татар шәкерте Габдулла Әлказаныйны мәсхәрәләп: «Үләнле җирдә мал симерер, үлекле җирдә мулла симерер», – дип әйтүенә җавап буларак яңгырый. Шәкерт Акмулла турындагы әлеге риваятьне бәкнең хәтеренә төшерә һәм бөек мәгърифәтче сүзләре белән: «Үләнле җирдә мал симерер, үлекле җирдә мулла симерер, казакъның караңгы даласын муллалар килеп агартмаса, синең кебек наданнарның башын бет кимерер», – дип җавап кайтара (2, 402–403).

Риваятьләр белән бергә, Галимҗан Ибраһимов иҗатында әкияти характерда булмаган халык прозасының башка жанрларына караган әсәрләр дә очрый. Мәсәлән, «Татар хатыны ниләр күрми» повестендагы Нурый карт нәселенә – «саескан», ә Солтан карт нәселенә «кәҗә» кушаматы тагылу тарихларын без сөйләк жанрына кертеп тикшерә алабыз. Сөйләкләрнең жанр табигатен, аның халык прозасындагы урынын, төп сыйфатларын ачыклау әлегә кадәр татар фольклористика фәнендә хәл ителмәгән мәсьәләләрнең берсе булып кала. Безнең фикеребезчә, «сөйләк үзенең жанр үзенчәлекләре буенча риваять һәм мәзәк арасында тора. Риваятьләр кебек үк сөйләкләргә дә тарихилык хас, ягъни алар чыннан да тормышта булган вакыйга турында сөйлиләр. Ләкин риваятьләр, гадәттә, җитди характерда булып, халык тормышындагы әһәмиятле вакыйгаларны бәян итәләр. Сөйләкләрдә исә җитдилек бик аз. Мәзәкләргә якынлык ике жанрның да үткен сатира, яисә нечкә юмор белән сугарылуында күренә. Әмма мәзәкләргә тарихилык хас түгел» (10, 30). Шушы үзенчәлекләр, безнең карашка, сөйләкләрне мөстәкыйль жанр итеп санап, югарыда атап үтелгән кушамат тагылу тарихларын да сөйләкләр составында тикшерергә мөмкинлек бирә.

Нурый картның бабасы Сөләйман бик ярлы гаиләдә туа. Бервакыт бер кием дә рәтли алмагач, анасы аңа җыен калдыкларны ямап, бишмәт ясый. Моның арты кара, ике җиңе ак, күкрәге кара, култык асларына да ак туры килә. Сөләйман бу киемне урамга киеп чыккач, малайлар: «Ала саескан, ала саескан!» – дип мыскыллап көләргә тотыналар. Тора-бара «ала» сүзе төшеп кала да, «саескан» исеме малайга кушамат булып ябышып кала. Зурайгач, бай крестьян булгач та төшми. Сөләйманнан нәсел буенча Нурыйларга һәм аның гаиләсенә күчә (1, 156–158).

Солтан карт гаиләсенә «кәҗә» кушаматы тагылуы да кызык тарихлы. «Сабира карчыкның атасы Солтан заманында сунарчы булган, диләр. Бервакыт үзенең бер дус адәмендә әче балны эчеп, кызыбрак чыккан да, зур мөгезле ак кәҗәне болан дип, аты белән куып җиткән, диләр. Авылдагы дошман байлары, җәй, кыш мәптектә ятучы бер аксак хәлфәгә тутырган тавык, илле тиен акча биреп, зур бәет чыгарттылар. Бу бәетне өйдән-өйгә кереп, сәдака җыеп йөрүче бер сукыр хәерчегә ятлаттылар. Халыкка бик кызык тоелды... Шуннан Солтанга кәҗә Солтан дип ат куштылар, бу кушамат балаларына да күчте, нәселенә дә җәелде» (1, 158).

Белүебезчә, кешегә кушамат бирү борыннан, ырукабилә чорларыннан ук килә. Дөрес, ул вакытта кушамат алмаш исем буларак чыгыш ясап, практик функция башкарган – кешене явыз рухлардан саклаган. Күренекле фольклорчы Х. Ш. Мәхмүтов сүзләре белән әйтсәк, «кеше алмаш исемнәр кулланып, сүзнең тылсым көченнән файдаланырга, үзе өчен хәвефле затны сүз ярдәмендә зарарсызландырырга, буйсындырырга, якшы якка үзгәртергә омтылган» (7, 8). Ягъни, явыз рухлар җибәрәсе зыян кешегә түгел, ә атамасы шушы кешенең кушаматы булып киткән тере затка, предметка, яки күренешкә табан юл алган. Җәмгыять үсеше белән, яшерен тел элекке әһәмиятен җуйган, кушамат үзенең практик функцияләрен югалтып, сатирик эчтәлек алган. Бөек әдибебез геройларының характерын ачар өчен, кушаматларны бик оста файдалана. Сабира да атасы кебек үк киребеткән, усал кеше. Халык теле белән әйткәндә, «кәҗәдәй кире». Улы Закир да аңардан калышмый. Менә шулар килен булып төшкән Гөлбануны һәлакәткә китерә дә инде. Кыскасы, кушаматлар повестьта геройның характерын бер сүз белән ачучы мөһим художестволы деталь вазифасын үтиләр.

Шулай итеп, Галимҗан Ибраһимов үз иҗатында татар халкының меңьеллык әдәби һәм тамырлары белән тәүтормыш чорларына ук барып тоташкан эпик фольклор традицияләренең табигый үрелүенә, синтезына ирешә. Аның әсәрләренең бүгенге көндә дә халык тарафыннан яратып укылуы, сәнгати кыйммәтләрен югалтмавы – аларның халык моңы белән сугарылу нәтиҗәседер мөгаен.

ӘДӘБИЯТ


1. Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда / Г. Ибраһимов; беренче томны төзүче Г. К. Камалиев; текстларны, искәрмәләр һәм аңлатмаларны Р. Р. Гайнанов әзерләде. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. – 1 т.: Хикәяләр (1907–1929). – 510 б.

2. Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда / Г. Ибраһимов; икенче томны төзүчеләр: А. Ш. Шамов, Х. Я. Гобәйдуллин; текстларны, искәрмәләр һәм аңлатмаларны хәзерләүчеләр: А. Ш. Шамов, Р. Р. Гайнанов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. – 2 т.: «Яшь йөрәкләр», «Казакъ кызы». – 477 б.

3. Книга тысячи и одной ночи. В 8-ми томах. Т. V / Перевод с арабского М. А. Салье.– М.: ГИХЛ, 1959. – 470 с.

4. Садекова А. Х. Фольклор в эстетике Галимджана Ибрагимова / А. Х. Садекова; науч. ред. Ф. И. Урманчеев. – Казань, 1995.– 104 с.

5. Сафуанов С. Г. Рухи күперләр / С. Г. Сафуанов. – Уфа: Китап, 2006. – 376 б.

6. Татар халык иҗаты. Риваятьләр һәм легендалар / Томны төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләрне язучы С. М. Гыйләҗетдинов; фәнни редакторы Х. Ш. Мәхмүтов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. – 368 б.

7. Татар халык иҗаты. Табышмаклар / Томны төзүче, кереш мәкалә язучы, искәрмәләр хәзерләүче Х. Ш. Мәхмүтов; фәнни редакторы Х. Курбатов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. – 272 б.

8. Урманче Ф. И. Татар халык иҗаты / Ф. И. Урманче; фәнни редакторы Х. Ш. Мәхмүтов. – Казан: Мәгариф, 2005. –384 б.

9. Фазлетдинов И. К. Башкортстан татарларының топонимик легендаларында алпамшалар мотивы / И. К. Фазлетдинов // Татар теле һәм әдәбиятының актуаль мәсьәләләре: фәнни-методик мәкаләләр җыентыгы.– II кисәк. – Стәрлетамак, 2005. – Б. 193–200.

10. Фазлетдинов И.К. Сөйләдем сөйләк... / И. К. Фазлетдинов // Тулпар. – 1998. – № 2. – Б. 30.

# КОЛ ГАЛИ, ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ, ШӘРӘФ МӨДӘРРИС ИҖАТЛАРЫНДА АКЫЛ ҺӘМ ХИС КУЛЬТЫНЫҢ ЧАГЫЛЫШ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

*Р. К. Ганиева, Р. И. Сәйфуллина (Казан)*

В статье на примере поэмы Кул Гали «Киссаи Йусуф», романа Галимджана Ибрагимова «Молодые сердца», поэмы Шарафа Мударриса «Бессмертие» прослеживается эволюция мотивов двух видов познания мира – разумом и чувствами. Подчеркивается, что в эпоху средневековья проблема разума-чувств освещалась в контексте философии мусульманского неоплатонизма, а в Новое время в философско-эстетическом контексте руссоизма и марксизма.

Бик борынгы заманнардан ук галимнәр дөньяны танып белүнең акыл һәм хисләр ярдәмендә ике баскычы булуына игътибар иткәннәр. Безнең эрага кадәр мондый карашлар грекларның бөек акыл ияләре Платон (Әфләтүн) һәм Аристотель (Арасту) фәлсәфи хезмәтләрендә чагылыш тапкан. Платон (б. э. к. 427–347) галәмне һәм яшәешне кабул итүдә җан, калеб, хисләр беренче урында тора дип исәпләгән. Аристотель исә (б. э. к. 384–322) дөньяны танып белүдә төп корал – акыл дигән фикерне яклаган. Шактый гасырлар үткәч (безнең эраның III–VI гасырларында) борынгы грекларның Платон белән Аристотель хезмәтләренә таянып Плотин һәм аның укытучысы Аммоний эшкәрткән неоплатонизм (яңа Платон) философиясе мәйданга чыга. Мәҗүсилектән Бер Аллалыкка таба хәрәкәт иткән грек фәлсәфәсе тарафдарлары яшәешне Берлектән (Единое) нурлар рәвешендә таралган Акыл – Җан – Матдә баскычлары рәвешендә аңлаталар. VII гасыр башында кризис кичерүче, тарих сәхнәсеннән төшеп килүче грек мәдәнияте, фәне, фәлсәфәсе казанышлары «мөселман неоплатонизмы» дигән исем белән ислам дөньясына – Коръәнгә дә үтеп керә һәм ул гарәп, фарсы, төрки әдәбиятлардагы әһәмиятле фәлсәфи-этик һәм әдәби-эстетик төшенчәләрнең берсенә әверелә.

Грек-юнаннарның нурлар чәчү рәвешендә галәмне барлыкка китергән Берлек турындагы карашлары ислам динендә «Аллаһы бар һәм ул Бердәнбер» (Лә иләһә илләллаһ), ягъни әт-Тәүхид фәлсәфәсе буларак иждади үзләштерелә. Шуңа күрә дә мөселман фәлсәфәсендә галәм, андагы барлык җисемнәр яктылык һәм куелык дәрәҗәләре төрле булган Аллаһы Тәгалә нурларыннан барлыкка килгән, диелә. Илаһи нурлар ярдәмендә ул башта олы галәм акылын, ә аннан сибелеп чыккан кечкенә нур кисәкчәләре ярдәмендә җир кешеләренең акылын хасил итә. Шуңа күрә хәдисләрдә дә «Аллаһы Тәгалә беренчел итеп акылны яраткан» диелә (Әүвәлү мә халәка Аллаһу әл-акла). Үз чиратында акыл нурларыннан җан, калеб нурлары пәйда була, ә алардан исә матдә (кешеләрдә исә бу – тән) туа (2, 14–23).

Әт-Тәүхид фәлсәфәсенә таянып үскән мөселман әдәбиятларының һәр өч юнәлешендә (дини-әхлакый, суфыйчылык, дөньяви-Яңарыш) галәмне, яшәешне, шул исәптән мәхәббәтне дә Алла – Акыл – Җан – Матдә (тән) кебек эманацион баскычлар һәм нур фәлсәфәсе рәвешендә аңлату озак гасырлар дәвам итә. Мондый карашлар Урта гасыр татар Ренессанс әдәбиятының йөзек кашы булган Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» романтик поэмасында да чагылыш таба.

Кол Гали дастанының төп каһарманнары – Йосыф белән Зөләйха. Әсәрнең буеннан-буена гүзәл Йосыф образы акыл даһие итеп сурәтләнә. Шуңа күрә дә аңа «йөзе нурлы, хак динле, акыллы» дигән сыйфатлар бирелә. Фәнни хезмәтләрдә Йосыфның акыл куәте турында түбәндәге сүзләр языла: «Ум – главный критерий и при характеристике его красоты. Разум Йусуфа, обогащенный знаниями о мире, справедливо управляет обществом, служит благу людей» (1, 96). Йосыфның камил акылына юлдаш булып гыйлем бирелә; алар ярдәмендә ул гадел шәхес, гадел идарәче, гадел патша булып җитешә. Бу фикер «Кыйссаи Йосыф» поэмасының буеннан-буена ассызыклана:

> Гакълы камил, хикмәт гыйльмен яхшы белер,
> Дәгъвачылар дәгъва белән аңа килер,
> Бай-ярлыга дөрес, гадел хөкем кылыр, –
> Берәүгә дә җәбер-җәфа кылмас имди (7, 203).

Гүзәллек, акыл, сабырлык һәм гаделлек даһие Йосыф, нинди генә авырлыкларга дучар булмасын, яшәешнең төп кыйбласы итеп акылны саный һәм шуның нәтиҗәсендә ул барлык авырлыкларны җиңеп чыга.

Поэманың икенче үзәк каһарманы – хисләр өермәсендә яшәүче Зөләйха. Төшләрендә Йосыфка гашыйк булган Зөләйха җан тынычлыгын җуя, йокысыз кала, ашау-эчүдән баш тарта, бертуктаусыз елый, һуштан яза. Аның гашыйклык дәрәҗәсен билгеләүдә Йосыфның физик һәм рухи матурлыгы да бик зур роль уйный. Табиблар да гашыйк Зөләйханы мәхәббәт чиреннән дәвалый алмыйлар. Зөләйханың мәхәббәте борынгы грек һәм шәрекъ әдәбиятларында канун рәвешен алган эстетик карашларга нигезләнгән: башта ул Йосыфка гашыйклыктан авыруга сабыша, ә аннан юләрләнү дәрәҗәсенә җитә һәм мәхәббәт мәҗнүненә әйләнә (1, 101).

Поэманың азагында зур сынаулар аша үткән пәйгамбәр Йосыф һәм ислам динен кабул иткән мәҗүси Зөләйханың мәхәббәт тарихы Аллаһы Тәгаләнең әмере белән уңай чишелеш таба. Гүзәл Йосыфның үткер акылы Зөләйханың ялкынлы мәхәббәт хисләре белән берләшә, алар гаилә корып, балалар үстереп, бәхетле гомер кичерә башлыйлар.

Нәтиҗә ясасак, Шәрекъ һәм Гареб әдәбият белемендәге төшенчәләр ярдәмендә Кол Гали поэмасында Йосыфның акылы, аның сабырлыгы (бу соңгысы грекларның стоицизм фәлсәфәсенең чагылышы) һәм Зөләйханың ләззәтле җан һәм тән мәхәббәтенә омтылышы (гедонизмы) бергә килеп очраша. Ахыр чиктә каһарманнарның мәхәббәте, әт-Тәүхид фәлсәфәсенә таянып, Илаһият – Акыл – Җан – Тән гармониясе рәвешендә мөселман неоплатонизмы эстетикасындагыча тормышка ашырыла.

XX гасыр башында да татар әдәбиятында неоплатонизм эстетикасы традицияләре саклануын, башка төр идеологияләр белән үрелеп, аларга ярашып яшәвен дәвам итә. Моңа дәлил – Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» психологик романындагы Зыя – Мәрьям, Сабир – Камилә кебек каһарманнарның сәнгатьчә гәүдәләнеше. Бу романтик парларның хисси кичерешләре, акыл кануннары буенча яшәргә омтылулары

төрле нәтиҗәләргә китерә. Мәхәббәтне илаһият бүләге, матурлык һәм илһам чыганагы итеп санаган, шәхес азатлыгы, милли идеаллар белән бәйләп караган Зыя – Мәрьям мәхәббәте драматик кичерешләр, фаҗигалэр белән тәмамлана. Зыя белән Мәрьям образларында неоплатонизм эстетикасының чагылышын тикшергән Р. К. Ганиева болай дип яза: «Столкновение божественно-платонической любви Марьям и Зыи с “низкой телесной” любовью фахриподобных приводит к трагическому финалу... Духовная драма, вызванная крушением идеалов “божественной любви” к Марьям и служения музыкальным талантом своему народу, уносит в могилу и Зыю. Так, романтические герои гибнут в разладе и с самим собой, и в разладе с обществом» (5, 64).

«Яшь йөрәкләр» романындагы икенче романтик пар – Сабир белән Камилә. Аларның да мәхәббәт тарихы, Кол Гали дастанындагы кебек, неоплатонизм эстетикасындагыча акыл белән хиснең үзара мөнәсәбәтләре яктылыгында бирелгән, әмма дөньяга башка төрле карашлар белән дә үрелгән.

Зыяның бертуган абыйсы Сабир хисси мәхәббәт тарафдары түгел. Ялкынлы хиссият аның өчен чит нәрсә. Автор язганча, «ул гакыл, салкын мөхәкамә колы, шуларның күргәзүенчә бара» (6, 267). Авылдашлары да Сабирны «кирәгеннән артык акыллы, сабыр, ниндидер эчке куәткә ия» кеше итеп саныйлар. «Ул юк-барга илтифат итми, сантиментальлеккә бирелми; нәрсә уйлый, шуны яшерүсез һәм куркусыз әйтә» (6, 261). Сабир үзенең һәм физик, һәм акыл куәте белән башкалардан аерылып тора; ул гадел фикер йөртә, мәдрәсәдәге тискәре күренешләрне дә курыкмыйча тәнкыйть итә; шуңа күрә хәлфәләр дә аннан шикләнә, аңа хөрмәт белән карый. Аңлашылса кирәк, яңа тарихи шартларда, заманнар алмашкан чорда мәйданга чыккан, акыл культы символы буларак гәүдәләнгән Сабир образы баштанаяк руссочыл карашлар белән үрелеп бирелгән.

Жан-Жак Руссо (1712–1778) – XVIII гасырның атаклы француз мәгърифәтчесе, язучысы, философы, композиторы һәм педагогы. Аның җәмгыять, яшәеш, сәнгать һәм әдәбият турындагы карашлары бөтен дөнья мәдәниятенә, шул исәптән татар әдәбиятына да, зур йогынты ясый. Аның тәэсиреннән Г. Ибраһимов та читтә калмаган. Бу мәсьәләне махсус тикшергән Р. Минһаҗева фикеренчә, руссочыл карашларның үзэген табигать һәм җәмгыять, мәдәни шәһәр һәм авыл антиномиясе тәшкил итә (9). Г. Ибраһимовның байтак кына әсәрләрендә бу антиномия геройларның яшәү фәлсәфәсенә һәм эчке кичерешләренә бәйле рәвештә чагылыш таба.

Сабир XX гасыр башы татар дөньясында шәхес азатлыгын кыскан феодаль-патриархаль тәртипләр басымыннан да, буржуаз җәмгыять өчен хас кешелексез мөнәсәбәтләрдән дә риза түгел. Мәдрәсәдә тирән белем алып, ахунлык һәм мөдәррислек дәрәҗәсенә күтәрелү мөмкинлеге булса да, күпмедер вакыт мәктәп-мәдрәсәләрдә мөдирлек вазифасын башкарса да, байларга ялланып, контора вә сату эшләре белән шөгыльләнсә дә, ике ел дәвамында ниндидер фетнәчел яшерен инкыйлаби эшләргә катнашса да, Сабир катгый рәвештә шәһәрдә мәдәни тормыш белән яшәүдән баш тарта. Француз мәгърифәтчесе Жан-Жак Руссо тәэсирендә аның хәяты да, дөньяга карашлары да зур үзгәрешләр кичерә: цивилизация җимешләрен, мәдәни кыйммәтләрне кабул итми; шәхеснең, иҗтимагый продукт булудан бигрәк, табигать баласы булуына, табигыйлек кануннары буенча яшәргә тиешлегенә басым ясый.

Әсәрдә язылганча, ул татарларга, җәдидчә уку кирәк, рәсми мәктәпләр кирәк, милли тәрәккыять кирәк, дип тә сөйләми. Сабир уенча, мәдәни кыйммәтләр даирәсендә яшәү шәхеснең азатлыкка булган омтылышын буа, кешегә табигать бүләк иткән кануннар буенча яшәргә мөмкинлек бирми, чөнки ул «кемнәргәдер баш иярга дә, түбәнчелекләр күтәрергә дә, һәр адым саен сатылырга да, ике йөзле шәхес булырга да теләми» (6, 268). «Шуңа күрә дә ул, – ди автор, – мәдәни тормыштан, каланың баштанаяк зиннәт вә мода эченә күмелгән ялтыравыклы хәятыннан гомергә кул селкеп, ничек булса да, үз табигатенә ягышлы бер дөнья табарга тәбган мәҗбүрият хис итеп, моның өчен дә тын, караңгы авылга югалырга карар бирде» (6, 269).

Сабир – чын мәгънәсендә руссочыл образ. Ул бөтен барлыгы белән шәһәр мәдәниятен күрә алмый. Энесе Зыяның «Шәһәрнең шул тәзиянаты *(бизәге),* шул шау-шулы театрлары, шул матур музыкалы опералары, концертлары, шул бай китапханәләре – кыскасы, мәдәнияте сине тагы тартыр, син тагы боларны сагына башларсың ... яисә гомер буена шул «тын, караңгы авыл»ыңнан бизеп, мужиклыгыңа нәфрәт чигеп, газапланырга тугры килер» (6, 271), дигән сүзләренә Сабир түбәндәге сүзләр белән җавап бирә: «... Мәдәниятеңездән дә, театр вә музыкаларыңыздан да туйдым... Гыйлем хәзинәсе булган көтебханәләреңезгә дә ихтирамым бик аз; мәдәниятнең бирдеке башка бик күп “сәгадәтләре”нең дә һичберен сагынырмын дип уйлый алмыйм. Барыннан да туйдым, барыннан биздем» (6, 271).

Заманында Сабирның бу сүзләре кискен тәнкыйть ителде. Ул рухи-мәдәни яшәешне кабул итмәгән, кулак булырга омтылган, «салкын акыл, исәп-хисап белән көн итүче» образ итеп каралды. Сабирны кулаклыкта гаепләү совет чоры тәнкыйтьчеләренә совет чоры сәясәте һәм большевистик идеология ясаган басым нәтиҗәсе иде. Сабир кулак кебек бай булырга да омтылмый, зур бәягә иген сатып, мужикларны таларга, капитал тупларга да җыенмый. Шуңа күрә дә ул: «Бәлки бай булмам, ләкин ачка да үлмәм, дим. Мин ул тормышны табигатем белән яратам. Дөрест, минем тормышым түбән, тупас һәм простой булыр. Тирә-ягымны да тышлары бик артык ялтырамый торган чабаталы адәмнәр – мужиклар чорнар. Ләкин шулар илә бәрабәр минем үз малым, үз дөньям булыр», – ди (6, 271).

Сабир үзенә хатынлыкка кәләшне дә руссочыл карашлар күзлегеннән чыгып сайлый. Руссо – белемгә каршы, аныңча, китаплар уку – вакыт әрәм итү генә, ул кешенең тумыштан килгән табигатен боза. Сабир үзенең булачак хатыны итеп «әлифне таяк дип, ваүны чукмар дип белмәгән, әмма табигате белән бик тере, артык җанлы иптәш»не күрергә тели. Аның өчен кызның белемле булуы кирәкле сыйфат түгел, аның өчен иң мөһиме – кызның табигате. «Ул тере булсын, артык җанлы булсын, мин үзем дә авыр, басынкы кеше. Хатыным да шулай булса, безне җир күтәрә алмас... Шул сыйфатлары табылып, укымаган булса – минем өчен ул бигрәк мөнасиб. Ул зат укымаган икән, димәк яратылышы, табигате, табигый нәфасәтләре үз хәленчә, бөтен көенчә калган; тышкы тәэсирләр белән бозылмаган

димәктер», – дип фикер йөртә ул. Камилә – нәкъ ул күрергә теләгән сыйфатларга ия хатын-кыз булып чыга, ул Сабирның йортына яңа бер сулыш алып керә, аның тормышын җанландырып җибәрә, гаиләгә ямь өсти. Сабир туган авылына кайтып, крестьян-мужик кебек җир сөреп, мәдәният дигән төшенчәнең нәрсә икәнен дә белмәгән, бәдәви, ягъни күчмә гарәпләр кызын хәтерләткән Камиләгә өйләнеп, табигый тормыш белән яшәүне өстен күрә.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә кирәк: Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романында акыл һәм хиснең үзара мөнәсәбәте табигать һәм җәмгыять, мәдәни шәһәр һәм тышкы тәэсирләр йогынтысында үзгәрмәгән, табигый асылын югалтмаган, физик хезмәтне яшәешнең нигезе дип санаган, әхлакый бозыклыклардан азат булган гади крестьян тормышы антиномиясе тәшкил итә. Бу антиномия, Жан-Жак Руссо фәлсәфи-эстетик карашларының йогынтысы буларак, язучының байтак әсәрләрендә чагылыш таба.

Татар совет әдәбиятында акыл һәм хис мәсьәләләрен үзәккә куйган әсәрләр очрап тора. Шундыйларның берсе – шагыйрь Шәрәф Мөдәрриснең (1919–1963) «Үлемсезлек» поэмасы. Әсәрдә Бөек Ватан сугышы елларында Мәскәү тирәсендә барган канлы бәрелешләрдә Казан полкының ике сугышчысы, байрак сакчылары – олы яшьтәге Захар Бакланов белән татар егете Тимербулат Рахмановның тиңдәшсез батырлыгы сурәтләнә. Поэма, башыннан азагына кадәр, фәлсәфи фикер коруга нигезләнгән. Кereштә үк автор кешелек тарихына, мәдәниятенә мөрәҗәгать итеп, «нәрсә ул үлемсезлек?» дигән сорауга җавап эзли. Аныңча, үлемсезлек ул – бөек романтик идеал, сихри нур, күктәге йолдыз; үлемсезлекнең чыганагы һәм нигезе – Ватанга, туган җиргә, горур һәм батыр татар халкына, көзге төсле Кабан күленә, Ослан тауларына, туган телгә, Тукайның кабер ташына сөю-ярату хисләрен белдерү. Кол Гали һәм Г. Ибраһимовтан аермалы буларак, Ш. Мөдәррис мәхәббәт төшенчәсенә универсаль эчтәлек сала. Бөек Ватан сугышында совет солдатының һәйкәлләрдә мәңгеләштерерлек каһарманлык күрсәтүенең сәбәптамырлары кайда? дигән сорауга ул рус халкының акыл куәтендә һәм татар егетләренең «ашкын хисле йөрәк»ләрендә дип җавап бирә:

Булат – ашкын, пафосларга буйсынучан,
Захар – акрын һәм хискә дә тонык сыман.
Берсе булса чаткыланып тузгылучан,
Берсе чыдам, ут-су үткән корыч сыман... (10, 206).

Поэманың һәр тугыз җыр-бүлегендә Захар образы акыллы, сабыр, тыныч канлы, көчле рухлы, кырыс җанлы батыр итеп сурәтләнә. Ул сугыш кырында «айнык акыл, көчле хәйлә» белән эш итү тарафдары. Аныңча, дошман белән бәрелеш-тартышларда ярсып китеп, кирәксезгә гомер белән уйнарга ярамый:

Алар шундый: «Үлем, – диләр, – җиңел нәрсә,
Бирмә ләкин тормышыңны файдасызга!
Өйрән шуңа – сугышларда җиңелмәскә,
“Юк, үлмәм!” дип, соң чиктә дә даулашырга»
(10, 197).

Татар егете Тимербулат Захарның капма каршысы: ул ашкын хисле йөрәк белән эш итә, «батырлыкны чәчеп бара йөрәгеннән». Мондый татар солдатлары – Тимербулатлар турында автор:

Бар тагын да лачын җанлы фидакарьләр,
Андыйларны йөрәк кертә ялкыннарга;
Алар шашкын, уттан-судан бихәбәрләр,
Ярсый-ярсый һәҗүмнәргә ашкынганда (10, 199).

Булатның бөтен хис-кичерешләре ярсу, ашкын фидакарьлеккә корылган. Аның үлемгә мөнәсәбәте дә рус баһадиры Захарныкыннан аерыла:

Алар шундый: «Үлем, – диләр, – нәрсә безгә!
Батырларга чүп әйбер ул һәр эш кебек» (10, 199).

Әсәрдә Тимербулат Рахманов образы даими рәвештә «ашкын», «лачын» эпитетлары белән сыйфатлана. Бу эпитетлар Шәрәф Мөдәррис поэмасына М. Горькийның «Лачын турындагы җыр»ыннан («Песня о Соколе») үтеп кергән. Рус язучысының бу әсәреннән алынган цитата, реминисценция, аллюзияләр татар шагыйренең башка шигырь һәм поэмаларында да очрый. Мәсәлән, «Тупчы Ваһап» поэмасы да М. Горькийдан алынган «Батырларның шашкынлыгына җырлыйбыз без җырны» дигән эпиграф белән ачылып китә.

Шәрәф Мөдәррис Захар Баклановның сугыш чынбарлыгын акыл белән тануын да, татар егете Тимербулат Рахмановның хисси «ашкын батырлыгы»н да югары бәяли, аның хисчәнлеген дә «зирәклек» («мудрость»)төшенчәсе белән дә бәйләп аңлата («Безумство храбрых – вот мудрость жизни»).

Бөек Ватан сугышында совет халкының фашистларны җиңеп чыгуын Шәрәф Мөдәррис Захар кебек акыллы рус солдатларының, батыр йөрәкле, хисчән Тимербулат кебек татар егетләренең бердәмлеге, дуслыгы, совет патриотизмы нәтиҗәсе итеп аңлата:

Әкияттәге ике батыр кебек, – диләр, –
Бергәлектә көчле дә сез, камил дә сез!

Кол Гали, Г. Ибраһимов, Ш. Мөдәррис иҗатларындагы акыл һәм хис культының сәнгатьчә ничек гәүдәләнешенә күзәтү ясаганда, аларның һәр чорда яңа эчтәлек алуы һәм өр-яңа дөньяга карашлар белән үрелеп бирелүе күзәтелде. Борынгы греклар әйткәнчә, галәмне, яшәешне танып белүдә акыл һәм хис кебек төшенчәләрнең дә үсеш-үзгәреш кичереп торуы ачыкланды.

ӘДӘБИЯТ

1. Ганиева Р. К. Разум и любовь // Ганиева Р. К. Восточный ренессанс и поэт Кул Гали. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1988. – С. 95–108.

2. Ганиева Р. К. Философско-эстетические основы тюркских литератур Средневековья // Ганиева. Р. К. Татарская литература. Традиции, взаимосвязи.– Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. – С. 14–23.

3. Ганиева Р. К. «Тәгаллемдә – сәгадәт» хикәясендә акыл һәм гыйлем культы // Ганиева Р. К. Татар әдәбияты. Традицияләр, бәйланышлар. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 2002. – Б. 156–163.

4. Ганиева Р. К. Восточный ренессанс и его традиции в тюркских литературах: автореф. дис. … д-ра филол. н. – Казань, 1992. – 38 с.

5. Ганиева Р. К. Платоническая концепция любви в тюркских литературах конца XIX – начала XX века // Ганиева Р. К. Татарская литература. Традиции, взаимосвязи. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. – С. 59–69.

6. Ибраһимов Г. Сайланма әсәрләр. 3 томда. I т.– Казан: Таткнигоиздат. –525 б.

7. Кол Гали. Кыйссаи Йосыф. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. – 540 б.

8. Лебедев А. В. Аристотель // Философский энциклопедический словарь. – М.: Советская энциклопедия. 1983. – С. 35–38.

9. Мингазова Р. А. Руссоистские традиции в творчестве Галимджана Ибрагимова: автореф. дис. … канд. филол. н. – Казань, 2009. – 26 с.

10. Мөдәррис Ш. Х. Үлемсезлек / Ш. Х. Мөдәррис. Дуслар күңеле: лирика, юмор-сатира, поэмалар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – Б. 195–224.
11. Спиркин А. Г. Любовь // Философский энциклопедический словарь. – М.: Советская энциклопедия, 1983. – С. 328–329.
12. Халидов А. Б. ‘илм // Ислам. Энциклопедический словарь. – М.: Наука, 1991. – С. 95.
13. Шичалин Ю. А. Платон // Философский энциклопедический словарь. – М.: Советская энциклопедия, 1983. – С. 496–498.
14. Шичалин Ю. А. Неоплатонизм // Философский энциклопедический словарь. – М.: Советская энциклопедия, 1983. – С. 427–428.

# Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ «КӨТҮЧЕЛӘР»ЕННӘН «ЧЫБЫРКЫ ФӘЛСӘФӘСЕ»НӘ КҮЧКӘНДӘ ТУГАН УЙЛАР

***Ф. Ф. Хәсәнова (Казан)***

Данная статья посвящается исследованию прозы известного писателя, одного из классиков татарской литературы Г. Ибрагимова. В статье рассматриваются актуальные проблемы народа начала XX века. Уже в предоктябрьские годы Г. Ибрагимов выразил мысль о зависимости творчества писателя от объективной действительности. В статье раскрываются особенности изображения выбранной темы на современном этапе, формы проявления лирического героя в поэзии, многообразие художественных средств в описании его внутреннего состояния в зависимости от материального положения человека, социального статуса.

*Көтүче һөнәре болай*
*Кызык ул кызыгын да...*
*Тик менә... ачу килгәли*
*Көннең озынлыгына.*
*Үзәккә үтә кайчакта*
*Чамасыз яңгырлары.*
*Төмсә күккә карый-карый,*
*Малай күп каңгырады.*

Ркаил Зәйдулла

Г. Ибраһимов (1887–1938) иҗатында совет чорында мәктәп дәреслекләренә кертелеп киленгән, әмма соңгы ике унъеллыкта җәмгыятьтә зур үзгәрешләр килеп чыгу сәбәпле онытыла төшкән «Көтүчеләр» хикәясе бар. Хикәянең язылу вакыты – 1913 ел. Бу ел, язучының иҗади яктан уңышлы булган беренче Казан чоры тәмамланып, иҗтимагый һәм эстетик карашларында борылыш күзәтелгән дәвергә күчеп барган ел буларак саналырга хаклы. 1913 ел – Г. Ибраһимов тормышында шактый мәшәкатьле ел, язучы төрмәдә дә утырып чыга; патша хөкүмәте күзәтүе астында да яшәп ала; «Аң» журналында җаваплы сәркатип вазифасын башкара; Киев, Одесса, Сухуми шәһәрләрендә яшәп, сәламәтлеген ныгыта; аннан соң килеп, 1915–1917 елларда «Галия» мәдрәсәсендә укыта. Әдәби тәнкыйть язучының әлеге революция алды елларындагы әдәби эшчәнлеген яңа сыйфат үзгәрешләре барлыкка килгән чор буларак билгеләп үтә, образлар сурәтләнешендә реалистик рухның зур урын алып торуына басым ясый (1, 575).

Хикәянең беренче башланып киткән җөмләсен һәр татар кешесе диярлек хәтерли: *«Мин түбәннән, тормышның төбеннән күтәрелдем. Атам көтүче иде...»* Хикәя яшәү рәвеше үк көтүче булган әтисе белән генә үскән малай исеменнән сөйләнелә. Аларның яшәгән җирләре, бер яктан, *«ялангач соры ташлары белән күккә күтәрелгән зур тау»* булса, икенче яктан, көне-төне шаулап утырган караңгы урманга туры килә. Әтисе көн буе көтү көтә, соң гына кайтып егыла, малай аның иртән эшкә китүен күрми дә кала. Шуңа аның төшләре өнгә охшый, өнендә булганнарын төштән аера алмый. Кыскасы, малай үзе үсә, тәрбия күрми. Әтисе Әптерәш картның күндәм, тыңлаучан, гадел, карусыз, талымсыз, эшне җиренә җиткереп башкара торган сыйфатлары улына күчәргә өлгерми. Берзаман картның чыбыркы тотар хәле калмый, карар кешесе булмагач, илгә чиратка салына, ахырдан берәүнең мал өендә, сәке астында, бозаулар арасында актык сулышын ала.

Әдәбият теориясендә «пастораль» исемле антик жанр төре бар. Бу жанрда көтүчеләрнең (шулай ук: йә игенче, йә балыкчы) авылдагы тыныч тормышлары сурәтләнә торган була. Яңарыш чорында пастораль жанрында язылган әсәрләр эпик, лирик, драма формаларында иҗат ителгән. Авылдагы тыныч тормышка дан җырлаган, көтүчелек хезмәте белән турыдан-туры бәйле шигъри формадагы әсәрләрнең «буколистик шигърият» дип аталуы да мәгълүм. Жанрның таләбе буенча буколистик шигырьдә табигать матурлыгын сурәтләү урын алырга тиеш була. Димәк, әдәбият фәне тарафыннан танылган жанр да булгач, аерым шигърияте дә билгеләнгәч, бу тема турында тикшеренү эшләрен башлап җибәрү дә хата булмас. Г. Ибраһимовның «Көтүчеләр» хикәясе безне: Хәзерге әдәбиятта көтүче хезмәте турында язарга алынучы язучы бармы икән? Булса, көтүнең үзе дә бетеп барган бер дәвердә, ул нәрсә турында язарга алыныр? Гомумән, кирәкме хәзер бу тема, актуальме? – дигән сораулар туугa этәрде.

Татар халкында көтүчелек хезмәте, гәрчә бик кирәкле эшләрнең берсе саналса да, мактаулылардан түгел. Ул тормышта да, әдәби әсәрләрдә дә материаль җитмәүчәнлек, хәерчелек, чарасызлык, ятимлек, мәҗбүрилек халәтенең нәтиҗәсен генә чагылдыра ала. Бер әсәрдә дә көтүче булып җитеш гаилә әгъзасы алынмый. Без, билгеле, бу очракта совет чорындагы колхозларның йөзләгән сыерларыннан торган көтүләрен мисалга алмыйбыз. Ул вакытларда мондый көтүләрне бары тик сайлап алынган коммунист-көтүчеләргә генә ышанып тапшыра торганнар иде. Хәзер заман башка...

Хәер, Г. Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр» (1921) повестендагы «бишлек»нең берсе булган Шаһбаз да көтүче бит. Бай малае Гали тарафыннан әйтелгән сүзләр җиде яшеннән ятим калган малайның язмышын төгәл характерлый: *«Нәрсәгә ул чаклы хәйран каласыз. Чабатачы Әхми баласының көтүче булып китүендә нинди гаҗәп эш бар?»* «Көтүче нинди, көтү шундый» дигән мәкаль сакланып калуга да карамастан, бу хезмәт һөнәр булып та саналмый. Моны халык әкиятләре дә күрсәтә. Тәҗрибә дә раслый. Соңгы еллар шигъриятендә «көтүче»,

«чыбыркы» төшенчәләре сәяси-сатирик планда да кулланыла башлады. Мәсәлән, шундый сәяси символларны Р. Харис (1941) иҗатында очратырга була.

Хәзерге шигърияттә көтүче хезмәтенә социаль-психологик планда якын килгән шагыйрьләрнең берсе – Г. Сәгыйров (1938–2009). «Көтүче» исемле шигыренә ул Степан образын кертә (игътибар итик: татар түгел!). Арып эштән кайткач, бераз салып та алгач, ул хыяллары турында сөйләргә ярата. Гаиләдә өлкән бала булуына, укырга мөмкинлек тимәвенә басым ясый. Хәзерге үз тормышын күршеләренеке белән чагыштыра. Күршесе – шофер. Аның малае да әтисе кебек шофер булырга уйлый, тизрәк әтисе машинасына утырып, руль бора башлый. Ә Степанның малае бу вакытта капкадан чыбыркы өстерәп чыга да шартлатырга тотына. Степанның андый вакытларда яңаклары буйлап яшь тәгәри. Әлеге күренешне ул «тәкъдирнең көлеп торуы» итеп кабул итә. «Көтүче» шигыре буенча гына түгел, гомумән алганда да, «наданлыктан – көтүчелеккә бер адым» мотивы татар язучылары өчен чит түгел икәнлеген әйтү урынлы булыр.

Татар теленең аңлатмалы сүзлеге «көтүче» сүзенә мондый аңлатма бирә: *«Көтүне болынга, кырга һ. б. ш. урыннарга алып чыгып, карап, саклап йөртүче, ашатып йөртүче»,* – ди. Күренеп тора: көтүчелек хезмәте бернинди матурлык, сөенеч хисләре вәгъдә итми. Г. Кутуйның да (1903–1945): *«Минем атам бөтен гомерен көтүчелектә, газап-михнәт эчендә уздырган, үлгәндә дә сарыклар арасында үлгән»,* дигән фикерләре бар. Көтүчелек хезмәте бернинди дә романтик хисләр тууга сәбәпче була алмас шикелле тоела. Матурлык табылмаган җирдә шигырь дә тумас кебек.

Алайса, М. Галиевнең (1946) «Мин көтүче булам, дигән идем» шигырен ничек аңларга? Әлеге шигырь пастораль жанры таләпләренә җавап бирә, буколистик шигырьгә дә туры килә. Лирик герой авыл уртасында күктән агып барган Киек каз юлын күзәтә. Күккә юнәлгән карашын җиргә төшерсә, елга ярында каз кебек бер аягына басып, йокымсырап торган өянкеләрне күрә. Ул хәзер көтүче түгел инде, әмма шушы табигать матурлыгына хуҗа булган елларын юксына. Хәтер агачына сөялгән лирик герой иртәнге таңда көтү киткән эзләргә юлыга, дөресрәге, чыклы йолдыз юлын көтү киткән юлга тиңли. Билгеле, әлеге шигырь – романтик рухлы шигырь.

Азнакай төбәге табигате пастораль жанрындагы шигырь тууга үзе үк этәрә булса кирәк. И. Гыйлаҗев (1946) иҗатындагы «көтүчелек» мотивын башкача ничек аңлатасың?! «Көтү чираты» шигыре, исеменнән аңлашылганча, ихтыяри-мәҗбүри хезмәтне күздә тота. Әмма лирик герой өчен көтү чираты иртәнге, чыклы, тургайлы табигать белән хозурлану хисләрен генә бирә. Чираттагы көтүче маллар көткән вакытта дөнья мәшәкатьләрен оныта, телефоны да чырылдамый; көтү көткәндә кешегә тәне арыса да, җаны ял итә торган халәт иңә. Ә менә «Гүзәл мизгел» шигырендә И. Гыйлаҗев көтү кайткан вакытны сурәтли. Көтү үткән юлдагы тузан ялкау сыерны хәтерләтә, чыбыркы да шартламый, хәтта *«һәрбер сыер үзе эзләп таба, үзе ача кирәк капканы».* Шагыйрь көтүче хезмәтен данлый, аны авылдагы муллыкны тәэмин итүнең шарты итеп куя. «*Иминлекнең гүзәл бер мизгеле – Көтү кайткан чагы авылның!*» – дигән нәтиҗәсен чыгара. Ә менә «Көтү көтәм, имеш» шигыре бөтенләй башка характерда. Бу шигырьдә лирик герой күзәтүче генә түгел, үзе көтүче. Биредә ул һәр капкадан чыккан малларны аларның хуҗасына тиңләп бара. Бер капкадан шапшак Мәһибану кебек сыер чыга; аклы-каралы бер сыер, хуҗасына охшап, чит бозау имезеп тора; ферма мөдире сыеры чемченмичә мөгрәп кенә ала (аны шагыйрь «түрә» дип атый); эчеп йөри торган Сәкинәнең сыеры коры сөяк кенә, карак Мәгъсүмнеке качарга гына тора. Лирик геройның үзенең дә күңеле тыныч түгел, чөнки авылда да әхлаксызлык арта бара. «*Яланда да юк тынгылык, Җанда – уйлар көрәше. Маллар көтәм, үзем йөрим Авыл белән сөйләшеп...*»

В автобиографическом романе «Давайте помолимся!» (1991–1993) А. Гилязов так зафиксировал свое первое знакомство с наследием великого классика татарской литературы: «В детстве я успел прочитать только это произведение Г. Ибрагимова, и вскоре писателя истребили». Речь идет об «Адәмнәр» («Люди», 1923), которое произвело на юношу неизгладимое впечатление. Навсегда врезалось ему в память, как вместе с Гурием Тавлиным они обежали всю деревню в поисках сохранившихся книг Г. Ибрагимова, чье творчество оказалось под запретом (4, 56).

В 1946 г. это творение классика вдохновило молодого писателя на создание новеллы «Гибель гитариста» (1946), в которой А. Гилязов «постарался зафиксировать» пережитое. В авторских комментариях он пишет: «Не спорю, мое мировоззрение было еще ограниченным, с художественной точки зрения имеются, наверное, корявости, однако я написал!!!» «События, нарисованные в этой новелле, из лично пережитого мной. Бабушка Паулина, упоминаемая в тексте, дана под настоящим именем. Это бабка Паулина из Верхнего Багряжа» (5). Голод явился в 1944 г. причиной настоящей трагедии, которую пришлось пережить всему населению республики. Страшная эпидемия асептической ангины унесла десятки тысяч жизней. Однако ценность этого раннего произведения вовсе не исчерпывается достоверностью изображения быта этих страшных лет. Оно помогает понять, в каком направлении велись творческие поиски писателя. В романе «Давайте помолимся!» А. Гилязов признается: «В эти годы я написал много рассказов, некоторые из них сохранились до сих пор, писал и стихи, и они есть. Написанное я не предлагал в газеты-журналы. Я не спешил открыться, но и не собирался замолчать» (4, 110). «Голод сделал из меня писателя» (4, 56, 71).

Безусловно, вдумчивый читатель легко обнаружит в тексте новеллы А. Гилязова реминисценции из Ф. Достоевского, Г. Ибрагимова, Х. Такташа. Однако уже на раннем этапе творчества молодой прозаик не ограничивается односторонней рецепцией духовной мысли своих предшественников. Произведение являет собой пример любопытного сочетания самых разнообразных мотивов и художественных традиций собственно национальной и мировой культуры. Творчески осмысливая опыт классиков, А. Гилязов создает удивительное по архитектонике произведение, проявляя при этом талант самобытного художника (6).

Г. Ибрагимов и А. Гилязов – великие творцы-деятели своего времени. Многое не бесспорно в их творчестве. Создавая яркие художественные полотна, они сумели запечатлеть важные вехи в истории татарского народа и стать еще при жизни классиками татарской литературы. Их объединяет желание познать и оставить потомкам панораму народной жизни, пропущенную через душу творца.

Вслед за своими предшественниками А. Гилязов осваивает все богатство фольклора. Как и Г. Ибрагимову, ему удалось в своем творчестве достичь органического сплава фольклорной и литературной традиций. В целом ряде произведений (особенно в повестях «Один» (1959), «Три аршина земли» (1962), «Пальцы-тростинки, ногти-монетки из серебра» (1969), «В пятницу, вечером» (1979), «Рана» (1984–1985)) А. Гилязов использует фольклор для создания эпического народного характера, эпического стиля повествования. Несомненно, татарские песни, пословицы, поговорки, описание обычаев, обрядов способствовали созданию в произведениях этих великих татарских писателей самобытной национальной духовной сферы.

Так, Г. Ибрагимов вкладывает в уста романтического героя Зыи («Молодые сердца») свое видение песенного творчества татарского народа: «Истинно национальная музыка – плод чаяний и надежд народа, горя и печали его души. Суть татарского характера – величие и широта души, щедрость сердца, но с другой стороны – тяжелая судьба, особенно последние страницы его истории заполнены грустью и скорбью... Поэтому и музыка, неотделимая от судьбы народа, все время плачет и печалится... » (7, 185).

Стремясь докопаться до скрытого смысла любого переживания, и А. Гилязов пытается понять, определить, что же такое татарский *моң* и в чем его сила. Так, например, 5 декабря 1978 г. в письме к писателю М. Магдееву, размышляя о роли музыки в жизни человека, он пишет: «Ожегов в словаре так определяет слово “флюид”: “Истечение, ток, то, что исходит от кого-чего-нибудь”. Моң, подобно флюиду (а может, это и есть флюид?!), родится в человеческой душе и невидимыми микроскопическими волнами растекается по поверхности земли в разные направления, достигает небес, сливается с облаками, переплетается с солнечными лучами, обретая голос чистый, звучный, как родник. Моң рождается в душах тысяч представителей нации, это сила, объединяющая, соединяющая татар в единое целое» (8). В архиве писателя также сохранилась дневниковая запись, датированная 22 ноябрем 1994 г., где А. Гилязов так определяет сущность моң: «Душа – это океан, движения и колебания этой стихии в мире татар и есть моң» (9).

Важное место в произведениях Г. Ибрагимова и А. Гилязова отводится праздникам татарского народа. Особое место занимает в их творчестве сабантуй. В романе «Молодые сердца» (1912), повести «Серый в яблоках» (1922) Г. Ибрагимову удалось передать атмосферу, дух народного праздника. Здесь раскрылось его удивительное мастерство в изображении народных сцен. Уже в раннем творчестве у А. Гилязова сабантуй выступает, с одной стороны, как мирный земледельческий праздник, с другой стороны, ему свойственны черты праздника героического. Так, например, уже в рассказе «Беглец» (1959) через этот праздник писатель прославляет жизнетворческую энергию жителей деревни.

А. Гилязов считал фольклор в литературном произведении инструментом формирования национального мироощущения, способом сохранения национального уклада жизни. Как верно подметил литературовед М. И. Ибрагимов, сабантуй у А. Гилязова не только праздник, ему присваивается ритуальная функция – во-первых, сохранение генофонда общины (а в широком смысле – народа), во-вторых, сохранение единства народа (10, 18). Писатель стремится убедить своих читателей из числа татар в необходимости приезжать на

родину в дни этого праздника, чтобы ощутить преемственность поколений и свою причастность к жизни нации («Три аршина земли» (1962), «Любовь и ненависть» (1972–1973), «В пятницу, вечером» (1979)).

Доля определенного сходства выявляется и в образной системе произведений великих классиков. Так, например, в повести «Четверо» (1958) у А. Гилязова появляется интересный эпизодический персонаж – скрипач Хафиз, хромой старик лет шестидесяти. В нем угадываются черты старика Ярми из романа Г. Ибрагимова «Молодые сердца»: он – «хранитель истории», «голос совести своего народа». Как верно подметила литературовед А. Х. Садекова, образ народного мудреца «взят из народных представлений, из уважительного отношения татарского народа к знаниям, к старинным обычаям. Ибрагимов создал психологически верный портрет старика-татарина, он всем образом мышления, жизни именно представитель татарского народа» (11, 48–49). Старик Хафиз А. Гилязова, как и Ярми, воспитывает в молодых чувство гордости своим народом, его великим прошлым (12, 237–238).

Стремясь постичь жизненную драму великого художника, А. Гилязов с горечью размышляет в «Дневнике писателя»: «Галимджан Ибрагимов искал среди социалистов, большевиков татарских революционеров. Критиковал татарский уклад жизни, рисовал темные стороны татарской жизни. По-детски верил, что революционные идеи выведут татар к новой светлой жизни. Посмотри-ка на повесть “Судьба татарки”. Были, наверное, жили такие татары. Однако, изображая жизнь татарской женщины столь ограниченной, темной, полной страданий, разве Г. Ибрагимов не тянул татар назад?!!» (2, 18).

За кажущейся резкостью суждения скрывается специфическое понимание А. Гилязовым смысла писательского труда. В письме к писателю Ибрагиму Салахову (25 сентября 1991 г.) он с горечью пишет: «Мы несчастливый народ. Нация, разбросанная, рассеянная по миру. Нам не удается увидеть себя во всей полноте и цельности. Наша литература – подобна старому, залатанному зипуну, перехваченному тут и там грубой нитью. Кому-то удалось выхватить взглядом рукав, кто-то поведал лишь о воротнике… Распростерся зипун по земле, ходят по нему, топчут, наступая куда кому заблагорассудится» (13). Художники слова обязаны восстановить национальные скрепы, которые помогут татарам, при всей их разбросанности по миру, обрести и сохранить национальный дух. Общность языка, религии и территории – вот что, по убеждению писателя, может обеспечить единство нации.

Размышляя о роли женщины в жизни мужчины, писатель неустанно повторял, что «только женщина в силах спасти, уберечь мужчину даже в самые безнадежные мгновения»; «мужчина не может управиться в жизни без женщины. <…> Женщина – предводительница мужчины, указывающая ему путь» (4). «Жена в доме – это солнце, а мужчина – это месяц, который порой показывается из-за облаков» (14); «Если мужчина – месяц, то его освещает сила солнца женщин»; «Женщина словно лакмусовая бумага показывает, какой он мужчина» (15, 12).

Татарский писатель в женских персонажах акцентирует личностное начало, проявившееся в их способности сохранить нравственные принципы рода вопреки обстоятельствам (Махибадар («Один»), Бибинур («В пятницу, вечером»)). В татарской женщине он увидел духовные силы и волевую решительность, которые способны пробудить национальное самосознание татар.

Кодекс поведения женщины-татарки нашел свое воплощение ярче всего в повести «Рана» (1984–1988). Главная героиня – старушка Зулейха – всегда относилась к мужу с большим уважением и заботой. В ее глазах он был «старейшиной, мудрейшим из мудрейших, честным, участливым, трудолюбивым Сулейманом» (16, 366). Когда он надевал войлочную шляпу, то муж напоминал ей пророка или уполномоченного властью правителя (16, 365). Чтобы передать чуткое отношение героини к супругу, А. Гилязов обращается к арсеналу изобразительных средств, характерных для любовных дастанов и народных песен: Зулейха мечтает стать родниковой водой, чтобы унести с собой горести-беды своего мужа, «безгрешным облачком, плывущим в синем небе», чтобы, заслонив солнце, дать передышку старику; превратиться в ветерок, который в силах развеять его грусть-тоску, лишь на миг захотелось ей стать Круглым камнем, чтобы принять на себя его боль, Хозяйкой ручья, чтобы своим журчанием дать отдых его сердцу (16, 368).

Суть взаимоотношений между супругами А. Гилязов гениально передает через одну скупую фразу-обращение «Тебе говорю!»: «Они всегда понимали друг друга благодаря этим словам. / Два слова! / Разве их недостаточно для двух душ, которые были рождены друг для друга?» (16, 385).

За годы супружества Зулейха накрепко усвоила: «Когда не надо, не лезть под руку!», «Без нужды под ногами не путаться!», «Лишнего не знать», «быть терпеливой и выносливой» (16, 382). Соотнося героиню с коранической женой пророка, А. Гилязов подчеркивает незыблемость и истинность этого национального идеала.

В письме к В. Юнусову от 9 сентября 1992 г. А. Гилязов обобщает опыт предшественников в изображении образа татарина: «Маджит Гафури представил татарский мир средоточием бедных, униженных, оскорбленных, скопищем нищих...Гаяз Исхаки поднял татар и татарскую литературу на небывалую высоту. У Фатиха Амирхана было свое отношение к татарам, он восхищался татарами, любил их, начертал для них путь дальнейшего развития. Особенные татары и у Шарифа Камала. Он разглядел то, что не заметили другие... Затем длительное время писатели показывали татар очень скупо, сквозь призму большевистской идеологии. Искусственные герои, кукольные фигуры провозглашались воплощением настоящей татарской жизни. Татарская литература длительное время была отлучена от татарской истории, татарской судьбы, национальных героев. Все это привело естественно к отчуждению татар от национальных обычаев, языка, размыванию национального характера» (17).

С первых шагов на литературном поприще А. Гилязов стремился разбудить национальное самосознание татар. Не только у татарских писателей «золотого века», но и у своих современников – А. Еники и М. Магдеева – он черпал вдохновение для своего творчества. А. Гилязов обратился к татарским писателям с призывом «подарить миру произведения, в которых наиболее

глубоко воплотилась бы душа татарского народа, неповторимые черты национального характера и бытия». Писатель мечтал увидеть произведения о жизни татарского народа такого уровня, которого достигли на сегодняшний день европейская и русская литературы.

ЛИТЕРАТУРА

1. Гилязов А. «Оглянуться, чтобы понять» // Вечерняя Казань. – 3 марта. – 1987. – С. 3.
2. Гыйләҗев А. Күңелем серләре... (Куен дәфтәреннән) 12 июль 1992 ел // Казан утлары. – 2000. – №11. – Б. 5–41.
3. Архив писателя: Гыйләҗев А. Сайланып чыккан сүзләр. Июнь, 1989 ел.
4. Гыйләҗев А. Йәгез, бер дога! Роман-хатирә. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. – 448 б.
5. Архив писателя: Комментарий к рассказу «Гитарачының һәлакәте» («Гибель гитариста») от 15 июля 2001 г. (неопубликованный источник).
6. Хабутдинова М. М. Роль Ф. М. Достоевского в формировании Аяза Гилязова как писателя // Вестник ТГГПУ – 2011. – №4. – С. 266–273.
7. Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. 2 т.: Яшь йөрәкләр. Казакъ кызы. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. – 456 б.
8. Архив писателя: письмо к М. Магдееву от 5 декабря 1978 г.
9. Архив писателя: дневниковая запись от 22 ноября 1994 г.
10. Ибрагимов М. Миф в татарской литературе XX века: Проблемы поэтики. – Казань: Gumanitarya, 2003. – 62 с.
11. Садекова А. Х. Фольклор в эстетике Галимджана Ибрагимова. – Казань: ИЯЛИ, 1995. – 103 с.
12. Хабутдинова М. М. Сакральная топонимика в творчестве А. Гилязова // Вестник ТГГПУ – 2010. – №4. – С. 235–240.
13. Архив писателя: письмо к Ибр. Салахову от 25 сентября 1991 г.
14. Архив А. Гилязова: Письмо к родным Талгату и Гузель от 19 сентября 1991 г. (неопубликованный источник).
15. Камалетдинова Р. Кодрәтле сүз иясе.( Аяз Гыйләҗевка 70 яшь) // Сөембикә. – 1998. – 1 нче сан. – Б. 12–14.
16. Гыйләҗев А. Яра // Гыйләҗев А. Әсәрләр: дүрт томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. – Т. 4: Роман. Повесть. – Б. 344–438.
17. Архив А. Гилязова: письмо к В. Юнусову от 9 сентября 1992 г. (неопубликованный источник).

# ӘМИРХАН ЕНИКИ ИҖАТЫНДА ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ТРАДИЦИЯЛӘРЕ

*Ә. Р. Мотыйгуллина (Казан)*

В статье рассматриваются проблемы продолжения традиций Г. Ибрагимова в творчестве А. Еники. Изучение критического наследия А. Еники дает возможность раскрыть литературные взаимовлияния различных эпох и писателей. Особое внимание обращается на сравнение образно-стилевых особенностей Г. Ибрагимова и А. Еники.

Әдәби традицияләр дигәндә дәвамчанлыкны күздә тотабыз. Мондый күренешнең бер милли әдәбият кысаларында күзәтелүе үсеш эволюциясен билгеләргә дә ярдәм итә, алдагы буын каләм осталары өчен аерым «мәктәп» тә булып тора. Шундый дәвамчанлыкны XX гасырның ике күренекле әдибе Г. Ибраһимов һәм Ә. Еники иҗаты мисалында күреп була. Моның җирлеген Ә. Еникинең «Безне ул өйрәтте» дигән мәкаләсе тудыра.

Әдәби процесска бәя бирүче күп кенә тикшеренүчеләрнең хезмәтләрендә XX гасыр башының күренекле әдибе Г. Ибраһимовның үзеннән соңгы әдәби барышка ясаган йогынтысы турында мәгълүматлар бирелә. Әлеге йогынтының ачык мисалын югарыда телгә алынган Ә. Еники мәкаләсендә ачык күрәбез. Әмма әдип каләмдәше Г. Ибраһимовның бөтен иҗатына бәя бирү максатын куймый, ә «тел-стиль үзенчәлекләренә» генә аерым басым ясауны күз алдында тота.

Әлеге мәкалә ике әдип арасындагы әдәби бәйләнешләрнең шактый тирән булуын ассызыклау мөмкинлеге бирә. Ә. Еники Г. Ибраһимовның тел-стиль үзенчәлекләренә бәя бирү барышында «хикәяләү чарасының компонентларын бик нык арттырды» дип, өч юнәлешне аерып чыгара:

– аның әсәрләрендә кешеләрнең, примитив прозага хас булганча, исемнәрен дә хәрәкәтләрен генә түгел, портретларын күрәбез, характер үзенчәлекләрен, рухи кичерешләрен ачык сизәбез;

– ул үзенең әсәрләрендә вакыйганы хикәяләү өчен кирәк булган вакыт, хәл-шарт, көнкүреш элементларын әйтеп кенә узмыйча, аларны детальләр ярдәмендә ачык картиналар итеп сурәтләп күрсәтә;

– аңа чаклы прозада табигать бик аз чагылдырылса, Галимҗан аны чынлап торып эшкә җигә. Һәр хикәясенә, һәр романына диярлек, йә вакыйганың фоны-җирлеге, йә образның рухи халәтен ачыклаучы чара, йә авторның фикерен көчәйтүче символик образ булып, табигать күренешләре әсәрнең тукымасына органик рәвештә керә (2, 8).

Ә. Еники ясаган нәтиҗәләргә таянып, ике әдип иҗатына чагыштырма бәя биреп карыйк. Әдип ассызыклап узган беренче үзенчәлек – ике әдипнең портрет тудырудагы, характер үзенчәлекләрен ачудагы һәм рухи кичерешләрне бирүдәге уртаклык. Бу нисбәттән ике әдип иҗатында да әлеге үзенчәлекнең психологизм күренеше белән бәйле булуын ассызыкларга кирәк. Әдәбият белемендә Г. Ибраһимов һәм Ә. Еники иҗаты турында сүз барганда, аларны психологизм белән бәйләп карау алгы планга чыга. Әдипләр иҗатында психологизм күренешен татар әдәбияты галимнәре шактый тирән өйрәнгәннәр. Ике әдип иҗатындагы уртаклыкны дәлилләү максатыннан алар иҗатын тәфсилле өйрәнгән галим М. Җәләлиеваның ачыш-табышларына мөрәҗәгать итик. Аның «Әдәбиятыбызның җырлы чишмәләре» дигән хезмәтендә ике әдип иҗаты да бу нисбәттән шактый тирән бәяләнә (3).

Минемчә, галимә М. Җәләлиева нәкъ әдипләрнең сурәтләү объектларын өйрәнү вакытында психологизм күренешенә аерым басым ясый, мисаллар нигезендә дәлилләүгә ирешә. М. Җәләлиева үзе дә әлеге юнәлешне үз хезмәтләрендә куәтләп, күтәреп җибәрүче галимнәребезнең берсе. «Г. Ибраһимов иҗатында төп проблема – шәхесне сурәтләү. Ул, шәхес, – үзенең төрлелеге, рухи дөньясындагы каршылыклы табигате, реаль көче вә көчсезлеге, үзенең балкышлары һәм фаҗигасе белән сурәтләнә торган бакый җирнең олуг заты. Шуннан чыгып, язучының әсәрләрендәге киеренке

язмышлы геройларына якын киләсең. Галимҗан, тәүге хикәясендәгечә мәгърифәтчелек реализмы белән артык мавыкмастан, шәхес характерының тирәнәюенә баш биреп, аның эчке дөнья катламнарын табу өчен эзләнергә керешә» (3, 15). Ул Г. Ибраһимовның «Яз башы», «Диңгездә», «Уты сүнгән җәһәннәм», «Сөю – сәгадәт», «Карак мулла», «Йөз ел элек» хикәяләрен чагыштырма планда өйрәнеп, «әлеге хикәяләр кичереш агымына күмелгән романтик шәхесне сурәтләү белән бербереснә якын торалар», – дип белдерә (3, 16). Галимә югарыда аталган җыентыкка кергән «Әдип Галимҗан Ибраһимов» мәкаләсендә язучының характерлар тудыру алымнарын иҗат методына да бәйләп карый. Әдипнең «Карт ялчы», «Көтүчеләр» әсәрләрендәге геройларның (Шаһи карт, Сәфәр) «реаль типлар» буларак ачылуы ассызыклана. Г. Ибраһимовның «Табигать балалары» хикәясен дә М. Җәләлиева «реализмга бик тартым» дип дәлилли. Фикерен тагын да тәгаенләү максатыннан галимә: «Хикәянең бөтен сюжетындагы табигать образын, үзе яраткан адәмнәреннән, аларның хис вә акылыннан аерып алып булмый», – ди (3, 18). Шул рәвешле, галимә Г. Ибраһимов иҗатында психологзмның тирәнәюен, төрле ракурсларда, төрле дәрәҗәдә булуын, портретларны һәм характерларны ачу чарасы икәнлеген мисаллар нигезендә дәлилләп тә бара.

Шул ук мәкаләсендә М. Җәләлиева Г. Ибраһимовның әдәби геройларына бәя биреп тә уза: «Габдрахман – көйсез тормышы белән татар зыялысының юмористик образы буларак, котсыз хәят дулкынына бирешмичә, намус пакьлеге саклый алган оптимист зат», – дип Г. Ибраһимовның «Габдрахман Салихов» хикәясендәге төп геройга хас характерлы сыйфатны да ачыклап бирә (3, 19). Шушы ук мәкаләдә М. Җәләлиева Г. Ибраһимовның «Адәмнәр» повестенә бәя биреп, «Г. Ибраһимов кебек әдипнең оста каләме ач кешенең психологиясен сурәтләүдә хаклыкка, чынбарлыкка тугрылыклы булып кала», – дип билгеләп үтә. Шул рәвешле, аның хезмәтләрендә Г. Ибраһимов иҗатында характер тудыру алымнарының, психологизм күренешен бирүнең иҗат методларына бәйле булуы дәлилләнә.

Ә. Еники мәкаләсендәге фикерләрнең нигезле булуын исбатлау максатыннан да М. Җәләлиеваның мәкаләсенә мөрәҗәгать итү урынлы булыр. Шушы ук җыентыкка кергән «Әмирхан Еники (Тойгы катламнары)» дигән бүлектә әдип иҗатындагы психологизм күренеше төркемләп тә бирелә. Тикшеренүче М. Ш. Җәләлиева Ә. Еники әсәрләрендәге психологизның өч үзенчәлеген аерып чыгара: «Әдәби герой бирелешендәге беренче үзенчәлек бер персонажның үз эчендә күп тавышлар тудыра алу сәләте»... «Ә. Еники геройларының эчке тавышы нигезендә антитеза алымы белән, ягъни герой хисләренең тышкы дөнья хәлләре белән каршылыкка керүендә күренә»... «Бер әйбернең яки күренешнең үз эчендәге каршылыгы әдәби характер өчен дә хас һәм аны Еникинең иҗат тәҗрибәсендә психологик сурәтләүнең өченче үзенчәлеге итеп карарга кирәк» (3, 55–57).

Күреп үткәнебезчә, ике әдип иҗатында да психологизм күренеше геройларның эчке дөньясын, характер үзенчәлекләрен ачу чарасы булып тора икән.

Ә. Еникине Г. Ибраһимов иҗатында җәлеп иткән икенче үзенчәлек – «вакыт, хәл-шарт, көнкүреш элементларын әйтеп кенә узмыйча, аларны детальләр ярдәмендә ачык картиналар» ярдәмендә тасвирлап бирү (2, 8). Бу яктан ике әдипнең хикәяләрен чагыштырып карасак, уртак якларны шактый табарга мөмкин. Г. Ибраһимовның «Табигать балалары» һәм Ә. Еникинең «Төнге тамчылар» хикәяләрен чагыштырып карасак, түбәндәге нәтиҗәләргә килергә мөмкин. Ике әдип тә төп геройларның (Хафиз һәм Хәлил) тормышындагы вакыйгаларны детальләп сурәтлиләр, алар яшәгән чорның сурәтен күз алдына бастыралар. Шундый ук тәңгәллекләрне ике әдипнең башка әсәрләре мисалында да күрергә була.

Мәкаләдә Ә. Еники билгеләп узган өченче үзенчәлек Г. Ибраһимов иҗатындагы пейзаж белән бәйле. Дөрестән дә, Г. Ибраһимов табигать тасвирларын һәр әсәренең тукымасына кертеп җибәрә. Ә. Еникинең дә пейзаж тудыру остасы булуын  дәлилли алабыз. Табигать тасвирына ишарә әдипләрнең әсәр исемендә үк чагыла. (Г. Ибраһимовта: «Яз башы», «Диңгездә», «Табигать балалары», «Кызыл чәчәкләр», «Тирән тамырлар» һ. б.)

Ә. Еники прозасында пейзажның роле көчле һәм автор аңа олы идея-эстетик бурыч йөкли. Табигать күренешләрен кешенең күңел дөньясын, эчке халәтен ачуга буйсындырып сурәтләү Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять», «Рәшә» әсәрләрендәге дала картинасы, «Тауларга карап» хикәясендәге таулар, «Туган туфрак»тагы Питрәчнең көлсу туфрагы,  «Төнге тамчылар», «Бер сүз» хикәяләрендәге яз табигате, «Тынычлану»дагы җәйге эсселек аша бирелә. Аларның һәрберсе дә күпмедер дәрәҗәдә геройларның рухи халәтен ачуга хезмәт иткән символик образ булып торалар. Шуның белән беррәттән, әдәби геройларның киләчәк язмышларын күзаллауга ярдәм итәләр.

Ә. Еникинең табигать тасвирына мөрәҗәгать итүе сугыш елларындагы иҗатында ук ачык күренә. «Бала» хикәясендә табигать психологик контраст тудыруга хезмәт итә. Бу яктан, Зариф күзәткән табигать хозурлыгы («усакның калган яфраклары», «ак томан») әсәрдәге сугыш дәһшәтенә каршы куелса, икенче яктан, ул очраткан бала, афәттән сакланып, табигать кочагына яшеренгән, куак аны бәладән саклап тора. Хикәядә сурәтләнгән табигать геройларның үзара мөнәсәбәтен ачу өчен җирлек булып тоелса да,чынлыкта исә, әдип әйләнә-тирәлекнең геройга йогынтысын күрсәтеп, аның рухи дөньясына үтеп керә һәм шул тирәнлектә яткан рухи дөньяны сурәтли башлый.

Ә. Еники әсәрләрендә кеше һәм табигать арасындагы мөнәсәбәт тирән, эчке бәйләнештә бирелә. Бер яктан, пейзажны сурәтләү, икенче яктан, типик халәтне тасвирлау кеше характерын ачуда кулланылган ике параллель алым гына түгел, ә бәлки бер алымның, синтезлашкан бербөтеннең ике ягы, ике юнәлеше булып тора. Бу үзенчәлекне язучының «Төнге тамчылар», «Тынычлану» хикәяләрендә ачык күреп була.

Ә. Еникинең «Тынычлану» хикәясендә пейзаж эмоциональ фон булып тора. Хикәядә ул төп герой Гасыйм Сәләховичның эчке дөньясы, кәефе, кичерешләре белән тыгыз бәйләнештә бирелә. «... Көне ... иртәнге сәгатьтән үк бөркү эсселек үзен шул чаклы сиздерә башлар икән! Гаҗәп! Хәтта төне дә җиңеллек китермәде. Суынырга өлгермәгән таш йортлардан, таш урамнардан, тузан исен аңкытып, һаман бөркелеп торды бу китмәскә килгән эсселек...» (1, 386). Әсәрдәге табигать геройның эчке дөньясын гына ачып калмый, аны чолгап алган тирәлекне күзаллау мөмкинлегенә дә тудыра. Шул юл белән әдип үзенең эстетик вазифасын (күңел халәтен ачу) чишә.

Гомумән алганда, Ә. Еники һәм Г. Ибраһимов әсәрләрендә пейзаж эмоциналь фон ролен башкара. Табигать һәм кешенең рухи халәтендәге үзгәрешләр кешенең рухи дөньясындагы халәт белән тәңгәлләшә. Табигать һәм кеше рухи берлектә яши.

Җыеп әйткәндә, ике әдип арасындагы әдәби-эстетик, образ-мотив, тема-проблема, тел-стиль яссылыгындагы бәйләнешләрне өйрәнү татар әдәбиятындагы традицияләрнең нигезен ачу мөмкинлеген тудыра. Әдибебез Ә. Еникинең тәнкыйди мирасын өйрәнү шундый юнәлештәге эзләнүләр алып бару өчен җирлек булып тора.

ӘДӘБИЯТ

1. Еники Ә. Әсәрләр. 3 томда. III том. – Казан: Татар. кит нәшр., 1991.
2. Еники Ә. Хәтердәге төеннәр: Мәкаләләр, очерклар һәм истәлекләр. – Казан: Татар. кит нәшр., 1983.
3. Җәләлиева М. Ш. Әдәбиятыбызның җырлы чишмәләре. Казан: Мәгариф, 2001
4. Ибраһимов Г. Әсәрләр. Сигез томда. III том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1975.

## Г. ИБРАҺИМОВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ТУЙ АЛДЫ ЙОЛАЛАРЫ

*И. Г. Закирова (Казан)*

Г. Ибрагимов в своем творчестве опирается на народное творчество, а также на народные обычаи и обряды. Предсвадебные обряды, их описание есть в его повести «Судьба татарки». В повести «Дочь степи» писатель показал своё знание обычаев другого, родственного народа.

Г. Ибраһимов иҗаты, беренче чиратта, татар халкының бай фольклорына нигезләнгән булса, халыкның үзенчәлекле йолалары да язучы игътибарыннан читтә калмый. Г. Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» һәм «Казакъ кызы» повестьлары татар һәм казакъ халкының туй йолаларын бөтен тулылыгы белән тасвирлаган әсәрләрдән. Язучы иҗатының халык иҗаты белән бәйләнешен өйрәнгән А. Х. Садыйкова әлеге әсәрләрнең турыдан-туры фольклорга мөнәсәбәтен – «Татар хатыны ниләр күрми» повестеның шәхси фаҗига бәетләре белән, «Казакъ кызы» повестеның дастаннар белән сюжет уртаклыгын күрсәтә (3: 59, 64).

Татар халкының туй йолалары бер-берсенә тыгыз бәйләнгән өч өлешкә бүленә: туй алды (яучылау, килешү, билге алышу, ярәшү), туй үзе (никахны рәсмиләштерү, кыз һәм егет ягында туй үткәрү белән бәйле гореф-гадәтләр), туй арты (килен төшерү, шәл салдыру, кияү кайтармасы һ. б.) (4, 10).

Ике әсәр дә туй алды вакыйгалары белән башланып китә. «Татар хатыны ниләр күрми» повестенда татар халкындагы туй алды йолаларының беренче этабы – кызга яучылар килү бәян ителә: «Бер атна эчендә кызга ике яучы килде». Яучы җибәрү татар халкы өчен традицион йола. Егетнең ата-анасы, улларының гаилә кору яше җиткәч, аны башлы-күзле итүне үзләренең төп бурычы санап, үзләренә тиң булырлык гаиләгә кыз сорарга яучы җибәргән. Яучы җибәргәндә, беренче чиратта, кызның нәсел-нәсәбе турында белешкәннәр. Бу ерак туганнар арасында никах мөнәсәбәтләрен булдырмау, нәселләренә начар холыклы, тәртипсез яки җинаятькә сәләтле кан кушылмасын өчен эшләнгән. Шулай ук кызның эшкә уңганлыгы, бирнәсе, матурлыгы да игътибардан читтә калмаган. Яучы итеп авылның дәрәҗәле, шушы эштә тәҗрибә туплаган кешеләре җибәрелгән.

Татар халкында кыз яучылаган вакытында әйтелә торган махсус текстлар да булган:

Өер-өер айгырдан
Җайдак булып килгәнмен,
Чаптар атым чаптырып,
Чыңлап сиңа килгәнмен.
Бохарадан ияр алган мин,
Юлым сиңа ярган мин,
Каеш баулы лачыным бар,
Былбылыңа килгән мин;
Тимер булсаң, мин – күмер,
Эретергә килгән мин (4, 57).

Кызның ата-анасы яучының сүзен кире кайтарган, яки уңай җавап биргән. Әмма беренче уңай җавап та, кире җавап та төгәл, хәл ителгән җавап түгел. Кызны бирергә теләмәгән очракта «Кызыбыз яшьрәк», «Быелга мөмкинлегебез юк» кебек җаваплар бирелгән. Кызны бирергә каршы булмаганда да, яучы «Туганнар, кардәш-ыру белән киңәшергә кирәк», дигән җавап белән кире кайткан.

«Татар хатыны ниләр күрми» повестенда ике очрак та тасвирлана. Беренче яучыны Нурый карт кабул итми: Бик мәшәкатьле чагым, менә хәзер өй кузгатырга торам, җир-урман алдым; быел туй ясаулар турында уйларга чамабыз килмәстер», – дип кире кайтара. Уңай җавап түбәндәгечә яңгырый: «Үзең дә зур, сине җибәргән кеше дә зур... Аптырабрак калдым: быел андый өлкән эшләргә кул сала алмабыздыр дигән идек; җиңел генә кире сугарга көчем җитми, хәзергә өзеп әйтә алмыйм, анасы белән сөйләшик, кардәш-ыруга да киңәш итим». Бу җавап яучының икенче тапкыр киләчәгенә ишарә итә, икенче килгәндә килешү йоласы үтәлә. Килешү йоласында кызның бирнәсе, яки мәһәре, егет бирәсе калым, бүләкләр турында, никах-туй вакыты, аның кемгә күпмегә төшәсен сөйләшәләр. Шул ук вакытта биредә кыз бирүнең бер гаилә эчендә генә хәл ителмәве, кардәш-ырулар белән киңәшергә кирәклеге дә, аларның фикере дә мөһим булуы аңлашыла.

Әсәрдә туй алды йолаларыннан карала торган үзенчәлекле күренеш – ябышып чыгу турында да мәгълүмат теркәлгән: «Асып куймаслар әле, бер рәнҗерләр, бер каргарлар да туктарлар», – дип уйланып, үзенең сөйгән егете Лотфыйга ябышып чыгарга күңелен беркетте». Ябышып чыгу – кызларның өеннән качып китеп, ата-ана ризалыгыннан башка, яраткан кешесенә кияүгә чыгу йоласы. Гадәттә, бу очракта ике йола үрелеп киткән, егет кызга өеннән качып китәргә булышкан,

аны суга барганда яки башка сәбәп белән өеннән чыккан арада урлап киткәннәр. Кыз урлау татар халкында шактый таралган күренеш булган. Ул ике төрле була. Беренче очракта кызны үз ризалыгы белән урлыйлар, икенчесендә, кызның ризалыгы булмый. Туганнары белеп калганда, кызны куып тотып, кире алып кайту очраклары да булган. Әмма яратмаган кешесе белән гомер иткән кызлар да күп була. Татар халкында аерылу бик зур гаеп саналган. «Казакъ кызы» повестенда да кыз урлау йоласы тасвирлана.

Казакъ халкының кыз ярәшү йоласы татар халык йолаларыннан аерыла. Казакъ халкы балаларны бик яшьтән, еш кына тугач ук, яки берничә айлык вакытта ярәшә. «Казакъ кызы» повестенда шушы йола тасвирлана: «Шул көнне сүз куештылар. Бер атна үтүгә, югары-түбән ат җибәреп, илне җыйдылар. Кымызның мул чагы, туктыларның симез заманы, йөгерекләрнең дә, дер кайнап, йөрәк суккан вакытлары иде. Яше, карты, бүз баласы, сылу кызлары җыелып, үлән, җыр әйтеп, думбра чиертеп, ат уйнатып, утыз көн уен, кырык көн туен кылып, ике ыруг кодалыкка кул бирештеләр». Әсәрдән бу күренешнең традицион булуы аңлашыла: «тукалның ике айлык кызын Йолдызбайның яңа туган улына әйттерү турында кодалык сәүдәсе бара иде», «шул көзне сабый Миңсылу белән ике яшәрлек Куйбагарны әйттерделәр» һ. б. Казакъ халкында әйттерү йоласы ил-ыруг белән киңәшләшеп башкарылган. Кодалашу йоласы ыруглар арасында дошманлык булса, аны бетерү, туганлашып, ике ыруг берләшеп, дошман ыруглардан саклану, аларга каршы тора алуны күз алдында тоткан. Кодалашуның беренче максаты шул булу «Казакъ кызы» повестенда ачык сурәтләнә. «Ике йортның өлкәннәре кода булды дип ишеттек, мәгәр күз белән күрмәдек. Әгәр бу дөрес булса, җир берлеген кан беркетсәк, кайсы яман бу ике илгә җау чыгарыр?», «Найманнар белән дүрткаралар һәр ике йортның мазасын китәрәләр, кызларын урлыйлар, җәйләүләрен басып алалар, аяклы малларын куып китәләр; сарманнар белән кара-айгырларның кода булып кушылулары дошманның йөрәгенә ут салыр, башыннан акылын алыр, кодалык котлы булсын».

Яңа туган балаларны ярәшү йоласы төрки халыкларның күбесенә таныш булып, аның татар халкында да булуын «колак тешләтү» дигән гыйбарә исбатлап тора. Татар халкында яңа туган балаларны ярәшү нәкъ шулай дип аталган да. Казакъларда бу йола «бишек қода» дип тә аталган. Төрки халыкларның уртак мирасы булган «Кузы-Көрпәч белән Баян-Сылу» дастанында да шушы йола турында сүз бара. Дөрес, эпос геройлары балаларын туганчы ук ярәшеп куялар. Бу ярәшү «бел қода» яки «атастыру» дип аталган. Казакъларда да, бала чагында ук ярәшелмәгән очракта, кызны яучы җибәреп сораганнар.

«Казакъ кызы» повестенда кодалыкка килешкәннән соң калым өчен сатулашу тасвирлана: «Озак талашканнан соң, йөз баш кара, дүрт йөз алтын, ике сандык асыл зат өстендә килештеләр». Шул көннән яшь ярымлык Карлыгач белән ай ярымлык Калтай әйттерелгән булып, берсе кияү, берсе калымлык санала башлый. Кыз унсигезгә җиткәндә калым түләнеп бетеп, ике йорт та зур туйга әзерләнә, Карлыгачны каената йортына озатырга әзерләнәләр. Казакъ йолалары буенча, кияү дә, калымлык та бер-берсен белеп, язмыш яки Аллаһ тарафыннан бирелгән кешесен тиң күреп, яратырлык итеп тәрбияләнә. Калым түләнеп беткәндә кияү белән кәләш очраша башлыйлар, һәм татарларга караганда иреклерәк гореф-гадәтләр яшьләрне бу очрашулар өчен гаепләми, ул йола буларак кабул ителә.

«Татар хатыны ниләр күрми» повестенда никах, туй мәҗлесе, бүләк, бирнә багу, ишек бавы, кияү келәте, кияү мунчасы, кияүләп йөрү, кыз озату, килен төшерү кебек туй йолалары да тасвирлана. Әсәрдә туй алды йолалары туй һәм туй арты йолаларына күчә. «Казакъ кызы» повестенда кызның урлануы белән бәйле рәвештә ул йолалар булмый.

ӘДӘБИЯТ


1. Ибраһимов Галимҗан. Казакъ кызы // Ибраһимов Галимҗан. Әсәрләр. Сигез томда. Т. II. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. – Б. 319–465.

2. Ибраһимов Галимҗан. Татар хатыны ниләр күрми // Ибраһимов Галимҗан. Сайланма әсәрләр. Өч томда. Т. III. – Казан: Таткнигоиздат, 1956. – Б. 435–605.

3. Садекова А. Х. Фольклор в эстетике Галимджана Ибрагимова. – Казань, 1995. – 103 с.

4. Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – 320 б.


## ИҖАДИ ЭЗЛӘНҮЛӘР ЮЛЫНДА...


***Л. И. Минһаҗева (Казан)***



Ибрагим Салахов – один из тех татарских авторов, чья жизнь и творческий путь полны сложностей, противоречий и драматических эпизодов. Его сложная биография оказала большое влияние на его произведения. Получивший известность еще в студенческие годы, благодаря своим произведениям, молодой и перспективный писатель в 1937 году становится жертвой культа личности И. Сталина, лишается на десять лет свободы и на пять лет гражданских прав.

А вдохновителем и отправным толчком в начале его творческого пути был Галимджан Ибрагимов.


Галимҗан Ибраһимов – татар әдәбияты тарихында җуелмас эз калдырган бөек шәхес. Язмышы авыр, фаҗигале вакыйга-хәлләрдә өзелгән әдипнең тормышы белән бәйле аерым истәлекләр, соңгы көннәре турында кайбер мәгълүматлар Ибраһим Салаховның «Колыма хикәяләре» роман-хроникасында да чагылыш тапкан. Һәм бу гаҗәп тә түгел. Чөнки әлеге әсәрнең язылу сәбәбе һәм тарихы гына түгел, бәлки, И. Салаховның анда чагылган гыйбрәтле язмышы да байтак дәрәҗәдә Г. Ибраһимовка барып тоташа. Эш шунда, 1937 елда

яшь язучы И. Салахов тормышының көтелмәгән якка үзгәреп китүе Г. Ибраһимов исеме белән бәйләнә: шәхес культы еллары башлангач, ул «халык дошманнары» Г. Ибраһимов белән К. Нәҗми арасында элемтәче булуда гаепләнә. Нәтиҗәдә, суд карары нигезендә, ун елга ирегеннән һәм биш елга гражданлык хокукларыннан мәхрүм ителә.

Мәгълүм ки, «Колыма хикәяләре» роман-хроникасында сталинизмның куркыныч җинаятьләреннән берсен ачуга басым ясала. Әсәрдән һәм, гомумән, тарихтан күренгәнчә, Сталин репрессияләре беренче чиратта халыкларның интеллектуаль җегәрен тәшкил итүче көчләргә каршы юнәлтелә. Шунлыктан «халык дошманнары» сыйфатында иң әүвәл интеллект ияләре – дәүләт һәм җәмәгать, фән һәм мәдәният эшлеклеләре юк ителә. Шул нигездә аерым милләтнең һәм бөтен җәмгыять тормышының интеллектуаль җегәре һәм куәте шактый киметелә һәм көчсезләндерелә. Сталинизм репрессияләре тудырган шушы афәтне күрсәтү өчен И. Салахов роман-хроникасында төп игътибарны репрессиягә эләккән күренекле әдәбият-сәнгать, фән һәм дәүләт эшлеклеләренә юнәлтә. Мондый шәхесләрдән әсәрдә Г. Ибраһимовка зур гына урын бирелә һәм, истәлекләр аңа илле яшь тулу уңаеннан туган хисләрне җиткерү белән башланып китә: «Бу елның уникенче мартында Г. Ибраһимовка илле яшь тулды. Без, яшь язучылар, шул уңай белән Казанда, әдәбият дөньясында зур тантана булыр, дип өметләнгән идек. Гаҗәпкә, бу көннәр бик «тыныч үтте» (2, 17).

Олы әдип белән бәйле рәвештә автор, лирик чигенешләр ясап, роман-хроникада укучыларны үзенең үткәне, яшьлек еллары белән дә таныштыра. Кече яшьтән үк Г. Ибраһимов әсәрләрен укып әдәбият белән танышкан, әдип иҗатына чын мәгънәсендә гашыйк И. Салахов Казанга да аны очрату хыялы белән килгән була (2, 21). Алга таба, Ялтада әдип белән турыдан-туры очрашудан соң ул озак вакытлар язучы образы белән рухланып яши. Шул җирлектә «Колыма хикәяләре»ндә һәм аерым истәлекләрендә дә (2; 3; 4) аның санаторийда үткәргән берничә ай вакытын, тормышын һәм иҗади эшчәнлеген сәнгатьчә ачып бирергә, тарихи шәхесне катлаулы характеры белән күз алдына бастырырга омтыла.

И. Салаховның әдәби иҗатка килү юлын чагылдырган «Беренче адымнар» истәлегендә (бу вакыйга беркадәр романда да чагыла) автор, 1927 елда Күкчәтау җидееллык татар мәктәбенә Г. Ибраһимовның кырык еллык юбилее уңаеннан аның исемен бирү тантанасы турында дулкынланып яза. Биредә яшь И. Салаховны Г. Ибраһимовның гүзәл әсәрләре генә түгел, бәлки, «кабарып торган чәч, киң маңгай, уйчан күзләр, калку күкрәк, мәһабәт сынлы әдип»не гәүдәләндергән портреты да сокландырса (4, 29), «Колыма хикәяләре» роман-хроникасында әлеге хисләрнең чынбарлык белән кинәт кенә контраст куелуы укучыны сискәндереп җибәрә: «Ялтада мин менә шушы мәһабәт кешене, атаклы әдипне эзләп киттем.

Мин аптырап калдым... Аның өстендә аксыл-сары иркен күлмәк һәм шул ук материалдан тегелгән чалбар. Аякларында да ак йоннан басылган йомшак каталар. Өстендәге киемнәре, нигәдер, гәүдәгә ятышмый, сәлберәп торалар. Йөзе озынча, яңак сөякләре калкып, битен тагын да суза төшәләр. Монда да кан тамырлары бүртеп, күгәреп, йөзен суытып-куыртып торалар. Чәчләр дә кабарып иңнәргә төшмәгән, сыланып ятканнар. Ара-тирә чал кылчыклар да күренә.

Тукта, кайда соң ул теге, мин Күкчәтау җидееллык мәктәбе залында сокланып караган, портрет кысасына сыймый, тулып, ташып торган мәһабәт ир?» (2, 22).

И. Салаховның портретта күргән Г. Ибраһимов образы белән озак еллар рухланып яшәве, күптән көтелгән очрашу алдыннан сурәтләнгән табигать тасвирында да чагыла кебек. Чөнки әдип портретын биргән вакытта кулланылган «баш аз гына, беленер-беленмәс кенә иелгән, уйга талган. ... Күкрәк калку, иңнәр киң» кебек тасвирлар табигать сурәтенә дә күчерелгән: «Урамның ике ягында төп-төз баскан биек, кырыс, тирән уйга талган кипарислар» (2, 23).

Автор әсәрендә Г. Ибраһимовның кешелеклелек һәм әдиплек сыйфатларын, тышкы кыяфәтен, ул яшәгән шартларны сурәтләүгә аеруча дикъкать итә. Аның авыру булуына карамастан тулы канлы, җанлы тормыш белән яшәвен тасвирлый. Шул хәлендә дә ул Казанда басылган барлык китаплардан, газета-журналлардан, яшь язучылардан хәбәрдар. Табигать күренешләренә бәйләп бирелгән фикер исә образны тагын да тулыландыра, ача төшә кебек: «...Күпме кораблар килә, күпме кораблар китә. Кара диңгез кочагы киң...» (2, 23).

И. Салахов романында үзе илаһи зат дип күзаллаган әдипнең чынлыкта гади, тыйнак кеше булуын ача. Бу хәл яшь язучылардан алган мәдхия хатын укыгач, Г. Ибраһимовның үзен «бөек түгел», бары «эшче каләм – иҗат эшчесе» булуына басым ясавында ачык чагыла: «...Галимҗан ага башын күтәреп, миңа шелтәле карады, – нигә алай артык мәдех? ... Язган әсәрләремнең күбесеннән риза түгел, дөресрәге, канәгать түгел. Менә “Татар хатыны ниләр күрми”, “Безнең көннәр”не яңадан төзәтеп язып чыктым. ... Юк, “бөек” сүзе артык» (2, 24). (Әлеге романда әйтелгәнчә, хатка кул куйган яшь язучылар, «Кызыл Татарстан» газетасы хезмәткәрләре Г. Мөхәммәтшин, Л. Гыйльми, К. Шәйхетдинов, С. Рафиков һ. б. 1937 елда кулга алыналар. Кайбер мәгълүматларга караганда, аларның кулга алынуы әлеге хат белән бәйле була. 1937 елда, СССР язучылар идарәсенең ул вакыттагы секретаре В. М. Ставскийга язылган доноста нәкъ менә шушы хат нигез итеп алына. Әлеге язучы аңа кул куючыларны Г. Ибраһимовка ялагайлыкта, бер сүздә булуда һ. б. гаепли. Мәгълүм ки, ул вакытта И. Салахов өстеннән педагогия институты студенты Фазыл тарафыннан да донос була. Шуның өстенә, төрмәдә Алмакаев фамилияле берәү «контрреволюцион оешмада торалар» дип, унөч кеше өстеннән ялган күрсәтмәләр бирә. Аларның уникесе атыла, исемлектәге унөченче кеше – И. Салахов ниндидер көч, бәхетле очраклык нәтиҗәсендә генә исән кала).

«Колыма хикәяләре» роман-хроникасында Г. Ибраһимовның соңгы көннәре турындагы хәбәрләрдән, тагын, тоткыннарга Бестужев әлифбасы ярдәмендә җиткерелгәннәре китерелә: «... Га-лим-җан Иб-ра-һи мов ка-ты а-вы-рый. Төр-мә боль-ни-ца-сына сал-ды-лар...» (2, 58). «Га-лим-җан Иб-ра-һи мов төр-мә боль-ни-ца-сында үл-де...» (2, 61).

Гомумән, шәхес культы елларының бөтен фаҗигасен, социализм идеяләренең гарипләнүен, Сталин һәм аның тарафдарлары тудырган системаның совет кешесен кол дәрәҗәсенә төшерүен «Колыма хикәяләре» роман-хроникасында аянычлы язмышы аша тасвирлап,

үз вакытында тарихыбыздагы «ак тап»ны ачарга батырчылык иткән И. Салаховның әдәбиятка ныклап юл алуы Г. Ибраһимов исеме белән бәйләнгән була. Бу олы әдип әсәрләре белән ул Күкчәтау җидееллык татар мәктәбендә укыган елларында ук таныша башлый. Мондый танышлыкның ничек башлануын Г. Ибраһимов әсәрләрен укырга яраткан, «китап җене кагылган» бабасы белән бәйләп, ул күренекле әдипнең сиксән еллык юбилее уңаеннан язылган «Еллар сәхифәсе» дигән истәлегендә түбәндәгечә искә ала: «...кичләрнең берсендә миңа Г. Ибраһимовның “Татар хатыны ниләр күрми” повестен укырга туры килде. Барыбызга да бик ошады. ... Моңа кадәр бабай нинди китап туры килсә, шуны алып кайта иде. Ә менә “Татар хатыны ниләр күрми”не укыгач Күкчәтау буенча йөреп, Г. Ибраһимов китабын гына эзләде» (3, 14).

Алга таба, тагын бер истәлегендә И. Салахов Н. Арсланов табып биргән «Алмачуар» хикәясен кызыксынып укуы, икенче көнне үзенең дә беренче тапкыр казакъ авылында күргән ат бәйгесе турында хикәя язып каравы һәм Н. Арсланов тарафыннан мактау сүзләре ишетүе турында искә төшереп үтә (3, 15).

Г. Ибраһимовның «адаш» дип эндәшүеннән соң туган хисләрен, язучының үзенә турыдан-туры тәэсирен бәяләп, соңрак, И. Салахов: «Бу очрашулар (Ялтада әдип белән очрашулар) миңа иҗат хезмәтемнең серле ишекләрен ачты, армый-талмый эшләргә, укырга, өйрәнергә, өйрәнергә, өйрәнергә кирәклеген төшендерде», – дип язды (2, 25).

Академик М. Хәсәнов үзенең бер мәкаләсендә татар халкының милли һәм социаль азатлыкка, яңа тормышка омтылыш юлында алдану-фаҗигаләрен «әсәрләрендә гаять тулы һәм тирән, бөтен катлаулылыгы һәм каршылыклары белән чагылдырды» дип, Г. Ибраһимовның хакыйкатьне ничек бар шулай гәүдәләндерүенә аерым басым ясаган иде. Өлкән әдипнең шушы сыйфатлары алга таба И. Салахов өчен үзенә бер иҗат үрнәгенә әверелә. Кече яшьтән үк Г. Ибраһимовның шушындый әсәрләрен укып үскән И. Салахов, бигрәк тә реабилитациядән соңгы иҗатында, Г. Ибраһимовның әлеге үрнәгенә, шушы юнәлешенә ияреп тормыш хакыйкатен ничек бар шулай укучыларга җиткерергә омтылды. Аның бу омтылышы шәхес культы елларын чагылдырган әсәрләрендә аеруча ачык күренде.

«Партия каршында, халык каршында һичбер гаебем юк. Хакыйкать ачылыр, тарих үз сүзен әйтер» (7, 17). Г. Ибраһимов вафатыннан соң, төрмә камерасындагы тумбочка ишегенең эчке ягында шундый язу табылуы инде мәгълүм. И. Салахов остазының өметен aклады, үзен «халык традицияләренең – кайгы, горурлык һәм куркаклык, кешелеклелек һәм вөҗдансызлык картиналарының тере шаһите» (7, 3) дип атаган язучыбыз аннан үрнәк алып, тормыш хакыйкатен ничек бар шулай ачып бирә алды, аның традицияләрен дәвам итте. Ягъни, Г. Ибраһимов әсәрләрен уку, аның белән очрашу И. Салаховның иҗатына, бигрәк тә реабилитацияләнгәннән соңгы иҗатына нык тәэсир иткән дип нәтиҗә ясарга мөмкин.

ӘДӘБИЯТ

1. Ибраһимов Г. Сайланма әсәрләр / Төз. һәм кереш сүз авт. Л. И. Минһаҗева. – Казан: ТаРИХ, 2002. – 542 б.
2. Салахов И. Колыма хикәяләре. Фаҗига-хроника. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. – 256 б.
3. Салахов И. Еллар сәхифәсе: Г. Ибраһимовның тууына 80 ел // Ялкын. – 1967. – № 3. – Б. 14–15.
4. Салахов И. Беренче адымнар // Ялкын. – 1973. – № 4. – Б. 28–29.
5. Салахов И. Киләчәк буыннар белсен // Социалистик Татарстан. – 1988. – 4 декабрь.
6. Салахов И. Правда нужна живым // Советская Татария. – 1988. – 20 декабря.
7. Минһаҗева Л. И. Ибраһим Салахов. Тормышы һәм эшчәнлеге. – Казан: Матбугат йорты, 1999. – 176 б.

## ТӨРЕК-ТАТАР ӘДӘБИ БАГЛАНЫШЛАРЫ: ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ЧОРЫ

*Р. Г. Ханнанов (Казан)*

В формировании татарской драматургии существенна роль турецкой литературы, что в свое время было отмечено отдельными выступлениями в прессе и писателем, общественным деятелем Г. Ибрагимовым. Как известно, первые татарские пьесы появляются на основе творческих достижений турецких авторов. В то же время важную роль на начальных этапах становления татарской драматургии сыграли переводы с турецкого языка. Особенно ярко проявляются турецко-татарские связи в конце XIX – начале XX в. Внимание татарской интеллигенции привлекает турецкая литература, впитавшая в себя передовые просветительские идеи. У двух родственных народов формируются общие цели, возрастают духовные потребности, в особенности в сфере культуры и образования. Через турецкую литературу татарские писатели приобщаются к литературе и культуре народов Западной Европы. Татарская интеллигенция, в свою очередь, вносит вклад в развитие литературы, культуры, искусства, общественной мысли турецкого народа.

Дөнья әдәбиятлары тарихында әле бер халыкның, әле икенчесенең сәнгать казанышлары әйдәүче көчкә әверелә. Урта гасырда бөтен төрки әдәбиятларны (шул исәптән төрекнекен дә) фарсы һәм гарәп телле язма мирас баетып килә. Нинди дә булса бер әдәбиятның көчәюенә һәм башка әдәбиятларга тәэсир ясавына карамастан, әлеге бәйләнешләрнең икеяклы, катлаулы күренеш булуын кире кагып булмый. Әдәбиятыбыз һәм сәнгатебез, иҗтимагый аң үсешебез турында сөйлибез икән, төрекләр белән татар халкы арасында булган багланышларның әһәмиятенә игътибар итми кала алмыйбыз.

XIX гасырның икенче яртысында үсә башлаган төрек драматургиясе вәкилләре Шәмсетдин Сами (1850–1904), Әбүззыя Тәүфикъ (1848–1913), Рәджанзадә Мәхмүд Әкрәм (1847–1914), Әхмәд Мидхәт (1844–1912),

Самипашазадә Сәзаи (1858–1936) һ. б. ның әсәрләрендә без төрле әдәби юнәлешләрнең, стиль һәм жанрларның үзара үрелешен күрәбез. Классицизм иҗат методына буйсынган трагедияләр һәм романтик драмалар белән бергә, мещаннар тормышын яктырткан тормыш-көнкүреш драмалары да үсеш ала. Төрек драматургиясе әле яралган гына чорда авторлар күбрәк тарихи пьесалар иҗат итәләр, әсәрләр тарихи яки легендар сюжетка корыла. Ә менә Г. Хәмиднең «Сәйди Яхъя» (1875) һәм Ш. Саминең «Гавә» (1877) пьесаларында социаль тигезсезлек, гаиләләрдәге таркаулык, гаделсезлек, кешенең хис-кичерешләре белән санлашмау кебек мәсьәләләр күтәрелә. Мәгълүм ки, конфликтның чишелеше дә трагик төс ала: бер-берсен яраткан кыз белән егет үз-үзләрен үтерә. Н. Кямалның «Кызганыч бала» (1873), Ә. Тәүфикъның «Каргышлы үлем» (1873), Р. М. Әкрәмнең «Вуслет яки кыска вакытлы шатлык» (1875) пьесаларындагы сюжет алга таба татар драматургларының әсәрләренә дә күчә.

XIX гасырның җитмешенче елларында төрек драматургиясендә сәяси яңгырашлы романтик драма өстенлек итә. Әлеге жанрда иң күп эшләгән Н. Кямал да, Ш. Сами, Р. М. Әкрәм, Ә. Тәүфикъ та үз әсәрләрендә идеал образ – уңай герой тудырырга тырышалар, аны гади халык арасыннан эзлиләр (мәсәлән, Ш. Саминең 1875елда иҗат иткән «Бәя яки антка тугрылык» әсәрендә). Бу, күпмедер дәрәҗәдә, Көнбатыш Европа классикларының әсәрләрен тәрҗемә итү, аларчарак язуга булган омтылыштан да килә. Шул рәвешле Р. М. Әкрәмнең «Атала» (Шатобрианның «Атала» повесте буенча) пьесасы, Ә. Тәүфикъның «Гашыйк кыз яки эчкерсез мәхәббәт» (Гюгоның «Анджело» әсәренең ирекле тәрҗемәсе) әсәре һ. б. лар иҗат ителә.

Шушы елларда француз әдәбияты йогынтысында, мөстәкыйль жанр буларак, мелодрама барлыкка килә, Ибраһим Шинасиның «Шагыйрьнең өйләнүе» әсәре белән башланып киткән милли комедия уңышлы гына үсә. Халыкчан, сәяси җирлеккә корылган комедияләрдә миллилек үзен көчле сиздерә, аларда яшерен уен-тамашалары белән мәгълүм «Карагөз» һәм «Урта уены» театрларына хас гадилек ярылып ята. Тәүге комедияләрнең тууына француз драматургы Мольерның пьесаларын тәрҗемә итү этәргеч бирә. Моңа, беренчеләрдән булып, тарихчы һәм театр эшлеклесе Әхмәд Вакыйф-паша (1823–1891) алына һәм төрек теленә Мольерның уналты пьесасын тәрҗемә итә. Бу төрек театрының оешып китүенә дә сәбәп була. Бер-бер артлы Али бәйнең «Куып җибәрелгән кунак» (1871), «Күп сөйләшә торган сакал кыручы» (1873), Хәмди бәйнең «Ике карбыз бер култык астына сыймый» (1871), Р. М. Әкрәмнең «Күп белгән күп ялгыша» (1875) кебек оригиналь комедияләре языла. Җиңел рухлы әлеге пьесалар күп очракта мәгърифәтчел төсмер ала.

Драматургиянең төрле жанрларында эшләгән Габделхак Хәмиднең әсәрләре дә мәгърифәтчелек реализмы кысаларында языла. «Хисчән кыз» (1875) социаль-көнкүреш драмасында ул хатын-кызның җәмгыятьтә ир-атлар белән тигез хокуклы булырга тиешлеген проблема дәрәҗәсенә күтәрә, «Нәстерен» (1876) сәяси трагедиясенең идеясен колбиләүчелеккә каршы чыгуга, кешеләрнең үзара тигез хокукларга ия булырга тиешлеген раслауга кора. Аллегориягә нигезләнгән «Либертә» (1876) шигъри драмасында исә Колбиләүче тарафыннан зинданга ябылган Ирек, Либерал ярдәмендә аннан котылып, сөйгән халкы янына ашыга, халкының ирекле тормыш корачагына нык ышана.

Көнбатыш Европа әдәбиятына йөз тоткан Г. Хәмид үзенең сәяси трагедияләрен француз классицизмына, төгәлрәк итеп әйткәндә, Расин һәм Корнель әсәрләренә яраклаштырыбрак яза. Аларның сюжет кору, әсәр идеясен булдыру, сәнгать чараларыннан оста файдалану тәҗрибәсенә таяну төрек драматургиясенең формалашу чорында әһәмиятле фактор була. Мәсәлән, Н. Кямал драматургиясендә, төрекләрнең милли карашлары белән Европа әдәбиятларына хас мәгърифәтчелек идеяләре тыгыз бәйләнештә бирелә. Төрек сәхнә әдәбиятына нигез салучыларның берсе буларак, ул Ж.-Ж. Руссо, Монтескье, К. Ф. Вольнейларның фикерләрен уздыра. Төрек язучыларының традицион алымнарын, халык уеннарын, ягъни халык театрын кире кагып, дөнья әдәбияты орбитасына тартылырга чакыра. Шул рәвешле, төрек сүз сәнгатенә Европа мәгърифәтчелек әдәбиятына хас идеология үтеп керә.

Бер-бер артлы иҗат ителгән пьесалар театр сәхнәсендә даими уйнала башлый. Профессиональ төрек театры 1868 елда оеша. Ул «Шәрык театрысы» дип атала.

Безнең төрек әдәбиятына булган игътибар нәрсә белән аңлатыла соң? Төрек сүз сәнгате, төрки әдәбиятлар арасында беренчеләрдән булып, Көнбатыш Европа әдәби эстетик тәҗрибәсен актив үзләштерә, драматургия, проза кебек яңа әдәби төрләргә, жанрларга байый, әдәбият белеменә һәм тәнкыйтькә караган беренче хезмәтләр языла, вакытлы матбугат җанлана, әдәби телне халыкка аңлаешлы итү өчен көрәш кыза; феодаль тәртипләрне, иске культураны тәнкыйтьләү үзәккә куела; ватан, милләт, ирек, хатын-кыз азатлыгы, шагыйрьнең гражданлык бурычы кебек әһәмиятле мәсьәләләр күтәрелә. Шул юнәлештә яңару кичергән төрек әдәбияты билгеле күләмдә татар язучыларының игътибарын җәлеп итә (1, 530).

XIX гасыр – XX йөз башында тагын да көчәя төшкән бәйләнешләр татар милләтенең мәгарифе үсешенә, әдәбияты һәм сәнгате җанлануга, үз вакытлы матбугаты барлыкка килүгә зур этәргеч ясый.

Мондый тәэсир күпмедер күләмдә борынгырак чорларда да татар халкының рухи тормышына дәрман өстәп торган. Үз чиратында, ата-бабаларыбызның укымышлылыгы, иҗатка һәвәслеге һәм әдәби мираска игътибарлылыгы төрек кардәшләргә шулай ук игелекле йогынты ясаган, XX йөздә, бигрәк тә Россиядәге Ватандарлар (гражданнар) сугышыннан соң, күп кенә күренекле татар мәдәни, сәяси эшлеклеләренең Кече Азиягә күчеп килүе Төркиянең иҗтимагый фикере, гуманитар фәннәре үсешенә куәтле этәргеч бирә, дәүләтнең, Көнбатыш казанышларын үзләштереп, көчәюенә хезмәт итә (2, 156).

XIX гасыр ахыры – XX йөз башында татар яшьләре арасында дөньяви югары белем алу теләге арта, әмма патша Россиясенең колониаль сәясәте бу омтылышка ныклы киртә сала, алар илнең югары уку йортларына кабул ителми. Алдынгы яшьләр бар өметләрен чит илгә, башлыча, Төркиягә юнәлтергә мәҗбүр була. Дин уртаклыгы, телләрнең якынлыгы, Госманлы империясе дәүләт эшлеклеләренең Росссиядән килүче төрки кардәшләренә теләктәшлек күрсәтүе аралашуның тагын да көчәюенә китерә. «Татар шәкертләренең Төркиягә барып, андагы гимназия һәм хәрби уку йортларына кереп укуы ихтыяҗга һәм модага әйләнә» (3, 64). Татар

дөньясында дан казанган алдынгы рухлы «Бубый», «Галия», «Мөхәммәдия», «Хөсәения» мәдрәсәләрендә Төркиядән алып кайткан дәреслекләр буенча Истанбулда белем алган яшьләр укыта башлый.

Язучыларыбызның төрек әдипләре иҗатына мөрәҗәгать итүе татар әдәбиятын, идея-тематик яктан булсын, форма ягыннан, эстетик яктан булсын, яңалыкка этәрә, баета. Әлеге өлкәдәге катлаулылык, әдәби бәйләнешнең күпкырлылыгы турында шактый сөйләп булыр иде. Әйтик, төрек әдипләренең Европа, бигрәк тә француз әдәбияты үрнәкләрен үзләштерүләре, аларның иҗат үзенчәлекләреннән файдаланулары, татар язучыларының төрек әдипләре язганнарга иярүе, шуның аша Европа әдәби үрнәкләренә якынаюы, ә бу очракта төрекләрнең арадашчы вазифаларын үтәве һ. б.

Татар әдипләренең төрек әдәбиятына тартылуы мәгърифәтчелек идеологиясенең милләт өчен зур мөмкинлекләр вәгъдә итүе белән дә бәйле. Гасырлар буе формалашкан эстетик нормалар инде әкренләп үзгәреш кичерә, аларны яңалары алмаштыра. Хатын-кызның ир-атлар белән тигез хокукка ия булырга тиешлеге, заманча тәрбия һәм дөньяви белем һәр кешенең камиллеккә, бәхеткә ирешүендәге беренче адымы булу, мәдәниятнең, сәнгатьнең беренче чаткыларын үстерү, гыйлемгә омтылу һәм фәннәрне өйрәнү халыкның наданлыктан котылуына төп чара икәнлекне алга сөрү әнә шундыйлардан. Үсешкә омтылган татар әдәбияты өчен нәкъ менә шулар кирәк була. Татар иҗат зыялылары бу мәсьәләләрдә күп яктан төрек әдәбиятын үзләренә үрнәк итеп куялар. «Без бервакыт госманлы әдәбиятына шәкерт идек. Ул вакыт бездә госманлы тәэсире бар иде» (4, 231), – ди Г. Ибраһимов.

XIX гасыр ахыры – XX йөз башында иҗат иткән язучыларыбызның байтагы төрек вакытлы матбугатын даими күзәтеп бара, төрек әдәбияты-сәнгатеннән яхшы хәбәрдар була. «Сәүдәгәрләребез Истанбулдан төрек китапларын алып кайтып сата – бу җәдитчелек килеп чыгуга да мөһим этәргеч һәм җирлек бирә» (3, 65).

Г. Ибраһимов чыгтай (борынгы үзбәк) әдәбияты тәэсирен телгә алганнан соң: «...хаҗилар Истанбулдан, Анадулыдан кайбер китаплар китерделәр. “Мөхәммәдия”ләр бездә үз җәүһәребез кебек урын алды. Менә шул ике – чыгтай һәм госманлы – тәэсире астында татарның борынгы әдәбияты яшәде, акрынлап үсте, эчтәлекне генә түгел, әдәбилекне, стильне, атаманы шул тәэсир астында ясады» (5, 217), – ди. Әлеге фикерләр белән килешмәү мөмкин түгел.

XX гасыр башында Төркия зыялылары Госманлы империясен җөмһүрият буларак ныгыту, дәүләт чикләреннән тышта калган төрки кавемнәрне ят халыклар йогынтысыннан саклау идеяләрен алга сөрә, бу юнәлештә зур эшчәнлек алып бара. Тугандаш халыкның фикерләренә кушылып, татар әдипләре дә төрки кавемнәрне европалаштыру, империалистлар тарафыннан изелүдән коткару, мәгариф-тәрбия челтәрен яңарту программаларын һәм чараларын тикшерү юнәлешендә эш башлый.

1913 елның мартында Фатыйх Кәримигә язган хатында Г. Ибраһимов Төркиядә яшәүче зыялы милләттәшләребезнең татар халкына кызыклы, ә язучы-әдипләренә үрнәк булырдай әдәбияты турында күбрәк сөйләмәүләре өчен борчыла. Ф. Кәриминең элегрәк матбугатта басылган мәкаләләренә бәйле рәвештә, ул болай ди: «Татар журнализмысында бөтенләй яңа, бөтенләй башка төстә килеп чыккан ул мәктүбләреңез җан ачлыгы белән укылдыгы хәлдә, күңел сездән тагын бер нәрсә көтә иде. Әйтәчәгем – төрек әдәбияты мәсьәләседер. Сез аңа бик аз урын бирдеңез. Сәбәбе ачык. Әхвәле мәмләкәт язмышы (дәүләт язмышы хәлләре) хәл ителәчәк бер ноктага җиткәндә, әллә кем шагыйрьләр тугрысында тәфсыйләт сөйләп утыру ятрак булыр иде. Шулай да без һаман сездән, әдәбиятчы улмагыңыз сыйфатыннан, ул хакта бер сүз көтәбез.

Истанбулда ни чаклы шәкерт укый. Йосыф әфәнде (сүз Йосыф Акчура турында бара. – *Р. Х.*) ничә еллар анда яши, шунда ук М. Гаяз әфәнде барды, ләкин һичбере шул матур, шул нәфис әдәбиятны авызга алмады һәм алмый. Хәлбуки Фөзүли (Фөзүли Мөхәммәт – атаклы азәрбайҗан шагыйре. – *Р. Х.*) вә Кәмальләре (Нәмык Кямал – төрек язучысы, атаклы драматург. – Р. Х.)... Габделхак Хәмид (күренекле төрек драматургы. – *Р. Х.*), Әкрәм (танылган төрек шагыйре, пьесалар авторы. – *Р. Х.*), Халид Зыя (Ушаклыгөл – танылган төрек язучысы, төрек әдәбиятында роман жанрын нигезләүчеләрнең берсе. – *Р. Х.*) һәм Тәүфикъләры (Тәүфикъ Фикрәт – төрек поэзиясе вәкиле. – *Р. Х.*) булган ул әдәбиятта безем татар өчен бик күп гыйбрәтләр, бик күп нәмүнә (үрнәк. – *Р. Х.*) вә хәзинәләр бардыр» (6, 71–72).

Шуннан соң ул күптән түгел генә Габделхак Хәмиднең трагедияләре белән танышып чыгуын әйтә. Аның 1886 елда шигырь һәм проза белән язылган «Зәйнәб» драмасын җентекләп укыганнан соң, Ф. Кәримидән шул зат хакында «тәфсыйль өмид иткәнлеген әйтеп», элегрәк тә бер хат язганлыгын белдерә. «Вакыйган, мин ул куәт алдында хәйранмын, – ди Г. Ибраһимов. – Ул трагедияләр яза. Ләкин иң зур трагедия аның үзендә, үз язмышында. Ул төрек галәмендә төрек угылы булып туган, менә шул аны Шекспир, Шиллер, Гетелар белән беррәттән алырга тиеш булган урыныннан мәхрүм итә. Мин рус әдәбиятында да моңа тиң шәхесне күрмим. “Нәмидә” (“Бәхетсез”), “Фәрди вә шөрәкясе” кебек нәфис, “Мави вә сияһ” (“Зәңгәр вә кара”) кебек назик әсәрләр тудырган Гошшакый Задә (төрек суфи шагыйре. – *Р. Х.*) Халид Зыя бәк, Нәҗад Әкрәм (төрек әдәбиятында тәнкыйди реализм методын нигезләүчеләрнең берсе, көчле сатирик. – *Р. Х.*) белән хатимәләнгән (тәмамланган. – *Р. Х.*) әшгаре сәхибе (шигырьләр иясе. – *Р. Х.*) безем өчен, безем әдәбияттан мужик чабатасы күренеп торуын эзләгән тупас натуралистларымыз өчен бөек тәэсир итә белерләр иде» (6, 72–73).

Әдип, теле татар халкына аңлашылып бетмәсә дә, күренеп торган ниндидер кимчелекләре булса да, «бөтенләй читкә ташланган» шул әдәбиятның безнең милли сүз сәнгатебезнең үсеше өчен әһәмиятле булуын аңлый. «Ул косурын (кимчелекләрне. – *Р. Х.*) игътираф илә бәрабәр (тану белән бергә. – *Р. Х.*) татар андагы сәнгатькә, андагы нәфасәткә (нәфислеккә. – *Р. Х.*) ирешергә бик ерак төсле күренә. Төрек әдәбияты диләр дә, кул селкәләр, хәлбуки, бу – балалык. Берничә косуры (кимчелеге. – *Р. Х.*) өчен бөтен шәйне инкярдыр (бөтен нәрсәне юкка чыгарудыр. – *Р. Х.*). Шуның белән көрәш башлансын иде, – дип яза ул әлеге хатта. – Төрек әдәбиятына хәсрәтем әдәбиятка мотлак (ничек кенә булмасын. – *Р. Х.*) рус народниклары күзе илә карауны (народниклар әдәбиятны революцион идеяләрне пропаган-

далауда куәтле чара итеп бәялиләр. Г. Ибраһимов төрек әдәбиятында да шуңа якын караш урнаштыру ягында тора. – *Р. Х.*) бераз игътидальгә (урта дәрәҗәгә. – *Р. Х.*) китермәсме дигән өмидемнәндер» (6, 72–73).

Әлеге хаттан күренгәнчә, Төркиядә барган сәяси реформалар, мәгърифәтчелек идеяләрен тормышка ашыра башлау һ. б. үзгәрешләр биредә яшәгән татар зыялыларын да читтә калдырмый. Төрек әдәби процессын татарларга тәфсилләп язылган мәкаләләр сирәгәя (алар моңа кадәр дә күп булмый, XIX гасырның икенче яртысында әдәбиятлар үзара багланышка ныклап керешә генә башлый). Болар, әлбәттә, Г. Ибраһимовны борчуга сала. Ул моңа берникадәр аптырый да әле. Татар зыялыларының, татар халкына төрек әдәби әсәрләрен шәрехләп утырмыйча, сәяси процессларга катышып йөрүе аны гаҗәпкә сала. Ләкин әлеге чор (XIX йөз ахыры) татарлар һәм төрекләрнең уртак максат-бурычлары билгеләнү белән әһәмиятле. Бу, иң беренче чиратта, мәгариф һәм мәдәният, рухи тормыш кебек өлкәләргә карый: «...фикердә һәм гамәлдә урта гасырлар торгынлыгыннан котылу, ислам динен, яшәеш фәлсәфәсен искергән төшенчәләрдән арындыру, дөньяви белем алу һәм кәсеп итүдә Европаның алдынгы халыкларына иярү» (2, 165).

Алдынгы фикерле милләттәшләребезнең Төркиядәге илкүләм билгеле булган оешмаларда хезмәт итүе, югары мәктәпләрдә белем бирүе сер түгел. Мәсәлән, әүвәл Бакчасарай шәһәрендә «Тәрҗеман» газетасын чыгарышкан мәгърифәтче, әдип, җәмәгать эшлеклесе Муса Акъегет уку программасы, өйрәнелгән фәннәре белән бүгенге көндә дә күпләрне үзенә җәлеп иткән Хәрби командованиенең югары мәктәбендә укыта. Төрекләр татар мәгърифәтчесен сәяси икътисад буенча хезмәтләре өчен аеруча югары бәяли.

Гаяз Исхакыйның да төрек-татар халыклары арасындагы һәм әдәби-мәдәни, һәм иҗтимагый-сәяси йогынтыларга катнашы М. Акъегетнекеннән ким булмый. Беренче тапкыр 1909 елда Истанбулга килеп, биредә ике ел яшәү дәверендә, Г. Исхакый «күренекле фикер ияләре һәм язучылар, журналистлар белән таныша, төрек мәдәни хәрәкәтенә катнашып китә. Танылган әдип Сөләйман Назыйф һ. б. белән төрек әдәби теле хакында бәхәскә керә. Г. Исхакый, гади (халыкчан) тел һәм купшы (сарай) тел табигатен аңлатып, “Сыйраты мөстәкыйм” журналында берничә мәкалә бастыра, төрек язучыларын гарәп-фарсы алынмаларыннан котылган гади төрки телдә, Анадулы игенчеләре һәм терлекчеләре җиңел аңлый торган телдә язарга өнди, “Төрек дәрнәге”ндә татар әдәбиятына бәйле интервьюлар бирә» (2, 161).

Шулай ук Абдулла Баттал-Таймас, Зәки Вәлиди Тоган, Абдулкадыйр Инан, Рәшит Рәхмәти Арат, «Йосыф Акчура, Садрый Максуди һ. б. төрек тарихында зур эз калдырулары ике гасыр чигендә дә, хәзер дә төрек хөкүмәте, иҗтимагый эшлеклеләре, галимнәре тарафыннан танылa» (7, 27). Әлбәттә, гомерләрен милли үзаңны үстерүгә, матур әдәбиятка багышлаган татар зыялыларының, иҗтимагый-сәяси эшчәнлеге белән беррәттән, төрек әдәби хәрәкәтенә, биредә мәгърифәтчелек реализмы формалашуга ясаган йогынтысы да зур була.

Ф. Кәриминең төрек язучысы Ә. Мидхәт белән иҗади бәйләнештә торуы, бу танышлыкның Ф. Кәрими Төркиягә киткәнче үк булганлыгы мәгълүм. Алар күпмедер хат алышалар. Бер хатында Ә. Мидхәт Ф. Кәрими сораткан газеталарны җибәрүен хәбәр итә һәм татарларны белемгә-укуга, чит телләр өйрәнүгә омтылышлары булмауда гаепли. Рус ориенталистлары исламнан курыкмаган заманда, христианлыктан өркеп, татарларның рус мәктәпләренә укырга кермәвенә гаҗәпләнә. Ул татар яшьләренә башка халыкларда булган мөмкинлекләрдән файдаланырга киңәш итә. Әлеге хатлардагы киңәш-тәкъдимнәр, ике халык арасындагы уртак һәм аермалы якларны билгеләү Ә. Мидхәт белән Ф. Кәрими арасында барлыкка килгән туганнарча якын мөнәсәбәтләргә сәбәп була.

Татар драматургиясенә нигез салучыларның берсе Г. Камал да сәхнә әдәбияты өлкәсендәге адымнарын төрекчәдән тәрҗемә белән башлый. Ул Н. Кямалның «Зәваллы чоҗык» драмасын «Кызганыч бала» исеме астында тәрҗемә итә. Г. Исхакыйның «Алдым-бирдем», М. Фәйзинең «Кызганыч», «Галиябану» әсәрләрендә дә «Зәваллы чоҗык»ның чалымнарын тоемларга була.

XIX гасыр ахыры – драматургиябез туган чор. Тәүге драма әсәрләре, нигездә, төрек әдәбиятыннан тәрҗемә ителә, оригиналь сәхнә әсәрләре тудыруга омтылыш көчәя. Шул рәвешле, XX гасыр башында татар драматургиясе зур үсеш ала, беренче спектакльләр куела башлый. Инде 1868 елда ук оешкан төрек театры татар сәхнә сәнгатен булдыруда әһәмиятле вазифа башкара. Төрек театрының оешкан чорында милли телдә күбрәк француз, итальян авторларының пьесалары уйналу алга таба татар драматургиясе һәм театрында да чагылыш таба.

Төрек-татар әдәби багланышлары кысасында караганда, без татар драматургларының әдәби-эстетик карашларындагы үсеш-үзгәреш закончалыкларын, тенденцияләрен, милли сүз сәнгатенең татар чынбарлыгына якыная баруын, әдәбиятның заман мәсьәләләре белән торган саен ныграк сугарылуын күрәбез.

ӘДӘБИЯТ

1. Ганиева Р. Көнчыгыш традицияләрен үстереп / Р. Ганиева // Татар әдәбияты тарихы. XX гасыр башы татар әдәбияты: 6 томда. III т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986.
2. Әйди Т. Хәзинәләр уртак / Т. Әйди // Казан утлары. – 1993. – 11 нче сан.
3. Гасрый Н. Пробуждение русских татар и их литература / Н. Гасрый // Мирас. – 1993. – № 5.
4. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. V т. / Г. Ибраһимов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978.
5. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. VII т. / Г. Ибраһимов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1987.
6. Ибраһимов Галимҗан: хатлар һәм документлар. – Казан: Фикер, 2000.
7. Харрасова Р. Әдәби бәйләнешләр яктылыгында / Р. Харрасова. – Казан: РПФ «Гарт», 2002.

# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫҢ 1917 ЕЛГА КАДӘРГЕ ФӘННИ-ТӘНКЫЙДИ ЭШЧӘНЛЕГЕ

*Р. С. Зарипова (Казан)*

В этой статье обращается внимание на научно-критическую деятельность Г. Ибрагимова до 1917 года.

Галимҗан Ибраһимовның беренче тәнкыйди хезмәтләрендә татар дөньясында 1905 ел революциясе нәтиҗәсендә барлыкка килгән үзгәрешләр, яңа әдәбиятның формалашуы, әдәби тәрҗемә, мәктәптә милли әдәбият укыту, милли театр, нәшрият эшчәнлеге, китап сату һ. б. мәсьәләләр яктыртыла.

Аерым алганда, аның «Татар матбугаты» (1910), «Әдәбият мәсьәләләре» (1910), «Яңа китап мөнәсәбәтилә» (1912), «Яңа әсәрләр, яңа имзалар вә яшь куәтләр» (1915) һәм башка исемдәге мәкаләләре, гомумән, әдәбиятка һәм аерым әсәрләргә анализ һәм бәя бирү белән бергә, татар укучысында югары әдәби зәвык тәрбияләү максатын да күздә тотып языла.

Г. Ибраһимовның әдәби-эстетик карашлары формалашуда рус әдәбияты зур гына роль уйный. Ул бигрәк тә В. Белинский иҗаты белән нык кызыксына, аның әсәрләрен тирәнтен өйрәнә. 1910 елда тәнкыйтьченең тууына 100 ел тулу уңае белән «Рус мөхәррирләреннән мәшһүр интикадчы В. Г. Белинский җәнабләре хакында» дип исемләнгән аерым мәкалә бастырып чыгара. Ул революцион-демократ В. Белинскийның крепостнойлык хокукына, сәяси һәм рухи коллыкка каршы алып барган көрәшен күрсәтә, татар җәмәгатьчелеген рус тәнкыйтьчесенең идеяләре белән таныштыра. Г. Ибраһимов В. Белинскийның яңа, реалистик әдәбият өчен көрәшүе турында яза. Тәнкыйтьченең әдәби-эстетик карашларын бәян иткәннән соң, Г. Ибраһимов татар әдәбиятында әле чын тәнкыйтьнең булмавын, аңа нигез салыр өчен В. Белинскийның әдәби-эстетик принципларын кабул итәргә кирәклеген әйтә. Язучы үзе дә әдәби тәнкыйть эшчәнлегендә В. Белинский принципларын тормышка ашырырга тырыша, әдәбият һәм сәнгать үсешенә кагылышлы күп кенә мәсьәләләрне рус тәнкыйтьчесе рухында хәл итәргә омтыла.

Г. Ибраһимов үзенең башлангыч чор тәнкыйть мәкаләләрендә үк әдәбият һәм сәнгатьнең иҗтимагый функциясен алгы планга чыгара. «Әдәбият, бигрәк тә романнар, кызык өчен, укып, көлеп тә, ахырында ташлар өчен генә язылмый һәм язылмаска тиешле. Анда мөхәррирнең әйтергә теләгән бер уе, күрсәтергә теләгән бер күренеше, халык һәр көн күреп, сөйләп тә сизми кичкән мөһим вә хас бер мәгънә була» (1, 68).

Шул нигез принциптан чыгып, Г. Ибраһимов Кәбир Бәкернең «Җанлы курчаклар» әсәре уңае белән 1912 елда язылган «Яңа китап мөнәсәбәтилә» рецензиясендә реалистик әдәбиятның капиталистик җәмгыятьтәге социаль каршылыкларны кискен фаш итәргә тиешлегенә басым ясый (1, 60–62).

Г. Ибраһимов, әдәбиятның изге бурычы – халыкка һәм җәмгыятькә хезмәт итү, дип саный. Аның карашынча, шундый вазифаны башкарган әсәрләр генә әдәби һәм иҗтимагый кыйммәткә ия.

Г. Ибраһимовның эстетик һәм теоретик карашларын тулырак чагылдырган хезмәте булып «Татар шагыйрьләре» исемле күләмле китабы (1913) тора.

«Татар шагыйрьләре» өч бүлектән тора. Аның беренче бүлеге С. Рәмиев иҗатына багышланган. Тәнкыйтьче С. Рәмиевнең шагыйрь буларак төп үзенчәлеген билгеләп кенә калмый, аның бунтарьлыгының сәбәпләрен дә ачарга алына. Аның фикеренчә, төп сәбәп – шагыйрьнең үзе яшәгән тормыштан ризасызлыгында, аның белән җәмгыять арасындагы каршылыкта. Шул сәбәпле, «аның бик күп шигырьләре ниһаясе булмаган истираб, фәрьят вә фәган, аһ-зар илә тулы» (1, 89). Автор С. Рәмиев бунтарьлыгын тагын аның әлеге каршылыктан чыгу юлларын таба алмавы, шагыйрь идеалларының чынбарлыктан аерылган булуы белән дә бәйләп аңлата.

С. Рәмиевнең иҗат лабораториясенә дә мөрәҗәгать итеп, тәнкыйтьче аның шагыйрьлек стихиясен ачуга шактый урын бирә. С. Рәмиев шигырьләренең ритм ягыннан ныклап эшләнмәгән булуын да Г. Ибраһимов аның әлеге стихиясе көчлелеге, телнең табигый агышына бу стихиянең сыя алмавы белән бәйләп аңлата. Иҗат стихиясе белән чамасыз мавыгып киткән тәнкыйтьче иҗат эшенең стихияле процесс кына түгел, акыл хезмәтенә нигезләгән икәнен дә истән чыгара.

Г. Ибраһимовның С. Рәмиев иҗатына романтик карашы тагын аның әсәрләрен тикшерүгә, башлыча, гомуми шигърият көче, абстракт матурлык яссылыгыннан килүендә чагыла. Табигый, мондый очракта шигырьләрнең идея-тематик ягына, аларда күтәрелгән мәсьәләләргә, гомумән, шагыйрьнең иҗтимагый йөзенә әллә ни игътибар ителми.

«Татар шагыйрьләре»нең икенче бүлеге Дәрдемәндкә багышланган. Бүлеккә эпиграф итеп

> Исә җилләр… Күчә комнар… бетә эз,
> Дәригъ, мәхзун күңел, без дә бетәбез, –

дигән мәгълүм юлларны алып, тәнкыйтьче аларда шагыйрьнең поэтик кредосы чагылуын билгеләп. Мәсьәләне тагын да төгәлләштереп, Г. Ибраһимов Дәрдемәнднең шагыйрьлек йөзен түбәндәгечә билгели: «Аның әдәби йөзе мөмтаз дәрәҗәдә матур булмак илә бәрабәр, күзләренә бер өметсезлек катыш хәзин һәм ниндидер авыр тәфәккер әсәре ялтырый» (1, 97). Автор Дәрдмәнднең тирән кичерешле, кайгылы шагыйрь булуын ассызыклый. Күренә ки, биредә дә шагыйрь иҗатына романтик караш өстенлек ала. Шундый карашка нигезләнеп, Г. Ибраһимов, Дәрдемәнд әсәрләре кешене канатсызландыралар, аны актив эшчәнлектән читкә алып китәләр, дигән нәтиҗәгә килә.

Г. Ибраһимов, татар тәнкыйтендә беренче буларак, Дәрдемәнднең сәнгатьчә фикерләү көчен, шигъри стилендәге музыкальлекне, бай табигый аһәңен ачып бирә.

Хезмәттә Дәрдемәнд иҗатында традицияләргә мөнәсәбәт мәсьәләсе дә күтәрелә. Ул шагыйрьгә «...Шәрыкның барлык табигый гүзәллекләрен җыйнап, Гаребнең иң соңгы нәфасәте илә артык зәвыкъ вә тәмийз үзәгенә киенмеш бер хури ки, карыйсың да, садәлек илә катышкан гүзәллекне күреп, хәйран каласың», – дип

бәя биреп, Г. Ибраһимов, гомумән, татар поэзиясенең тирән тамырлары Көнчыгышка да, Көнбатышка да киткән булуын ассызыклый (1, 97).

Дәрдемәнд поэзиясен анализлаганда автор «Кораб» шигыренә аерым урын бирә, чөнки бу шигырьдә, аныңча, шагыйрьнең иҗтимагый-сәяси идеалларының җимерелүе, 1905 ел революциясеннән соң килеп туган иҗтимагый шартларда, сәяси киләчәкне югалтып, аптырап калуы тулырак чагылыш таба.

«Татар шагыйрьләре»нең соңгы бүлеге Г. Тукай иҗатына багышлана һәм ул күләм ягыннан хезмәтнең яртысыннан артыграк өлешен алып тора.

Поэзиядәге урыннарын билгеләгәндә С. Рәмиев белән Дәрдемәндне алгы планга чыгарып, Тукайны алардан соң куюы да, ахыр чиктә, Г. Ибраһимовның мәсьәләгә романтик позициядән торып каравы белән бәйләнгән.

Ул, шигъриятне романтик рухта кабул итеп, С. Рәмиев белән Дәрдемәнднең лирик-романтик, фәлсәфи яңгырашлы иҗатын Тукайның реалистик поэзиясеннән өстенрәк күрә.

Гәрчә бу караш Г. Ибраһимовны Тукай иҗатын берьяклырак бәяләүгә китерсә дә, хезмәттә аның шагыйрь турында күп кенә кызыклы һәм нигезле күзәтүләре дә бар. Мәсәлән, Тукайның иҗат эволюциясенә игътибар итеп, ул иҗатының башлангыч чорында шагыйрьнең әле халык тормышыннан шактый ерак торуын, теленең дә киң катлау укучыга аңлаешсыз булуын искәртә. Әлеге күренеш шагыйрьнең ул вакытта шигъри традицияләргә нык бәйле булуы белән аңлатыла. Шунлыктан Тукай иҗатының бу этабын Г. Ибраһимов эчтәлеге һәм формасы буенча «Мөхәммәдия дәвере» дип атый.

Хезмәттә алга таба, халык тормышына һәм рухи ихтыяҗларына якыная баруы сәбәпле, шагыйрь иҗатының тизләтелгән үсеш алуы күрсәтелә.

Моннан тыш, Г. Ибраһимов Тукай поэзиясенең күп кенә мөһим сыйфатларын дөрес бәяли. Аерым алганда, татар халкының тормышында әле яшәп килгән патриархальлекнең һәм искелекнең Тукай әсәрләрендә көчле тәнкыйть уты астына алынуын әйтә. Бу өлкәдәге уңышлы әсәрләреннән аның «Ишан», «Могҗиза», «Ысулы кадимче», «Әнә-менә», «Бәгъзе зыялыларыбыз», «Хәзерге өйләнүчеләр», «Улмы? – Ул...», «Мәҗрух указ» исемле шигырьләрен атый.

Г. Ибраһимов Тукайның «Печән базары, яхут яңа Кисекбаш» поэмасына төпле анализ бирә. Кисекбаш образында «татарлыкның, гасырлар буенча җыелып килгән искелекнең, барлык каралык вә тәгассыбның» сатирик рәвештә гәүдәләнгән булуын күрсәтә.

Тәнкыйтьче Тукайның халык иҗатыннан файдаланып язылган «Шүрәле», «Су анасы» кебек әсәрләренең асыл сыйфатларын болай билгели: «Габдулла әфәнденең каләме татарлыкның тышкы сурәтен вә кабыгын гына сызгалап китми. Ул халыкның эченә, җанына да төшә, хыял вә әкият дөньясына да керә. Бунда килсә, аның язуларыннан аңкый торган татарлык исе бигрәк куера да, куәтләнәдер дә» (3, 148). Г. Ибраһимов Тукай иҗатында халык тормышының бик күп өлкәләре чагылуын ассызыклый.

Гомумән алганда, Г. Ибраһимовның «Татар шагыйрьләре» хезмәте узган гасыр башы татар поэзиясен фәнни анализлау һәм бәяләүдә беренче җитди адым була.

«Татар шагыйрьләре»ндәге кебек әдәбиятның күбрәк аурупача эстетик дәрәҗәсе яки сыйфаты турында кайгырту Г. Ибраһимовның башка кайбер фәнни-тәнкыйди чыгышларында да күзәтелә. Мәсәлән, «Альбом мөнәсәбәте белән бер-ике сүз» дип исемләнгән хезмәттә (1915) бу тенденция шактый ачык сизелә.

Бер үк вакытта Г. Ибраһимов бу хезмәтендә сәнгатьнең халыкчанлыгы, сәнгать әһелләренең халык мәнфәгатьләренә хезмәт итәргә тиешлеге хакында да уйлана һәм: «Сәнгатькярнең теләсә кайсы – шагыйрь вә әдип булсын, теләсә рәссам вә композитор булсын – халыкка мөнәсәбәтенең, халыкның аны үз итүенең, йөрәгенә якын алуының сере – иштә шул ике йөрәк арасындагы уртак тәэсирнең шул әсәрдә, шул рәсемдә, шул көйдә табигый вә ачык рәвештә тәҗәссем итүендә, сүз беләнме, рәсем беләнме – шуның гәүдәләнә алуында; тагы ачыграк әйткәндә, сәнгатькяр йөрәгеннән халык йөрәгенә тугрыдан-туры юл салынуындадыр» – дип яза (1, 180).

XIX гасырдан татарларның башка халыклар белән ныклап аралашу юлына басулары, табигый, аларның рухи-мәдәни мирасын өйрәнү бурычын да көн тәртибенә куя. Мәгълүм ки, Г. Ибраһимов бу өлкәдә башлап йөрүчеләрдән була.

«Яңа әдәбият» хакындагы тәнкыйтьләр мөнәсәбәте илә» дигән мәкаләсендә (1914) ул, мәсәлән, рус әдәбиятының үз эчендә берничә юнәлеш булуын искәртү белән бергә, бу әдәбиятка мөнәсәбәт, аңа эстетик караш белән чикләнмичә, социаль күзлектән дә карап, аңлы һәм планлы рәвештә өйрәнү һәм кабул итүдән гыйбарәт булырга тиеш, дигән нәтиҗәгә килә.

«Каһарман шагыйрь» мәкаләсендә (1914) украин халкының атаклы шагыйре Тарас Шевченко турында сүз алып барганда Г. Ибраһимов аның, барыннан да элек, хөррият каһарманы, патша самодержавиясе тарафыннан изелгән һәм кимсетелгән халыкның тарихи идеалларын җырлаучы булуына басым ясый. Тәнкыйтьче каһарман шагыйрьнең һәм, гомумән, украин халкының язмышында безнең халыкныкына зур якынлык күрә. Шуңардан чыгып, Т. Шевченко иҗатын өйрәнүнең татар әдәбияты өчен зур әһәмияткә ия булуын әйтә.

«Мөгаллимә»нең Уфада уйналу мөнәсәбәте белән» мәкаләсендә (1915) Г. Ибраһимов башта Г. Исхакыйның моңа кадәр булган иҗатына тукталa. Ул аны, идея бөтенлегенә ирешә алмаган, шунлыктан төрле темаларга ташланучан автор, дип бәяли. Алга таба Г. Исхакыйның «Тормышмы бу?», «Шәкерт бабай» повестьларын, «Мәдрәсә җимеше» хикәясен хәтта порнографиягә бирелүдә гаепли. «Мөгаллимә»не ул әдипнең «әдәби вә рухани йөзен» тагын бер мәртәбә бозган әсәр, дип карый.

Әдәби әсәрнең кыйммәтен билгеләүдә Г. Ибраһимов реализм яссылыгыннан чыгып бәяләүне өстен күрә. Күп кенә тәнкыйтьчеләр «Мөгаллимә»не әдип идеалын чагылдырган романтик әсәр дип исәпләсәләр, Г. Ибраһимов аңа реалистик әсәргә куела торган таләпләрдән чыгып бәя бирә. Ул романтик рухта язылган бу пьеса герое Фатыйма образында «хакыйкый мөгаллимә язмышына гаид *(бәйләнешле)* бер ишарә дә» күрми. «Хәятның көзгесе була алмаган» бу пьесаның «әдәби вә иҗтимагый кыйммәте....нольгә якын» дип фараз кыла Г. Ибраһимов. Мәкаләсенең ахыр өлешендә автор А. Пушкиннан: «Әсәрне, мөхәррирне тәнкыйть өчен, иң элек, аның үзенең әдәбиятта нинди кануннарны рәһбәр *(юл күрсәтүче)* итә иканен белергә, соңра

шул кануннар мизаны *(бизмәне)* белән үлчәргә кирәк», – дигән сүзләрне китерә. «Мөгаллимә»гә бәя биргәндә Г. Ибраһимов бу акыллы фикерен оныта, Г. Исхакыйның бу әсәрендә нинди максат куюы белән кызыксынмый, аны үзе теләгәнчә бәяли. Ул татар мөгаллимәләре турында әдәбиятта беренчеләрдән булып сүз әйткән әлеге пьесада аларның җәмгыятьтә борчу уятырлык реаль тормышын күрергә тели. Шуңа өстәп, Г. Исхакыйның еш кына татар әдипләрен чын тормыштан алып язарга чакыруын да искә төшерә. Г. Ибраһимов «әдәбияттагы реализмның бердәнбер әһәмиятен» түбәндәгечә билгеләли: мөхәррир «үзенең тугры тасвиры белән тормышның авыр җәрәхәтеннән бүген укучы алдына ачып салып, халыкны шул хакта уйларга, авыр язмышны җиңеләйтү турында чаралар күрә башларга, һич булмаса, шуны бер мәсьәлә итеп мәйданга салырга мәҗбүр итсен!» Г. Ибраһимовның нияте изге булса да, аны башкаларга көчләп тагарга тырышу, авторның үз максатын санга сукмау, әлбәттә, үзен акламый. Шул ук вакытта Г. Ибраһимовның әдәбияттагы реализмны тарайтыбрак аңлатуы да күренә.

Г. Ибраһимов татар әдәбият теориясен тудыру өлкәсендә дә башлап йөрүчеләрдән була. Аның бу юнәлештәге эзләнүләре һәм уй-фикерләре «Әдәбият дәресләре» (1916) һәм «Әдәбият кануннары» (1918) дигән хезмәтләрендә тулырак чагыла. Аларның беренчесендә автор үзенең әдәби әсәр нәзариясен тәкъдим итә. Ул «сәнгать әсәрендә үзәк – идея, әдәби әсәрнең һәр элементы идеягә бәйле сайлана һәм үзенчәлекле була» дигән карашка нигезләнә. Г. Ибраһимов фикеренчә, язучы теманы үзе әйтергә теләгән төп уйга бәйле рәвештә сайлаган кебек, әсәрне шул идеягә йөз тотып тудыра. Идеяне исә автор язучы иҗатын бербөтен итеп тотучы һәм һәр әсәреннән кызыл җеп булып сузыла торган лейтмотив итеп карый. Хезмәтнең икенче бүлеге әдәбиятның төр һәм жанрларга бүленеше мәсьәләләренә багышлана.

«Әдәбият кануннары»нда исә Г. Ибраһимов, рус-аурупа әдәбият теориясе казанышларына нигезләнеп, әдәбиятның барлык жанрларына, төрләренә кыскача билгеләмә һәм тарихи аспектта аңлатмалар бирә. Теоретик аңлатмаларын дөнья, рус һәм татар әдәбиятларыннан мисаллар белән ныгытып бара.

Хезмәттә авторның татар әдәбиятындагы юнәлешләргә, иҗат алымнарына, тел-стиль мәсьәләләренә карашы да чагылыш таба. Ул әдәбиятның тарихи-иҗтимагый роленә зур игътибар бирә. Эпик жанрларны характерлаганда реализм әдәбиятының үсешенә аеруча басым ясый.

Гомумән алганда, Г. Ибраһимовның 1917 елга кадәрге фәнни-тәнкыйди эшчәнлеге шул әдәби чор татар тәнкыйте һәм эстетикасының күркәм бер сәхифәсе булып тора.

ӘДӘБИЯТ


1. Ибраһимов Г. Әсәрләр. Сигез томда. V т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – 615 б.

2. Исхакый Г. «Мөгаллимә»нең Уфада уйналуы мөнәсәбәте белән // Әсәрләр. Унбиш томда. VIII т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – Б. 224–235.


## ГАБДРАХМАН СӘГЪДИНЕҢ ӘДӘБИ-ТАРИХИ ЭЗЛӘНҮЛӘРЕНДӘ ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ИҖАТЫ


***Ч. М. Гыйлаҗева** (Казан)*



Определенный вклад в изучение многогранного наследия Г. Ибрагимова внес его современник, коллега, ведущий литературовед 1920–30-х гг. Габдрахман Сагди. Исследования Сагди отличаются подробностью и конкретностью анализа. Ученый обращает внимание и на жанровое разнообразие, и на систему образов в творчестве Г. Ибрагимова, предлагает идейно-эстетический анализ его произведений, прослеживает литературно-мировоззренческую эволюцию взглядов писателя, изучает язык и стиль, четко определяет и новизну, и недостатки художественной манеры автора. Поиски Сагди являются началом системного и монографического изучения творчества Г. Ибрагимова.


Быел әдәби-гыйльми җәмәгатьчелек татар халкының зур әдибе, могтәбәр галим Галимҗан Ибраһимовның 125 еллык юбилеен билгеләп уза. Язучының мондый рухтагы беренче зур тантанасы 1928 елда үткәрелә. Мәгълүм булганча, 1927 ел Г. Ибраһимовның тормыш һәм иҗат биографиясендә ике яклап үзенчәлекле: беренчедән, аның әдәби иҗат белән шөгыльләнә башлавына 20 ел тула. Икенчедән, каты авыру сәбәпле, ул, әдәби-гыйльми мохитне юлбашчысыз калдырып, Кырымга китәргә мәҗбүр була. Менә шундый шартларда татар җәмәгатьчелеге зурлап, олылап, элеккеге Союз күләмендә Г. Ибраһимовның 20 еллык хезмәт бәйрәмен үткәрә. Татар Педагогия җәмгыяте каршында юбилей әзерлеге белән шөгыльләнүче махсус Дәүләт комиссиясе төзелә. Әлеге истәлекле датага әзерлек йөзеннән язучының әсәрләрен барлау, бастыру, әдәби иҗат юлын, филология, лингвистика һәм тарих фәнен үстерүгә багышланган хезмәтләрен өйрәнү мәсьәләсе планга куела. Дәүләт комиссиясе составында аның хезмәттәш дусты, фикердәше, әдәбият тарихчысы Габдрахман Сәгъди дә була.

Шушы уңайдан, матбугат битләрендә Г. Ибраһимовның әдәби эзләнүләрен өйрәнеп язылган күпләгән язмалар басыла. Алар арасында сан ягыннан да, тикшеренүләрнең гыйльми-нәзари дәрәҗәсе ягыннан да Г. Сәгъди каләменә туры килгәннәре үзенчәлекле урын алып тора. «Карт марксист, бөек әдип Галимҗан Ибраһимов һәм аңа юбилей хәзерлеге», «Зур әдипләребездән берсе (Аның 20 еллык хезмәте уңае белән)», «Егерме еллык әдәби хезмәтнең беренче адымында», «Галимҗан Ибраһимов һәм аның әдәби иҗатлары», «Галимҗан Ибраһимов иҗатында типлар эволюциясе» мәкаләләре белән галим 1920 нче еллар ахырында Г. Ибраһимов иҗатын монографик өйрәнүне башлап җибәргән дияргә дә мөмкин.

Беренче язмада Г. Сәгъди, исеменнән үк аңлашылганча, нәкъ менә юбилейга әзерлек эшләренең торышы, алга куелган максат-бурычлар, эшләнәсе эшләр белән таныштыра. Барлык хезмәт ияләрен, укытучыларны, укучыларны Г. Ибраһимовның хезмәт бәйрәменә тиешле югарылыкта әзерләнергә чакыра (2).

«Зур әдипләребездән берсе» мәкаләсен Г. Сәгъдинең Г. Ибраһимов иҗатына нисбәтле алда язачак күләмле монографик хезмәтләренең план-проспекты төсендә кабул итәргә мөмкин. Анда ул Г. Ибраһимовның 20 ел эчендә алып барган төрле төрдәге (әдәби, гыйльми, иҗтимагый, мөгаллимлек һәм дәүләт органнарындагы) эшчәнлекләрен кыскача анализлап үтә. «Чынында Галимҗан әле бездә ныклап тикшерелергә башланмаган тирән һәм гаять катлаулы бер сәнгать хәзинәсе булып тора» (3), – дип яза галим йомгак ясап һәм моның белән Ибраһимов иҗатын төрле яклап, тирәннән тикшерә башлау, яшь язучыларга аннан әдәби осталыкка өйрәнү вакыты җиткәнен билгели.

Г. Сәгъдинең югарыда телгә алынган язмаларыннан «Галимҗан Ибраһимов һәм аның әдәби иҗатлары» (5) исемендәгесе аеруча әһәмияткә ия. Ул 1928 елда юбилей мөнәсәбәте белән дөнья күргән «Галимҗан Ибраһимов» гыйльми-тәнкыйди җыентыгына кертелгән. (Бу мәкаләнең русча варианты «Татарларны өйрәнү» фәнни җәмгыяте чыгарып килгән журналда басыла.) Әлеге гыйльми хезмәтендә Г. Сәгъди әдипнең тормыш юлын һәм күпкырлы эшчәнлеген киң яктырта, сәнгатьтә үсәкамилләшә баруын күздә тотып, язучының иҗатын өч этапка бүлеп тикшерә, һәр чорын карауга аерым-аерым тукталa. Дүрт бүлектән торган хезмәтнең беренче өлешендә Г. Ибраһимовның тормыш һәм иҗат баскычлары барлана, икенчесендә язучы иҗатына, әдәби-эстетик зәвыгы, иҗтимагый карашлары формалашуга турыдан-туры тәэсир иткән «мохит» һәм «заман» мөнәсәбәте өйрәнелә.

Өченче бүлектә әдипнең иҗат эволюциясе тикшерелә. Биредә Г. Ибраһимовның 20 еллык иҗаты тарихи үсештә карала, өч период аерылып чыгарыла: 1907–1910, 1910–1916 еллардагы һәм Октябрь инкыйлабыннан соңгы чор. Дүртенче бүлек заманы өчен өр-яңа мәсьәлә күтәрүе белән игътибарга лаек. «Галимҗан иҗатында эчке рухи яклар» дип тамгаланган әлеге өлештә язучы әсәрләрендәге психологик сурәтләү алымнары өйрәнелә. Галим әдипнең оста сәнгать каләме белән татар тормышының һәр төрле катлавын сәнгатьле итеп сурәтли алуы, татар тормышыннан алынган бик күп төрле типлар бирүе турында яза. Г. Сәгъдинең бу тикшеренүләре Э. Галиеваның «Татар әдәбият белемендә культура-тарих мәктәбе» монографиясендә дә җентекле анализлана.

1928 елгы «Мәгариф» журналының 2 нче санында дөнья күргән «Галимҗан Ибраһимов иҗатында типлар эволюциясе» (6) исемендәге эзләнүләр шулай ук оригинальлеге белән аерылып тора. Биредә Г. Сәгъди әдипнең иҗат психологиясе турында сүз алып бара, «Г. Ибраһимов иҗатында байтак типларның иҗтимагый-фикри эволюция кичерүләре, бер үк төрле типларның әдипнең төрле әсәрләре аркылы фикердә, дөньяга караштa баскычлап үсә, үстерелә баруы» турында яза. Анализ үзәгенә «Безнең көннәр» романыннан Давыт Урманов тибы чыгарыла. Моның өчен галим түбәндәге математик формуланы тәкъдим итә: Зәки + Сәлим = Давыт Урманов. Ягъни Давыт Урманов ул – Г. Ибраһимовның тәүге әдәби әсәрләреннән – «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы»ндагы Зәки һәм «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә», «Яшь йөрәкләр»дәге Сәлим образларының кушылмасы, дәвамчысы, «шул баскычларны үтеп, бер ноктага утырып алган иҗтимагый-психологик бер тип». Иске фикерле мәдрәсә шәкерте Зәкидән «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә»дәге башта – «милләтче», соңрак «халык хадиме»нә әверелгән Сәлим тибына таба хәрәкәт күз алдына бастырыла. Г. Сәгъди бу образның әзер килеш, «билгесезлек битлеге» кигән, тормышта үз урынын таба алмаган Сәлим йөзендә «Яшь йөрәкләр» романында гәүдәләнүен күзәтә. Әлеге романда Сәлимнең гомере фаҗига белән тәмамланса да, галим аның күләгәсен Давыт тибында таба. Давыт Урманов образын хәрәкәттә, Зәки, Сәлим үткән баскычлардан үтүен чагыштырма планда укучыга тәкъдим иткәннән соң, әдәбият белгече үзе билгеләгән формулага әйләнеп кайтып, түбәндәге нәтиҗәне ясый: «Шулай итеп, Давыт озын бер фикри эволюция уздырган акыллы, “тирән уйлы, киң карашлы”, батыр һәм нык ирекле бер “рухи” тип булып эшләнеп чыккан була».

Г. Сәгъдинең Г. Ибраһимов иҗатын өйрәнүгә кагылышлы хезмәтләре моның белән генә чикләнми. Югарыда телгә алынганнары – галимнең юбилей мөнәсәбәте белән басылган язмалары. Әдәбият галименең болардан алда, 1926 елда дөнья күргән «Татар әдәбияты тарихы» (1) китабында әлеге язучы иҗатын анализлауга шактый зур урын бирелә. Әдәби әсәрләргә идея-эстетик, проблемалы-тематик анализ, образлар системасы, әдипнең иҗат методы, тел-өслүб үзенчәлекләре һәм башка мәсьәләләр аша укучыларны Г. Ибраһимовның XX йөзнең беренче чирегендәге әдәби иҗаты белән таныштыра. Г. Сәгъди язучы иҗатының әдәби-фикри эволюциясен түбәндәгечә аңлата: «Ул яңа фикерле шәкертнең иске тәрбия, схоластикага, иске мәдрәсәләргә каршы көрәшеп куылулары белән башлап, гаилә тартышлары, аталар белән балалар арасындагы көрәшләр эченнән барды да, хезмәт халыкларының гомуми иҗтимагый азатлык юлындагы көрәшләре белән тәмам итте».

Г. Сәгъди әлеге язучы каләменә туры килгән сәнгать әсәрләренең һәрберсенә тукталырга тырыша, кыскача аңлатмалар бирә, әсәрләр арасында параллельләр уздыра, һәр әсәрнең үзенчәлеген билгеләргә омтыла. Мәсәлән, «Табигать балалары»н галим сәнгатьчә эшләнеше ягыннан иң камил әсәрләрдән саный: «әдипнең бу әсәре теле-өслүбе ягыннан да, тасвиры ягыннан да татарның сүз сәнгате дөньясында иң табигый, иң матур классик бер әсәр булып чыкты. Бу әсәр сүз һәм фикердә, тасвирда икътисад канунының да ачык бер үрнәге булып калды».

Г. Сәгъди Г. Ибраһимов иҗатының йөзен билгеләрлек әсәрләрен тәфсилләп анализлый. «Безнең көннәр», «Казакъ кызы», «Яшь йөрәкләр», «Кызыл чәчәкләр» әсәрләрен тикшерүгә иң күп урын бирелә. Галимнең барлык әдәби-тарихи эзләнүләренә хас булганча, монда да үз фикерләрен әдәби тәнкыйтьтә урын алган башка авторларның бәя-хөкемнәре белән үреп алып бара. Югарыда саналган әсәрләрне өйрәнгәндә Г. Газиз, Җ. Вәлиди, Х. Кәримов, Ф. Сәйфи-Казанлы, Г. Рәхим, С. Җәлал, рус тәкыйтьчеләреннән М. Павлович кебекләрнең фикер, карашларына мөрәҗәгать итә, үз бәяләрен аларның язмаларыннан

цитаталар белән дәлилли, моның белән объективлыкка омтыла.

Әдәбият тарихчысының романтик сентименталь әсәр буларак бәяләгән «Яшь йөрәкләр» романын образлар системасы, геройлар арасындагы мөнәсәбәт, каршылыкларны билгеләү аша үткәргән анализы игътибарга лаек. Иҗат методы ягыннан да Г. Ибраһимов әсәрләре арасында үзенчәлекле яссылыкта торган бу әдәби ядкарьнең яңалыгын Г. Сәгъди башка нокталарда да таба: «Бердән, бу роман аркылы татарда беренче мәртәбә авыл тормышы, авыл яшьләренең хәрәкәте киң сызыкта матур әдәбиятка мөндәриҗә итеп алынды. ... Икенчедән, монда вакыйга һәм нәрсәләр турындагы фәлсәфи карашлар, эчке рухи дулкыннар (бигрәк тә романтизм дулкыннары) яхшы ук киң бер алым белән бик оста тасвир ителде». Моның белән галим язучы иҗатында психологизм мәсьәләсен күтәрә.

Әдәбият тарихчысы Г. Ибраһимов әсәрләренең уңышы, уңай яклары белән бергә, кимчелекләрен, җитешсезлекләрен дә билгеләп бара. «Безнең көннәр» романын сюжетта вакыйгаларның бәйләнеп җитмәве, таркаулыгы, кабатланулары өчен тәнкыйтьләсә, «Яшь йөрәкләр»нең төп җитешсезлеген авторның геройларга сыйфатламаларны үзе сөйләп, күрсәтеп бирүендә күрә: «Чын шигъри әсәрләр өчен бу хәл җитешлелек түгел, әлбәттә, каһарманнарның характеристикалары аларның үз эшләре, итенеш-кыланышлары, хәрәкәтләре, башкалар белән мөгамәләләре, сүзләре аркылы үз-үзеннән беленеп торырга; укучы аларның характеристикаларын, аларның шушы хәлләреннән үзе чыгарып алырга тиеш». Бу урында шуны әйтеп үтәсе килә: Г. Сәгъди сәнгатьнең бер төре булган матур әдәбият әсәрләренең сәнгатьчә эшләнешенә аеруча зур таләпләр куя. Социологик анализ методы беренчел саналган заманда да ул әдәби әсәрнең формасына, эстетик һәм эмоциональ тәрбияви көченә игътибарын киметми. Шуңа күрә дә, Г. Ибраһимовның әдәби иҗатындагы икенче чорны ул пролетариат диктатурасы дәверендәгесеннән югары куя һәм хаклы рәвештә «Галимҗан Ибраһимовның 20 еллык әдәби иҗат эшчәнлегендә икенче чорның иң әһәмиятле бер хосусияте аның бу чордагы сәнгать иҗатлары һәр яктан аны татарның бөек әдибе, оста бер сүз сәнгатьчесе итеп танытырлык дәрәҗәдә югары булуындадыр» дигән нәтиҗә-хөкем чыгара (киләчәктә нәкъ шушы фикерләре өчен Г. Толымбай тарафыннан тәнкыйтьләнә).

Күзәтүләрдән чыгып, шуны әйтергә мөмкин. Г. Сәгъди Галимҗан Ибраһимов иҗатын тарихи планда тикшерә, аның әдәби-фикри эволюциясен, мирасын системалы һәм комплекслы өйрәнү юлын алга куя. Әлеге язучы иҗатын монографик өйрәнү эшен дә башлап җибәрә, киләчәктә язылачак әдәбият тарихы хезмәтләре өчен аның күпсанлы язмалары бай чыганак ролен үти.

ӘДӘБИЯТ

1. Сәгъди Г. Г. Татар әдәбияты тарихы. – Казан: Татарстан дәүләт нәшрияты басмасы, 1926. – 300 б.

2. Сәгъди Г. Г. Карт марксист, бөек әдип Галимҗан Ибраһимов һәм аңа юбилей әзерлеге // Мәгариф. – 1927. – № 12. – Б. 94–98.

3. Сәгъди Г. Г. Зур әдипләребездән берсе (Аның 20 еллык хезмәте уңае белән) // Кызыл Татарстан. – 1927. – 25 октябрь.

4. Сәгъди Г. Г. Егерме еллык әдәби хезмәтнең беренче адымында (Бөек әдип Галимҗан Ибраһимовның егерме еллык юбилеен ясау мәсьәләсе кузгалу уңае белән) // Кызыл Татарстан. – 1927. – 20 ноябрь.

5. Сәгъди Г. Г. Галимҗан Ибраһимов һәм аның әдәби иҗатлары // Галимҗан Ибраһимов. – Казан: Татарстан дәүләт нәшрияты, 1928. – Б. 13–47.

6. Сәгъди Г. Г. Галимҗан Ибраһимов иҗатында типлар эволюциясе // Мәгариф. – 1928. – № 2. – Б. 24–33.

# ФАЗЫЛ ТУЙКИН ШИГЫРЬЛӘРЕ ТУРЫНДА ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ

*Э. М. Галимҗанова (Казан)*

В данной статье рассматривается отношение Г. Ибрагимова к стихам Ф. Туйкина, включенным в хрестоматию «Яңа әдәбият» («Новая литература») (составители: Г. Ибрагимов и Г. Баттал).

XX йөз башы татар поэзиясе тарихында Фазыл Туйкин иҗаты билгеле урын алып тора. Гасыр башы татар әдәбиятын үстерүгә күп көч куйган әдип тәүге шигырьләрен 1906 елда «Фикер» газетасында бастыра башлый. Унынчы-егерменче елларда исә, яшь шагыйрь үзен «Шура», «Идел» кебек мәшһүр газета-журнал битләрендә таныта. 1911–14 елларда Уфа каласында «Хәкимия» мәдрәсәсендә мөгаллимлек иткәннән соң, бар гомерен туган ягы Татарстанның көнчыгыш районнарында (Лениногорск, Әлмәт, Бөгелмә районы мәктәпләрендә) балалар укытуга багышлый. Талантлы әдип гомере буе, әлбәттә, татарларның гыйльми үзәге булган Казанга килеп урнашырга өметләнеп яши. Әмма сигез кешелек зур гаиләне туендыручыга башкалага күченү зур хыял гына булып кала.

Яшь шагыйрьнең газета-журналларда басылган әсәрләрен җәмәгатьчелек бик тиз күреп ала һәм үз итә.

Фазыл Туйкинның шигырьләренә беренчеләрдән булып югары бәя бирүче галим – Галимҗан Ибраһимов була. Ул 1914 елда Г. Баттал белән берлектә мәктәп балалары өчен төзелгән «Яңа әдәбият» дәреслегенә Ф. Туйкинның берничә шигырен урнаштыра. Китап басылып чыккач, әлбәттә, җәмәгатьчелек арасында төрле фикерләр туа. «Вакыт» һәм «Ил» газеталарында «китапның яртыдан күбесе бер-ике кешегә хәсыр ителгән» (9), яисә, «материал, әдәбият галәмендә үзләренең исемнәрен танытып, “чын әдип” исемен алырга хаклы булып, киләчәктә әсәрләрен оныттырмаслык дәрәҗәдә азмы-күпме әдәбиятка хезмәт иткән язучыларның әсәрләре эченнән сайланырга тиеш» (7) кебек фикерләр дә була. «Ил» газетасының яңа әсәрләр рубрикасында басылган «Яңа әдәбият» мәкаләсендә Гали Рәхим: «“Яңа әдәбият”ны актарып карасагыз, сез аның эчендә нинди-нинди генә ишетелмәгән исемнәр очратырсыз: Ш. Әхмәдиев, Фазыл Туйкин, Хәлим

Искәндәров, Х. Атлаши, Шәммаси, К. Хәмәдев... соң болар кемнәр? Һәммәсе – моңа кадәр тәнкыйтьчеләр тарафыннан булсын, әдәбият укучылар тарафыннан булсын – "Бу татар әдибе, бу татар шагыйре" дип утыртылып куелмаган, әле һаман да шул гәзитә һәм журнал битләрендә калтырый торган яшь каләмнәрен сынаучылар», – дип, тискәре мөнәсәбәтен белдерә. «Әлбәттә чын әдип булмаган кешенең дә тырышып, гомерендә бер тапкыр матур әйбер язып ташлавы мөмкин. Ләкин аның өчен генә ул кешегә әдип исемен тагып булмый бит!» – ди ул (7). Әлеге тәнкыйть мәкаләләренә, аеруча Гали Рәхимгә җавап итеп, «Яңа әдәбият» төзүчеләреннән Г. Ибраһимов имзасы белән «Йолдыз»ның 1914 елгы 28 декабрь (1337) санында «"Яңа әдәбият" хакындагы тәнкыйтьләр мөнәсәбәте илә» дигән мәкаләсе басыла. Әлеге язмадан соң, «Ил»дә Г. Рәхим янә, «Тәнкыйть мөнәсәбәте илә язылган мәкаләгә җавап урынында» исемле мәкалә белән чыгыш ясый (6).

Г. Ибраһимов югарыда телгән алынган мәкаләсендә «Вакыт»та дөнья күргән «бер-ике кешегә хәсыр ителгән» сүзләренә җавап итеп түбәндәгеләрне китерә: «Без бу сүзне аңламадык, – ди ул. – Менә беренче баб. Башлана Тукай белән. Аның артында Сәгыйть Рәмиев, [...] Гафури, Укмаси, Фатих Әмирхан, Чыгтай, Әхмәдиев вә Туйкиннардан алынган бер вә берничәшәр әдәби парчалар тезелешеп баралар.

Ачыйк икенче бабны. Башында Фазыл Туйкинның "Җәй"е тора. Аның соңында [...]Гафури, Тукай, Закир Һади, Укмаси, Фатих Кәрими, Зыя Ярмәкиләр тезелеп китәләр.

Карыйк өченче, дүртенче бабларны. Боларда шул югарыгы исемнәр өстенә Заһид Нуркин, Г. Газиз, Г. Шәрәф, Г. Гыйсмәти ... вә башкалардан алынган парчалар кертелгән». Алга таба: «...бу әсәр бер-ике кешегә хәсыр кыйлынмаган, бәлки егермедән артык язучыларымызның мәктәп сыйныфында укытырга ярарлык һәм җиңел аңлашырлык табылган әсәрләреннән тәшкил ителгән», – дигән фикерне җиткерә (4, 170).

«Яңа әдәбият»ның кереш сүзендә үк Г. Ибраһимов «Яңа әдәбиятымызны мөмкин кадәр киң рәвештә кертү өчен, әсәрләре журнал вә гәзитә битләрендә калган мөхәррирләр дә алынды», – дигән аңлатма биргән була (3, 2). Г. Рәхимнең «Искәндәров, Туйкин, Шәммаси, Атлаши – болар кемнәр?» дигән соравына каршы чыгып: «Менә бу сөальне көлми укырга мөмкин түгел! Теләсә кем булсыннар, анысы безгә ник кирәк? Әсәрләре алдымызда, тәнкыйть итәчәк булсак, исемнәренә бәйләнергә түгел, язуларын укырга да, ярыймы, дәрес китабына кертерлекме – шул ягын карап хөкем чыгарырга кирәк. Шәммаси, Хәмәдев, Атлаши, Туйкин – болар кемнәрдер, мин аларны үзем дә белмим, ләкин әсәрләрен гәзитә вә журналларда укып яратканмыз, хәтеремездә калган – тәртип вакытында яңадан актарып чыгаргач, муафикъ табылган. Безгә аларның кем булулары мөһим түгел, әсәрләре кирәк. Шул әсәрләре эчендә мәктәпкә ярарлык парчалар кирәк!» – дип, яңа танылып килүче шагыйрьләрнең әсәрләрен күтәрә. Фазыл Туйкинның шигырьләренә аерым тукталып: «Туйкин кемдер – ул безгә караңгы..., ләкин аның хрестоматиягә кергән "Сабанчы карт"ы һәм "Җәй"е сыйныфта шәкерт кулына бирер өчен шундый гүзәл нәрсәләр ки, болар тузан арасында калган булса, мәшәкатенә карамый, эзләп алынырга тиешләр иде», – дип язып чыга. Хәтта Г. Тукай шигырьләренә тиңләп: «Тукайның "Авыл"ы шәкерт кулына ничек рәхәтләнеп бирелсә, Туйкинның бу ике мәнзумәсе дә шул дәрәҗәдә сокланып дәреслеккә кертерлектер», – ди. Алга таба фикерен дәвам итеп, «Бик мәшһүр исемнең гомер буена чүбек сатуы, әмма биш-ун кешегә генә мәгълүм бер куәтнең язган бер-ике бит нәрсәсенең саф алтын булуы бик тә мөмкин» икәнен искәртә (4, 176–177).

Г. Ибраһимовның Ф. Туйкин шигырьләрен «Яңа әдәбият» ка кертүе һәм мәкаләләрендә шигырьләренә югары бәя бирүе аның алдагы иҗат юлында да төп ышаныч һәм терәк була. Ф. Туйкинның шигырьләре мәшһүр язучыларның әсәрләре белән бер рәттән төрле-төрле дәреслек, җыентыкларга урнаштырыла. Мәсәлән: Көйле әсәрләр (1922) (5); Шигырьләр (1922) (9); З. Салихи. Мәктәпкәчә тәрбия (1923) (8) һ. б.

Мәшһүр галимебез Миркасыйм ага Госманов исә, Фазыл Туйкин шигырьләренең утызынчы елларда чит илләрдә дә билгеле булуын әйтә. Ул аларның Кытайдагы Голҗа шәһәрендәге татар җәмгыяте тарафыннан Хөсәен Таранов типографиясендә басылган «Туган тел» дәреслегенә кертелүен һәм шул дәреслектән аларны укып, бик яратканын, хәтта яттан сөйләп йөрүен искә ала (2, 154; 1, 8). Тик яраткан әсәренең авторын белмичә «яшьтән үк нигездә Тукай шигърияте белән тәрбияләнгән, әйбәт шигырьләрне "бары" Тукай гына язган булырга "тиеш" дигән кебегрәк иманга ияргән бала буларак, әсәр ахырында автор исеме сыйфатында куелган "Ф. Т." инициалларын «Г. Т.» урынына ялгыш басылган хата кебегрәк кабул итеп йөргән». М. Госманов фикерен дәвам итеп: «1960–62 елларда элеккеге басмаларыбыз белән якыннан танышкач, әлеге серле "Ф. Т." артында Фазыл Туйкин дигән кеше торуын, аннары әлеге "Ямьле җәй" шигыренең – шедеврлардан булган әсәрнең – төрле хрестоматия-дәреслекләргә кертелүен, өстәвенә Октябрьгә кадәр үк Галимҗан Ибраһимов тарафыннан бик югары бәяләнүен белү бәхетенә ирешкән идем», – дип яза (1, 9).

Кызганычка каршы, Фазыл Туйкин да, күп кенә язучыларыбыз кебек, утызынчы еллар сәясәте корбаны була. Нахакка рәнҗетелеп, исеме – тарихыбыздан, иҗаты әдәбиятыбыздан сызып ташлана.

ӘДӘБИЯТ


1. Госманов М. Демократик рухлы язучыларыбыз // Бертуган Туйкиннар: тарихи-документаль җыентык / Төзүче-автор: Э. Ханнанова-Галимҗанова. – Казан: Рухият, Җыен, 2007. – Б. 5–15.

2. Госманов М. Гыйбрәтле язмышлар // Бертуган Туйкиннар: тарихи-документаль җыентык / Төзүче-автор: Э. Ханнанова-Галимҗанова. – Казан: Рухият, Җыен, 2007. – Б. 153–154.

3. Ибраһимов Г., Баттал Г. Яңа әдәбият. (Урта мәктәпләр, курслар, семинарияләр һәм мәдрәсәләр өчен). Өченче басма, икенче китап. – Казан: Сабах, 1918. – 224 б.

4. Ибраһимов Г. «Яңа әдәбият» хакындагы тәнкыйтьләр мөнәсәбәте илә // Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. V т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. –Б. 170–177.

5. Көйле әсәрләр (Күчмә уку китабы, Икенче төп, дүртенче китап) (Ф. Туйкин, Ә. Сәгъди, Г. Тукай, С. Сүнчәләй, С. Рәмиев, М. Гафури, Б. Мирзанов, Тупал Тимер). – Казан: Татар социал шуралар җөмһүриятенең дәүләт нәшр.,1922. – 14 б.

6. Рәхим Г. Тәнкыйть мөнәсәбәте илә язылган мәкаләгә җавап урынында // Ил. – 1915. – 14 гыйнвар.

7. Рәхим Г. «Яңа әдәбият» // Ил. – 1914. –17 декабрь.

8. Салихи З. Мәктәпкәчә тәрбия. – Казан: Татарстан матбугат нәшрият комбинаты басмасы, 1923. – 41 б.

9. Шигырьләр (Күчмә уку китабы, беренче төп, унбишенче китап) (Думави, Укмаси, Сүнчәләй, Ф. Туйкин, М. Гафури, С. Рәмиев). – Казан: Татар социал шуралар җөмһүриятенең дәүләт нәшр., 1922 – 16 б.

10. *** («Яңа әдәбият» – Г. Ибраһимов вә Г. Баттал әфәнделәр тарафыннан тәртип ителгән...) // Вакыт. – 1914. –28 ноябрь (1642 нче сан).

# Г. ИБРАҺИМОВ ТӘНКЫЙТЕНДӘ ДӘРДЕМӘНД ИҖАТЫ

*Н. М. Йосыпова (Казан)*

Статья посвящена изучению труда Г. Ибрагимова «Татар шагыйрьләре», где на материале творчества С. Рамиева, Дэрдменда, Г. Тукая исследуется проблема образности, стиля татарской поэзии начала XX века. В книге, поднимающей проблемы поэта и поэзии, народности и национального своеобразия в художественной литературе, разрабатывая критерии эстетичности, определяя функции литературы, категории красоты, Г. Ибрагимов особое внимание уделяет особенностям образности в творчестве Дэрдменда. На основе трансформации системы образов и символов, стиля выявляется своеобразие его лирики, определяются национальные традиции и новшества.

XX йөз башы милли сүз сәнгате, тәнкыйди фикере тарихында Г. Ибраһимов иҗаты үзенчәлекле урынны били. Шушы дәвер сүз сәнгатендә ул татар әдәбиятының идея-эчтәлеген, стилен яңарту омтылышы белән яна; гыйлем, мәгърифәт, тәрбия һәм әхлак мәсьәләләреннән иҗтимагый, сәяси, аеруча милли проблемаларга борыла, әдәби иҗат мәйданында романтизм юнәлеше мөмкинлекләрен киңәйтә; әдәби тәнкыйтьнең үсешенә, татар нәзарияте алгарышына зур өлеш кертә. Шуңа мөнәсәбәттә ул XX йөз әдәбият мәйданы әдәби тәнкыйтендә тирән эз калдырган әдип, күп мәкаләләре белән чыгышлар ясаган тәнкыйтьче, «милли әдәбият нәзариясенең нигезләрен эзләү юнәлешендә рухиятчеләр мәктәбенә нигез салучы»ларның берсе (4, 202) буларак бәяләнә.

Тәнкыйтьче-галимнең «тулысы белән 1913 елда дөнья күргән һәм Тукайның вакытсыз югалту кайгысын кичергән көннәрдә очраклы рәвештә Казан каласына килеп җиткән» «Татар шагыйрьләре» (3, 25) хезмәте XX йөз башы татар әдәби тәнкыйтендә үзгә сүз, борылыш кебек кабул ителә. Әлеге хезмәтендә Г. Ибраһимов шигырьне «шагыйрь рухының көзгесе» кебек билгеләп, әсәрдәге тормыш-чынбарлыкның ролен «хәятта булган бер вакыйга, бер күренеш тәэсире илә аның йөрәген ут ала, рухына ялкын тулып, күңеле ашкына» (5, 77–78) рәвешендә аңлатып, төп законны – рухиятчеләр мәктәбен хасил итәрлек үзәк кагыйдәне тәкъдим итә һәм аны нәзари яктан нигезли. «Татар шагыйрьләре», басылып чыгуга, әдәби җәмәгатьчелекнең игътибар үзәгенә алына: «Татар шагыйрьләре» циклыннан шагыйрь һәм шагыйрьлек сәләте, шигърияtнең торышы, поэзиянең сурәтләү объекты мәсьәләләрен эченә алган берничә мәкалә – Җ. Вәлидинең «Татар шагыйрьләре» (1), Н. Хәлфинның «1913 елда татар шагыйрьләре» (7, 11–12), Ф. Сәйфи-Казанлының «С. Сүнчәләй шигырьләре» (6, 8–14) – әдәби мәйданга чыга.

Романтик әдәбият һәм тәнкыйтьнең үрнәге булган «Татар шагыйрьләре» хезмәтендә Г. Ибраһимов, өч шагыйрь – С. Рәмиев, Дәрдемәнд, Г. Тукай иҗатларын тикшерү объекты итеп алып, шигырь һәм шагыйрь, назыйм һәм нәзым, матур әдәбиятның миллилеге, халыкчанлыгы, лирик әсәрләргә хас төп үзенчәлекләр, аның сурәтләү объекты, тел-өслүб, матурлык эстетик категориясе кебек әдәби, нәзари проблемаларны күтәрә.

Өйрәнү барышында Г. Ибраһимов Дәрдемәндне икенче урынга куя. Тәнкыйтьче игътибар үзәгенә шагыйрь иҗатының төп үзенчәлекләреннән булган образлылык һәм стиль мәсьәләсен ала. Нәкъ менә шушы ноктада ул шагыйрьнең әсәрләрен югары күтәрә, эстетик сыйфаты ягыннан күпчелек әдипләр иҗатына каршы куя: «Һәр җирдә аңкыган мәдрәсә исе белән тел кабалыгы, өслүб тупаслыгы шу дәрәҗәдә туйдыра ки, татар телен сөеп, аның эчендә аз булса да матур яза, нәзек хис итә, хыял вә тойгыларын яңа галәмнән алып, аны нәфис өслүбтә әйтә ала торган бер куәтне җанның табигый ихтыяҗы кебек эзли башлыйсың. ... Дәрдмәнднең "Кораб", "Без" һ. б. шигырьләрендә... яңа рух сизелә – мәдрәсә исе аңкымый, тупас та түгел, бәлки ниндидер мәдәнилек, чын каләм сәнгате, матур өслүб, җыйнак вә кыска тәкъбирләр күренә ...» (5, 97).

Г. Ибраһимов Дәрдемәнднең төп үзенчәлеге төсендә аның иҗатында символлар кулланылышын, югары образлылыкны аерып куя һәм аны шагыйрь стиле кебек билгели. Образлылыкка бәйләп, тәнкыйтьче шагыйрь лирикасына хас ике үзенчәлекне аера:

«1) Дәрдмәнднең шигырьләре сүзне сайлау, төзү, матлубны мөкәммәл аңлатып та, һичбер хәреф артык кертмәүдә шул дәрәҗәдә мөкәммәл ки, аларны укыганда сүзләр ничектер күзеңә дә чалынмый. Гүя ул, ниндидер бер сихерле куәт белән, әйтергә теләгән мәгънәсен йөрәгеңә турыдан-туры яра да сала... Алыйк "Кораб"-ны, "Без"не, "Өмидләр"не һ. б.

2) ... Ачык күренә ки, аның каләме табигатьтәге хәдисәләрнең тәгакыбе тәртибен бик нәзек аера һәм нәсердә мөшкил улырлык мәртәбәдә ифадә дә кыйла ала – җөмләләрнең төзелеше мәгънәләрнең төзелешенә тәмам-тәмам мөтәнасиб рәвештә бара» (5, 98).

Г. Ибраһимов Дәрдемәнд иҗатына хас иң төп үзенчәлек буларак охшату, чагыштыру, метафораларның еш кулланылуына игътибар итә: «...аның өслүбендә ...дәхи шундый сыйфатлар бар ки, һич булмаса, бер-икесен әйтеп китми мөмкин түгел. Иң әүвәл хәтергә килә аның тәшбиһләре. Бу аңарда бик еш очрый. Ул һәркайчан диярлек тәшбиһнең адатен төшереп калдыра. Шуның кебек, тегенең, моның сыман, шикелле, дайларны ул кертми, һәм шул аның мәгънәсенә зур куәт тә бирә, өслүбендәге матурлыкны тагын да бер мәртәбә арттыра да», – ди (5, 100). Шул рәвешле, Г. Ибраһимов 1913 елда ук Дәрдемәнд иҗатының төп үзенчәлеген – символларга таянып иҗат итү сыйфатын аерып билгели. Ул аны шагыйрь стиленең бер хасияте итеп күрсәтә һәм, шуңа бәйләп, стиленең тасвирый стиль булуын ачыклый.

Шулай ук аерым сүзләрнең янәшә килеп, сүзтезмәдә бөек мәгънәләр ирештерә алуын шагыйрь иҗатындагы образлылыкка бәйле чираттагы сыйфаты итеп аера, «аның аз сүз вә садә тәркибләр белән нинди бөек мәгънә вә нинди зур куәт аңлата алу» сәләтенә соклана: «…теләсә бөек вә чуалчык мәфһүмне шу дәрәҗәдә садә калыпка коп бирә алу җәһәтеннән булсын, теләсә шул бөек вә мөшкил мәфһүмне бик садә берничә сүз белән матур вә шагыйранә бәян итә алу ягыннан каралсын – һәрхәлдә, андый гаҗиб тәфәккере алдында да, ул өслүбе каршында да баш имәү мөмкин дәгелдер. Аңларга кирәк ки, шагыйрь тел вә каләм генә түгел – ул баш та, йөрәк тә» (5, 107). Күренә ки, тәнкыйтьче шагыйрьнең шартлы сурәтлелеген, төрлечә уку мөмкинлеге калдырылган символик образлардан файда-

лану осталыгын югары бәяли. Нәкъ шушы сыйфатын Дәрдемәнд иҗатының терәк баганасы, башкалардан үзгә сыйфаты итеп күтәрә.

Икенче яктан, Г. Ибраһимов Дәрдемәнд иҗатында стиль мәсьәләсенә туктала, стиль белән бәйләп, аһәң, аһәңлелек төшенчәләрен аерып ала: «Дәрдмәнднең өслүбендәге мусыйкыять *(аһәңлелек)* илә эшләнүе аз булган татар теле өчен хәрәттә калдырачак мәртәбәгә ирешкән табигый аһәңе хакында да сөкүт үзәренә кичәргә мөмкин түгел... Аның, укып килгәндә мәгънәнең ачыклыгы, ифадәнең мәфһүмгә мөтәнасиб вә табигыйлеге, сүз вә тәркибләрнең башка һичкемдә күрелә алмаган мәртәбәдә саф вә матур төзелеше өстенә, аһәң вә гармониясе илә шу дәрәҗәдә сихерләнәсең ки, вакыт-вакыт: "әллә мин маһир музыкант каршысындамы?" – дип шөбһәгә төшәсең» (5, 101). Г. Ибраһимов Дәрдемәнд шигырьләренең популярлыгын, камиллеген дә тел-стильгә бәйле аңлата.

Күзәтүләрдән күренгәнчә, Г. Ибраһимовның «Татар шагыйрьләре» хезмәтендә Дәрдемәнд иҗатындагы образлылык һәм стиль күренеше шактый эзлекле өйрәнелә. Ул татар халкының иҗтимагый фикере, милли үзаңындагы үзгәрешләр, яңарыш хәрәкәте, тел өлкәсендәге эзләнүләр, хис-кичереш үзгәрешләре һ. б. белән тыгыз бәйләнештә тикшерелә-бәяләнә. Г. Ибраһимов Дәрдемәнд шигырьләренең образлылыгына, сүзләр бәйләнешенә, тел-сурәтләү чараларына, стиль сыйфатларына игътибар итә. Шул үрнәктә Г. Ибраһимов шартлы образлылык, символик сурәт, язучы стиле, чор стиле, стиль төрләре (мәсәлән, тасвирый стильне аерып билгели) күренешләрен ачыклый, аларны фәнни нигезгә сала.

ӘДӘБИЯТ


1. Вәлиди Җ. Татар шагыйрьләре / Җ. Вәлиди // Вакыт. – 1913. – 25 апрель; 24 июль; 25 июль; 26 июль.
2. Гафиятуллина Н. XX гасыр татар шигъриятендә Тукай / Н. Гафиятуллина. – Казан: Матбугат йорты, 2002. – 152 б.
3. Гыйлаҗев Т. Әдәби мирас: тарих һәм заман / Т. Гыйлаҗев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005. – 206 б.
4. Заһидуллина Д. Әдәбият кануннары һәм заман / Д. Заһидуллина. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. – 271 б.
5. Ибраһимов Г. Татар шагыйрьләре / Г. Ибраһимов // Әсәрләр: сигез томда. 5 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – Б. 74–157.
6. Сәйфи-Казанлы Ф. Сәгыйть Сүнчәләй шигырьләре / Ф. Сәйфи-Казанлы // Аң. – 1913. – № 21. – Б. 8–14.
7. Хәлфин Н. 1913 нче елда татар шагыйрьләре / Н. Хәлфин // Аң. – 1914. – № 1. – Б. 11–12.


# ПОЭТИК ФИКЕРЛӘҮ ОСТАСЫ


***Ф. А. Абдуллина (Уфа)***



В сфере поэтики объединяются и лингвистический, и эстетико-стилистический, и литературоведческий, и иные искусствоведческие подходы к изучению структуры литературно-художественных произведений.
Поэтичность является одной из существенных индивидуальных черт стиля прозы Г. Ибрагимова. Такое заключение о таланте писателя относится, безусловно, и к его словоупотреблению. Об этом говорили его современники. Лиризм, поэтика у него от природного таланта, горячего, пламенного сердца, поэтических произведений, лирических песен, пословиц, прекрасных баитов, изучения высокохудожественных произведений И. С. Тургенева, Л. Н. Толстого и других писателей.


Поэтик фикерләү поэзиягә генә (шигырь, поэма) кайтып калмый. Академик В. В. Виноградов, мәсәлән, телдәге фонетик, морфологик, синтаксик, лексик-семантик, фразеологик, мелодик, ритмик һ. б. тел чараларын поэтикага кертә. Чыннан да, сөйләгәндә дә, язганда да, поэтик сөйләмгә аларның барысы да яраклаша. Һәр грамматик чара (кушымча, бәйлек, теркәгеч һ. б.), төрле лексик мәгънәдәге сүз, фраза, сурәтләү чарасы һ. б. поэтик сөйләмдә билгеле бер эстетик концепциягә китерелә. Поэтик формулаларда, барыннан да элек, аналитик фикерләүнең поэтик синтетиклашуы була.

Телдә шушы үзенчәлекне искә алмаган шагыйрь, язучы, драматург юктыр. Ләкин моның өчен һәр әдипнең үз маһирлыгы, хосусияты, егәрлеге бар. Образлы тел остасы Г.Ибраһимов хакында сүзне нәкъ менә шуннан башлыйсы килә. Әдипнең беренче өйрәнчек әсәрләре – «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» (1907–1908), «Гыйшык корбаннары» (1908), «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә» (1909) хикәяләре. Ләкин Г. Ибраһимовның иҗатын 1910 елда басылган «Яз башы» хикәясеннән башлау гадәткә кереп китте. Хикәя «мул», образлы, поэтик тел белән язылган. Бу үзенчәлек язучының зур тарихи вакыйга, иҗтимагый-сәяси, социаль хәлләрне чагылдырган «Безнең көннәр», «Тирән тамырлар», «Казакъ кызы» романнарында һ. б. әсәрләрендә дәвам итела. Яз чәчкән орлык көзен мул уңыш биргән кебек, әдәбият дөньясына «яз башы» белән аяк баскан әдипнең көзе уңышлы булды. Башта ук поэтик тел өчен көрәшә ул. Тәнкыйть мәкаләләрендә Ф. Әмирхан прозасына, Г. Тукай, М. Гафури поэзиясенә зур бәя бирсә, коры тел белән язылган З. Бәшири, М. Укмаси, Н. Думави әсәрләре өчен ачына. Димәк, ул үз әсәрләренең поэтик тел белән язылуына гына түгел, барлык татар әдәбиятының югары сәнгать таләпләренә җавап бирерлек булуы өчен көрәшә. Әдип, һичшиксез, үз максатына ирешә.

Г. Ибраһимов поэтикасы – стиленең бер үзенчәлеге. Ләкин поэтик телне «коры», «тышкы», «ялтыравыклы» матурлык өчен кирәк дип кенә уйларга ярамый. Әдип беренче хикәясендә үк, дулкынланып торган мул иген арасыннан зәңгәр чәчәк эзләп йөргән кеше кебек, «тышкы» матурлыкка «бай» булган сүзләргә генә табынмады. Гади сөйләм лексикасы, архаизм (иске сүз), неологизм (яңа сүз), поэтизм һ. б. – барысы бергә образлар тудыручы тел чаралары системасына диалектик яраклаштырылып, стилистик-эмоциональ функция үтәде. Икенче төрле әйтсәк, көнкүрештәге гади генә сүзләр дә Г. Ибраһимов әсәрләрендә поэтик яңгыраш тапты. Аның бер поэтик моделенең мәгънәсен аңлау өчен бөтен әсәрнең эчтәлеген белергә кирәк. «Безнең

көннәр» романында ул, мәсәлән, кар бәйрәме дигән поэтик тезмә куллана. Халык аны төрлечә әйтеп карый: «кар уйнаклый», «кыйгач кар ява», «кар буранлый» һ. б. Г. Ибраһимов исә үзенчә әйтә: «Күгелҗем төтен болыты белән капланган бүлмәдән килеп чыгуга, Булатны шундый матур дөнья, шундый ак кар бәйрәме урап алды. Ул бер ел Урал башкортларында торган иде. Уразгул атлы дәртле карт аучы аны чаңгыга өйрәтте. Зур таулар, карлы киң урманнар буенча үзе белән алып, җәнлеккә, куян, төлкегә, бүрегә сунарчылык өчен йөрүнең тәмен татытты». Димәк, кар бәйрәме кыш көне кар яугандагы революцион (вакыйга 1905елларда бара) Казан урамнары белән башкортлар яшәгән Урал буйларын бәйли. Ул роман героеның прототибы – революционер Х. Ямашевның эчке дөньясын, күңел түрендәге матурлыгын да, аның гади халыкка булган кешелекле, саф тойгысын да ачыклый. Поэтик яңгыраш та көчле, мәгънә дә тирән. Мондый поэтик фразаларны әдип әсәреннән бик күп китерергә мөмкин: ялкынлы яңгыр, аяз яңгыр, алсу нур, эссе ялкын, асыл ватан, матур могҗиза, тәмле роман һ. б. Боларның һәрберсе тирән анализ ясауны таләп итә.

Поэтик фикерләү белән публицистик фикерләүгә дә кыскача тукталыйк. Моның беренчесе – матур әдәбият, икенчесе публицистика стиле аша чагылыш таба. Беренчесендә – язучы кешенең уй-хисенә, йөрәк тойгысына, эчке дөньясына, икенчесендә аң-акылына тәэсир итү максатын куя. Соңгысында фикернең логик яктан дөреслеген күрсәтергә тырышыла. Чөнки анда төрле тарихи вакыйга, социаль-сәяси хәлләр хакында языла. Әмма зур фикерләр поэтик чаралар формасына төрелмәсә, әсәр сәнгатьлелек дәрәҗәсен югалта, коры була, укучы йөрәген хисләндерми, күңелен җылытмый. **Димәк, әдәби әсәр тукымасында матур әдәбият стиле белән публицистик стильнең үрелүе, аралашуы, «кочаклашуы» мөһим.** Тарихи темага язылган кайбер әсәрләрнең «салкын» чыгуы, укучы күңеленә юл таба алмавы публицистик стильнең өстенлек итүенә бәйләнгән дә. Г.Ибраһимовның «Безнең көннәр», «Тирән тамырлар» романы, «Кызыл чәчәкләр» повесте зур тарихи вакыйгаларны чагылдырсалар да, алар поэтик стильдә иҗат ителгән. Бу – сүзнең нәфисләнгән тоеп, төрле сурәтләү чараларының җанлылыгын, әдәби әсәрнең эстетик әһәмиятен аңлап яза белүдән килә. «Безнең көннәр» романының беренче битендә үк әдип «олы Россия диңгезендә күтәрелгән революция дулкыны» дигән поэтик тәгъбир куллана. Берничә фраза берләштерелеп, зур фикер синтетикалаштырылып бирелә. Олы Россия – бер фраза. Туган илне олылау, зурлау, хөрмәтләү төшенчәсе. Россия диңгезе – икенче поэтик фраза. Зурлык төшенчәсенең стилистик-экспрессив куәте арта. Аның эчендә халык массасы барлыгы сиземләнә. Революция дулкыны – өченче фраза. Бу массаның революцион көрәшкә ашкынганы аңлашыла. Күтәрелгән дигән сыйфат фигыль аларның эчке мәгънәсен конкретлаштыра. Бу киңәйтелгән поэтик формулага бөтен романның идея-эчтәлеге сыйган дияргә мөмкин. Ул, әлбәттә, әле диңгездәй киң олы Россиядә беренче рус революциясенең башлануына ишарә итә генә кебек. Әмма ул гына түгел. Романда вакыйга хәзерге Татарстан, Башкортстан җирендә бара. Ләкин язучы сүзне аннан башламый. Карашын әүвәл киң дөньяга ташлый. Үткәннәр хакында төпле аналитик фикер йөртеп, аннан гына конкретлыкка күчә. Бу поэтик фразага салынган мәгънә әсәрнең азагына хәтле бара.

Һәр сүз, фраза, җөмләне кәгазьгә төшергәнче әдип, нигездә, өч нәрсәне күз уңында тота: зур фикер, кыскалык, эмоциональлек. Шуларның комплексында образ туа. Димәк, поэтик формулалар аның өчен тышкы модификация түгел, ә бәлки зур фикерләрнең калыпка салынуы.

Г. Ибраһимов өйрәнчек хикәяләрендә абстракт сурәтләү чаралары, телнең тышкы күренешенә игътибар итү, матурлыкны матурлык өчен генә тасвирлау белән дә бераз мавыга. Вакытында ул моның өчен шелтәләнә дә. Романтик-Ибраһимовта ул әле һаман дәвам итеә. Реалист-Ибраһимов исә абстракт поэтик фикерләүдән котыла.

Сурәтләү чарасы, төрле поэтик бизәк (чагыштыру, метафора, эпитет һ. б.) куллануда да Г. Ибраһимов классик үрнәк күрсәтә.

ӘДӘБИЯТ


1. Виноградов В. В. Теория поэтической речи. Поэтика. – М.: Изд-во АН СССР, 1963.
2. Курбатов Х. Р. Татар теленең лингвистика стилистикасы һәм поэтикасы. – Казан: Мәгариф, 2002. – 199 б.
3. Поварисов С. Ш. Г. Ибраһимов стиленең үзенчәлекләре һәм аларны мәктәптә өйрәнү. – Уфа, 1974. – 163 б.
4. Сафиуллина Ф.С. Сүз иясе белән йөри. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1985. –Б. 40–45.
5. Татар грамматикасы. Т. I. – М.: Инсан; Казан: Фикер, 1998. – 510 б.
6. Хаков В. Х. Мәктәптә татар язучыларының тел үзенчәлекләрен өйрәнү. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. – Б. 89–95.


# ТАТАР ДАСТАННАРЫНЫҢ ХОСУСИЯТЕН БИЛГЕЛӘҮДӘ Г. ИБРАҺИМОВ КАРАШЛАРЫ


*Л. Х. Мөхәммәтҗанова (Казан)*



В статье представлены литературно-критические взгляды Г. Ибрагимова на фольклорное наследие татарского народа. Акцентируется внимание на том, что Г. Ибрагимов одним из первых в татарском литературоведении поставил вопрос о жанре дастана и дал ему научное обоснование.


Идел буе татарларында популяр дастаннарның иң зур күпчелеге кулъязмада һәм басма чыганакларда урын алган, теге йә бу дәрәҗәдә «авторлар» тәэсиренә юлыккан. Биредә дастан тексты, башка күп кенә халыклардагы кебек, тулы рәвешендә чичән-импровизатор тарафыннан башкарылмаган. Татар дастаннары тек-

стында фольклор башлангыч белән бергә индивидуаль иҗат башлангычлары да әһәмиятле роль уйный. Татар дастаннары, халык иҗаты әсәрләренә хас билгеләрне үзенчәлекле саклап, аерым шәхесләр, күчерүче-дастанчылар тарафыннан күпмедер дәрәҗәдә әдәби үзгәртү-эшкәртелүләргә дә дучар булганнар. Әдәбият һәм фольклор чигендә торган мондый язма истәлекләр китаби дастан категориясендә карала. Зур күләмле эпик истәлекләребезнең язма мәдәният белән тирән керешеп, дастан жанрының аерым бер тибын – китаби дастаннарны тәшкил итүен татар дастаннарының характерлы билгесе, төп үзенчәлеге дип тану – халкыбызның дастани мирасына объектив якын килү дигән сүз. Татар фольклористикасы тарихында XX йөз башында ук куелып, әле сүрелеп, әле катгый төс алып дәвам иткән «Татарда дастан бармы?» дигән фәлсәфи һәм сәяси сорауга аргументлы җавап буларак мондый концепция гаять мөһим.

Әлбәттә, татарлар – дастанлы халык һәм иң беренче чиратта китаби дастанлы халык. Идел буе татарлары халык иҗатының чын мәгънәсендә таҗы дип аталырлык әлеге гүзәл жанр әсәрләре һәм аларның төрле вариантлары үз заманы өчен бик тә популяр булган. Алар халыкның игътибарын бик нык җәлеп иткәннәр, бөек Тукай сүзләре белән әйткәндә, боларны «кечкенә чагында укып, җыламыйча үскән ирләремез вә хатыннарымыз сирәктер» (4, 279). Китаби дастаннар әллә ничә нөсхәдә кульязма вариантлар булып, соңрак басма китаплар рәвешендә гасырлар буе халыкның рухи ихтыяҗын канәгатьләндереп килгәннәр. Чичән-импровизатор тарафыннан башкарылып та, язып алынмый калган беренчел вербаль эпик текстлар белән чагыштырганда китаби дастаннарыбызның язмышы куанычлырак та, чөнки аларның шактые безнең көннәргә барлык тулылыгы белән килеп ирешкән, кайберләре хәтта безнең күз алдында диярлек китаби булып оешкан һәм аларны һәрьяклап фәнни өйрәнү мөмкинлеге дә зур.

Бездә татар халык дастанының жанр буларак өйрәнелү тарихы әллә ни озын вакыт аралыгын биләми. XX йөзнең егерменче елларында да әле татар әдәбиятында һәм фольклористикада ачык һәм аңлаешлы рәвештә «дастан» дигән жанрны аерып чыгару һәм аңа бәя бирү күзәтелми. Мондый төр ядкарьләребезнең хасиятләрен билгеләү принциплары шактый еллар фәнни кысаларга салынмый килгән.

Бүгенге көндә дастан жанрында карала торган әсәрләребезне «дастан» термины белән атау, бигрәк тә китаби дастан дип билгеләү шушы дастаннар халык арасында укылып-күчерелеп йөргән этапта булмаган һәм була да алмаган. XX йөз башында: «Бу кем китабы? Татар китабы. Бу – татарның бик искедән бирле укылып килгән әдәби китабы...», – дип язган Г. Тукай да (4, 27), бүген китаби дастаннар дип билгеләнә торган әсәрләребезгә игътибар иткән кайбер башка авторлар да (1) кульязма һәм басма дастаннарыбызны дастан категориясендә караудан ерак тора. Бу ул чорда татар филологиясендә күп кенә әдәби терминнарның әле ныгып урнашмаган булуыннан да килә. Хәлбуки жанр атамаларына ачык, төгәл билгеләмә бирү, жанр чикләрен билгеләү кебек проблемалар татар фольклористикасында әле бүген дә бар. Татар фольклорының үзенең дә илленче еллардан соң гына татар халык иҗаты термины белән аталып йөртелә башлавы мәгълүм (5, 6). Ә XX йөз башында татар әдәбияты белемендә фольклор яисә халык иҗаты мәгънәсендә халык әдәбияты дигән сүз кулланылышта булган.

Халкыбыз дастани эпик мирасының жанр буларак татар әдәбият белемендә һәм фольклористикасында лаеклы урын алу процессы – берничә дистә елны колачлый торган күренеш. Дастаннар мәсьәләсен хәл итүнең кичектерелә килү сәбәпләре татар, бигрәк тә Идел буе татарлары иҗатында дастани эпосның язмачылык һәм шуңа бәйле язма индивидуаль иҗат белән тыгыз керешкән булуында һәм шушы фольклорны укып үскән галимнәрнең мондый әсәрләрне халык иҗаты дип таный алмауларында гына түгел, әлбәттә. «Дастан» дип аталырлык әсәрләрне өйрәнүдә алга китмәүнең төп сәбәбе чорның иҗтимагый-сәяси шартларына да нык бәйле.

Татар дастаннары мәсьәләсендә иң әүвәл юл яручылар исемлеген әллә ни озын дип әйтеп булмый. Бу исемлекнең иң башында торучы киң карашлы шәхес – ул, әлбәттә, күренекле әдип һәм әдәбият галиме Г. Ибраһимов. Аның дастани эпосыбызны күзаллавына мөнәсәбәтле фикерләре татар дастаннары проблемасының әдәбиятыбызда куелышы процессында мөһим бер этапны чагылдыра, шуңа да татар фольклористикасы үсешендә тарихи әһәмияткә ия. XX йөз башы әдәби менталитетын чагылдыруы җәһәтеннән дә татар дастаннарына карата Г. Ибраһимов карашлары шактый кызыклы.

Бүгенге татар телендә шактый киң мәгънәне сыйдыра торган «дастан» сүзе хәзерге татар фольклор фәнендә эпос-дастаннар төркеменә карый торган жанр атамасы буларак тәгаенләнгән. Әмма дастан исеме белән мәгълүм бу жанрга нинди әсәрләрне кертеп карау нечкәлекләре, локаль төркемнәргә мөнәсәбәттә дастанның типларын билгеләү соңгырак чорда гына ачыкланган һәм ачыклануын әле дә дәвам итә.

Ә термин үзе гомумтатар фольклористикасы тарихында беренче мәртәбә Галимҗан Ибраһимовның «Пролетариат әдәбияты турында» (1924) дигән хезмәтендә очрый (3, 420–470). Әлеге мәкаләсенең искәрмәсендә ул, терминны Көнчыгыш әдәбиятына нисбәтән, роман, эпопея мәгънәсендә куллана һәм: «Безнең Шәрекъ әдәбиятларында буны (эпопеяны. – *Л. М.*) дастан дип атыйк. Буңарчы “поэма” сүзен “дастан” диюебез хата иде», – дип әйтеп уза (3, 466). Әлбәттә, биредә әле «дастан» бүгенге фольклористика һәм әдәбият теориясендә кулланыла торган мәгънәдән шактый ерак. Шулай да терминны фәнни әйләнешкә кертү җәһәтеннән Г. Ибраһимовның «дастан» сүзенә мөрәҗәгате үк әһәмиятле роль уйный.

Дастанны әдәбият һәм фольклор жанры буларак тикшерә башлауга килсәк, татар фольклор фәнендә бу жанрга багышланган беренче фәнни хезмәт дип шулай ук Галимҗан Ибраһимов мәкаләсен күрсәтергә тиешбез (2, 68–70). Хезмәт әле XX йөз башында дастани эпос жанрына төгәл билгеләмәнең булмавын, бу төргә караган әсәрләрне халыкныкы дип аерымлауның фәнни җәмәгатьчелеккә дә әле ят булуын, ә инде кульязма дастаннарыбызны фольклорга мөнәсәбәттә карауның акылга сыймаслык бер гамәл буларак аңлашылуын янә дәлилли. Г. Ибраһимовның әлеге хезмәтендә дөнья эпосы үрнәкләре «Илиада», «Одиссея», «Шаһнамә» турында сүз алып барылып та, үз халкыбызның нәкъ шундый әсәрләргә тәңгәл ядкарьләре хакында бер сүз дә әйтелми. Ә «эпос» сүзен ул «бердән, имлабызга килми, икенчедән, телемезгә, аһәңебезгә ят», – дип бәяли (2, 69).

Бу – ул чор өчен фольклор материалларының әле тиешле дәрәҗәдә тупланмаган, классификацияләнмәгән булуыннан һәм татар фольклорын, аерым алганда, аның язма иҗат белән тирән керешкән дастан жанрын теоретик күзаллауның әле башлангыч этапта гына булуыннан килә торган нәтиҗә.

Татар әдәбияты тарихын өч чорга бүлеп караган, 1922 елда язылган «Иҗтимагый, әдәби хәрәкәтләр тарихын тикшерүдә марксизм ысулы» исемле хезмәтендә (3, 330–358) Г. Ибраһимов халкыбызның «Йосыф – Зөләйха», «Таһир – Зөһрә» сюжетлы ядкарьләре, «Бүз егет», «Каһарман Катил», «Кыйссаи Сәед Баттал» һ. б. истәлекләрне аерым телгә алып узган. Бу мәкаләсендә әдип, татар әдәбиятында дәверләр мәсьәләсенә кагылып, әлеге әсәрләрнең «кадимге Шәрекъ (борынгы Көнчыгыш. – *Л. М.*) – Русия мөселманлыгы» дәвере әсәрләреннән булуын искәрткән, аларның җирлеген «үзенең дине, фикере, иҗтимагыйәте, бөтен тормышы белән бөтен Шәрекъкә гам булган (уртак булган. – *Л. М.*), шулар кыйбласына карап барган» ядкарьләрдән дип билгеләгән. Димәк, әдәбият белемендә Г. Ибраһимов чорында ук бу һәм башка күп кенә әсәрләргә «бу дәвернең халыкка җан азыгы булган кыйммәтле әдәби җәүһәрләре» дигән теоретик караш булган, теге йә бу дәрәҗәдә аларга бәя бирелгән, әдәбиятыбыз тарихында боларның булу факты искә алынган. Әдип телгә алган җәүһәрләр аерым кешеләр йогынтысын кичергәннәр, язма истәлекләрдән башлангыч алганнар, нигездә язмача таралганнар да. Шуңа күрә бүгенге көндә алар халыкның китаби дастаннары категориясендә каралалар. Әмма үз чорында Г. Ибраһимов бу ядкарьләребезне «халык әдәбияты»ннан аерып куя.

XX йөз башы әдәбият галимнәре арасында халыкка күп санлы вариантларда мәгълүм күләмле эпик әсәрләрне «татар дастаны» атамасы белән билгеләү гомумән юк. Әдәбият теоретигы Г. Ибраһимов та XX йөз башы эстетик карашлары тәэсирендә фикер йөртә, Көнчыгыш әдәбиятларындагы сюжетларга үзебезнең җирлектә формалашып өлгергән дастаннар турында сүз алып барып та, аларны аерым жанр буларак карамый. Әмма Г. Ибраһимовның үз хезмәтендә әлеге әсәрләргә тукталуы – халкыбыз яшәешенең билгеле бер этабында мондый тип әсәрләргә халык ихтыяҗының никадәр зур булганлыгын ассызыклау ягыннан бүгенге көндә чиксез әһәмияткә ия.

Гомумән әйткәндә, татар фольклористикасында дастаннарыбызның кыйммәтен дөньякүләм һәм төрки эпик ядкарьләр янәшәсендә билгеләү өлкәсендә Г. Ибраһимовның төп роле күпчелек дастаннарыбызның чишмә башы Борынгы Көнчыгыш язма истәлекләренә барып тоташуны ачыклау, мәсьәләнең нәкъ менә шушы җитди ягына игътибарны юнәлтү булды.

Татар эпосын, бигрәк тә Урта Идел буе татарлары эпосын гомумтөрки масштабта карау безнең халыкка хас эпик иҗатның башка төркиләр эпосы белән чагыштырганда шактый зур специфик үзенчәлекләргә ия булуын күрсәтә. Дастан жанрының татар халкына хас булган хосусиятен бар тирәнлеге белән ачу мәсьәләләрен татар фольклористикасында әлегә хәл ителгән мәсьәлә дип санап булмый. Г. Ибраһимовның бүгенге көндә дастан жанры буларак карала торган текстларга үз чорында юнәлтелгән игътибары дастан жанрын һәм аның Идел буе татарларына хас китаби тибын дәвамчанлык һәм иҗтимагый-тарихи үсеш яссылыгында карар өчен этәргеч бирә. Татар әдәбият белемендә һәм фольклористикада халыкның дастани эпик мирасын барлап, яшәү һәм үсеш юллары, сәнгати үзенчәлекләре ягыннан, шулай ук язма әдәбият һәм башка төрки халыклар фольклоры белән чагыштырып өйрәнүдә Г. Ибраһимов хезмәтләре бүгенге көндә гаять актуаль.

ӘДӘБИЯТ

1. Акчурина М. Иске әдәбиятымыз // Шура. – 1911. – 16 сан. – Б. 508–510; Гобәйдуллин Г. Сәед Баттал Гази хикәясе тугрысында // Шура. – 1911. – 22 сан. – Б. 682–685.

2. Ибраһимов Г. Әдәбият кануннары. – Казан: «Сабах», 1918. – 120 б.

3. Ибраһимов Г. Әсәрләр. Сигез томда. Т. 5: Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – 615 б.

4. Тукай Г. Әсәрләр 4 томда. Т. 4. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. – 432 б.

5. Урманче Ф. Татар халык иҗаты. Югары уку йортлары һәм колледжлар өчен дәреслек. – Казан, 2002. – 335 б.

# ЯҢА ЗАМАННАН ЯҢАЧА КАРАШ
## (Г. Ибраһимовның совет чоры иҗаты турында)

***Р. Р. Сабиров (Казан)***

В нынешнее время творчество Г. Ибрагимова советского периода нуждается в еще более глубоком научном осмыслении и оценке. Не секрет, что наследие писателя в прежние годы трактовалось в духе советской идеологии, весьма идеологизированно и поэтому однозначно. Причем и судьбу самого автора следует трактовать теперь по-иному, а именно как трагедию человека, порожденную той общественной системой, в которую он искренно верил и был предан до конца жизни. Данная статья является одной из попыток обновленного изучения творчества Г. Ибрагимова советского периода.

Галимҗан Ибраһимовның әдәби эшчәнлеге утыз еллап вакытны иңли. Әлеге вакыт тарихи борылышларга, сәяси, иҗтимагый системаларның үзгәреп торуына гаять бай булган XX гасырның беренче яртысына туры килә. Иҗатының башлангыч чорында романтик принципларга нигезләнеп, милли проблемаларны, шәхес азатлыгы мәсьәләсен күтәргән, соңрак социалистик хәрәкәтнең эсерлар төркеменнән большевиклар ягына күчкән Ибраһимов шәхесенә һәм иҗатына үз чорында да, бүген дә карашлар төрле булып кала. Инкыйлабка кадәр үзе дә социаль тигезлек, шәхес иреге мәсьәләләре аша милләт язмышы белән янса, егерменче елларда

әдипкә киң колачлы эшчәнлеге һәм уңышлы әсәрләре өчен (ягъни системага яраклы дип табылганга) Хезмәт Герое исеме бирелә. Утызынчы еллар ахырында исә «халык дошманы» дип гаепләнеп кулга алына, үзе үк данлаган совет иле төрмәсендә вафат була, әсәрләрен уку-өйрәнү тыела. Иҗаты Сталинның шәхес культы фаш ителгәч кенә укучыга кире кайтарыла.

Сүз дә юк, татар халкының зур өлеше, шул исәптән, зыялылары да 1917 елгы октябрь инкыйлабын шатланып каршы алды. Күпчелек әдипләр кебек, Галимҗан Ибраһимов та большевикларның «милләтләргә – азатлык, бар халыкка – тигезлек» дигән шигарьләренә ышанып, идеологияне алга сөрүче каләм иясе буларак күз алдына килә. Гражданнар сугышы елларында язылган «Яңа кешеләр» пьесасыннан башлап, язучы үз иҗатында сыйнфыйлык принципларына таянып яза. Әмма бүгенге көндә без Ибраһимовның әсәрләренә дә аклар-кызыллар, байлар-ярлылар, колхозчылар-кулаклар каршылыгы аша гына якын килүдән ерак торабыз, иҗат җимешләренә заманча күзлектән чыгып, объектив бәя бирү, әсәрне әсәр иткән башка үзенчәлекләргә игътибар итү кирәклеген аңлыйбыз. Дөресен әйтергә кирәк, соңгы елларда язучы иҗатына советчыл рухта якын килгән белгечләр дә әлеге зарурлыкны аңлый. Бу хакта язучының 120 еллык юбилеена багышланган фәнни-гамәли конференциядә чыгыш ясаучылар да искәрткән иде. Әйтик, Ф. Мусин «Ибраһимовның совет чоры мирасын яңадан өйрәнгәндә, ниһаять, иҗатының инкыйлабка кадәрге һәм 1917 елдан соңгы чорлары арасындагы бәйләнеш булуына игътибар итәргә кирәк...», – дип язган иде (4, 9).

Октябрь инкыйлабының өч еллыгы уңаеннан язылган «Яңа кешеләр» пьесасының күзгә бәрелеп торган каршылыгы – аклар белән кызыллар арасындагы канлы көрәш. Әмма бу беренчел – тышкы конфликт кына. Автор биредә халык бәхете өчен көрәш юлына баскан, дөньяны үзгәртергә тырышкан, иң мөһиме, инкыйлаб нәтиҗәсендә туган яңа кеше образларын үзәккә куя. Яңа җәмгыять өчен көрәш, гражданнар сугышы андыйларны рәхимсезлеккә өйрәткән, алар, тигезлекне, бәхетле тормышны көч белән генә урнаштырып була, дип уйлыйлар. Ярый әле Батырхан, Тимеркәй, хәтта Камәр (хатын-кыз бит ул!) кебек яшьләрне авылның өлкән буын кешеләре тыеп тора. Шәйбәк картның үзенчәлекле киная белән әйткән фикере гыйбрәтле һәм чоры өчен гаять актуаль яңгырый: «Чүп утыйм, дип, ашлыкны әрәм итә күрмәгез». Әйе, Ибраһимовның олырак буыны мәгънәсез кансызлыкны берничек тә аклап булмый торган мәрхәмәтсез, гөнаһлы гамәл дип бәяли. Пьесаның төп конфликты шушы ике төркемнең дөньяга карашлары арасындагы каршылыкка нигезләнгән түгелме? Ягъни автор тарафыннан төп геройларның эш-гамәлләре гомумкешелек кануннары белән бәхәскә китерелә. Өлкәннәрнең өйрәтүе (автор үз идеясен геройлары аша җиткерә) юкка китми кебек: Батырхан хатасын бераз булса да танырга мәҗбүр, соңрак ул үзе дә Тимеркәйнең гайрәтләнеп йөрүен гаепли башлый. Икенче төрле әйткәндә, «Яңа кешеләр» драмасында миһербанлылык белән нәфрәт хисләре каршылыкка килә.

Жанр үзенчәлеге ягыннан да, сурәтләү чаралары, сәнгатьчә эшләнеше ягыннан да «Яңа кешеләр» әдипнең башка әсәрләреннән түбән тора. Моның шулай булуын язучы үзе дә аңлаган булса кирәк: башкача Г. Ибраһимов драма әсәрләре язмый.

Романтизм һәм реализм иҗат методлары синтезының матур үрнәге булган «Кызыл чәчәкләр» (1922) повестендә чор идеологиясенең йогынтысы шик уятмый кебек, әсәрнең конфликт сызыгы булып капма-каршы сыйнфый көчләрнең бәрелеше тора. Автор әсәр дәвамында һаман тормышның, җәмгыятьнең төрле катлауларга бүленеше хакында, сыйныфлар аермасы турында сөйли. «Авылның уртасында зур базар кайный; аның ике ягыннан биек матур сарайлар, зур тимер йозак белән бикләнә торган ак таш кибетләр тезелеп китәләр... Боларга тоташып, бераз читкә таба, урта хәлле кешеләрнең уртача зурлыктагы өйләре, уртача биналар үз дәрәҗәләренә күрә урын алалар. Тагын бераз китсәгез, йортлар кечерәя, каралтылар, егылмасам ярар дип куркып, үзләренең иске черек терәкләренә таяна төшеп, һәр җилгә калтыранып, һәм яңгырны эченә алып, язмышның бөтен көчләре алдында ыңгырашып гомер итәләр. Иң ахыр барып, күпер башларында, басу капкасы буйларында чүплекләргә, тиресләргә салынган балчык өйләр, корымлы читән куышлар, үзләренең кайгылы йөзләре, сәләмә кыяфәтләре белән, каты җилләргә, көчле бураннарга каршы тора алудан өмет өзгән бер хәлдә дөнья кичерәләр....» (1, 9).

Шулай итеп, авылдагы йортлар, базардагы сату урыннары, кешеләр, хәтта дуслар – бар да берничәгә бүленә: бай, хәлле, ярымхәлле, хәерче, бик хәерче. Әсәр үзәгенә алып сурәтләнгән биш малайның, биш дусның холык-фигыле һәм киләчәк язмышлары да аларның социаль чыгышлары белән тыгыз бәйләнештә тора. Ахыр килеп, сыйнфый баскычның төрлелеге малайларның психологиясенә нык тәэсир итә, берсе үзен икенчесеннән өстенрәк хис итә.

Әсәрнең исемендә үк образ күренеп тора, аның турыдан-туры мәгънәсеннән тыш башка мәгънәсе дә бар. Кызыл – ул революция, көрәш, сугыш төсе, киләчәк өчен коелган канны чагылдыра. Чәчәкләр исә шушы киләчәктә яшәргә тиешле, ә хәзергә көрәшеп, кан коючы яшьләр образын белдереп килә. Әсәрнең исеме повестьнең башламы аша тагы да ныграк ачыла, биредә ул вакыйга-метафора булып килә. Әлеге башламда карт мөсафир биреп киткән кызыл орлыкларга үсеп китәргә комачаулыйлар, өстенә тирес түгеп, кара таш белән бастырып китәләр. Төп вакыйгаларда яшь кызыл буынга комачау итүчеләр табыла, «кызыл чәчәкләр» дип сыйфатланган Солтан, Гыйлаҗи, Шаһбазларга тормышта «үсеп чыгар» өчен шактый тырышырга, кыенлыкларны җиңәргә туры килә. Гыйлаҗи белән Шаһбаз исә, бастырылган чәчәк кебек, бөтенләй һәлак булалар.

«Кызыл чәчәкләр» әсәрендә кабатланган тагын бер момент – ул сугыш, тарткалаш турындагы өлешләр. Әсәр дәвамында сугыш вакыйгалары шулкадәр күп кабатлана ки, әйтерсең, билгеле бер җәмгыятьтә яшәү тулысынча бер-береңнең көчен күрсәтүдән, сугышлардан гына гыйбарәт. Игътибар итегез, «мин» (Солтан) барлык иптәшләре белән дә сугыш-тарткалашлар нәтиҗәсендә дуслаша. Беренче вакытларда баерак, хәллерәк һәм хәерчеләрдән бөтенләй читләшеп йөргән бик хәерче ятим Шаһбазның да дүрт дус янында үз булуы өчен сугыш кирәк булган: «... Галиләр, Фазыйллар, Гыйлаҗилар белән бик күп тапкыр бергә уйнап, җенләнеп, көрәшеп, башка компанияләргә каршы сугышларга катнашып, үзе бик күп батырлыклар күрсәткәч кенә Шаһбаз безнең арада үз булып китә алды» (1, 21). «Талаш-сугыш булмагач» Солтанга бөтенләй кызык

түгел. Ахыр-чиктә, инде үскән, кызыл сугышчы булган Солтан нәтиҗә дә ясап куя: «Мин көрәшне яратам. Көрәшсез үткән көннәремне әрәм саныйм. Каты көрәш дулкыннары арасында минем җаным рәхәтләнә, йөрәгем үзенә көч ала, гайрәт ала» (1, 76). Ягъни төп герой – тумыштан ук сугышчы. Тукмашу, кан кою, үч алу аның канына сеңгән һәм ул шуннан тәм таба.

Ирексездән, «Яңа кешеләр»дәге Шәйбәк картның кинаяле сүзләре искә төшә. Шул рәвешле, Г. Ибраһимов, бер яктан, идеология таләпләренә тугры булган әдип буларак та күз алдына килә, шул ук вакытта, меңьгасырлык татар әдәбиятының буеннан-буена кызыл җеп булып сузылган кешелеклелек, миһербанлылык, шәфкатьлелек идеяләрен дә сиздерми генә белдерә алган. Бүгенге көн күзлегеннән караганда, «Кызыл чәчәкләр»дә сыйнфыйлык икенче планга да күчмиме икән? дигән сорау туарга мөмкин. Чөнки әсәрнең башыннан ахырына кадәр дуслык проблемалары ярылып ята. Повесть башында, төрле социаль катламнардан чыгуларына карамастан, биш малай шактый ук дуслашып, якынлашып китәләр. Бергә булганда, аларга якын килүче дә юк. Малайларның дуслыгы инкыйлаби күтәрелешләргә кадәр дәвам итә. Кан коешлар башлангач, егетләр баррикадаларның төрле ягында кала. Хәзерге югарылыктан ике якны да һәм хаклы, һәм хаксыз дияргә мөмкин (гражданнар сугышының фаҗигасе дә әнә шунда).

Солтан үзенең балачак дуслары Гали белән Фазыйлга дошманнар ягында булганнарына ачулана. Ләкин аның ачуланырга нигезе бармы? Ахыр чиктә, һәр кешегә гамәлләре өчен җәзасы бирелә. Әнә, үз тырышлыклары белән тупланган мал-мөлкәтләрен ярлылар урлый-талый башлагач, дошманнарга ярдәм итә башлаган Гали соңыннан үз-үзен атып үтерә. Гали тормышта үз урынын таба алмый кала. Фазыйл да бәргәләнә: әле аклар белән кызыллардан үч ала, ахырдан большевиклар ягына күчеп, яңа җәмгыять төзешә башлый. Һәр кешегә саклану инстинкты салынганлыгын да онытырга ярамый, кемдәдер бик аз хас ул, кемдәдер көчлерәк. Әнә, Гыйлаҗи да «Ярманга пленга» киткән, анда да югалып калмый, үз һөнәре белән көн күрә, инкыйлабтан соң гына кызылларга кушылган. Хәер, Солтан әллә ни ачуланмый да кебек. Гали аның күңелендә балачак дусты, ләкин сыйнфый дошман булып кала. Фазыйлны искә төшергәндә исә «бик аз гына яратам да бугай» дип белдерә. Аерым тикшеренүчеләр фикеренчә, «авторның теләге дә сыйнфый дошманлыкны раслау түгел, милләтнең киләчәген, бөтен дөньяны дуслыкка, мәхәббәткә бизәлгән итеп күрү» (6, 317). Әйе, җәмгыятьне көрәш, сугыш, кан коешлар түгел, бәлки дуслык һәм бердәмлек кенә тынычландыра һәм саклап кала ала. Минемчә, Галимҗан Ибраһимов та милләтнең үз эчендә барган тарткалашулар нәтиҗәсендә дуслык бетүе, бердәмлек югалуы өчен борчылып яза.

Шул ук бердәмлек идеясе язучының тагын бер гаять гүзәл әсәре – «Алмачуар» хикәясендә (1922) дә үткәрелә. Ни гаҗәп, әлеге хикәядә сыйнфыйлыкның эзе дә юк, әсәр әле дә яратып укыла, төрле уйларга этәрә, кешелек дөньясының асыл кыйммәтләрен чагылдыра. Хикәянең исеме астында «Бер мәхәббәтнең тарихы» дип куелган. Әсәрнең сюжет-композициясе төп герой Закирның колынга булган мәхәббәтенә багышланган вакыйгаларга корыла. Хикәядә балалар өчен кызыклы, хәтта үрнәк алырдай, хайваннар яратучы үсмер образы тудырыла кебек, малайның борчу-кичерешләре, шатлык-сөенечләре дә ышандыргыч итеп тасвирлана. Әмма хикәянең тәрбияви нигезе башка мәсьәләгә салынмадымы икән? Әсәрнең башы белән ахыры кабатлана: хикәя Сабантуй вакыйгалары белән башлана, шул ук Сабантуй вакыйгасы белән тәмамлана да. Әсәр башында көрәшче башкорт Әлемгол, бил алышканда хәрәмләшкәне өчен, җәза ала, авырый башлый. Бары тик биргән вәгъдәсен (икенче тапкырдан) үтәгәч кенә җан тынычлыгы ала. Хикәя ахырындагы Сабантуйда исә төп геройның узышта беренче урынны алган аты үлә. Димәк, Закир да җәза ала түгелме? Төптәнрәк уйлап карасаң, әсәр дәвамында үсмер үзенең аты белән милли бәйрәмебездә узышу, алай гына да түгел, җиңү турында хыяллана. Шуның өчен җәзасын да ала.

«Алмачуар» хикәясендә төп вакыйгалардан аерылып торган өлеш бар. Биредә ат сакларга барган яшүсмерләр кечкенә елгаларның зуррakларына, анналары диңгезгә кушылуы турында сөйләшәләр. «Безнең авылның буеннан аккан бу елга – Өршәккә, Өршәк – Димгә, Дим – Агыйделгә коя» (1, 116). Әлеге бүлектә Г. Ибраһимов революциягә кадәр үк язган милләтнең берләшүе турында сүз алып бара түгелме соң? Әлбәттә, шулай! Әдип берләшү идеясеннән яңа шартларда, совет чоры иҗатында да баш тартмый, асылда, совет идеологиясенең нигезендә дә шул идея ята. Ә Закирның атын беренче урынны алган өчен генә яратуы, асылда, үзен генә кайгыртуы берләшүнең киресе булып чыга. Моның өчен җәзасын да аласың, дип кисәтә автор. Шул рәвешле, Г. Ибраһимовның кечкенә генә «Алмачуар» хикәясе гомумкешелек мәсьәләләрен күтәрүе, мораль якка игътибар итүе, вакыйгаларны реалистик планда яктырта алуы белән кадерле һәм бәһале.

Г. Ибраһимовның бер төркем әсәрләре әлегәчә төгәл фәнни бәя алмаган. «Безнең көннәр», «Казакъ кызы», «Татар хатыны ниләр күрми» кебек күләмле хезмәтләре 1917 елга кадәр үк иҗат ителеп тә, инкыйлабтан соң шактый үзгәртелә. Аңлашыла ки, иҗтимагый-сәяси позицияләрен үзгәрткән әдип идеология таләпләренә буйсынырга мәҗбүр була һәм, асылда, аның әсәрләренең нәкъ менә үзгәртелгән вариантлары гына өйрәнелеп килде. 1923 елда язылып, Идел буендагы ачлык вакыйгаларын сурәтләүгә корылган «Адәмнәр» повестеның да «20 нче еллар татар прозасын һәм идея, һәм эстетик яктан баета торган әсәр икәнлеге ачыкланып беткәне юк» (3, 13).

«Тирән тамырлар» романы турында соңгы елларда Галимҗан Ибраһимов иҗатын тикшерүчеләр шактый язды. Әлеге мәкаләләр әсәргә совет елларында бирелгән бәя-мөнәсәбәттән бөтенләй аерылып тора. Чыннан да, «большевиклар диктатурасының татар халкы тормышына китергән афәтләрен, гомумкешелек һәм милли идеалларның чәлпәрәмә килүен күрсәтү бүгенге тормыш өчен бәһасез» (2, 13).

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә мөмкин: Г. Ибраһимовка «чын мәгънәсендә советчыл язучы» дип бәя бирү бик үк дөрес түгел икән. Гомере буена язучы иҗатын өйрәнгән М. Хәсәнов та, яңа дәвердә әдипнең партия идеалларына тугрылыклы шәхес булуын таныган хәлдә дә, аны ортодаксаль большевик дип санарга кирәкмәвен искәрткән иде (5, 11).

ӘДӘБИЯТ

1. Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. III т. / томны төзүчеләр: А. Ш. Шамов, Х. Я. Гобәйдуллин; текстларны, искәрмәләр һәм аңлатмаларны әзерләүчеләр: А. Ш. Шамов, Р. Р. Гайнанов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. – 455 б.

2. Минһаҗева Л. Зур шәхес, бөек талант // Г. Ибраһимов. Сайланма әсәрләр. – Казан: Хәтер, 2002. – Б. 5–17.

3. Мусин Ф. Г. Ибраһимов иҗатын өйрәнүнең торышы һәм бурычлары // Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман: тууына 115 ел тулуга багышланган фәнни конференция материаллары. – Казан: Фикер, 2002. – Б. 12–20.

4. Мусин Ф. Ибрагимов: вчера, сегодня, завтра // Галимджан Ибрагимов и XXI век: Материалы международной научно-практической конференции, посвященной 120-летию со дня рождения Г. Ибрагимова. – Казань, 2007. – С. 6–18.

5. Хәсәнов М. Галимҗан Ибраһимов: шәхесе һәм иҗаты, ул яшәгән заман турында уйланулар // Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман: тууына 115 ел тулуга багышланган фәнни конференция материаллары. – Казан: Фикер, 2002. – Б. 6–17.

6. Яхин А. Тирән тамырлар // Кызыл чәчәкләр: Татар совет әдәбиятының 20–30 нчы еллар прозасы. – Казан: Мәгариф, 2003. – Б. 289–297.

# ӘДИПНЕҢ СОВЕТ ЧОРЫ ИҖАТЫНДА ЗАМАН ҺӘМ ГЕРОЙ КОНЦЕПЦИЯСЕ
## («Кызыл чәчәкләр» повесте, «Яңа кешеләр» драмасы мисалында)

***Ф. Х. Миңнуллина (Казан)***

В статье рассматривается концепция эпохи и героя в повести Г. Ибрагимова «Красные цветы» и драме «Новые люди». В связи с этой концепцией определяются идейно-эстетические взгляды писателя. Делается вывод о том, что героя порождает эпоха. В статье также освещаются кровавые события в истории татарского народа.

XX йөз татар әдәбияты классигы, тел-әдәбият галиме Г. Ибраһимовның тормыш һәм иҗат юлы озын вә катлаулы булып, анда татар халкының тулы бер гасырны эченә алган тарихи яшәеше, язмышының кискен борылышлары, рухи дөньясын биләгән өмет-хыяллары, сөенеч-шатлыклары, кичергән фаҗигаләре чагылыш тапкан дияргә мөмкин. 1917 елда патша хөкүмәте бәреп төшерелүен дә, Россия империясе халыкларына милли азатлык, хокукый тигезлек, хезмәт кешесенә «бәхетле тормыш» вәгъдә иткән Октябрь күтәрелешен дә Г. Ибраһимов икеләнүсез кабул итә. Әлеге күренешләр аның «Кызыл чәчәкләр» повесте, «Тирән тамырлар» романы, «Яңа кешеләр» драмасында һ. б. хезмәтләрендә чагылыш таба. Әлеге әсәрләрнең сюжеты, геройлары, образлары да шул заман көрәшен күрсәтүгә, яңа тормышны төзү вакыйгаларын ачуга буйсындырыла. Алай гына түгел, яңа хөкүмәтне икеләнүсез кабул иткән автор, үз әсәрләрендә яңа хөкүмәтнең асыл гамәлләрен, нигезен ачып бирә. Мәсәлән, «Кызыл чәчәкләр» повестенда һәм «Яңа кешеләр» драмасында яңа тормыш өчен көрәш вакыйгалары тасвирлана. Яңа герой концепциясе хакында сүз бара. Пьесасында барлык персонажлар да сыйнфый карашларга бәйле рәвештә совет хакимиятен яклаучылар, яки аның дошманнары буларак хәрәкәт итәләр. Мәсәлән, «Кызыл чәчәкләр»дә халыкның төрле социаль катламнарга каравы йортларның үз дәрәҗәләренә карап урын алуларында да чагылыш таба. Әсәрнең төп геройлары да шул авылның төрле урамнарында, байлыклары төрлечә булган өйләрдә туып үсәләр. Повестьта, бала чаклары, яшьлек еллары беренче империалистик сугыш, Октябрь инкыйлабы, гражданнар сугышы елларына туры килгән биш егетнең язмышы аша, әдип авылдагы һәм гомумән, ил күләмендәге мәгълүм үзгәрешләрне чагылдыра. Төрле социаль катлам вәкилләре булган Шаһбаз, Солтан, Гыйлаҗи, Фазыйл белән Гали образлары ярдәмендә автор, бергә уйнап үскән егетләрне революция елларында капма-каршы лагерьларда калдыра. Бу хәл илдә хөкем сөргән социаль-сәяси тәртипләр белән аңлатыла. Автор заманның бу сыйфатларын тирән белеп эш итә. «Яңа кешеләр»дә дә автор Батырхан белән авыл бае Хәйри арасындагы мөнәсәбәтләре, Тимеркәйнең Вәлине үтерү вакыйгалары аша бер милләт вәкилләренең кан дошманга әйләнүен сурәтли. Драмада кайчакта Батырханның зиһене ачылып китә сыман. Ул революцион нәфрәтнең анархия башбаштаклылыгы белән бернинди дә уртаклыгы булмавын аңлый. Ләкин барлык геройлар да мондый эволюцияне кичерми. Яшьлегендә Батырхан кылган эш-гамәлләрне алга таба Тимеркәй сыман авыл яшьләре башкара. Г. Ибраһимов шул рәвешчә яңа дәүләт төзергә килүчеләрнең, ягъни яңа кешеләрнең рәхимсез, салкын канлы булуларын тасвирлый. Әдәбият мәйданына социалистик герой концепциясен чыгара. Аларның вәхшилеген сурәтли. Гомумән, әсәрдә инкыйлаб елларында геройларның эш-гамәлләрен, хис-тойгыларын бирүдә сыйнфый-социологик метод үзен шактый сиздерә. Шул ук вакытта Г. Ибраһимов яңа тормыш тарафдары булган геройларына тирәнрәк мәгънә сала. Мәсәлән, ул «Кызыл чәчәкләр»дә Солтанның көрәш юлында бер аягын югалтуын еш искә төшерә. Әлеге киная ярдәмендә халык өмет иткән матур киләчәкнең килмәвенә, көрәш юлында меңләгән кешеләрнең һәлак булуына, кан коелуга ишарә ителә. Шаһбазның аянычлы, фаҗигале язмышы ярдәмендә Г. Ибраһимов, объектив рәвештә, яңа хөкүмәтнең тугандаш төрки халыкларны үзара ызгыштыру сәясәтен фаш итә. Гыйлаҗиның һәлак булуы да яңа җәмгыять төзү өчен көрәштә үзен аклап бетермәгән мәгънә төсмерен ала. Бала чактан зирәклеге, тапкырлыгы белән аерылып торган Фазыйл исә гражданнар сугышы елларында аклар лагеренда көрәшә, аннары совет ягына күчә. Ачыграк әйтсәк, ул төрек-татар байрагы астында милли азатлык өчен көрәшә, шул исәптән милли идарәгә кушылып, Колчак ягына чыга. Соңыннан, алардан өметен өзеп, ул милли азатлык хыялы белән пролетариатка килеп кушыла. Ягъни герой үзенең милли идеалларына ахыргача тугрылыклы булып кала. Яңа тормышны кабул итә алмаган Гали исә ак офицер була. Соңыннан үз-үзен үтерә. Шул рәвештә, бер милләт, бер авыл кешеләре бер-берсен үтерү юлына басалар. Әлеге вакыйгалар аша әдип сыйнфый көрәш законнарының рәхимсез булуын ачып бирә.

«Яңа кешеләр»дә автор Тимеркәй образы ярдәмендә ул сыйнфый каршылыкларның кеше психологиясенә тәэсир итүен күрсәтә. Ул, гомумкешелек бәхетенә көрәш юлы белән генә ирешеп була, дип уйлый. Кан коюны киләчәк матур тормыш белән бәйли. «Кызыл чәчәкләр»дән аермалы буларак, драмада кискен социаль бәрелешләр заманында аерым бер кешеләр, халык бәхетенә көрәшсез дә ирешеп була, дип ышаналар. Кызганыч ки, шундый хыял-омтылышлар белән гомер иткән шәхесләр дә ахыр чиктә рәхимсез сугыш корбаннары булдылар. Бу яктан тормышчанлыгы белән гаҗәп тирән тәэсир калдыра торган Шәйбәк карт образы гыйбрәтле. Ирекне, бәхетле, матур киләчәкне көрәшсез, корбаннарсыз гына китерергә тели ул. Шәйбәк хезмәт халкы мәнфәгатьләрен кайгырту юлында эволюцион юлны сайлый. Әмма сыйнфый көрәш законнары рәхимсез. Гражданнар сугышының куәтле өермәсе аны да үз эченә ала. Шәйбәк белән Камәр һәлак булалар. Шәйбәк бабайның: «Әй, туган! Син тагын кан түккәнсең икән! Ярамас, бер дә ярамас иде!» (1, 425) – дип кисәтүенә Батырхан: «Юл бер генә! Менә шушы канлы юл – изге юл» (1, 426), – дип җавап бирә. Шулай итеп, Г. Ибраһимов Шәйбәк һәм Батырхан образлары ярдәмендә ике төрле караш яшәвен күрсәтә. Татар халкының каты бәрелешкә китергән сәбәпләрнең берсе – социализм, икенчесе – милли азатлыкка ирешү өмете. Драмада урыс Каменин да, татар Әхтәм Бакаев та словаклар ярдәме белән милләт проблемасының хәл ителүенә ышаналар. Каменин бүленмәгән бөек Россия турында хыялланса, Әхтәм Бакаев ... яшәсен чехлар! Диңгез, яшәсен бергә азатлык бирүче туганымыз диегез» (1, 427), – ди. «Яңа кешеләр» – реаль вакыйгаларны тасвирлаган әсәр генә түгел, ә булачак вакыйгаларны да күзаллый торган пьеса. Шәйбәкнең: «Белмим, белмим, белмим, күп кан түгүдән саклан! Чүпне утыйм, дип, ашлыкны әрәм итә күрмә» (1, 426), – дигән сүзләре шуңа ачык мисал. Мәгълүм ки, гражданнар сугышыннан соң татарның бик күп асыл уллары, шул исәптән Г. Ибраһимов үзе дә культ корбаны булдылар.

Шул рәвешчә, ике әсәрдә дә бер милләт, бер авыл кешеләре, ике сыйныфка бүленеп, бер-берсен үтерү юлына басалар. Әлеге вакыйгалар аша яңа оешып килүче дәүләтнең канга, вәхшилеккә нигезләнүен күзалларга була. Язучының бу әсәрләре, яңа чорның иҗтимагый-сәяси үзенчәлекләре турында аның җитди уйлануларын чагылдыра. Беренче карашка, аларда заман таләп иткәнчә, сыйнфый яссылыктан иҗат ителгән уңай геройлар да якты киләчәк өчен көрәштә туа, дигән фикер өстенлек ала сыман. Әмма, әсәрләрнең мәгънәсен тирәнрәк аңлаганда, аларда Октябрь инкыйлабының үзара тату, дустанә яшәгән бер милләт вәкилләрен кискен үзгәртүен, бер-берсенә каршы булган ике төркемгә аеруын, язмышларын бермә-бер катлауландыруын, хәтта фаҗигале төстә бирелүен күрәсең. Язучы шул дәвер тудырган геройларны әдәбият мәйданына чыгара. Г. Ибраһимов таныш материалларга таянып, татар халкы тарихындагы канлы вакыйгаларның берсен күрсәтүгә ирешә. Җыеп әйткәндә, җәмгыятьне тамырдан үзгәртеп, халыкка бәхетле тормыш алып килүче яңа кешеләрнең мәйданга чыгуын теләгән авторның теләк-омтылышлары тормышка ашмый.


ӘДӘБИЯТ

1. Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда. III т. – Казан, 1975. – 615 б.


## Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ «АДӘМНӘР» ПОВЕСТЕНДА НАТУРАЛИЗМ


***З. Г. Сәлахова (Казан)***



Статья посвящена исследованию натурализма в повести Г. Ибрагимова «Адәмнәр».


Галимҗан Ибраһимов – татар әдәбиятының инкыйлаблар, сугышлар, социалистик җәмгыять төзү өчен барган авыр көрәш заманының күренекле сүз остасы, атаклы язучысы. Г. Ибраһимовның язган әсәрләре, гыйльми хезмәтләре, кылган гамәлләре, көрәшләре – һәммәсе дә безнең тарих. Шулар арасында халкыбызның фаҗигале үткәнен чагылдырган «Адәмнәр» әсәре аерым игътибарга лаек.

«Адәмнәр» 1923 елда Казанның «Шәрекъ» типография комбинаты нәшриятында басылып чыга. Повестьта 1921–1922 елларда Идел–Урал буйларында булып үткән ачлык вакыйгалары натурализмның иң югары ноктасына җиткереп тасвирлана. Г. Ибраһимов повестьның буеннан-буена совет хакимиятенең халыкны рәхимсез талавы һәм дә Идел буена ябырылган икенче афәт – корылык аркасында килеп туган коточкыч ачлык күренешләрен натуралистларча гәүдәләндерүче реалист буларак чыгыш ясый. Язучы биредә кешене биологик организм итеп күзаллап, ачлык дигән социаль-иҗтимагый күренешнең кешенең физик халәтенә бәйле рәвештә генә түгел, ә аның психикасына да коточкыч тәэсир ясавын, вәхшилеккә этәрүен ямьсез һәм куркыныч натуралистик күренешләр аша укучыларга җиткерә

Билгеле, Г. Ибраһимовның замандашлары да, аннан соңгы чорлардагы тәнкыйтьчеләр дә повестьтагы натурализм белән килешә алмыйлар, әдипнең әсәрдә бу алымны куллануын аның кимчелеге дип санап, каты тәнкыйтьлиләр, аны зур идеологик хаталар ясауда гаеплиләр. Шуңа да «Адәмнәр» повесте озак еллар буена укучылардан читләштерелеп киленә. Бары 90 нчы елларда гына ул үзенең тиешле бәясен ала. Биредә профессор Ф. Галимуллинның «Адәмнәр» әсәренә карата әйтелгән: «…Г. Нигъмәти, Ш. Усмановларга ияреп, язучыны һич тә натурализмда гаепләп булмый» (1, 172), – дигән фикере игътибарга лаек.

Чыннан да, Г. Ибраһимов 1921 ел ачлык трагедиясен үтемле итеп күз алдына китерү өчен, әсәрдә бик еш натуралистик алымнарга мөрәҗәгать итә. Ул укучы игътибарын беренче җөмләсеннән үк авыл тормышындагы коточкыч, куркыныч вакыйгаларга юнәлдерә. Тормыш авырлыгы баскан ачларны кызгану хисе уятыр-

лык җөмләләрне натуралистик юл белән җентекләп яза. Бу җөмләләрдә Г. Ибраһимовка хас булган әдәби осталык кына түгел, халык язмышы, аның бик тә авыр иҗтимагый-сәяси халәткә куелуы турында тирән уйланулар күзәтелә. Әдип чынбарлыкны бөтен кырыслыгында натуралистларча сурәтләргә омтылып, кеше яшәешен биологик яктан күрсәтүгә юнәлтә.

«Адәмнәр» повесте үзенең фаҗигале асылы һәм дәһшәтле чынбарлыкны булганынча, гадел тасвирлавы белән дә үзенчәлекле. Әсәрдәге һәр герой иң элек газапланучы, җәфа чигүче ачлык корбаны буларак күз алдына килеп баса. Җан өшетерлек күренешләр әсәр сюжетында кино тасмасындагы кебек алмашынып тора. Беренче абзацтан соң әдип укучыны Галим карт янына алып килә һәм хиссез, кыска җөмләләр ярдәмендә аның белән таныштыра. Үз героена игътибар итмәгән кебек тоелса да, автор төрле эпизод, фрагментларны бер-бер артлы тезә дә, шуларны бик оста итеп монтажлап, натурадан фотога төшереп алган шикелле, ачлык елларының киң панорамасын күз алдына китереп бастыра. Әсәрне уку барышында татар халкы башыннан кичкән куркыныч реаль вакыйгалар, кино лентасындагы сыман, бер-бер артлы күздән кичерә барыла.

Әсәрнең беренче битеннән үк кешенең биологик хайвани табигатен, физик халәтен тасвирлаган, авыр дәһшәтле картинаның эченә кереп китәбез. Түбәндәге өзек шуны расласа кирәк: «Мәгәр ул бераз гына кичеккән иде инде: бик зур бер карт ала эт үлекнең эчен актарып, эчәген, бавырын ашап ята!!» (2, 4). Бу юллар коточыргыч вәхшилекне тулылыгы белән күз алдына китереп бастыра. Автор хакыйкый дөньяны, чынбарлыкны, әйтерсең лә, бер үзгәрешсез әсәр тукымасына күчереп утырткан.

Әсәрдә кеше тормышы һәм психологиясе турыдантуры биологик һәм физиологик сыйфатлары белән ялангачландырып күрсәтелә. Повестьта геройларга артык зур характеристика бирелми, төп игътибар ачлык аркасында килеп туган, алар белән булган хәлләргә юнәлтелә.

Бүгенге көн галимнәре натурализм теориясенең нигезендә О. Конт позитивизмын һәм И. Тэнның сәнгать һәм әдәбият турындагы карашларын гына түгел, ә билгеле бер күләмдә һәм дәрәҗәдә нечкә һәм катлаулы күренеш булган – пантеизмны да күрәләр. Шуңа да натуралистик стилистикага үлем, череп таркалу, ягъни яшәешнең тәмамлануын күрсәтү мотивлары да күпмедер дәрәҗәдә хас дип саныйлар. Әлеге күренеш натурализмны әдәбиятта декадентлык алымы белән дә якынайта. Г. Ибраһимов та укучыга тагын да үтемлерәк, көчлерәк тәэсир итү чарасы буларак, ачлыкның кешеләргә китергән һәлакәтен натурализмның шушы сыйфаты аша җиткерә.

«Монда үзенә бер дөнья – караңгы, куркыныч үлем дөньясы иде: келәтнең ишегеН ачуга бөтенләй ялангач бер хатын белән бер зур, киң, ак сакаллы картның гәүдәсе ята. Киемнәре юк, өсләрендәге капчык бер яккарак төшкән. Каралып, күгәренгән коточкыч тәнләре кабер җәфасын күрсәтәләр. Болардан арырак аяккуллары төрле якка таралган, биш-алты яшь баланың үләксәсе бер-беренә ябышып туңып катканлар. Балаларның гәүдәләрен башына мендәр кебек ясап сөялгән бер карчык, бик артык шешенгән тәне белән тау кебек өелеп сузылып төшкән. Ул, беренче карауда тере кебек күренә, чәчләре тузып җилкәсенә салынган, авызы елмайган рәвештә ачык, сирәк сары тешләре бер-беренә кысылганнар, пыяла күзләре ишекдән керүчегә, гүя шелтә белән, үпкәле ачу белән карап торалар…» (2, 8).

Әсәрдәге натуралистик ысул белән җентекләп язылган бу тасвирны уку җиңел түгел. Алар күңелдә бик тә авыр тәэсир калдыралар. Әсәрнең бу ягына ачлык вакыйгалары белән таныш тәнкыйтьчеләр дә игътибар итми калмый. Күренекле галим Гали Халит: «Бу әсәрдә Г. Ибраһимов осталыгына хас көчле генә сурәтләр, укучының йөрәген тетрәтерлек психологик элементлар байтак. Ләкин алынган теманың гомуми рухы чыгышсыз трагизм, куе бер вәхшәт караңгылыгы, гадәттән тыш авыр вакыйгаларны натуралистик чагылдыру белән сугарылган» (3, 24), ди.

«Адәмнәр» повестьтендагы үзәк урынны кеше һәм җәмгыять, аларның үзара мөнәсәбәте мәсьәләсе алып тора. Натуралистлар, гомумән, кешенең социаль мохиткә бәйле булуына басым ясарга яраталар. Шуңа да алар әдәби әсәрне «кешелек документы» буларак кабул итеп, көнкүрешне тулы итеп тасвирлау, кеше психикасының физиологик нигезләрен тәфсилле итеп күрсәтү белән мавыгалар.

Г. Ибраһимов та повестьта кеше яшәгән әйләнәтирәлекне натуралистларча гәүдәләндереп, һәр җөмләсе белән укучыны фаҗигале вакыйгалар һәм халәтләр чолганышына алып кереп китә. Әдип ачлыкның кешенең физик халәтенә генә түгел, ә аның психологиясенә дә тискәре йогынты ясавын күрсәтә. Кешеләр үзләренең кылган гамәлләре өчен җавап бирә алмаслык дәрәҗәгә җитәләр, кешелек сыйфатларын югалталар.

Г. Ибраһимов әсәрендә бер татар авылында барган ачлык вакыйгаларын гына түгел, ә гомумкешелек мәсьәләләрен күтәрә. Шушы авыл мисалында ачлыкның татар халкына алып килгән коточкыч газапларын ача. Кешелектән, ачлык нәтиҗәсендә, ерткычлыкка бару юлын тасвирлый. Повестьны укыган саен бөтен җаныңны шом баса. Әхмәт Сәхапов әйткәнчә: «“Адәмнәр” повесте, чыннан да, җан өшетерлек образлары, натуралистик картиналары, дәһшәтле фактографик эпизодлары һәм йөрәк яргыч психологик нюанслары белән тетрәндерә» (4, 325). Г. Ибраһимов кебек оста каләм иясе генә натуралистик сурәтләү аша чынбарлыкның тере картинасын тудырып, бу вакыйгаларны үзәк өзгеч итеп әйтеп бирә ала.

Ачлык – куркыныч хәл. Аның тәэсир көчен тиешле дәрәҗәгә җиткереп, кешеләргә китергән һәлакәтен, кайгы-хәсрәтен яшермичә ачыктан-ачык бары натурализм юлы белән генә биреп була. Әдипкә нәкъ менә шушы иҗат алымын сайларга ул яшәгән чор да этәргеч ясый. Чөнки кайбер тәнкыйтьчеләр дә натурализмның барлыкка килүен чорның үзенчәлеге һәм җәмгыятьнең тарихи халәте белән бәйләп аңлатырга тырышалар. Заманга хас булган пессимизм әдәбиятка да чынбарлыктан канәгатьсезлек, тирән кайгы-хәсрәт, әчке нигаг алып керә дип саныйлар. Француз натурализмы да пессимизм барлыкка китергән замана баласы, ул үзенең игътибарын тормышның иң күңелсез якларына юнәлтә, бөтен әйләнә-тирәдә ялган, әхлакый бозыклык һәм үлем газабыннан торган җәмгыять кенә күрә дип исәплиләр. Димәк, кара елан явызлыгына әверелеп, бөтен Идел буен урап алган каты ачлык газаплары язучыны натуралистик юл белән язарга этәрә.

Алга таба «Адәмнәр» поэмасына күз салсак, ачлыкның кеше психикасына тәэсир итү көче тагы да ачыла.

Повестьтагы һәр җөмлә акрынлап ачлык дәһшәтен арттыра бара. «Бу икесенең авыз-борыннары изелде; идәндә тапталып, аяк астында изелгән кызыл иттән башка нәрсә калмады» (2, 14), – дигән юллар, бер яктан, ачлыкның кеше аңына ни дәрәҗәдә тәэсир итүен ачып бирсә, икенче яктан, Г. Ибраһимовның бу әсәрендә натуралистик тенденциянең бик көчле булуын күрсәтә.

Ф. Бәширов та әсәргә карата: «Коточкыч ачыгу нәтиҗәсендә акылдан шашарлык булган, кеше ите ашауга кадәр барып җиткән адәмнәрнең кылганнары кырыс, хәтта әйтергә кирәк, фактографик, натуралистик тәфсиллек белән сурәтләнгән» (5), – дигән фикерне әйтә. Әйе, Ф. Бәширов хаклы. Ул вакыйгалар күңелдә авыр, гаять авыр тәэсир калдыралар. Повестьның бер генә җөмләсен дә тетрәнмичә уку мөмкин түгел. Язучы крестьян тормышының шундый күңелсез яклары, татар халкының фаҗигале үткәнен ачып, мөгаен, укучының күңелен йомшартырга, аны уйландырырга телидер. Әсәрдә кешеләрне чолгап алган тирәлек тә караңгы, кызганыч итеп сурәтләнгән. Шул тирәлектә яшәүче геройларның да дөньяда гамьнәре, ниндидер хыяллары, теләк-омтылышлары юк. Араларында аерылып торган образлар да юк, бөтенесен дә ачлык берләштерә. Ачларның кылган эш-гамәлләре дә бары тик ризык табу белән генә бәйле. Шушы ачлык хәлләрен Г. Ибраһимов Гәрәй гаиләсе мисалында гәүдәләндерә. Әнә шул бер гаилә аша авыр трагедияләрнең дәһшәтле күренешләрен укучыга җиткезә. Гаиләдә һәрберсенең аңы ризык табу, ашау кайгысы белән томаланган. Алар һәр сәгатьне, һәр минутны шул уй белән генә үткәрәләр. Гәрәйнең улы Зәйни ачлыкка тиз генә бирешергә теләмәсә дә, акырынлап ул да ачлык корбанына әверелә бара. Ә кызы Нәфисә исә, яшәүдән өмет өзеп, үлем генә көтеп ята кебек. Өйдә ризыкка алыштырырга мөмкин булган барлык әйбер дә, шул исәптән аш пешерә торган соңгы казан да калмаган. Актыккы тире бияләй дә пешереп ашалган. Әйтерсең, бу гаиләгә үлем карары чыгарылган да, алар шул карарның тормышка ашырылганын гына көтеп яталар. Тик Гәрәйнең генә бөтенләй томаланып бетмәгән аңында ризык табу уе яши. Ачыгуы соңгы чиккә җиткән Гәрәй ачлыктан шешенә башлый. Аның фикерендә ялгыш, буталчык төшенчәләр барлыкка килә. Ул үз балаларын танымый. Соңыннан, балаларына куркыныч күз карашы белән озак карап тора да, кечкенә кызының бугазына пычак сала. Гәрәйнең нәни кызы Нәфисәне суюын тасвирлаган юлларны еламыйча, әрнемичә уку һич мөмкин түгел.

Повестьта Артур Шопенгауэрның кеше табигатенә хас вәхшилек турындагы: «В глубине своего существа человек – животное дикое и жестокое. Человек единственное животное, способное истязать других ради самой цели...» (6, 150), – дигән фикерләре үзәк мотивны тәшкил итә. Г. Ибраһимов әсәрдә билгеле бер ситуациядә кешенең йомылып яткан кыргый инстинктлары уянып баш калкытуын һәм аның куркыныч ерткычка әйләнүен ышандырырлык итеп тасвирлый. Повестьның «Адәмнәр» дип аталуы ук, биредә сүзнең кешеләр турында түгел, ә алардан түбәнрәк баскычта торучы җан ияләренең яшәеше, ягъни немец философы әйткәнчә, тереклек итү өчен өзлексез көрәше турында барачагына ишарә ясый. Әсәрне уку барышында, әлеге адәми затларның кешеләргә хас булмаган гамәлләр кылып, иң зур ерткычка әверелә баруларына инанасың. Әдип Кеше дигән олуг затның куллары дөньяда матурлык тудыру, изгелекләр кылу белән бергә, үз баласының гомерен дә чикләүгә сәләтле икәнлеген күңелнең иң нечкә кылларын тетрәндерерлек итеп ача.

Ачлык гасырлар буе яшәп килгән әхлакый принципларны һәм тыюларны, мораль кагыйдәләрне җимерә. Г. Ибраһимов мондый дәһшәтле фаҗига бүтән кабатланмасын өчен чаң кагып, кешелекне кисәтә. Әдип фаҗигале кичерешләрнең тәэсирен көчәйтү өчен натуралистик эпизодлар кулланып, бу кисәтүне күңелгә үтеп кереп, кеше бәгърен теләрлек итеп әйтеп бирә ала.

Г. Ибраһимов «Адәмнәр» повестенда көнкүрештәге һәр детальне җентекләп язып, геройларның үз-үзләрен тотышын, кылган эш-гамәлләрен биологик детерминизм аша сурәтләп, һәр эпизодны натурада бирергә тырыша. Әдип тормыштан «җанлы кисәкләрне» алып ачлыкның коточкыч фаҗигасен, кешеләргә тәэсир итү көчен, натуралистик буяулар белән тетрәндергеч итеп ачып бирә. Бу дәһшәтле вакыйгаларның тере картинасын тудыра. Повестьтагы һәр вакыйга куркыныч күренешләр җыелмасыннан гыйбарәт, һәр җөмлә натуралистик буяуларга мул манылган йөрәк яргыч психологик нюанслардан, гадәттән тыш хәл-әхвәлләрдән тора. Шуңа да Г. Ибраһимов әлеге әсәрен классик натурализм үрнәгендә иҗат итә.

«Адәмнәр» повестен анализлап чыкканнан соң шундый нәтиҗәләргә киләбез. Беренчедән, Идел буендагы ачлык табигать китергән бәла-каза гына түгел. Аның тамырлары тирәнгә, большевикларның властька мәҗбүри рәвештә килеп, халыктан көчләп, соңгы бөртек икмәген дә кырып-себереп җыеп алып, аны ач калдырган продразверстка кебек мәгънәсез эш алымнарына, ягъни сәясәткә барып тоташа.

Г. Ибраһимов совет хөкүмәтенең әлеге кара җинаятен яшереп калдыра алмады, аның татар халкына алып килгән җан тетрәткеч газапларын «Адәмнәр» повесте аша киләчәк буынга язып калдырды. Моның фаҗига икәнлеген әсәрдә, тамырында «кара» сыйфаты булган сүзләрнең 26, «үлү» фигыль формасының 20, «үлем» сүзенең 22, «үлек» сүзенең 18 тапкыр кабатлануы да расласа кирәк.

Икенчедән, натурализм турында язган галимнәрнең хезмәтләренә таянып, Г. Ибраһимов «Адәмнәр»дә натурализмның натурализм-биологизм яки натурализм-физиологизм төрен файдаланган, дип әйтә алабыз.

Шулай итеп, әдип ачлыкның кешеләргә алып килгән коточкыч нәтиҗәләрен бизәмичә, шомартмыйча, «канлы кисәк», «кып-кызыл ит» кебек детальләр, кеше физиологизмы белән бәйле натуралистик тасвирлар кулланып, татар әдәбиятында натурализмның классик үрнәгенә лаек әсәр бирде, дип, һич икеләнмичә нәтиҗә ясыйбыз.

ӘДӘБИЯТ

1. Галимуллин Ф. Әле без туганчы… – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001.

2. Ибраһимов Галимҗан. Адәмнәр. – Казан: Татарстан матбугат һәм нәшрият комбинаты нәшере, 1923.

3. Халит Г. Татар совет әдәбияты тарихы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1960.

4. Сәхапов Әхмәт. Исхакый һәм XX гасыр татар әдәбияты. – Казан: Мирас. – 1997.

5. Бәширов Фәрит. Ачыла тарих битләре… // Мирас. – 1997. – № 3. – Б. 5.

6. Джованни Реале и Дарио Антисери. Западная философия от истоков до наших дней. – Т. 4. – СПб.: ТОО ТК «Петрополис», 1997. – С. 150.

# Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ «ЯШЬ ЙӨРӘКЛӘР» ӘСӘРЕНДӘ РОМАНТИК БАКЧА МОТИВЫ

*Р. Ә. Минһаҗева (Яр Чаллы)*

Статья посвящена рассмотрению романтического мотива сада в произведении Г. Ибрагимова «Молодые сердца». Анализ романа свидетельствует о том, что мотив сада в произведении Г. Ибрагимова имеет самое разное функциональное содержание. Сад – не только единственное место встречи героев романы Зии и Марьям, он и хранитель их страшной тайны. Он воплощает в себе совершенство, свободу, безграничные возможности. Новаторский характер творчества автора, как утверждается в статье, мог быть реализован только при достаточно хорошем освоении автором эстетики романтизма.

1912 елда Казанның «Өмид» нәшриятында Г. Ибраһимовның шактый күләмле әсәре – «Яшь йөрәкләр» романы басыла. Язучының бу романы XX йөз башы татар әдәбиятында психологик роман жанрын ачып җибәрүче тәүге әсәрләрдән санала.

Әсәрнең гашыйк каһарманнары Зыя белән Мәрьям төрле психологик халәтләрдә биреләләр. Яшьләрнең рухи кичерешләренең күбесе мәхәббәт белән бәйле. Гашыйклар бик еш табигать кочагында – бакчада, ай яктысында очрашалар, аның сихри тынлыгында мәхәббәтләре хакында уйланалар, бер-берсенә күңелләрен бушаталар, ихлас яратуларын аңлаталар.

Шул рәвешле, «Яшь йөрәкләр» романында мәхәббәт культы белән тыгыз бәйле мотивларның берсе – табигать. Табигатьнең образ-символы буларак әсәрдә *бакча* образ-мотивы аеруча тулы гәүдәләнеш алган.

*Бакча* – романтик әдәбиятта иң популяр һәм функциональ эчтәлеккә ия мотив. «Ул эстетик тойгылар уянуына һәм уйлану, танып белү дәрәҗәсен күтәрүгә хезмәт итә» (2, 36).

Романтик компонент буларак, бакча, иң әүвәл, романтик геройлар Зыя белән Мәрьямнең мәхәббәт мөнәсәбәтләрен яктыртуда әһәмиятле роль уйный.

Белүебезчә, романтизм бакчаларының эстетик асылы һәрвакыт диярлек алга куеп сурәтләнә. Андагы гүзәл, сихри пейзаж, кошлар сайраулары, музыка моңы, архитектур төзелмәләр, затлы хуш исләр аңкуы – барысы да үзенә бер әкияти-сәнгати дөнья хасил итә. Академик Д. Лихачев хаклы искәрткәнчә: «Сад – это прежде всего своеобразная форма синтеза различных искусств...» (3, 476).

Безнең карашка, Г. Ибраһимовның сәнгатькә тартылган геройлары Зыя белән Мәрьямне очраштыру, аралаштыру, яратыштыру өчен бакчаны сайлавы − бик тә отышлы алым. Шулай итеп, бакча – «мәдәни», зыялы табигатьле геройларга мәдәниләшкән, оккультлаштырылган табигать почмагы булып хезмәт итә, аларның мөнәсәбәтләренә аерым бер сәнгати романтика өсти.

Әдәбиятчы Н. А. Корзина фикеренчә: «Бакча романтик идеалның бер чиген гәүдәләндерә. Романтик язучыларның игътибарын ул үзенә, беренче чиратта, кеше җанының төрле халәтләренә җавап бирә алу сәләте белән җәлеп итә» (2, 39). Дөрестән дә, романтикларча тасвирланган бакчаларда бөтен нәрсә дә инсанның күңел кичерешләренә буйсынган: кешенең аң-интеллектына тәэсир итүдән бигрәк, алар хис-тойгыларны уяталар, иң нечкә күңел кылларын тибрәтәләр. «...сад – это место для мечтаний и раздумий. Он рождает неясные предчувствия и томления, вернее, способствует их проявлению, кристаллизации в душе героя...» (2, 40).

Бакча образы белән иң әүвәл Мәрьямнең беренче шомлы төшенең икенче (төш эчендә төш) – Зыяга багышланган өлешендә очрашабыз. Укучы алдында гаҗәеп гүзәл бакча манзарасы ачыла: *«Гүя илаһи бер кул белән җир йөзендәге һәммә биналар, ташлар каядыр алынды да, аларның урынына иге-чиге булмаган бакча хасил булды. Җир өстендә туфрак та, таш вә каралык та юк; һәр җирдә әллә нинди матур агачлар, күктән агылган нур белән гаҗиб бер матурлык алган аллыгөлле чәчәкләр, дөньяның матурлыгы хакында эчтән зикер әйтешеп утырган гүзәл үләннәр, белмим, тагы әллә ниләр, әллә нинди чибәрлекләр, әллә нинди хыялый нурга чумган чәчәкләр... чәчәкләр... чәчәкләр...»* (1, 14). Романтизм бакчаларына хас булганча, бу бакчада көмеш кебек ялтыраган гаҗәеп матур елга да, гүзәл чәчәкләргә күмелгән чатыр да бар.

Әмма бу төшендә аның Зыя белән кавышуы озакка бармый кала, ниндидер сәбәпләр аркасында бакчада *«бөтен тирә-як кара пәрдә илә чолганып, чәчәкләр кара көйде; дөнья, теге хыялый төсле нурдан язып, кара корымдай бер сыйфатка керде...»,* – диелә (1, 15). Шул рәвешле, төштәге гүзәл бакча күренешенең кинәттән шулай юкка чыгуы гашыйк парларга бәхетсез киләчәк юрый, киләсе аяныч хәлләрнең кайтавазы булып яңгырый.

Җитмәсә, бу төшендәге бакча сурәте Мәрьямгә бик тә үзләренең өндәге бакчаларын да хәтерләтә: *«Ике йорт арасында булган бакча − Мәрьямгә бик якын, бик таныш җир. Анда аның бик күп кыйммәтле хатирәләре саклана. Ул Мәрьямгә һәрвакыт бер дә бетми торган җуаныч та, дуст та»* (1, 17).

Хактан да, Н. А. Корзина язуынча, хыялый геройларның киләчәкне күрәзә итүче төшләренә бакча образы керүе романтик әдәбиятта еш очрый торган күренешләрдән санала (2, 42).

Яшьләрнең тәүге очрашулары, Зыя кымыздан кайтышлый, Мәрьямнең әнисе Фатима бикә туган шәһәрнең бер бакчасында була. Монда инде аларга берничә көннәр, төннәр буена иркенләп аралашу мөмкинлеге туа. Бу очрашу аларның мөнәсәбәтләренә мәхәббәт утлары иңдерә: *«Пакь вә саф балалык дәвереннән соң, мондый азатлыкта, иркенлектә беренче кавышулары булгангамы, артык вә бик үтә сагынылгангамы; әллә һәр икесе дә бу кавышуда тәмам вә тәмам пешеп җитеп, җан вә тәннәрнең барлык куәләре тәкямелгә (өлгереп җитү) ирешкән дәвере башлангангамы, – белмим, нидәндер, бу юлыгышуда әүвәлгеләргә бөтенләй башка бер хәл тойдылар. <...> бу очрашу аларның арасында булган мөнәсәбәтне чын мәгънәсе белән «романга» әйләндерде; һәм һәр ике якның йөрәгендә әүвәлгегә бөтенләй башка булган эзләр калдырды»* (1, 112–113).

Авылда булсынмы, кала-шәһәрдәме, Зыя белән Мәрьямнең бердәнбер очрашу урыны булып бакчалар кала бирә: *«...бер авылда янәшә йортларда торгач, кеше алдында күрешеп сөйләшү-фәлән мөмкин булмаса да, караңгы төннәр анларны кавыштыра, зур бакчаның куе куаклары, карт иманнәре аларны явыз күздән саклый иде»* (1, 109). Аерма тик шунда: шәһәр бакчасында алар иркенләп очраша алсалар, авылныкында кача-посып кына күрешәләр, чөнки бакча караучы картның килеп чыгуы, «уйнашчылар» дип тоттыруы ихтимал.

Шундый бер очрак була: бер-берсен өзелеп сагынган яшьләр, бик озак аерылып торганнан соң, бакчага очрашырга дип чыгалар һәм бакчачы карт күзәтүенә эләгәләр. Аның:

*– Әй, җәмәгатьчеләр!... Әй, хәлаикъ (халык)! Харап булдык!.. Тиз... Уйнашчылар!.. Уйнашчылар!...* – дип акыруы аздан гына халыкка ишетелмичә кала. Авылда шулай бер тотылып, урам буенча битләренә корым буяп йөртелгән Вәли белән Сабираны искә төшереп, тикторганда гомер буена шулай яманат алуларын, бигрәк тә яратканы Мәрьямнең пакь намусын уйнашчылык пычрагына батырудан куркып, Зыя үзенә бөтенләй ят булган гөнаһлы адымга бара: кесәсеннән револьвер чыгарып, каравылчыга ата һәм гәүдәсен бакча кырыеннан аккан суга ташлый. Икенче көнне, табигать кушуы белән, суга боз түшәлеп, мәетнең эзе югала, Зыяның бу кырын эше, шулай итеп, бары тик Мәрьям белән икесенең генә сере булып кала. Күрәбез, табигать үзенчә бу парны яклый төшә, яманатлары таралудан саклап кала.

Әмма бу бакчачы Хаҗи карт Мәрьямнең дә, Зыяның да уйларына, төшләренә кереп, «бармак янап», һәрвакыт борчып торуын әле дәвам итәчәк. *«Айлар, еллар үтсә дә, Хаҗи карт үлеменең шул мөдһиш күләгәсе үзенең куркыныч кара сурәте белән булар артыннан йөрүдән тукталмады... Төннәр, ялгызлыклар аны хәзер чакырып, Зыя илә Мәрьямнең күз алдына китереп чыгара иде»* (1, 127).

Шул рәвешле бакча яшьләрнең серен саклаучы бердәнбер шаһит функциясен дә үтәп килә. Бу хәлләрдән соң бакчадагы очрашуларына да ниндидер бер шомлылык, куркулы хис керә башлый: *«Гүя әнә шул таш өйнең бер почмагы ачылыр да, кәфеннәрен өстерәп Хаҗи карт килеп керер... яисә аның, белмим, каяндыр авыр ыңгырышулары ишетелер кебек тоела иде»* (1, 126).

Яшьләрнең азаккы, Зыяның солдатка озатыласы төнне бакчада буласы күрешүләре, бакча каравылчысы Гали карт комачау итү сәбәпле, килеп чыкмый кала. Зыяга бу вакыйга аеруча нык тәэсир итә, автор, лирик чигенеш ясап, бу каһарманның иреклек хакындагы зар тулы монологын урнаштырган: *«Менә тормыш! Менә сиңа хөррияте шәхсия! Яшәргә уйлыйсың, бәхет эзлисең! Бар да әрәмгә! Бар да юкка!.. <...>.*

*Олуг Тәңре, син кайда, син кайда? Күрәсеңме, без нинди хәлдә? Син бит безне хәят өчен яратмагансың, син безне туган көнебездән алып авыр трагедия эченә ташлагансың! Синең үзеңнән бер чаткы булган җаннарымыз бер нәрсә тели; безнең йөрәгемез табигатьтән тәэсир ала; музыканы гашыйклар зикере кебек тоя; безгә хәят кирәк, безгә ирек кирәк...<...> ... Үләм, Ходаем, үләм, бу тормышның тарлыгыннан, кысуыннан үләм. Моның тупаслыгыннан, моның сасы вә тар һавасыннан тончыгып үләм!*

*Әй, Ходаем! Түзем бир! Чыдам бир! Юк, яңлыш әйтәм, түзем кирәкми, чыдам да бирмә: син безгә талантлар бир; син безгә бу тормышның тар рамкаларын ватып, җимереп ташларлык куәтләр бир! Тормыш киңәйсен, һәркем ирекле булсын, дөньяңда матурлык белән ирек кенә солтанлык итсен...»* (1, 208–209).

Сөйгәне белән ахыргы очрашуы барып чыкмаудан *«...аның чыдамы югалды. Бүген ул эчендә яшәгән тормышының артык тарлыгы, артык кысанлыгы, анда тончыгып үләрлек мәртәбәдә сасылыгын бигрәк ачык тойды – шул гади вакыйга сабыр савытын таштырды»*, – дип яза автор (1, 210).

Әйтергә кирәк, Зыяның романтик өзгәләнүендә шул чор яшь йөрәкләрнең изелгән, авыр рухи халәте, хыял-омтылышында исә аларның эстетик идеаллары, киләчәккә баглаган изге өметләре чагылыш алган.

Романтик бакчаның әсәрдәге башка роленә килгәндә, аның эстетик вазифасына да ассызыклау мөһим. Чөнки бакча – шәһәр халкын үзенә сыендыручы, аларга иркенлек, рәхәтлек, шатлык бүләк итүче гүзәл табигать почмагы, эстетик ләззәт алу чыганагы, үзенчәлекле мәдәният үзәге ролен дә үтәп килә: *«Яңгырдан качып, тар, кысык биналарга, дивар эчләренә бикләнгән кала халкы, бу минутларны ганимәт белеп (файдаланып, бәхет дип санап), киенде, ясанды да зур урамнарга, өлкән бакчаларга агылды. <...> Бакчаның агачларыннан куәтле бер ис аңкый; халык – ирләр, хатыннар, яшьләр, парлап-парлап, шунда агылалар; музыка башка вакытта булмый торган бер тәэсир белән моңлана, нидер сөйли, каядыр чакыра, ниндидер үткән көннәрне, үзенә хас бер тел белән хикәят итеп, әллә нинди вакытларны искә төшерә, кемнедер сагындыра иде»* (1, 288).

Күрәбез, әсәрдә табигать-бакча образы халык һәм аерым герой язмышы аларның кичереш-тойгылары, кылган гамәлләре белән тыгыз бәйләнештә бирелә. Символ дәрәҗәсенә җиткерелгән бакча образы каһарманнарны төрле психологик халәтләрдә сурәтләүгә ярдәм иткән. Романтик бакча Г. Ибраһимовта җанлы итеп, гашыйк каһарманнарның дусты, сердәшчесе, хәтта яклаучысы итеп бирелгән. Ул туктаусыз вакыт әйләнешенә, гүзәл яшьлек чорының кыскалыгына да ишарә ясаучы символ. Әсәрдә аның ел фасылына нисбәтле бирелүе дә аерым мәгънәгә ия: яшьләрнең күп очракта караңгы төннең ай яктысында яисә көзге бакчада очрашулары киләчәкләренең караңгы төгәлләнүенә ишарә ясап килә.

«Яшь йөрәкләр» романындагы романтик бакча образы әдипнең үз иҗатында табигать культына өстенлек бирүен һәм, бер үк вакытта, аның романтик эстетика кануннарын яхшы белүен дә дәлилли.

## ӘДӘБИЯТ


1. Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. II т.: Яшь йөрәкләр. Казакъ кызы / Текстларны, искәрмәләр һәм аңлатмаларны А. Ш. Шамов, Р. Р. Гайнанов әзерләде. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. – 478 б.

2. Корзина Н. А. Сад как мотив литературы немецкого романтизма / Романтизм: эстетика и творчество: сб. науч. тр. к 80-летию со дня рождения д-ра филол. наук, проф. Н. А. Гуляева. – Тверь: Твер. гос. ун-т, 1994. – С. 36–45.

3. Лихачев Д. С. Избранные работы: в 3-х т. Т. 3: Человек в литературе Древней Руси; О «Слове о полку Игореве»; Литература – реальность – литература; О садах.– Л.: Худож. лит., 1987. – 520 с.

# ТАТАРСКАЯ ПОВСЕДНЕВНОСТЬ КОНЦА XIX – НАЧАЛА XX ВЕКА В РОМАНЕ ГАЛИМДЖАНА ИБРАГИМОВА «МОЛОДЫЕ СЕРДЦА»

*Л. Р. Габдрафикова (Казань)*

Литературные произведения, как известно, являются ценными источниками для исторических исследований. Конечно, при условии, если автор – современник тех лет. Никто не будет отрицать роль произведений Льва Толстого при изучении Отечественной или Крымской войны. Пушкинского «Евгения Онегина» давно уже окрестили «энциклопедией русской жизни». Татарская литературная классика пока мало используется для реконструкции начала XX века. Хотя в прозе Гаяза Исхаки, Фатиха Амирхана и, безусловно, Галимджана Ибрагимова есть дух того времени, «картина мира» татарского мусульманского общества.

Для данной статьи мы выбрали роман Галимджана Ибрагимова «Молодые сердца», опубликованный в 1912 году. События в произведении также разворачиваются в начале XX века. Ясно очерчивается борьба старого и нового, разные настроения в обществе, отношение к новым явлениям. Речь идет о времени после 1905 года. В центре повествования две сельские семьи – семья муллы и семья мирзы. Обе старательно противопоставляют себя миру «мужиков» – простых крестьян. У мирзы Гарая это получается более естественно. Вероятно, в силу происхождения и сложившихся традиций поведения. Интересно, что даже при обращении к его дочери Марьям односельчане обязательно употребляли слово «туташ» (барышня) – Марьям туташ. Обычных крестьянок называли просто по имени.

Мулла Жалял, выделившийся из общей массы благодаря своей образованности, без врожденных привилегий, эту приобретенную инаковость пытается подчеркнуть красивой одеждой, хорошим экипажем, добротным домом, городским интерьером, новыми манерами.

Отдельные моменты романа указывают на то, что герои проживают вдали от Казани. Скорее всего, это Уфимская губерния. Как известно, там родился и сам Галимджан Ибрагимов. Также в семье сельского муллы. И если высматривать дальше автобиографичные краски, то бросается в глаза следующий эпизод. Мулла Жалял, уловив новое веяние времени, но не определившись до конца, что выгоднее, отдает сыновей в разные медресе – старшего в новометодное, младшего – в старометодное… Ибрагимов тоже некоторое время учился в кадимистском медресе «Валия» в Оренбурге, а его старший брат Шакирджан в «Хусаиние». Объясняли это они тем, что Галимджана не взяли в новометодное медресе по болезни (1, 53).

Кроме того, писатель акцентирует внимание еще на одной интересной детали. Как известно, в новометодных учебных заведениях год начинался уже в сентябре и длился до конца июня. В старометодных он больше зависел от сельскохозяйственного уклада. Шакирды собирались в медресе лишь поздней осенью и расходились по домам уже ранней весной, к началу полевых работ. Крестьянин, прежде чем отдать сына в то или иное медресе, руководствовался не только идеологическими соображениями, но и бытовыми моментами. Сможет ли он справиться с полевыми работами без помощи сына-шакирда? Вместе с джадидскими медресе в татарском обществе происходил слом традиционного уклада жизни. Человек все меньше подчинялся природе.

Деревенская жизнь более размеренна и менее подвержена переменам. Жизнедеятельность татарских слобод в городах до середины XIX века мало чем отличалась от неё. Крупные медресе действовали как в городских центрах, так и в селах. Выделялись лишь большие базары. Но во второй половине XIX века динамичнее развивается сфера услуг. С появлением в жизни татар театров, библиотек, клубов, общественных садов и т. д. произошел окончательный разрыв между городом и деревней. Это остро ощущала дочь мирзы Гарая – Марьям, скучая в деревне без занятий, без общества; тяжело было и сыну муллы Жаляла – Зии. Из-за своей сословной принадлежности он не мог общаться с крестьянскими парнями и участвовать в обычных деревенских развлечениях. Мешал статус «махдума» (сына муллы). Другое дело в городе – полная анонимность. И Зия позволяет себе даже походы в публичные дома. Интересно, что привлекала его там возможность не таясь слушать музыку. Только там никто за это не осудит. Действительно, в увеселительных заведениях работали многие татарские музыканты, участвовавшие потом в работе клубов, народных оркестров. Такая карьера была у музыканта Гали Зайпина (2).

Основной фон романа – это призыв Зии в армию. Вся семья и окружение взволновано будущим рекрутским набором, вернее, предстоящим осмотром призывников. Кого-то возьмут, кого-то по болезни или по иной причине (отец похлопотал перед начальниками) оставят. Тема рекрутства и армии уже поднималась ранее в татарской литературе Гаязом Исхаки в повести «Солдат». Тогда главным героем у Исхаки был простой крестьянский сын. Галимджан Ибрагимов описывает сына муллы – «махдума», которого даже в деревне ограждали от общения с ровесниками – «мужицкими» сыновьями. Поэтому предстоящая служба для его окружения стала полной катастрофой. Не только из-за потерянных лет, но и из-за психологического слома. Менялся сам военнослужащий, менялось и отношение к нему самому. Эти изменения в восприятии будущего рекрута Зии хорошо иллюстрируют рассуждения мамы Марьям – дворянки Фатимы: «Как можно столько лет ждать человека, который ушел наравне с сыновьями мужиков, нацепив желтый армяк, и будет теперь питаться одной картошкой да начищать двухкопеечным “ефрейторам” сапоги; как можно ждать такого бедолагу, чтобы выйти потом за него замуж?» (3, 454). Зия пытается както повлиять на ситуацию. Он сильно похудел, и, глядя на него, многие думали, что он голодает специально. Этот способ был довольно популярен среди призывников. Так, казанский врач Алексей Сухарев отмечал, что татары стараются избежать воинской повинности из-за религиозных убеждений, невозможности соблюдать пост, войн с единоверцами. Надо добавить, что пугала их и нехаляльная пища. Многие возмущались тем, что

в армии есть православные священники, но нет мулл. Поэтому пользовались «симуляцией и даже членовредительством», одним из распространенных практик было «истощение» (4, 75). В романе главный герой не голодал, но решил прибегнуть к услугам медиков. Знакомый аптекарь дает ему неизвестное лекарство, заверив, что после него его уже никто не тронет. Однако чудо-средство совсем по-другому отразилось на организме Зии. Он почувствовал себя очень плохо, падал в обмороки, некоторое время пролежал в больнице. Из-за этих переживаний даже похудел. В своей рецензии на роман «Молодые сердца» историк и писатель Газиз Губайдуллин пишет о том, что общественное значение произведения заключается в акцентировании Г. Ибрагимовым внимания читателей на вопросе под условным названием «сәхәрсез руза» (голодовки рекрутов). Эта проблема мусульман в российской армии (5, 84).

Любопытны описания татарских рекрутов в день осмотра. Этот эпизод вырисован довольно подробно. «Среди них нет никого в обычной одежде. Каждый приоделся, как мог, все нарядные» (3, 341). Будущие солдаты будто надеялись своей нерядовой одеждой задобрить начальство, подчеркнуть свою значимость и, возможно, избежать набора. Рядом с нарядными призывниками ходят их старшие братья, в неприметной одежде. Они озабочены тем, кем бы заменить отбывшего на службу работника. По сравнению с татарами более буднично выглядят рекруты-представители других народностей, как будто для них это самое обычное дело и ничего особенно не происходит. Татарские же рекруты воспринимали осмотр как некое «чистилище» и готовились к нему как к последнему дню. Так же относились к ним и в деревне, как к людям обреченным.

Одна из линий романа – это личная трагедия муллы Жаляла, крах его надежд. Он верил, что сыновья пойдут по его стопам, станут духовными служителями. Однако и Сабир, и Зия отказались от подготовленной родителем дороги. Сабир, бросив учебу в медресе, решил заняться простым крестьянским трудом. Зия мечтает о музыке. Но выбор старшего «махдума» Сабира кажется малоубедительным. Хотя такого рода противостояние родителям на тот период было довольно частым явлением. Чаще всего бывшие шакирды вместо служения муллой выбирали светскую деятельность, работу мугаллимами, журналистами и т. д. Часть из них, после отчисления из медресе, пополняли ряды пролетариата. Как писала большевистская газета «Урал» в 1907 году, из оставшихся не у дел учащихся «богатые шакирды начали обучаться по-русски, бедные искали работу, некоторые стали фабрично-заводскими рабочими» (6, 397). Способствовали этому буржуазные перемены в обществе. Появились новые возможности наемного труда, прежде всего для интеллектуальной деятельности. Мулла же был зависим от общины. Он не имел ни фиксированной заработной платы, ни особых привилегий. Образ мулл, как, впрочем, и шакирдов, претерпел серьезные изменения благодаря работе татарских газет и журналов, в которых высмеивались их невежество, жадность и другие качества.

Вместе с тем менялось и само религиозное сознание. У части молодежи вера была уже не столь очевидной, само собой разумеющимся состоянием. Она подвергалась сомнениям, иногда и вовсе отрицалась. В романе Галимджана Ибрагимова нет рассуждений на этот счет. Но поведение героев указывает на царящие настроения. Например, в одном из эпизодов приводится случай самоубийства молодого парня Салима. Как известно, в исламе это тяжкий грех. У Салима не было явных причин для суицида. «Человек почти умирает от голода, уходит на каторгу – и там терпит... У этого отец – богач, дом – полная чаша, все есть … Ни в каком деле не был замечен, ничего не натворил... Бог его знает, бог знает – видимо, не убежать от судьбы...» – рассуждают односельчане по этому поводу (3, 509). Религиозные ритуалы также выполнялись не в полной мере. В романе из сельских прихожан выделялся единственный человек, не пропускающий намазы и читающий их в мечети. За прилежное поведение он получил прозвище «шакирд». Односельчане уважали его за это, но сами не спешили следовать данному примеру.

Другие противоречащие исламу примеры – пьянство и открытые конфликты с родителями – конечно, случались и раньше. Но на рубеже XIX–XX веков «проблема отцов и детей», помимо эмоционально-бытовых моментов, имела еще некоторую идеологическую окраску. Противопоставление нового понимания мира старому выражалось как во внутреннем конфликте, так и во внешних проявлениях, вроде одежды, еды, досуга. В «Молодых сердцах» старшее поколение придирается к молодежи за ношение «длинных волос», «ремней» и т. п. Вопрос о несоответствии облика молодых образу мусульманина – один из главных камней преткновения между родителями и детьми начала XX века. Среди женщин – это проблема хиджаба. Например, молодая жена Сабира, Камиля, по велению мужа не закрывает лицо и не носит длинные платки. Ее не одобряют ни односельчане, ни некоторые родственники. Противоречия не заканчиваются на вопросах внешнего вида. Зулейха абыстай, мать Зии, не понимает предпочтений сына в еде. Она удивляется тому, как сын вместо чая пьет черный кофе. Действительно, среди интеллигенции кофе стал довольно популярным напитком. Вероятно, здесь играло роль и влияние Османской империи.

Еще большее недовольство вызывали музыкальные инструменты Зии. Для его матери они равнялись прелюбодеянию, страшному преступлению. Для сына же музыка – смысл существования. Он преображается, когда музицирует сам. Интересно, что в татарском мусульманском обществе музыка развивалась в основном благодаря простым слоям населения. Вопреки запретам многие играли на музыкальных инструментах и пели. Связующим звеном между бедными слоями и богатыми было медресе, где втайне от мударриса шакирды разучивали песни и музицировали. Главный герой «Молодых сердец» Зия открыл в себе любовь к музыке именно в этой среде.

Менее агрессивно, но с недоверием воспринималась светская литература. Такие книги были не особо распространены. Уважением среди подавляющего большинства пользовались лишь религиозные сочинения. Интересны рассуждения героев романа о новой книжной продукции. «Вот времена... вот катастрофа... Дескать, написал песенку, написал сказку, называй это книгой, да еще и получай потом за это деньги... – возмущается пожилой мулла. – Если нужны такие глупости, вон приходите к нашему дурачку Хафизу: он вам без денег, за один день напишет пять сказок... сочинит и песню!..» Аналогичная оценка была дана и перио-

дической печати. «Газеты? ... Кто выпускает эти газеты <...> Думаете, там есть хоть один порядочный человек?.. На хлеб насущный не могут заработать, вот и получают деньги, продавая сплетни мира» (3, 347–348). У молодого поколения совсем иное отношение к светским книгам, к газетно-журнальной продукции. К примеру, Марьям в городской женской школе увлеклась турецкими романами, и они долгое время составляли основную ее радость.

Буржуазные формы досуга, светская литература, новый внешний вид опосредованно вели к внутреннему конфликту – рушился традиционный уклад жизни. Иные модели поведения диктовали и перемены, произошедшие в социально-экономической сфере. В буржуазном обществе у человека есть выбор. Конечно, он может зависеть от материальных условий, но перед ним уже не стоят сословные барьеры, традиции общины и т. д. Так, в «Молодых сердцах» каждый пытается сделать свой выбор. Сабир против воли отца становится крестьянином и женится на девушке, которая понравилась ему самому, а не родителям. Меньше повезло Зии и Марьям. Зия не успел осуществить свою мечту – стать музыкантом. Помешали служба в армии и неожиданная смерть. Марьям поздно поняла, что могла бы повлиять на судьбу и настоять на своем решении перед матерью. Потом у нее был шанс для развода, но она им не воспользовалась. Семейная драма Марьям имеет печальный финал. Молодую женщину, обвинив в смерти нелюбимого супруга, отправили на каторгу. Перед нами три уровня противостояния старого и нового миров. У Марьям – это скорее внутренняя борьба, она убеждает саму себя в необходимости решительных действий. Зия, с одной стороны, решил начать новую жизнь, с другой – сомневается в правильности выбора, опять возвращается к учебе и вновь её бросает. Более последователен и решителен Сабир. Он точно знает, как хочет жить. Даже мулла Жалял оставляет махаллю и уезжает в Мекку. Семья так и не дождалась его возвращения. Сабир называет это «чем-то вроде самоубийства», но не в физическом понимании.

В романе «Молодые сердца» вырисовывается типичная картина повседневности, со всеми тенденциями. Но к литературному источнику надо подходить с осторожностью. Так, Газиз Губайдуллин критикует Галимджана Ибрагимова за то, что в описании типажей есть шероховатости. По его мнению, не совсем правдоподобны образы мирз – татарских дворян (5, 79). Несмотря на автобиографические моменты, писатель, прежде всего, реализовывал собственные представления и идеалы, не всегда соответствующие действительности. Лишь сопоставление эпизодов романа, отдельных деталей с информацией из других источников (архивными данными, периодической печатью и т. д.) помогает выделить документальные моменты и использовать их при реконструкции реалий татарского мусульманского общества рубежа XIX–XX столетий.

ЛИТЕРАТУРА

1. Ибраһимов М. Туганым турында // Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр. – Казан, 2007. – 544 б.
2. Национальный архив Республики Татарстан. Ф. 41, оп. 4, д. 308, л. 35.
3. Ибраһимов Г. Яшь йөрәкләр // Г. Ибраһимов. Сайланма әсәрләр. – Казан, 1957. – 528 б. (Цитаты переведены автором статьи.)
4. Сухарев А. Казанские татары (уезд Казанский). Опыт этнографического и медико-антропологического исследования. – СПб., 1904. – 196 с.
5. Гобәйдуллин Г. Яшь әдәбиятыбызда – Яшь йөрәкләр // Т. Ш. Гыйлаҗев. Рецензияләрдән тәгъзияләргә. XX йөз башы татар әдәбияте тәнкыйте. – Казан, 2008. – 254 б.
6. Ибраһимов Г. Татарлар арасында революция хәрәкәтләре // Г. Ибраһимов. Тарихи хезмәтләр (1911–1927). – 7 том. – Казан, 1984. – 540 б.

# ТАТАР ДЕТЕКТИВЫ «ТИРӘН ТАМЫРЛАР» БЕЛӘН БАЙ

***Р. Р. Галиуллин (Яр Чаллы)***

Данная статья посвящена творчеству выдающегося классика татарской литературы Г. Ибрагимова. Анализируется его роман «Тирән тамырлар» («Глубокие корни») как детективное произведение. Делается вывод, что это первый татарский советский детектив, что в 20–30 годы XX века происходит трансформация детективной формы и все события, герои романа характеризуются с позиции классовой принадлежности.

Совет чоры татар әдәбиятынның башлангыч чорын, 1920–1930 еллар әдәбиятын күзәтсәк, галим, язучы Галимҗан Ибраһимов иҗаты беренче сафларда тикшерелә. Үзенең әсәрләрендә ул революция вакыйгаларын, ялкынлы революционерларның аяусыз көрәшен, яшь совет хөкүмәтенең аякка басуын һ. б.ны сурәтли.

Татар совет әдәбиятының беренче детектив әсәре дә Г. Ибраһимов исеме белән бәйле. «Революциядән соңгы әдәбиятыбызда детектив сюжет алымнарына беренчеләрдән булып Г. Ибраһимов үзенең «Тирән тамырлар» романында мөрәҗәгать итә» (2, 250). Ф. Хатипов та бу романның детективка якын булуын әйтә: «Автор биредә детектив материал белән эш итә» (6, 11).

Детектив әсәрләрнең берничә үзенчәлегеннән чыгып, «Тирән тамырлар» романының детектив әсәр икәнлеген түбәндәге фикерләр белән исбатларга мөмкин:

1. Г. Ибраһимов романының беренче битендә үк укучы Фәхринең үле гәүдәсенә тап була. Автор аның үз үлеме белән үлмәвен дә әйтеп бирә. «*Фәхрине үтереп ташладылар*» (2, 137).

2. Совет чорында детектив әсәр трансформация кичерә, шулай булгач шәхси мөнәсәбәтләр сыйнфый позициягә күчә, ягъни теге яки бу шәхеснең кайсы катламга, сыйныфка бәйле булуыннан гыйбарәт. Ф. Хатипов шул ук фикерне әйтә: «Традицион җинаять һәм җәза сюжетын Г. Ибраһимов капма-каршы торучы көчләрнең социаль тамырларын ачып, кешеләрнең бу көрәшкә катнашу психологиясен ачыклау өчен куллана» (5, 20). Кеше гомере, кеше каны соңгы планда. «*Хуҗалык,*

*сәясәт, үлем – өчесе бер-бер артлы тезелделәр»* (1, 302).

3. «Тирән тамырлар»дагы геройларның барысын да тискәре һәм уңай персонажларга җиңел итеп бүлеп була, Г. Ибраһимовның уңай геройларына карата симпатиясе дә сизелә. Ләкин монда да шул ук сыйнфый күзлектән бүленеш күзәтелә. «Тирән тамырлар»да персонажның ниндилеге бер үлчәм белән – революциягә, гражданнар сугышына мөнәсәбәте, катнашы белән билгеләнә» (5, 12). Автор советларны да уңай яктан гына гәүдәләндерми. Садыйкның Зирекледәге «кара көчләр»гә каршы көрәше, аның боерыгы нигезендә ишанны атып үтерү моңа ачык мисал. Язучы кулланган чагыштыруларга күз салсак, көчләрнең кайсысы – чынлап кара, кайсысы ак, дигән икеләнүле сорау туарга мөмкин. *«Чәүкә көтүенә лачын сугылды. Яисә сарыклар өстенә көтелмәгән арыслан сикереп төште. Ишанның бөтен йорты, өйләре, кешеләре, бөтен Зирекле авылы менә шулай кайный башлады»* (1, 355).

4. Традицион детективтагы кебек үк, романда ике конфликт аерылып чыга: җинаятьче – корбан, җинаятьче – җинаятьне ачучы конфликтлар. Шулай да әсәрдә конфликтның тамырлары тирәнрәк икәнлеге ачыла, бу – сыйныфлар конфликты. Фәхретдин Гыйльманов белән көрәштәше Паларусов – ялкынлы революционерлар, большевиклар, Вәли Хәсәнов – бай, сыйнфый дошман, контра.

5. «Тирән тамырлар»да традицион өч төп персонажны аерып күрсәтергә мөмкин: корбан – Фәхри, җинаятьчене ачкан кеше – Паларусов, җинаятьче – Вәли Хәсәнов. Җинаять тикшерү эше роман дәвамында алып барылса да, Вәли бай белән, аның иптәшләре белән укучы әсәр башында ук таныштырыла.

6. Совет чорындагы детектив әсәрләрнең сере бары тик бер юл белән чишелгәне факт – җинаятьне ачкан кеше хокук саклау оешмасыннан гына була ала. Бу да, билгеле, сәясәткә бәйле. Үзлектән эшләүче детектив җинаятькә, җинаятьчегә, корбанга сыйнфый күзлектән карамаска да, партия сызыгын якламаска да мөмкин. Милиция, прокуратура хезмәткәрләре исә, совет идеологиясен яклап, сыйнфый күзлектән чыгып хөкем чыгара, җәза бирә.

7. Автор детектив ретроспекция алымын киң куллана. Фәхри белән дә укучы ретроспекция алымы ярдәмендә генә таныша. Аның кем булганлыгы, ничек дөнья күргәне, карашлары, дус-ишләре, дошманнары һ. б. аның фаҗигале үлеменнән соң гына беленә.

Детектив романнарда ярдәмче геройлар мөһим роль уйнамаска да мөмкиннәр. Бу очракта алар сыйнфый фон булдырырга ярдәм итәләр. Аларның истәлекләре аркылы Фәхри образы тулырак ачылып бирелә, үтерелү мотивлары күрсәтелә һ. б.

Детектив алымнардан тыш, Г. Ибраһимов үз романында сыйнфый көрәшнең ни дәрәҗәдә кырыс, түгелгән канның ни кадәр күп булуын, вәхшилекне сурәтләү өчен натуралистик алымнарга еш мөрәҗәгать итә. Шулай да аларның күбесе сюжет сызыгына бәйле түгел. Җиһанша картның крестьяннарның баш күтәрүләрен гаскәр тарафыннан бастырылуын тасвирлавы, Фәхринең этисе – Тимершаны үтерү күренеше моңа ачык мисал: «*Шуннан яшь әфисәр кызып сүгенде дә штык белән Тимершаның эчен каерып җибәрде. Аннан эчәгеләр, каннар агып, Тимершаның авызын, йөзен, кулбашларын, бөтен, гәүдәсен буядылар...* » (1, 175).

Әсәрдә сурәтләнгән кулаклар бунты да үзенең вәхшилеге белән укучыны тетрәндерерлек. Биредә дә натуралистик алымнар кулланып сурәтләнгән комсомол Бирәхмәт белән мөгаллим Хәбибнең үтерелү күренеше, аларны атка бәйләп авыл буйлап йөртүләре игътибарга лаек. «*Аның кулы, аягы сынды, башы изелде, эчәгеләре агып чыкты. Идән кара кан белән тулды. Әллә ничә мужикның кулы, җиңе канга буялды.<...>Ат ни эшләргә, кая барырга белмичә, туры килгән бер йортка керә башлады. Арканга тагылган мөгаллимнең канлы башы капка баганысына килеп уралды. Ат бер омтылды – ала алмады, тагы омтылды – тагы ала алмады, шундагы кечкенә этнең өрүеннән куркып, өченче тапкыр омтылган иде – баш, ике баганага кысылып, өзелеп калды. Бирәхмәт белән Хәбибнең гәүдәсен өстерәп, айгыр абзарга чапты*» (1, 257–258).

Ачлык елларын да автор язмыйча калдырмый. Г. Ибраһимов кешеләрнең җәфа чиккәннәрен, ачлыктан интеккәннәрен сурәтләп бирә. Иң куркынычы – балачаганың шул ачлыкның корбаннарына әверелүләрен күрсәтә. «*Өлкәннәр бер хәл! Балаларның язмышлары бик авырга калды. Башта эчләрен тырнап-тырнап: – Икмәк бир! Икмәк бир! Икмәк бир! – дип еладылар. Талашып-ызгышып беттеләр. Хәзер инде тындылар. Куәтләре юк. Йөзләре кибеп саргайды. Тәннәрендә ит әсәре калмады, кара саргылт җыерчыклы тиреләре кечкенә, нечкә сөякләренә ябышып катты. Алар хәзер җыерчык битле, җитмеш яшьлек карчык кебек күренәләр. Күзләрендә нур, җан бетте, сүнеклек капланды, аннан тик хәлсез ачлык газабы карый. Бирсәң, сүзсез чәйнәп йотлыгалар, булмаса, дәшми, тынмый, бозлы, салкын почмакта, иске киемнәргә уралган килеш, бөгәрләнеп ята бирәләр*» (1, 248–249).

Күргәнебезчә Г. Ибраһимов үзенең әсәрендә революция чорын, гражданнар сугышы елларының ни дәрәҗәдә авыр булуын сурәтли. Шулай да «Тирән тамырлар»да, детектив – башлангыч көч, икәнлекне исәпкә алып, аерым нәтиҗәләр ясарга мөмкин.

1917 елгы революциядән соң әдәбиятта яңа этап – социалистик реализм дәвере башлана, моннан чыгып, барлык әсәрләр җәмгыятьне, анда барган процессларны сыйнфый күзлектән сурәтләүгә дучар ителә. Детектив жанр формасы буржуаз әдәбиятның үрнәге булса да, совет әдәбиятында да юкка чыкмый. Аның беренче үрнәге булып Г. Ибраһимов әсәре тора. Шул ук вакытта детектив әсәрләр трансформация кичерә – шәхси мәнфәгатьләр арткы планга күчеп, сыйныфлар көрәше алга куела.

Шулай итеп, Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романы татар әдәбиятында – икенче, ә революциядән соң исә совет чорында иҗат ителгән беренче детектив әсәр буларак бәяләнергә хаклы, гәрчә бу әсәр совет әдәбияты тарихында детектив буларак каралмаса да. Бу роман совет әдәбияты тарихында бары тик сыйнфый күзлектән, социалистик реализм методының ачык мисалы рәвешендә генә анализлана килде. Яисә галимнәр аны, күмәкләштерү сәясәтен сурәтләүче әсәр, дип карадылар. «Күмәкләштерү сәясәтенең башлануы белән авыл романы, социалистик канунның бер үзенчәлегенә әверелгән колхоз романы жанрына трансформацияләнә» (5, 279). Бу күзлектән Г. Ибраһимов әсәрен М. Шолоховның «Күтәрелгән чирәм» («Поднятая целина») романы белән янәшә куеп була. «Авылдагы бәрелешләр турында бездә тәүге сүз әйтүче

Г.Ибраһимов булды. <…> Әдәбият белемендә бу роман күмәкләштерү турындагы әсәрләр рәтендә карап йөртелә» (5, 9).

«Тирән тамырлар» татар совет әдәбиятында яңа жанр формасына нигез салды, алга таба аңа мөрәҗәгать иткән авторлар, һичшиксез, Г. Ибраһимов тәҗрибәсен кулланганнар. «Нәтиҗәдә, детектив хикәяләү алымнары социалистик реализмның иҗат палитрасына органик рәвештә килеп керәләр һәм аны баеталар» (2, 252).

Роман үзе татар әдәбиятында детектив формалашуның мөһим үрнәге булып тора, чөнки XX гасырның икенче ярысында иҗат ителгән детектив әсәрләр туры-дан-туры сыйнфыйлык позициясенә таянып иҗат ителмәсәләр дә, соцреализм кысаларыннан азат була алмаганнар. Г. Ибраһимов әсәренең персонажлары сыйнфый дошманнарга түгел, ә социалистик канун-нарга буйсынмаган һәм бу кануннарны саклаучы милиционерлар образларына әвереләләр.

Гомумән, совет чоры әдәбиятка гына йогынты ясамаган билгеле. Ул зур бер дәүләттә яшәгән кешеләрнең тормышын гына түгел, ә аларның фикер сөрешен үзгәртергә тырышкан аянычлы, канлы дәвер булып тарихка кереп кала.

ӘДӘБИЯТ

1. Ибраһимов Г. И. Тирән тамырлар. Сайланма әсәрләр: 8 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. – Т. 3.

2. Мусин Ф. Детектив турында // Көмеш көзге: Әдәби тәнкыйть мәкаләләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1989.

3. Скороспелова Е. Б. Русская проза XX века: от А. Белого («Петербург») до Б. Пастернака («Доктор Живаго»). – М.: ТЕИС, 2003.

4. Хатипов Ф. Мөлкәтебезне барлаганда // Мөлкәтебезне барлаганда: Иҗади портретлар, тәнкыйди-теоретик мәкаләләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003.

5. Хатипов Ф. Истоки психологизма татарской прозы // Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман: Тууына 115 тулуга багышланган фәнни конференция материаллары. – Казан: Фикер, 2002. – Б. 20.

## ПРОИЗВЕДЕНИЯ Г. ИБРАГИМОВА И ТАТАРСКАЯ КЛАССИЧЕСКАЯ ЛИТЕРАТУРА ДЛЯ ДЕТЕЙ

*А. Р. Абдулхакова (Казань)*

В структуре татарской детской книги важное место принадлежит произведениям классической литературы. Понятие «классика» включает в себя художественные произведения, созданные, как правило, с конца XVIII в. по начало XX в. Под классической литературой мы понимаем лучшие произведения литературы прошлого и настоящего, имеющие глубокую идейно-художественную ценность, неповторимое содержание. Данные произведения имеют непреходящую ценность для национальной и мировой культуры. В понятие классики для детей также входит литература, созданная после 1917 года, получившая название «советская детская классика», а также литература зарубежная, написанная специально для детей, а затем переведенная. Понятие «классика» изменчиво, обусловлено конкретно-исторической ситуацией восприятия текста художественного произведения. Произведение воспринимается как классическое, когда оно соответствует жизненным интересам современных читателей (1).

Чем вызвано такое постоянное обращение отечественных издателей к произведениям классической литературы? Прежде всего, тем, что в них представлены идеи и мысли, определяемые как «вневременные категории» (2). Обращение к вечным человеческим ценностям обусловлено периодами кризисных ситуаций развития общества, когда именно в прошлом общество пытается найти ответы на современные злободневные вопросы. И здесь особую роль начинает играть классическое наследие. «Причисление к классике – это возведение в высшую степень по критериям истины, красоты, нравственности и т. п. Это оценка общезначимая, сформированная в общественном сознании, ставшая объективной» (2, 69).

Выделение в структуре классического наследия классики для детей позволяет обозначить определенный пласт литературы, который отличается от классики для взрослого читателя. Во-первых, этот список значительно меньше, так как в него не входят многие произведения мировой литературы, недоступные детям из-за психолого-возрастных особенностей; во-вторых, многие классические произведения взрослой литературы были пересказаны (переложены) для детей, в силу чего стали фактически совершенно другими. То есть это произведения, которые имеют одновременно автора и адаптатора. Это больше относится к переводам, так как уже самим переводом и адаптацией сделан определенный выбор.

Что касается издания классического наследия в СССР, то здесь мы наблюдаем жесткий отбор, освещение отобранного с позиций идеологии, подмену эстетических категорий социальными и т. п. Данный тезис хорошо иллюстрируется материалами Института детского чтения. «По данным исследований Института конца 1920-х годов, 1924 г. можно считать годом создания советской детской книги. Уже в 1930 г. основная масса библиотек имеет фонды, на 60–70% состоящие из книг, изданных после 1923–1924 гг., а некоторые вообще не знают старых книг» (2, 72).

Как показало исследование «Состояние и тенденции развития чтения детей и подростков (1988–1992)», не все современные дети воспринимают этические идеалы прошлого. Многим воспитанным в другой системе ценностей они кажутся непонятными и странными. И это естественно, так как глубина восприятия всегда зависит от личного дарования и знания, от предшествующего индивидуального опыта. Из мировой и русской классической литературы для детей в Татарии в разные годы были изданы произведения А. С. Пушкина, Л. Н. Толстого, В. В. Маяковского, Н. А. Некрасова, К. Д. Ушинского, Ж. Верна, Д. Дефо, А. Экзюпери и др.

Интересны динамика и тенденции публикации классических произведений татарской литературы для

детей. Разрыв с общекультурными ценностями, наблюдаемый в советское время, привел к подрыву и национальных традиций. Выработался особый тип воспитания, признающий только классовый подход. Этот надкультурный, наднациональный, надындивидуальный тип воспитания подмял под себя и язык, и литературу, и науку. Таким образом, как констатируют исследователи, «негативное отношение к классике – это не что-то присущее ребенку изначально, а навязанное ему системой» (2, 76).

Неоднозначно было отношение к выпуску классических сочинений в разные периоды отечественной истории. Например, в 20-е гг. Государственное издательство «оказалось во власти распространенного убеждения о ненужности русской классической литературы для детей и, следовательно, для воспитания нового поколения» (3, 141). Только с конца 1920-х гг. начинается решительное преодоление этой тенденции.

В репертуаре татарской советской детской книги представлены все направления классической литературы: национальной, русской, зарубежной, что свидетельствует об открытости детской книги, о ее огромном воспитательном потенциале.

Говоря об изданиях татарской классической литературы для детей, следует назвать имена М. Гафури, Г. Ибрагимова, Г. Тукая, Х. Такташа, Ш. Маннура, М. Джалиля, Ф. Карима и др.

Литературно-творческая деятельность *Галимджана Ибрагимова* (1887–1938) началась в 1907 г. ( был опубликован первый его рассказ «Изгнание из медресе шакирда Закия»). Первым сочинением, написанным специально для детей, специалисты считают рассказ «Ранней весной» (1910). Г. Ибрагимов знакомит читателя с одним днем из жизни мальчика Салиха. Писатель заставляет посмотреть на происходящее глазами маленького ребенка. Творчество классика татарской литературы Галимджана Ибрагимова было широко известно татарскому детскому читателю. Первые его сочинения для детей на татарском языке – рассказы «Начало весны» и «В сельской школе» – в советский период увидели свет в 1921 г. В дальнейшем были изданы в 1920-е гг. его книги «Пастухи», «На море», «Алмачуар», «Наемный старик». Данное произведение было издано всего 4 раза (1957, 1967, 1990 гг.). В 1930-е гг. опубликованы его произведения «Красные цветы», «Глубокие корни». Роман «Глубокие корни» – высшее художественное достижение писателя. Его книги издавались в серии «Кучмэ уку китабы». Всего нами было выявлено 15 изданий его сочинений общим тиражом более 268 тысяч экземпляров. Галимджан Ибрагимов известен прежде всего как прозаик.

Подытоживая сказанное, следует подчеркнуть, что в репертуаре татарской детской книги советского периода была широко представлена классическая литература. Несмотря на появление заметного числа переводных изданий, круг чтения детей оставался достаточно стабильным: в нем преобладали произведения национальных авторов и классические произведения мировой (в том числе и русской) литературы. Издания классических произведений татарской литературы для детей выходили практически в течение всего рассматриваемого периода.

ЛИТЕРАТУРА

1. Бутенко, И. А. Книги для детей: общественные потребности и их удовлетворение / И. А. Бутенко // Книга. Исследования и материалы. Сб. 60 / ВКП. – М.: Кн. палата, 1990. – С. 20–28.

2. Дети и подростки в мире книжной культуры: сб. науч. тр. / РГБ. – М., 1993. – 128с.

3. Шомракова, И. А. Детская книга в Госиздате (к вопросу о формировании принципов издания) / И. А. Шомракова // Книга. Исследования и материалы. Сб. 52 / ВКП. – М.: Книга, 1986. – С. 138–153.

## Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ БАШЛАНГЫЧ ЧОР ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ ЭШЧӘНЛЕГЕ

***Ф. Ә. Гайфуллина (Арча)***

В статье проанализированы критические труды Г. Ибрагимова, написанные в десятые годы XX века. Раскрыты литературно-критические взгляды писателя, определено значение этих статей для развития истории татарской литературы.

XX гасыр башында татар әдәби тәнкыйте, иҗтимагый фикернең бер төре буларак, нык үсеш ала. Бу юнәлештә Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Г. Исхакый, Г. Камаллар аеруча актив эшләгәннәр. Бигрәк тә 10 нчы елларда нәшер ителгән «Шура», «Аң», «Мәктәп» журналларында матур әдәбият, әдәби тәнкыйть мәсьәләләренә зур урын бирелгән. Тәнкыйди фикер камилләшкән, тәнкыйтьчеләрнең профессиональ осталыгы да үсә барган. Җ. Вәлиди, Г. Тукай, Г. Исхакый, Ф. Әмирханнар реалистик юнәлештә эш алып барганнар, әдәби тәнкыйть мәкаләләрендә мөһим социаль, милли мәсьәләләр күтәргәннәр. Әдәби тәнкыйтьнең реалистик юнәлеше белән янәшәдә, сәнгатьчә фикерләүнең романтик төре калыплашкан. Романтик тәнкыйть татар әдипләренең, галимнәренең гыйльми-нәзари эзләнүләре, төрле теоретик концепцияләрнең, рус-Европа әдәбият белемендә формалашкан әдәби мәктәпләрнең тәэсире нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Романтик тәнкыйтьнең теоретик нигезе, фәнни концепциясе, бигрәк тә, Г. Ибраһимов хезмәтләрендә эшләнгән. Г. Ибраһимовның бишенче томында тупланган язмалар шул хакта сөйли. Әлеге язмаларда яшь тәнкыйтьче үз чорында иҗат иткән әдипләргә, аларның әсәрләренә үз мөнәсәбәтен белдерә барган; үзендә милли әдәбият һәм сәнгать язмышы өчен зур җаваплылык тоеп, әдәби иҗат һәм эстетиканың катлаулы мәсьәләләрен күтәреп чыгарган.

Әдипнең «Әдәбият мәсьәләләре», «Татар матбугаты», «Яңа әсәрләр», «Татар шагыйрьләре», «Тәрҗемә һәм аның шартлары» исемле хезмәтләренә аерым тукталып үтәм.

«Әдәбият мәсьәләләре» исемле мәкалә өч бүлектән тора. Беренчесе «Тәгъриф»(билгеләмә) дип атала һәм анда автор «әдәбият» төшенчәсенә аңлатма бирергә омтыла. Фәнни, фәлсәфи, әдәби әсәрләрнең барысы да

әдәбиятка керә, ди. Әдәбиятның төп үзенчәлеге – тормышның төрле күренешләрен чагылдыруда, хис һәм хыялга тәэсир итүдә, дип күрсәтә.

Икенче бүлек «Халык мосаннәфате» дип аталып, анда әдип халык авыз иҗаты мәсьәләләренә туктала. Халык авыз иҗатының ничек тууы, халык арасында ничек таралуы турында сөйли. Аларны җыю, туплау кирәклеген искәртә. Әдәби һәм тарихи мирас булган халык авыз иҗаты яшәргә, буыннан-буынга тапшырылырга тиеш, ди. Татарларда бу эшнең торышы бик түбән булуын билгеләп үтә. Бары бер әдипне генә бу эштә үрнәк итеп куя. «Бу турыда һәркемнән артык мәшһүр шагыйребез Тукаевка бурычлыбыз. Ул үзенең матур вә шагыйрәнә җөмләләре илә шул гавәм әкиятләрен тасвир итеп, һәркем тарафыннан сөелеп укылырлык бер хәлгә куйды. Мәсәлән, аның күптәннән чыккан «Шүрәле»се, «Су анасы» бунның иң гүзәл нәмүнәләреннән *(үрнәкләреннәндер)*», – ди (4, 28).

«Шигырь» дип аталган өченче бүлектә тәнкыйтьче шигъриятнең гомуми хәле өчен борчыла. Шул чорда иҗат иткән З. Бәшири, М. Укмасый, М. Гафури, Н. Думави, С. Рәмиев әсәрләрен анализлап, аларның җитешсезлекләрен күрсәтә. Төп кимчелек дип, шигырьләрдә фикер тирәнлеге сай булуны, тематик киңлек җитмәүне саный. Ә Г. Тукай әсәрләреннән ул канәгать булуын белдерә.

«Татар матбугаты» мәкаләсендә Г.Ибраһимов унынчы елларда татар матбугаты эшенең торышы турында яза. Бу чорда газета-журналларның күпләп чыгарылуын, аларда сыйфатсыз язмалар урнаштырылуын күрсәтә. Теләсә кем шигырь язды, теләсә кем хикәя бастырды, ди автор. Моны ул тәнкыйтьнең көчсез булуыннан күрә. «Наширләр дә, тәнкыйть куәте сай булганга, баш максат парә *(акча)* булганга, килгәнне алдылар, басып тараттылар. Шулай итеп, татар көтепханәсе канунсыз, юлсыз, мәгънәсез язылган әсәр белән тулды. Ләкин зарар юк. Бу дәвер безнең өчен тәҗрибә вә гыйбрәт дәвере иде. Һәр милләт башыннан үткәргән «каләм сынау дәверен» без дә үткәрдек. Һәркем бер тәҗрибә, дәрес алды», – ди (4, 6). Соңрак инде шагыйрь исемен йөрткән күпләрнең каләм мәйданыннан төшеп калуын күрсәтә. Ә Г. Тукай иҗатына югары бәя бирә. Татар шагыйрьләре арасында аның иң зурысы булуын әйтә: «Хәзер шигырь мәйданында иң шәүкәтле вә галәбәле рольне мөхтәрәм Тукаев уйный. Шул дәрәҗәдә ки: татар шагыйре диелүгәчә, укучы зиһенендә Тукаев мәүҗүд була. Бу шагыйребез көннән-көн күтәрелә. Халык күңелендә хак вә ихтирамлы урын ала барадыр», – дип яза (4, 6).

1913 елда дөнья күргән «Татар шагыйрьләре» хезмәтенең I–II бүлекләрендә Г. Ибраһимов С. Рәмиев һәм Дәрдемәнд әсәрләренә җентекле анализ ясый. Алар иҗатындагы уңай һәм кимчелекле якларны ачып бирә.

Шагыйрьләр арасында бик аз язганы, әмма иң талантлысы дип, С. Рәмиевне күрсәтә. «Аның барлык шигырьләрен игътибар, дикъкать илә укып чыгу – аның бөтен рухын, барлык куәтен күз алдыңа ача да куя... Аның һәрбер сүзе йөрәгенең әллә кай җиреннән кайнап, рухының төбеннән, эчке нокталарыннан ялкынланып килеп чыга» (4, 77). Иң яхшылары дип, «Авыл», «Таң вакыты», «Дөньяга», «Ул», «Пигамбәр» кебек шигырьләрен билгели.

Г. Ибраһимов Дәрдемәндне С. Рәмиев белән янәшә куя. «Татар телен сөеп, аның эчендә аз булса да, матур яза, нәзек хис итә, хыял вә тойгыларын яңа галәмнән алып, аны нәфис өслүбтә әйтә» (4, 97). Шагыйрьнең әсәрләрендә аз сүз белән дә күп мәгънә белдерелүен, гарәп-фарсы сүзләренең дә аның шигырьләрендә ярашлы кереп утыруын, әдипнең сурәтләү чараларыннан оста файдалануын күрсәтә. Дәрдемәнд шигырьләрен анализлап, аның күңел төшенкелегенә, өметсезлеккә бирелгән кеше булуын белдерә.

III бүлектә Г. Ибраһимов Г. Тукай әсәрләренә туктала. Яшь тәнкыйтьче шагыйрьнең башлангыч чорга караган әсәрләренең телен, стилен тискәре бәяли. Аны табигатьне тасвирлый алмауда, мәхәббәт шигырьләре яза белмәүдә гаепли. Ә алда инде әдип теленең сафлануын, чит тел сүзләреннән арынуын күрсәтә. Тәрҗемә эшендәге осталыгына игътибар итә. Тукай иҗатындагы тематик байлыкны, көчле сатираны билгеләп үтә. Тукай иҗатының халыкчанлыгын ачып бирә. «Шул заманда халык ни уйлый, ни хис кыйла – Тукаевта да шул», – дип, Тукай поэзиясенең бу күркәм сыйфатына басым ясый. Ә инде «Халык үзендәге тәэссератны *(тойгы),* әфкяр *(фикер)* вә хиссиятне Тукаевта таба. Бу куәт вә кабилият *(сәләтлелек)* ноктасыннан артык мактаулы эш түгел, ләкин халык каршында күтәрелү, илтифатка керү, дикъкатькә алыну өчен моннан да уңайлы талант юктыр. Һәм Габдулла әфәнденең «шагыйрь Тукаев» урынын тота алуының бөтен сере дә шундадыр», – дигән юлларында аны халык мәнфәгатен кайгыртуда гаепли (4, 142).

Бу тәнкыйть әсәренә чаклы язган мәкаләләрендә Г. Тукай иҗатына автор тарафыннан югары бәя бирелә. Нигә аның карашлары болай кискен борылыш алды икән? Бу сорауга җавап итеп, әдәбият галиме М. Хәсәнов фикерләренә иярәсе килә: «Ибраһимовның ул еллар тәнкыйть практикасындагы романтик берьяклылык, «саф сәнгать» йогынтысына бирелүенең нәтиҗәсе» (4, 534).

«Тәрҗемә һәм аның шартлары» исемле язмада әдип тагын бер мөһим мәсьәләне алга куя. Ул – тәрҗемә эше. «Чит телләрдән үз теленә мөнасиб *(файдалы)* әсәрләрне тәрҗемә кыйлмак һәр милләтнең әдәбиятында мөһим бер урын тотадыр. Безнең кеби гыйлем вә тәмәддengә *(культуралылыкка)* яңа керә башлаган бер милләтнең үз әдәбиятын баетуына, гыйлем вә фән илә ашналануына *(якынаюына)* хезмәт җәһәтеннән караганда, тәрҗемәчелек дәхи артык әһәмият, хәтта зарурат *(зарурлык)* мәртәбәсен алганлыгы мәгълүмдер», – дип, тәрҗемә эшенең кирәклеген искәртә (4, 38). Әмма теләсә нинди әсәрне тәрҗемә итәргә ярамый, татарларның фикер үсешенә туры килгәнен, ярашлысын гына сайларга кирәк. Тәрҗемәче дә әсәрнең идеясен укучыга җиткерерлек дәрәҗәдә оста һәм сәләтле булырга, ике телне дә камил белергә тиеш, ди.

Г. Ибраһимов тәрҗемә итүнең ике төрен күрсәтә: сүзгә-сүз тәрҗемә ясау һәм эчтәлекне бирү. Әдәби әсәрләрне (хикәя, романнарны) тәрҗемә итүчеләргә икенче юлны тәкъдим итә, чөнки әсәрнең бер өлешен, яисә төрле урыннарын чүпләп тәрҗемә итү отышлы түгел. Ә менә гыйльми, фәнни, иҗтимагый мәсьәләләрне яктырткан әсәрләрдә укучыга төп фикерне җиткерү шарт, хезмәтнең төп мәгънәсен бирү файдалы, дип күрсәтә. Фән турында иң гомуми төшенчәләрнең генә зарурлыгына басым ясый.

Әлеге хезмәтләрдән чыгып, түбәндәге нәтиҗәләргә килергә була: 10 нчы елларда Г. Ибраһимов тарафыннан шигърият хакында, аның асылы һәм үзенчәлеге турында мөһим күзәтүләр ясалган. Шигъри талант һәм поэтик иҗат процессы турында игътибарга лаеклы оригиналь фикерләр әйтелгән. Яшь тәнкыйтьче

XX гасыр әдипләре: Г. Тукай, С. Рәмиев, Дәрдемәнд һ. б. иҗатына игътибар иткән, аларның әсәрләренә анализ ясап, бәхәсле һәм каршылыклы булса да, үз фикерләрен белдергән. Халыкны аңлы, белемле итүдә, милли культураны алга җибәрүдә тәрҗемә эшенең дә кирәклеген искәрткән. Кыскасы, Г. Ибраһимов унынчы елларда ук үзенең тирән белемле, киң эрудицияле, принципиаль тәнкыйтьче һәм әдәбият белгече булуын раслаган. Аның хезмәтләре әле бүген дә үзләренең әһәмиятләрен югалтмаган.

ӘДӘБИЯТ

1. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007.
2. Гыйләҗев Т. Ш. Әдәби мирас: тарих һәм заман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2005.
3. Заһидуллина Д. Әдәбият кануннары һәм заман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2000.
4. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. V т.: Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978.
5. Миңнегулов Х. Й. Гасырлар арасында уйланулар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010.

## СВОЕОБРАЗИЕ СЦЕНИЧЕСКОГО ВОПЛОЩЕНИЯ РАССКАЗА Г. ИБРАГИМОВА «АЛМАЧУАР» В КТГТЮЗ ИМ. Г. КАРИЕВА

*Е. Н. Садирова (Казань)*

Галимджан Ибрагимов принадлежит к тому отряду татарских писателей-прозаиков, творчество которых оказалось востребовано на драматической сцене. Общеизвестно, что поэтическим ресурсом для прочтения средствами театрального искусства обладает далеко на каждый образец эпической литературы. В произведениях Г. Ибрагимова этот потенциал очевиден. «Среди татарских прозаиков Галимджан Ибрагимов, пожалуй, один из самых «театральных» авторов. Его произведения в большинстве своём удивительно драматургичны», – отмечает театровед Д. Гимранова (1, 298).

Можно найти и другие причины привлекательности поэтики ибрагимовского письма для сцены. «Ибрагимов сравнительно мало прибегает к раскрытию характера через поступки, действия героев. Центр тяжести – на психологическом анализе. Романтический стиль Г. Ибрагимова обогатил татарскую прозу психологизмом в смысле более эмоционального и возвышенного повествования, граничащего порой с исповедью и монологом “Я”» (3, 377). Именно стремлением Ибрагимова к исследованию психологии своих персонажей, их особой исповедальностью во многом объясняется интерес татарского театра к художественному мышлению писателя. В перечне сценических воплощений его прозы – роман «Глубокие корни» и повесть «Судьба татарки».

Этот список успешно дополняет спектакль «Алмачуар», поставленный на сцене Казанского татарского государственного театра имени Г. Кариева в 2004 году.

Одноименный рассказ Ибрагимова повествует об истории трагической дружбы деревенского паренька Закира и молодого коня Алмачуара. Трепетная и проникновенная любовь мальчика к жеребенку сопрягается со страстным желанием сделать из него сильного скакуна, которому на скачках не было бы равных. Одержимость героя обрекает еще не окрепшее молодое животное на гибель. Принеся своему хозяину победу на сабантуе, Алмачуар умирает.

Подвергая героя «психологическому анализу», Ибрагимов через личную драму Закира поднимает далеко не частную проблему, суть которой емко и лаконично сконцентрирована в известной мысли Экзюпери: «Мы все в ответственности за тех, кого приручаем».

Авторы сценической версии рассказа – инсценировщик Ф. Галиев и режиссер Р. Аюпов – значительно расширяют нравственно-этический посыл писателя, извлекая из локальной истории философскую притчу и кардинально смещая акценты. Если рассказ строится в форме монолога мальчика, то в спектакле идейным центром выступает «очеловеченный» образ Алмачуара. Именно через его восприятие перипетий повествования высвечивается мысль о людской жестокости, эгоизме, губительной, антигуманной по своей сути силе осознания человеком собственного превосходства над природой. Этот мощный философский зачин определяет всю архитектонику спектакля, в которую режиссер встраивает еще одну группу персонажей – упоминаемую в рассказе мимоходом стаю (в спектакле семью) волков, занимающую свое место в иерархии взаимоотношений людей и животных. Так структура конфликта получает развитие в трех сюжетных линиях: люди и лошади, люди и волки, волки и лошади, каждой из которых в общей партитуре спектакля отведена своя тема, своя философия и свои выразительные средства, но взаимообусловленные и приводящие все к единому знаменателю.

Установка на подобное восприятие изначально задается в художественном решении, смысловым ядром которого выступает подвешенная в центре сцены конструкция из множества элементов конской амуниции – подпруг, оголовий, стремян, кожаных ремешков с колокольчиками. Экипировка лошадей здесь не просто формальный признак, неотъемлемая составляющая их «имиджа», она подчеркивает их зависимость от людей и вырастает в спектакле до уровня символа человеческой власти, обозначенного уже в прологе спектакля, открывающемся появлением Закира. Чуть поиграв со сбруей, мальчик разводит ее части на три стороны, очерчивая визуальное обрамление конфликтной структуры, и призывным выкликом «Э-ге-гей» дает толчок поочередному появлению всех трех групп персонажей драмы – своих родителей, лошадиного табуна и волчьей стаи. Их представление происходит в виде лаконичных, выразительных музыкально-пластических миниатюр. Светлая, окрашенная мажорной тональностью татарская мелодия с вкраплением пения петухов сопровождает появление на сцене отца и матери Закира. Контрастно теме родителей вливается в партитуру пролога ведущая тема лошадей, в танцевальных движениях которых угадывается и мотив извечной любви к вольной стихии, жажда свободы и трагический надрыв, обреченность на неизбежную зависимость от люд-

ских потребностей. Экспозицию образов венчает выход волчьего семейства, ассоциативно выражающий через пластику (крадущаяся поступь) их условия существования в экосистеме – ежесекундная готовность к нападению, постоянная забота о хлебе. Так в прологе режиссер производит расстановку исходных смысловых акцентов. Пролог становится не только экспозицией персонажей, но и экспозицией художественных средств и приемов, принятых в спектакле. Слово, музыка и пластика образуют на сцене некое триединство – одно будто рождается другим и продлевается третьим. И все же приоритет принадлежит пластике.

Наиболее разнообразно и изобретательно пластический рисунок воплощается в образе Алмачуара. Все зигзаги его короткой, трагической судьбы получают пластический эквивалент. Так, невероятно достоверно представлен момент его появления на свет: артист с необычайной выразительностью передает пластику новорожденного жеребенка. Еще плохо держат ноги, робко поднявшись, он распластывается на земле. Снова поднимается, удивленно раскрыв глаза, знакомится с окружающим миром, изучает своего будущего молодого хозяина, льнет к нему. Потом он познает и гордость дружбы с человеком, и его жестокость.

Возвышенной тональностью проникнута сцена общения Алмачура со своей возлюбленной – молодой кобылицей. Танцевальный диалог, в котором лошади, полностью утратив свою природную пластику, почти по-человечески постигают трепет и первозданность светлого чувства, оборвется под ударом человеческого хлыста, так и не раскрывшись.

Кульминации пластическая партитура спектакля достигает в финальной сцене (сабантуй), воспроизводящей азарт, экспрессивность, напряжение и драматизм лошадиных скачек, из которых Алмачуар, жертвуя своей жизнью, выходит победителем.

Здесь нельзя не отметить работу актера Ильнара Низамиева – исполнителя роли Алмачуара, удивительно тонко и убедительно воплотившего образ своего героя.

Речевые характеристики персонажей – еще один стилеобразующий штрих концепции спектакля. Каждый из представителей животного мира получает, помимо танцевально-музыкальной, еще и вербальную характерность, через которую раскрывается его житейская философия. Так, лошади пытаются постичь мотивы противоречивости властвующего над ними социума: «Люди не понятные, иногда хорошие – вкусно кормят, а иногда злые – бьют нас. Почему бы им не быть как мы простыми?! Мы ведь простые, знаем вкус сена, воды, вкус воли». Свои счеты с людьми и у Старого волка. Представляющий постоянную опасность, как для конского молодняка, так и для самого человека, этот матерый хищник озабочен продолжением своего рода, находящегося на грани вымирания, и тем самым оправдывает свое узаконенное положение в природе: «Из всех моих детей ни один не дорос до настоящего волка – или умирают по болезни или люди убивают, а мне нужен преемник».

При этом каждая из трех групп ведет свою линию, ни разу не вступая в словесный диалог с представителем другого племени и оставаясь понятным только в среде себе подобных. Постановщик, таким образом, не оставляет им шанса для нахождения общего языка, но всячески подчеркивает их принадлежность к единому мирозданию, наделяя животных способностью сопереживать, любить, страдать, тем самым уравнивая их в правах с человеком.

Рассказ заканчивается словами Закира: «Алмачуар вместе с собой унес из моего сердца любовь к земле, небу, людям, ко всему живому. После его ухода я навсегда утратил способность любить» (2, 134). Автор сочувствует своему герою.

Постановщики спектакля более жестки в своей позиции и трактуют действия людей как агрессивное вторжение в природу, отдавая моральное превосходство и место для исповеди животным. И в этом состоит, пожалуй, единственное расхождение авторов сценического «Алмачуара» от «Алмачуара» литературного.

В остальном же спектакль дал редкий пример убедительного, достойного воплощения прозаической литературы на драматической сцене. В этом большая роль принадлежит режиссеру по пластике Р. Фаткуллину, композитору Ю. Чаплину и всему актерскому ансамблю, сумевшим всеобщими усилиями раскрыть художественный мир и эмоциональную возвышенность рассказа Г. Ибрагимова.

ЛИТЕРАТУРА

1. Гимранова Д. Судьба татарки // Татарский государственный драматический театр имени Г. Камала. Сто лет. В двух томах. – Казан: Заман – Татар. кн. изд-во, 2009. – Т. 1.– 568 с.

2. Ибрагимов Г. Алмачуар // Сайланма әсәрләр. Сигез томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. – Т. 3. – 456 б.

3. Хасанов Х. Галимджан Ибрагимов // История татарской литературы нового времени (XIX – начало XX в.). – Казань: Фикер, 2003. – 472 с.

## XX ЙӨЗ БАШЫ ТАТАР ПРОЗАСЫНДА «МОРЗА КЫЗЫ» ОБРАЗЫ

*Л. Ш. Бәдертдинова (Казан)*

Данная статья на примере романа «Молодые сердца» Г. Ибрагимова, повестей «Дочь мурзы Фатима» Ф. Карими, «На берегу *Демы»* С. Джаляля, «Идель» Г. Рахима, «Осень»Г. Исхаки освещает воплощение образа «дочь мурзы» в произведениях татарской литературы начала XX века. Путем сопоставления выявляются общие и отличительные черты в изображении образа разными авторами.

XIX йөз ахыры – XX гасыр башында әдәби әсәрләрдә, иҗтимагый-тарихи катлам буларак, морзалар тормышын яктыртуга шактый урын бирелә.

«Морза (мирза) (*фарсы*. әмирзадә ‒ әмир улы) – титул, аксөяклек дәрәҗәсе; 1) Иранда идарәче династия әгъзалары титулы. Күчмә төшенчәдә: эш башкаручы

(чиновник), сәркятиб; 2) Алтын Урда һәм соңыннан Россия империясенә кергән төрки-татар халыкларында эре феодал яки аерым ыруг, кабилә башлыгы титулы. Бәк дәрәҗәсенә, русларның дворян дәрәҗәсенә тиң аксөяклек билгесе» (9, 437).

Язучылар арасында морзалык дәрәҗәсен йөрткән Ә. Еники үзенең истәлекләрендә, тарихчы Г. Гобәйдуллинның «Татарларда сыйныфлар тарихы» дигән хезмәтенә таянып, нәсел-фамилиясенең килеп чыгышын тикшерә һәм морзалар катламының тарихын да яктыртып уза (3, 6–16).

Г. Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» (1912) романында (Мәрьям), Ф.Кәриминең «Морза кызы Фатыйма» (1901), С. Җәлалнең «Дим буенда» (1914) (Фәридә), Г. Рәхимнең «Идел» (1921) (Рәбига), Г. Исхакыйның «Көз» (1923) (Гөлсем) повестьларында «морза кызы» төп герой буларак урын алган.

Морза кызын әсәр исеменә чыгарып, аны татар мохите өчен гадәти булмаган рәвештә тасвирлап биргән беренче язучы – Ф. Кәрими. «Аны хәтта әдәбиятыбызда бу юнәлешне башлап җибәрүчеләрдән дип хисаплап булыр иде», – дип яза әдәбият белгече М. Гайнетдинов (2, 16). Әлеге образны гәүдәләндергәндә һәр язучы морзалар катламы турында тарихта сакланган мәгълүматларга нигезләнсә дә, һәр әдип образга үзенчә якын килеп иҗат итә.

Язучылар «морза кызы» образын ул яшәгән иҗтимагый тирәлек, җәмгыятьтә бу катлам тоткан урын аша тудыралар. Аларның барысы да бай тормышта яшәмәсәләр дә, билгеле бер дәрәҗәдә белем алуга ирешәләр. Шуңа да аларны гади татар кызларыннан аерып карау яшәп килә. Мәсәлән, авылда яшәүләренә карамастан, Гәрәй морза йортында тудырылган яшәү рәвеше Мәрьямне гади авыл кызларыннан аерып чыгара һәм шуңа да аңа «Мәрьям туташ» дип кенә мөрәҗәгать итәләр. Үлгән аталары ярлы морзалар хисабыннан булса да, Рәбигалар ел саен җәйне Идел буенда бер йортта үткәрә.

Әлбәттә, XX йөз башында хатын-кызның җәмгыятьтә тоткан урынын, азатлыгын яклаган мәсьәләләр күтәрелгәндә, язучыларга укымышлы, фикер йөртә ала торган кыз үрнәген нәкъ менә морза кызы аша бирү уңышлы чараларның берсе. Бу – әсәрне чынбарлыкка якынайта. Шәһәрдәге морзалар тормышын якын күргән аналар, тутакайлар кызларын алдынгы карашлы итәргә, рус культурасына ияләштерергә омтыла (Мәрьям, Гөлсем). Хәтта шәһәрдәге уку йортларында белем алырга омтылучы кызны да (Рәбига) әлеге образ аша җиткерү җиңелләшә, чөнки морзалар кызларын башлангыч белемсез калдырмый.

Образны тасвирлау өчен, авторлар «морза кызы» туып-үскән гаилә тормышына да игътибар итәләр. Саналган әсәрләр арасында, ятим калып Исхак морза гаиләсендә тәрбияләнгән Фәридә, анасыз калып, тутакае үстергән Гөлсем бар. Ахыр чиктә алар икесе дә бәхетсез гомер кичерә. Әлеге фактка карата шуны билгеләргә мөмкин: үзләрен ятим хис иткән ике образ тәкъдиргә буйсынып, язмышларын үзгәртә алмыйлар. Тормышта бер югалтуга дучар ителгәч, алар булганыннан да канәгать кала сыман яки аларга кыюлык җитми. Фикерне алга таба Г. Ибраһимов сурәтләгән морза кызы мисалында дәвам итәргә мөмкин. Мәрьям туташ әсәрдә төп геройларның берсе булып тора. Зыя белән морза кызы арасында булган мөнәсәбәтләр укучыны әсәр ахырына кадәр кызыксындырып тора. Әмма автор-хикәяләүче Мәрьям язмышының алдан ук билгеләнгән юл буенча үтәсен кисәтеп куя. Романның өченче бүлеге морза кызының яшәү рәвешен сурәтләүдән башлана һәм бер бүлекчәнең ахырында түбәндәге фикер җиткерелә: «*Язмыш ни куша – анлар шуны кыйла; мохит ни сөйли – шул канун була; мохитның биргән тәэсире анларга табигать булып китә. Мәрьям дә шундый колларның берсе*». Ягъни язмышын бай, тулы гаиләдә үткәргән бу туташ та Гөлсем, Фәридә кебек үз сөйгән ярын югалта. Әлеге образларга оппозиция рәвешендә морза кызы Фатыйманы китереп була. Ф. Кәрими тарафыннан иҗат ителгән бу туташ, кабул ителгән гадәтләргә каршы чыгып, бәхете өчен үзе кыю адымга бара. Аның сөйгән яры Мостафа гади генә бакчачы булса да, кыз аның күңел киңлегенә, хисләренең саф булуына ышана. Озак кына вакыт егет Фатыйманы морза кызы буларак якын китермәсә дә, мәхәббәт, яшьләрнең бер-берсенә булган ашкынуы җиңә. Билгеле бер дәрәҗәдә татар мохите өчен мондый кыю кызны сурәтләргә аның прототибы булу да ярдәм иткәндер. «Әсәр сюжеты нигезе – бу чор яңару хәрәкәте башында торган Исмәгыйль бәк Гаспринский (1851–1914) әтисе Мостафаның морза кызына өйләнү маҗаралары» (2, 16). Г. Рәхим әсәрендәге Рәбиганың бәхете-бәхетсезлеге исә укучы өчен билгесез кала.

Гаилә бәхете кору мәсьәләсенә карата Ф. Кәрими үзенең повестенда мондый фикерне җиткерә: *«Морза халкы бераз мәдәниятле вә тәрбияле булганлыктан, анлар арасында үзе сөймәгән вә теләмәгән кешегә кызны көчләп кияүгә бирү гадәте юктыр»*. Бу сүзләрне истә тоткандай, игътибар үзегенә алынган бер автор да морза кызын көчләп кияүгә бирү күренешен әсәр сюжетына кертми. С. Җәлалнең «Дим буенда» повестенда Фәридә исә гомер буена ялгыз кала. Морза кызлары арасында бары тик Мәрьям генә, билгеле бер прострация халәтендә калып, үзе теләмәгән ир белән гомер кичерергә мәҗбүр.

«Морза кызы» образын тулырак күзаллау өчен, язучылар аның портретына мөһим урын бирәләр. Биредә тышкы гүзәллек белән эчке, күңел дөньясы матурлыгы берләшә. Ф. Кәрими бу хакта: *«Кирәк Русиянең эчендә булсын, кирәк Кырым кеби читләрендә булсын, мөселман морзаларының хатын вә кызлары гади халык хатын-кызлары кебек шәлләр вә чапаннар аз бөркәнеп, бик качынмый йөрсәләр дә, чапан астыннан һәр кешегә көлеп карап, күз кысып китә торган Казан вә Оренбург хатыннарыннан бәгъзеләре кебек, тәрбиясезлек вә әдәпсезлек бонларда аз буладыр».* – дип яза. Аның әсәрендә *«Фатыйма туташ – һәм гүзәл, һәм дә тәгълим вә тәрбияле, вә атасы да бай бер морза булдыгыннан, тирә-яктагы яшь морзалардан бик күбесенең күзе кызып, морза Туганский гаиләсенә мөмкин мәртәбә мокаринәт хасыйл итәргә тырышалар иде»*. Шулай да Фатыйманың характерын аның кылган гамәлләре күбрәк ачып бирә.

Г. Ибраһимов та Мәрьямнең тулы бер портретын тудыра дип әйтә алабыз. Ул татар кызлары мәктәбен тәмамлый, белемле, рус телен дә үзләштергән, китаплар укырга ярата, шул укыган романнарның образларын күңеленнән үткәреп, Зыя белән үзен күзаллый. Фатыйма бикәнең кызын шәһәр мохитенә ияләштерү теләге дә юкка китми: ёлкалар, спектакльләр, театрлар Мәрьямне тар авыл дөньясыннан читләштерә. Морза

кызының тышкы портреты сөеклесе Зыя тарафыннан бирелә: «*...ул озынрак, нечкә һәм зифа буйлы; гәүдә вә әгъзалары табигый һәм килешле. Аның бөтен тәнендә хатыннарга аерым бер лятафәт бирә торган назиклек бар. Бите озынчарак; тавышы назлы... Авыз, борын уртача; башка әгъзалары да гади...*».

«Дим буенда» Исхак морзаның үз балалары белән бергә үскән «*кара кашлы, кара күзле, әзһәр йөзле, аз сүзле, мөлаем табигатьле Фәридә Исхак мирза гаиләсендә яши, аның балалары белән бергә Уфадан китерелгән урыс кызы мөгаллимәдән укый, Зөләйха абыстайдан төрле догалар, намаз тирәләрен өйрәнә*». Әлеге морза кызында ятимлек үзен нык сиздерә. Ул бик тиз тәэсирләнә, күзләре яшьләнә. Фәридәнең музыкага тартылуы көчле. Гомумән, әлеге образ хисләнүчән, сабыр, тыйнак. С. Җәлал сюжет үстерелеше аша аның авыр кичерешләрен ахыр чиктә йөз-кыяфәтенә чыгарып тасвирлый: ул ябыга, күзләре эчкә батып кала, авырый. Үзенең язмышын исерек ир белән бәйләгән Гөлсемнең портреты Нәфисә, Хәлил кабул итүе аша җиткерелә. Авыр тормыш аны тәмам изгән. Әсәрнең исеме дә гомер көзенә кергән бу морза кызының язмышы узуына ишарә кебек яңгырый.

Г. Рәхимнең «Идел» повестенда сурәтләнгән Рәбига портреты Ильясның сүз-фикерләре аша җиткерелә. Беренче очрашуда аны кызның күзләре җәлеп итсә, Рәбигалар гаиләсендә булган күңелсез вакыйгадан соң Ильяс аны *«өсте-башы рәтсез, чәче дә ясалмаган, пудралары беткән, кискән чәчләре маңгае өстенә рәтсез таралганнар...»* рәвешендә күреп, аның морза кызыннан күңеле кайта. Шул ук вакытта, төп герой сүзләре аша әсәрдәге морзалар гаиләсенә хас сыйфатлар ачыла: *«Ләкин аларның үз-үзләрен тотуларында да, сөйләшүләрендә дә морзалык сизелми, кызлары аналарына «анакай» дип эндәшмиләр иде. Гомумән, алар бик ачык һәм тәкәллефсез кешеләр, гадәттә, морза халкында була торган, морза булмаган кешеләргә ят һәм кызыксыз тоела торган хосусиятләр аларда күренми иде»*. Ягъни морзалар катламының яшәү рәвеше дә чор, тирәяк мохит, төрле иҗтимагый үзгәрешләргә бәйле алмашынып тора.

XX гасыр башы язучыларының әсәрләрендә урын алган «морза кызы» образы бирелешенә күзәтү ясаганнан соң, аерым бер нәтиҗәләр дә чыгарырга мөмкинчелек туа. Һәр образ әсәрдә төп геройларның берсе булып килә, аның язмышы сөйгән ярына бәйле. «Морза кызы» алда әйтеп үтелгән проза әсәрләренә күпмедер дәрәҗәдә әзер килеш килеп керә: аның морза катламына бәйле тарихи килеп чыгышы, иҗтимагый-мәдәни тормышта үз урыны, дәрәҗәсе бар. Әлеге образга аерым сыйфатлар хас: ул укымышлы, тәрбияле, аның тышкы портреты әсәрдәге башка персонажларны сокландыра, аңа тормыш иптәшен сайлау хокукы бирелгән. Әмма болар барысы да тулаем аның үз ирегендә генә түгел. Морза кызы үз сыйнфый катламының кануннарын кабул итәргә тиеш була. Шул мохиткә буйсыну, куркаклык, вакытында аңлаша белмәү (Фәридә, Гөлсем), шуларга өстәп, хыяллар белән яшәп, чынбарлыкны кабул итмәү, яисә күпмедер дәрәҗәдә тәкъдиргә (төшкә бәйле) буйсыну (Мәрьям) яшь туташларны бәхетсез итә. Аларга каршы Ф. Кәриминең Фатыймасын куеп була. Әлеге морза кызы бәхетен кулдан ычкындырмый һәм, шулай итеп, язмышын да үкенечтә үткәрми. Чагыштырып, шунысын да билгеләргә мөмкин: әгәр Фәридә, Гөлсем, Рәбига үз язмышларына риза булып яшәүләрен дәвам итсәләр, Мәрьям, гаиләле булганнан соң да, Зыя белән аралашу чарасын табарга тырыша. Г. Ибраһимов романының «морза кызы» әнә шул ягы белән аерылып тора. Әсәрдә Мәрьямнең портреты, яшәү даирәсе дә повестьларда бирелгән образларга караганда тулырак сурәтләнә. Бу исә роман авторының язучылык талантын, тел байлыгын тагын бер кат дәлилли.

ӘДӘБИЯТ


1. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.
2. Гайнетдинов М. Кереш сүз // Кәрими Ф. Г. Морза кызы Фатыйма. Сайланма әсәрләр. – Казан: Татар кит. нәшр., 1996. – 414 б.
3. Еники Ә. Әсәрләр: 5 томда. IV т.: Соңгы китап. Истәлекләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 479 б.
4. Җәлал С. Дим буенда: повесть һәм хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. – 255 б.
5. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. II том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. – 477 б.
6. Исхакый Г. Әсәрләр: 15 томда. V том. – Казан, 2009. – 559 б.
7. Кәрими Ф.Г. Морза кызы Фатыйма. Сайланма әсәрләр. – Казан: Татар кит. нәшр., 1996. – 414 б.
8. Рәхим Г. Сайланма әсәрләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 287 б.
9. Татар энциклопедик сүзлеге / Баш мөхәррир М. Хәсәнов. – Казан: Татар энциклопедиясе институты, 2002. – 830 б.


# Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ «КАЗАКЪ КЫЗЫ» ҺӘМ Г. МОНАСЫЙПОВНЫҢ «ТАРАНЧЫ КЫЗЫ, ЯКИ ХӘЛИМНЕҢ БЕРЕНЧЕ МӘХӘББӘТЕ» РОМАННАРЫНДА КАРДӘШ ТӨРКИ ХАЛЫКЛАР ТОРМЫШЫ


***Г. Ф. Төхвәтова (Казан)***



Статья посвящена анализу изображения жизни тюркских народов в романах «Дочь степи» Г. Ибрагимова и «Дочь таранчи, или Первая любовь Халима» Г. Мунасыпова. Романы Г. Ибрагимова и Г. Мунасыпова – оригинальные произведения начала XX в., в которых на фоне романтической любви рассказывается о природе далеких стран, о жизни людей в тех краях, о культуре, истории других народов. Автор подчеркивает, что в начале XX века ознакомление с историей, бытом, культурой других народов определялось главной особенностью романтической эстетики, и это обуславливается требованием эпохи.


XX гасыр башы татар әдәбияты үзенең байлыгы, язучыларның әдәбиятны үстерү юнәлешендә эзләнүләре, моңа кадәр милли сәнгатьтә күзәтелмәгән алымнарны файдалану, татар укучысына традицион

булмаган әсәрләр тәкъдим итү ягыннан яңа югарылыкка күтәрелә – сан һәм сыйфат ягыннан үстерелеп, ул Ауропаның алдынгы әдәбиятлары сафына бастырыла. Бу дәвердә аның тагын бер яңалыгы – татар укучысын кардәш төрки халыкларның тормышы белән таныштыру. Бу елларда чит халыкларның мәдәниятен, тормышын сурәтләгән, чит милләт вәкилләрен төп герой итеп алган, ягъни әдәби бәйләнешләр яктылыгында үсеш-үзгәреш кичергән яңа төр әсәрләр пәйда була. Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы» (1923), Г. Монасыйповның «Таранчы кызы, яки Хәлимнең беренче мәхәббәте» (1918), Касыйм Бикколовның «Төркестан» (1908) романнары, З. Бәширинең «Чуваш кызы Әнисә» (1910), С. Шәриповның «Алтынбасар» (1926) повестьлары шундыйлардан. Әмма татар язучылары тарафыннан сурәтләнеш тапкан кардәш төрки халыкларның йолалары һәм гореф-гадәтләре әлегә кадәр галимнәр тарафыннан өйрәнелмәде дип әйтергә мөмкин.

XX йөз башы татар әдәбиятында бу типтагы аерым иҗат үрнәкләре татар реалистик прозасында романтизмның тамыр җәя баруына дәлил дә була алалар (1, 179). «XX йөз башы татар прозасы» исемле хезмәтендә Ф. К. Бәширов В. В. Вансловның фикерләрен китерә: «Это соответствовало духу эпохи, богатой бурными историческими событиями и потрясениями, которые заставляли задумываться над судьбами народов, над сменами эпох, над путями, которыми идёт человечество» (2, 216). Димәк, башка халыкларның тарихы, яшәү рәвеше белән таныштыру романтик эстетиканың төп үзенчәлеге булып саналырга хаклы, һәм ул чор таләбе буларак билгеләнә.

Икенче яктан, узган гасырның 10 нчы елларында тарихи әсәрләрнең барлыкка килүе – «...милли хисләрнең куеруы, тарихчыларның, әдип-шагыйрьләрнең, тәнкыйтьчеләрнең татар канының кайнарлыгын күрергә теләп тарихка мөрәҗәгать итүләренең нәтиҗәсе» (8, 223) дә. Ә XX йөз башы авторларының тугандаш халыклар тормышына, аларның тарихына игътибары «милләтнең җәмгыятьтә барган берләшүоешу хәрәкәте татар дөньясының чикләрен киңәйтергә, төрле җирләрдә яшәүче төрки кавемнәрне кардәш-туган итеп карарга кирәклекне ... көн тәртибенә кую» (5, 178) белән аңлатыла.

Галимҗан Ибраһимовның (1887–1938) «Казакъ кызы» һәм Габделгазиз Монасыйповның (1888–1922) «Таранчы кызы, яки Хәлимнең беренче мәхәббәте» романнары да татарларны башка мөселман халыкларына якынайту, бердәмлек тойгылары уятырга омтылуның бер мисалы булып тора. Авторлар романнарны язу барышында үз тәҗрибәләренә таяналар. Билгеле булганча, Г. Ибраһимов яшь чагында казакъ даласында укытучылык итә, бу халыкның бай авыз иҗатын, тормыш-көнкүрешен өйрәнә. Татарстанның Арча районы Яңа Тазлар (хәзерге Байкал) авылында мәзин гаиләсендә туып үскән Г. Монасыйпов хакында мәгълүматлар аз, әмма аның 1902–1908 елларда Көнчыгыш Төркестандагы Голҗа шәһәрендә таранчылар (уйгырлар) арасында яшәве һәм укытучы булып эшләве билгеле.

Әлеге ике әсәрнең язылу тарихында да шактый уртаклыклар бар. Г.Ибраһимов «Казакъ кызы» исемле әсәренең язылу тарихы турында аның беренче басмасында «Мөхәррирдән» дип бирелгән сүз башында түбәндәгеләрне әйтә: «“Казакъ кызы” 1909 елның җәендә, Уралның Миасс заводында языла башлап, 1911 елда Казанда тәмам булган иде. Шул заманнарда бу әсәрне Оренбурдагы “Вакыт” нәшрияты басар өчен алса да, дөньяга чыгара алмады: ... Оренбурдагы тентүләр чагында бу китап жандармерия кулына эләкте дә кайтмады. Кулымда караламасы бар иде. Шуның буенча 1912–1913 елларда мин моны яңадан аклап чыктым. Ләкин тагын казага очрады: шул елның язында, Киевта булган булган мәгълүм хәрәкәт эчендә, апрель 17 сендә үземне ябып, китапларымны, барлык кульязмаларымны охранка алды; унбиш айлар үткәч, күп нәрсәм кире кайтса да, “Казакъ кызы”ның җитмеш бите тагы югалды». Һәм ниһаять, роман 1924 елда Мәскәүдә дөнья күргән «Галимҗан Ибраһимов әсәрләре тулы җыелмасы» дип аталган басманың икенче томына кертелә.

Алда әйтелгәнчә, Г. Монасыйпов берничә ел уйгырлар арасында яши һәм язучыда, Голҗадан Казанга кайтып төшкән вакытта, «сан җәһәтеннән күп булмасалар да, төрек-татар милләтенең иң зирәк вә мәдәнияткә кабилиятле бер кисәге булган таранчыларның хәятлары вә кыска гына булса да тарихлары, гореф-гадәтләре җентекләнергә тиешлеген» күздә тотып, «таранчылар арасында торган вакытта ишеткән вә хәтерендә саклаганнарны» язу фикере туа, «таранчыларның төреклегенә гаид берничә рәсемнәр вә таранчы көйләреннән берикесенең ноталары белән» «Таранчы кызы...» романын нәшер итү теләге кабына (7, 126). Әмма әсәрне язу 1912 елның декабрендә генә башланып китә. «Бәгъзе бер сәбәпләр» һәм Беренче бөтендөнья сугышы «Таранчы кызы...»на нокта куелуны чигендерә килә, әсәр 1915 елның урталарында гына тәмамлана. Аннан соң да роман тиз арада нәшер ителә алмый, бары тик 1918 елда гына укучылар аның белән танышу мөмкинлегенә ирешә. Әмма кырыс чынбарлык автор уйларына үзгәрешләр дә кертә: роман нотасыз һәм рәсемсез булып дөнья күрә.

«Казакъ кызы» һәм «Таранчы кызы, яки Хәлимнең беренче мәхәббәте» романнарын татар язучылары каләменнән чыккан кардәш төрки халыклар тормышы энциклопедиясе дип санарга җирлек бар.

XIX гасыр ахыры – XX гасыр башларында казакъ даласында булып үткән вакыйгаларны тасвирлаган «Казакъ кызы» әсәрендә бала туу, өйләнү һәм үлем кебек кеше тормышындагы вакыйгалар тирәсендә барлыкка килгән йолалар һәм гадәтләр аерым-ачык күрсәтелә. Аларның күбесе казакъ халкы тормышында бүген дә яши, ә кайберләре, табигый ки, халык тормышыннан төшеп калган (4, 273).

Романда казакъ халкының көнкүреше, яшәү рәвеше дала күренешләре һәм малларга өстенлекле мөнәсәбәтне сурәтләү аша ачыла. Бу әсәрнең беренче юлларында ук чагылыш таба: «Меңләгән җылкылары, яхшы нәсел дөяләре, исәпсез куйлары белән Сары-Арканың киң далаларында ак тирмәләр корып, бер җәйләүдән икенче җәйләүгә үзләренең маллары артыннан рәхәтрәхәт күчеп йөриләр иде...» (6, 391).

Кымыз мәҗлесләре, күп уен-көлке дә әсәрдә казакъ тормышының асылын ачып бирүче детальләр булып торалар. Автор халыкның ашау-эчү гадәтләрен тәфсилләп тасвирлый. Казакълар ит, казылык, майлы ялса ашауга, кымыз эчүгә өстенлек бирәләр. Ләкин итне табынга бирүнең һәм аны ашауның да далада үз тәртибе бар. Ит табакка сөзелеп, башта өлкән өйгә, ирләргә бирелә.

Ә хатын-кыз исә аерым тирмәдә ашый, шуңа күрә дә аларга ит аерым куела. Әсәрдә ит бүлү, ашап-эчкәннән соң, табындагыларның бит сыйпап, яраткан иягә шөкер белдерү, кунакны сыйлау күренешләре дә шактый кызык тасвир ителә. Ч. А. Зарипова-Четин билгеләвенчә, романда урын алган хатын-кызларның көндәлек эшләре, көндәлек мәшәкатьләре дә безгә казакъ халкының яшәү рәвешен аңларга ярдәм итә (4, 277). Мәсәлән, уянуга төнлекне ачып, уң якның киезен күтәрү, сөттән корт ясау, киез басу һ. б.

Әсәрдә урын алган йолалар исә күбрәк өйләнү һәм җеназа белән бәйле. Кодалыкка кул бирешү, кыз өчен калым бирү, сүз куешу көне, кыз белән егетнең очрашулары, кыз урлау һ. б. туй йолалары Г. Ибраһимов тарафыннан иң нечкә үзенчәлекләре белән сөйләнеп бирелә. Халык ышануларына бәйләнештә сурәтләнгән җеназа йолалары казакъ халкының милли йөзен тагын да тулырак ачарга мөмкинлек тудыра.

Шагыйрь, драматург, прозаик, журналист, сәясәтче, милли азатлык хәрәкәтенең күренекле вәкиле Габделгазиз Монасыйповның «Таранчы кызы, яки Хәлимнең беренче мәхәббәте» романы исә уйгырлар, аларның да XIX йөздә Кытайның Шен-Җаң өлкәсенә (провинциясенә) күчеп килгән бер өлешенең тормышын сурәтләүгә багышлана. «Г. Монасыйповның повестендагы бу тема сурәтләнгән мохите (уйгырлар белән аралашып яшәүче татарлар) белән генә дә татар әдәбиятында зур яңалык алып килде» (3, 202), – дип яза Фоат Галимуллин. Уйгырлар, алар аралашып яшәгән калмыклар, кытайлар тасвирланган бу әсәргә уйгыр әдәбияты галиме Кадыйр Хәсәнов югары бәя бирә: «Уйгыр халкының үткән тарихы белән милли азатлык юлындагы көрәш-хәрәкәтләре тарихчыларны да, уйгыр әдипләрен дә кызыксындыра. Әмма уйгыр кызы турында роман язган татар язучысы Габделгазиз Монасыйпов беренче тапкыр төрки-уйгыр тормышыннан уңышлы әсәр бирде...» (9).

«Таранчы кызы...» романында таранчыларның гореф-гадәтләрен, көнкүрешен, тарихын, туй йолаларын сурәтләүгә зур урын бирелә. Мәсәлән, таранчыларда 17–18 яшьлек аталарны, 14–15 яшьлек аналарны күрергә мөмкин. Хәтта 11–12 яшьлек кызларны кияүгә бирү очраклары да күзәтелә. Таранчыларда, кызның балигъ булу-булмавын тикшерү өчен, аерым йола да кулланыла икән. Берәүнең яшь кызына яучы килсә, таранчылар кызга көтмәгәндә генә түбәтәй ыргыталар. Әгәр дә түбәтәй кызга тигәч, кыз куркып егылса, балигъ булмаган дип кызны бирмиләр. Кыз егылмавы исә кияүгә чыгар вакыт җиткәнлеген аңлата.

Г. Монасыйпов укучыларның игътибарына таранчыларның йорт-җир төзелешендәге милли үзенчәлекләрне дә тәкъдим итә. Романның берничә җирендә йортларның күбрәк балчыктан эшләнүе әйтеп үтелә. «Яз башында, карлар эрегән чакларда, юешрәк, сулар күбрәк җыелып тора торган урындарак булган мондый гыймарәтләр (корылмалар) судан йомшыйлар вә хәтта җимерелгәлиләр» (7, 133). Өй түбәләренең калын балчыктан ябылган булуы һәм балчыкның кояш эссесен үткәрмәве кешеләрне Төркестан якларындагы эссе һавадан саклый.

Авторны өй эче, өй җиһазлары да кызыксындыра. Зәйнәп хушнәнең өен тасвирлау рәвешендә, прозаик барлык таранчы өйләренә хас сыйфатларны күрсәтеп бирә: «Аның өендә бер дә артык нәрсә юк; гомумән, таранчы өйләре төсле, аның өе дә күңелсез иде. Рәшәткәләп ясалган тәрәзәгә юка кәгазь ябыштырылган булып, ул тәрәзә идәннән ике аршын чамасында югары иде. Ярлырак таранчыларның һәммәсенеке төсле, аның өенең дә идәне юк; идән вазифасын җир әда итә иде. Түрдә ... сәке булып, сәкенең өстендә һәрвакытта да кызыл кашгар киезе җәелгән була торган иде. Стеналар һәрвакытта ак, чиста итеп акшар белән сыланган булып, сәке өсте тугрылары сәке буйлап, фанил шикелле итеп, ак чәчәкле кызыл француз (комач) белән кагылып чыгылган иде. Стенаның берничә җирендә кечкенәрәк шкаф зурлыгында итеп, стенаны уеп ясалган урыннар булып, алар гардероб, шкаф хезмәтләрен әда итәләр иде. Аларның эчләрендә басма белән тышланган берничә сырылган күрпә (юрган) вә бер-ике бүрәнә башы формасында итеп эшләнгән вә тышы кызыл гөлсез французлан тегелгән мендәрләр куелган була торган иде...» (7, 135).

Г. Монасыйпов «Таранчы кызы...» әсәрендә милли уйгыр ризыкларын да атап үтә, кайберләренең аңлатмаларын да бирә. Таранчылар бик еш кына кунакларын пылау, нан (күмәч), пәтернан (кече төче күмәчләр), гүшкәр, манты белән сыйлыйлар.

«Таранчы кызы...»нда таранчы, кытай халыклары тормышыннан алынган этнографик материалны татар халкы, татар халкының тормыш итү рәвеше, гореф-гадәтләре белән чагыштырып күрсәтү алымы да кулланыла. Таранчы өйләренең түрендә «безнең Казан арты авылларындагы мужик өйләрендәге шикелле итеп ясалган» сәке тора, таранчы кызлары «татарларның кечкенә генә ир балалары кия торган иштән булган кызыл плюш кәләпүш» кия... Г. Монасыйпов чагыштыру алымын ирек, азатлык өчен алып барылган көрәшне тасвирлау вакытында да файдалана. Мәсәлән: «Ләкин берәм-берәм таралып, дөньяның әллә кай җирләренә кадәр барып, килмешәк булып йөрсәләр дә, бер Ватанны ташлап, икенче Ватанга бер җәмгыять булып һиҗрәт итүдән курку, аңа кире тору гадәте безнең татар халкында булган шикелле, аларда да булган» (7, 153). Әлеге юллар аша автор үзенең татар укучыларын да көрәшкә чакыра төсле тоела.

Романда таранчылар тарихы да шактый тулы тасвирлана, автор бу урыннарны төп сюжет сызыгыннан аерып та куя. Хикәяләү барышында Г. Монасыйпов бу халыкның милли йөзен, характер сыйфатларын ассызыклап бирә.

«Таранчы кызы...» романында шулай ук кытай халкына хас гореф-гадәтләр дә сурәтләнә. Авторны Кытай шәһәрләрендәге «пур ату» күренешләре, аларның кунак сыйлау белән бәйле гореф-гадәтләре, кытай һәм таранчы милләтләреннән оешкан катнаш гаиләләрдәге үзара мөнәсәбәтләр дә кызыксындыра. Мәсәлән, «Шансән, кытай гадәтенчә, аның өйдә булмыйча Хәлимне көттерүенә бик фасыйх (матур, килешле) гыйбарәләр белән гафу үтенү өстенә, ул өйдә булмау сәбәпле, Хәлим белән озаклап сөйләшеп утыру шәрәфенә ирешкәне өчен шатланганын да белдерде» (7, 185–186). Автор кытайларда җинаятьчеләрне җәзалау, үтерү өчен кулланыла торган бик күп төрле коточкыч гадәтләрне дә укучыга җиткерә, төрмә, хөкем итү шартлары, халыкның шуларга мөнәсәбәте тасвирлана.

Автор татар укучыларын таранчыларның кайбер мәкаль-әйтемнәре (мәсәлән, «Чырайликта (сылуда) вафа юк»), кытайлар һәм таранчылар яшәгән кайбер

шәһәрләрнең тарихы белән бәйле риваятьләр, мәзәкләр (мәсәлән, Көрә шәһәре хакында) белән таныштыруны да максат итеп куя.

Күренгәнчә, Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы» һәм Г. Монасыйповның «Таранчы кызы, яки Хәлимнең беренче мәхәббәте» романнарында казакъ далаларында, Кытайда, Голҗада яшәүче мөселманнар хакында шактый кызыклы тарихи-этнографик мәгълүматлар бирелә. Авторлар татар укучысын тугандаш төрки халыкларның кием-салымнары, йорт-җир төзелеше, милли ризыклары, гореф-гадәтләре, милли бәйрәмнәре һ. б. белән таныштыра, йолаларны сурәтләүгә дә зур урын бирә һәм әсәр тукымасы эченә төрле риваятьләрен, мәкаль-әйтемнәрен кертеп җибәрә. Тарихи-этнографик материалның романтик мәхәббәт тарихы белән бергә кушылуы исә татар әдәбиятын эчтәлек һәм форма ягыннан баетуда мөһим роль уйный, иҗатта яңа темаларның ачылуына, яңа сәнгати алымнарның кулланылуына җирлек әзерли.

ӘДӘБИЯТ

1. Бәширов Ф. К. XX йөз башы татар прозасы / Ф. К. Бәширов. – Казан: Фикер, 2002. – 286 б.
2. Ванслов В. В. Эстетика романтизма / В. В. Ванслов. – М.: Искусство, 1966. – 216 с.
3. Галимуллин Ф. Табигыйлеккә хилафлык / Ф. Галимуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 304 б.
4. Зарипова-Четин Ч. А. Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы» романында казакъ халкының гореф-гадәтләре һәм мәдәни кыйммәтләре // Галимҗан Ибраһимов һәм XXI гасыр: Тууына 120 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. – Казан, 2007. – Б. 273–287.
5. Заһидуллина Д. Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы / Д. Заһидуллина. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 255 б.
6. Ибраһимов Г. Сайланма әсәрләр / Г. Ибраһимов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – 464 б.
7. Монасыйпов Г. Таранчы кызы, яки Хәлимнең беренче мәхәббәте / Габделгазиз Монасыйпов, басмага әзерләүче Т. Әйди. // Әдәби мирас (Икенче китап) / Төз.-мөх. Г. Г. Гыйльманов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – Б. 3-126.
8. Нуруллин И. XX йөз башы татар әдәбияты / И. Нуруллин. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1966. – 427 б.
9. Хәсәнов К. Уйгур қизи һәккәдә роман / К. Һасанов // Коммунизм туги. – 1973. – 12 июль.

## XX ЙӨЗ БАШЫ ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЕНЕҢ ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ХИКӘЯЛӘРЕНӘ МӨНӘСӘБӘТЕ

***Г. Н. Зәйниева (Казан)***

В статье рассматриваются рецензии на рассказы Г. Ибрагимова в татарской периодической печати начала XX века.

Татар әдәбияты классигы, күренекле дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, галим, Хезмәт Герое Галимҗан Ибраһимов (1887–1938) – XX йөз башы татар әдәбияты тарихында тирән эз калдырган бөек шәхесләрнең берсе.

Әдип иҗатының башлангыч чоры «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» (1907), «Гыйшык корбаннары» (1908), «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә» (1909) хикәяләре белән башланып китә. Аннан соң «Яз башы», «Диңгездә», «Йөз ел элек», «Сөю – сәгадәт», «Уты сүнгән җәһәннәм», «Карак мулла», «Карт ялчы», «Көтүчеләр», «Табигать балалары», «...мәрхүмнең дәфтәреннән», «Габдрахман Салихов» әсәрләре дөнья күрә. Алар күләм ягыннан зур түгел, эчтәлекләре белән кызыклы, романтик рухта язылганнар, шул чор проблемаларын яктырталар. Г. Ибраһимов әсәрләре басылуга, аларга мөнәсәбәтле тәнкыйть мәкаләләре күренә башлый. Нәкъ менә әдип иҗатының Октябрь революциясенә кадәрге хикәяләренең XX йөз башы татар матбугаты тәнкыйтендә чагылышын күзәтсәк, шул чордагы бәяләрен ачыклап була.

«Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясе беренче тапкыр «Әлислах» газетасында (1907–1908) басыла, аннан соң 1910 елда «Өмет» матбагасында дөнья күрә. Бу әсәрдә XX йөз башы татар әдәбияты тарихында күтәрелгән җәдит һәм кадим мәдрәсәләр арасындагы каршылыклар тасвирлана. Төп герой – Зәкине үзе укыган мәдрәсәдә яңача укытуны таләп итүе, башкаларны да җәдитчә укырга өндәве аркасында мәдрәсәдән куалар.

Бу хикәягә карата «Безнең юл» газетасында тәнкыйтьче Хәйретдин Вәли ««Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» (Г. Ибраһимовның беренче әсәре, 1907–1927)» исемле рецензия-мәкаләсен бастыра (1). Аның бу язмасы Г. Ибраһимовның беренче әсәрен язуына 20 ел тулуга багышланган. Ул әсәргә шул вакыт күзлегеннән җентекләп анализ ясый: гомумән алганда уңай бәяли, булган кимчелекләрен дә күрсәтеп үтә. Әсәрнең чыккан вакытын искә төшереп: «...Татар шәкерте тормышына һәм аның рухына көчле тәэсир иткән бер әсәр ул», – ди. Автор мондый әсәрнең үз заманасында бик кирәкле булганлыгын ассызыклый: «Темасы һәм зәмине – “Зәки шәкерт...” – татар иҗтимагый тормышының иң үзәк бер почмагын – аның иске мәдрәсәләрен тасвир иткән бер әсәр ул. ... Татарның шәһәрдәге зур мәдрәсәләренең эчке тормышын ачып салган әсәр “Зәки шәкерт...”кә кадәр юк иде». Х. Вәли Зәкинең фикер үзгәрешенә игътибар юнәлтеп: «Башта Зәки тәнкыйтьче малай була. Аннан мантыйк укып кызу канлы, талашучы, моназарәче шәкерт килеп чыга. Соңыннан, җәдитләрнең мәҗлесләренә йөреп, фикер алучы, яшереп кенә яңа әдәбият укучы шәкерткә әйләнә. Соңыннан шул әдәбият фикере һәм җыелышлар тәэсире белән үз көченә нык ышанган, үзсүзле, сүз белән дөнья төзүче – идеалист исляхчы булып ясала. ... Зәки ул – хис кешесе түгел, акыл кешесе. Шәхси кеше түгел, иҗтимагый кеше. Ул җәмгыять өчен уйлый. ... Ул сәбатлы *(фикердә, эштә нык торучы)* кеше, ул чын исляхчы кебек үзенең тартышын ахыр чиккә кадәр – үзен мәдрәсәдән куып чыгарганчы алып бара. Шуның өчен Зәки безнең татар матур әдәбиятында исляхчы шәкертнең чын-чын тибы ул! Әдип Зәкидә исляхчы шәкертнең бөтен эчке мөндәриҗәсен биргән» – дип югары бәяли. Шулай ук Зәкинең тышкы кыяфәтенең кимчелекләренә туктала. Аның фикеренчә: «Зәки әсәргә

исляхчы шәкертнең тышкы кыяфәте, үзенең исляхчылык дәверенә хас кием-салымы белән килеп төшә алмаган. Зәки ... исляхчы шәкертчә, чәче җиткән, ябык йөзле, чандыр гына, кызыл күлмәк өстеннән киң каеш бәйләгән, ләкин мәдрәсәдә йөргәндә, бу кыяфәттә үк күренергә ярамаганга, өстән җилән кигән кыяфәттә булып килеп баса». Тәнкыйтьче хикәянең теленә аерым игътибар итеп түбәндәге фикерләр әйтә: «Галимҗан Ибраһимовның тел һәм өслүбе "Зәки шәкерт..."тә әле гаять башлангыч хәлдә тора, "Зәки шәкерт..."нең өслүбенең тасвирыйлыгы бик әз процент ала. Анда истигарәләр *(күчерелмә мәгънәдәге сүзләр),* мәҗазләр *(метафоралар),* кинаяләр, җанландырулар юк. Сыйфатлаулар да бик аз очрый. Телдә кайбер урыннарда нәхүсезлекләр дә күренә. ... "Зәки шәкерт..."нең өслүбендә җитешсезлекләр булуга карамастан, язучысында әдиплек чаткысы барын күрсәтеп тора. ... Аның да башта теле гарәпчәдән саф булмаган, аның өслүбе эволюция юлы белән сафлана, халыклаша, тормышка яраклы булып кристаллаша һәм сәнгатьчә матурлана килгән». Мәкалә авторы язучы хакында: «Әдип "Зәки шәкерт..."тә сәнгатьче булып түгел, фикерче булып күренә. ... Әсәрдә ялкын бар. Анда тар мантыйкка, публицист әсәрнең табигать һәм кануннарына сыймаслык көчле ялкын бар», – ди. Х. Вәли әдипнең 20 еллык иҗатын күз алдыннан кичереп: «"Зәки шәкерт..." – Галимҗан Ибраһимовның сәнгать-әдәбият хәяты тарихының башы. ... Ул һәр әсәрендә сәнгатьчә һәм идеология буенча тәдриҗи *(акрынлап, эзлекле)* рәвештә үсә барган. ... Әлбәттә, 1907–1927 еллар арасында татарның иҗтимагый тарихи үсүе зур булган шикелле, Галимҗан Ибраһимовның да әдәби үсүе «Зәки шәкерт...» белән башлану вакытына чагыштырылмаслык дәрәҗәдә алга китте» сүзләре белән мәкаләсен тәмамлый.

Г. Ибраһимовның «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә» хикәясе 1909 елда язылып, 2 тапкыр бастырыла (1909, 1911). Әсәрнең төп герое – Сәлим шул дәвер милли интеллигенциясе вәкиле. Аның образы аша язучы үзенең шул чордагы мөһим иҗтимагый-фәлсәфи карашларын чагылдыра.

Г. Ибраһимовның бу әсәренә беренчеләрдән булып Сәгыйть Рәмиев (1880–1926) игътибар итә. Хикәянең беренче басмасы чыгу белән, ул «Идел» газетасында С. Р. имзасы астында кечкенә бер рецензия бастырып (2): «хакыйкый яңа бер әсәр», «мәзмуне (эчтәлеге) дә матур һәм мәүзугсы (темасы) да безнең өчен бик кызык», – дип уңай бәяли. Тәнкыйтьче хикәянең реализмын, авторның типик характерлар тудыруын, «тасвиратында… бер шигърият уйнап», «мөхәрриренең каләменнән һәрвакыт талант чаткылары сачрап торганын» билгеләп үтә. «Бу кадәр матур бер мәүзугны матур итеп тасвир кыйла алуда һәм әдәбият галәмемезгә матур бер хикәя һәдия итүдә муаффәкыяте белән яшь вә ләкин ачык талантлы мөхәрриремезне тәбрик итәмез», – ди С. Рәмиев.

Хикәя дөньяга чыгып дүрт ел узгач, «Ил» газетасында Оренбургның «Хөсәения» мәдрәсәсе әдәбият мөгаллиме Нәҗиб Гасрый «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә» исемле махсус рецензия (газетада фельетон дип бирелгән) бастыра (3). Тәнкыйтьче, әсәргә анализ ясап, байтак кимчелекләрен күрсәтә. Галимҗан Ибраһимов тасвир иткән төп герой Сәлим тәнкыйтьчедә сораулар тудыра: «...Аның халыкка иткән хезмәтләрен күрергә ашыгып, назарының үткенлеге, рухының галимлеге нинди урыннарда күренер, кай нокталардан тишеп чыгар икән, дип укуыңда дәвам итәсең». Н. Гасрый хикәянең сюжетын күздән кичереп тиешле нәтиҗәләр ясый: «Мөхәррир, Сәлим әфәнденең рухындагы үзгәрешләрне күрсәтү өчен аны Урта Азиядән өч мәртәбә Казанга китерә. Сәлим әфәнде, Урта Азиядә мамык белән сату итә белер, ләкин Бохарадан милләтчелек, инсаниятчелек фикерләрен, мәсләкләрен өйрәнеп кайта алмас!» – ди. Сәлимнең шундый билгесезлек халәтендә булуы, берничә тапкыр фикер алыштыруы нык тәнкыйтьләнә: «...Университет тирәсендә әйләнеп йөреп "гүзәл тормыш"ны уйлавы да аның "гали рухлы" булуына дәлил була алмый. Билгакес, куян йөрәкле, куркак рухлы булуын белдерә! Бүген Кәримнең, иртәгә Җәлилнең сүзенә карап фикер алмаштырып тору, Сәлим әфәнденең сөбатсызлыгын күрсәтә. Сәлим әфәнденең рухының тирәнлегендә яткан ... "чаткы наразыйлык" чаткысы, һичбер заман бер идеалны яктырта алачак түгел!»

Тәнкыйтьче Сәлимнең үз-үзен тотышы хакында: «Сәлим берлән Җәлилнең "рәсми!" сөйләшүләре, Җәлилнең бүлмәсенең "пөхтә" булуы, ул озын-озын салмак нотыклар, бер дә яшьләргә килешә торган нәрсәләр түгел. Әсәрнең сәхифәләре, кинематограф ләүхәләре кебек хәрәкәттән гыйбарәт буласы урында, җансыз, хәрәкәтсез, рухсыз!». Хикәянең исеменә дә үзенең бәясен бирә: «Әсәрнең исеме "Сәлим әфәнденең хәятыннан бер ләүхә"гә алмаштырылса, бәлки мәсъүлият бераз җиңеләер иде. ... Әлхасыйл, "Яшьләр хәятыннан бер ләүхә" Галимҗан әфәнденең 6–7 сәнәлек хәят әдәбиясендә бик зур тышлы бер китаптан башка бер нәрсә түгелдер».

Шушы ук вакытта «Хөсәения» мәдрәсәсенең икенче мөгаллиме Җамал Вәлиди дә «Вакыт» газетасында «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә»гә карата рецензия (4) белән чыга. Ул Н. Гасрый мәкаләсен «бик мөһим тәнкыйть» дип атый һәм нигездә аның фикерләренә кушыла. Хикәядә Сәлимнең мәкаләсе хакында Җ. Вәлиди үзенең бәясен бирә: «Сәлимнең бу дәвердәге фикер вә назарын күрсәткән "Милләт кайгысы" исемле мәкалә татар яшьләренең мәсләк алмашынуында һичбер беренче баскычны хәрәкәт ризавәт итми. ... Мәкаләнең ахырында Сәлимнең артык миллилеген күрсәтер өчен әйттергән "Милләтнең иттифак вә иттихадына балта чапкан таңчы малайлар..." дигән сүз бу мәкаләдә бөтенләй урынсыз тора. Әдәбиятымыз эчендә мисле булмаган "Ике йөз елдан соң инкыйраз" кеби сүзләр илә бергә оешып бетми. ... "Милләт кайгысы" исемле мәкаләдән ... таң белән мәгасыр сәлби миллият бер дә аңкымый». Тәнкыйтьче Сәлимнең төпле үз фикере булмавына тискәре бәя бирә: «Хәер инде, Урта Азиядә мәсләк алмашыну эше мәркәз булган Казан илә бергә үк йөрмәсә йөрмәс, мәсәлән, Сәлим әфәнде Урта Азиядән килеп йиткәнче, Казанда аның алып килгәне миллият модадан чыккан булыр. Шулай ук таңчылыкны Азиядән әйләндереп килгәнче Казанда "Таң", "Тавыш" тынган булыр!» Җ. Вәлиди мәкаләсен түбәндәге җөмләләр белән тәмамлый: «Әсәрдә шул рәвешчә Сәлимнең мәсләк авышдыруына бер хатимә, бер чик бирелми, ... ягъни фәггаль димаглы, үткен нәзарлы, гали рухлы Сәлим мәсләксез вә сөбатсыз бер кеше хәлендә танылып, күңелгә урнашып кала. Ошбу оешкысызлык, аһәксезлек илә бәрабәр "Яшьләр хәятыннан бер ләүхә"дә тасвирдагы осталык, өслүбдәге тугрылык вә матурлык

ихтыярсыз кешене үзенә җәлеп итә. Шуның өчен боны укыгач та “никадәр матур нәрсә, ничек тәртипсез, әсассез, аһәксез оешдырылган” диясе килә».

Бу ике мәкаләдән соң журналист, тәрҗемәче Заһид Нуркин (1888–1966) «Аң» газетасында «Кем җинаяте?» исемле мәкалә-рецензия бастыра (5). Бу мәкаләсен ул хикәя дөньяга чыккач та язылганын, ләкин Н. Гасрый һәм Җ. Вәлиди мәкаләләреннән соң гына матбугатка тәкъдим ителгәнен әйтеп уза. Тәнкыйтьче бу әсәр җентекләп тикшерелергә тиеш иде дип яза: «...Бу кечкенә генә әсәрнең нинди зур әһәмият вә җәдит белән каршы алынырга тиешлеге күз алдына килергә кирәк». Заһид Нуркин төп герой Сәлимнең фикер үзгәртеп йөрүенә каты бәрелми: «...Сәлимдәге эчке инкыйлаб садә генә, тыныч кына булмаган, юк, ул шиксез зурзур тәрәддедләр вә көчле эчке көрәш – фикерләр көрәше соңында булган». «Соң бу эчке инкыйлаб ничек вә нинди мөәссәрләр тәхетендә вөҗүдкә килгән?» – дигән сорау куела мәкаләдә. Тәнкыйтьче фикеренчә: «...Иң әһәмият бирелергә тиеш булган вә әсәрнең чын әдәби булып чыгуы өчен, мөхәррир тарафыннан иң зур мәһарәт әдәбия белән күрсәтелергә мохтаҗ булган нокта – шушы ноктадыр. Ләкин Галимҗан әфәнде, мәгаттәәссеф, бу ноктаны бөтенләй әһмаль итә, шулай итеп әсәрнең әдәби әһәмиятен җуя, диярлек. Фәкать аның белән әсәрнең иҗтимагый әһәмияте кимеми, тик, “ник болай булган, ничек ул Сәлим идеалсыз калган?” сөаленә җавап үземез бирергә генә тиеш буламыз». Соңыннан: «Аны, Сәлимне, мәгыйшәт кыскан. Киләчәгенең маясене мәгыйшәт шул чаклы кысканда халык, милләт ни эшләгән? Аларга ярдәмгә йитешкәнме? Аларны җуатканмы? Юк... халык яшьләрне сүккән, аларга нәфрәт күрсәткән, аларны арасыннан сөргән. Шулай булгач, бу: “Кем җинаяте?”» – дигән риторик сорау белән мәкаләсен тәмамлый.

«Яз башы» (1910) хикәясенең төп герое – авыл малаеның, мәдрәсәдән ялга кайтып, авыл тормышының, яшәешенең, табигатьнең гүзәллеге, чиксезлеге белән сокланулары романтик рухта сурәтләнә. Хикәянең басма вариантлары шактый. Бу әсәргә карата «Ялт-йолт» журналында авторы билгесез булган «Матбугат кызыклары» сәхифәсендә «Яңа әсәрләр: Яз башы. Мөхәррире – Галимҗан Ибраһимов» исеме астында мәкалә-бәяләмә бастырыла (6). Тәнкыйтьче Г. Ибраһимовның «Яз башы» хикәясен «вафли төслерәк итеп әвәләп чыгарган», «вафли һәмишә тозсыз була, вафли кебек хикәяләр дә тозсызрак чыгалар», дип бәяли. Шунда ук хикәянең теленә, язылу стиленә тискәре бәя бирелә.

«Идел» газетасының «Яңа әсәрләр» сәхифәсендә «Карак мулла» һәм «Сөю – сәгадәт» хикәяләре хакында кыскача белешмә китерелә, һәм: «Матур һәм кызык кына хикәяләр булып чыкканнар», – диелә (7).

«Карак мулла» (1912) хикәясе 1912 елда «Гасыр» нәшриятында 9 нчы китап итеп басылган, аннан соң 1957 елда чыккан «Сайланма әсәрләр»нең I томында дөнья күрә. Әсәрдә төп герой – Тимри мулла, караклар нәселеннән булып, мәдрәсәдә укыса да, мулла булып торса да, соңыннан барыбер карак булып китә. Аны бер җинаяте аркасында Себергә куу белән хикәя тәмам була.

Бу хикәягә карата «Сибирия» газетасының «Яңа әсәрләрне тәнкыйть» сәхифәсендә, авторы күрсәтелмәгән, «Карак мулла. Г. Ибраһимов әсәре. Гасыр нәшере» исеме астында мәкалә урнаштырылган (8). Хикәя хакында тәнкыйтьче: «Әсәр ... әллә ниндәй бер ашыгучылык вә әллә нәрсәгә бер ашкынлык илә язылган. Шулай да тасвирләре матур, теле йиңел улып укырга күңелледер», – дип яза. Мәкаләдә әсәрнең кайбер уңышсыз дип саналган сюжет элементларын атап, башкача булса отышлырак булыр иде дигән фикер уздыра. Мәсәлән, Тимринең мәдрәсәдән куылуы, Сафа байның атын урлавы башкачарак бирелсә, уңышлырак чыгар иде, дип яза. Шулай ук матур итеп тасвирланган урыннарын да читтә калдырмый, мәсәлән, Тимри мулланың кеше йортларына сакчы булып калуы, халыкның Тимри мулла кебек усалларга карата берни дә кыла алмавы. Гомумән, хикәя уңай бәяләнеп: «...Кимчелекләреннән башка бик матур әсәр улып, ләззәт илә укырлыктыр. Тәбгысы бик ул кадәр нәфис булмаса да, зарарсыздыр», – диелә.

«Сөю – сәгадәт» хикәясе 1912 елда Казанда «Әхмәтгәрәй Хәсәни вә шөрәкясе» наширлегендә басыла, аннан соң 1957 елда чыккан «Сайланма әсәрләр»нең I томында дөнья күрә. Хикәянең башы астына җәяләр эчендә «Карт шагыйрьнең тәәссераты» дип куелган. Хикәядә бер картның яшь вакытларын, гыйшкын искә төшереп, шул вакыттагы уй-кичерешләре тасвир ителә.

Әсәр басылып чыгу белән үк тәнкыйть фикерен җәлеп итә. «Идел» газетасының «Яңа әсәрләр» сәхифәсендә Әбрар Мускиевнең «Сөю – сәгадәт». Мөхәррире Галимҗан Ибраһимов» исемле мәкаләсе урнаштырылган (9). Анда ул хикәягә югары бәя бирә. Әсәр башында кояш бату һәм үлем күренешләре чагыштырыла, тәнкыйтьче фикеренчә, бу урын уңышсыз булып чыккан. Аннан соң картның мәхәббәте хакындагы өлеше әсәрнең «иң гүзәл, иң матур һәм иң художественный урыны», «нәзек психологияле» булуы, табигать күренешләренең оста тасвирлануы, сандугачның сайраулары, шәрык музыкасының ишетелүе «әсәргә әйтеп бетермәслек художество бирә». Тәнкыйтьче Г. Ибраһимовны геройларына «психологик анализ ясауда» Достоевскийга охшата. Мәкалә ахырында нәтиҗә буларак: «...Бу әсәр безнең әдәбиятта да художество бөтен мәгънәсе берлән башлануына дәлаләт кыйла... Бу әсәре берлән Галимҗан әфәнде үзенең дә талантының тәрәккый итүен ачык белгертә», – диелә.

Шулай ук бу хикәягә карата «Сибирия» газетасында «Татар» имзасы астында «Яңа әсәрләрне тәнкыйть» сәхифәсендә «“Сөю – сәгадәт”. Г. Ибраһимов әсәре. Гасыр нәшере» исемендә мәкалә урнаштырылган (10). Биредә әсәр «бик матур итеп язылган», «тәбгысы гүзәл вә нәфис» диелә. Хикәядәге мәхәббәт-гыйшык, табигать күренешләре «бик матур тасвир ителгән». Тәнкыйтьче: «Хикәя үзенең төп максудын аңлатса да, укучының тәэсиратен бозмас өчен аңсыздан тәмам булмаса, тагын матур чыгар иде», – дип яза.

Нәтиҗәдә шуны әйтеп булыр иде: Г. Ибраһимовның хикәяләре басылган вакытта да матбугатта бәяләрен алганнар, еллар үтү белән дә бу әсәрләргә карата яңаданяңа фикерләр басылганы күренеп тора. Ягъни әдип иҗаты һәрвакытта тәнкыйтьнең күз уңында булып, каршылыклы фикерләр дә, уңай бәяләмәләр дә чагылыш тапкан.

ӘДӘБИЯТ

1. Хәйретдин Вәли. «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» (Г. Ибраһимовның беренче әсәре, 1907–1927) // Безнең юл. – 1927. – № 12. – Б. 35–38.

2. Сәгыйть Рәмиев. Яңа әсәр // Идел. – 1910. – 10 декабрь (№309).
3. Нәҗиб Гасрый. «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә». Галимҗан Ибраһимов әсәре (фельетон) // Ил. – 1914. – 2 гыйнвар (№ 10).
4. Җамалетдин Вәлидов. Яшьләр хәятыннан бер ләүхә // Вакыт. – 1914. – 26 гыйнвар (№1400).
5. Заһид Нуркин. Кем җинаяте? (Г. Ибраһимовның «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә»се мөнәсәбәте белән) // Аң. – 1914. – № 4. – Б. 86–87.
6. Яңа әсәрләр: «Яз башы». Мөхәррире – Галимҗан Ибраһимов // Ялт-йолт. – 1912. – 15 апрель (№ 37). – Б. 4.
7. Яңа әсәрләр // Идел. – 1912. – 28 февраль (№ 431).
8. Яңа әсәрләрне тәнкыйть. «Карак мулла». Г. Ибраһимов әсәре. Гасыр нәшере // Сибирия. – 1912. – 3 июнь (№ 15).
9. Әбрар Мускиев. Яңа әсәрләр. «Сөю – сәгадәт». Мөхәррире Галимҗан Ибраһимов // Идел. – 1912. – 6 март (№ 433).
10. Татар. «Сөю – сәгадәт». Г. Ибраһимов әсәре. Гасыр нәшере // Сибирия. – 1912. – 17 июнь (№ 17).

# Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ «ТАТАР ХАТЫНЫ НИЛӘР КҮРМИ» ӘСӘРЕНДӘ ТУЙ ЙОЛАСЫНЫҢ ӘДӘБИ ЧАГЫЛЫШЫ

*Л. Ф. Җамалиева (Казан)*

Статья отражает художественное воплощение свадебного обряда в произведении Г. Ибрагимова «Татар хатыны нилəр күрми».

Халык авыз иҗаты – әдәбиятның чишмә башы. Татар фольклоры һәм әдәбияты багланышларын өйрәнү эше шактый еллар элек башланган булса (1), соңгы елларда бу мәсьәлә тагын көн тәртибенә күтәрелде (2, 4). Г. Ибраһимов иҗаты да бу юнәлештә инде тирәнтен өйрәнелгән. Шундый хезмәтләрнең берсе – фольклорчы галимә А. Садыйкова тарафыннан язылган «Фольклор в эстетике Галимджана Ибрагимова» дип аталган монография (3).

Г. Ибраһимовның «Татар хатыныниләр күрми» әсәре XX гасыр башында уздырылган никах туе йоласының гаҗәеп тулы һәм җанлы чагылышы белән игътибарны җәлеп итте. Гомумән алганда, гаилә тормышы белән бәйле йола иҗатында өйләнешү – никах туена бәйле йолалар һәм поэтик әсәрләр үзәк урынны алып торалар. Чөнки өйләнешү – кеше тормышының иң җаваплы һәм күркәм чоры, кешенең мөстәкыйль тормышка аяк баскан вакыты. «Туй – барыннан да элек билгеле бер хуҗалык акты: гаилә, хуҗалыкка яңа әгъза кабул итү – эшче һәм нәсел үрчетүне максат итеп куя. Димәк, туй – экономик хаҗәтлек факторы булып тора. Шуңа күрә туй поэзиясенең һәрбер төрендә менә шул як чагылыш таба. Алай гына да түгел, кабиләчелек, ыручылык чорында бер төркемнең (гаиләнең) ныгуы, үрчүе дошман төркемдә (гаиләдә) ачу, көнчелек тудыра. Шуңа күрә туй үткәрү, уңышлы ярәшү (никах) турында реаль хәстәрлек күрү өстенә, кияү белән кәләшкә, туганлашкан гаиләләргә дошман көчләрдән (явыз рухлардан һәм үз өй-йорт рухларыннан һ. б.) саклану чараларын күрергә кирәк була. Болар өстенә яңа өйләнешкәннәрнең матур киләчәген булдыру, хуҗалыгын ныгыту, мал-туарын, нәселен үрчетү мәсьәләләре дә килеп баса. Менә шуларны искә алганда традицион туйларның һәртөрле ышану-табынуларга бай булуы бик табигый күзаллана (7, 10).

Гасырлар дәвамында никах туеның төрле йолагадәтләре формалашкан. «Урынына-ягына, авылынатирәлегенә карап, туйлар төрле җирдә төрлечәрәк үткән... Бу тарих һәм көнкүреш, җирле шартлар һәм тирә-юньдәге элемтә-йогынтылар белән бәйләнгән табигый бер хәл» (5, 11). Әмма халкыбызның туй йолаларында һәм туй поэзиясендә барлык этник төркемнәр һәм төбәкләр өчен дә уртак катламнар бар. Бу катламнар туй йоласының һәм иҗатының борынгыдан килгән тотрыклы табигатен һәм гомуми милли йөзен билгелиләр. Туй йолаларының төп мәгънәсе кайсы халыкта, кайсы чорда булуга карамастан – яңа гаиләне, яңа союзны булдыру, аны рәсмиләштерү, тануга кайтып кала. Төп юнәлеше һәм составы исә бер йорттан икенче йортка кыз (кәләш) тапшыру, булачак ирнең йортына озатудан тора. Октябрь революциясенә кадәр татарларда өйләнешүнең өч төре булуы билгеле: 1) яучы җибәрү, кодалау аша; 2) кызның ата-ана рөхсәтеннән башка, үз теләге белән сөйгәне белән кушылуы (ябышып чыгу); 3) кызны урлап алып китеп өйләнү. Соңгы ике очракта туй йолалары үтәлми кала. Ә менә яучылау (килешеп сөйләшү) аша никахлашуга бәйле туй йолалары рухи һәм физик яктан сәламәт, матди ягы тәэмин ителгән яшь гаилә булдыруны, шуңа күрә туй йоласы этапларын бөтен ваклыклары белән үтәүне күздә тота һәм гасырлар дәвамында саклана.

Г. Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» әсәре «Бер атна эчендә кызга ике яучы килде» (6, 225) дигән җөмлә белән башланып китә. Шушы җөмлә укучыны әсәр герое булган кыз тормышында булачак кискен үзгәрешләргә әзерләп куя. Гадәттә, «кемнең кызын сорату мәсьәләсе хәл ителгәч, егет ягы дәрәҗәләрәк кешене яучы (башкода, димче) итеп билгели. Гадәттә, туган тиешле, телгә оста, дипломат кеше билгеләнә» (7, 11). Гөлбануга килгән яучыларның берсен этисе тиз генә борып җибәрсә дә, Шибай кантоннан килгәнен бора алмый. Әсәрдәге вакыйгалар Нурый карт йортында туйга әзерлекне тасвирлау белән дәвам итә.

Автор хуҗаларның туйга чакырылган кунакларны, аеруча кодаларны бик дулкынланып көтүләре турында яза. Башкодалар туйга беренче чанада киләләр. Аларны кызның эти-әнисе каршылый. Кияүнең кankардәшләрен кызның бертуган абый-җиңгәләре каршы ала. Күчтәнәчкә дигән туй ашларын аерым чанада алып килүгә дә игътибар бирелә (6, 247).

Никах туе табынындагы милли ризыкларны сурәтләүгә дә зур урын бирелә. Татар халык ашлары искиткеч тәмле. Ә инде мондый төр мәҗлесләрдә ризык әзерләүгә аеруча зур игътибар бирелә. Чөнки туй ашлары кодалар тарафыннан да бәяләнә. Кодалар үзләре дә туйга бик зурлап килгәннәр. Өлкән кода Шибай, Әфтәх, Алтынбай кодаларның бүләк ашларын исемләп, табынга чыгарып күрсәтәләр һәм кунакларга бүлеп

бирәләр. «Арада иң шәбе, әлбәттә, Шибайныкы булды. Аның майлары тулышып торган ике симез казы белән симез күркәсе, өсләренә каклар, җимешләр сибеп пешерелгән дүрт зур ләвәш күмәче, кечкенә дүрткел тау кебек торган, өсте, читләре кәнфит белән чәчәкләнгән зур ике баллы бавырсагы – тагын әллә ничаклы оста әзерләгән аш бүләкләре мәҗлеснең күзен уйнатты» (6, 249). Туйдан соң кәләшнең иптәш кызларын җыеп, аларга кияү бүләкләре өләшә торган бүләк чәе табынында да, кызны кияү йортына төшерү һәм андагы мәҗлестә дә туй өчен пешерелә торган ризыкларны сурәтләүгә дә аерым игътибар ителә. Бүгенге көндә уздырыла торган туйларда борынгы йолаларның бик күбесе онытылса да, кода-кодагыйларның туй табынына махсус ризыклар пешереп алып килүләре, аларны, зурлап, кунакларга күрсәтү һәм һәрберсенә авыз иттерү сакланып калган.

Кияү килү күренешен сурәтләү дә игътибарга лаек. Закир туры кыз йортына түгел, ә өндәүче Хәбип йортына төшә. «Никах укылганчы шул өндәүче йортында калачак, аннан кыз катына киләчәк» (6, 250). Өндәүче – ул туйга кунакларны чакыру өчен махсус билгеләнеп куелган кеше. Фольклор материалы нигезендә диалекталь үзенчәлекләрне өйрәнүче галимә Ф. Баязитова өндәүче сүзенең Башкортстан татарларында бик актив булуын билгеләп үтә (10, 221).

Кияү кыз янына кияү егетләре белән килә. Бик шаулап, мылтыктан атып киләләр (6, 254). Р. Мөхәммәтҗанов моны: «кияү килгәндә яки килен төшергәндә мылтыктан ату борынгыдан килгән ышану, явыз көчләрне куарга яки куркытырга мөмкин булган нәфрәт уятучы магия», – дип саный (7, 28). Кияү килгәндә мылтыктан һавага ату күренеше Мордовиядә яшәүче татарларда, төгәлрәк әйткәндә Белозерьеда бүгенге көнгә кадәр сакланып калган.

«Ишек бавы» җырлары туй иҗатында аерым бер төркем тәшкил итә. «Никах укылганнан соң шул ук көндә, яисә күпмедер вакыт үткәннән соң, кичен кояш баегач, кияү үзенең дуслары (кияү егетләре) белән пар атта яки тройкада кыз янына килә торган булган. Кыз янына келәткә яки ак өйгә үтү өчен, кияүдән ишек хакы түләве таләп ителгән. “Ишек бавы” җырлары әнә шундый чакта, кыз янына керер алдыннан башкарылганнар» (8, 88). Әсәрдә «Ишек бавы» җыр текстлары үзләре бирелмәсә дә, кияү килү, ишек бавы тотучы балаларның бүләк сорау күренешләре бик халыкчан итеп сурәтләнә: «Тышкы яктан малайлар һаман киреләнделәр: “Җизни! Ишек бавы бер акча, безнең апай мең акча!” – дип, кулларына бирелгән егермешәр тиенлек көмешкә риза булмадылар, тыш яктан ишек бавын җибәрми тордылар. Кияү тагын берәр көмеш салды, балалар һаман усалландылар, шул ук сүзне кабатладылар: “Җизни! Ишек бавы бер акча, безнең апай мең акча!”

Егет өченче тапкыр бирде. Малайлар шатлыктан сикерешеп чаптылар. Кияү ишек бавын тартып җибәрде, эчтән кунак килен келәне ычкындырды» (6, 271).

Туй буласы йорт, бигрәк тә кияү керәсе бүлмә, гадәттә кияү келәте, ә бу очракта түбән оч Хәмит йорты турында укыганда да авторның оста рәссам кебек эш итүенә сокланмый мөмкин түгел. Алар укучыны шул чордагы татар авылларындагы яшәү шартлары, йорт җиһазлары, бүлмә бизәлеше белән таныштыру өчен махсус эшләнгән кебек (6, 269). Кунак килен Мәрхәбә белән матур җиңги Мәфтуха «кызның бирнәләре, өшәнчекләре белән тулы ак калайлы зур ике сандык»тан чыккан «киҗеле сөлгеләр, чигүле намазлыклар белән өйнең бөтен ялангач стеналарын бизәп бетерәләр» (6, 269). Чыннан да, әсәрне укып, ул чорда кызның бирнәсен әзерләүгә күпме вакыт, көч һәм акча сарыф ителүен күрергә мөмкин: «Гөлбану, ундүрт яшеннән алып, һәр яз берничә ай киндер сукты, үзенә, булачак киявенә сөлгеләр, ашъяулыклар, күлмәкләр, чаршаулар, чыбылдыклар әзерләде... Менә шулай итеп, унҗиде яшенә кергәндә, кызның өшәнчеге, бирнәсе бик бай булып әзерләнеп җитте» (6, 272). Әмма шушы бай бирнә һәм кыз өчен түләнгән мәһәр Гөлбануның бәхетсезлегенә дә сәбәп булып тора. Кызның кайнана йортында коточкыч шартларда яшәвен белсә дә, әтисе Нурый карт аның ирен ташлап кайтуына каршы була. Чөнки ир аермаса, хатын китә алмый. Әгәр китсә, аның барлык әйбере ир кулында калачак. Фәтхия мәһәр, бирнә дип, бердәнбер кызын ут эчендә яндырырга теләмәсә дә, ире Нурый: «Өч йөз сум мәһәрне ничек ташлап китәсең» дип, кызны кайтартмый.

Туйга кияү ягыннан килгән кунакларны хөрмәтләү, аларны кәләш гаиләсендә генә түгел, туй күтәрешүчеләрдә дә кунак итү, кодалар җигеп килгән атларны саклау күренешләре дә әсәрдә бик җанлы итеп тасвирланган. Бик тырышып саклауларына да карамастан, кодалар атының койрыгын кисәләр. Дөрес, беленер-беленмәс кенә. Әмма бу инде хурлык булып санала. Алга таба Гөлбануның «әрем тел»ле кайнанасы тарафыннан киленне рәнҗетеп күп мәртәбәләр телгә алына.

Әсәрдә туй йоласының бөтен өлешләре дип әйтерлек бик җентекле рәвештә тасвирланган, кәләшне иптәш кызлары белән кызлык гомере үткән яланнардан саубуллаштырып кайтару да, кияү йортына озата бару да һ. б. Кияү килгәндә күчтәнәч туй ашларының аерым арбада килүен күрсәк, килен төшергәндә, алдан киленле көймә, ирле-хатынлы кунак арчилар, алардан соң сандыкның аерым арбада баруына игътибар иттек. Бик сирәк очрый торган күренеш – яшь егет-җилкенчәкнең бер-берсен сөзмә белән буяп, аклап, киленне каршы алуы сурәтләнгән урыннар, шушы чорда гамәлдә булган халык йолаларын бөтен нечкәлекләре белән күз алдына китерергә ярдәм итә.

Автор Гөлбануның беренче мәртәбә суга баруын да җентекләп тасвирлый (6, 316). Башкорт халык авыз иҗатын киң планда тикшергән галим С. Галин фикеренчә: «...бу йолада табигать культы – суга табынуны, шушы йолага ниндидер магик мәгънә салынганлыгын күрмәү мөмкин түгел». Бер үк вакытта бу йоланың икенче – психологик ягы да булган, күрәсең. Һәрхәлдә, су юлы әле генә озатылып төшкән киленгә бераз тынычланып алырга, соңгы тапкыр булса да үзенең тиңнәре белән йөреп кайтырга мөмкинлек биргән (9, 28–29).

Туй никадәр генә матур булмасын, ул бик тиз уза. Кияү йортына төшкәннең беренче көненнән үк, Гөлбану ишле гаиләнең бик күп эшләрен үз җилкәсенә алырга мәҗбүр була. Кайнатасы Шибай үлгәннән соң, кәләшнең тормышы бик авырлаша. Иренең кыйнаулары, кайнананың явызлыгы, игезәк балаларның үлүе Гөлбануны соңгы чиккә җиткерә – ул суга ташланып үлә. Әсәрнең халык иҗаты белән бәйләнешен өйрәнгән галимә А. Садыйкова, әсәрнең сюжеты традицион бәетләрне кабатлый, дип саный (3, 64).

Нәтиҗә ясап әйткәндә, Г. Ибраһимов тарафыннан халыкның гореф-гадәтләрен, этнографиясен тирәнтен өйрәнеп язылган «Татар хатыны ниләр күрми» әсәрен укып, XIX гасыр азагы – XX гасыр башында уздырылган никах туе йоласының эчтәлеге, аның аерым этаплары хакында бик тулы һәм кызыклы мәгълүмат алырга мөмкин.

ӘДӘБИЯТ

1. Ахметова Ф. О некоторых особенностях использования фольклора в современной татарской прозе // Вопросы татарского языка и литературы.: Кн. 4. – Казань, 1969. – С. 81–87; Галиуллин Т. Илһам чишмәләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988.

2. Урманчеев Ф. Дастаннарга лаек замана. Борынгы фольклор һәм хәзерге поэзия. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990; Урманчеев Ф. Волшебный клубок. Муса Джалиль и народное творчество // Ф. Урманчеев. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1995; Урманчеев Ф. Борынгы миф һәм бүгенге шигырь. Татарстанның халык шагыйре Равил Фәйзуллин шигъриятенә бер караш // Ф. Урманчеев. – Казан: Мәгариф, 2002; Урманчеев Ф. Роберт Миңнуллин: шигъри осталык серләре. – Казан: Мәгариф, 2005.

3. Садекова А. Фольклор в эстетике Галимджана Ибрагимова. – Казань, 1995.

4. Надиров И. Шифалы чишмә (Татар фольклорының мәдәният тарихында тоткан урыны турында берничә сүз) // Фәнни эзләнүләр. – Казан: Фикер, 2000. – Б. 218–234.

5. Надиров И. Татар халкының йола поэзиясе, уен җырлары, бию такмаклары // Татар халык иҗаты. Йола һәм уен җырлары. – Казан: Татар.кит. нәшр., 1980.

6. Ибраһимов Г. Татар хатыны ниләр күрми // Әсәрләр: сигез томда. I т.: Хикәяләр (1907–1929). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974.

7. Мөхәммәтҗанов Р. Башкортстан Ык буе татарларының йола иҗаты (Туй поэзиясе): «Татар халык иҗаты» курсы буенча читтән торып укучы студентлар өчен уку әсбабы. – Уфа, 1977.

8. Бакиров М. Туй йолалары һәм аларга бәйләнешле поэтик әсәрләр. – Мирас. – 1998. – № 4. – Б. 81–95.

9. Галин С. Йыр. Такмак. Сеңләү // Башкорт халык ижады. Йырзар. Икенсе китап. – Өфө: Башкорт. кит. нәшр., 1977.

10. Баязитова Ф. Г. Ибраһимов әсәрләрендә этнографизмнар // Г. Ибраһимов һәм хәзерге заман: Тууына 115 ел тулуга багышланган фәнни конференция материаллары. – Казан: Фикер, 2002. – Б. 218–225.

# ДУХОВНО-НРАВСТВЕННЫЙ МИР ЖЕНЩИНЫ В РОМАНАХ ГАЛИМДЖАНА ИБРАГИМОВА «СУДЬБА ТАТАРКИ» И «ДОЧЬ СТЕПИ»

***А. М. Ибрагимова (Уфа)***

Тема социального и духовного раскрепощения женщины в художественной прозе и публицистике начала XX века – одна из важнейших тем литературы того времени. Классик татарской литературы, уроженец Башкортостана Галимджан Ибрагимов (1887–1938) является одним из тех, кто поддержал и продолжил в своем творчестве эту тему.

Перешагнув в новое столетие, мы, читатели, нуждаемся в переосмыслении и переоценке многогранного творческого наследия выдающегося писателя. Труды по истории советского народа, созданные очевидцем и участником трех русских революций Ибрагимовым, представляют большой интерес, прежде всего, богатством фактического материала. «Однако природный талант способствовал тому, что его романтические в основном произведения становились, как правило, подлинными творениями искусства»– так отозвался о творчестве писателя Ф. М. Мусин (4, 7).

Наше внимание привлекли два произведения – «Судьба татарки» и «Дочь степи».

В «Судьбе татарки», с одной стороны, достаточно объективно отображен духовно-нравственный мир дореволюционной татарской деревни, с другой стороны, он привлекает оригинальным художественным решением судьбы татарской женщины, ставшей тогда общенациональной проблемой.

В романе «Дочь степи» Ибрагимов задается целью отразить свой идеал свободолюбивой женщины, не желающей покориться судьбе и по-своему отстаивающей свою честь и человеческое достоинство.

Эти произведения – уникальные образцы национальной, политической и культурной жизни татарского и казахского народов. Рассматриваемые нами произведения, к сожалению, были недостаточно изучены. При рассмотрении имеющихся источников было установлено, что практически отсутствовала критическая литература по исследуемой теме, поэтому анализ и исследование проводились на основе своего читательского опыта, для чего использовались архивные и личные документы семьи Ибрагимовых.

Действительно роль женщины в обществе велика. На неё возложена огромная по своей значимости функция – сохранение человеческого рода.

Кто она? Каков ее духовно-нравственный мир, созданный культурой ее народа? Женщина – это и мать, и сестра, и дочь, и жена. Для женщин в исламском обществе существовали строгие правила и порядки: обязательное выполнение всех предписаний Корана; строгое соблюдение традиций Востока; полное подчинение мужу.

По нашему мнению, заголовок роману «Судьба татарки» автор дал неслучайно. Г. Ибрагимов мог назвать свое творение «Судьба Гюльбану», по имени главной героини. В названии же отражена судьба большинства татарок того времени.

Ключом к пониманию заглавия романа «Дочь степи» служит собирательный образ женщины – казашки, которая была воспитана степью, укладами кочевого образа жизни. Слово «дочь» указывает на неразрывную связь, на родственные отношения со степью. Именно это заглавие и раскрывает глубинный смысл всего произведения.

Время создания этих произведений, на наш взгляд, весьма интересно. Дело в том, что из существующих документов и установленных нами были выявлены две версии. Суть которых заключена, на наш взгляд, в следующем: оба варианта романов были написаны в одно и то же время, в дооктябрьский период – в 1909 году.

Предпосылкой для написания этих романов послужили следующие факты. Так, в предисловии к первому

изданию «Татар хатыны ниләр күрми» в сентябре 1909 года Г. Ибрагимов написал: *«Знаете, наверное, что у татар, жалующихся на свою трудную жизнь, сбежавших из-за обид и унижений, скрыв свою женскую сущность в облике мужчин, изредка встречаются среди нас и такие. Говорят, в давние времена семь девушек в облике мужчин учились в медресе. Позже с ними случились большие неприятности. Об этом сочинено много песен и рассказов. С такими горькими случаями я сам столкнулся дважды. Однажды в Стерлитамакском уезде, второй случай в Оренбурге. Оба случая произошли в двадцатом веке. После рассмотрения этих случаев появилось это повествование. 1909 г. Сентябрь»* (3, 169–170) (здесь и далее перевод наш. – *А. И.*).

Однако, как мы видим, роман «Татар хатыны ниләр күрми» был издан в 1909 году, а роман «Дочь степи» – в 1923 году.

Роман «Судьба татарки» первоначально имел название «Татар хатыны ниләр күрми» («Что только не видит татарская женщина»). Но, по нашему мнению, столь длинное название не звучало и не воспринималось основной массой читателей. Допускаем, что именно это послужило толчком к изменению названия романа, которое стало звучным, кратким и емким.

Нас заинтересовали первые варианты издания этих произведений, так как политические и общественные взгляды Г. Ибрагимова после Октябрьской революции несколько изменились под влиянием большевистской идеологии.

Однако, несмотря на это, с точки зрения культурологических понятий эти произведения вызывают огромный интерес, так как именно в этих произведениях писатель с исключительной достоверностью изображает картины жизни двух великих народов: казахского и татарского, достигших захватывающих высот в области духовной культуры.

Что же побудило столь молодого человека, которому в 1909 году было всего 22 года, задуматься о судьбах угнетенных, скованных многовековыми рабскими условиями жизни женщин?

Считаем, что этому способствовали в немалой степени следующие факторы.

Во-первых, история его семьи, в которой отец – мулла, мать – праведная послушная жена, живущая по строгим законам ислама; родственницы по женской линии, выдаваемые замуж насильно, в браке не были счастливы.

Это подтверждает высказывание Шакирзяна, старшего брата Галимджана Ибрагимова: *«Мама, вспоминая историю замужества Нагыйми* [сестра Галимджана Ибрагимова], *всегда плакала, причитая при этом: “Вышли в хлев, там поговорили и девушку выдали замуж”. Что за человек, кто такой, достоин ли он, быть мужем нашей дочери, никто не спросил. Никто со мной не посоветовался по поводу замужества дочери. Сестра Нагыйма умерла в 1916–1917 годах»* (1).

Во-вторых, он работал учителем в Казахстане. Общаясь с казахским народом, наблюдал обычаи, нравы и, конечно, жизнь женщин – казашек, судьбы которых не могли не заинтересовать молодого писателя.

В-третьих, осмелимся предположить, что рано оставшись без матери, Г. Ибрагимов не мог понять, как можно было так унижать женщину – мать, достойную почитания и уважения.

Главная героиня романа «Судьба татарки» – Гюльбану (Цветок), счастливое детство которой в родительском доме сменяется невыносимой жизнью в доме нелюбимого мужа с постоянными упреками свекрови. Все это доводит женщину до самоубийства. Поступок Гюльбану – горький протест против насилия. Трудно принять такое освобождение, но другого выхода несчастная женщина не видит. В этом сила ее характера.

Для полноты картины создания романа «Судьба татарки» представляет несомненный интерес следующая история.

Прообразом героини романа «Судьба татарки», гордой Гюльбану, явилась красивая девушка Хатима из села Балыклыкуль (что недалеко от Султанмуратово – родного села писателя), которую сосватали в деревню Дюртюли. Этот история была опубликована 12 марта 1967 году в газете «Кзыл Тан» в статье «Минияр» Габделхаком Ибрагимовым (двоюродный брат писателя): *«<…> Шул ук Авыргазы районында, Балыклыкүл исемле авылда, Хәтимә исемле матур гына бер җиткән кыз була»* («В Аургазинском районе [Республика Башкортостан] в деревне Балыклыкуль жила очень красивая девушка – Хатима») (2, 3).

В этой публикации рассказано о судьбе молодой женщины, которой в доме мужа пришлось многое пережить и испытать от новой родни. Г. Ибрагимов достаточно объективно и полно изобразил ее жизнь в романе. Духовно-нравственный мир женщины дореволюционной татарской деревни был показан в этом романе настолько правдиво, что полностью соответствовало действительному положению женщин в большинстве мусульманских семей глубинки.

Главная героиня романа «Дочь степи», Карлыгач (Ласточка), свободна и независима в своих действиях словно птица. Этот образ выделяется своей смелостью и решительностью.

Сопоставляя образы женщин, мы видим, что у главных героинь нет индивидуальных черт в портретных зарисовках. Писатель продолжает традиции фольклора, где герои так же не имеют личного портрета. Ему был важен не внешний облик героя, а его внутреннее содержание.

Считаем, что Г. Ибрагимов провозглашает этими романами свободу человеческой личности, говорит о том, что человек сам творец своей судьбы.

При исследовании архивных документов и материалов из жизни и творчества Галимджана Ибрагимова нами была установлена взаимосвязь между содержанием романов и его общественной деятельностью:

– в 1917 году писатель организует высшие женские курсы при медресе «Галия» (Уфа);

– в 1926 году спобствует возрождению журнала для женщин «Сююмбике» под названием «Азат Хатын» («Освобожденная женщина»).

В ходе сравнительно-сопоставительного анализа женских образов этих романов нами была выявлена следующая взаимосвязь сюжетов: и в том и в другом романе присутствуют одинаковые элементы композиции: сватовство, свадьба и жизнь в семье мужа. Но в то же время в сюжетах наблюдается зеркальное отображение некоторых композиционных элементов:

1. ***Карлыгач*** намерена утопиться – ***Гюльбану*** хочет бежать.

2. ***Карлыгач*** устраивает побег – ***Гюльбану*** отказывается от побега.

3. ***Карлыгач*** счастлива в браке – ***Гюльбану*** живет с нелюбимым.

4. ***Карлыгач*** с мужем покидают степь – ***Гюльбану*** топится.

Таким образом, мы видим, насколько тесно переплетены судьбы героинь и насколько различны характеры.

В процессе анализа произведения установлено, что наряду с образами женщин, смирившихся со своей тяжкой долей, есть личности, способные противостоять устоям общества. Этот образ автор вывел в романе «Дочь степи». Продолжение традиций русской литературы привело к поискам нового героя, обладающего сильной волей и твердым характером. Нельзя не отметить, что своей независимостью, открытостью и решительностью Карлыгач напоминает Катерину из драмы Н. Островского «Гроза».

В заключение хочется отметить, что место и роль Галимджана Ибрагимова в истории национальной литературы вызывает особый интерес. Его многогранное творческое наследие нуждается в дальнейшем глубоком и внимательном изучении.

ЛИТЕРАТУРА

1. Ибрагимов М. Х. Личный архив. Стенограмма беседы с родственниками Галимджана Ибрагимова – братьями Шакирзяном и Хакимом от 13 марта 1957 г. (на татар. яз.), 14 л.

2. Ибрагимов Хак. Минияр // Кзыл Тан. – 1967. – 12 марта. – № 60.

3. Йосыф Г. Кәләм. Нур. Ашкадар // Казан утлары. – 1968. – № 9.

4. Галимджан Ибрагимов и ХХ век: Материалы международной научно-практической конференции, посвященной 120-летию со дня рождения Галимджана Ибрагимова. – Казань: Мәгариф, 2007. – 239 с.

# Г. ИБРАҺИМОВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ТАБИГАТЬ КОНЦЕПЦИЯСЕ

***К. А. Габбасова (Уфа)***

Данная статья посвящена выявлению концепции природы в произведениях Г. Ибрагимова. Тема природы в творчестве Г. Ибрагимова является ведущей, пейзаж и различные природные явления, образы отчётливо фигурируют в его произведениях, им отводится должное место в характерной для писателя концепции мира и человека. Цельность художественного мира Г. Ибрагимова определяется именно концептуальностью системы образов природы.

XX йөз башы татар прозасында Г. Ибраһимовның табигать концепциясе мөһим урын ала. Г. Ибраһимов әсәрләрендәге үзенчәлекләрнең берсе үзе туып-үсеп, канат чыгарган якларының колориты киң колачлы иҗатында зур урын алып торудан гыйбарәт. Язучының пейзаж поэтикасы динамик, хәрәкәтчел сыйфатлар алды, психологизм һәм лиризм сферасына үтә нечкә килеп керде. Аның әсәрләрендә табигать картиналарының гади, ачык һәм эзлекле булуын язучының табигатьне кеше тормышында кирәкле, аннан башка гомумән тормыш юк дип каравы белән аңлатырга кирәк.

Шуның беренче матур, тулы үрнәге итеп Г. Ибраһимовның «Яз башы» (1910) хикәясен санарга мөмкин. Бу әсәр «кеше рухи дөньясына үтеп керү көченедә, аның фикер һәм хис хәрәкәтен бирү, табигать күренешләрен җанландырып сурәтләү осталыгында, әдәбиятның төп коралы булган тел белән оста эш итүендә, аның һәртөрле төсмерләрен нечкә тоя һәм файдалана белүендә күренде» (2, 339).

Табигатьне барлык нечкәлекләре белән тасвирлау Галимҗан Ибраһимовның характерлы алымнарыннан берсе. Бу осталык һәр күренешкә ия үз буявын таба һәм сәнгатьлелеккә ирешүдә тел чараларын уңышлы куллануга бәйләнгән. Табигать күренешләрен тасвирлау ярдәмендә Г. Ибраһимов кабатланмас образлар тудырды. Мәсәлән, «Яз башы» хикәясендә елга агышын назлы кыз йөреше белән чагыштыра: «Бу киң вә дулкынлы үлән диңгезенең нәкъ уртасыннан назлы кыз йөреше кеби боргаланып-боргаланып аккан елга үзенең көмештәй ялтыраган төсе белән бөтен тирә-якның күркен әллә ничә кат арттырып җибәрә» (1, 7).

Г. Ибраһимов әсәрләрендә табигать картиналарын: болыт, җил-давылларын тасвирлау һәм моңа бәйле рәвештә психологик контрастлар, параллелизмнар, каршы һәм янәшә куюлар еш чагыла. Автор еш кына онтологик күренешне (кешенең эчке халәте белән үзен мөстәкыйль калдыру, яисә табигать, яисә җәмгыять белән калу) чагылдыра. Безнең очракта геройлар табигать стихияләре (көчле җил, буран, күк күкрәү, яңгыр) белән күзгә-күз очраша.

Геройларның эчке халәтен ачар өчен автор күк күкрәүләргә, яңгырларга, җил-давылга, йолдызларга һ. б. табигать образларына мөрәҗәгать итә. Табигатьтәге халәт туп-туры кешегә күчерелә.

Иң тәүдә язучы табигать хозурлыгыннан үзе ләззәт кичерә һәм шушы сихри гүзәллекне укучыга оста җиткерә белә. Укучы һәрбер юлдан тәм табып әсәрнең эченә, «моңнар иленә», «әкият дөньясына» тирәнрәк керүен сизми дә кала: «... Без шулар, шул матурлыклар уртасыннан, шул моңнар эченнән, табигатьнең өстеннән ярып барабыз... Әнә безнең алдыбызда – барачак юлыбызда, киң яшел ялан белән биек һәм урманлы тау уртасында зур, түгәрәк сихерле күл ялтырый... Ничаклы матурлык!» (1, 8).

Табигатьне автор кеше белән бәйләнештә ике төрле сурәтли. Йә табигать тасвирлары булачак вакыйгаларга фон рәвешендә бирелә дә, геройларның киләчәктәге язмышлары хакында хәбәр җиткерә. Кешеләр нәфесен табигать күренешләре тулы ачып бирә. Йә табигать хозурлыгын сурәтләп, алдагы вакыйгаларга, кеше халәтенә ишарә ясамыйча, коллизик моментларны кинәт бирә. Бу очракта табигать сурәтләвенә аерым игътибар туа һәм ул импрессионистик күренешләрне хәтерләтә башлый. Автор үз геройларын үзе сурәтләгән табигать белән гармониядә булуларын әйтеп, аңлатып бара.

Табигатьне мондый төрле-төрле итеп тасвирлавы тормышның чын табигый матурлыгын күрсәтергә теләве белән аңлатыла.

Г. Ибраһимовның пейзаж сурәтләнгән һәрбер әсәрендә диярлек романтиклык үзен сиздерә. Антропоморфизация күренеше дә ачык чагыла. Табигать күренешләрен бирү реаль тормыш картиналарына өстәмә итеп түгел, ә психологик параллель ясау, шуларга аңлатма төсендә символ итеп бирелә.

«Казакъ кызы», «Диңгездә», «Табигать балалары», «Яшь йөрәкләр» һ. б. әсәрләрдә табигать тасвиры геройларның язмышына һәм әсәрдә сурәтләнгән вакыйгаларга әхлакый-фәлсәфи шәрехләү рәвешендә килгән.

Әдип табигатьнең кеше гомерендәге бик әһәмиятле роль уйнавын яхшы аңлый, шуның өчен үз әсәрләрендә аңа зур урын бирә.

Гомумән алганда, Г. Ибраһимовның табигать матурлыгын бирү осталыгы, ихлас соклана белүе, табигать образларының күп төрлелеген һәм күп яклыгын сурәтләве, геройларның характеры белән әсәрдәге вакыйгаларны бер-берсе белән үткер бәйли белү һәм, шул рәвештә, психологик контрастлар, янәшә куюлар, гомумән кеше мөнәсәбәтен гәүдәләндерүгә табигать аша килүе – гаять кызыклы поэтик функция үти.

Галимҗан Ибраһимов – татар әдәбиятында үз табигать концепциясен булдыра – кеше белән табигать арасында чикне куймый диярлек. Язучының дөнья картинасы гүзәллекне күрә һәм аңлый белү белән бәйле. Г. Ибраһимов рухи дөньясындагы үзгәрешләрне, чор вакыйгаларын, гомум проблемаларны табигать концепциясе аша ача.


ӘДӘБИЯТ

Ибраһимов Г. Г. Хикәяләр, повесть, роман / Галимҗан Ибраһимов; төз. Р. Акъегет. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 463 б.

Хәсәнов М. Галимҗан Ибраһимов // Татар әдәбияты тарихы. – Казан: Татар. кит. нәшр.,1986. – Т. 3. – Б. 338–357.


# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ МӘКАЛЬЛӘР БИРЕЛЕШЕ


***Д. Х. Җәләева (Казан)***



Данная статья посвящается изучению пословиц татарского языка (на материале произведений Г. Ибрагимова).


Кеше балачактан ук телне һәм аның белән үз халкының мәдәниятен үзләштерә, шәхес буларак формалаша. Мәдәният тармакларының барлык нечкәлекләре халык телендә чагылыш таба һәм ул һәр милләттә үзенчәлекле, бердәнбер була, чөнки дөньяны һәм андагы кешене аларның һәркайсы үзенчә тасвирлый. Аерым бер төбәккә генә хас тел – аралашу чарасы булудан бигрәк, халыкның тарихы, хәтере, дөньяга карашы, психологиясе, туган якның гореф-гадәтләрен саклау һәм үстерү максатыннан тупланган, буыннан-буынга күчеп килгән белемнәр ул. Татар теленең тарихы да бик тирәнгә барып тоташа. Хәзерге матур әдәбият теле формалашу өчен галимнәр, язучылар зур тырышлык куйганнар. Шуларның берсе – Галимҗан Ибраһимов. Ул үз чорының күренекле әдибе, тарихчы, педагог, тел галиме дә. Аның матур әдәбият әсәрләре, лингвистика һәм публицистикага караган хезмәтләре гаять әһәмиятле. Гомумән, Г. Ибраһимов – татар теле һәм тел гыйлеме үсешенә зур өлеш керткән галим.

Язучының беренче әсәрләрендә үк халык теленә якынлык, гадилек хас. Әйтергә кирәк, Г. Ибраһимов әдәби сурәтләү чаралары сыйфатында искергән сүзләрне, алынмаларны еш файдалана. Аның әсәрләрендә гомумтөрки традицион язма сүз һәм сүз формаларын күрергә мөмкин. Мәсәлән, *йыглау, угыл, газап чикмәктә, дөрест* һ. б. Әсәрләрен карасак, язучы сүзләрнең бу формаларын эзлекле рәвештә файдалана. Шул ук вакытта язучы фольклор жанрына да еш мөрәҗәгать итә.

Һәр милли тел кебек үк, татар теле дә, аның сүзлек хәзинәсе дә чорлар, гасырлар аша буыннардан-буыннарга халык авыз иҗаты әсәрләре, язма әдәбият аша тапшырыла килгән (1,214). Фольклор жанрлары арасында сан ягыннан да, сәнгатьчә эшләнеше ягыннан да аерым урын алып торган мәкальләрнең тел-стиль үзенчәлекләрен өйрәнү халкыбызның дөньяга карашлары, телебезнең стилистикасы хакындагы мәгълүматларны гомумиләштерүгә ярдәм итә. Әлеге тел-сурәтләү чаралары язучыга үз фикерен үтемлерәк итеп җиткерергә, билгеле бер күренешләргә үз мөнәсәбәтен белдерергә, күп гасырлар туплаган тәҗрибәсен укучысына тапшырырга юл ача. Паремияләр фольклор чагылышы буларак, лингвокультурологик тикшеренүләр өчен зур әһәмияткә ия, чөнки фольклор мәдәният яшәешенең мөһим формасын тәшкил итә. Әлеге форма рухи тормышның төрле якларын, йолаларны, хезмәт эшчәнлегенең традицион төрләрен бергә туплый. Милли мәдәният төсмере яки үзенчәлеге буларак, мәкальләр төрле мәгънәви-семантик катламнарда: мифология һәм дини компонентларда, тарихи-социаль күренешләрдә, гореф-гадәтләргә, йолаларга бәйләнешле фактларда чагыла. Шушы катлаулы бай эчтәлек, мәкальдә җыйнак формага салып бирелә. Нәкъ менә паремиологик берәмлекләрдә халыкның җәүһәрләре саклана, шуннан милләт башлана (2, 214).

Ләкин, шулай да, без бүгенге көндә телебездә яшәп килә торган меңнәрчә мәкальләрне, нәкъ үзләренең борынгы формаларында калганнар, дип әйтә алмыйбыз. Әлбәттә, сүз, беренче чиратта, аларның теле турында бара. Тел сурәтләү чараларының, мәкаль-әйтемнәр, йолалар һ. б. ның урынлы кулланылуы хисабына байый. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, Г. Ибраһимов әсәрләрендә төрки халыкларга хас йолаларны сурәтләүгә өстенлек бирелә. Шулай ук аның әсәрләрендә татар халкының көнкүрешенә, тарихына, әхлак кагыйдәләренә бәйле мәкальләр дә очрый. «Кызыл чәчәкләр» әсәрендә мәкаль-әйтемнәр халыкның ачы язмышын, фаҗигасен чагылдыруда мөһим роль уйныйлар:

«Фазыйлларның бер асравы күп савыт-саба күтәреп бара икән – аягы тайган да, егылып, бөтен нәрсәсен ваткан. Остазбикә:

– Мин кереп килә идем ... менә бу уйнаштан туган малаегыз әллә кайдан йөгереп каршыма чыкты да миңа бәрелде... Мин шуннан егылдым... – дигән.

– Заһит хәзрәтнең остазбикәсе Шаһбазны чакырып ала да:

*– Ятим бозау асрасаң, авызың-борының май итәр, ятим бала асрасаң, авызың-борының кан итәр*, дигән борынгылар... Синнән хәер булмас, күземә күренмә, бар, бүгеннән чыгып кит! – дип, аяк тибеп тиргәп куа».

Әлеге өзектә бирелгән мәкаль кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне, ятим баланың аяныч язмышын ачып бирә. Мәкаль бүгенге көндә дә актив кулланылышта йөри. Г. Ибраһимов әсәрләренең үзәгендә тормышта булган гыйбрәтле хәлләрне сурәтли. Мәкальәйтемнәрнең дә татар халкы язмышына якыннары сайланып бирелә. Тагын бер мисалга игътибар итик:

«Гәрәйнең кулына кечкенә, нәзек, аз итле бер сөяк туры килгән иде.

– Карагыз, бармак бит бу?! – дип каты кычкырып җибәрде.

Яңа кергән Намаҗан карт килеп карады да көлде:

*– Курыкканга куш күренә, диләр...* Нинди бармак булсын, эт кабыргасы бит. Әллә күзең чыкканмы? – дип шелтә ташлады».

«Адәмнәр» әсәреннән алынган әлеге өзектә кешеләрнең ерткычлыгы сурәтләнә. Намаҗан карт авызыннан әйтелгән әлеге мәкаль куркуның дәрәҗәсен ачуда ярдәм итә, образлылыкны арттыра. Ачлыкның кеше психологиясенә нинди йогынты ясавын түбәндәге мисалдан да аңлап була: *«Курыкканга куш ишетелер», «Курыкканга – куш, барып караса – буш»* һ. б. (3, 229). Бу мәкальләрнең формалары төрле булса да, алар бер үк мәгънәне белдерәләр.

Мәкальләрнең эчтәлегендә тормышның барлык яклары (катлаулы тарихи-иҗтимагый мөнәсәбәтләрдән алып гади көнкүреш детальләренә кадәр) бик тулы бирелә, кешеләрнең үзара аралашып, ярдәмләшеп яшәүләре мактала, бердәмлекнең көче һәм өстенлеге күрсәтелә.

Мәкальләрнең төрлелеге әсәрнең тематикасына бәйле рәвештә үзгәрә. «Казакъ кызы» романында ил, гаилә темасына караганнары шактый. Мәсәлән, *«Илчегә үлем юк», «Кеше илендә солтан булганчы, үз илеңдә олтан бул»*. Әсәрдә үз иле, ыруг-кабиләсе өчен чын яклаучы булырдай ирләр сурәтләнә. Шулай ук, язучы гаилә тормышын чагылдырган мәкальләргә туктала. Борынгылардан килгән, әлеге мәкальләр әсәрнең телен баета. Чит гаиләгә килеп кергән яшь кызның язмышын сурәтләргә ярдәм итә. Шушы бер әсәрдә генә дә автор бу темага караган, берничә мәкальне файдалана. Мәсәлән: *«Килен көне – эт көне», «Ирдән китсәң дә илдән китмә», «Иткәнем – коллык, күргәнем – хурлык», «Кыз чагың – алтын чагың»* һ. б. Гомумән, башка гаиләгә килеп, андагы яшәү рәвешенә кереп китү беркем өчен дә җиңел түгел. Ә кыз баланың язмышы, фәкать шуннан гыйбарәт. Шуңа да мәкальләрдә, күпмедер дәрәҗәдә, яңа яшәү рәвешеннән куркыту сизелә, ул, хәтта, эт тормышы белән чагыштырыла.

Гомумән, Г. Ибраһимов – халыкның рухи һәм матди мәдәниятен тирәнтен белүче шәхес. Шуңа да аның әсәрләре бүгенге көндә дә популяр. Язучы үзенең әсәрләрендә фольклор алымнарын, халык йолаларын, төрле сурәтләү чараларын, мәкальләрне күпләп һәм яратып файдалана. Лингвокультурологик тикшеренүләр өчен телнең паремиологик фонды халык менталитетын һәм аның үзенчәлекләрен тикшергәндә иң бай чыганакларның берсе булып тора. Г.Ибраһимовның әсәрләрен бу яктан өйрәнү татар тел байлыгының күп кенә әһәмиятле якларын күрсәтергә мөмкинлек бирә.

ӘДӘБИЯТ

1. Галимҗан Ибраһимов һәм хәзерге заман: Тууына 115 ел тулуга багышланган фәнни конференция материаллары. – Казан: Фикер, 2002. – 272 б.

2. Җамалетдинов Р. Р. Тел һәм мәдәният: Татар лингвокультурологиясе нигезләре / Р. Р. Җамалетдинов. – Казан: Мәгариф, 2006. – 351б.

3. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре: мәкальләр җыелмасы: III т. / Н. Исәнбәт. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – 799 б.

# ҒӘЛИМЙӘН ИБРАҺИМОВ ХИКӘЙӘЛӘРЕНДӘ КОМПОЗИЦИЯ-ТЕЛМӘР ФОРМАЛАРЫ

***Л. Р. Кирәева (Стәрлетамак, Башкортостан)***

В статье изучаются ранние рассказы писателя с точки зрения повествования. Во многих произведениях Галимджана Ибрагимова речь повествователя оказывается способна вбирать в себя голос героя, причем он может совмещаться с авторской позицией, с авторским голосом. Такие композиционно-речевые формы в дальнейшем перенимались и развивались в башкирской прозе (М. Гафури, Д. Юлтый, С. Агиш).

Теоретик поэтиканың һәм тарихи поэтиканың иң бәхәсле мәсьәләләренең береһе – автор хаҡындағы тикшеренеүҙәр. Ысынлап та, был проблема бик күп ҡаршылыҡлы фекерҙәр уята, теге йәки был мәсьәлә менән бәйле ҡарағанда ла ҙур ауырлыҡтар тыуҙыра.

Һүҙ сәнғәтендә «авторлыҡ рухы» һәр ваҡытта ла: индивидуаль ижадта ла, коллектив ижадта ла, авторы билдәле булмағанда ла, йәшерелгәндә лә (анонимлыҡ, псевдоним, мистификация) йәшәй. Ләкин шуны әйтергә кәрәк: мәҙәни үсештең төрлө стадияларында, әҙәбиәттең төрлө баҫҡыстарында уның сағылышы үҙгәрә бара.

Ошо тәбиғи процесс XIX быуат – XX быуат башы әҙәбиәтендә бик үҙенсәлекле: бер яҡтан көнсығыш әҙәбиәтенән килгән традиционализм һыҙаттары ла көслө, икенсенән европа традициялары өҫтөнлөк ала, шулар менән бергә үҙ аллы ижади манераның алғы планға сыға барыуы ла билдәләнә.

Ғәлимйән Ибраһимов ижады, айырыуса уның тәүге хикәйәләре, беҙҙә бигерәк тә һүҙ сәнғәтендә автор интонацияларының, автор позицияһының көсәйә барыуы, реалистик фекерләүҙең, мотивтар һәм сюжеттарҙың үсеше һәм үҙгәреше, ябай китап уҡыусыны художестволы донъя менән бәйләүсе функцияларға

эйә хикәйәләүсе образы киүек мәсьәләләр менән бәйле ҡыҙыҡһындыра.

Әйтәйек, «Һөйөү – сәғәҙәт» (1911) әҫәрендә автор башланғысы төрлөсә сағылыш таба: реаль картиналарға һәм ваҡиғаларға үҙ ҡарашыңды белдереү, сюжет ағышындағы комментарийҙар, геройҙарға характеристика биреү, тәбиғәтте һәм әйберҙәр донъяһын ҡабул итеү һ. б. Йәғни был осраҡта ниндәйҙер традицион ҡанундар, традицион мотивтар күҙ уңында тотолмай, ә авторҙың ирекле ижади манераһы алғы планға сыға. Мәҫәлән: «…Мин ғүмеремдә шул ҡояшҡа оҡшатам. Бына, тим, нисек: иртән төндөң ҡараңғылығын ярып ҡояш сыға. Ер һәм унда булған һәр нимә үҙенең ғүмерен унан ала. Ерҙәге бөтә үҙгәрештәр – һәрбер тәбиғи эштәр тик уның тәәҫиренә генә буйһона. Ул башта түбән, йыраҡ һәм аҙ ҡеүәтле булып, йылыһы, тәәҫире лә уртараҡ. Ләкин ул хәлдә ҡалмай: ул аҡрын, әммә туҡтауһыҙ рәүештә йыраҡ вә юғары күккә ҡарап юл тота – сикһеҙ бушлыҡтың иң бейек нөктәһенә ғорур бара башлай […] Ләкин был хәл мәңгелек түгел. Ул оло ҡояш, ирекһеҙ һәм теләмәйенсә генә түбәнгә табан йөҙ тота […] Минең ғүмерем дә, тим, шулай. Мин үҙем дә, тим, шулай булдым…».

Шуныһы мөһим: һөйләүсе (Ризабәк) бында үҙе герой булып килә, үҙе һүрәтләгән ваҡиғалар донъяһына ҡарай, шул ваҡиғаларҙың шаһиты булараҡ һүҙ алып бара. Әҫәр аҙағында хикәйәләүсе «автор» образына яҡынлаша: «…ләкин ғажизмын, һүҙ таба алмайым, әҙәм теле уның хиссиәтенән бик күп тар һәм ярлы. Башҡа тәғъбир булмаһас, хисем ташып, телемә ирекһеҙ шул килә: Һөйөүҙә генә ысын сәғәҙәт!»

Ошондай үҙенсәлектәрен күҙ уңында тотоп, «Һөйөү – сәғәҙәт» әҫәренә ҡарата «автор ваҡыты», «автор арауығы» төшөнсәһен ҡурҡмайынса ҡулланырға була. Сөнки әҫәрҙә художестволы ваҡыт реаль ваҡытты субъектив ҡабул итеүҙең төрлөлөгөнән туҡыла. Төп герой үткәнгә әйләнеп ҡайта, бөгөнгөһөн, хәҙерге хәлен анализлай, киләсәккә күҙ ташлай.

Ғәлимйән Ибраһимовтың «Көтөүселәр» (1913) хикәйәһендә лә хикәйәләү автор аңының берҙән-бер сағылышы түгел. Хикәйәләүсенең телмәре бөтөнләй икенсе бер геройҙың тауышы, ҡарашы аша бирелергә мөмкин: «Әҙәм башы ниҙәр генә күрмәй, ниҙәргә күнекмәй! Аҡрын-аҡрын мин дә көтөүсе малай булып киләм…».

Был – автор планы, автор ҡарашы (точка зрения) менән бәйле хикәйәләү формаһы. Күреүебеҙсә, формаль яҡтан текст фрагменты хикәйәләүсегә ҡарай. Ләкин был осраҡта персонаж (Вахит) аңы менән бәйле хикәйәләү өҫтөнлөк ала. Ике аң субъекты берләшкән (автор һәм герой, йәки персонаж) бындай телмәр формалары әҫәрҙә йыш осрай: «Һөйләгеҙ! Беҙ, тормоштоң төбөндәгеләр, һеҙҙән яуап һорайбыҙ! Нисә мең йыллыҡ тәжрибә иҫке юлдарҙың хатаһын асманымы; беҙ яуап көтәбеҙ! Миллиондарса ас балалар, аслыҡтан балаһын имеҙергә һөтө булмаған миллиондарса әсәләр, ғүмере буйына эшләп тә, аҙаҡтан урамға ташланған ҡарттар, аһ-зарҙары, ҡайғылары менән ер йөҙөн ҡаплаған бөтә мазлумдар, – беҙ һеҙҙән яуап көтәбеҙ…».

Әҫәрҙәрҙә ҡулланылған ошондай композиция-телмәр формалары бер-береһенән йәше, социаль хәле, дини, сәйәси ҡараштары менән айырылып торған персонаждар галереяһын реалистик планда асыуға хеҙмәт итә.

Ғәлимйән Ибраһимов ижады башҡорт прозаһының эпик фекерләүенә лә йоғонто яһаны: автор тарафынан ҡулланылған композиция-телмәр формаларының төрлөлөгө, идея-эстетик ҡараштар, хикәйәләү үҙенсәлектәре артабан Мәжит Ғафури, Сәғит Агиш, Дауыт Юлтый кеүек яҙыусыларҙың прозаһында үҫтерелде һәм байытылды.

## Г. ИБРАҺИМОВ ХИКӘЯЛӘРЕНЕҢ ТЕКСТ БУЛАРАК ОЕШУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ («Диңгездә» хикәясе мисалында)

***З. Ф. Әхәтова (Яр Чаллы)***

Произведения, в том числе рассказы, талантливого писателя Г. Ибрагимова оригинальны в плане их текстовой организации. Особое внимание писатель уделяет вычленению в них глав, абзацев. Даже небольшие рассказы состоят из множества глав, а целые страницы могут состоять из абзацев, оформленных из одного предложения,между которыми наблюдается параллельная связь. В рассказе «На море» в создании когезии и интеграции текста важную роль играют параллельные описания и синтаксические повторы. Своеобразие стиля писателя находит отражение в логичности, четкости и прозрачности внутритекстовых связей.

Белгәнебезчә, татар әдәбиятында проза жанрының югары сәнгать дәрәҗәсенә күтәрелүендә атаклы язучы һәм галим Г. Ибраһимовның роле гаять зур. Ул – прозага күп яңалык, үзгәреш керткән язучы.

Г. Ибраһимов әсәрләренең әдәби эшләнеше, сүз-сурәт тукымасы, лексик-стилистик бизәкләре генә түгел, текст буларак оешуы да бик үзенчәлекле.

Текст төзелешендә язучы күләмгә бәйле кисәкләрне аерып чыгаруга зур игътибар бирә. Җыйнак кына хикәяләр дә, гадәттә, берничә бүлектән тора. Мәсәлән, «Яз башы» – 4, «Уты сүнгән җәһәннәм» – 6, «Карак мулла» – 7, «Диңгездә», «Сөю – сәгадәт», «Карт ялчы», «Йөз ел элек», «Габдрахман Салихов» хикәяләре – 8 бүлектән, «Көтүчеләр» – 13 бүлектән тора.

Аның әсәрләрендә бүлекләр әсәргә килеп кергән персонажның үзен яки үткән һәм хәзерге тормышын сурәтләүгә багышланалар, яисә аерым тормыш күренешләрен тасвирлыйлар. Мәсәлән, «Диңгездә» хикәясендә беренче бүлектә хикәяләү диңгез буенда кояш баю күренешен сурәтләү белән башлана, алга таба көймәнең кузгалып китүе хәбәр ителә.

Икенче бүлектә диңгез буе табигатенең илаһи матурлыгы Г. Ибраһимовка гына хас булган буяулар белән тасвирлана.

Өченче бүлектә исә хикәяләүченең диңгездәге күңел халәте, рәхәт кичерешләре сурәтләнә.

Дүртенче бүлектә диңгезгә керүнең икенче көне бәян ителә, хикәяләүченең кичерешләренә үзгәреш керә: ул инде бераз ялыккан, алдагы көннең матурлыгы да беткән. Биредә вакыйгалар үстерелә: хикәяләүче татар карты белән танышып китә. Алдагы – алтынчы бүлек исә тулаем бу картның үткән тормышын сурәтләүгә багышлана, ягъни хикәяләү ретроспектив планга күчә.

Алтынчы бүлектә вакыйгалар кабат бүгенге көнгә әйләнеп кайта һәм юлчылар диңгездә йөзүләрен дәвам итәләр. Ләкин аларны диңгездә давыл кубу шомландыра.

Җиденче бүлектә үзенчәлекле композицион алым белән очрашабыз: карт авызыннан диңгез белән бәйле бер шомлы вакыйга бәян ителә.

Соңгы бүлектә хикәяләүче сәяхәтенең диңгездәге соңгы көне тасвирлана. Хикәянең бетем өлеше аның логик төгәлләнүен белдерә.

Язучы хикәяләренең абзац төзелеше дә үзенчәлекле. Еш кына бүлекнең соңгы җөмләсе лексик-семантик һәм грамматик яктан алдагы абзацның беренче җөмләсе белән тыгыз бәйләнештә була. Абзацның соңгы җөмләсе алдагы абзацның беренче җөмләсе өчен нигез булып тора. Мәсәлән, «Диңгездә» хикәясендә дүртенче бүлек белән бишенче, алтынчы, җиденче һәм сигезенче бүлекләр синтаксик яктан, ягъни бербөтен текст буларак, аеруча тыгыз бәйләнгән.

Г. Ибраһимов абзацларны күп очракларда гомумиләштерүче җөмләләр ярдәмендә оештыра. Мондый җөмләләр йә абзац алдыннан, яисә аны тәмамлап киләләр. Язучы аларда еш кына *шулай, шундый, мондый* кебек алмашлыкларны куллана. Мәсәлән: «Төнне шулай үткәрдек».

Абзацның ким җөмләләр чылбырыннан оешуы да характерлы. Башта герой атала, аннан соң ким җөмләләр белән кыска-кыска гына аның тормышы, халәте сурәтләнә. «Диңгездә» хикәясендә Нурый картның тормышы шул рәвешле тасвирланган. Текстны болай төзү бертонлылыктан коткара, аны кабул итүне җиңеләйтә кебек.

Г. Ибраһимов хикәяләрендә җөмләләрнең структур мөнәсәбәттәшлеге, еш кына, аларның бертөсле төзелеше аша да белдерелә. Җөмләләр арасында параллель бәйләнеш булганда, алар йә янәшә куеп чагыштырылалар, яисә каршы куелалар. Синтаксик параллелизм күренеше җөмләләр арасындагы структур һәм мәгънәви бәйләнешне барлыкка китерә. Һәрбер җөмләне җөмлә итүче шарт бар. Бу – предикатив үзәк. Һәрбер параллель килгән җөмләләрдә предикатив үзәк хәлиткеч роль үти. Шул предикатив үзәкләрнең параллелизмы структур һәм семантик бердәмлек барлыкка китерә.

Мондый бәйләнеш ягыннан язучының «Диңгездә» хикәясе аеруча үзенчәлекле. Биредә абзацлар сан ягыннан бик күп һәм гадәттәгедән күпкә кыскарак. Җиденче бүлекнең ахырында ундүрт җөмлә рәттән абзацланып килә. Алар шактый кыска булып, параллель яки бер-бер артлы булган күренешләрне белдерәләр:

«Үлем үзенең корбанын ала.
Кораб урыныннан кузгала.
Без һаман барабыз.
Көн кичегә, һава бозыла, бераз җил дә кузгала».

Текстның болай бирелеше укучының игътибарын төп вакыйгаларга юнәлтә, хикәяләүне җанландырып җибәрә.

Бәйләнешләр никадәр күп булса да, сөйләмдә аларның иң гомуми, иң типик төрләрен күрергә мөмкин. «Диңгездә» хикәясендә чылбырлы бәйләнеш исә күбрәк җөмләләрнең, текст кисәкләренең мәгънә ягыннан бәйләнеше яисә лексик чаралар исәбенә формалаша. Чылбырлы бәйләнешне грамматик яктан формалаштыруда *ләкин* теркәгеченең актив булуы күзгә ташлана.

Хикәядә аерым абзацлар бер сүзле генә җөмләләрдән дә оеша, аларда баш кисәк – хәбәр еш кына фигыль белән белдерелә:

«Карыйлар <...> . Тордым <...> . Киттек.»

Шул рәвешле, текст кисәкләре ачык күренеп тора, алар эзлекле тезеләләр, ретроспектив сурәтләү белән чиратлашып баралар.

Хикәянең бербөтен текст булып формалашуында кабатлау алымына өстенлек бирелгән. Биредә «Без һаман барабыз» җөмләсе күп кабатлана, хикәянең лейтмотивы булып килә һәм укучыга да хәрәкәтне, вакыйгалар урынын ачыграк тоемларга ярдәм итә, текст интеграциясен формалаштыруда катнаша.

«Диңгездә» хикәясендәге параллель синтаксик бөтеннәр арасында хикәяләүче, тасвирлама, фикер йөртүле, номинатив (атау җөмләле) һ. б. төрле синтаксик бөтеннәр бар. Тасвирлама бөтеннәр аеруча игътибарны җәлеп итә, аларны өстән-өстән генә укып үтү мөмкин түгел. Алар диңгез табигатен бөтен нечкәлеге белән, илаһи матурлык итеп сурәтли. Сурәтләүгә семантик параллелизм да кушылып китә: диңгез күренешләрен кешеләрнең, бигрәк тә хикәяләүченең күңел кичерешләре белән бәйләп, хикәяләүче фикерләве аша һәм җанландырып бирүгә язучы аеруча игътибар итә һәм моны бик табигый итеп, зур осталык белән башкара. Бу янәшәлек хикәянең башыннан ахырына кадәр күзәтелеп, хикәяләүнең төп алымына әверелә, аңа символик мәгънә сала.

Фикер йөртүле бөтеннәр биредә күбесенчә риторик сорау җөмләләрдән формалаша: «Ләкин ул кайда? Кая андый яшәү? Шул күктә, шул йолдызлар, айлар арасында мин уйлаган яшәү бармы? Әллә ул да ерактан гына шулай матур, изге күренәме? Эченә керсәң, анда да шул каты кайгы, авыр күз яше, ямьсез, мәгънәсез яшәү булачакмы?» Биредә хикәяләүгә уртак сөйләм килеп керүен дә күзәтәбез.

Күренгәнчә, текстның ачык, үтә күренмәле диярлек төзелеше язучы иҗатының бер үзенчәлеге булып тора.

Г. Ибраһимов иҗатының укучы күңеленә көчле йогынты ясавының серләре ачык: алар әдәби камиллектә, әсәрләренең сәнгатьчә югары дәрәҗәдә эшләнешендә, шул исәптән, аның текст оештыру осталыгында, кабатланмас стилендә дип уйлыйбыз.

ӘДӘБИЯТ

1. Галимҗан Ибраһимов. Хикәяләр, повесть, роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 464 б.

2. Бабенко Л. Г. Филологический анализ текста. Основы теории, принципы и аспекты анализа. – М., 2004. – 150 с.

# Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ РОМАНТИК ХИКӘЯЛӘРЕНДӘ ТАБИГАТЬ ҺӘМ КЕШЕ МӨНӘСӘБӘТЕ

***Ф. И. Габидуллина, Р. Ә. Минһаҗева (Алабуга)***

В татарском литературоведении существует мнение, что дооктябрьское творчество Г. Ибрагимова протекает в русле романтизма. Романтический подход к проблеме отношения человека и природы ярко проявляется в рассказах «Начало весны», «В море», «Любовь – счастье». В этих рассказах писателя большое место занимает пейзаж, описание картин природы.

Пейзаж в творчестве Г.Ибрагимова не обычное средство изображения, он помогает раскрытию внутренних чувств и переживаний персонажа. Пейзаж очень тесно связан и с идейным содержанием рассказов.

Кешеләрнең тормыш-көнкүреше күбрәк табигатькә, аның кануннарына бәйләнгән. Табигать кешеләрнең кәефе белән идарә итә. Табигать белән кешене аерып карап булмый, чөнки алар бербөтен. Кеше табигатькә сыенса, аңа «яшәргә» ярдәм итсә, табигать тә кешегә булыша. Табигать, яшәү һәм матурлык чыганагы буларак, кеше өчен мәңгелек. Г. Ибраһимов әсәрләрендә дә табигать һәм кеше аерылгысыз. XX йөз башы татар әдәбиятында тирән мәгънәле, «эчтәлекле» пейзажны әдәби әсәрләренә беренчеләрдән булып кертеп җибәрүчеләрнең алгы сафында, әлбәттә, Г. Ибраһимов торган. Бу юлларның хаклыгын дәлилләп, күренекле әдибебез Ә. Еникинең язучыга багышлап язылган «Школа для всех и каждого» исемле мәкаләсеннән түбәндәге юлларны китерү урынлы булыр: «Он очень умело использовал в своих произведениях мир живой природы как для выражения душевного состояния героя, так и для образного воплощения авторской мысли. И если в наших произведениях такого рода приемы стали обычным явлением, то этим мы в большой степени обязаны новаторскому творчеству Галимджана Ибрагимова» (2, 5).

Г. Ибраһимовның башлангыч чор иҗатында романтизм концепциясен һәрьяклап чагылдырган «Яз башы», «Диңгездә», «Сөю – сәгадәт» хикәяләрендә табигать һәм кеше мөнәсәбәте мәсьәләләре дә игътибардан читтә калмый, билгеле. Г. Ибраһимовның «Яз башы» (1910) хикәясе – әдипнең Казан чоры иҗатын ачып җибәрүче тәүге әсәре. Язучы бу әсәрендә кешенең рухи дөньясын ачып бирүче оста психолог, фольклор белгече һәм табигать матурлыгына мәдхия җырлаучы пейзаж остасы буларак ачыла. Әдәбият галиме М. Хәсәнов искәртүенчә, моңарчы, күпчелек татар язучыларында табигать күренеше вакыйгалар сурәтләнешендә фон төсен генә үтәп килсә, Г. Ибраһимовның «Яз башы» хикәясендә пейзажны геройларның рухи халәтенә мөнәсәбәттә сурәтләвен үзенә күрә бер новаторлык дип санарга мөмкин (5, 28).

Мәгълүм булганча, XX йөз башы татар әдәбиятында кешенең рухи дөньясын, күңелендәге эчке каршылыклар көрәшен ачып бирүдә иң отышлы юнәлеш романтизм булган. Шәрекънең күренекле әдипләре Фирдәүси, Сәгъди, Хафиз, Фөзүли һ. б. ның иҗатлары белән яхшы таныш, Аурупа һәм рус әдәбияты белән үзенең карашларын даими киңәйтеп торган Г. Ибраһимов иҗатында Шәрекъ, Аурупа, шул исәптән рус романтизмының йогынтысы бик көчле була. Мәсәлән, Г. Ибраһимовның башлангыч чор иҗатына караган «Диңгездә» хикәясендә без XVIII йөз әдибе Ж.-Ж. Руссодан башлангыч алган романтик традицияләр белән очрашабыз.

Тормыш гармониясен табигатьтән эзләү – хикәя герое шәһәрдән ерагайган саен, табигать белән соклanудан туган халәтен Ж.-Ж. Руссо каһарманы Сен-Пре кебек аңлата: «Диңгезгә кереп югалу белән, үзеңдә акрын, ләкин тирән бер рәхәтлек сизенә башлыйсың. Тән басыла, рух җиңеләя, күңел киңәя, йөрәкне әрнеткән авыр кайгылар үзеннән-үзе эриләр, таралып, каядыр югалалар». Әйе, романтик каһарманыбыз нәкъ менә табигатьтә генә үзенең уй-хыяллар дөньясына чума, яшәешнең табигый хасиятен ача, сыкранган җанына ямь-дәва таба.

Г. Ибраһимов диңгез пейзажын тасвирлау ягыннан татар әдәбиятында беренче маринист әдипләрдән саналырга хаклы. Ул табигать сурәтләрен тәэсирле шигърият көче белән, музыкага тартым итеп кенә биреп калмый, ә үзенә бер символ рәвешенә китерә. Мәсәлән, романтиклар яратып тасвирлый торган символик образ – диңгез – төрле төсләргә һәм халәтләргә керә. Ул аның тыныч ягын да, җил-давыллы, яшенле, ярсыган чагын да күрсәтә. Диңгез – романтик әдәбиятта мәңгелек хәрәкәт, гомер агышы, үзгәреш символы. Кеше белән чагыштырганда, диңгез ирекле, ул җирнең әсире түгел. Диңгез кеше җанының идеалга булган мәңгелек омтылышын тасвирлый.

Г. Ибраһимов үзенең бу әсәрендә диңгез образының бар киңлеген һәм бөеклеген күрсәтә алган: *күгелҗем шома диңгез; бөек диңгез; куркынулы диңгез; көмеш төсле; нурлы айлар белән зиннәтләнгән олы көзге кебек диңгез; иге-чиге булмаган диңгез; тын, авыр, куе диңгез.* Романтик идеаль дөнья үзенең ассоциатив чагылышын күк, йолдызлар, ай кебек Шәрекъ романтизмыннан килгән символик образларда таба. Аларны сурәтләгәндә Г. Ибраһимов «якты, җылы» буяулар палитрасын кызганмый. Мәсәлән: Күк йөзе – *ачык; нурлы, киң; сөеп, иркәләп елмая торган.* Йолдызлар – *нурлы; миллионнарча; алар арталар, күбәяләр, шул хәлгә җитәләр ки, бөтен күк йөзе якты алмаз белән зиннәтләнә.* Ай – *нурлы; ул башта кызгылт-сары. Соңрак аксыл-сарыга, ахырдан көмеш кебек ак нурга әйләнә; бөтен дөньяга, җәфа чиккән һәммә җаннарга сөеп, иркәләп караучы.*

Г. Ибраһимов романтик-руссочыл рухта табигать күренешләренә бозык шәһәр тормышын, җәфа чиккән меңнәрчә адәмнәре белән реаль җир тормышын каршы куя. Мәсәлән, шәһәр пейзажын тасвирлаганда, язучыбыз тулы бер «караңгы, салкын» төсләрдәге семантик рәткә кергән лексик берәмлекләр куллана: *аклы-кызыллы байраклы (!); шау-шулы; биек таш коймалы; катлаулы тәрәзәләре; тирә-ягы олы йортлар; гөрелтеле урамнар; андагы поездның вәхши кычкырулары; корымнар, төтеннәр белән буялып беткән завод морҗалары.* Мондый коточкыч сыйфатларга ия шәһәр куенындагы кешелек яшәеше дә куе караңгы төсләргә манылган: *каты кайгы; авыр күз яше; ямьсез мәгънәсез*

*яшәү, авыр газаплар, башны чуалткан зур, кечек борчулар.*

Әйе, беренче тапкыр нәкъ менә романтиклар иҗатында капиталистик шәһәр кешегә коточкыч хәшәрәт, инсаннарның канын суыручы ерткыч (чудовище) рәвешендә килеп баса. Кешеләр монда шул зур, капиталистик шәһәрнең бер кечкенә генә көпчәгенә әйләнеп калалар. Алар табигать-ана белән тәмам элемтәләрен өзгән, ниндидер билгеле бер төркемгә куып кертелгән, кешелек сыйфатларын җуйган җансыз механизмны хәтерләтәләр. Монда кысанлык, пычраклык, хәерчелек хөкем сөрә. Бүген, XXI гасырда, «мәдәни» шәһәр тормышының зыянын медицина өлкәсендәге фәнни-тикшеренү нәтиҗәләре дә раслады: «В настоящее время до 80 % больных находящихся в психиатрических лечебницах, – больные с так называемым синдромом большого города» (3,38).

Аурупа романтизмында Ж.-Ж. Руссодан башлангыч алган табигать культы, диңгез хәяты аша, төп каһарман «мин»нең бозык әхлаклы шәһәр тормышына каршы бунты рәвешендә гәүдәләнгән.

Рус әдәбиятында исә руссочыл фикерләр Л. Толстойның фәлсәфи һәм әдәби әсәрләрендә дә үзенчәлекле чагылышын таптылар. Мәсәлән, иҗатының чишмә башын тәшкил иткән «Казаклар» (1852) повестеның төп каһарманы Дмитрий Оленин шәһри Мәскәү тормышын ташлап, көньякка – казак станицасына килә һәм үзе өчен өр-яңа, рухи яктан бозылмаган саф хәят ача. Үзенең «мәдәни» үткәнендәге дус-танышларына мөрәҗәгать итеп: «Как вы мне все гадки и жалки! Вы не знаете, что такое счастие и что такое жизнь! Надо раз испытать жизнь во всей ее безыскусственной красоте ... Счастье – это быть с природой, видеть ее, говорить с ней», – ди (4, 259). Бөек рус әдибе Л. Толстой үзенең яшәү рәвешен дә руссочыл рухка күчерә: тулаем авыл тормышы белән, табигый-руссочыл кеше кануннары буенча яши башлый. Еш кына, үзенең геройларының фаҗигасенә сәбәпче булган төп фактор итеп, техник казанышлары белән дан тоткан шәһәрне гаепли. Мәсәлән, «Анна Каренина» (1873–1877) романында Л. Толстой тимер юлны кешенең табигый яшәешен бозучы образ буларак тәнкыйтьләп чыга: Анна Каренина, тимер юлга − гөрселдәүче паровоз астына ташланып, һәлак була.

Дөнья һәм рус әдәби-эстетик фикере белән яхшы таныш Г. Ибраһимов та, татар прозасында беренчеләрдән булып, руссочыл-толстойчыл рухта антиурбанизм темасын күтәреп чыга һәм цивилизациянең, фәнни-техник алгарышның кешегә зыянын, табигатьнең исә дәвалау, рухларны чистарту өслүбен тану кебек руссочыл карашларын «Диңгездә» хикәясендә калку төстә гәүдәләндерүгә дә ирешә.

Нәтиҗә ясап, шуны әйтергә кирәк: Г. Ибраһимовның башлангыч чор хикәяләре Аурупа, рус, Шәрекъ романтизмы традицияләре синтезында иҗат ителә. Күренекле әдибебез, дөнья әдәбиятына яңа төсмер бирүче Ж.-Ж. Руссо, Л. Толстойлар кебек үк, шәхес һәм табигать мөнәсәбәтенә җитди игътибар бирә. Хикәяләреннән күренгәнчә, табигать тасвиры төп каһарманнарның психологик халәтенә параллель итеп бирелә, аның кәеф-кичерешләренең мөһим компоненты да булып тора.


ӘДӘБИЯТ

1. Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. I т.: Хикәяләр (1907–1929). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974.
2. Еники А. Школа для всех и каждого // Советская Татария. – 1987. – 12 марта (№ 59).
3. Соколова Е. Красота и польза // Мой ребенок. – 2004. – № 9.
4. Толстой Л. Н. Повести. Рассказы / сост., вступ. ст. и коммент. И. Виноградова. – М.: Советская Россия, 1985.
5. Хасанов М. Х. Галимджан Ибрагимов. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1969.


# A. İBRAHİMOV'UN KÖY ÇOCUKLARI HİKÂYESİNDEKİ EVLENME ADETLERİNİN TÜRK EVLENME ADETLERİ İLE MUKAYESESİ


***Ç. Yıldız (Adıyaman)***



Г. Ибрагимов – один из ярких представителей татарской литературы, в своих произведениях глубоко выразивший социокультурные особенности своего времени. Используя разные формы устного народного творчества, он показал богатую культуру и духовные ценности татарского народа. В статье на примере рассказа Г. Ибрагимова «Дети природы» (к сожалению, на сегодняшний день этот рассказ является единственным произведением писателя на турецком языке) в сравнительно-сопоставительном аспекте анализируются фольклорные мотивы, связанные с женитьбой, выявляются этнокультурные связи и особенности татарского и турецкого народов.


## Giriş

Tatar edebiyatının önemli yazarlarından olan Alimcan İbrahimov toplumun içerisinde bulunduğu durumlara kayıtsız kalmamış, eserlerinde toplumsal hassasiyetlere değinmiştir. Bu hassasiyetler bazen toplum için yaşamsal kıymet taşıyan, toplumun varoluşuyla ilgili öğeler olarak, bazen de toplumsal değerleri, gelenekleri, görenekleri canlı tutmak şeklinde kendini göstermiştir. İlk dönem eserlerinden sonra sosyal ve içtimai meselelere yönelen İbrahimov, ait olduğu toplumun kültürel değerlerini eserlerinde işlemiştir. Özellikle Tabiat Balaları, Çobanlar, Merhumun Defterinden, Bizim Günler gibi çalışmaları bu nitelikleri belirgin şekilde yansıtan eserlerdendir (12, 381).

"Sanat eserlerini, gerçek hayatın etkisi altında, mana ve hislerin insanda belirli bir imgesel yansıma içerisinde yeniden şekillenmesi" (9, 38) olarak gören yazar, Tabiat Balaları (Çocukları) hikâyesini 1914'te kaleme almıştır. Hikâye, özellikle dönemin sosyal, kültürel ve ekonomik şartlarına dair önemli ipuçları barındırmaktadır. Yazar bu hikâyede özellikle Tatar toplumunun folklorik unsurlarından olan evlilik adetleri üzerinde durmuştur. Bir köy

ortamında evlenme şartları, kız alıp verirken ekonomik ve sosyal durumların göz önünde bulundurulması kısacası evlenme adetleri dikkatle üzerinde durulan olgulardandır.

Evlilik, toplumun devamlılığını sağlayan önemli müesseselerdendir. Bu yüzden her toplum kendi devamlılığını sağlamak için evlilik kurumunu sağlam temeller üzerine oturtmaya çalışmıştır. Bu da evliliğe dair pek çok adet ve geleneğin oluşmasını sağlamıştır. Oluşan bu adet ve gelenekler genellikle üç safhada incelenmektedir. Bunlar; düğün öncesi gelenekler (kız isteme, söz kesme, nişan), düğün (kız ve erkek tarafında düzenlenen törenler, bunlarla ilgili çeşitli inançlar), düğün sonrası gelenekler (gelin getirme, duvak açma, dünür yemeği, erkek tarafının kız tarafında ağırlanması) dir (7, 95). Bu hikâyede düğün ve düğün sonrası gelenekler kısmı ele alınmamış, genellikle düğün öncesi safhadan bahsedilmiştir.

## 1. Köy Çocukları Hikâyesinde Evlenme Adetleri

### *1.1. Evlenilecek Kızın Özellikleri*

Pek çok Türk halk anlatısında kahramanların evlenmek için aradığı kızlar güçlü, çalışkan ve savaşçı tiplerdir. Bunun en bariz örneğine Dede Korkut hikâyelerinde rastlanmaktadır. Yarı göçer bir toplumun özelliklerini yansıtan Dede Korkut hikâyelerinde aranan kızın savaşçı özelliği ön plandadır. Kahramanlık, savaşçılık ve vücut kuvveti evlilik noktasında erkekler için güzellik kavramından daha önemli durmaktadır (11, 39–40). Bu durumun benzeri yerleşik hayata geçilmesiyle de devam etmiştir. Özellikle tarımla geçinen toplumlarda kadınların erkekler kadar çalışkan ve iş yapabilir olması önemli hale gelmiştir.

Eskiden, Anadolu'da aileler gelin olacak kızı bir şekilde sınarlardı. Kız istemeye sabah erkenden gidilerek kızın uyanıp uyanmadığını, uyandıysa temizlik yapıp yapmadığını öğrenmeye çalışırdı. Yahut erkek tarafından kadınlar, kız evine çeşitli vesilelerle misafir olup kızın hamaratlığını test ederdi. Böylece talip oldukları kızın çalışkan, iş bilen biri olup olmadığını ölçmeye çalışırlar. Bu noktada alınacak gelinin iş bilen olması oldukça önemlidir. Buna Anadolu'dan örnek vermek gerekirse; Adana-Karaisalı'da aileler oğullarına kız ararken, gelinlik kızın huyunun güzel olmasına ve kendi kendine iş yapabilme yeteneğinin olmasına dikkat ederler (2, 7).

Tarihin kadim devirlerinden beri yerleşik hayata geçen Tatar toplumu geçimini tarımdan sağlamaktaydı. Bu durumda özellikle yaz aylarında tahılların biçilmesi en önemli işlerden sayılır. İşlerin yoğunluğu kadınların ve kızların da çalışmasını gerektirmektedir. Bu yüzden aileler kendilerine gelin olacak kızların çalışkan, hamarat, iş bilen kişiler olmasına özen gösterir.

Hikayenin kahramanı Hafiz'in yengesi ona kız aramaktadır. Şahi isimli birinin kızını Hafiz'e tavsiye ederken kızın çalışkanlığını belirtir.

"İşte dedi, yaşlı Şahi'nin elma gibi kızı var. Çalışmada köyde bir tane. Öyle endamlı, öyle boylu poslu, bir içim su" (4, 121).

Tahıllarını biçme işini kendi başlarına halledemeyen köylüler imecelerle köydeki kız erkek bütün gençleri çağırır ve işin kısa sürede bitirilmesini sağlarlar. Hafiz, gönül verdiği Bibiesma ile ilk olarak imecede tanışmıştır.

Bibiesma'nın babası, Ramazan ayında köyün gençlerini imeceye çağırır. Hafiz, imeceye gelenlere hizmet eden Bibiesma'nın hamaratlığını, iş bilirliğini şu sözlerle över:

"Bibiesma epey hamarat kız. Onun her şeyi ak olsun, her şeyi pak olsun, her şeyi parlayıp dursun… Çaya oturunca, aklın gider; sofra örtüsü o biçim… Semaveri altın gibi, tabak çanak desen her şey hamarat kız eli işte" (4, 28).

Böylesine çalışkan bir kızı alacak olan erkeğin de kendisini ispatlamış olması gerekmektedir. Hafız bunun için orakta o zamana kadar geçilmemiş olan Kerim'le yarışır. Kavurucu sıcağın altında oruçlu halde Kerim'i yenince Bibiesma'nın babası kızını o güne kadar birkaç defa istemesine rağmen vermediği Hafız'a verir.

### *1.2. Mehir ve Başlık Parası*

Mehir (mehr, mihr), müslüman bir erkeğin nikâh esnasında eşine vermeyi kabullendiği mal veya paraya denir (6, 603). "Bu para erkeğin kadından ayrılması durumunda, belli bir süre geçimini sağlaması amacıyla kadına verilir. Böylelikle kadının mağdur olması engellenir. Arap toplumundan Müslüman toplumlara aktarılan bu gelenek, Kur'an-ı Kerim'de pek çok ayette geçmesinden dolayı İslami bir hüviyete de sahiptir" (10, 125–126). Adana-Karaisalı'da imam nikâhı esnasında ortaya altın konur. Buna 'mihir' denir. İlerde boşanma durumunda koca, eşine bu mihri ödemek zorundadır (2, 12). Aynı şekilde Eskişehir'in Mahmudiye ilçesine bağlı İsmetpaşa Köyü'nde de imam nikâhı esnasında belirlenen altın veya para ortaya getirilir. İmam nezaretinde belirlenen miktara gelinin ve babasının razı olmasına dikkat edilir.

Hikayede, kızı istenen babanın direkt olarak mihri düşünmeye başladığı belirtilir.

"Önceleri böyle değilmiş galiba, artık birini kız istemeye göndersen, kızın babası mihiri düşünürken; anası, çok kaynı var mı, kaynanası yavuz mu diye düşünmeye başlıyor" (4, 121–122).

Başlık parası ise bazı bölgelerde, evlenirken damadın kaynatasına ödemesi gereken para veya mala verilen isimdir (3, 219). Mehir, evlilik esnasında geline verilirken, başlık parasını kızın babası alır. Pek çok Türk halk anlatısında da bu durumun örnekleri vardır. Söz gelimi; Dede Korkut'ta Bamsı Beyrek, Dede Korkut vasıtasıyla Deli Karçar'ın kız kardeşi Banı Çiçek'i isteyince Deli Karçar kız kardeşini vermenin karşılığında; maya yüzü görmemiş bin buğra, kısrağa aşmamış bin aygır, koç görmemiş bin koyun, kuyruksuz kulaksız bin köpek ve bin de iri pire ister (5, 80–81).

Koşay, ilgili çalışmasında Erzurum, Malatya, Niğde gibi illerden başlık parası ile ilgili adetlere değinir (1, 312). Başlık, her zaman para olarak verilmeyebilir. Kız isteme esnasında pazarlıkla belirlenen başlığın miktarı ve cinsi tarafların anlaşmasına bağlıdır. Bu doğrultuda Anadolu'da çoğunlukla para olarak alınan başlık, küçük veya büyükbaş hayvan, tarla, arazi gibi başka şekillerde de alınabilir. Eskiden Anadolu'da oldukça yaygın olan bu gelenek bugün geçerliliğini önemli ölçüde yitirmiştir.

Hikayede, Şeyahmet, Eptireş Amcanın Mahibeder isimli kızını istemiştir. Ancak başlık parasında anlaşamadıklarından Mahibeder'i alamamıştır. Bunun üzerine Satkay isimli başka bir kişi kızın babasının istediği başlığı verip Mahibeder'i alır.

"Eptireş Amcanın Mahibeder'ini Şeyahmet istemiş. Safa Amca aracılığıyla haber gönderip vermeye niyetleri olduğunu öğrenmiş, yalnız başlıkta anlaşamamışlar. Eptireş, kalın bir kaftan, bir paket çay, yarım kovan bal artırmalarını istemiş. Fakat buna razı olmaya yanaşmıyorlarmış. Satkay bunu birilerinden duyunca Hayrullah Amcayı istemeye gönderip, "Ne isterlerse ver; ne kadar verirsen ver, yalnız Mahibeder'i kaçırma."demiş. Hayrullah

Amca gitmiş ve Eptiri'nin istediğinden fazlasını vermiş, hemen oracıkta yirmi beş lira çıkararak söz bohçasını alıp gelmiş" (4, 130).

### *1.3. Kız İstemeye Aracı Koyma*

Toplumda saygınlığı olan insanlar toplum içerisindeki hemen her önemli olayda ön sıralarda bulunur. Bu durum halk anlatılarında olduğu gibi modern anlatılar için de geçerlidir. Kız isteme gibi hassas bir konuda özellikle hatırı kırılamayacak kişilerin istemeye gönderilmesi olumlu neticeyi elde etmek açısından önemlidir. Tatarlarda bir kızı seven genç, kızın evine köyün en saygıdeğer, en açıkgözlü, atak ve ağzı söz yapan ağası veya ninesini gönderirmiş (8, 86). Bazen damat adayının anne-babası olmadığında ya da çok yaşlı olduğunda kız istemeye damadın başka yakınları da ön ayak olur.

Geçmişte de kız istemede aracılardan yardım alındığı belirtilir. Hunlarda, aracılar kız isteme için uygun zemini hazırlayan kimselerdir (1, 308). Anadolu'da, eskiden kız istemelerde aracı olarak toplumda önde gelenlerden yardım istense de günümüzde daha çok damat adayının yakınları (annesi, ninesi, yengesi vs.) bu işi yüklenmiş durumdadır.

Hikayede, Hafız'ın babası olup olmadığından bahsedilmez. Annesi ise çok yaşlıdır. Bu yüzden Hafız'a kız bakma işi yengesine kalmıştır.

"Bir yengem var. Her türlü yarım akıllılık, şaklabanlık, hafiflik onda. Güz gelip ekin harmana girdi mi o bana kız bakmaya başlıyor" ( 4, 120).

İmece esnasında bahsi geçen bir kız isteme durumu daha olmaktadır. Burada da yine aracılar bulunmaktadır. Şeyahmet, Eptireş Amcanın kızını istemeye Safa Amca isimli birini gönderir.

"Eptireş Amcanın Mahibeder'ini Şeyahmet istemiş. Safa Amca aracılığıyla haber gönderip vermeye niyetleri olduğunu öğrenmiş" (4, 130).

Başlık miktarında anlaşılamadığından kız verilmemiştir. Satkay isimli bir başkası bunu duyunca Hayrullah Amca isimli birini araya koyarak aynı kızı istetir.

"Satkay bunu birilerinde duyunca Hayrullah Amcayı istemeye gönderip, "Ne isterlerse ver; ne kadar verirsen ver, yalnız Mahibeder'i kaçırma demiş" (4, 130).

### *1.4. Düğün Zamanı*

Günümüzde, Anadolu'da düğün zamanları şehir ve kırsal kesimlerde farklılık göstermektedir. Şehir merkezlerinde modernleşmeyle beraber düğün salonlarının sunduğu imkanlardan dolayı düğünler yılın hemen her gününde yapılabilmektedir. Ancak aynı durum kırsal kesim için geçerli değildir. Kırsal kesimlerde düğünler çoğunlukla yaz aylarında, ekinler biçilip toplandığı, böylece maddi durumun daha iyi olduğu zamanlarda yapılmaktadır. Aynı şekilde Tatarlarda da düğün, nikah törenleri genelde sonbaharda, hasatlar toplanıp ambarlar dolduğu, yani tokluk zamanında yapılmıştır (7, 95).

Bibiesma, Hafız'a verilince önceden yapılan düğün hazırlıkları biter ve ekinler toplandıktan sonra düğün yapılır.

"Ekin, darı toplandıktan sonra bütün köyü toplayıp çoşkulu bir düğün yaptık" (4, 137).

### Sonuç

A. İbrahimov'un toplumun aynası niteliğindeki ilk dönem eserleri Tatar toplumuna dair sosyal ve kültürel veriler taşımaktadır. Bu veriler esas alınarak yapılan çalışmada evlilik ile ilgili öğeler mukayese edilmiştir. Başlıklar altında verdiğimiz; 'evlenilecek kızın özellikleri', 'mehir ve başlık parası', 'kız istemeye aracı koyma' ve 'düğün zamanı' öğeleri Anadolu Türkleri ve Tatar toplumunun kültürlerinde ortaklık arz etmektedir. Bunların dışında çalışmanın sınırlı olmasından dolayı, ortak özellikler barındıran söz bohçası, evlenme yaşı, erkek seçme oyunu, mendil verme vs. gibi öğeler ele alınamamıştır. Ancak bu öğelerin de Anadolu'da pek çok yerde uygulandığı bilinmektedir. Kısacası, yapılan bu çalışmayla Türk ve Tatar toplumlarının tarihin kadim devirlerindeki ortak yaşam kaidelerinin halen devam ettiği anlaşılmaktadır.

KAYNAKÇA

1. Alptekin A. B. Ceyhun'dan Ceyhan'a evlenme ile ilgili bazı kavramlar (kalın, saçı, okuntu, aşerme, toy) üzerine. – Erzurum: A. Ü. Türkiyat Araştırmaları Enstitüsü Dergisi, 2009. – S. 307–321.

2. Başçetinçelik A. Karaisalı ve çevresinde doğum, evlenme, ölüm. http://turkoloji.cu.edu.tr/CUKUROVA/makaleler/bascetin celik_karaisali.pdf. 2012. –S. 1–18.

3. Büyük Türkçe sözlük. 10. Baskı. –Ankara: TDK Yayınları, 2005. – 2243 s.

4. Vasiyet. (Çev: Kutlu F., Ersoy H., Arslan N.). – İzmir: Zambak Yayınları, 2005. –144 s.

5. Gökyay O. Ş. Dede Korkut hikâyeleri. – İstanbul: Kabalcı Yayınevi, 2006. – 361 s.

6. Devellioğlu F. Osmanlıca-Türkçe ansiklopedik Lügat. 22. Baskı. – Ankara: Aydın Kitabevi Yayınları, 2005. – 1195 s.

7. Zaripova Çetin Ç. Tatar Türklerinin düğün geleneği. – Ankara: Modern Türklük Araştırmaları Dergisi, 2005. – S. 93–119.

8. Zaripova Çetin Ç. Tatar Türklerinin gelenek ve görenekleri. – Ankara: Karadeniz Dergisi Yayınları, 2009. –160 s.

9. Yarullina R. Büyük tatar yazarı Alimcan İbrahimov. – Ankara: Türksoy, 2007. – S. 37–40.

10.Yıldız Ç. El-Ferec Ba'de'ş-Şidde'de motif incelemesi (ilk yirmi hikâye). – Adıyaman: Yayımlanmamış yüksek lisans tezi Adıyaman Üniversitesi, 2011. – 213 s.

11. Kaplan M. Türk edebiyatı üzerine araştırmalar I. – İstanbul: Dergah Yayınları, 1976. – 578 s.

12. Türkiye dışındaki Türk edebiyatları antolojisi 18 Tatar edebiyatı II. – Ankara: Kültür Bakanlığı Yayınları, 2001. – 480 s.

# Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ «ТАБИГАТЬ БАЛАЛАРЫ» ХИКӘЯСЕНДӘ СЮЖЕТ СТРУКТУРАСЫ

*Г. Р. Гайнуллина (Казан)*

Татарский рассказ прошлого столетия целесообразно рассматривать с точки зрения строения событийного ряда. В статье на примере рассказа классика татарской литературы Г. Ибрагимова выделяется несколько взаимосвязанных особенностей эпического сюжета.

Билгеле булганча, хикәя – татар әдәбиятында үзгәрешләргә иң сизгер жанр (3, 9) буларак тамгалана. Хәзерге татар хикәясенең сюжет структурасындагы үзгәрешләрне бер гасыр элгәре иҗат ителгән эпик

текстның корылышын өйрәнү аша ачыкларга мөмкин.

Әдәбият белемендә эпик сюжет үстерелешен тәэмин итүче берничә үзенчәлекне аерып карау кабул ителгән (4, 233). Беренче – үзәк вакыйганы кабатлау – дупликация принцибы «эпик сюжетны оештыручы төп элемент» (4, 233) буларак билгеләнә. «Эпик сюжет нигезендә каршы якларның тотрыксыз тигезлеге ята, хәрәкәт исә – әлеге тигезлекнең вакытлыча җимерелеп, яңадан үз урынына кайтуы» (4, 233). Төп эпик ситуация кабатлана, кире симметрия (көзгеле композиция) закончалыгы саклана (4, 234).

Галимҗан Ибраһимовың «Табигать балалары» (1914) хикәясе 10 бүлектән тора. Хикәяләү егерме бер яшьлек Хафиз исеменнән алып барыла. Әсәрдә төп герой итеп алынган субъектив образның өйләнү тарихы бәян ителә. Беренче бүлектә өйләнергә нияте булган егетнең матди хәле яктыртыла: *«Өч атым, ике сыерым, ун баш сарыгым бар. Үткән көз өйне дә сипләтеп, алты почмаклы ясаттым. ... Насыйб булса, тагы бер-ике имән багана алып, киләсе көзгә капканы яңадан эшләтергә, кечерәк булса да, келәт салдырырга исәплим»* (1, 71). Урта хәлле, ялгыз егет *«кемгә башкода җибәрсә дә, сүзе кире кайтыр»*, дип шикләнми (1, 71). Тирә-якның ару тормышлы адәмнәреннән саналган Җамалый карт Фәхернисасы да, Шаһи карт кызы Бибиәсма да аңа кияүгә барырга әзер икәнлеген егет белә. Икенче бүлектә Бибиәсмага күңеле төшкән Хафиз *«сөеп алган, сөеп барган бәхетсез булалар имеш»* (1, 72) дип, өйләнергә кыймавының сәбәбен әйтә, беренче һәм төп проблема кыюсызлыкка кайтып кала.

Хикәянең өченче бүлегендә үткәнгә кайту (ретроспекция) алымы ярдәмендә Әсма белән Хафизның өч ел элек булган кара-каршы әйтешү вакыйгасы сөйләнә. Вакыйга өчен өмә ситуациясе сайлана, бишенче бүлектә кабатланган өмә «эшнең ахыры» да (1,74) булып тора. Шул рәвешле, егетнең кыюсызлыгын хәл итү өчен күмәк хезмәт вакыйгасы тасвирлана.

Эпик сюжет структурасының икенче закончалыгы булып ретардация тора. «Әкренәйтү (ретадация) алымы – хикәяләүне ашыкмыйча, аерым бер күренешләргә (пейзаж, портрет, фәлсәфи уйланулар, лирик чигенешләр, көчле хисләр) тукталып алып бару дигән сүз» (2, 25). Өченче бүлектә Әсмага бәя бирелә: *«Әсма, диләр! Бибиәсма, диләр; карчыклар, иркәм, дип, аның аркасыннан кагалар; имеш, күргән җегетләр аның йөзенә, зифа буена, аяк атлавына хәйран булып сөйлиләр. Йөрәгемдә күптән үк аңар дәртем булса да, моңарчы бер сүз әйтү түгел, юньләп күрә дә алганым юк иде»* (1, 72). Иген уңган елны күрше Бәдри карчык оештырган өмәдә Әсма катнашачагын белүгә Хафиз *«минем эшем бик күп, үз ашлыгым да яланда, фәлән дип бер әйтүгә, азрак җилкәне кашырга уйлаган»* (1,72) җиреннән *«ярар, барымын»* дигәнен сизми дә кала (1, 72). Хезмәт белән үткән күңелле көн ахырында яшьләр бер-берсенә йөрәк түрендәге хисләрен әйтешеп таралышалар: *«Ни дияргә белмим инде, күңелемдә булганмы, үзем шуны эзләгәнменме, әллә Ходай үзе туры китергәнме – ни дә булса бар, мин, урагымны атып бәреп, таллык эченә кергән генә идем, искәрмәстән, алдымда бер зифа буй күрдем: ул Әсма булып чыкты; тагын кызуладым, тагын омтылдым да, шул зифа буйны тотып ала язып, артыннан: "Әсма, Әсма, мин сине яратам!" – дип кычкырып җибәрдем. ... Шуңа каршы аның да үзенең көмеш тавышы белән: "Мин дә", – дигәнен ишетеп калдым. Миңа шуннан артыгы кирәкми дә иде»* (1,74).

Хафиз белән Бибиәсма турында тирә-якка сүзләр таралса да, тотыла язсалар да, кыюсыз егет проблемаларны уйлап табып кына тора. Дүртенче бүлектә *«тик әнкәйне ризалату гына авыр иде»* (1, 74), дип, алдагы проблема атала. Шул ук вакытта Хафиз, әнкәйнең картаюы бар, иптәшләрем инде күптән уллар-кызлар үстерә, дип, уңайсызланып йөри, *«агай-энеләрдән дә яхшы түгел, яшең егермеләрне үтеп, һаман өйләнмәгәч, алар минем өчен кызарып, гарьләнеп йөриләр бугай»* (1,74), дип тә уйлана. Шул рәвешле, сюжет хикәяләүченең уйланулары белән әкренәйтелә (ретардацияләнә).

Бишенче бүлектә өмә вакыйгасы кабатлана, дидек. Ураза тоткан вакытта Бибиәсманың атасы Шаһи бабай Ханбикә тугаендагы печәнлекне чабарга өмә итә (1, 74). Биредә Шаһи бабай турындагы сүз сюжетны әкренәйтә: *«Ул – авылыбызның әйбәт картларыннан, аның Ибракаен солдатка алдылар, эш кулы ялгыз калды. Җитмәсә, тагы печән алдыннан гына менә дигән ике алашасын урлап киттеләр. ... Мондый кеше өмә итсә, бик үк ялгыз булмаганнар сүз кайтарырга килештермиләр инде, өстәвенә, аның Әсмасы да бар»* (1, 75).

Алтынчы бүлек – тулысы белән ретардация. Хикәяләүче уразада өмә оештыру авырлыгы, шул ук вакытта рәхәте турында уйлана: *«Рәхәт тә соң, валлаһи, шундый чакларда киң тугайларда күкрәк киереп печән чабулар!.»* (1, 75). Җиденче бүлектә пейзаж белән әкренәйтелгән өлештә печәнче егетләрнең ярдәм итәм, хезмәт күрсәтәм, дип ашкынып торулары бәяләнә: *«Көн үтә аяз; күк әллә кая ерак иде; иртәнге салкында чабу җегетләргә бәйрәм генә булса да, соңгы чәй вакытлары үтү белән кояш эсселәтә, кайберәүләрне йомшарта да башлады... Без һаман чабабыз... Шаһи картның үзенең дә эсседән күзләре агарган. Ул: "Я, балалар, без бит сәхәрдән үк килгән идек, әле дә күп чаптык... Инде кайтабыз дисәгез дә, сүзем юк", – диде»* (1, 75–76). Араларында Шәяхмәт дигәне эсседән егылгач кына, егетләр ял итеп алырга карар кылалар. Сигезенче бүлектә аяз яңгыр сурәте белән сюжет ретардацияләнә. Шул рәвешле, сюжетның кумулятив өлеше әкренәйтү вазифасын башкара.

Янәшә бирелгән ике пейзаж сюжетны үзгәртә – Хафиз күңелендәге рухи хәлсезлеккә китерә торган тотрыклы кыюсызлык *(«эсселек җиңә башлаган дигән сүз»)* кинәт кенә күптән көтелгән чишелеш *(«аяз яңгыр»)* белән алышына (1, 75, 78). Җыр образы герой күңелендәге хисләрнең иң югары ноктага җитүенә ишарәли.

Шулай итеп сюжет корылышында тугызынчы бүлек – *«бер якта – кояш, икенче якта – болыт»* (1, 78) – аяз яңгыр дип аталган табигать сурәтенең кабатланышы. Гыйлаҗи, Хафизны котыртып, Шаһи бабайдан Әсманы сорый. Шаһи карт та югалып калмый: *«Менә Кәрим карт белән ярышыгыз, ике әйләнгәнче аны кайсыгыз җир буе калдырса, Әсма шуныкы!»* – ди (1, 78).

Циклик каймалап алу, ягъни башлам һәм бетем өлешләренең кабатлану закончалыгы да үтәлә. Унынчы бүлектәге чишелеш – Хафизга кыюсызлыгын җиңәргә шарт тудыру, ягъни Кәрим картның күз күреме җирдә артта калуы, тиз арада Хафизның келәт белән капкасын

эшләтүе, иген-тару җыйгач, җәйне көтмичә, кыш көне үк шаулатып туй итүе әйтелә. Егетнең *«сөеп алган, сөеп барган бәхетсез булалар имеш, эт көнендә гомерләре үтә»* (1, 72) дигән шиге акланмый: *«Без бик яхшы торабыз. Бөтен авылда безне мактап сөйлиләр. Инде озакламый балабыз да булачак»* (1, 80).

Күренгәнчә, Г. Ибраһимовның «Табигать балалары» хикәясендә төп эпик ситуация кабатлана, кире симметрия, циклик һәм кумулятив схемаларның тигезлеге дип аталган закончалыклар саклана. Бер гасыр үткәнгә нисбәтле классик хикәя сюжет структурасы җәһәтеннән гаҗәп дәрәҗәдә төгәл булуы белән игътибарны җәлеп итә.

ӘДӘБИЯТ


1. Ибраһимов Г. Табигать балалары // Татар хикәясе антологиясе. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – Б. 71–80.
2. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.
3. Заһидуллина Д. Яңа дулкында (1980–2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык). – Казан: Мәгариф, 2006. – 255 б.
4. Теория литературы. Том III. Роды и жанры (основные проблемы в историческом освещении). – М.: ИМЛИ РАН, 2003. – 592 с.


## Г. ИБРАҺИМОВ ХИКӘЯЛӘРЕНДӘ БАЛА ОБРАЗЫ


***Ф. А. Гафурова (Уфа)***



В статье рассматривается вопрос воплощения образа детей в рассказах Г. Ибрагимова. Анализируются психологизм, драматизм в описании событий из жизни героев.


Һәр дәвернең алдынгы әдипләре баланың чынбарлыкны танып белүендә, аның эстетик зәвыгын, характерын формалаштыруда куәтле чара итеп әдәбиятны санаганнар. Татар әдәбияты классигы Галимҗан Ибраһимов татар балалар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертә. Г. Ибраһимовның һәр хикәясе татар балалар әдәбияты өчен яңалык була. Язучының «Яз башы», «Карт ялчы», «Көтүчеләр» исемле хикәяләре белән татар балалар әдәбиятына заманның иҗтимагый хәлләре килеп керде, хезмәт иясе баласы уңай герой дәрәҗәсенә күтәрелде, ярлы баласының эчке матурлыгы, бай рухи дөньясы ачылып китте, ул бәхетле булырга хокуклы һәм шуның өчен көрәшергә сәләтле итеп бирелде. Балаларга багышланган беренче хикәясе «Яз башы» 1910 елда дөнья күрә. Хикәядә сурәтләнгән вакыйгалар беренче заттан –Салих авызыннан сөйләтелә. Салих – урта хәлле крестьян малае. Авылның матур табигате, әти-әнисенең ягымлы мөнәсәбәте, гомумән яшьлек ваемсызлыгы аны назлап, иркәләп үстерә. Ләкин мондый ваемсыз тормыш озак дәвам итми. Бераз үсә төшкәч, аны күңеленә якын һәммә нәрсәдән – туган авылыннан, аның сихри табигатеннән, кадерле әти-әнисеннән, бергә уйнаган иптәш малайларыннан аерып, мәдрәсәгә илтәләр. Моңа кадәр әнисе кочагыннан бер җиргә дә чыкмаган сабый балага кыш буена читтә яшәү, тар мәдрәсә кысаларында бикләнеп яту җиңел түгел, билгеле. Ул бик сагына, язучы әлеге мизгелләрне, герой төннәрен йокларга яткач, юрган астында балавыз сыккан чаклар белән тулыландыра. Түземсезлек белән яз житүен, мәдрәсәдән кайтыр вакытларын көткән Салих туган җирендә, яңадан табигать кочагында, кадерле әнисе янында, бергә үскән иптәшләре арасында гәүдәләндерелә.

Биредә язучы беренче хикәяләрендәге кебек, вакыйгаларны сөйләп чыгу юлыннан бармый. Ул әһәмиятле бер моментны – сабыйның озак вакытлар аерылып торганнан соң яңадан әнисе белән күрешү моментын сайлап ала да, шул вакытта ана белән балада булган рухи халәтне сурәтли, ана һәм бала тормышындагы төп сызыкларны бирүгә ирешә. Хикәядән ананың буй-сынын, аның йөреш-килбәтен һәм характерын гына түгел, хәтта тормышының үткәне белән киләчәген дә күз алдына китереп була (1, 13). Аның «арып, талган куллары» һәм «саргылт йөзе» дүрт стена эченә бикләнеп яшәүче, авыр физик хезмәттән җәфа чигүче татар хатынының типик язмышын сөйли. Ананың бөтен өмет һәм теләкләре шул сабыйга бәйләнгән булуы да аңлашыла. Автор характерлы калку моментларны сайлап ала һәм аларны җанлы образлар аша тасвирлап күрсәтә, типик картиналар тудыра. Әсәрдә һәммәсе табигый, һәммәсе тормышчан килеп чыккан: мәдрәсәдән кайтып төшкән сабый баланың әнисе янында утырып берәр чынаяк чәй эчкәч тә, тизрәк ишек алдына, иптәш малайлары янына атылуы да, аннан соң алар белән бергәләшеп табигать кочагына ташлануы да.

Кыш буена аерылып торган крестьян малаена барысы да кадерле: «түтәл вә агачлар белән тулган бакчасы да», мал-туар исе сеңгән абзар-куралары, яшел хәтфә белән капланган инеш буйлары да, балык тоткан тугайлары һәм төнлә ат сакларга йөргән урманнары да. Салихның хисләре шулкадәр мул булып ташый, эчке кичерешләре шул кадәр көчле һәм киеренке, хәтта сабый йөрәге күтәрә алмый. Аның хыял-фантазиясе табигать дөньясында булган үзгәрешләргә гаять сизгер. Ә табигать дөньясы аның күңеле белән уйнаган шикелле: ул, әйтерсең, үзенең нәфислеге һәм йомшаклыгы белән кытыклап көлдерә дә, гүзәллеге белән шатландыра һәм сөендерә дә, дәртлелеге белән күкләргә ашырырдай итеп җилкендерә дә. Ләкин табигать вакыты белән усал һәм рәхимсез, шомлы һәм куркыныч та. Аның дәһшәтле минутлары сабый хыялында хәвефле күренешләр тудыра, аны кайгыга сала, хәтта һушыннан яздыра.

Халык гасырлар дәвамында җеннәр, пәриләр, аждаһа, су анасы, убырлы карчык шикелле хыялый образлар иҗат иткән. Бу куркыныч әкиятләрне шәкертләр мәдрәсәләрдә тыңлаганнар, гаиләдә ата-аналар тәрбия чарасы итеп кулланганнар. «Яз башы» хикәясендә Г. Ибраһимов мондый әкиятләрнең, тәрбия чарасы буларак, зарарлы булуын, шәхесне куркак итеп үстерүен

күрсәтә. «Кыядан нинди балалар туа бит», – дип нәтиҗә ясый хикәянең ахырында автор.

Физик хезмәтнең бала характерын формалаштырудагы ролен поэзиядә Тукай билгеләсә, прозада – Г. Ибраһимов моңа басым ясады (2, 112). «Ялчы» хикәясендәге үсмер Сәфәр дөньяның ямен, яшәүнең тәмен хезмәттә күрә. «Көн-төн эшлисең, җаның рәхәтләнә, аруның нәрсә икәнен дә белмисең», дип уйлый малай. Малайның иң изге хисләре дә хезмәт кешесенә карата уяна. «Шаһи бабай, син безгә күчәр идең, безнең әткәй – картларга йомшак күңелле кеше», – ди ул, карт ялчыны кызганып.

«Көтүчеләр» хикәясендә Г. Ибраһимов татар балалар әдәбиятында моңа кадәр күренмәгән яңа сәхифә ача, кечкенә геройны тормышның иҗтимагый хәлләренә мөнәсәбәттә сурәтли. Әсәрдә бала һәм сыйнфый каршылык дигән төсмер килеп чыга (2, 113). Хикәядәге төп герой – кечкенә Вахит булдыра алган кадәр үзенең кешелек дәрәҗәсе өчен көрәшә. Ул, этисе кебек, бөтенесенә түзеп, эчтән сыкрап яши алмый, ризасызлыгын ачык рәвештә белдерә. Әтисен һәм үзен кимсетүчеләр белән килешмичә, туган авылын ташлап чыгып китә. Вахит, көрәшчене тимер киемнәр киеп, гайрәтле атка атланган каһарман егет итеп күз алдына китерә. Вахит этисе Әптерәш картны һәм аның сыйныфташларын һәлакәткә дучар иткән газаплы тормыштан котыла. Ләкин нинди юл белән? Ул юл башка Вахитлар өчен яраклымы? Һич юк. Вахитның социаль газаплардан котылу юлы типик түгел. Ул бит бары тик очраклы хәлләр аркасында гына шәһәр больницасына килеп эләгә һәм анда эшләүче бер туташның очраклы мәрхәмәте аркасында аның белән «бәхетле семья» корып җибәрә. «Көтүчеләр» хикәясендә Г. Ибраһимов бәхетең өчен көрәшергә кирәк дигән фикер үткәрә (2, 113).

Авыл кешесенең җиргә, сабый баланың яшәү һәм хезмәт символы булган атка мәхәббәте аркылы, язучының туган җиргә, аның табигатенә һәм кешеләренә, андагы яшәешкә дан җырлаганын, яшь буынны патриотизм рухында тәрбияләргә омтылганын «Алмачуар» хикәясендә ачык күрәбез. Г. Ибраһимов «Алмачуар» хикәясен 1922 елда яза. «Алмачуар» хикәясе – гәрчә анда социаль яңгырашы ягыннан зур булмаган вакыйгалар сурәтләнсә дә, сюжеты белән гади, күләме ягыннан кыска булса да – татар һәм башкорт халыклары иҗтимагый үсеш баскычының әһәмиятле бер этабын гәүдәләндергән, шул чордагы халык тормышы, психологиясе, гореф-гадәтләре көзгесе булган бер классик әсәр (1, 158). Рус әдәбиятының күренекле белгече П. С. Коган аны бер дә юкка «проза сәнгатенең җәүһәре» дип атамаган.

Бу әсәрдә сурәтләнгән чорны татар халкы инде күптән үтеп китте, аның тормышы, холкы, гадәтләре дә хәзер бөтенләй башка. Ул дәверне башыннан кичергән кешеләр дә азаеп бара. Әмма Г. Ибраһимовның хикәясе халык тарихының әнә шул үткән, яңадан әйләнеп кайткан бер чорын киләчәк буыннарга гаять төгәл күрсәтүче бер ядкарь булып калачак. Хикәянең башында, халыкча әйткәндә, «Кеше күңеле карурман» дигән сыман, геройның эчке кичерешләре, борчулары, үзенә генә билгеле булган күңел газаплары сурәтләнә. Әлемгол белән Хафиз – ике баһадир – сабан туенда көрәшәләр. Озак еллар буе мәйдан батыры булып танылган Хафизны Әлемгол хәйлә белән җиңә. Хафиз бу җиңелүне бик авыр кичерә, шушы хәлдән соң сабан туйларына бөтенләй йөрмәс була. Әлемголны вөҗдан газабы эзәрлекли башлый, ул авыруга сабыша. Аякка бассам, Хафизны бәхилләтермен – бурлы биямне илтеп дога кылдырырмын, дип нәзер әйтә. Ниһаять, эчке каршылыклы уйларын җиңеп, үзенең биясен китереп бирә. Язучы, шәхесенең эчке кичерешләре аша гамәл, гөнаһ мәсьәләләрен намус, вөҗдан белән бәйләп, әдәби герой мисалында күрсәтә алган.

«Алмачуар» хикәясендә иркен табигать кочагында яшәгән малайның саф күңеле, самими хисләре крестьян тормышының гадәти көнкүрешенә тыгыз үрелеп сурәтләнә. Хикәя халык авыз иҗаты әсәрләрендәгечә сүз сәнгатенең бөтен байлыгын, бизәкләрен, төсмерләрен оста файдаланып иҗат ителгән. Андагы вакыйгалар җанлы булып күз алдына килә. Әсәрдәге күренешләр төп герой Закир күзәтүләре, кичерешләре, уй-фикерләре, аның сүзләре аша хикәя ителә. Шул җирлектә сабыйның дулкынлануы, борчылуы, сөенечкөенечләре – бөтен барлыгы баланың самими хисләре чишмәсендә сугарылып бирелә. Закирны тасвирлаганда автор урыны-урыны белән әкиятләргә хас алымнар куллана. «…кунакка барырга ясанган бояр җегете кебек чибәр» итеп Алмачуарның ялын кистерүе, тасмалар тагуы үзе үк баланың матурлыкны аңлавын, нечкә зәвыклы икәнен күрсәтеп тора. Закирның шатлыгы да, кайгысы да, мәхәббәте дә Алмачуар тайга мөнәсәбәттә ачыла. Малай үтә нечкә хисле, һәрнәрсәне йөрәк аша кичерә. Алмачуарның үлүе Закирны тетрәндерә. Язучы бу әсәре белән тормышта төрле югалтулар кичерергә туры килүен күрсәтә, укучыларны түземле булырга өнди. Хикәя психологик тирәнлеге белән дә яңалык булarak кабул ителә.

Шулай итеп, язучының балалар өчен язылган нинди генә әсәрен алма, андагы күренешләр, күтәрелгән проблемалар әле дә актуаль. Һәр әсәр үзәгендә нинди дә булса тормыш сынавына (кайбер очракта психологик сынауга да) дучар булган бала образы гәүдәләндерелә. Язучы әлеге образлар аша чынбарлыкка мөнәсәбәтне, яшәешнең асылын ачарга омтыла.

## ӘДӘБИЯТ


1. Ибраһимова Ф. И. Балалар әдәбияты. Хрестоматия. – Казан: Мәгариф, 2004.
2. Ибраһимова Ф. И. Заман белән бергә. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1971.
3. Хәсәнов М. Х. Галимҗан Ибраһимов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964.
4. Ибраһимов Г. Хикәяләр, повесть, роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – Б. 51–65.
5. Минһаҗева Л., Мияссарова И. Татар балалар әдәбияты. – Казан: Тарих, 2009.

# Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ «СӨЮ – СӘГАДӘТ» ХИКӘЯСЕНДӘ ВАКЫТ-УРЫН БИРЕЛЕШЕ

*А. Г. Хәлиуллина (Уфа)*

Статья посвящена исследованию проблемы художественного хронотопа в рассказе «Сөю – сәгадәт» Г. Ибрагимова. Категории пространства и времени позволяют писателю четко выделить основные сюжетные узлы произведения и выражают философские представления автора.

Әдәби әсәрдә чагылдырылган бербөтен урын һәм вакыт хакындагы күзаллау хронотоп буларак билгеләнә (4, 214). Хронотоп теориясенең нигезләре М. М. Бахтин тарафыннан эшкәртелә. Урын һәм вакыт бирелеше әсәрдә сурәтләнгән вакыйгаларны конкретлаштыра төшә, чор картинасын, вакыйгалар барган урынны төгәлләү мөмкинлеген булдыра. Системалы оештырылган урын һәм вакыт әдәби әсәрнең «эчке сурәтләнгән дөньясын» (Д. С. Лихачев) күзалларга ярдәм итә. Хронотоп урын һәм вакыт бәйләнешен, кушылу үзенчәлеген бирүдән тыш, М. М. Бахтин билгеләвенчә, аларның образлы чагылышын да өйрәнә.

Әдәби урын һәм вакыт бирелеше Г. Ибраһимов әсәрләрендә дә кызыклы күзәтүләр ясарга мөмкинлек бирә. Язучының «Сөю – сәгадәт» хикәясе 1911 елда язылып, бер елдан соң матбугатта басылып чыга. Композицион яктан 8 бүлектән торган әсәр «Карт шагыйрьнең тәэссораты» дигән аңлатма белән тәкъдим ителә һәм экзистенциализм фәлсәфәсен тулысы белән чагылдыра. Әсәрдә әдәби вакыт һәм урын ике катламга: тышкы (объектив) һәм эчке (субъектив) катламнарга бүленә. Хикәядә әйдәп баручы перцептуаль хронотоп вакыйгаларны үткән, бүгенге һәм киләчәк арасында урнаштыра, геройның «тышкы» һәм «эчке» тәҗрибәләренең синтезы рәвешендә тәкъдим ителә. Хикәяләүче геройның хатирәләренә алып кереп киткән беренче бүлек әсәрдә бирелгән пространствоның төп компонентларын алдан ук билгеләп тә куя шикелле. «*Мин өебезнең бакчага караган тәрәзәсе аркылы зур күл артына батып барган олуг кояшка карап хыялга батам*». Хыял, билгеле булуынча, алга әйдәү көченә ия, чөнки ул киләчәк компоненты буларак карала. Хыялда туган вакыйга һәм күренешләр алга төбәлгән булулары белән янәшә хатирәләр рәвешендә үткәнгә дә әйләнеп кайту сыйфатына ия. Г. Ибраһимовның «Сөю – сәгадәт» хикәясендә борчулы һәм авыр хыял дөньясына чумган Риза исемле герой «Х. туташ»ка бәйле хатирәләрен тергезә. «*Үзем дә, шуңар тәмам бирелеп, иске хатирә дәфтәрен актарган адәм кеби, артта калган күренешләрне актара башлыйм!*» Хикәяләүченең хатирәләре катламында геройның тормышында булган вакыйгалар вакытның төрле юнәлештәге агышына корылган. «*Күз алдыма хәзергедән, үткән вә киләчәктән, буталып, кисәкләнеп, чуалчык күренешләр килә. Мин шунлар эчендә хыялымны байтак әварә кыйлып талдыргач, мием авырып, рухым куәтен азайткач, табигый юл буенча, үткән гомернең төрле күренешләре хыялымда гәүдәләнеп күренә башлый*». Сәгадәтле тормыш мизгелләре үкенү хисләре аша тергезелә. Яшьлекне, «хур кызына биргесез» булып кабул ителгән гади бер туташны сагыну, беренче саф, самими хисләргә сусау геройны бүгенгедән үткәнгә алып кайта.

Чикләнгән вакыт аралыгында хикәяләүче геройның күңел хисләре динамикасы гына түгел, ә фикер үзгәреше дә ачык күренә. «*Кигән кием ничек туза, яшь гомер шулай уза*» дигән җыр юлларын герой хәзерге вакыт ноктасында башкачарак аңлый башлый. «*Шул җырның чын мәгънәсе минә хәзер беленде*». Вертикаль сызыкта яшь гомернең узуы «*май ахырында бөтен тирә-ягына ямь вә хәят биреп утырган чагы белән көз көне актык яфракларын коярга әзерләнгән*» агач һәм хикәяләүче герой арасындагы уртаклыкта да ачык чагыла.

Тормыш кануннарын чагылдыручы реаль урын буларак төнге тынлыгын «заводларның вакыт-вакыт мәгънәсез акыруы» бозган шәһәр билгеләнгән. Әсәрдә кызның «икенче адәмгә билгеләнгән булуы», өзек-өзек штрихлар белән генә сурәтләгән өй эче (бүлмә, «яхут бүлмә», зал, чәй өстәле, мич һ. б.) шул чордагы татар тормышы белән тарихи-мәдәни ассоциацияләр тудыра. Билгеле булуынча, өй – XX йөз башы татар әдәбиятында тормышта күнегелгән тәртипләр, көнитеш, гаиләдәге зәвык һәм культура күрсәткече булып тора (2, 87). Тормыш тәртибен ачыклаучы әлеге ябык пространство Г. Ибраһимовның «Сөю – сәгадәт» хикәясендә романтик рухта, шактый якты буяуларда тәкъдим ителә. Кеше кичерешләренең нечкәлекләрен бирү максатында язылган әсәр тормыш ваклыкларыннан өстен, иҗтимагый кануннардан азат итеп оештырыла.

Өй эчендә геройларның хәрәкәт-гамәлләре пространство һәм кабул ителгән тәртипләр белән чикләнсә дә, мәхәббәтне яшәүнең мәгънәсе дип тәкъдим ителгән хикәядә алар җимерелә. «*Сәгать төнге өч иде. Өйдәге һәммә кеше йоклап беткән. Тик мин дә ул гына. Мин үз бүлмәмдә, ул залында…*». Х. туташның һәр көн кич «пичнең душнигын ачу мәсьәләсе белән бүлмә»гә килеп керүе бөҗраны хасил итүче гадәти-көнкүреш вакыт рәвешен ала. Саналган гамәлләрнең даимилеге вакыт агышын туктата, тарихи барыштан читкә алып китә.

Караватъ Ф. Әмирханның Хәяте өчен хыялга бирелә торган бердәнбер урын булса, «Сөю – сәгадәт»тә хикәяләүче герой өчен бәхетле мизгелләрне татыган урын булып конкретлаша. «*Ачык хәтерләмим, аяк астындагы җирнең каядыр авышып, караватка таба ауганыбызны гына беләм*». Язучы караваты-урынны махсус ассызыклый, чөнки ул җирлек геройлар арасындагы мөнәсәбәтләрне тулыландыруда катнаша. Ризаның туташны асыл чәчәк белән чагыштыруы, аны хур кызына тиң итү серлелекне тагын да арттыра, шәркый әдәбият традицияләренә ярашлы рәвештә сөйгәнен илаһилаштырып, символ дәрәҗәсенә күтәрә.

Вакыт һәм урынның образлы чагылышы буларак тәрәзә, ишек хронотопларын билгеләргә кирәк. Ишек хронотобы тупса хронотобына туры килә һәм геройның нинди дә булса чикне атлап чыгу алдында торуын билгели. Бу очракта яшьләрнең бер-берсенә мәхәббәтен генә түгел, ә пространстводагы күчеш-үзгәреш траекториясенең мәгънә тирәнлекләрен ачарга ярдәм итүче гомумиләштерелгән ишек образы геройларны ачык пространствога алып чыга. «*Язмыш безгә артык рәхимле имеш ки, безгә гали сәгадәтнең*

*ишекләре тәмам ачык иде. Без аның белән бу ишектән кереп, үзебезнең рухларыбыз теләгән һәрбер эшләр белән хәятыбызны илаһи бер рәвешкә сала идек»*. Ишек, тәрәзә хронотоплары ябык һәм ачык пространстволарны тоташтыра, эчке һәм тышкы дөньяны аеручы чик булып тора. Тәрәзә, үз чиратында, кешенең дөньяга карашлары киңлеген, тирә-якны кабул итү үзенчәлеген чагылдырып килсә, ишек – геройларның үзара мөнәсәбәтләрендә башка баскычка күчешне, көндәлек-гадәти проблемаларны калдырып, бары тик мәхәббәт хакына гына яшәүне тормыш фәлсәфәсе итеп тану мизгелен гәүдәләндерә.

Хикәянең 7 бүлегендә вакыйгалар «*шәһәрнең һәртөрле чәчәкләр белән бизәнгән әгъла бакчасы*»ннан *«зур һәм карт урманлы биек таулар*» һәм *«яшел үләннәр, ал-гөл чәчәкләр белән түшәлгән зур, киң тугай»* уртасыннан аккан елгага күчә. *«Шунда төштек тә, уңай бер кимәгә икәү генә утырып, кояш баешына таба карап акрын гына киттек…»* Көймә – бәхетле мизгелне гомумиләштерүче ябык пространство моделе буларак тәкъдим ителә. Сөю ялкынында янучы яшьләрнең аерым микродөньясын булдыру көченә ия итеп сурәтләнгән «кимә», тормыш агымында тыныч кына агучы гаилә моделе белән тиңләшә. Табигатьтәге тынлык тулган айның *«хыялый, мөэссир, ләкин бик мөлаем, гүзәл, шигъри һәм серри төс»*е белән тулыландырыла, сандугач-былбыл сайравы, яшьләрнең бәхет-сәгадәттән туган күңел ярсуы белән алышына. Герой күңелендәге хисләр көчәйгән, киеренкеләнгән саен пространстводагы күчеш тә тизләнә, хронтопның эчке мөмкинлеге тагын да киңәя. Бүлек ахырында хикәяләүче *«Шунда пәрдә төшә»* дип искәртә һәм әсәрдәге вакыйгалар чиген икегә бүлә, үткән һәм бүгенгене «караңгы пәрдә» белән аерып куя.

Хикәянең соңгы бүлеге үткәннәргә тагын бер кат бәя бирә, табигатьнең «шагыйрь вә сентименталист итеп» яратылган бәндәсен хисләр дулкынында йөздерә. Әмма үткәндәге тыныч кына агучы елга урынына күл пәйда була. Хикәяләүченең күңелендә тергезелгән хатирәләрне «ярым сары төстәге күл» (I бүлек) һәм «сары алтын төсенә әйләнгән зур күл» (VIII бүлек) бојрасы каймалап ала. Бер урында торучы сары күл таулы елга агымына каршы куела. Үткәндә ярсыткан шашкын хисләр күл кебек тынып калса да, шагыйрьнең хәтирәләрен җуя алмаганлыгы ачык тоемлана.

Вертикаль проекциянең үзәген кояш тәшкил итә. Әсәрнең башыннан ахырына кадәр язучы «*кояшка карап хыялга бата*», «*хәятын шул кояшка охшата*». Кояш образы белән бергә бакый/фани дөнья оппозициясе кертелә. Кеше гомеренең чикләнгәнлеге дә кояш бату белән чагыштырыла, Мәңгелек бојрасының уртасында торуы аны «олуг кояш» итә, әлеге фикер экзистенциализм фәлсәфәсе кануннары яссылыгында шәрехләнә. «*Ә бәхетле кояш алай түгел: ул чыга, күтәрелә, бата, югала, әмма мәңгегә түгел, – таңда янә чыкмак, дәхи дә ерак күкнең иң гали ноктасына ирешеп, табигатькә үзенең олуглыгын белдермәк, куәт вә матурлыгы белән адәмне үзенә табындырмак өчен генә бата. Ул – туктаусыз; бәлки, мәңге дә шулай әйләнер*».

Әсәр ахырында хикәяләүченең «Сөюдә генә чын сәгадәт!» дигән нәтиҗәсе вакыт киртәләрен җимерә, карт шагыйрьнең генә түгел, ә «гайрәтле егет» Риза авызыннан да әйтелгән хакыйкать кебек яңгырый.

Гомумән, шуны да аерым билгеләп китәргә кирәк, Г. Ибраһимовның 10 нчы еллардагы сәнгатьчә фикерләү үзенчәлеге «Сөю – сәгадәт» хикәясендә ачык тоемлана. «Саф сәнгать» теориясенең чагылышы булган башка әсәрләрнең күбесе өчен ачык пространство (диңгез, печәнлек, ялан-кырлар һ. б.) хас булу язучының «гомуми агымга иярмәгән»леге белән аңлатыла.

Шулай итеп, Г. Ибраһимовның «Сөю – сәгадәт» әсәрендә хронтоп турыдан-туры вакыйгалар барган урын һәм вакытны гына билгеләп калмый, ә аларның образлы берләшүен, язучының эстетик бәясен дә чагылдыра. Хикәядәге әдәби урынның киңлеккә омтылышы, әдәби вакытның субъективлыгы хикәяләүченең фәлсәфи уйлануларына гомумиләштерүләр ясарга мөмкинлек бирә.


ӘДӘБИЯТ

1. Ибраһимов Г. Хикәяләр, повесть, роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – Б. 51–65.
2. Заһидуллина Д., Әминева В., Ибраһимов М. Әдәби әсәр: Өйрәнәбез һәм анализ ясыйбыз: Урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма. – Казан: Мәгариф, 2007. – 112 б.
3. Заһидуллина Д., Ибраһимов М., Әминева В. Әдәби әсәргә анализ ясау: Урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма. – Казан: Мәгариф, 2005. – 111 б.
4. Әдәбият белеме. Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 321 б.
5. Бахтин М. Формы времени и хронотопа в романе // Вопросы литературы и эстетики. – М., 1975.


# ҒӘЛИМЙӘН ИБРАҺИМОВ МЕНӘН РИЗА ФӘХРЕТДИНОВ:
## фекерҙәш һәм теләктәш замандаштарҙың осрашыуына ҡарата


***Н. Ә. Хөббитдинова (Өфө)***



В статье речь идет о встрече национального писателя, общественного деятеля и ученого Г. Ибрагимова с уфимским муфтием, теологом и ученым Р. Фахретдиновым в Казани. Их объединяли общие проблемы, связанные с наукой, религией, исламским образованием, взлету и упадку которых они были свидетелями. Во время встречи двух деятелей в 1925 г. обсуждались вопросы, связанные с состоянием и преспективой развития ислама, науки, образования в национальных регионах на фоне происходящих социально-политических перемен в стране.


XIX быуат аҙағы – XX быуат башындағы Башҡортостан мәҙәниәте үҫешендә, бер яҡтан, ҡатмарлы ҡаршылыҡтар, икенсе яҡтан, оло уңыштарға ҡаҙаныштар күҙәтелде. Дөйөм Рәсәй һәм Башҡортостандың (ул ваҡытта республика биш губерна составына ингән ер була) сәйәси, иҡтисади ҡоролошо, уларҙың үҙгәрештәре һәм үҫештәре фонында ерле башҡорт мәҙәниәтенең, мәғрифәтенең хәле бик үк яҡшы булмай.

Унда әле «консерватив, клерикаль мөхиттең көсләп тыңҡысланыуы», «белем кимәленең түбән булыуы», «артта ҡалыуы» кеүек етешһеҙлектәр күҙәтелә (2, 27).

Быңдай артта ҡалыуҙың төп сәбәбе булып батша хөкүмәтенең сәйәси маҡсаты – рус булмаған башҡа милләттәрҙе (шул иҫәптән башҡорт менән татарҙы ла) урыҫлаштырыу, уларҙы үҙ-ара сәкәштереп, дошманлаштырыу, уларға ҡарата оло державалы – шовинистик сәйәсәтте йүнәлтеп, киңәйтеп ебәреү – торҙо.

Әлеге ҡаршылыҡлы сәйәси-иждимағи ваҡытта, халҡыбыҙҙың мәҙәниәте, мәғрифәте ҡатмарлы осор кисерһә лә, шул уҡ мәлдә, унда бер ни тиклем үҫеш, үҙгәрештәр, алға китеш саҡҡылдары күренгеләп ҡала. Ошондай саҡ һиҙелерлек үҙгәреш-үҫештәрҙе ортодоксаль ҡарашлы официаль дин әһелдәре, руханиҙары аҫтына ташлап тапарға, юҡҡа сығарырға тырышты. Быңдай алыш-тартыш, көрәш, бигерәк тә, мәғрифәт тармағында көслә булды. Ҡаты көрәш һөҙөмтәһеҙ булмай ҡалмай. Өфө һәм Ырымбур губерналарында байтаҡ рус-башҡорт, 800-гә яҡын мосолман мәктәптәре һәм мәҙрәсәләре асылған була (2, 27). Ундай мәғрифәт усаҡтарында уҡытыу эше тәүҙә тик дини схоластик-догматик рәүештә булһа, һуңғараҡ уның программаһына өҫтәп рус теле лә индерелә башлай.

XIX быуат башында үҫеш юлынан алға тәгәрәгән тормош мәғрифәттә яңыса уҡыу-уҡытыу реформаһын талап итә ине. Мәҙрәсәләрҙә әүәлгесә уҡытылып килгән ҡатмарлы, сыбар-сыбар ғәрәп, фарсы графикаһы урынына балаларға тыумыштан яҡын һәм таныш булған туған телендә йәҙит методы буйынса уҡыу-уҡытыу эше йәйелдерелә. Ғалим Б. Юлдашбаев асыҡлағанса, Октябрь революцияһына тиклем үк тарихи Башҡортостандың мәҙрәсә һәм мәктәптәренең 53% яңы йәҙит методын үҙләштергән була (7, 210). Йәҙитселек методы буйынса уҡытҡан «Ғәлиә» мәҙрәсәһе сығарылышының юғары кимәлдә булыуы шуға дәлил булырлыҡтыр. Унан М. Ғафури, Ғ. Ибраһимов, Ш. Бабич, З. Йәрмәш, Х. Туфан, Б. Ишемғол кеүек һәм башҡа күренекле шағирҙар һәм уҡытыусылар, дәүләт һәм йәмәғәт эшмәкәрҙәре сыға.

Йәмғиәттең алға китеше мәҙәниәттең үҫеше менән тығыҙ бәйле. Прогрессив үҙгәрештәр бигерәк тә яҙма әҙәбиәттә сағыла. «Быға тиклем күп быуаттар буйына ҡатнаш-синкретик формала һәм айырым, үҙаллы төрҙәр булараҡ художестволы проза менән драматургия майҙанға сыға, яңы жанр һәм жанр формалары ярала һәм үҫешә башлай ... реалистик һүрәтләү көсәйә, йәмғиәт һәм ... халыҡ тормошондағы көнүҙәк проблемаларға иғтибар арта һәм башҡа яңылыҡтар күҙәтелә» (4, 19). Урта быуаттарҙа һәм унан һуңғараҡ йылдарҙа яҙма әҙәбиәткә хас булған көнсығыш әҙәбиәте традициялары, абстрактлығы, дөйөмләлөгө индивидуальлеккә, конкретлыҡҡа, романтизм менән фантастиканан реальлеккә ынтылыштар көсәйә.

Халҡыбыҙҙың мәҙәниәте, мәғрифәте торошоноң яңырыуы, үҫешенең башында тороусы, уҡыу-уҡытыуҙа йәҙитселек алымын алға һөрөүселәрҙең береһе булған Ризаитдин бин Фәхретдиновтың (1859–1936) эшмәкәрлеге әйтеп бөткөһөҙ оло мәғнәгә эйә. Ғүмере буйына дин, фән, әҙәбиәт, мәғрифәт, тип янып йәши, уларҙы үҫтереүҙә, мәсьәләләрен хәл итеүҙә янып-көйөп фиҙаҡәр хеҙмәт итте ул. Һөҙөмтә булараҡ байтаҡ ғилми, дини һәм тәрбиәүи китаптары һәм махсус мәҡәләләре ижад ителде (күп томлы «Аҫар», «Ислам хаҡында хөкүмәт тәҫбирләне», «Нәсихәт», «Тәрбиәле ана», «Мәшһүр ирләр», «Әһле-ғыял», «Ғаҡидә», «Әдәбе тәғлим», «Ибне Тәймиә», «Шәкертлек әдәбе», «Мөхәммәд», «Имам Ғазали», «Тел ярышы», «Ибн Фаҙландың Болғарға килеүе», «Шәйех Зәйнулла хәҙрәттең тәржемәи хәле» һ. б.).

Тормош юлында Р. Фәхретдинов төрлө ғалимдар, әҙиптәр, йәмғиәт эшмәкәрҙәре менән осрашып, фекерҙәш була, улар менән яҡындан аралашыуҙа үҙенә рухи көс, осар ҡанат алғандай хис итә. Шаһабетдин Мәржәни, шәйех Ямалетдин әл-Афғани хәҙрәт, М. Өмөтбаев, М. Аҡмулла, Зәйнулла ишан Рәсүлев ише һәм башҡа байтаҡ шәхестәр араһында Гәлимйән Ибраһимов та бар ине.

1925 йылда дин, мәхкәмә хоҡуҡтары хаҡында килешеү кеүек мөһим мәсьәләләрҙе Мәскәүҙә хәл итеп ҡайтып килешләй Р. Фәхретдинов Ҡазанда туҡталып китә. Унда Татарстан Академияһы үҙәге рәйесе, оло әҙип һәм ғалим Ғәлимйән Ибраһимов (1887–1938) менән осраша.

Әҫәрҙәрендә күбеһенсә синфи көрәш, революцион хәрәкәт, шул дәһшәтле йылдарҙа геройҙың сынығыуы кеүек картиналар, проблемалар яҡтыртылһа ла, Ғ. Ибраһимов дин белгесе, ғалим һәм мөфтөй Р. Фәхретдинов менән ярайһы уҡ ихлас әңгәмәләшә, уны ихтирам итә. Сөнки мөфтөй дин әһеле генә түгел бит, ул шулай уҡ эҙләнеүсән оло ғалим да, байтаҡ баҫмалар, китаптар авторы ла; фәнгә булған мөхәббәт уларҙы берләштерҙе, дуҫлаштырҙы.

Тик был осрашыу мәлендә уларҙың барыһы менән бер рәттән мәғрифәт, бигерәк тә, дин мәсьәләләренә нығыраҡ туҡталыуҙары мәғлүм. Билдәле булыуынса, XX ғасырның 20–30-сы йылдарында илдә коллективлашыу, индустриаллашыу процессы эре аҙымдар менән атлаған осорҙа дингә, дин әһелдәренә, ғибәҙәт ханаларға (мосолман булһынмы, христианмы), уҡыу йорттарына ҡараш ҡырка кире яҡҡа үҙгәрә, уларҙан арыныу эше йәнләндерелеп, хатта киҫкенләшеп китә. Илебеҙҙең Ислам донъяһында күпләп мәҙрәсәләр ябыла, мәсеттәр йә емерелә, йә уның нигеҙендә, бинаһында берәй ойошма ойошторола. Дини йәки ғәрәп, иҫке төрки графикаһындағы төрлө дини, донъяуи яҙмалар юҡ ителә һ. б. Ошоларҙың барыһы ла Р. Фәхретдиновты нығыраҡ борсой ине ул осорҙа. Ошо борсолоуҙары менән ул үҙен яҡын күргән, ихтирам иткән Г. Ибраһимов менән уртаҡлаша. Һуңғыһы уны бик тә яҡшы аңлай ине, әлбиттә, мөфтөйҙөң тойғолары уның өсөн дә ят булмауын белдерә.

Ғ. Ибраһимовтың ғүмере Октябрь революцияһы, граждандар һуғышы йылдарына тура килә. Ул шул дәһшәтле осорҙа сыныҡҡан, нығынған, сәйәсәткә ҡарата аңлы ҡарашы, идеялылығы формалашҡан һәм үҫешкән шәхес булараҡ күҙаллана. Уның әҙәби ижады иһә, шул быуын яҙыусыларына хас булғанса, ана шул утлы-ялҡынлы ваҡиғаларҙың, социаль күренештәрҙең сағылышы булды.

Тап шул осорҙа байтаҡ ижад иткән хикәйәләр шуға миҫалдыр: революцион күтәрелеш менән бергә уның рухи, ижади донъяһында ла күтәрелеш күҙәтелә. 1910–16 йылдарҙа «Яҙ башы», «Диңгеҙҙә», «Уты һүнгән жәһәннәм», «Сөю – сәғадәт», «Мәрхүмдең дәфтәренән» һ. б. әҫәрҙәре ижад ителә.

Йәш быуындың иҫке тормошҡа ҡаршы көрәшен һүрәтләп, 1912 йылда татар әҙәбиәтендә беренсе

психологик роман яҙа. Шулай уҡ, уның «Йәш йөрәктәр» (1912), «Беҙҙең көндәр» (1914–1919) ишеләре татар әҙәбиәтенең Октябрь революцияһына хәтлем үк өлгәшкән уңыштары булып иҫәпләнә (3, 223).

Революцион хәрәкәттәр, большевиктарҙың йәшерен көрәше, ул эшкә йәш быуындың килеүе – быларҙың барыһы ла Ғ. Ибраһимов ижадына төрлө актив көрәшсе геройҙар, сәйәси һәм социаль шаңдауҙар рәүешендә килеп инә. Хәҙер инде ул әүәлге романтик кисерештәр, тойғоларҙан арынып, революцион көрәш ялҡынына ташлана. Элекке «Йәш йөрәктәр»ҙән айырмалы рәүештә, «Беҙҙең көндәр»ҙә инде хәҙер ғәйрәтле, сәйәси идея яғынан аяҡтарында ныҡ торған, социалистик киләсәк өсөн йәнен бирергә әҙер булған шул осор өсөн актуаль төҫ алған герой хәрәкәт итә. Был роман, шул осорҙағы тормоштоң күп яғын сағылдыра: бер яҡтан, иҙелгән массалар самодержавияға ҡаршы сығыш яһай, икенсе яҡтан, буржуазия феодалдарға ҡаршы тора, өсөнсө яҡтан, йәш шәкерттәр иҫкесә уҡыу-уҡытыу методынан арыныу юлын эҙләй.

1905-се йылғы революциянан һуң 1917 йылғы Социалистик революция алдынан, башҡорт, татар яҙыусылары ижадына хас булғанса, Ғ. Ибраһимовтың да әҫәрҙәрендә ошо дәһшәтле ваҡиғалар, унда ҡайнаған әлеге яңы көрәшсе герой художестволы сағылыш тапты. Яңы осор яңы әҫәр, яңы герой талап итте.

Ғ. Ибраһимов әҙәби ижад менән бер үк ваҡытта сәйәси-ижтимағи эшмәкәрлек менән дә булыша. Революциянан һуң Милли халыҡ комитеты янындағы Мосолман комиссариатының рәйесе урынбаҫары булып эшләй. Шул йылдарҙа ул В. И. Ленин менән осраша.

1918 йыл аҙағында Татарстан Академияһы үҙәге рәйесе булып эшләй. «Беҙҙең юл», «Мәғариф» ише ғилми, педагогик журналдарҙы нәшер итеү эшендә ҡатнаша. Ошо эштәре уның ижады эшмәкәрлегенең күтәрелеүе менән тап килә («Ҡыҙыл сәскәләр» (1922), «Алмачуар» (1922), «Ҡаҙаҡ ҡыҙы» (1924), «Тәрән тамырҙар» (1926).

Әҙәби ижад, йәмғиәт эштәре менән бергә Ғ. Ибраһимовтың фән өлкәһендә байтаҡ хеҙмәттәре лә юҡ түгел. Ул лингвистика, филология, тарих, әҙәбиәт ғилеме кеүек фәндәр буйынса мәҡәләләр, хеҙмәттәр авторы («Татар теленең грамматикаһы», «Татар орфографияһы принциптары», «Әҙәбиәт теорияһы», «Туған телде уҡытыу методикаһы», «Бөйөк Октябрь революцияһы һәм пролетариат диктатураһы», «Татар шәкерттәренең хәрәкәте тарихы», «Татарҙар араһындағы революцион хәрәкәт» һ. б.).

Ошондай күп яҡлы файҙалы, мөһим эшмәкәрлеге өсөн 1928 йылда Ғ. Ибраһимовҡа «Хеҙмәт ветераны» исеме бирелә.

Яулы-дауыллы, ҡанлы-һуғышлы дәүер кисереп, ижтимағи-сәйәси, әҙәбиәт, тарих, тел фәндәре өлкәләрендә оло уңыштарға өлгәшкән шәхес, әлбиттә, тик тыныс оҙон ғүмергә, артабан емешле хеҙмәткә лайыҡ ине. Тик 30-сы йылдарҙа илебеҙҙе йолмап алған репрессиялар шауҡымы байтаҡ аҡыл эйәләрен, милли интеллигенцияны һәләкәткә дусар иткән кеүек, Ғ. Ибраһимовты ла урап үтмәне.

Ул йылдарҙа төҙөкләнеп килгән яңы тормошто тағы ла яҡты һәм тыныс итеү урынына, уның нығынып барған тамырҙары балта менән сабыла. Революция, иркен тормош өсөн даулашып, шуның хаҡта художестволы әҫәрҙәр ижад итеп, милли әҙәбиәт, сәнғәт нигеҙҙәрен һалыусы яҙыусыларҙың ғүмере ошо балта аҫтында ҡалды. Ғәлимйән Ибраһимов, үҙенә яғылған башҡа «енәйәт эштәре» менән бер рәттән, «билдәле контрреволюционер Р. Фәхретдинов менән килешеп, уны йәшерен рәүештә өйөндә ҡабул итеүендә лә» ғәйепләнеп, ғүмере фажиғәле өҙөлдө (6, 3).

Хәйер, мөфтөйҙең үҙенә был ҡот-осҡос «таҙартыуҙар» осоронда зыялы замандаштарының күпләп һәләк булыуына шаһит булмау «бәхете тейә».

Шулай итеп, Р. Фәхретдинов менән Ғ. Ибраһимов бер заман һауаһын һулаған, бер ҡараштa фекерҙәш булған, башҡорт һәм татар мәҙәниәтендә тәрән эҙ ҡалдырған шәхестәр ине. Уларҙың ғилми-әҙәби, дини әҫәрҙәре, китаптары, күҙәтеүҙәре бөгөнгө көндә үҙ баһаһын тапты, бөгөнгө фәндә айырым тема, проблема булараҡ өйрәнелә, тикшерелә, ташҡа баҫтырылып донъяға сығарыла. Шуның менән уларҙың исемдәре, хеҙмәттәре мәңгелләштерелә.

ӘҘӘБИӘТ


1. Башҡорт әҙәбиәте тарихы. Т. 2. – Өфө: Китап, 1990. – 280 б.
2. Баишев Ф. Н. Общественно-политические и нравственно-этнические взгляды Ризы Фәхретдинова. – Уфа: Китап, 1996. – 176 с.
3. Гайнуллин М. Татарская литература и публицистика. – Казань, 1983. – 352 с.
4. Научное наследие Р. Фәхретдинова и актуальные проблемы Востоковедения // Материалы республиканской научной конференции. –Уфа, 2001. – 148 с.
5. Ибраһимов Ғ. Тәрән тамырҙар. Роман, хикәйәләр. – Өфө: Баш. кит. нәшр., 1987. – 280 б.
6. Султанбаев Б. Олинцев М. Несколько эпизодов из жизни муфтия // Наука и религия. – 1990. – № 1. – С. 3–5.
7. Юлдашбаев Б. Х. Из истории духовного формирования башкирской нации до Октябрьской революции // Ученые записки Башкирского Государственного Университета. Вып. 35. – 1968. – № 7. – С. 210–229.


## Г. ИБРАҺИМОВ ҺӘМ Г. ТУКАЙ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ ТУРЫНДА


*А. М. Гайнетдинов (Казан)*



В статье сообщается о воспоминаниях, написанных татарским поэтом и писателем Зарифом Башири. Он был современником Г. Ибрагимова и Г. Тукая и хорошо знал их обоих. Впервые дается содержание этих воспоминаний, выявляется причина конфликта, возникшего между Г. Ибрагимовым и Г. Тукаем.


Белгәнебезчә, Г. Ибраһимов белән Г. Тукай арасында үзенә күрә бер каршылык була. Г. Ибраһимов башта Тукайны чын шагыйрь дип санаса да, соңыннан аңа карата мөнәсәбәте кискен үзгәрә. Тукайның һәр китабына ул тискәре бәя биргән рецензияләр яза башлый. 1911 елда чыккан мәкаләсендә Г. Ибраһимов аны сүнгән

шәм белән чагыштыра. 1913 елда чыккан «Татар шагыйрьләре» китабында хәтта «Тукай шагыйрьме, юкмы?» дигән сорау куя. Моңа турыдан-туры җавап бирмәсә дә, аны шагыйрьгә санамавын бик ачык күрсәтә (1, 215). Г. Тукай үзе дә аңа төрле фельетоннар, шигырьләр белән җавап бирә.

Алар арасында туган каршылыкларның сәбәбен Ибраһимовның әдәби-эстетик карашларында, төгәлрәк әйткәндә, Белинскийларга ияреп, поэзияне башка төрле аңлавында, лирикага билгеле бер таләпләр куюында күрәләр. Һәрхәлдә, күп гомерен Тукайны өйрәнүгә багышлаган И. Нуруллин моны шулай аңлата (1, 214). Г. Ибраһимовны өйрәнгән галим М. Хәсәнов та аның әдәби-эстетик карашларындагы җитди каршылыклар, хаталар һәм Тукай иҗатына тенденциоз мөнәсәбәттә булуыннан килеп чыккан, дип аңлата. Г. Ибраһимов белән Тукай арасындагы мөнәсәбәтләр хакында тарих безгә тулы мәгълүматлар калдырмаган һәм ул турыда аларның замандашларының истәлекләрендә дә бөтенләй диярлек әйтелмәвен искәртә (2, 56–57). Ләкин Г. Ибраһимов белән Г. Тукайның замандашы З. Бәшири хатирәләрендә аларның мөнәсәбәтләре, араларының ни өчен бозылуы турында мәгълүматлар бар. З. Бәшири бу ике әдип арасында туган каршылыкларның сәбәбе башкада икәнлеген исбатларга тырыша, Г. Ибраһимовның әдәби-эстетик карашларының монда бөтенләй катнашы юк дигән фикердә тора (3, 3). Аның бу турыда язылган истәлекләре беркайда да басылмаган. Алар Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә З. Бәширинең фондында саклананалар.

Зариф Шәрәфетдин улы Бәширинең шәхесенә килгәндә, ул шагыйрь, прозаик, журналист, педагог буларак билгеле. 1888 елның 5 маенда элекке Казан губернасы, Чуел өязе (хәзерге Татарстан Республикасының Кайбыч районы), Чүти авылында мулла гаиләсендә туа. Башлангыч белемне этисеннән ала. 1898–1902 елларда Буа мәдрәсәсендә, аннан соң Акъегет авылы мәдрәсәсендә укый. З. Бәшири 1907 елда Казанга килеп, «Мөхәммәдия»дә белем ала (4, 44–45). Ул үзе Г. Тукай белән дә, Г. Ибраһимов белән дә якыннан таныш була.

1968 елда З. Бәширинең «Замандашларым белән очрашулар» исемле китабы басылып чыга. Анда Г. Тукай һәм Г. Ибраһимов хакында байтак истәлекләр тупланган. Әмма бу китапта аларның аралары ни өчен бозылуының сәбәбе әйтелми. Бәлки, алар билгеле бер сәбәпләр аркасында кертелмәгәннәрдер дә. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклаучы истәлекләрдә тулысынча Г. Ибраһимов белән Г. Тукай каршылыкларының сәбәбе ачыла. Эш болай булган: бервакыт Г. Ибраһимов «Матбагаи Шәрәф» нәшире Гыйльметдин Шәрәф белән ачуланыша һәм аларның низаглары судка кадәр барып җитә. Нәтиҗәдә, Третейский суд эшне Гыйльметдин Шәрәф файдасына хәл итә, Г. Ибраһимовны гаепләп карар чыгара. Моны белгәч, Г. Тукай: «Бик әйбәт булган, шулай кирәк аңа», – дип әйтеп куя. Аның янында утырган Фатих Әмирхан да иптәшен хуплап: «Әлбәттә», – ди. Г. Ибраһимов шул сүзләрне ишеткәннән соң, аларның нинди нигездә, нинди карашта әйтелүләрен тикшереп тормыйча: «Димәк, Г. Тукай белән Ф. Әмирхан да әнә шуны яклый икән», – дип ачуы чыга. Хәтта эш йодрыкка да барып җитә яза. Шул вакыйгадан соң, Г. Ибраһимов, уңае туры килгән саен, Г. Тукайның иҗатын кимсетеп сөйли башлаган, дип яза З. Бәшири (3, 1).

Гыйльметдин Шәрәф – күренекле шәхес. Ул 1906 елда Казанда «Матбагаи Шәрәф» типографиясен ача һәм китаплар бастыра башлый (4, 225). Аның типографиясендә Г. Тукай, М. Гафури, Ф. Әмирхан, Г. Камал, С. Рахманкол, Х. Ямашев һәм башкаларның китаплары дөнья күрә. Г. Тукайның гына анда ундүрт китабы чыга (5, 274). 1912 елда Казан губернаторы типографияне алдынгы идеяләр чагылдырган әсәрләр бастырганы өчен яба (4, 225). Гыйльметдин Шәрәф күренекле китап бастыручы булганга, аның белән Г. Ибраһимов арасында, бәлки, китап бастыру мәсьәләсендә низаг чыккандыр, дип чамаларга мөмкин. Кызганычка каршы, безгә бу хәлнең бөтен нечкәлекләре билгеле түгел. Фәкать 1910 елда булганлыгы гына мәгълүм.

З. Бәширинең «Замандашларым белән очрашулар» исемле китабында да әлеге Третейский суд турында бераз сөйләнелә. Аннан аңлашылганча, Бәшири суд булган вакытта Казанда булмый, шуңа күрә аның ни сәбәпләр аркасында булуын хәтерләми. Казанга кайткач, ул Г. Ибраһимов белән беренче очрашуында ук аннан бу хәл турында сораша. Тегесе исә бу хөкем карары белән риза булмавын, үзенең хаклы икәнлеген сөйли (6, 182). Третейский судта рәис зур урынны тоткан, ул кайсы якка тавыш бирсә, шул як җиңгән. Әмма ул ике тарафның да ризалыгы белән генә билгеләнгән. Әлеге Третейский судта рәис итеп Уфа морзаларыннан Ибнеямин Әбүсогуд улы Әхтәмев сайлана. Ул хокук белгече, сәясәт эшлеклесе буларак мәгълүм. 1910 елда Петербург университетын тәмамлап Казанда һәм Уфада антлы вәкил ярдәмчесе һәм антлы вәкил булып хезмәт итә башлый (7, 249). Г. Ибраһимовка бу кеше гадел, укымышлы булып тоела, шуңа күрә аның рәис булуына каршы булмый. Бәлки, Ибнеямин Әхтәмев якташы булганга, суд эшен үз файдасына хәл итәр, дип уйлагандыр. Соңыннан Г. Ибраһимов аны сайлаганына бик нык үкенә, ялгышканын аңлап: «...Ә мин, ачык авыз, сәяси аңымның тарлыгы аркасында, «карганың күзен карга чукымаганлыгын» аңламаганмын!..» – дип үз-үзен битәрли (6, 182–183).

Шулай ук Г. Ибраһимов әрнеп З. Бәширигә түбәндәге сүзләрне әйтә: «Син күрсәң иде, бу суд Аитов, Апанаев, Әхмәрев кебекләр өчен шундый шатлыклы бер бәйрәм булды, алар шатлыкларыннан нишләргә дә белми, бөтенләй чигеннән чыгып киттеләр. Башта ук судка җыелып килгән адәмнәр, хөкем карары укылгач та, кул чабып, миннән көләргә, мыскылларга керештеләр...» (6, 183). Шуңа күрә Г. Тукайның да бу мәсьәләдә аңа каршы булуын, якламавын Г. Ибраһимов бик авыр кичерә һәм бик каты үпкәли.

З. Бәшири язганча, бу вакыйгага хәтле Г. Ибраһимов Г. Тукай иҗатына чиксез дәрәҗәдә зур бәя биргән, аңа зур хөрмәт баглаган. М. Гафури иҗаты турында сүз кузгалганда: «Аның шигырьләрен Г. Тукай шигырьләре янына куйган чагында, художество ягыннан да, эшләнеше ягыннан да бер нәзым-бәет, такмак булып калалар», – дип әйтә торган булган (3, 2). Әмма Г. Ибраһимов үзе тәнкыйть мәкаләләрендә, киресенчә, Тукайның нәзым язуын ассызыклый (8, 54). М. Гафури белән Дәрдемәндне күкләргә күтәреп мактавы фәкать Г. Тукайдан үч алуы гына, ди З. Бәшири. Гарәпләрдә бер мәкаль бар: «Лә лихөбби Гали, бәл либәгдый Мөгавия»,

ягъни «Минем Галине яклавым аны яратканлыктан түгел, ә, бәлки, аның дошманы булган Мөгавиягә ачудан». З. Бәшири бу мәкальне нәкъ менә Г. Ибраһимовка карата куллана (3, 3).

З. Бәшири сүзләренчә, ачуланышканчы Г. Ибраһимов еш кына Г. Тукай янында булган. Алар иҗат хакында фикер алышканнар, бер-берсе белән киңәшләшкәннәр. Мәсәлән, Г. Тукай «Мияубикә» әсәрен язып бетергәннән соң, аңа нинди исем бирү турында Г. Ибраһимовтан киңәш сорый. Тегесе исә «Песи Гөлҗамал» дип атарга киңәш бирә. Ләкин Тукай: «Монда мин бит песине матур гөлләргә ошатып, аны җәмал-зиннәткә чумган бер кош итеп тасвир итмимен, Галимҗан әфәнде», – ди. Ягъни әсәрнең исемен аның эчтәлегенә каратып куярга кирәк, дип әйтә. Шуннан соң Г. Ибраһимов Тукайның әдәбият мәсьәләсендә искитмәле тапкыр уйлавын сөйләп, аны мактап ала. Галимҗанның бу сүзләре һаман да исемнән чыкмый әле, дип яза З. Бәшири. Ләкин, шуңа карамастан, Г. Ибраһимов «Мияубикә» әсәрен тәнкыйтьләп чыга. Ул аны хәтта бу шигырь түгел, ә нәзым гына, дип әйтә. Ул бу әсәрнең фазыйләтен бары телендә генә күрә. Шулай ук Тукайны башка әһәмиятлерәк нәрсәләр өстендә эшләмичә, «мәктәп баласы өчен» әсәрләр язып мавыгуын тәнкыйтьли (8, 54–55).

З. Бәшири үзенә Зөһрә ханым Гафури сөйләгән бер кызыклы вакыйганы искә ала. М. Гафури үлгәннән соң, аның хатыны Зөһрә Кырымга Г. Ибраһимовны күрергә бара. Бераз эче пошкан яисә кәефе күтәрелгән чакларда Зөһрә ханым җырлап йөрергә яраткан. Монда да шулай Г. Ибраһимов янында Тукай шигырьләрен җырлап ала. Тегесе исә: «Нәрсә, син, һаман да Тукай такмакларын җырлыйсың? Нигә Гафури шигырьләрен түгел?» – дип канәгатьсезлеген белдереп сорый. Зөһрә ханым аңа түбәндәгечә җавап бирә: «Гафури миндә Тукай шигырьләренә бөтен яктан да мәхәббәт тойгысы тәрбияләде һәм ул Тукай шигырьләренә, үзенекенә караганда, күбрәк югары бәя бирә иде. Мин шушы тәрбия аркылы туган карашларымнан аерыла алмыйм!» Г. Ибраһимовка шулай җавап бирүен белгәч, З. Бәшири: «Телең белән картай», дип сөенеп аның кулын кыса (3, 4).

Гомумән, З. Бәшири, заманында үзе дә Тукай белән дошманлашуына карамастан, бу очракта тулысы белән Тукай яклы булуын, аны Г. Ибраһимов юкка, нигезсез гаепләвен күрсәтә.

Г. Ибраһимовның үзенә каршы әйтелгән сүзләренә, фикерләренә Г. Тукай «эт өрер, бүре йөрер» дигән сыман караган. Г. Ибраһимовка һәм аның иҗатына карата бер генә төрле дә кимсетеп карау моментларын күрсәтми, һәрхәлдә, З. Бәшири мондый хәлләрнең булганын белми.

З. Бәшири Тукай янына килеп: «Чынлап та, син, Третейский судның Галимҗан зарарына нәтиҗәләнүен хуплап, әнә шундый сүзләр әйттеңме?» – дип сорый. Тегесе исә: «Әйе, әйттем. Һәм әле дә шулай әйтәм, моннан соң да әйтәчәкмен. Әгәр дә мәсьәләгә дөрес карау ниятендә булсагыз, сез дә, Нәҗип тә, Вәли дә, Гали дә, Әмин белән Мөхәммәдәмин дә шулай әйтергә тиешле», – дип җавап бирә.

Тукай Г. Ибраһимовның аңа каршы кылган гамәлләренә бары балалык дип караган. Чөнки Тукай Бәширигә: «Галимҗанның әнә шулай судлашып йөрүләренә “балалык” дип караган шикелле, минем сүзләремнең төп нигезен аңламастан, артык шәхсияткә бирелүенә дә “балалык” дип кенә карыйм», – дип әйтә.

Шунысын да искәртеп узмыйча булмый, З. Бәширинең «Замандашларым белән очрашулар» дигән китабындагы мәгълүматлар, вакыйгалар чынбарлыкка туры килмиләр, дип әйтүчеләр дә була. Мәсәлән, С. Кудаш китап авторының Г. Тукай, М. Гафури, Г. Ибраһимов һ. б. хакындагы истәлекләрне оятсыз рәвештә ялганлап язуын кабул итә алмый, чөнки ул үзе бу вакыйгаларның шаһиты була. Әдәбият галиме Гали Халит, аның сүзенә карамыйча, З. Бәширинең бу китабын бастырып чыгара. Бу турыда С. Кудаш белән Хәсән Туфан хатларыннан белеп була. Хәсән Туфанның да шул ук фикердә булганлыгы мәгълүм. З. Бәширинең китабын чыгармауларын сорап ул нәшриятка да бара. Дусты С. Кудашка 1968 елда язган бер хатында Х. Туфан түбәндәге сүзләрне яза: «Татиздатка барып фикерләребезне, тулысынча синең якта икәнебезне әйттек. Аерым-аерым кереп тә сөйләшеп карадык. Бәширинең оятсыз, битсез уйдырмаларын шул хәлендә халыкка чыгару әдәбиятка нәҗес сылау булганын да әйттек. Ләкин бәла Бәширине әзерләүгә байтак акча сарыф итеп өлгергән бәндәләр: “Расходны ничек капларга? Димәк, чыгармый булмый. Барын да искә алып төзәтеп чыгарабыз”, – диләр» (9, 1). Шулай ук: «...Бу эштә төп гаеп Гали Халиттә, әлбәттә. Мин аның Бәшири нәҗесләренә кул тыгуына, үз исемен пычратуына шаккатам. Халиткә (ягъни Гали Халиткә. – *Г. А.*) мин “Әдәбиятка килгән елларында без сине Белинский кебек тугры булачак бу, дип уйлаган идек. Белинскийның Булгариннарны – Пушкин дошманнарын редакцияләве һич мөмкин булмаган нәрсә. Ә син Тукай дошманы Бәширине редакцияләп, кул пычрату түбәнчелегенә төштеңме, энем!?” – дип записка язып җибәрдем» (9, 2). Бәлки, шул сәбәпләр аркасында, З. Бәширинең Г. Ибраһимов белән Г. Тукай каршылыклары турындагы истәлекләре беркайда басылмыйча калганнардыр.

Ничек кенә булмасын, архив фондларында сакланган истәлекләрне дөрес түгел, дип уйлап, аларга игътибар бирмичә, өйрәнмичә торырга безнең хакыбыз юк. Җәмәгатьчелек алар белән таныш булырга тиеш.

## ӘДӘБИЯТ


1. Нуруллин И. З. Тукай / Авториз. пер. с тат. Р. Фиша (Жизнь замечат. людей. Серия биографий. Вып. 5 (568). – М.: Молодая гвардия, 1977. – 240 с.
2. Хәсәнов М. Х. Галимҗан Ибраһимов. Тормыш һәм иҗат юлы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1964. – 332 б.
3. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге: 57 ф., 1 тасвир., 58 сак. бер.
4. Бәширов Ф. Зариф Бәшири // Татар әдипләре, мәгърифәтчеләре (ХХ йөз башы). – Казан, 2005. – 276 б.
5. Айди Т., Гарифуллин Д. Знатные люди из села Аксу // Эхо веков = Гасырлар авазы. –2010. – № 3/4. – С. 270–274.
6. Бәшири З. Замандашларым белән очрашулар (Язучы истәлекләре). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1968. – 292 б.
7. Татарская энциклопедия: в 5 томах / Гл. ред. М. Х. Хасанов, отв. ред. Г. С. Сабирзянов. – Казань: Институт Татарской энциклопедии АН РТ, 2002. – Т. 1: А–В. – 672 с.
8. Галимҗан Ибраһимов. Әсәрләр: 8 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – Т. 5. – 616 б.
9. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге: 133 ф., 3 тасвир., 292 сак. бер.

# ИСТӘЛЕКЛӘРДӘ Г. ИБРАҺИМОВ ШӘХЕСЕ

*Д. М. Абдуллина (Казан)*

Путем анализа воспоминаний о Г. Ибрагимове в данной статье выявлены его личностные особенности.

Г. Ибраһимов халкыбыз тарихында, аның мәдәни үсешендә күренекле урын биләп торган шәхес. Аның тормышы, иҗаты, иҗтимагый эшчәнлеге турында инде күп язмалар дөнья күрде. Аларның күбесе фәнни нигездә, аерым бер максатны күздә тотып эшләнгән хезмәтләр. Шулай ук, болардан тыш, әдипне нәкъ тормыштагыча, үз күзләре белән күргәнчә, ихлас күңелдән гәүдәләндергән истәлек язмалары да бар. Боларда инде Г. Ибраһимовның шәхесе, аның табигате, холкы, тормышы һәм фаҗигасе тагын да ачыграк, яктырак гәүдәләнеш ала.

Г. Ибраһимов турында истәлекләр – аның белән турыдан-туры аралашкан, хезмәттәш булган, очрашкан шәхесләрнең, туганнары һәм якыннарының язмалары бергә тупланып китап рәвешендә ике тапкыр дөнья күрде. Аның беренчесе шәхес культы тудырган авыр заманннар үтеп, әдипнең исеме кабат халкыбызга кайтарылган елларда – 1966 елда басылган иде. Бу гаять игелекле эшне Афзал ага Шамов эшләде. Бу хезмәтнең отышлы ягы шунда: ул Г. Ибраһимовны белгән, аның белән аралашкан кешеләр әле безнең арабызда шактый күп булган чорда туплана. Димәк, материал туплау һәм сайлану мөмкинлеге дә зур була. Әмма ул совет идеологиясе кысаларынннан читкә тайпыла алмый. Шунлыктан А. Шамов истәлекләрне билгеле бер таләпләрдән чыгып сайларга тиеш була һәм һәр язманы да урнаштыра алмый. Кайбер язмаларны китабына кертә алмавын ул үзе дә турыдан-туры искәртә: «Миннән генә тормаган сәбәпләр аркасында истәлекләрне (ул аларның авторларын да саный. – *А. Д.*) җыентыкка урнаштыра алмавым өчен чын күңелдән гафу үтенәм һәм бу хезмәтләрнең кайчан да булса бер матбугатка чыгачакларына ышанам» (4, 7).

Чыннын да, аның ышанычы 40 елдан артык вакыт үткәч кенә булса да тормышка ашты. Г. Ибраһимовның 120 еллык юбилеен бәйрәм иткән көннәрдә Рөстәм Акъегет Афзал ага Шамов төзегән истәлекләрне, аның архивында сакланган әлеге материаллларны да өстәп һәм яңа язмалар белән дә шактый ук тулыландырып тагын укучыга тәкъдим итте.

Истәлекләр ... Алар хәтердә сакланган аерым вакыйгалар гына түгел. Ә күңелгә үз төсләре, үз буяулары белән мәңгелеккә уелып калган тормыш мизгелләре, аның тулы картинасы. Билгеле, аларда субъектив карашлар да аз түгел, шулай да алар үткәннәрне бүген белән бәйләп торучы иң ышанычлы чыганак.

Г. Ибраһимов турында истәлекләрне туплау, аны белгән кешеләр белән очрашып, аларның күргән-белгәннәрен барлау да билгеле сәбәпләр аркасында шактый соңара. Утызынчы елларда, үзе кулга алынганнан соң аның турында сөйләшү, кызыксыну, уңай фикер әйтү турыдан-туры үз язмышыңны да фаҗигага этәрүгә тиң була.

Аерым каршылыкларга карамастан, әдипне якыннан белгән кешеләрнең үзләре тарафыннан язылган бай, эчтәлекле, тирән мәгълүматлы истәлекләр туплап калдырылган. Алар – Г. Ибраһимовның бертуган энеләре Хәким һәм Шакир Ибраһимовлар, әтисе ягыннан икенче буын туганы Мохтар Ибраһимов, «Галия» мәдрәсәсендәге укучысы Мәгъдән Мәһдиев, сыйныфташлары Фәтхел Корбангалиев, Шәһит Әһмәдиев, тормыш иптәше Гөлсем Мөхәммәдова, шактый вакытлар якын аралашкан Исмәгыйль Рәмиев, яшьлек дусты Әхәт Сөләйманов, язмышларының иң кискен бер мизгелендә очрашкан, фикерләшкән Хәйбик Сибгатулин, Габделхак Батталов, Ибраһим Салаховларның язмалары. Кызганыч, Г. Ибраһимов белән күп кенә милли, сәяси мәсьәләләрне бергә хәл иткән Фатыйх-Сәйфи Казанлы, Галимҗан Нигъмәти, Гомәр Гали, Садрый Җәләл, Мәҗит Гафури, Сәгыйть Рәмиев, Мулланур Вахитов кебек шәхесләрнең махсус язмалары калмаган. Чөнки аларның берничәсе Г. Ибраһимовка кадәр үк вафат, кайберләре аның кебек үк фаҗигале язмышка дучар ителгән.

Ә истәлекләрдә Г. Ибраһимов шәхесе төрле яклап ачыла. Аның балалык, шәкерт булган елларын гәүдәләндергән истәлекләр дә, укытучы буларак сурәтләгәннәре дә, милләтпәрвәрлеген, кыюлыгын, максатчанлыгын һәм башка бик күп мактауга лаек якларын тасвирлаганнары да бар.

Алар арасында Г. Ибраһимовның кешелек сыйфатларын, әдәбиятка, яшь буын язучыларга мөнәсәбәтен, ярдәмен ачык чагылдырган Фатих Хөсни, Сәрвәр Әдһәмова, Мирсәй Әмирләрнең язмалары аеруча кызыклы.

Шулай иң тетрәндергеч, күңелгә уелып кергәннәре – Г. Ибраһимовның соңгы көннәрен, ахыргы сәгатьләрен сөйли торганнары.

1937 елның 29 сентябрендә Ялтада кулга алынып, авыру Г. Ибраһимов Пләтән төрмәсенә кайтарыла. 1938 елның 21 гыйнварена кадәр ул шунда җан һәм тән сызлавы бергә газаплаган гаҗәп авыр көннәр үткәрә. Шундый шартларда да ул рухи ныклыгын сакларга, башкаларга күңел тынычлыгы, киләчәккә ышаныч уятырга тырыша. Аның төрмә хастаханәсендәге хәлен тасвирлап Г. Батталов түбәндәгечә яза: «Ул, каты авыру булуына карамастан, өметсезлеккә бирелми, үзенең әрнүләрен, борчылуларын кешеләргә сөйләми, киресенчә, хәтта аларның төшенке күңелләрен күтәрергә теләп, үзенең башыннан үткән кызыклы вакыйгаларны сөйләштергәләп ала. Барыннан да бигрәк, кешеләрнең үзләрен сөйләтергә, сөйләгәннәрен тыңларга ярата иде. Камерадагы кешеләр арасында ул үзенең яше белән дә, кылган хезмәтләре белән дә ихтирамга лаек кеше иде. Без аны барыбыз да бик хөрмәт итә идек. Аның әсәрләрен укып тәрбияләнеп үскән без генә түгел, камерадагы башка милләт вәкилләре дә аны сабырлыгы, чыдамлыгы, зирәк акылы һәм яхшы киңәшче булуы өчен ихтирам итәләр иде» (2, 462).

Истәлекләрдән күренгәнчә, ул бу авыр көннәрнең вакытлы гына, ниндидер бер ялгыш, хата гамәл булуына ышына. Әмма үзенең хәленең чиккә якынлашканын, килер көннәренең матурлыгын күрергә ирешә алмасын да яхшы аңлый, иҗатының ил-көннән яшерелүнә бик әрни. Шулай да вакытлар үтүгә халык белән кушылачагына, иҗатының укучысына кайтарылачагына чын күңеленнән ышана:

– Дөреслек ачылыр. Ачылмый калмас, ди торган иде, – дип яза бу хакта Г. Батталов. – Сез моны күрерсез. Менә шул вакыт китапларым яңадан халык кулына кайтыр һәм мине яхшы сүз белән искә алырлар… – диюен искәртә.

Хәйбик Сибгатуллин әдипнең соңгы көннәрен бик җентекләп искә ала. Аның янында 25–26 яшьләрдәге татар кызының кизү торуын яза. Урын өстендә генә ятып торган Г. Ибраһимов янына ул, яшеренеп кенә, берничә мәртәбә керә. Үзен борчыган сорауларына җавып алырга тырышып карый. Әмма, вакыт бик тар булганлыктан, иркенләп сөйләшү мөмкинлеге тими. Чираттагы мөмкинлектән файдаланып, ул тагын бер тапкыр әлеге бүлмәгә аяк баса. Әмма гаҗәеп тетрәндергеч күренешкә тап була: «Беркөнне, гыйнварның икенче яртысында, иптәшләрем белән коридордан узганда, мин аның камерасына тагын яшеренеп кереп калдым. Ләкин бу юлы Г. Ибраһимов урынында юк иде. Идәнне яңа гына юып чыгарганнар, караватын урыныннан кузгатканнар. Тумбочка әрҗәсен чыгарып, ни өчендер, аны тумбочка өстенә каплап куйганнар. Аңа кемдер зур-зур гарәп хәрефләре белән нәрсәдер язган. Язучы кешенең куллары калтыраган булса кирәк, диагональ юллар шактый тигезсез. Мин, кызыксынып, язуга күзләремне төшердем. «Утыз еллар әдәбият юлында эшләгән эшләремнең соңгы көннәре болай тәмамланыр дип уйламаган идем. Нишлисең! Тарих үзе тикшерер, дөрес бәһасен бирер», дип язылган иде анда. Шул көнне таныш санитарканы күрүгә ул Г. Ибраһимовның кайдалыгы белән кызыксына:

– Ул бүген иртә белән үлгән, – дигән җавапны ишетә (3, 465).

Г. Ибраһимовның соңгы сәгатьләрен сурәтләгән, язмышын бәян иткән «Олы юл» документаль повесте авторы Г. Мөхәммәдова да әдип язып калдырган әлеге язуны китерә. Ул каләмне санитарка кыз аша табуын, аны С. Җәлал алдында ук язуын һәм язганнан соң каләмен аңа бирүен дә әйтә (1, 266).

Истәлекләр хәрәкәтчән, белемгә омтылышы булган, хезмәт сөючән, туганлыкчыл, дуслык кадерен белә торган үсмер егетне дә, үз-үзенә ышанган, кыю, максатчан Галимҗанны да, милли җанлы, гаделсезлекләргә каршы бөтен җаны-тәне белән көрәшүче һәм үткен каләмле язучы һәм галимне дә күз алдына бик төгәл чалымнары, үзенчәлекләре белән китереп бастыралар.

Фаҗигале язмышлы, авыр елларда да өметен югалтмаган, күзенә карап якынлашкан әҗәлен дә лаеклы каршы алган көчле рухлы, нык ихтыярлы әдип укучының күңелен бөтенләй яңача тетрәндерә. Иманга, идеалга тугры калуның ачык үрнәге буларак сокландыра. Алдан күрүчәнлеге белән гаҗәпләндерә.

Чыннан да, ул күрергә теләгән көн килде. Г. Ибраһимов исеме халыкка кайтарылып кына калмады, үз бөеклегенә күтәрелеп, тиешле бәһасен алды. Әмма яңа эзләнүләргә дә урын бар әле. Аның эзләре сакланган урыннарны вакыт тигезләгәнче, хатирәләре белән уртаклашырдай затлар арабыздан китеп беткәнче өлгереп кала алу гына кирәк.

ӘДӘБИЯТ

1. Мөхәммәдова Гөлсем. Олы юл / Гөлсем Мөхәммәдова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. – 224 б.

2. Батталов Габделхак. Рухыбызны ныгыта иде / Г. Батталов // Ибраһимов Галимҗан: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр / Төз. Р. Акъегет. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007 . – 544 б.

3. Сибгатуллин Х. Язулы такта / Х. Сибгатуллин // Ибраһимов Галимҗан: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр / Төз. Р. Акъегет. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007 . – 544 б.

4. Галимҗан Ибраһимов турында истәлекләр / Төз: А. Шамов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1966. – 423 б.

# «ТАРИХ»ЛАРДА КЕШЕ ЯЗМЫШЫ
## (Бер мәкалә уңае белән)

***Г. А. Хөснетдинова (Казан)***

В данной статье рассматривается рецензия Г. Ибрагимова «Татар әдәбияты тарихына материаллар», которая была написана после издания 2-х томов «Истории татарской литературы» Г. Рахима и Г. Газиза.

1920 елда Татарстан дәүләт нәшрияты каршында, мәктәпләрдә, югары уку йортларында туган телне, әдәбиятны фәнни укыту ихтыяҗларын истә тотып, татар теле һәм әдәбияты дәреслекләре төзүче авторлар коллективы оештырыла. Коллектив башында күренекле язучы, галим, педагог Г. Ибраһимов тора. Аның җитәкчелегендә дәреслекләр язу өстендә М. Корбангалиев, Г. Ходаяров, Ф. Сәйфи-Казанлы, Х. Бәдигый, Г. Рәхим, Г. Газиз һәм башкалар эшли.

Әлбәттә 20 нче елларга кадәр үк тә татар әдәбияты тарихын язу һәм теориясен эшләү буенча эш башланган иде инде. Бу вакытка Җамал Вәлидинең «Татар әдәбиятының барышы» (1912), Г. Батталның «Нәзарияте әдәбия» (1913), Г. Сәгъдинең «Мохтәсар кавагыйде әдәбия» (1911), «Әдәбият ысуллары» (1912) исемле хезмәтләре, Г. Ибраһимовның Г. Баттал белән берлектә эшләгән «Яңа әдәбият» (1914) дигән дәреслеге, «Әдәбият дәресләре» (1916), «Әдәбият кануннары» (1918), «Яңа әдәбият»ның башка басмалары дөнья күргән була.

Чагыштырмача кыска вакыт эчендә татар әдәбияты тарихы буенча Г. Рәхим һәм Г. Газизләрнең фәнни хезмәтләре басыла башлый. Аларда борынгы төрки язмачылыктан алып, XIX йөзнең беренче яртысына кадәр билгеле булган татар язма истәлекләренең барлыкка килүе һәм тарихи язмышы өйрәнелә. Гыйльми үзәк кушуы буенча язылган китапларны бастырыр алдыннан Г. Ибраһимов тикшерә. «Татар әдәбияты тарихы» буенча материалларны системага китергәндә Гали Рәхим белән Г. Газиз хронология ысулын кулланалар. Ләкин әлеге юл галимнәрне канәгатьләндерми. Чөнки, беренчедән, борынгы дәвердән калган бик күп

әсәрләрнең язылу тарихлары мәгълүм түгел, шуңа шәхесләргә дә игътибар бирергә туры килә (3, VI); икенчедән, әдәбият тарихын дәверләргә бүлү мәсьәләсе дә кыенлаша, XVIII гасыр ахырыннан башланган яңа әдәбият XIX гасыр белән керешеп китә. Шуңа күрә, хезмәтнең өченче кисәге «17, 18 һәм 19 нчы гасырда иске әдәбият» дип куела (3, VII). Әмма шуңа карамастан, галимнәр әлеге ысулның «хәзергә иң ансат вә уңайлы юл» (3, VI) икәнлегенә басым ясыйлар.

Хезмәт мәктәптә дәреслек-кулланма буларак түгел, ә татар әдәбияты дәресләрен укытучы мөгаллимнәргә кулланма итеп юллана (3, IX). Чөнки анда бик күп озын бәхәсләр, фәнни әсәрдә генә була торган тикшерүләр бар. Ләкин аерым дәреслек чыкканчы, бу китапны мәктәптә дә укыту әсбабы итеп кулланырга мөмкин була. Аның артык һәм кирәксез урыннарын төшереп калдырып, укучылар өчен җиңел итеп куллану эше мөгаллимнәрнең үзләренә тапшырыла (3, XI). Чыннан да моңа чаклы тикшерелмәгән гыйлем турында язылган хезмәтнең җитди әсәр булуы табигый. Чөнки татар әдәбияты тарихы җыелмаган, тикшерелмәгән таркау хәлдә була, ә Г. Рәхим белән Г. Газизнең хезмәтләре «шул төрле җирдә таралып яткан материалны җыю юлында бер тәҗрибә» рәвешен ала.

Г. Ибраһимовның «Татар әдәбияты тарихына материаллар» исеме белән басылган мәкаләсе, Дәүләт нәшрияты тарафыннан «Татар әдәбияты тарихы» әсәренең 2–3 бүлекләре басылып чыккач, һәм Гыйльми үзәккә бирелгән беренче бүлекнең кулъязмалары белән танышкач языла. Г. Ибраһимов хезмәткә бәя бирүне китапларның исеменнән башлап болай ди: «Язучылар әсәрләрен “тарих” дип атыйлар. Кеше теләсә ничек дип исем куярга хаклы, ләкин, укучылар яңлыш аңламасын өчен, җәяләр эчендә китапның тышында ук “Тарих өчен материаллар, тарих юлында кайбер тәҗрибәләр” дигән берәр каид (аңлатма) арттырган булсалар, гыйльми яктан дөреслеккә хезмәт кыйлган булырлар иде» (5, 367–368). Шуңа өстәп «әсәрне тарих дип түгел, тарих өчен материаллар дип карарга кирәк»леген дә искәртеп үтә (5, 368).

Бәлки шуңа күрә дә 1923 елда «Татар әдәбияты тарихы. Борынгы дәвер. Беренче җилд» исеме белән кулъязма буларак тәкъдим ителгән беренче кисәк 1924 елда (авторлары Г. Ибраһимовның киңәшен истә тотып) «Татар әдәбияты тарихы өчен материаллар җыю юлында бер тәҗрибә» исеме белән бастырылган булырга мөмкин.

Китапларның эчтәлегеннән үк «Татар әдәбияты тарихы»ның шактый бай һәм катлаулы хезмәт икәнлеген аңларга була. Инде алар белән җентекләбрәк танышкач, борынгы һәм урта гасыр татар әдәбияты чын мәгънәсендә бай зур әдәбият буларак күз алдына килеп баса. Хезмәтне төзү этабында галимнәр меңьеллык гомумтөрки тарихка, әдәбият, мәдәният тарихына кагылышлы татарча, русча, гарәпчә һәм Көнбатыш Европа телләрендәге бик күп чыганакларны җентекләп өйрәнгәннәр, анализларында файдаланганнар.

Ләкин хезмәт, татар әдәбият фәнендә зур казаныш булуына карамастан, басылган сәгатеннән үк әдәбиятчылар тарафыннан каты тәнкыйтькә очрый. Беренче булып хезмәткә бәяләмәне Галимҗан Ибраһимов бирә. Ул 1923 елда «Татар әдәбияты тарихына материаллар» исеме белән басылган мәкаләсендә хезмәтнең «чыннан да “татар әдәбияты тарихы” түгел, бәлки ул тарихка материаллар гынадыр», ди, чөнки моңарчы татар әдәбияты тарихында гаять кыйммәтле берничә әсәр – Риза Фәхретдинев, Шиһабетдин Мәрҗани һәм Каюм Насыйри әсәрләре булуын яза. Фикерен дәвам итеп «әмма алар таркау, гади укучы кирәк вакытта алардан тиз генә файдалана алмый. Ике язучыбыз <...> таркау материалны бер җиргә җыеп, укучыга җиңеллек ясаганнар. Матбугат дөньясында моның әһәмияте юк түгел. <...> китап <...> өченче тәҗрибә булып <...> тулы һәм тәфсилле булып чыккан» (5, 368), дип китапларның әһәмиятен билгеләргә тырыша. Ә инде хезмәтләрнең шул чор идеологиясен канәгатьләндермәгән бер мөһим кимчелеге итеп – авторларның марксист булмауларын, ә хезмәтне язганда марксизм ысулын кулланмауны күрсәтә. «Аларга Маркс-Энгельс ысуллары мәктәбендә кайнап чыгарга, яки бу мәүзугъны (проблеманы) бер марксист, коммунист эшләп чыгарырга тиешледер» (5, 371), – дигәннән соң, «шунсыз без әле марксизм ысулындагы “татар әдәбияты тарихы”н күрә алмабыз» (5, 371), – дип тә нәтиҗә ясый. Димәк, аныңча, хезмәтләр язу өчен, әдәбият тарихын белү ягыннан чын галим булу гына җитми, иң элек марксизм тәгълиматыннан хәбәрдарлык кирәк икән.

Г. Ибраһимовның тәнкыйтеннән соң матбугат битләрендә башка әдәбиятчыларның да мәкаләләре күренә башлый. Бигрәк тә Габдрахман Сәгъди бу эштә үзенең өлгерлеген күрсәтә. Аның беренче – «Әдәбият тарихымы, язмалар тарихымы?» (1923) мәкаләсе хезмәтнең өченче кисәге һәм «“Татар әдәбияты тарихы”ндагы хаталар» (1925) исеме белән басылган икенче тәнкыйди чыгышы хезмәтнең беренче һәм икенче кисәкләре дөнья күргәч, «Безнең юл» һәм «Мәгариф» журналы битләрендә басыла. Галим хезмәткә татар әдәбияты тарихы түгел, бәлки «төрек-татарлардагы язмалар, китаплар, документлар, васыятьнамәләр тарихы» (6, 42), – дип бәя бирә, кимчелеге итеп «иҗади эш вә истикъламиятнең (мөстәкыйльлекнең), билгеле бер системаның юклыгын» (6, 40–44) күрсәтә. Шуңа өстәп, авторлар хакында «Г. Рәхим һәм Г. Газиз кебек иптәшләрдән, әлбәттә, моны көтеп тә булмый, көтәргә хакыбыз да юк» икәнлеген искәртеп үтә (6, 44). Ә инде Г. Толымбайский барысыннан да уздырып, хезмәт хакында «пантюркизм карашында торып язылган китап» (7, 43), дигән нәтиҗә чыгара.

Күпчелек тәнкыйтьчеләрнең мондый рухта язылган чыгышларына карамастан, әдәбиятыбызның тарихын өйрәнү белән шөгыльләнүче икенче бер әдәбиятчы-галим Җамал Вәлиди хезмәткә уңай бәя бирә. Ул аны «безнең татар әдәбияты өчен генә түгел, бәлки хәзерге көндә язулы-сызулы булган бөтен төрек халыкларының әдәбият тарихы өчен мәдхәл булып хезмәт итәрлектер. Чөнки, безнең өчен хәзер иң кыйммәтлесе – әдәбият тарихы өчен материалларны җыеп бергә оештырудыр» (1, 228–229), дип саный.

Шулай ук, М. Фазлулла да үзенең бәяләмәсендә татар әдәбиятының «бер “бөтен” һәм тарихлы бер әдәбият» икәнлеген, аның «әдәбиятчыларга зур уңайлык бирүен, укучы өчен туры маяклы юл булуын» (8) раслый.

Матбугат битләрендә тәнкыйди мәкаләләрнең, чыгышларның басылуы, Г. Рәхим белән Г. Газизне изге эштән туктата алмый. Озак та үтми 1925 елда «Феодализм дәвере» исеме белән «Татар әдәбияты тарихы»ның кыскартылган икенче басмасы дөнья күрә һәм

югары уку йортлары өчен дәреслек-кулланма буларак тәкъдим ителә.

Төзелеше ягыннан икенче басма беренче басманың икенче һәм өченче кисәкләренең оешмасын тәшкил итә. Ул яңа материаллар белән баетылган (мисал «Нәһҗел-фәрадис»), һәр төркем әдәбиятына гомуми характеристика бирелгән, аннан соң аерым әсәрләргә, язучы иҗатына анализ ясалган.

Галимнәр фикеренчә, хезмәтнең икенче басмасы беренчесеннән «тарихи материализмга нигезләнеп» төзелгән булуы белән аерылып тора. Андагы материаллар татар әдәбиятының «борынгы дәвере икътисадият (экономика) һәм сыйнфыйлык ноктаи нәзарыннан» карап яктыртылган; ягъни аның сыйнфый нигезләре ачылып күрсәтелеп, бөтен барышы заманасының «икътисади мөнәсәбәтләре белән бәйләргә тырышылган» (4, 4). Ягъни элек басылган хезмәтләрендә галимнәр татар әдәбияты тарихын тарихи этаплар буенча тикшерү юлы белән барсалар, икенче басмада инде Г. Ибраһимов позициясенә, татар әдәбияты тарихын иҗтимагый-икътисади формацияләргә нигезләнгән бүленеш буенча бирергә тырышканнар.

Ләкин, шуңа карамастан, хезмәтнең икенче басмасы да тәнкыйть утына эләгә. Мәсәлән, Гомәр Галиев «Без әдәбият тарихын ничек өйрәнәбез?» исеме астында басылган мәкаләсендә хезмәтнең эчтәлеге нәрсәдән гыйбарәт икәнлеге күренмәүдә, авторларын, әдәбият тарихы бурычын аңлау мәсьәләсендә, талантлы сүзләр генә язуларында гаепли. Әдәбият тарихының төп объектын билгеләүдә читкә чыгып китүләренә басым ясый (2, 29).

Ни өчен соң хезмәтне болай тәнкыйть иткәннәр? Моның сәбәпләре, әлбәттә, төрле: монда шул чорның иҗтимагый-сәяси юнәлеше дә, әдәбият фәненең торышы да үзенең тискәре тәэсирен ясый. Чөнки XX йөзнең 20–30 нчы елларында 1917 елның октябренә кадәр иҗат ителгән барлык әсәрләргә буржуа эчтәлекле, аның яңа тормыш төзүчеләргә кирәге юк, дигән мөһер сугыла. Әдәбиятка, сәнгатькә чынбарлыкны объектив сурәтләүче генә түгел, бәлки идея өчен көрәшче дә булырга тиеш дигән таләп куела.

Нәтиҗә ясап шуны әйтәсе килә: Галимҗан Ибраһимовның «Татар әдәбияты тарихына материаллар» исеме белән басылган тәнкыйди мәкаләсе киләчәктә Гали Рәхим һәм Газиз Гобәйдуллиннарның (Г. Газиз) язмышында хәлиткеч роль уйный дип әйтергә кирәк. Алар икесе дә урынсыз рәнҗетелеп, репрессия чорларында юк ителәләр.

## ӘДӘБИЯТ


1. Вәлиди Җ. Матбугат дөньясында. «Татар әдәбияты тарихы өчен материаллар җыю юлында тәҗрибәләр» // Безнең юл. – 1924. – № 4–5. – Б. 228–230.
2. Галиев Г. Без әдәбият тарихын ничек өйрәнәбез? // Безнең юл. – 1927. – № 2. – Б. 20–30.
3. Гали Рәхим, Г. Газиз. Татар әдәбияты тарихы өчен материаллар җыю юлында бер тәҗрибә. – Беренче җилд. Борынгы дәвер. I бүлек. Мәдхәл (Борынгы төрекләрдә әдәбият). – Казан: Татар. матб. һәм нәшр. комб. нәшере, 1924. – 174 б.
4. Гали Рәхим, Г. Газиз. Татар әдәбияты тарихы. Феодализм дәвере. II басма. – Казан: Татар. матб. һәм нәшр. комб. нәшере, 1925. – 316 б.
5. Ибраһимов Г. Татар әдәбияты тарихына материаллар// Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. – V т.: Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910-1933) / Томны төзүче, текст, искәрмә һәм аңлатмаларны әзерләүчеләр Хәсәнов М. Х., Гайнанов Р. Р. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – Б. 366–371.
6. Сәгъди Г. Әдәбият тарихымы, язмалар тарихымы? // Безнең юл. – 1923. – № 12. – Б. 40–44; 1924. – № 13. – Б. 40–44.
7. Толымбайский Г. Татар буржуа теле – безнең тел түгел // Яңалиф. – 1931. – № 3. – Б. 37–48.
8. Фазлулла М. Әдәбият укучыларга җиңеллелек // Татарстан хәбәрләре. – 1923. – 7 март.


# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ҺӘМ АФЗАЛ ТАҺИРОВ


***Р. Ф. Бәдретдинов (Казан)***



Деятельность Г. Ибрагимова характеризуется уникальностью и многогранностью. В этой статье речь идёт о Г. Ибрагимове, который подвергает критике писателя, общественного и государственного деятеля Афзала Тагирова за драму «Янгура», сыгранную на сцене драматического театра. Г. Ибрагимов – влиятельная фигура, литературовед. В своей статье ставит Афзала Тагирова на один уровень с известными успешными, начинающими писателями своего времени.


XX гасырның беренче яртысы әдәби хәрәкәтенә һәм мәдәни-иҗтимагый мәсьәләләргә һәрдаим үз карашын, мөнәсәбәтен җиткерүче, язучы һәм галим, сәясәтче, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Галимҗан Ибраһимовның язучы, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Афзал Таһиров иҗатына карата әйтелгән фикертәкъдимнәре, мәкаләләре, бәяләмә-рецензияләре бар. Дөрес, алар күп түгел, әмма аларда күтәрелгән фикерләрнең әһәмияте, тирәнлеге игътибарга лаек. Чөнки алар үз чорының кыйммәтле ядкярләре булып торалар һәм рухи мирасыбызның асылын, әдәбинәзари барышын колачларга булышалар. Шулай ук әдәбият фәненең мөһим сәхифәләрен ачыкларга ярдәм итәләр.

1922 елда «Татарстан хәбәрләре»нең 31 гыйнвар санында Галимҗан Ибраһимовның «“Янгура” уйналуы мөнәсәбәте белән» исемле мәкаләсе басылып чыга (1). Анда Афзал Таһировның әлеге драмасы көчле тәнкыйть утына тотыла. Аның уңышсыз яклары күрсәтелә һәм берочтан кайбер урыннарын төзәтергә кирәклегенә дә басым ясала. 1924 елда язылган «Татар әдәбияты (Еллык хисап урынында)» (2, 410) исемле мәкаләсендә исә Афзал Таһировны актив иҗат итүче башка татар әдипләре белән беррәттән санап үтә һәм аның соңгы елларда язылган әсәрләренә этрафлы бәясен бирә. 1926 елда Галимҗан Ибраһимов «Тел-әдәбият мәсьәләләренең кирәкле бер тармагы (Татар халык әдәбияты турында)» (2, 492) мәкаләсендә ха-

лык авыз иҗатының торышы һәм әдәби процессның барышы белән таныштырып уза. Ул анда: «Большевик мөхәррир Афзал Таһиров иптәшнең дә яхшы материаллары бар», – дип, уңай яктан бәяли. Ә менә 1930 елдагы «Ерактан сәлам (Татарстанның ун еллыгына)» исемле мәкаләсендә ул Афзал Таһировны башка бик күп яшь язучы-шагыйрьләр белән беррәттән алдынгылар, хәтта беренчеләр рәтенә күтәрә: «...идеология ягының дөреслеге, революциянең, сыйнфый көрәшнең ачык кирәк урыннарын ала белүчелеге белән аерым урын тоткан Афзал Таһировлар безнең хәзерге әдәбиятыбызда төп нигез урын тоталар», – дип яза Г. Ибраһимов (3, 452). Туфан, Салих Баттал, Кави Нәҗми, Шамил Усманов, Толымбайский, Сәйфи Кудаш, Мәхмүд Максуд, Һади Такташ, Кутуй, Галимҗан Нигъмәти, Гомәр Гали, Идрис Туктар, Газиз Иделле, Мирсәй Әмирләр янәшәсендә Афзал Таһировны да татар язучылары, тәнкыйтьчеләре, гомумән, татар әдипләре арасында үз кеше саный, аларны татар әдәбияты мәйданының әйдаманнары дип атый.

Галимҗан Ибраһимовны да, Афзал Таһировны да язмыш җилләре төрле яклап сыный. Галимҗан Ибраһимовтан өч яшькә генә кечерәк булган Афзал Таһиров та Оренбург мәдрәсәсендә (1898–1905 елларда) белем ала. Шәкертләр арасында искелеккә каршы оештырылган чараларда алар бергәләп катнашалар. Казакъ далаларында юрталарда яшәп, укытучылык эшчәнлеге белән шөгыльләнәләр. Шуның тәэсиредерме, Афзал Таһиров та әдәбият мәйданына «ыргылып» килеп керә һәм кыю адымнар белән хәрәкәт итә башлый. Аларны темалар уртаклыгы да, сюжет бәйләнешләре, куйган максатлар яктылыгы, образлар тирәнлеге дә берләштерә.

Галимҗан Ибраһимовның «Татар сәхнәсе» исемле мәкаләсендә күтәрелгән тәнкыйди карашларга килсәк, биредә сүз күбрәк драманың үзе түгел, ә сәхнәдә куелуы, тамашачыга күрсәтелүе хакында бара. Афзал Таһиров «Янгура» драмасында төп тема итеп, тарихилыкны, милләт кайгысы, мөстәкыйльлек, азатлыкны күтәрә. Галимҗан Ибраһимов үзе дә татар тарихын өйрәнү эшенә зур өлеш керткән шәхес. 1925 елның азакларында аның да «Татарлар арасында революция хәрәкәтләре» исемле әсәре шушы өлкәгә карый (3). Ә инде «“Янгура” уйналуы мөнәсәбәте белән» исемле мәкаләдә сүз, нигездә, Казан ханлыгының ахыргы чорларына барып тоташа. Янгура каһарманның язмышы – уйдырма түгел, ә факт. Ул тарихи образ буларак та игътибарга лаек. Афзал Таһиров та архив чыганаклары белән таныш булып, аларны өйрәнеп язганлыктан, биредә төп игътибарны милләт язмышына юнәлтә. Тик шулай да Г. Ибраһимов, пьесага карата әйтелгән фикерләренә өстәп, драма «сәяси яктан зарарсыз», – дип тәмамлый. Төп геройларны халыкка җиткерә алмаган артистлар өчен дә борчылуын белдерә. «Монда татар-нугай мирзалары булмады: Исмәгыйль мирзаны Иван Грозный ясап, Алтынбикәне борынгы урыс бояры хатыны итеп, Янгураны бөтен киеме, кыйланмышы белән урта гасырлардагы рыцарь ясап уйнадылар. Чулпан исә моннан өч-дүрт йөз ел элек яшәгән нугай мирза кызы түгел, бәлки үзенең өс-башы, аяк киемнәре, кыйланмышлары белән бөтенләй хәзерге заманның мадмазельләре булып чыкты», – ди (3, 273–276). Димәк, драма әсәре һәм спектакль куелышы, Г. Ибраһимов белдергәнчә, икесе ике нәрсә. Ләкин аларның берсе икенчесен тулыландыра, баета, әсәрне тирәнәйтергә тиеш. Һәрбер әсәр көчле сәхнә куелышыннан соң гына тамашычыга барып җитә ала. Ә инде артистларның киемнәре, чор мохите тудырылмаса, автор язганча «аларга (артистларга. – *Р. Б.*) карау кызганыч иде», – дияргә генә кала (3, 276). Афзал Таһиров исә Галимҗан Ибраһимовның бу әсәргә карата әйтелгән тәнкыйди фикерләре белән килешә һәм автор бәян иткәнчә: «Мөхәррир, моны сизеп, ахырдан үз кулъязмасы буенча төзәттереп бастырып таратты», – дип, икенче бер мәкаләсендә искә алып үтә (3, 410). Г. Ибраһимов тәҗрибәле каләм әһеле буларак, әдәбиятның үзенчәлекле якларын, хосусиятләрен тирәнтен аңлый, сәнгати күтәрелешләрен тоя. Афзал Таһировка бәйле мәкаләләрендә дә ул авторга турыдан-туры бәрелмичә, җайлы-ипле мөрәҗәгать итә. «Янгура» уенындагы декорацияләргә, артистларның киеменә, үз-үзләренең тотышларына басым ясап күрсәтә, димәк, сәхнә уены драма әсәренең тәэсир итү көчен күтәрергә дә, юкка чыгарырга да мөмкин икән. Бу инде, үзгә бер әдәби процесс, сәнгатьнең үзгә юлы, үзгә юнәлеше...

Г. Ибраһимовның халык авыз иҗатына караган мәкаләләре дә шактый. «Тел-әдәбият мәсьәләләренең бер тармагы» (2, 490) мәкаләсендә ул болай дип яза: «Бер катлау – гарәпчә белән, бер катлау урысча белән ана теленең үзлегген боза бара. Әмма асыл саф тел – тик шул мәкальләрдә, табышмакларда, такмакларда, әкиятләрдә» (2, 491). Әдип юкка гына татар халык авыз иҗатын җыю, тәртипләү, бастырып чыгару турында уйланмый. Афзал Таһировның да «Уеннар»(1920) исемле татар балалар фольклорын туплаган китабы дөнья күрә. Бу басманың басылып чыгуына да Г. Ибраһимов нык булыша.

Г. Ибраһимов өчен әдәбиятта ят тема, ят өлкә, юнәлеш һәм хәрәкәт юк. Ул аларга бергә, бербөтен итеп карый. Дөрестән дә, татар әдәбияты үсешендә мөһим роль уйнаучы Г. Ибраһимов – әдәби мохиткә үз карашы, үз мәсләгә булган әдип, тәнкыйтьче, галим. Аның А. Таһиров иҗатына карата язылган берничә мәкаләсеннән генә дә башкаларның иҗат офыкларын ачучы остаз булуын тоемлау кыен түгел. Ул – милли-рухи казанышлар эчендә кайнаучы зат. Башкаларны да моңа өндәүче, дөрес юл күрсәтүче остаз.

ӘДӘБИЯТ


1. Ибраһимов Г. Татар сәхнәсе («Янгура» уйналуы мөнәсәбәте белән) // Татарстан хәбәрләре. – 1922. – 31 гыйнвар.

2. Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. V т.: Әдәбият һәм сәнгать турында мәкаләләр, хезмәтләр (1910–1933). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – 410 б.

3. Ибраһимов Г. Мәкаләләр, истәлек-хатирәләр / Төз. Р. Акъегет. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 544 б.

4. Миңнегулов Х. Гасырлар арасында уйланулар / Х. Миңнегулов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2010. – 319 б.

# Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ «КӨТҮЧЕЛӘР» ХИКӘЯСЕНӘ САЛЫНГАН ЭЧТӘЛЕК

*Г. Ф. Гәрәева (Казан)*

В данной статье предлагается анализ рассказа Г. Ибрагимова «Пастухи». «Пастухи» – произведение, в котором выражается переплетение реализма с романтизмом. В рассказе повествуется о старике Аптераша – пастухи, уставшем от тяжелой жизни и нищеты. Сначала старик трудится на мельнице, затем нанимается пастухом и живет в хибарке с земляным полом. Свои последние дни он вынужден проводить у разных людей, которые присматривают за ним по очереди. Сын старика Вахит – его противоположность. Идея произведения связана именно с этим образом. Вахит расскрывается как романтический герой, восставший против жестокости и мечтающий о счастье и духовной свободе. Стремящийся к красоте Вахит противопоставляется реальной действительности.

Хикәядә авыр тормыш һәм фәкыйрьлектән алҗыган күндәм Әптерәш карт һәм аның улы Вахит турында сөйләнелә. Карт башта тегермәндә эшли, соңыннан көтү көтәргә ялланып, җир идәнле куышта гомер сөрә. Соңгы көннәрендә өйдән-өйгә чиратка салынып гомер кичерә, «...берәүнең мал өендәге сәке астында бозаулар арасында» соңгы сулышын ала.

Авторның реализм белән романтизмның үрелеп яшәвен чагылдыра торган хикәясе. Бәхетне көтеп-көтеп тә, хайваннар абзарында җан биргән көтүче Әптерәшнең фаҗигасе коточкыч. Әптерәш картның улы Вахит образы романтик сурәтләнештә бирелгән. Әптерәш карт кебек хезмәт кешеләренең көйсез язмышы җәмгыятьтә меңнәрнең уртак фаҗигасе булса, Вахит исә – хыялдагы каршылыклы образ. Авылдашлары тарафыннан аңа «ярлы тәкәббер» кушаматы тагылган Вахит бәхет, рухи азатлыкка омтылучы, тормышның, авылдашларының гаделсезлеге һәм мәрхәмәтсезлегенә каршы баш күтәрүче романтик герой буларак ачыла. Хикәядә тормышның түбәнге баскычында торучыларның фаҗигале язмышы куе буяулар ярдәмендә сәнгатьчә үткен итеп күрсәтелгән.

Хикәянең исеменә салынган мәгънәгә дә игътибар итү сорала. Беренчесе – туры мәгънәсендә авыл көтүчеләре. Автор: «... Алланың барлык илчеләрен, мәдәни инсаниятнең барлык көтүчеләрен җавапка чакыра иде», – ди. Галимә Р. Ганиева фикеренчә, «Шәрык мәдәниятеннән һәм фәлсәфи фикереннән килә торган традицияләр белән бәйле “Көтүчеләр” төшенчәсе, дөньяның акыл ияләре, халыкны бергә туплаучылар, әйдәп баручылар, укымышлы кешеләр, гыйлем ияләре, дигән мәгънәне аңлата. Өстәвенә, Ибраһимов хикәясендәге «көтүчеләр» метафорасы Аурупа, рус философиясеннән һәм әдәбиятларыннан килә торган эчтәлек белән дә баетыла... Шәрык һәм Гареб мәдәниятеннән, француз һәм рус әдәби-эстетик фикерләреннән килгән традицияләр бергә килеп очраша һәм синтезлаша» (1, 229).

Татар кешесенең милли тормыш-көнитешенә кагылышлы күзәтүләр дә җәмгыятьне бәяләү белән үрелеп китә. Автор татар кешесенең җир белән тыгыз бәйләнештә булуын Вахит исеменнән әйттерә: «Хәят миңа башта шул тирмән булып күренде. Су чылтырап ага ... урман шаулый ... тирмән көн әйләнә, төн әйләнә. Мин, гүя, аның шул әйләнүенә сихерләнеп, гомернең кая барганын, уйнауның, балалыкның ни икәнен белми яшим» (2, 219).

Татар кешесенең милли тормыш-көнитешенә кагылышлы күзәтүләр дә җәмгыятьне бәяләү белән үрелеп бара. Йорт-тирмән образы тормыш, заман, җәмгыять төшенчәләрен ачыклап килә. Үзәк герой йорт образы белән тыгыз бәйләнештә яши. Һәрбер әйбернең, детальнең үткәндәге хәлен һәм бүгенгесен сөйли: «Бу өйгә самовар кергәнен хәтерләмим, шәм, лампа яндырылганы да исемдә юк ... беребез агач савыт, икенчебез әллә ничә җиреннән сыланып, бәйләнеп беткән кәсә белә чәй эчәбез» (2, 222). Әлеге мисал аша кешене әйләндереп алган чынбарлыкның да чикле, вакытлы, җимерелүгә һәм бетүгә йөз тотуы ачыклана. Автор бу хәлләргә әсәрнең буеннан-буена үзенең мөнәсәбәтен белдереп бара. Вахит хакыйкатьне эзләп карый, үлемнән һәм юкка чыгудан котылу юлын билгеләргә омтыла. Ләкин малай нәрсә булганын бик белергә теләсә дә, җавап таба алмый: ни өчен аның этисе мондый хәлгә төште, ни өчен әнисе үлгән – әлегә сәбәбе ачыкланмый. Кеше иҗтимагый хәлләргә карап түгел, кешелеклелек кануннары буенча яшәргә тиеш тә югыйсә. Вахит тарафыннан кабатлаулар кеше кадеренең юклыгы, кешене бернигә дә санамау хакындагы нәтиҗәгә китерә. «Дөньяң шундый матур, без ник болай бәхетсез соң, Ходаем!» (2, 242).

Эчке монологлар һәм ачыклаучы сөйләм татар язучылары әсәрләрендә кешенең читләшү процессын чагылдыра: төркемнән аерылу, ялгызлык, әхлакыйпсихологик нигезләрне югалту, шәхес буларак үзеңнән еракләшу. Вахитнең балачагы ялгыз үтә: этисе көне буе көтү көтә, кичен арып-талып кайтып, бер почмакка егыла, ә инде иртән ул чыгып киткәндә Вахит йоклап кала. «Җәйләре тагы бер хәл, ул инде бер төрле үтә: көндез тау арасында, төбе күренмәгән тирән чокырлар буенда йөрим. Кич өйгә кайтып ятам да, акрын искән җил белән агачларның сак кына шаулауларыннан йөрәгемдә кузгалган шомлы курку эчендә караңгы почмакка сиена төшеп, йокыга китәм» (2, 219). Бик ачык итеп эч пошу мотивы күрсәтелә. Монда сагыш мотивы көчәя генә: бу көчәю тышкы тирәлекне тасвирлау хисабына бара.

Автор хисләр матурлыгын табигать гүзәллеге белән янәшә куеп тасвирлый. Яшьләр күңелендәге сөю дулкыннары һәрчак табигатьнең искиткеч манзарасы биргән рәхәтлеккә кушып сурәтләнә. Бер үк вакытта мәхәббәт – табигатьнең матурлыгын күрергә ярдәм итүче көч, кешенең күңел күзен ачучы могҗиза. Ул этисенә ияреп килгән Сараны тауларга, урманнарга алып чыга: «...елтыр шома ташлар, матур чәчәкләр җыеп бирдем».

Язучы геройның рухи дөньясының чагылышы булган Сарага мөнәсәбәтен тасвирлый. Алар Вахитнең бер генә төрле барган тормышына, сүнә барган җанына шулкадәр көчле тәэсир итә , егетнең үпкә-шөбһәләре онытыла, җаны канатлана башлый: «Һәр көн йокыдан уянгач, шунда бару, матур Сарам белән бергә, икәү генә уйнау өмете минем йөрәгемне кузгата торган булды» (2, 220).

Ләкин Сараның башка малайлар белән дә бергә уйнавын күргәч кәефе төшә. Бу очракта да егет җанындагы хисләр көрәшендә күңел бушлыгы, моңлы хәят өстенлек ала. Кичерешләрнең тирәнлеген, хисләрнең үткенлеген күз яшьләре белдерә. Әсәрнең буеннан-буена яшерен күз яшьләре мотивы сызылып бара. Ана-бала арасындагы бәйләнеш яшәү мәгънәсен аңлатучыга әйләнә. Вахит иң авыр вакытында әнисен сагына, дөньяның аны җәберләгәне өчен күз яше белән бушанасы килә: «Ләкин ул кабердә... Башка һичкем мине аның кадәрле сөя алмый... Мин берәүгә дә кирәк түгел, мин үзем дә һичкемне, һичкемне якын күрмим, һичберсен яратмыйм, ярата алмыйм» (2, 221).

Биредә экзистенциализм фәлсәфәсе әсәрнең буеннан-буена сузыла. Әтисенең үлеме турында уйлау, үлемне уйлауның куркынычлылыгы турындагы сүзләр күңелгә шом сала. Төшендә күргән куркыныч халәт чынга аша: «Шул урман, шул караңгы төн, шул караңгы баз. Анда кемдер ыңгыраша, аның күз карашлары үлем сөйлиләр» (2, 228).

Әтисе урын өстендә ыңгырашканда, киңәшеп тормыйча, икенче берәүне көтүгә чыгарганнар. Чарасызлык исә яшәешкә, тормышка ләгънәт укуга илтеп җиткерә: «Чукынып, кадалып китсеннәр, сыерларның муены асларына килсен, берне түгел, меңне яллагыз... Мин әткәйне ташлап китәр хәлем юк» (2, 229). Сагыш, үкенеч, чарасызлык мотивлары геройны үз чоры кешесе, шул заманның борчуларын тирән белдерүче итеп күрсәтә. Кешенең гомере милләт, ил вакыты, җәмгыять контекстына куела.

Образларга салынган мәгънәне, авторның теләген, уен, бәясен укучыдан таптырырлык итеп язарга өйрәнү – бу чорның казанышы. Чорның тагын бер әһәмиятле казанышы – кеше күңелен, катлаулы тормышның үзе кебек, вакыйгалы, каршылыклы дөнья итеп ачу.

ӘДӘБИЯТ

1. Ганиева Р. К. Татарская литература: традиции, взаимосвязи. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2002. – 272 с.
2. Ибраһимов Г. Сайланма әсәрләр. – Казан: ТаРИХ, 2002. – 543 б.

# ГАЛИМДЖАН ИБРАГИМОВ В ПОИСКАХ ГЛАВНОГО НАПРАВЛЕНИЯ В ЛИТЕРАТУРЕ 20-Х ГОДОВ XX ВЕКА

***Ф. К. Даминова (Казань)***

*Среди тюркских писателей-реалистов Галимджан Ибрагимов занимает выдающееся место. В его лице татарская проза внесла значительный вклад в современную советскую литературу.*

Чингиз Айтматов

В 2012 году вся литературная общественность республики отмечает 125-летие со дня рождения выдающегося писателя, одного из основоположников и классика татарской советской литературы Галимджана Ибрагимова.

Талантливый писатель, критик и теоретик литературы, крупный ученый-востоковед, неутомимый государственный и общественный деятель – таким запечатлелся в памяти современников и вошел в историю этот замечательный сын татарского народа. Литературное творчество Г. Ибрагимова, его разносторонняя научно-просветительская и идейно-пропагандистская деятельность завоевали широкую популярность у народа, оказали огромное влияние на его духовную жизнь.

В дореволюционный период Г. Ибрагимов вместе с Г. Тукаем, Ф. Амирханом и Г. Кулахметовым возглавлял революционно-демократическое направление в национальной литературе, был ее крупнейшим представителем. Его рассказы «Начало весны», «В море». «Старый батрак», «Пастухи», «Дети природы» и роман «Молодые сердца», а также многочисленные литературно-критические статьи внесли большой вклад в формирование и становление новой татарской литературы, в развитие национального литературного языка и эстетической мысли.

Первый рассказ Г. Ибрагимова «Изгнание шакирда Заки из медресе» был опубликован в 1907 году в демократической газете «Аль-Ислах». Рассказ этот во многом автобиографичен: как и самого Ибрагимова, его героя изгоняют из медресе за вольнодумие.

Уже в ранних произведениях Г. Ибрагимова отчетливо видны напряженные идейно-эстетические искания, отмеченные резким конфликтом между идеалом и действительностью, например, рассказы «Угасший ад», «В море», «Любовь – счастье» и ранний роман «Молодые сердца».

Герой рассказа «В море» (1911) покидает город. В единстве с морской стихией он ищет духовной свободы, презирая людей безвольных и лишенных идеала. С рассказом «В море» в творчество Г. Ибрагимова вошел образ типичного романтического отшельника, который настойчиво искал, но не находил себе места в действительности того времени.

В татарской литературе начала XX в. «Молодые сердца» был первым психологическим романом. В нем идеалы положительных героев даны в резком столкновении с жизненными противоречиями. Национально-бытовые и пейзажные описания, насыщение языка фольклорными средствами – все это можно отнести к достоинствам романа.

Г. Ибрагимов относится к числу тех прогрессивных писателей-патриотов России, для которых не было вопроса: принимать или не принимать Октябрьскую революцию. Он принял ее всецело и стал активным борцом за ее идеалы. Именно Великий Октябрь и последующие важные политические события формировали его взгляды и накрепко связали писателя с большевистской партией, с марксистско-ленинской идеологией.

В январе 1918 года Г. Ибрагимов, будучи делегатом Учредительного собрания, вместе с большевиками покинул его, принимал участие в работе III Всероссийского

съезда Советов, где был избран членом ВЦИКа. Важной страницей в революционной биографии писателя является его работа заместителем председателя Центрального мусульманского комиссариата при Народном комиссариате по делам национальностей.

Деятельность Г. Ибрагимова в советский период чрезвычайно богата и многогранна. Как государственный деятель, пропагандист, ученый, журналист, писатель он сыграл огромную роль в становлении Татарской Автономной Советской Социалистической Республики, ее духовной культуры.

Способности Г. Ибрагимова как организатора научной и общекультурной работы со всей полнотой раскрылись на посту председателя Академического центра при Наркомпросе ТАССР.

Новаторское решение получает в послеоктябрьском творчестве Г. Ибрагимова проблема гуманизма. В своих произведениях («Новые люди», «Сказание о красных цветах») он отражает острую классовую борьбу среди татар в период революции и гражданской войны, показывая сложные общественные и личные взаимоотношения между людьми.

Ибрагимов и в творчестве, как и во всей разносторонней научно-общественной деятельности, не ограничивался национальными рамками, обращался к жизни и судьбам других народов нашей страны. Ярким примером этого служит его роман «Казакъ кызы» («Дочь степи»), свидетельствующий не только о возмужании таланта писателя, но и об удивительной многогранности его художнического взора. Это одно из лучших произведений татарской прозы, ставшее ценным вкладом во всю многонациональную советскую литературу двадцатых годов, способствующее расширению интернациональных связей.

Поистине новаторским произведением, вобравшим идейный, политический и художественный опыт эпохи, является роман «Глубокие корни». Г. Ибрагимов поднял здесь новую для татарской прозы тему социалистического переустройства мира, богатства и разнообразия социальных типов, которую татарская литература тех лет не знала.

Роман не только занял выдающееся место в национальной литературе, но и оказал существенное влияние на формирование реалистической прозы в ряде литератур.

В творчестве Г. Ибрагимова нашли художественное отражение многие темы и проблемы, имевшие особую актуальность в процессе революционного разрушения старого мира и строительства нового общества. В его произведениях, таких, например, как «Судьба татарки», «Новые люди», «Наши дни», «Глубокие корни», глубоко разработана проблема эмансипации женщины.

Широта и точность исторических воззрений писателя, богатство и гибкость историзма наглядно раскрылись в романе «Наши дни». Историю первой русской революции, ее влияние на жизнь татар Г. Ибрагимов обозрел здесь глазами художника и воссоздал пером зрелого мастера-реалиста. Писатель сделал попытку художественно обобщить и осмыслить такую большую и серьезную проблему, как отношение различных прослоек татарской интеллигенции к революции, народу, нации, классовой борьбе и национальной культуре.

Этот роман явился первой в национальной литературе историко-революционной эпопеей, огромным вкладом в национальную культуру. «Наши дни» оказал серьезное воздействие на последующее развитие национальной прозы. Выдающийся писатель этим своим произведением заложил прочный фундамент татарского историко-революционного романа.

Г. Ибрагимов в письме к своему другу Х. Кериму писал: «В новом романе “Наши дни” появится много новых людей. Если увидишь среди них себя, не удивляйся!»

Богатый материал дали Г. Ибрагимову архивные фонды, с которыми он познакомился после Октябрьской революции. Вот один любопытный факт. В жандармской переписке много раз упоминалось его имя, в охранку сообщалось, когда и где был писатель, что он говорил, с кем встретился. Агент перечислял участников таких встреч, исключая самого себя. Им оказался журналист И. Бикчурин. Так, жизнь и предательская деятельность И. Бикчурина легли в основу образа Баязита – эсера-анархиста.

В «Глубоких корнях» писатель создает панораму драматических событий, порожденных столкновением нового со старым на одном из решающих этапов социалистической революции – в условиях новой экономической политики. Автора интересует прежде всего раскрытие исторического смысла совершающихся событий и судеб их участников. Именно с этой позиции писатель сливает в едином повествовании ход социальных событий с личными историями героев.

Принцип биографизма наметился уже в ранних произведениях Г. Ибрагимова – «Пастухи», «Молодые сердца», «Наши дни». Однако в них биографические отступления и другие вставные элементы нередко выпадали из композиции, ослабляли сюжетную динамику, не диктовались художественной целесообразностью. В «Глубоких корнях» они составляют неотъемлемую часть целого и органически входят в единую композицию.

Народный писатель РТ М. Магдеев пишет об одном интересном прототипе Фазила – героя рассказа «Красные цветы». Г. Ибрагимов многопланово раскрывает сложную психологическую борьбу, происходящую в нем в решающие судьбу народа дни – в дни революции, гражданской войны. Это был Халим Искандеров – одноклассник по учебе в медресе, написавший большие критические статьи о творчестве Ибрагимова.

Позже Х. Искандеров преподавал в Арском педучилище, где учился народный писатель М. Магдеев. Он пишет: «И никто из нас, его учеников, сидевших тогда в классе, не догадывался, что тот, кто с волнением и восхищением рассказывал нам о поэтике Пушкина, Лермонтова, Толстого, Гоголя и Фадеева, – не кто иной, как прототип Фазила из прекрасного рассказа Г. Ибрагимова “Красные цветы”». Образ Халима Искандерова является одним из главных героев в произведении М. Магдеева «Мы – дети сорок первого года».

Г. Ибрагимов был не только крупным общественным деятелем и замечательным мастером художественного слова, но и талантливым ученым, внесшим огромный вклад в татарскую филологию и историческую науку. Прежде всего, важно подчеркнуть, что вместе с Г. Тукаем и Ф. Амирханом он основал татарскую литературную критику, прочно утвердившуюся как неотъемлемая часть национального литературного процесса после первой русской революции. В литературно-критических статьях Г. Ибрагимова доок-

тябрьского периода выдвинуты и обоснованы важные идейно-эстетические проблемы, имевшие чрезвычайно актуальное значение для развития татарской революционно-демократической литературы и эстетической мысли. После Октябрьской революции литературоведческие труды и критические статьи Г. Ибрагимова активно способствовали тому, чтобы поставить татарскую критику на подлинно научную основу.

Как и все великие художники, Г. Ибрагимов горячо и искренне любил свой народ и в этой любви видел мощный источник силы и вдохновения. Вместе с тем его многогранное дарование согрето любовью ко всем людям труда земли, оно сильно своей обращенностью к интернациональной дружбе между народами, отличается тонким проникновением в думы и чаяния людей иных национальностей. И потому его художественное наследие, как и его идейное наследство, выходит за рамки одной только татарской культуры, являясь общим интернациональным достоянием.

Необоснованный арест по ложному обвинению ускорил течение тяжелого недуга, преследовавшего писателя. Жизнь Ибрагимова оборвалась 21 января 1938 года.

В фондах Национального музея хранится небольшой архив писателя, который представлен несколькими рукописями и фотографиями. Сотрудница музея А. М. Ильина в отчете за 1937 год пишет: «Указы менялись в течение года три раза. Материалы о деятелях революционного движения, социалистического строительства изъяты с фондов и экспозиции. В том числе фотографии, личные вещи, библиотека и рукописи писателя и видного общественного деятеля Г. Ибрагимова». Сложные были времена…

## БҮГЕНГЕ ПРОЗАДА Г. ИБРАҺИМОВ ТРАДИЦИЯЛӘРЕ

*Л. К. Хисмәтова (Казан)*

В этой статье рассматриваются традиции Г. Ибрагимова в современной прозе.

Галимҗан Ибраһимов – бөек шагыйрьләр Г. Тукай һәм Дәрдеменд, олуг әдипләр Г. Исхакый һәм Ф. Әмирхан, мәшһүр драматурглар Г. Камал һәм М. Фәйзиләр белән бергә, XX гасырның беренче чирегендә татар әдәбияты үсешенә аеруча зур өлеш керткән язучы. Әдипнең иҗат эшчәнлегенең төп тармакларын санап кына чыгу да аның олы образын күз алдына китереп бастырыр.

XX йөз башында татар милли әдәбиятының ныклы нигезләрен салган, аның алга үсешендә төп юнәлешен билгеләгән язучылар сафында Галимҗан Ибраһимовның үзенә лаек урыны бар. Г. Ибраһимов әдәбиятка XX йөз башында хезмәт ияләре социаль һәм милли азатлык өчен актив көрәшкә күтәрелгән чорда килә. Әдип әсәрләрендә иҗтимагый һәм шәхси мотивлар, аралашып, чор сурәтен тудыруга хезмәт итә.

Г. Ибраһимов үзенең беренче хикәяләрендә үк җәмгыять үсеше өчен мөһим мәсьәләләр күтәрергә, татар дөньясының гаделсезлегенә, иске тәртипләргә каршы чыгучы шәхесләрнең образларын тудырырга омтыла. Зәки шәкерт («Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясе, 1907) мәдрәсәдәге иске укыту ысулларына, кадимчелеккә каршы чыга. «Татар хатыны ниләр күрми» повестенда (1910) Гөлбану хатын-кызларның хокуксызлыгына каршы күтәрелә.

Яшь язучының башлангыч иҗатында үз чорының әһәмиятле мәсьәләләре гәүдәләнгән: татар мәдрәсәләрендә укыту-тәрбия эшенең тормыш таләпләренә җавап бирмәве, шәхес азатлыгы, саф мәхәббәт һәм социаль тигезсезлек, 1905 ел революциясе идеалларына тугрылыклылык, хатын-кыз азатлыгы һ. б. Болар, нигездә, мәгърифәтчелек позициясеннән килеп яктыртылалар.

Борынгы татар әдәбиятында ук хатын-кыз образын сурәтләү кеше тасвирының аерылгысыз өлеше булып тора. Үзенчәлекле күңел дөньясына ия булган хатын-кызлар образларының хис тирәнлеге, сөю дәрте, кешелек сыйфатлары тулы гәүдәләндерелә.

Иҗтимагый чынбарлык, заман әверелешләре язучы иҗатына көчле йогынты ясый. Ул үзгәрешләрнең кешеләр тормышына, аларның психологиясенә йогынтысын язучы геройлар язмышы аша сурәтли, аларга үз мөнәсәбәтен ачыклый. Әдәбиятның мөһим темаларының берсе булган хатын-кыз язмышы мәсьәләсенең татар әдәбиятында үсеш-үзгәрешен күзәтүдә бу ачык күренә.

Соңрак Г. Ибраһимов «Татар хатыны ниләр күрми» әсәренең икенче вариантын да яза. Бу әсәрдә татар хатынының язмышы инкыйлабка кадәрге чордагы татар авылы тормышы, татар халкының гореф-гадәте, традицияләре, гаилә мөнәсәбәтләре, андагы хатын-кыз урыны, гади халык хезмәте, яшәеше, авылның бай табигате фонында сурәтләнә. Бу әсәр татар әдәбиятында гына түгел, төрки халыклар әдәбиятында да үзен билдерә һәм тиешле урынын ала.

Г. Ибраһимовның киң колачлы талант иясе булуы аның иҗатында да ачык чагыла. Ул әдәбиятта татар дөньясын гына сурәтләп калмыйча, башка халыклар тормышына үтеп керә. Моны без «Казакъ кызы» романында ачык күрәбез.

Бу әсәрләр хәзер дә татар әдәбиятының иң матур үрнәкләреннән саналалар.

Заманында төрекмән язучысы Бирде Кербабаев: «Минем беренче әсәрләрем төрекмән хатын-кызларының азатлыгы темасына багышландылар. Икърар итә алам һәм моны шатланып әшлим: минем әсәрләрем Галимҗанның зур йогынтысы белән иҗат ителде. Ул, совет язучыларының беренчесе булып, гаилә һәм җәмәгать ирүенә каршы баш күтәргән мөселман хатын-кызы образын иҗат итте», – дип яза.

Әдәбиятта хатын-кыз язмышы һәрвакыт иң актуаль темаларның берсе булып тора. Бүгенге татар әдәбиятында да инкыйлабка кадәрге яшәештә татар хатын-кызының урыны һәм хокуклары турында язалар. Гөлчәчәк Галиеваның 2009 елда «Казан утлары» журналында басылып чыккан «Газзәбану» романы да нәкъ шул проблемаларны күтәрә.

2011 елда язучы һәм шагыйрә Гөлнур Якупованың «Ерткыч каны» дигән җыентыгы чыкты. Китапка шул

исемдәге повесть һәм «Кыз бала» романы кертелгән. Ике әсәр дә үткән заманнарда булган хәл-вакыйгаларны сурәтли, икесендә дә гомум халык язмышы, ил өстенә төшкән төрлечә сынауларны адәм баласының, аерым алганда хатын-кызның, үз иңендә күтәреп, ерып чыгарга омтылышы сурәтләнә. Язучының повесте да, романы да мавыктыргыч сюжетка корылган.

Язучы үз героен әледән-әле төрле катлаулы сынаулар алдына куя. Шуның белән кешенең башка тере җан ияләреннән аермалы рәвештә, төрле кискен хәлләрдә дә югалып калмый торган олы көчкә ия булуын исбатлый. Ул көч – акыл, кешегә бирелгән югары аң. Шуңа Һәдия кыргыйлык тормышында да чыныга, үз тәҗрибәсе белән байтак нәрсәгә төшенә. «Ерткыч каны» повесте үткәннәрне бүгенге көн күзлегеннән бәяли.

Язучы, әйткәнебезчә, укучыны үткән заманнарга алып китә. Әмма моннан зыян юк. Һәр заманның үзенең матур һәм аяныч гореф-гадәтләре бар. Аны оныту мөмкин түгел, һәр чорның җитешсезлекләре була. Алардан сабак алу зарур. Яңа буын киләчәктә үзенең ата-бабаларының хаталарын кабатламасын дисәк, тарихи үткәннәребезгә әйләнеп карау кирәк.

# С. ПОВАРИСОВ ХЕЗМӘТЛӘРЕНДӘ Г. ИБРАҺИМОВ ОБРАЗЫН ИНТЕРПРЕТАЦИЯЛӘҮ

*Н. Ш. Насыйбуллина (Казан)*

В статье дается анализ трилогии С. Поварисова («Заря пророка», «На седьмом небе», «Трагедия») о классике татарской литературы Галимзяне Ибрагимове, получившей большой отклик литераторов, ученых, языковедов и критиков Республики Башкортостан и Республики Татарстан. Затрагиваются темы воспитания, просвещения, политической жизни, роли человека в семье и обществе; выявляется литературный идеал – образ сильного человека. Г. Ибрагимов предстает как Пророк, вобравший в себя и радости, и горе всего татарского народа. В произведениях рядом стоят два понятия – величие и трагедия личности.

Күпмилләтле Ватаныбыз халыкларының культурасы тарихында үзенең үлемсез әсәрләре белән халкына, аның сәнгатенә шөһрәт китергән шәхесләр аз түгел. Шундый шәхесләрнең берсе – Башкортстанның халык язучысы, күренекле галим, Башкорт дәүләт университеты профессоры, филология фәннәре докторы, Башкортстан һәм Татарстан Республикаларының атказанган фән эшлеклесе, РФ югары белем бирү учреждениеләренең шәрәфле хезмәткәре, Г. Ибраһимов исемендәге премия лауреаты Суфиян Шәмсетдин улы Поварисов. Ул берьюлы ике юнәлештә – әдәби иҗатта да, тел гыйлеме өлкәсендә дә уңышлы эшләп килә. Иҗатын шагыйрь булып башлап җибәргән әдип әдәбиятның драматургия, публицистика, әдәби тәнкыйть, аеруча проза тармагындагы роман-повестьлары, хикәяләре белән китап сөючеләрне сөендерде. Соңгы ун елда гына аның тугыз романы басылды. Аларда татар халкының бай рухи дөньясы, авторның кешеләр язмышына педагогларча каравы, кешелеклелек мәсьәләсе, халык язмышы беренче планга куела.

Суфиян Поварисов илһамының бер канаты төрле характердагы, төрле жанрдагы әдәби иҗаты булса, икенче канаты – олы гыйльми эшчәнлеге. Ул Г. Ибраһимов әсәрләренең тел үзенчәлекләрен тикшерү өстендә иң күп эшләгән галимнәрнең берсе. «Татар әдәби телен үстерүдә Г. Ибраһимовның эшчәнлеге» дигән темага докторлык диссертациясен уңышлы яклады. Галимнең фәнни хезмәтләре язучылык эшчәнлегеннән аерылгысыз.

Суфиян Поварисов – ике трилогия авторы. Тәүге трилогиясе Бөек Ватан сугышы темасына багышланган «Язмыш корбаннары», «Ут эчендәге мәхәббәт», «Канлы бәхет» романнарын берләштерә.

Икенче трилогия-эпопея бөек язучы, Хезмәт Батыры, тиңдәшсез сүз сәнгате остасы, репрессия корбаны, яңа татар совет әдәбиятына нигез салучы әдипләрнең берсе, талантлы тәнкыйтьче, әдәбият теоретигы, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе Г. Ибраһимовка багышланган. Башта романнар бер-бер артлы «Казан утлары» журналында басылып чыктылар (1996 ел, 10, 11 саннар). Соңыннан аерым китап булып Казанның «Матбугат йортты»нда (1999–2001), Татарстан китап нәшриятында (2004–2006) дөнья күрделәр.

«Пәйгамбәр таңы» романында XIX һәм гарасатлы XX гасырлар кисешкән чорда Башкортстанның хәзерге Авыргазы районы Солтанморат авылында туып, тарихка канлы вакыйгалары, сыйнфый бәрелешләре белән кереп калган фаҗигале елларда шәхес буларак формалашкан Галимҗан Ибраһимовның балачак һәм яшүсмер еллары сурәтләнә.

Әсәр баланың дөньяга килүе, аңа исем кушу вакыйгалары белән башланып китә. Исеме җисеменә туры килсен, йөрәк тибешен, эчке дөньясын, күңел хәзинәсен, холкы-фигылен аңлатып торсын, дәвер пәйгамбәре исемен йөртерлек укымышлы, акыллы, галим кеше булсын иде, дип, Гыйрфан мулла улына Галимҗан исемен куша. Аның фамилиясе дә Ибраһим Галәйһиссәламнең исеменнән алынган, чөнки нәсел тамыры Ибраһим хәзрәттән килә.

Әсәрдә баланы тәрбияләп үстерүче ата һәм ана образлары зур әһәмияткә ия. Атасының кырыс табигатенә, гаделлегенә, эш сөючәнлегенә күнеккән балалар аның һәр сүзен иман шарты кебек кабул итәргә гадәтләнеп үсәләр. «Ата әйтсә – хак әйтә», «Ата сүзе – иман» дигән төшенчәләргә тугры калалар.

Вәли мулла мәдрәсәдән куылгач, Галимҗан әтисенә: «Әткәй! Дөреслекне якларга, иманга тугрылыклы булырга, алдашмаска син безне үзең өйрәттең бит; әнкәй дә шул рухта тәрбияләде», – ди. Романда кешелеклелек, кечелеклелек, кеше бәхете өчен яшәү алгы планга куела. Әсәрнең кыйммәте дә әнә шунда. Гыйрфан мулла белән Хәсәнә абыстай шуларның бөек үрнәген күрсәтеп яшиләр, балалары күңеленә дә шундый

орлыкларны салалар. «Дин кануннары буенча икмәкнең кырыктан бер өлешен ятимнәргә, ярлыларга, Актүти кебек карт-корыга бирергә тиешбез. Тәңрем үзе шаһит, мин аны биш тапкырга арттырам», – ди Гыйрфан мулла. Хәсәнә абыстай да авылда кем генә бала тапмасын, аш-су тулы табак-савытын күтәреп аның янына ашыга, һәрчак хаер биреп тора, ятим кыз Мәдинә-Акчәчкәгә ярдәм итә. Алар кешеләрне ярлыга, байга аермый, күңел байлыгы, күңел ярлылыгы буенча эш итәләр. Язучы кешеләрне Галимҗан тарафыннан 4 төркемгә бүлдерә: «Югарыга әтисен дә куеп карады ул. Ләкин башлык түгел. Шуңа күрә, ил, халык мәнфәгате белән яшәү ягыннан караганда, аны өстән аска табан икенче баскычка бастырырга мөмкиндер. Яхшы, иҗтиһадлы башлыкка ул җанын фида кылырга да әзер тора. Өченче төркемгә Мөбахис мәзин кебек хәйләкәрләр керә. Дүртенчесенә – староста Тәхлис ишеләр. Аларга арба ватылса – утын, үгез үлсә – ит. Ә менә Хөрмәтулла абзый сыманнарны кая куярга? Андыйлар, үзләре кыерсытылган булсалар да, башкаларга яманлык теләми. Димәк ки, олы йөрәкле, киң күңелле, кешелекле булып чыгалар. Алар икенче төркемнең бер күзәнәге...» (1, 263).

Галимҗан турында әтисе горурлык белән: «Әнә нинди ул үстерәбез... – кайбер утын авыз кебек Хәрти дими бит. Матур итеп, олыларны кадер-хөрмәт итү йөзеннән, эчке бер җылылык, илаһилык белән “Хөрмәтулла абзый” дип әйтә. Димәк ки, һәр адәми затны кешегә саный. Ул гына да түгел, аның язмышы өчен ут йотып, үрсәләнеп йөри. Югалган сарыкны көне буе эзләп иза чиккәннәр. Дөрес әйтә бит, шайтан алгыры: “Ырынбур качмас әле” – ди. Әйе, Оренбург качмый да, югалмый да, җир дә упмый аны. Ә кеше югалса? Тап син аны яңадан. Менә бит ничек зур уйлый бу “таш маңгай”. Пәйгамбәрләр башы бар анда. Пәйгамбәрләр башы!» (1, 110)

Ходай Тәгаләнең пәйгамбәрләре кешелек дөньясын вәхшилектән, кыргыйлыктан йолып калып, халыкны тәрбияләгән, Ходай Тәгалә кушкан якты юлга чыгарган. Аларның бу миссиясе язучыларга тапшырылган, алар пәйгамбәрләр кебек үк, кешелек дөньясын матурлыкка өндәгән, кешеләрдә үзара дус булу, тыныч тормышта яшәү, бер-береңне хөрмәт итү кебек асыл сыйфатлар тәрбияләгән.

Суфиян Поварисов һәр бүлекне үгет-нәсыйхәт, киңәш бирердәй ата-ана кисәтүе, бала озатканда уйланулар, ана фатихасы кебек бик матур шигъри юллар белән башлап китә. Мәсәлән:

«Тормыш юлы түгел бит ул шома көзге –
Күрәшәләр анда яман белән изге;
Йөргән җирең булмас һәрчак чәчкә дә гөл,
Аяк асты тулы бәла – син шуны бел» (1, 52).

«И газизем, аяк бастың киң дөньяга,
Юлдаш булсын зур бәхетләр – атла алга;
Гөлләр сипсен фәрештәләр юлларыңа,
Авыр булса, һич сыкранма – түз барына» (1, 34).

Солтанморат, Зәңгәр Чишмә буйларының искиткеч гүзәл табигате кешеләрнең якты күңеле белән бергә үрелеп тасвирлана. «Солтанморат бит ул! Ходай Тәгалә аңа оҗмах бакчасының бер як читен кисеп биргән», – ди язучы. Табигать матурлыгы белән хозурлану кешене олы йөрәкле итә. Әтисенең: «Табигать йөрәге матур кешеләргә генә ачыла» дигән сүзләрен булачак язучы күңел сандыгына мәңгелеккә салып куя.

Роман 1906 елда Галимҗанның туган авылыннан Уфага «Галия» мәдрәсәсенә укырга китүе белән тәмамлана.

Әсәр «Казан утлары»нда басылып чыккач авторга төрле тарафлардан бик күп хатлар килә. Язучы Тәүфикъ Әйди: «...кочегезне “Пәйгамбәр таңы” романының дәвамын язуга багышласагыз, минемчә, отышлырак булыр иде. Ибраһимовның катлаулы тормыш, иҗат дәверен сурәтләү үтә җаваплы һәм кыен эш, аңа теләсә кем тотына алмый. Бездә әнә шундый батырлык таләп иткән иҗатка бирелүдән өркү, тарту-сузу аркасында даһиларыбызның балачагы гына кәгазьгә төшәргә өлгерә. Сезнең башлангыч андый язмышка очрамасын иде», – ди (5, 79).

Язучы героеның образын тулырак ачу максатыннан тагын ике роман иҗат итте. «Күкнең җиденче катында» (1999) дигән икенче өлеше Г. Ибраһимовның 1906–1917 еллардагы гомерен үз эченә ала.

Әсәрнең герое уйлап чыгарылган персонаж түгел – киң билгеле конкрет кеше, калебе-холкы ифрат катлаулы: усал, кырыс, моңлы, үзсүзле, башбирмәс, шул ук вакытта кешелекле, кечелекле, зиһенле, аңлы, көрәшчән, көчле рухлы. Ул гынамы: Галимҗан Ибраһимов – атаклы язучы, тарихчы, әдәбият галиме, публицист, методист, педагог, тел галиме, тәнкыйтьче, революционер. Шул сыйфатлар чытырманлыгында адашып тукталып калмыйча гүзәл әдәби образ коеп, Суфиян Поварисов үзендә пәйгамбәрләр зирәклеге, Галимҗанныкыдай сәләт һәм осталык барлыгын дәлилли.

Бу романнарның дәвамы «Оҗмагка бер адым» дип атала. Трилогиянең өченче кисәгендә репрессия корбаны Г. Ибраһимовның шәхес буларак формалашкан һәм «халык дошманы» дигән кара ягылганнан алып, төрмәдә һәлак булуына кадәрге тормыш юлы яктыртыла. Романның беренче җөмләсеннән үк без Г. Ибраһимовның «халык дошманы» булуын беләбез. Алга таба мондый хәлгә дучар булуның сәбәпләре, Г. Ибраһимовның үткәне – Ленин һәм Сталин белән бергә эшләве, ул еллардагы авырлыкларны җиңүе, гражданнар сугышы вакытында Колчак тылында разведчик булып йөрүе, кайнар мәхәббәте, якыннарын югалту кайгысын кичерү, Ялтада дәваланып яткан җиреннән кулга алынуы, Казанга кайтарып төрмәгә ябылуы, андагы кичерешләре сурәтләнә.

1937 елның 29 сентябрендә Г. Ибраһимов кулга алына. Ул бу вакытта Ялтада дәвалана торган була. Кичкә таба Г. Ибраһимов бүлмәсенә ике НКВД кешесе килеп керә. Бүлмәнең астын өскә китереп, бөтен кәгазьләрне актарырга керешәләр. Тентү үткәрүчеләр арасында Г. Ибраһимовның «шәкерте» Мөбарәк тә була. Бу кеше белән без Г. Ибраһимовтан соңгы сорау алганда да очрашабыз. Димәк, остазының үлеменә шаһит булган бу кеше йөзендә автор каһәр төшкән репрессия елларында заманның яман агышына җайланып алган, үз тиресен саклаган, үзеннән мең өлеш өстен торган кешеләр язмышына төкереп караган кешеләрне сурәтли.

Г. Ибраһимовны кулга алалар, ә аның тормыш иптәше Хәдичә ханым, ире артыннан ияреп, Казанга китә. Ләкин аны да «халык дошманының хатыны» дип төрмәгә утыртып куялар, бер ай буена җәзалыйлар, ә чыгаргач ул «анасыннан аерылып калган бәбкәдәй, ялгыз башын кая куярга белми, шәһәр урамнарында аптырап йөри».

Төрмәдә Г. Ибраһимов үзенең үткәннәрен исенә төшерә. Сталин аңа Үзәк мөселман комиссариаты

оештыруны тапшыра, шулай итеп, ул Сталин кул астында эшли башлый. 1918 елны аклар һәм чехларның кара дулкыны Казан, Самара һ. б. күп кенә калаларга ябырылгач, Г. Ибраһимовның җаны түзә алмый, һәм үзенең якташы Көнчыгыш фронты өчен батальоннар оештыру башлыгы Мәхмүт Шаһиәхмәтов янына килә, үзен берәр батальонга кушуын сорый. Аны аклар ягына разведчик итеп җибәрергә булалар. Өстенә ямаулы бишмәт кидереп, башына тишек-тошык эшләпә элеп, иягенә биленә кадәр сакал ябыштырып, арбага җигелгән атка утыртып, кырык тартмачы карт кыяфәтендә Г. Ибраһимовны яшерен юллар белән фронт сызыгына үткәрәләр.

1923 елда Г. Ибраһимов Казан университетына лекция укырга чакырыла. Аның керүен студентлар түземсезлек белән көтәләр, чөнки аларны бу лекторның язмышы, татар дөньясында үзенчәлекле шәхес, милләт йолдызы булып балкуы, Ленин, Сталин янында эшләве, Колчак тылында кылган каһарманлыклары – барысы да кызыксындыра. Лекциядән соң ул медицина факультетында укучы Гөлсем исемле кыз белән таныша. Гөлсем башка белгечлек буенча укыса да, әдәбият белән бик кызыксына, Галимҗанның лекцияләрен тыңларга килә. Тора-бара бу дустанә мөнәсәбәтләр мәхәббәткә әверелә. Уллары Рөстәм дөньяга килә. Ләкин әти кешегә улын рәхәтләнеп сөяргә насыйп булмый. Г. Ибраһимов туберкулез белән авырый, улын үзенең янына якын җибәрергә курка. Дүрт яшь ярымлык вакытында Рөстәмне йөрәк параличы якты дөньядан алып китә. Бала югалту кайгысын икесе дә бик авыр кичерә. Берникадәр вакыт үткәч, Гөлсем ханым Г. Ибраһимовны ташлап чыгып китә. Әсәрдә Галимҗанның кичерешләре табигать күренеше белән параллель куела. Кинәт көчле гарасат куба, җир тетри башлый, җирнең асты өскә килә.

Төрмәдә сорау алу вакытында Г. Ибраһимовны күп тапкыр «халык дошманы» булуын танып, кул куюын таләп итәләр, ләкин ул кул куймый. Соңгы сорау вакытында ерткыч бүредәй бер тентүче, каләм белән, аның күзләрен төртеп тишә, моннан соң бик каты кыйныйлар. Бу көнне, 1938 елның 20 гыйнварында Галимҗан Ибраһимов мәңгелеккә күчә.

С. Поварисов каһәрле репрессия елларында илнең алтын баганасына торырлык ватан каһарманнарының корбан булуы хакында ачынып яза. Совет хакимиятен оештыру һәм ныгыту өчен көчен һәм сәламәтлеген кызганмаган, коммунистлар партиясенең һәр карарын тормышка ашыру өчен хәтта фанатикларча хезмәт иткән көрәшче-революционерның шундый хәлгә дучар булуын сурәтли. Аның герое җирдә явызлыкның бетерелүен, гаделлекнең тантана итүен күрергә тели һәм шуңа бөтен җаны-тәне белән омтыла.

Моңа кадәр Г. Ибраһимовның тормыш юлын тулысынча чагылдырган әсәрләр юк дәрәҗәсендә иде. 1987 елда Гөлсем Мөхәммәтованың «Яшьлек көннәре» һәм «Эзләнүләр» исемле документаль повестьларында Г. Ибраһимовның 1909 елдан алып февраль революциясенә кадәрге тормыш юлы бәян ителә. Афзал Шамовның «Г. Ибраһимов турында истәлекләр» дигән китабында әдипнең тормыш юлы өлешчә генә яктыртыла.

С. Поварисов «Пәйгамбәр таңы», «Күкнең җиденче катында», «Оҗмахка бер адым» романнарында бөек әдипнең тормыш һәм иҗат эволюциясен бар нечкәлекләре белән ачып бирүгә ирешә. Таһир Таһиров «Таңхәйран калдыра» исемле мәкаләсендә: «Поварисовның ялкынлы революционер, әдәбият классигы, академик Галимҗан Ибраһимовны әдәби образга, романнар героена әверелдерергә җөрьәт итүе үзе бер кыюлык булса, шул авыр эшне искиткеч уңышлы башкарып чыгуы – чын-чыннан иҗади батырлык, әдәби каһарманлык. Трилогия – татар-башкорт әдәбиятының гына түгел, бөтен төрки халыклар мәдәниятенең зур казанышы, авторның таң-хәйран калырлык уңышы», – дип бәя бирә (4, 2).

Гомумән, трилогия С. Поварисовның тарихи темада эшләвенең янә бер уңышлы нәтиҗәсе булды, халкыбызның бөек улы, күренекле дәүләт эшлеклесе һәм төрки дөньяга танылган галим, Галимҗан Ибраһимовның исемен художestволы алымда мәңгеләштерүдә бәһаләп бетергесез иҗади каһарманлык үрнәге дә ул. Реаль шәхеснең тулы образын тудыру, фаҗигале язмышын тасвирлау – язучының талантыннан килә. С. Поварисовның таланты киң колачлы һәм күпкырлы булуы, тормыш күренешләренә һәм кеше күңеленә тирән үтеп керү көче, үткенлеге белән аерылып тора. Аның тирән эзләнүле трилогиясе әдипнең тагын да югарырак баскычка күтәрелүен генә түгел, талантының күпкырлы булуын да, иҗат даирәсенең киңлеген дә раслады.

ӘДӘБИЯТ

1. Поварисов С. Ш. Пәйгамбәр таңы: Роман / Суфиян Поварисов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 285 б.
2. Поварисов С. Ш. Күкнең җиденче катында: Роман / Суфиян Поварисов. – Казан: Матбугат йорты, 1999. – 279 б.
3. Поварисов С. Ш. Оҗмахка бер адым: Романнар / Суфиян Поварисов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 464 б.
4. Таһиров Т. Таң-хәйран калдыра / Таһир Таһиров // Кызыл таң. – 2001, февраль.
5. Поварисов С. Ш. Прометей яки Галимҗан Ибраһимов хәяты / С. Ш. Поварисов // Галимҗан Ибраһимов һәм XXI гасыр: Тууына 120 ел тулуга багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. – Казан, 2007. – 332 б.

## С. ПОВАРИСОВ ИҖАТЫНДА ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ШӘХЕСЕ

***А. Ф. Әсфәндиярова (Уфа)***

В историко-биографических романах С. Поварисова «Заря пророка», «На седьмом небе», «Один шаг до рая» создается образ великого писателя-классика, показывается его духовное формирование. Показывая своего героя с разных сторон (работа над художественными произведениями, педагогическая, научная и общественная деятельность), автор утверждает неразрывную связь духовно-нравственных черт человека с его исторической эпохой. Каждый шаг писателя обусловлен самой общественно-политической жизнью страны.

Г. Ибраһимовның үткән тормыш юлын һәм иҗатын фәнни өйрәнеп, татар укучысына җиткерүдә М. Хәсәнов, Г. Халит, А. Шамов, Ү. Гыймадиев һ. б. ның хезмәтләре аеруча зур әһәмияткә ия. Г. Ибраһимовның

сәнгатьле образын тудырырга омтылган әдәби әсәрләр арасыннан Гөлсем Мөхәммәдованың «Яшьлек көннәре» һәм «Эзләнүләр» (1987) исемле документаль повестьларын билгеләргә була. Авторның «Яшьлек еллары» һәм «Эзләнүләр» исемле повестьларындагы Галимҗан образы халкыбызның ялкынлы көрәшчесе буларак яктыртыла. Аның иҗтимагый-сәяси карашларына, эшчәнлегенә әсәрдә күп урын бирелгән. Геройның характерын формалаштыруда автор төрле сынаулар алымын кертә. Мәсәлән, аның «Хөсәения» шәкертләре алдында фикер йөртү күренешен сурәтләү язучыга героеның киләчәктә дөрес юл сайлап ала белүен күрсәтү өчен кирәк була. Галимҗан фикеренчә, һәрбер гыйлемне, һәрбер фәнне тикшереп укып утыру, аңа вакыт сарыф итү һич кирәк түгел. Мантыйкны тиешенчә үзләштерсәң, аның бөтен кануннарын, бөтен кагыйдәләрен белсәң, башка фәннәрне укымыйча, бер карап чыгу белән дә белергә мөмкин. Ләкин «Хөсәения» шәкертләре Галимҗанның белемен сынап карарга булалар. Берничә сорау биргәннән соң, Галимҗан җавапсыз кала. Шушы сынау аны бөтенләй үзгәртә.

Әсәрдә гәүдәләндерелгән шәхесләр, тасвирланган вакыйгалар – барысы да Мәскәү, Киев, Казан, Уфа архивларында сакланган материалларга, Афзал Шамов төзегән «Г. Ибраһимов турында истәлекләр» дигән китапка, Мансур Хәсәновның «Г. Ибраһимов: тормыш юлы һәм иҗаты» хезмәтенә һәм башка документаль чыганакларга таянып башкарылган.

Татар әдәбиятында Г. Ибраһимов тормышын һәм иҗатын сәнгатьчә чагылдырган С. Поварисовның трилогиясе аерым кызыксыну белән кабул ителде. Әдип өч романнан торган хезмәтендә татар прозасының классигы, бөек шәхесебезнең тормыш һәм иҗат эволюциясен ачып бирүгә омтылган. Трилогиянең ике өлеше: Г. Ибраһимовның 1906 елга кадәрге балалык чорына багышланган «Пәйгамбәр таңы» һәм 1906–1917 еллардагы гомерен үз эченә алган «Күкнең җиденче катында» дигән әсәрләре 1999 елда китап булып басылып чыгалар. Романның соңгы өлеше «Оҗмахка бер адым» китабы 2000 елда дөнья күрә. Жанр формасы ягыннан С. Поварисовның трилогиясе – тарихи-биографик роман. Олуг шәхес турында әдәби әсәр язу теләге язучының йөрәгендә күп еллар дәвамында яши килә. Аның «Пәйгамбәр таңы» китабы – XIX һәм гарасатлы XX гасырлар кисешкән чорда, Башкортстанның хәзерге Авыргазы районы, Солтанморат авылында туып, тарихка канлы вакыйгалары, сыйнфый бәрелешләре белән кереп калган дәвердә, шәхес буларак формалашкан Галимҗанның балачак һәм үсмер еллары хакында. Романның беренче битләрендә үк без Гыйрфан мулла, Хәсәнә абыстай образлары белән танышабыз. Һәм бу – очраклы түгел. Галимҗан Ибраһимов кебек бөек талант иясенең килеп чыгышы һәркемне кызыксындыра. Ата-ана тәрбиясенең даирәсе – ул геройның формалашу мохите. Шуңа күрә, автор героеның кешелеклелек кебек асыл сыйфатларын күрсәтүдә ата-ана тәрбиясенең мөһим роль уйнавына аеруча басым ясый. Баланы тәрбияләп үстерүче ата һәм ана образлары зур әһәмияткә ия. Әнисе Хәсәнә абыстай зур укымышлы, төскә чибәр, сабыр холыклы, түземле, һәрчак акыл белән эш итүче шәхес булып гәүдәләнә. Гыйрфан мулла – үзсүзле, кырыс холыклы, кызу канлы, дөреслекне, гаделлекне яклаучы, зур белемле, авылның абруйлы кешесе булып күз алдына баса. Язучының сурәтләвенчә, әнисенең сабырлыгы һәрвакыт атаның кызулыгын басып килә. Хәсәнә абыстай балаларына сугуга каршы, безнең кебек динле кешегә матчада чыбык тоту килешкән эш түгел, сугылган-кагылган балада акрынлап кире сыйфатлар күбәя бара, ди ул. Хәсәнә абыстай балаларына «Кыйссаи Йосыф», сабах җиле, фәрештәләр, пәйгамбәрләр турында күп сөйли. Йосыф пәйгамбәрнең кешелеклелек, кече күңеллелек сыйфатлары, аның зинданда утырганда бәндәләргә карата миһербанлылык тойгылары белән яшәве, Зөләйханың искиткеч маҗаралы мәхәббәте... – барысы да сабый күңеленә яшәүнең бер бинигһая яктырткыч көче булып салына, сеңә бара. Язучы романда шундый бер эпизод китерә: «Гыйрфан мулла улының пәйгамбәр буласын төшендә күрә. Балаларны укыту, аларга дөрес тәрбия бирү, күзләрен ачу – ата-ана өстендә. Бу юнәлештә Хәсәнә абыстайның да, Гыйрфан мулланың да өлеше зур. Улын аң-белемле итү өчен Гыйрфан мулла бөтен көчен-сәләтен бирә. Ул Галимҗанны мәгърифәт диңгезендә 3–4 яшьтән йөздерә башлый. Атасының кырыс табигатенә, гаделлегенә, эш сөючәнлегенә күнеккән балалар аның һәр сүзен иман шарты кебек кабул итәргә гадәтләнеп үсәләр».

Гомумән, әсәрнең баштагы өлешләрендә Гыйрфан мулла белән Хәсәнә абыстай образлары кешелеклелек, кече күңеллелек сыйфатларының бөек үрнәкләре буларак киң гәүдәләнеш таба. Шушы асыл сыйфатларның орлыклары аларның балалары күңелендә нинди шытым ала баруын күрсәтә. М. Мәһдиев «Мәшәкатьле һөнәр» исемле язмасында болай дигән: «Бөтен хикмәт – балачакта. Балачакта нинди юнәлеш бирелсә – кеше гомере буе шуны эзли, үзе дә аңламастан, шуңа омтыла икән. Кешене формалаштыруда өч шарт бар: нәселдән килгән сыйфатлар, тирәлек һәм тәрбия! Кеше гомерендә, кеше биографиясендә әнә шул өч шарт даими рәвештә катнаша, гомеренең төрле мизгелләрендә шул шартларның әле берсе, әле икенчесе калкып чыга» (1, 78). С. Поварисов та үз героеның формалашуын күрсәтүдә әнә шуларны күз уңаенда тотып эш иткән. Геройның характеры кече вакыттан ук ничек итеп формалаша башлавына басым ясаган. Баштагы өлештә бу үсеш ата-ана тәрбиясе кысаларында күрсәтелә. Хезмәтне сөю, дөреслеккә тугры булу, кешелекле, миһербанлы, намуслы булу кебек сыйфатларга нигез шунда салына.

Икенче китап, нигездә, 1906–1917 еллар вакыйгаларын үз эченә ала. С. Поварисов Галимҗан образы аша шул чор кешеләренең, тормышының бар якларын да яктыртырга омтылган. Язучы Г. Ибраһимов шәхесенә кагылышлы булган конкрет, фактик материаллардан читләшмәгән, киресенчә, китаптагы вакыйгалар, төрле күренешләр хронологик тәртиптә сурәтләнгән. 1906 елда Галимҗан «Галия» мәдрәсәсенә укырга кабул ителә, ләкин 1908 елның язында «Коръән Алладанмы, түгелме?» дигән хезмәте өчен, ул мәдрәсәдән куыла. Алга таба автор, Галимҗанның казакъ далаларында балалар укыту күренешләрен, Миасстагы эшчәнлеген, Казан, Киев шәһәрләре белән бәйле вакыйгаларны эзлекле рәвештә тасвирлый.

Трилогиянең «Оҗмахка бер адым» дигән өченче кисәгендә вакыйгалар исә үзәк геройның утызынчы еллардагы гарасатлы, катлаулы язмышын үз эченә ала. Тәүге ике роман классикның балачагы, характеры чыныккан, иҗат юлына баскан, көрәш мәйданына чыккан шанлы еллар турында булса, «Оҗмахка бер адым»

әсәрендә Г. Ибраһимовның Хезмәт Герое, олы галим, талантлы язучы дәрәҗәсенә ирешкән чаклары, шул ук вакытта коточкыч фаҗига кичергән көннәре, газаплы уйланулары, фәлсәфи фикерләре сурәтләнгән. «Плэтән» төрмәсендә Галимҗан үзенең бөтен гомерен башыннан кичерә. Хәтер бизмәненә салып, күргәннәрен янә йөрәге аша үткәрә. Билгеле булуынча, Галимҗан Ибраһимов гражданнар сугышында актив катнаша, аннары ул Бөтенроссия Үзәк Башкарма Комитеты әгъзасы итеп сайлана, Милләтләр эше буенча Комиссариатның төрле бүлекләрен җитәкли, Ленин, Сталин даирәсендә эшли, Казанда Академик үзәк оештыра, язучылар берлегенә нигез сала, аның җитәкчесе була. Романның беренче бүлегендә Г. Ибраһимовның Ялтадагы тормышы, нахакка кулга алыну вакыйгалары, аннары төрмәдә газап чигү күренешләре сурәтләнә. Вакыйгалар төп геройның хатирәләр тезмәсе агышы аша тасвирлана башлый. Г. Ибраһимов язмышындагы «Плэтән» төрмәсе белән бәйле булган хәлләр хакында фактик материалларны табу авыр. Язучының «Оҗмахка бер адым» әсәре хакында С. Сафуанов болай дигән: «С. Поварисов аның шушы моментта бөтен үткән тормыш, көрәш юлын хәтерләп, анализлап чыгуын күрсәтә. Герой әйтерсең лә үз эшчәнлегенә йомгак ясый, бәһа бирә, шулардан чыгып, үзенең әлеге язмышка ни сәбәпле дучар булуы турында уйлана. Әлбәттә, укучы буларак, олы язучының үз җәлладлары белән очрашуы, сорау алу моментларын тулырак күрәсе килгән иде. Ләкин алар әсәрдә җитәрлек урын алмаган кебек. Бу хәл, ихтимал, С. Поварисовның Уфада яшәвеннән, Г. Ибраһимовның тоткынлыкта үткәргән көннәрен, аңардан сорау алу материалларын тиешенчә өйрәнү мөмкинлеге булмаудан киләдер» (2, 317). Дөрес, Г. Ибраһимовның тоткынлыктагы көннәре хакындагы архив материаллары белән эш итә алмау, ахырда, язучыны иҗади уйдырмага этәрә.

Шулай итеп, С. Поварисов Галимҗан Ибраһимов язмышының аерым бер чорына гына тукталмаган, гомумән, героеның балачак, үсмер елларыннан алып, характеры формалашкан, тормыш тәҗрибәсе туплаган олы, горур милләт улы дәрәҗәсенә күтәрелгән һәм совет системасы тарафыннан һәлак ителгән вакытына кадәр тасвирлаган.

Әдип үз героеның характерындагы кешелеклелек сыйфатын аның барлык башка асыл сыйфатларыннан да калкурак итеп бирергә омтылган. Бу омтылыш заман рухына җавап бирә торган эстетик әһәмияткә ия.

ӘДӘБИЯТ


1. Мәһдиев М. Мәшәкатьле һөнәр. «Идел» альманахы. – Казан, 1984. –78 б.

2. Сафуанов С. Рухи күперләр / С. Сафуанов. – Уфа, 2000. – 367 б.


# ОБЩЕЕ И ОСОБЕННОЕ В СУДЬБАХ И В ТВОРЧЕСТВЕ ГАЛИМЗЯНА ИБРАГИМОВА И КЕДРА МИТРЕЯ


***В. Х. Хакимова (Ижевск)***


Основная часть художественно-поэтического арсенала, тип мышления и национальная картина мира всех народов Урало-Поволжья тесно связаны. Формирование любой литературной общности своими корнями уходит в глубь истории народов, и литературная общность вызревает в недрах историко-культурной общности того или иного региона. Литературу региона Урало-Поволжья, представленную татарами, башкирами, чувашами, удмуртами, коми, мари, мордвой, у которых культуры тесно переплетены, невозможно изучать изолированно.

Разностороннее творчество Галимзяна Ибрагимова (1887–1938), продолжавшего лучшие традиции критического реализма и романтизма классиков татарской, русской и западноевропейской литератур, и творчества Кедра Митрея (1892–1949), внесшего неоценимый вклад в зарождение художественной литературы удмуртского народа, еще не подвергнуто сравнительно-сопоставительному анализу. Сегодня в наших национальных литературах наблюдается повышенный интерес к духовному состоянию нации, осмысление которого невозможно без обращения к периоду формирования национального возрождения и воплощения этого сложного процесса в художественном творчестве на рубеже XIX–XX веков.

Изучая биографии выбранных нами двух писателей, можно в их судьбах обнаружить много общего. И тот, и другой – выходцы из бедного сословия. Оба трудолюбивы, плодотворно работали в любых условиях. Оба рано обратились к литературной деятельности, первое свое произведение каждый написал в возрасте 18–19 лет, уже тогда поднимая проблемы нравственного совершенствования личности, затрагивая тему простого человека, находящегося в жестоких условиях окружающего мира.

Их объединял и род деятельности: учительство, журналистика, публицистика, издательское дело. Множество параллелей в их жизни заставляет невольно задуматься: не об одном и том же ли человеке читаешь? Оба – гуманисты, просветители, талантливые организаторы, общественные деятели, лидеры, руководители. Оба были людьми сильного духа, твердого характера, с резко выраженным чувством собственного достоинства, неприятием несправедливости.

Оба писателя жили в переломное для России и своего народа время. Каждый формировался как личность, как писатель и общественный деятель под влиянием не только национальной культуры, но и традиций русской и западной литературы, революционных и демократических традиций, и потому оба пережили непонимание со стороны современников и будущих поколений.

Оба писателя отличаются многогранностью таланта и творческой продуктивностью. Их объединяют открытость гражданской позиции и ориентация на массового читателя. Оба стремились влиять на обще-

ственно-политические события с помощью своих произведений. Они использовали различные жанры.

И Галимзян Ибрагимов, и Кедра Митрей видели в революции 1917 года головокружительные перспективы, приветствовали ее, воспринимая ее, надеясь, что она приведет к справедливому решению национальной политики в многонациональной стране. Но когда новая политическая система трансформировалась в однопартийный большевистский террористический режим, они поняли, что их надеждам не суждено сбыться.

Оба писателя были репрессированы как враги народа. Репрессии 1929–1938 гг. затронули все слои общества; беспрецедентные масштабы приняли по решению «троек» массовые расстрелы и применение принудительного наказания в системе ГУЛАГа. В Татарстане были репрессированы многие видные политические деятели и работники науки и культуры. В их числе – выдающиеся татарские писатели Г. Ибрагимов, С. Сунчалей, Ш. Усманов, Х. Туфан, Ф. Карим, И. Салахов и многие другие.

В Удмуртии были репрессированы писатели Кузебай Герд, Кедра Митрей, Ашальчи Оки, Константин Яковлев, Михаил Тимашев, Трокай Борисов, Михаил Коновалов, Григорий Медведев и др.

Обозначив типологические общие черты в человеческих судьбах и творческих обликах Галимзяна Ибрагимова и Кедра Митрея (Дмитрия Корепанова), рассмотрим теперь более подробно и конкретно национальное своеобразие и индивидуальную неповторимость каждого из них.

Литературно-творческая деятельность выдающегося писателя-классика татарской литературы, крупного филолога и историка, известного общественного деятеля Галимзяна Ибрагимова началась в 1907 году, когда он написал первый рассказ «Изгнание Заки шакирда из медресе», опубликованного в газете «Альислах». А спустя три года (в 1910 г.) рассказ вышел в отдельном издании. Автор описал факты из своей жизни в Оренбургском медресе. В лице главного героя шакирда Заки мы видим образ молодого человека, пробуждающегося к активному действию, протестующего против духовного и интеллектуального порабощения. Подобно самому писателю, его герой изгоняется из медресе за вольнодумие и «недостойное» поведение. Поэтому нельзя не видеть в Заки черт положительного героя.

Первым крупным произведением Кедра Митрея была повесть «Дитя больного века», написанная на русском языке (1911). При жизни писателя из него печатались лишь отрывки. Он учился в Казанской инородческой учительской семинарии. Но окончить семинарию Д. Корепанову не удалось. Его исключили на последнем курсе. Официальной причиной исключения была болезнь. Но главной причиной послужила крупная стычка семинариста с начальством, отказ от изучения Закона Божия. Поэтому и объявили Дмитрия душевнобольным. Но в своей автобиографической повести автор не себя считает больным, больным он называет XX век, а себя – страдающим объектом.

Формирование мировоззрения и становление характера Кедра Митрея происходило в период обучения в Казани. Об этом можно судить по его автобиографической повести «Дитя больного века». Хотя главный герой называет себя атеистом, такое утверждение правомерно лишь по отношению к христианской религии, потому что автор в душе остается сторонником обожествляющих Природу. Герои произведений и Г. Ибрагимова, и Кедра Митрея по существу являются «детьми природы», поклоняются силам природы, живут в гармонии с природой.

Во многих произведениях и Г. Ибрагимова, и Кедра Митрея есть элементы автобиографии. В рассказе «Изгнание Заки шакирда из медресе» автор приходит к выводу о влиянии внешних факторов на становление личности. Его современник Кедра Митрей своей жизнью и творчеством стремился решить ту же проблему, что отразилось в его автобиографической повести «Дитя больного века».

В произведениях содержатся ценные сведения о быте татарского и удмуртского народов, о постановке просвещения того времени в казенных учебных заведениях. У авторов-юношей пробуждается протест против унижения человеческой личности, они остро переживают унижение, угнетенное положение.

В произведениях «Изгнание Заки шакирда из медресе» Г. Ибрагимова и «Дитя больного века» Кедра Митрея намечено множество тем и проблем, но главная из них – становление самосознания молодого человека из народа. В произведениях затронута проблема: роль интеллигенции в просвещении народа. Надо сказать, у обоих авторов это первое юношеское произведение, во многих аспектах далеко не совершенное, как по форме, так и по содержанию, молодым прозаикам многое еще было не под силу.

Действие в произведениях «Изгнание Заки шакирда из медресе» и «Дитя больного века» относится ко времени послереволюционной реакции, расцвета идеализма, богоискательства. Авторы произведений не хотят мириться с противоречиями. Главное в рассказе и повести – осмысление пути духовных исканий юношей татарина и удмурта, получавшего по счастливым обстоятельствам образование. Конфликт в них в столкновении молодого человека, духовно возмужавшего, с окружающим миром, с начальством медресе и семинарии. И «Изгнание Заки шакирда из медресе», и «Дитя больного века» по реализму освещения событий начала XX века являются документом времени. Произведения следует поставить в ряд произведений автобиографического жанра русской и национальной литературы. Они отражают черты талантливой натуры рассказчиков.

Автобиографический жанр продолжал и развивал в их творчестве литературные традиции предшествующих поколений и, самое главное, закладывал основы будущих жанровых и видовых «ответвлений» национальной литературы Татарстана и Удмуртской Республики. Осмысление этими писателями особенностей развития автобиографического жанра в начале XX века актуально для понимания литературного процесса сегодня.

По нашему мнению, из двух типов автобиографий (авантюрного и социально-бытового), выделенных М. М. Бахтиным, жанр автобиографии в татарской и удмуртской литературах в основном соответствует второму типу, ибо здесь нет стремления к семантизации, приближения к возвышенному идеалу. Авторы бытописуют конкретные переживания героя. Читатель видит в нем не самый высокий образец нравственности. Его описание вобрало в себя положительные черты национального героя своего времени.

ЛИТЕРАТУРА

1. Взаимосвязи и взаимодействие литератур мира: Библиогр. указ. (1961–1965). Ч. 1–2. – М., 1968; Библиогр. указ. (1966–1970). Ч. 1–2. – М., 1973; Библиогр. указ. (1981–1985). Ч. 2 / Сост. И. Н. Исаева. – М., 1988. – 194 с.

2. Бахтин М. М. Автор и герой в эстетической деятельности (эстетика словесного творчества). – М.: Искусство, 1986. – 444 с.

3. Ибрагимов Г. Сочинения в восьми томах. I том. Рассказы (1907–1929) – Казань: Татар. кн. изд-во, 1974. – 509 с.

4. Кедра Митрей. Дитя больного века. Отрывки из повести // Избранное / Предисл. А. Ермолаева. – Ижевск: Удмуртия, 1965. – С. 140–200.

5. Опаленный подвиг батыра. Жизнь и творчество Кедра Митрея. Воспоминания, статьи, письма, посвящения и произведения Кедра Митрея / Сост. З. А. Богомолова. – Ижевск: Удмуртия, 2003. – 352 с.

# ӘДӘБИЯТТА Г. ИБРАҺИМОВ ОБРАЗЫ

*Г. Ф. Нигъмәтҗанова (Лаеш районы, Олы Кабан)*

Статья, на примере произведений Г. Мухаммедовой и С. Поварисова раскрывает личность Г. Ибрагимова через воплощение в художественном образе.

Г. Ибраһимов татар әдәбиятын, фәнен үстерерүгә үзеннән зур өлеш керткән, халкыбызның катлаулы тарихында үз эзен калдырган шәхес. Сталин культы чорында фаҗигале язмышка дучар ителгән әдипнең әсәрләре, фәнни хезмәтләре китап киштәләреннән алынып торды.

Язмышның мондый катлаулы борылышын авыр кичерсә дә, лаеклы сабырлык белән күтәрә ул. Килер көннәрдә үзен һәм аның кебекләрне аклаячакларына, хезмәтенең үз халкына кайтарылачагына ышанычын югалтмый. Һәм, чыннан да, Сталин үлеменнән соң, алтмышынчы елларда Г. Ибраһимов исеме дә аклана.

Шуннан башлап аның хезмәтләре, әдәби әсәрләре кабат басыла. Тормышы һәм иҗаты ныклап фәнни тикшеренү объектына әверелә. Әмма фәнни хезмәтләр аерым таләпләргә буйсынганлыктан, документальлеккә дәгъва иткәнлектән алар беркадәр корырак һәм Г. Ибраһимов образын бөтен барлыгы, уй-хыяллары, хис-кичерешләре дәрәҗәсендә ачып бетерә алмыйлар. Ә менә әдәби хыялга, беркадәр уйдырма киңәйтелүләргә дә урын булган әдәби әсәрләрдә Г. Ибраһимов образы гаять киң һәм матур сурәтләүләр аша яктыртыла.

Әдип образын матур әдәбият үрнәгендә гәүдәләндергән әсәрләрдән Г. Мөхәммәдованың (1903–1988) «Яшьлек көннәре», «Ол юл» документаль повесте һәм С. Поварисовның «Пәйгамбәр таңы», «Күкнең җиденче катында», «Оҗмахка бер адым» исемендәге өлешләрдән торган трилогиясен атап китәргә кирәк.

Беренче китапларның авторы Гөлсем Мөхәммәдова – 1923–1933 елларда Г. Ибраһимовның тормыш иптәше, табибә, тәрҗемәче, СССР язучылар союзы әгъзасы. Ул Г. Ибраһимов турында үзе белгәннәргә, туганнарының, якыннарының, хезмәттәшләре һәм укучыларының истәлекләренә, аның турындагы язмаларга таянып яза. Аның «Яшьлек көннәре» повесте – 1975 елда, «Олы юл» әсәре 1994 елда дөнья күрә.

«Яшьлек көннәре» повесте Г. Ибраһимовның балалык һәм яшьлек елларын сурәтләүгә нигезләнгән. Автор Галимҗанның балалык елларын Солтанморат авылының гаҗәеп матур табигате кочагында, тату гаиләдә, дуслары һәм туганнары арасында тасвирлый. Башкалардан артык аерылып тормаган, әмма үтә җитез, һәр нәрсәне анализлап кабул итәргә ярата торган бу бала яшьтәшләре арасында дустанә мөнәсәбәт саклавы, оештыру сәләте белән аерылып тора.

Әсәрдә Галимҗанның укуга, белем алуга бик тырыш булуы, мәдрәсәдәге бәхәсләрдә бик теләп катнашуы, шул ук вакытта китапта язылган, хәлфәләре өйрәткән нәрсәләргә дә тәнкыйть күзлегеннән карый белүе күрсәтелә. Бу сыйфат аңа әтисе Гыйрфан мулладан күчкән булуы аңлашыла.

Галимҗан мәдрәсәдә укыган вакытта кешенең ирекен кыса, хыялларын йөгәнли торган иске һәм акыл белән кабул итү авыр булган тыюларга каршы чыга. Дөрес, повесть совет идеологиясе чорында язылганлыктан, ул анда дингә каршы баш күтәрүче буларак та күзаллана. Чынлыкта исә, ул ислам кануннарына түгел, надан муллаларга каршы чыга. Бу С. Поварисовның үз дөреслеге белән соңрак басылган трилогиясенең беренче китабында – «Пәйгамбәр таңы»нда чагылыш таба.

Повесть Галимҗанның үз эш-гамәлләре өчен үзе җавап бирә ала торган, төпле фикерле егеткә әверелүен күрсәтә. Әсәр ахырында ул:

– Тормышым җиңел булыр, дип уйламыйм. …Берәр студентнымы, учительнеме яллап, көн-төн укырга да «аттестат зрелости» дигән кәгазь алырга кирәк. Аннан соң университетларның да ишеген шакып карамакчымын. Мин үземә шул юлны сайладым, – ди (1, 182).

«Олы юл» әсәре авторның Г. Ибраһимов шәхесен турыдан-туры белгән чорын чагылдыра, шуңа күрә Г. Мөхәммәдова анда күбрәк төгәл фактлар белән эш итә. Биредә Г. Ибраһимовның тормышы, иҗат итү үзенчәлекләре, уй-максатлары, кешеләргә, якыннарына мөнәсәбәте бик нечкә детальләр ярдәмендә төгәл һәм матур ачылган. Бу китапны укыганда шул чор тормышында, шул кешеләр белән бергә яшәгәндәй буласың, алар арасына кереп китәсең.

Повестьта Г. Ибраһимов шул чорның танылган шәхесләре, фикердәшләре һәм көрәштәшләре арасында бирелә. Һәм аның образы шул заманның бик күп каршылыклы мәсьәләләрен хәл итү барышында ачыла. Татар алфавитын хәл иткән съезд вакыйгалары, әдәби мираска кагылышлы каршылыклар, Г. Ибраһимовны кулга алу вакыйгалары әсәрдә бик үтемле, ышандырырлык тәэсирле, тарихи дөреслеккә туры килерлек итеп тасвирланган.

Шулай ук Г. Ибраһимовның улы белән бәйле вакыйгалар, аны югалту фаҗигасе әдипнең нечкә күңелле, хисчән, әмма гаять сабыр һәм олы ихтыяр көченә ия булуын ачып бирәләр.

Повестьның ахыры аның Казанның Пләтән төрмәсендә уздырган соңгы көннәрен күзаллауга корылган. Боларны автор истәлекләргә нигезләнеп яза. Алар аеруча тәэсирле булып чыкканнар һәм язучының көчле шәхес булуын, гел ил язмышы, халык язмышы турын-

да кайгыртып яшәвен, кешеләргә үтә игътибарлы булуын дәлилиләр.

Г. Ибраһимовның тулы тормышын әдәби образ буларак бик тәфсилләп гәүдәләндергән икенче зур әсәр С. Поварисовның «Пәйгамбәр таңы», «Күкнең җиденче катында», «Оҗмахка бер адым» әсәрләреннән торган трилогия. Бу китапларның авторы үзе дә тел галиме, филология фәннәре докторы, профессор, Г. Ибраһимов әсәрләренең тел үзенчәлекләрен өйрәнү өлкәсенә дә зур өлеш керткән шәхес.

Трилогия чагыштырмача соңрак язылганлыктан, тагын да тулырак мәгълүматлылыкка дәгъвә итә.

Әсәрләрдә Г. Ибраһимовның туган беренче минутларыннан алып, соңгы сулышына кадәрге вакыт тасвирлана. Авторның Г. Ибраһимов турындагы тарихи дөреслекне үзенең гаҗәп матур әдәби сурәтләре белән баетып, мавыктыргыч сюжет сызыкларына берләштереп бирүе укучыны тагын да ныграк җәлеп итә.

Һәр ике автор да Г. Ибраһимов образын тирәнтен яктыртуга ирешкәннәр. Аның тормышындагы һәр мизгелен әһәмиятле итеп күрсәтә алганнар.

Әйткәнебезчә, Г. Ибраһимов турында фәнни хезмәтләр аз түгел, әмма аларны укучылар саны бик чикле. Ә менә әдәби әсәр аша аның тормышын халыкка һәм мәктәп укучысына җиткерү күпкә җиңелрәк. Чөнки әдәби әсәрләрне укучылар күбрәк. Алар аша без бөек шәхеснең тулы тормышын, фаҗигасен аңлыйбыз. Аңа тагын да ныграк якынаябыз.

ӘДӘБИЯТ

1. Мөхәммәдова Гөлсем. Яшьлек көннәре / Гөлсем Мөхәммәдова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. – 272 б.

2. Мөхәммәдова Гөлсем. Олы юл / Гөлсем Мөхәммәдова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1994. – 224 б.

3. Поварисов С. Ш. Пәйгамбәр таңы: Роман / Суфиян Поварисов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 285 б.

4. Поварисов С. Ш. Күкнең җиденче катында: Роман / Суфиян Поварисов. – Казан: Матбугат йорты, 1999. – 279 б.

5. Поварисов С. Ш. Оҗмахка бер адым: Романнар / Суфиян Поварисов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. – 464 б.

# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫҢ ШӘХСИ КИТАПХАНӘСЕНДӘ ТӨРЕК КИТАПЛАРЫ

*Э. Р. Нәбиуллина (Казан)*

Статья посвящена исследованию турецких книг в личной библиотеке Г. Ибрагимова. Писатель обращает внимание на турецких писателей, которые первыми среди тюркских литератур переняли опыт Западной Европы.

XIX гасыр урталарыннан, төрки әдәбиятлар арасында беренчеләрдән булып, Көнбатыш Европа тәҗрибәсен төрек әдипләре актив үзләштерә башлый. Жанр, әдәби төр, тема ягыннан яңару кичергән төрек әдәбияты билгеле бер күләмдә Г. Ибраһимовның игътибарын да үзенә җәлеп итми калмый.

1912 елның көзеннән язучы Киевта була. Анда мөселман студентларның яшерен «Якташлык җәмгыяте» эшләрендә катнашканы өчен, 1913 елның 17 апрелендә, бүлмәсенә тентү ясалып, үзе кулга алына. Галимҗан Ибраһимовның шәхси документларын, архивын өйрәнүче галимә Ф. И. Ибраһимова: «Г. Ибраһимовның Киев чоры документлары бик күп һәм төгәл алып барылган» (2, 11), – дип яза.

Киев чоры документлары арасында берсе эчтәлеге белән башкалардан нык аерылып тора. Ул – тентү вакытында Г. Ибраһимовтан алынган шәхси китапханә тасвирламасы. Унтугыз битлек бу тасвирламаны укыганда, 26 яшьлек егетнең кызыксыну даирәсенең киңлегенә хәйран каласың (2, 12). Китапханәдә тел, әдәбият, педагогика, тарих һәм башка фәннәр буенча искиткеч күп материал тупланган. Күпсанлы газета-журналлар, танылган әдипләрнең хезмәтләре арасында зур урынны төрек китаплары да алып тора. Алар – Габделхак Хәмид, Әхмәд Рәсим, Шиһабетдин Сөләйман, Әхмәд Мидхәт, Халид Зыя Ушаклыгөл, Халид Сәлим, Намык Кәмал кебек танылган төрек әдипләренең әсәрләре. Моннан тыш бередә әдәбият белеме һәм тәнкыйть мәсьәләләренә багышланган хезмәтләр дә бар.

Галимҗан Ибраһимовның шәхси китапханәсендәге әлеге китапларны өйрәнү ул кызыксынган даирәләрне, аның иҗатына, карашларына йогынты ясаган язучыгалимнәрне ачыкларга, чагыштырма планда өйрәнү алып барырга ярдәм итә.

Галимҗан Ибраһимов төрек әдәбиятын яхшы белгән әдипләрдән санала. Зур үсеш чорын кичергән әлеге әдәбиятны Г. Ибраһимов төрек телендә күп укыган. 1913 елда Киевтан Фатих Кәримигә язган хатында Г. Ибраһимов танылган төрек язучысы Габделхак Хәмиднең әдәби куәтенә хәйран калуын әйтә: «Ул төрек галәмендә төрек угылы булып туган, менә шул аны Шекспир, Шиллер, Гетелар белән беррәттән алырга тиеш булган урыныннан мәхрүм итә. Мин рус әдәбиятында моңа тиң шәхесне күрмим» (2, 72). Чыннан да, әдипнең шәхси китапханәсенә күз салсак, сан ягыннан Габделхак Хәмиднең әсәрләре күпчелекне тәшкил итә.

Габделхак Хәмид чыгышы белән аристократлар нәселеннән, чит телләр белгән һәм эше белән бәйле озак еллар Европа, Көнчыгыш илләрендә яшәп, төрле халыклар әдәбиятын өйрәнгән. Жанр ягыннан бай драма һәм лирик әсәрләр иҗат иткән язучы төрек әдәбиятында романтизмга нигез салучыларның берсе буларак телгә алына. Г. Хәмиднең төрки әдәбиятлар өчен яңа сүз булып яңгыраган пьесаларын («Тарык, яки Андалусияне яулап алу» (1879), «Һинд кызы» (1875), «Яшерен кыз» (1875), «Эшбер» (1880) һ. б.) Галимҗан Ибраһимовның шәхси китапханәсенең исемлегендә дә очрый.

Француз романтиклары тәэсирендә Г. Хәмид төрек шигырен реформалау юлына баса, традицион шигырь тәртибен бозып, ритм-рифма өлкәсендә яңа эзләнүләр башлый, шул рәвешле шәхси кичерешләрне тасвирлау өчен киңрәк мөмкинлекләр тудырырдай алымнарга мөрәҗәгать итә. Әдипнең шигъри җыентыкларын Г. Ибраһимов та үзендә булдырган («Зират» (1885),

«Үле» (1886) һ. б.). Югары дәрәҗәдә оста башкарылган әлеге шигырьләр үрнәгендә Г. Ибраһимов, үзе шигъри әсәрләр иҗат итмәсә дә, аларны, татар әдипләренә бәя бирүдә кулланган, дигән фикергә килергә мөмкин.

Галимә Р. Ганиева үз хезмәтендә: «Нәмык Кәмал, Әхмәд Рәсим кебек зур мәгърифәтче язучыларның әсәрләре ... Галимҗан Ибраһимовның игътибарын җәлеп итә» (3, 532), – дип яза. Нәмык Кәмалның «Ватан, яки Силистрия» (1872), «Җәләлетдин – Хорезм шаһы» (1885) исемле китапларының нөсхәләре Г. Ибраһимовның шәхси китаплары исемлегендә дә бар. Әлеге әсәрләрдә автор тарихи вакыйгаларны яңартып, үткәннәрне искә төшереп кенә калмый, ә вакыйгаларны чынбарлык белән бәйләп, җәмгыятькә бәя бирә.

Танылган төрек язучысы, төрек әдәбиятында роман жанрына нигез салучыларның берсе булган Халид Зыя Ушаклыгөлнең әсәрләре дә Г. Ибраһимовка чит түгел, әдипнең шигырь һәм прозада язылган «Кечкенә китаплар»ын үзе белән йөртүе моны тагы бер кат ассызыклый.

Галимҗан Ибраһимовны танылган төрек галимнәренең, тәнкыйтьчеләренең әдәбият теориясе буенча хезмәтләре дә кызыксындыра. Әдипнең шәхси китапханәсендә «Әдәбият могҗизалары» (Истанбул, 1329), «Әдәби белешмәләр» (Истанбул, 1330. Төзүчеләре: Күпрүле Задә Мөхәммәд Феванд, Шихәбетдин Сөләйман), «Тарих һәм язучы» (Истанбул, 1239. Төзүче: Әхмәд Рәсим), «Әдәбият» (Истанбул, 1325. Төзүче: Сөләйман Фихми) кебек китаплар була.

Төрек әдәбиятынең татар әдипләре иҗатына тәэсир итүе турында Г. Ибраһимов болай ди: «Без бервакыт госманлы әдәбиятына шәкерт идек. Ул вакыт бездә госманлы тәэсире бар иде» (4, 231). Ф. Кәримигә язган хатында төрекләрдән үрнәк алырга кирәклеге турындагы фикерен белдерә: «Безем әдәбияттан мужик чабатасы күренеп торуын эзләгән тупас натуралистларымыз өчен бөек тәэсир итә белерләр иде. ... шул әдәбиятның безгә тәэсире матлуб» (2, 73).

Булачак әдип үзенең башлангыч чорында ук туган халкының иң күркәм традицияләрен үзләштереп кенә калмый, аны гомумкешелек казанышлары белән бергә куша, баета, шул җирлектә татарның классик сүз остасы, зур тарихи шәхесе булып җитешә (1, 11).

Г. Ибраһимов укыган чорда төрек әдәбиятының төп үзенчәлеге үзгәреш кичергән була, анда җәмгыяви киңлектәге сораулар актуальләштерелә. Язучылар әсәрләрендә феодаль чынбарлыкка каршы көрәш, гасырлар буе оешкан тәртипләрне үсеш-үзгәрешкә чакыру, хатын-кыз хокукларын яклау, әхлак, мәгърифәт, гаилә, көнкүреш кебек мәсьәләләр күтәрелә. Г. Ибраһимов иҗаты да татар халкының сәяси, социаль, көнкүреш тормышының киң бирелүе белән аерылып тора. Ул социаль вакыйгаларны милли яктан ача, үз иҗатында авыл тормышын, милли гореф-гадәтләрне («Табигать балалары». 1914; «Көтүчеләр». 1913), татар мәдрәсәләре тормышын, шәкертләр хәрәкәтен, («Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы». 1907; «Карак мулла». 1911), хатын-кыз проблемасын («Татар хатыныниләр күрми». 1910), яшьләрнең өмет-омтылышларын («Яшь йөрәкләр». 1912, «Яшьләр хәятыннан бер ләүхә». 1909) һ. б. ны тасвирлый. Бу яктан әдипнең башлангыч чор иҗаты XIX гасыр төрек әдәбияты белән аваздаш. Г. Ибраһимовның әдәби-теоретик карашларына, фәнни бәяләмәләренә шулай ук төрек галимнәре хезмәтләренең йогынтысы зур дияргә була. Соңрак исә язучының үз әдәби һәм фәнни мирасы яшь буын татар язучыларына җитди үрнәк булып тора.

ӘДӘБИЯТ


1. Галимҗан Ибраһимов: Мәкаләләр, истәлек-хатирәләр / Төз. Р. Акъегет. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 544 б.

2. Галимҗан Ибраһимов: Хатлар һәм документлар / Төзүче Ф. Ибраһимова. – Казан, 2000. – 464 б.

3. Ганиева Р. Көнчыгыш традицияләрен үстереп / Р. Ганиева // Татар әдәбияты тарихы: 6 томда. –V т. – Б. 523–538.

4. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. V т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – Б. 231.


# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫҢ «КЫЗЫЛ ЧӘЧӘКЛӘР» ҺӘМ МӘХМҮТ ХӘСӘНОВНЫҢ «ЯЗГЫ АҖАГАН» ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ЗАМАН ҺӘМ ГЕРОЙ


***А. А. Хәйруллина (Казан)***



На основе произведений «Кызыл чәчәкләр» («Красные цветы») Галимжана Ибрагимова и «Язгы аҗаган» («Весенняя зарница») Махмута Хасанова рассматривается проблема времени и героя.


Мәгълүм ки, әдәби әсәрләрдә көнкүрешебез, тормышыбыз чынбарлыгы сурәтләнә. Тормыш вакыйгаларының актив кешесе әдәби әсәр героена әйләнә. Автор героен, чынбарлыктагы төп сыйфатларын саклап, үтәгән вазифасын бәяләп, теге яки бу вакыйгадагы ролен күрсәтеп сәнгатьчә чаралар ярдәмендә сурәтли. Язучыларыбыз әсәрләре безгә күп тарихи вакыйгаларны күз алдына китерергә мөмкинлек бирә.

1917 елгы Октябрь революциясе, гражданнар сугышы ил тормышына зур үзгәрешләр кертә. Ач, ялангач халык ирек, җир яулап көрәшкә күтәрелә. Канлы бәрелешләрдә үз-үзен аямыйча батырларча көрәшеп, бик күп милләттәшләребез башларын сала. Әлеге геройлар образы белән соңрак төрле әдәби әсәрләрдә очрашабыз.

Дәһшәтле еллар вакыйгалары Г. Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр» (1922) һәм М. Хәсәновның «Язгы аҗаган» (1967) әсәрләрендә дә чагылыш таба.

Мәгълүм ки, Галимҗан Ибраһимовның совет чорында иҗат ителгән әсәрләрен социалистик реализм кысаларында гына бәяләү үзен акламый. Чынлыкта ул киңрәк идея-эстетик позициядән торып иҗат иткән.

Г. Ибраһимов үзе шул чорда яши, шул вакыйгалар эчендә кайный. «Кызыл чәчәкләр» әсәре: «Без түбәннән, тормышның төбеннән күтәрелдек», – дип башлана (1, 403). Хикәянең беренче җөмләсе үк укучыда кызыксыну уята, фәлсәфи уйлануларга этәрә. Әсәрнең исеменә килгәндә, автор көрәш сафларына баскан ирләрне янып торган кызыл чәчәкләргә тиңли.

Әсәрнең төп геройлары – Зәңгәр чишмә авылының төрле катлавыннан чыккан биш егет. Әлеге биш егет авылның төрле урамнарында, байлыклары төрлечә булган өйләрдә туып үсәләр.

Шаһбаз – ятим малай. Фәкыйрь бабасы Әхми карт кулында, авыр тормышта яшәсә дә, рухы бай булып үсә. Бабасы үлгәч, җиде яшьтән үк бөтенләй ятим кала. Шаһбаз хәйләкәр, җитез, йөгерүдә, суда йөзүдә дә аңа житкән кеше юк, җырчы. Шаһбаз тормыш авырлыкларында чыныгып, үткен, эшчән, батыр ир-егет булып җитешә.

Заһит хәзрәт улы Фазыйл – озын, аксыл йөзле, күгелҗем күзле, акыллы малай. Малайлар арасында килеп чыккан ызгыш-талашны бик тиз җайга салучы, кызык сүз, яңа уен уйлап табучы да ул. Үсә төшкәч, Казанга китә, русча укый, ислам дине нигезләрен үзләштерә.

Малайлар төркемен нәрсә кирәк шуның белән тәэмин итүче Гыйфран бай улы Гали – сары башлы, әйбәт киемле малай. Әтисе аны сату-алу эшенә өйрәтә.

Гыйлаҗи – тырыш, уңган, балта остасы Зариф малае. Кулы оста, эш беләә. Малайларга көймәләр, сыерчык оялары, тубаллар ясап бирә.

Авыл читендә фәкыйрь генә өйдә туып үскән Солтан һәрвакыт игътибар үзәгендә. Үзе шук, эшчән. Ул балык тотуларда, урманга җиләккә йөрүләрдә командир.

Төрле катлау кеше балалары булсалар да, балачак уй-теләкләре, хыяллары аларны берләштерә, авыр вакытларда бер-берсенә терәк булалар.

Илдә көтелмәгән үзгәрешләр башлана. Зәңгәр чишмә егетләре дә төрлесе-төрле юлдан китә. Язмыш сынаулары һәркемнең үз гомер юлын билгели. Бергә уйнап үскән дусларны тормыш сынаулары, әкренләп, бер-берсенә каршы куя.

Ятим Шаһбаз, фәкыйрь Солтан, Гыйлаҗи, бер каршылыксыз, агымга кушылып, көрәш сафларында урын алалар. Шаһбаз яңа тормыш көрәшчесе булып китә, Фирганәдә басмачылар тарафыннан җәзалап үтерелә. Хөкүмәт алып барган сәясәт, әнә шулай, төрки, тугандаш халыкларны талаштыра, бер-берсенә каршы куя.

Гыйлаҗи төрле фронтларда сугыша, әсир төшә, кулын өздереп, туган якларына кайта. Яңа тормыш төзи башлый. Гали отряды байлар җирен тартып алып йөрүче дустын кызганмый. Гыйлаҗи фаҗигале төстә аклар кулыннан һәлак була.

Фазыйл төрек-татар байрагы астында милли азатлык өчен көрәшә, Колчак ягына чыга. Соңыннан, өметен өзеп, милли азатлык хыялы белән пролетариатка килеп кушыла. Язучы тарафыннан герой тормышчан сурәтләнгән, чөнки ул заманда икеләнүчеләр дә аз булмаган.

Гали илдәге үзгәрешләрне кабул итә алмый, үз-үзенә кул сала. Дусты Гыйлаҗиның үлеме аның намусын талап тора. Әсәрдә ул усаллыгы, явызлыгы белән аерылып тора. Аның советка нәфрәте шул чаклы көчле, гомер иткән авылдашларын, җан дусты Гыйлаҗины да аямый (2, 129). Чөнки ул революциягә каршы, шуңа да аның тискәре сыйфатлары калку сурәтләнә. Гали заман идеологиясенә бирелмәгән герой булып кала.

Солтан максатчан тырыш егет булып үсә. Шахталарда йөреп, акча туплап, авылга кайта. Чүплек башыннан өен авыл уртасына күчереп сала. Гайния исемле кызга өйләнә. Шәхси тормышын җайга салгач, Солтан сыйнфый көрәш юлына баса. Ул чын күңелдән якты матур тормыш төзеләчәгенә, халык мул, бәхетле яшәячәгенә ышанып яши. «Мин көрәшне яратам. Көрәшсез үткән көннәрне әрәм санаймын. Каты көрәш дулкыннары арасында минем җаным рәхәтләнә, йөрәгем үзенә көч ала, гайрәт ала», – ди ул (1, 57). Якты хыяллар аны олы көрәшкә, батырлыкларга рухландыра. Тик матур киләчәк бик зур югалтулар, кан коюлар, гомерләр өзелү бәрабәренә яулана.

Кечкенә генә авылда да күрше – күршегә, дус – дуска каршы. Солтан аягын өздереп, госпитальләрдә дәваланып авылына кайта. Бергә уйнап үскән дусты Гали һәм аның иптәшләре аны наган терәп каршы ала. Солтанны авылдашлары гына коткарып кала. Әсәрдән күренгәнчә, Солтан – чор идеологиясен үз иткән герой.

Г. Ибраһимов әсәрендә бер милләт, бер авыл кешеләренең бер-берсен юк итү юлына басулары күрсәтелә. Октябрь революциясе үзара дус, тату яшәгән егетләрне кискен үзгәртә, бер-берсенә каршы куя, язмышларын катлауландырып, төрле фаҗигаләргә китерә.

Илдә барган иҗтимагый-сәяси үзгәрешләр кешеләрнең рухи асылына көчле йогынты ясый, совет идеологиясе өчен көрәш, кешеләрдәге дуслык, туганлык, үз милләтеңә хөрмәт, ихтирам хисләрен үтерә. Г. Ибраһимов үзенең кечкенә генә әсәрендә әлеге проблеманы яхшы яктырткан.

Г. Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр» әсәренең объектив эчтәлеге анда революциянең һәм гражданнар сугышының бер милләт балаларын үзара дошманлаштырып, милләтне эчтән таркатуын күрсәтә. Автор үзенең әсәрендә әлеге проблеманы тирәнрәк яктырткан.

Совет чоры язучысы М. Хәсәнов үзенең «Язгы аҗаган» романында җәмгыятебезнең күләгәдә калган фаҗигале якларын тасвирлый. Революция, ирек өчен кан коеп кайткан батырларны әле алдагы тормышта шактый зур сынаулар көтә. Әсәрдә автор төп геройлары – Гази белән Иргалинең аянычлы, фаҗигале, шул ук вакытта гыйбрәтле тормыш юлын сурәтли.

Гази – авылның беренче большевигы Хаҗиның улы. Әтисе явызларча үтерелгәч, ул үзен әтисе эшен дәвам итәргә тиеш, дип саный. Ул комсомол, колхозлар оештыруда катнаша, кулакларга каршы көрәшә. Гази актив, кыю, ихтыяр көченә ия. Кулаклар фетнәсен фаш иткәндә, үзенең гомерен куркыныч астына куя. Шул чор идеологиясе йогынтысында көчсезлек күрсәтә һәм ялгышлары өчен гомере буе үкенеп яши. Газигә тыныч тормышта ничек кенә авыр булмасын, аңа нинди генә гаепләр такмасыннар – ул үз исеменә тап төшерми. Гаделсез җәмгыять кануннары шул җәмгыять, Ватан өчен гомерен бирергә әзер кешеләрнең язмышын зур сынауларга дучар итә.

Иргали – авылның урта хәлле крестьяны. Беренче Бөтендөнья сугышы фронтларын, гражданнар сугышын үтеп, яраланып авылга кайта. Ил өчен барган көрәштә үзен батыр солдат итеп танытса да, өстән кушканны берсүзсез үтәүче куштаннар, ялагайлар аны гаепсездән «гаепле» ясыйлар. Ул гадел, нык ихтыярлы, хезмәт сөючән, авырлыклар килгәндә дә югалып калмый. Тормыш сынауларын сабыр гына үтеп, үзенең кешелек сыйфатларын саклап калып, Себердә дә зурданзур уңышларга ирешә (3, 123).

Г. Ибраһимов әсәрләрендә геройлар гадел җәмгыять төзеләчәгенә, үзләре яклаган идеяләрнең чын дөреслегенә ышанып көрәшәләр. М. Хәсәнов үзенең геройлары язмышы аша кан коеп көрәшеп төзелгән җәмгыятьнең батыр улларына гаделсезлеген, кайгыхәсрәт китерүен сурәтли.

Г. Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр» әсәре гади, аңлаешлы телдә язылган, сурәтләү чараларына бай. Әсәрнең

сюжеты да катлаулы түгел. Укучыда ул үзе күреп торган вакыйгаларны бәян иткән тәэсир тудыра. Шул чор тарихы битләрен язуда актив катнашкан кеше буларак, язучыга әсәрендә чынбарлыкны дөрес итеп сурәтләү хас. Ә шулай да әсәрнең лирик герое Солтан совет идеологиясе йогынтысына бирелгән кеше. Әлеге герой вакыйгаларны совет идеологиясе яссылыгыннан чыгып бәяли.

М. Хәсәнов күптән булып узган тормышчан вакыйгаларны оста тоемлап, сюжетларны мавыктыргыч төзеп, фаҗигале һәм шатлыклы вакыйгаларны аралаштырып, укучыда зур кызыксыну хисләре уята. Теле матур, җанлы. Автор сәнгатьчә сурәтләү ысулларыннан файдаланган.

Әлеге әсәрләр, бердән, тарихи яктан әһәмиятле булсалар, икенчедән, алар әдәбиятыбызның бай мирасында зур урын алып тора. Укучыларга тарихи үткәнебезне барларга, объектив бәя бирергә мөмкинлек бирә. Нинди генә чорлар кичәргә туры килсә дә, кеше үзенең Ватаны, халкы, туган җире өчен үз-үзен аямаска тиеш, дигән хакыйкатьне җиткерә.

Мәгълүм ки, һәр заманның үз герое, үз проблемалары бар. Һәр герой проблемаларны үзенчә чишә. Аларны хәл итү барышында геройларның уңай, тискәре булуы аларның гамәли эшчәнлеге аша ачыклана. Үз мәнфагатьләренә караганда, халык, милләт мәнфагатьләрен өстен күргән, аны кайгыртып яшәгән, көрәшкән чын геройлар гына халкыбыз хәтерендә урын ала.

ӘДӘБИЯТ

1. Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. II т. / Икенче томны төзүче: А. Ш. Шамов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1956. – 595 б.
2. Заһидуллина Д. Ф. Татар әдәбияты. Теория. Тарих / Д. Ф. Заһидуллина. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2008. – 317 б.
3. Хәсәнов М. Язгы ажаган / М. Хәсәнов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2002. – 590 б.

## ПСИХОЛОГИЗМ В РАССКАЗЕ Г. ИБРАГИМОВА «ПАСТУХИ»

***В. С. Кудрякова (Казань)***

Татарская литература начала XX века занимает особое место в литературном процессе и богата на имена выдающихся личностей. Тем не менее рано еще ставить точку в вопросе изучения творчества того или иного таланта. Только путем осмысления исторической, общественно-политической, культурной ситуации эпохи, в связи с зарождением нового произведения, можно представить картину воплощения мысли творца.

Большинство произведений этого времени направлены на отражение реальных событий и перемен в общественном укладе. Нередко в них встречаются и образы, которые затрагивают в душе читателя самые элементарные нравственные начала. Одним из таких героев можно назвать Вахита из рассказа Г. Ибрагимова «Пастухи».

Как известно, начало 1913 года писатель провел в Киеве. Здесь он поступает вольным слушателем в университет и налаживает связи с организацией мусульманских студентов. Однако руководители и активные члены группы в скором времени были взяты под арест, в их числе оказался и Г. Ибрагимов. Заточение продлилось несколько месяцев. Как отмечает М. Хасанов, события в Киеве оказали непосредственное воздействие на революционное мышление писателя, в связи с чем он начинает более пристально уделять внимание общественным проблемам, обращаясь к образам людей, которые живут на «дне жизни» (5, 6). Примерами таких героев, по мнению литературоведа, являются старик Шахи из рассказа «Старый наемник», старик Аптераш и его сын Вахит из произведения «Пастухи». Безусловно, «дно жизни», перенесенное из действительности в литературное произведение, имеет свое место для анализа. Наряду с этим рассказ «Пастухи» важен и как объект исследования психологизма в творчестве Г. Ибрагимова.

«Психологизм – это освоение и изображение средствами художественной литературы внутреннего мира героя: его мыслей, переживаний, желаний, эмоциональных состояний и т. п., причем изображение, отличающееся подробностью и глубиной» (1, 86). Обратим внимание на то, что все произведение основано на пересказе событий Вахитом, воссоздании процессов его внутреннего состояния. Как оказывается, выбор такой формы не случаен. Именно «повествование от первого лица создает большую иллюзию правдоподобия психологической картины, поскольку о себе человек рассказывает сам. В ряде случаев психологическое повествование от первого лица приобретает характер исповеди, что усиливает впечатление» (1, 87–88). В рассказе «Пастухи» исповедь приобретает особенный оттенок.

Сюжетная композиция произведения представляет собой окунание в мир воспоминаний. Рассказчик с первого предложения дает понять свой прошлый и нынешний общественный статус: он поднялся из низов человеческого жития. Далее Вахит повествует историю своей судьбы с детства и жизнь отца. Тринадцатая глава более конкретизирует, что Вахит уже в зрелом возрасте, у него семья, дети. Однако смерть отца вызвала в душе героя бурю эмоций, которые заставили его взглянуть на прошлое и на мир иными глазами. Вахит ищет ответ, почему так жестока судьба по отношению к его отцу? В некоторой степени кажется, что сын ставит себя на место отца. Вот он, потеряв жену, один растит Вахита, работает на мельнице, затем пастухом. Все это повествование дается глазами мальчика-подростка. Переломным моментом в рассказе становится болезнь отца. Вахит, не желая оставить отца одного в предсмертном состоянии, не выходит пасти стадо, проявляет упрямство характера и прилюдно отказывается от подачек, считая это унижением. За это в селе Вахита называют «гордым бедняком». Отца Вахита в селе уважают, и молодому пастуху обидно слышать слова оскорбления старика Сафыя в свой адрес в присутствии отца. Вахит в слезах покидает село. Дальнейшие события герой описывает завуалированно, ибо это связано с некоторыми «провалами» в его памяти. Тем не менее, всю свою сознательную жизнь Вахит проводит с мыслью о том, что рядом с его стариком отцом добрые люди, которые всегда ему окажут теплый прием и согреют заботой. Факт, что старик Аптераш умер на скотном дво-

ре под лавкой в окружении скота, ломает прежнюю картину мира его сына. Если безысходная судьба старика и сына звучит в устах Вахита как исповедь, читатель с нетерпением начинает ждать покаяния героя перед отцом. Сын ничего не сделал для того, чтобы как-то облегчить участь отца, хотя мы знаем, в своем нынешнем мире он уже поднялся из «низов». Вместо этого Вахит призывает к ответу великих мира сего: Платона, Аристотеля, Канта, Декарта, Рафаэля, Шекспира, Эдисона и других. По его мнению, нет смысла в великих достижениях, поскольку они не способствуют улучшению жизни таких, как его отец. Под сомнение Вахита попадают Моисей, Иисус, Мухаммед, религия, философия, наука – все, чем он восхищался в своей «прекрасной» жизни и перед чем преклонялся. В какой-то степени размышления Вахита логичны, и в них есть своя доля правды. Но в этой ситуации главный герой рассказа не обращается к своей личности. Что мешало ему в своей налаженной жизни найти небольшое место для старика? Таким образом, исповедальный рассказ Вахита превращается в историю самооправдания и переложения ответственности на плечи других. Герой не пришел к состоянию покаяния перед отцом.

Причину отсутствия покаяния в рассказе можно понять, рассмотрев художественные средства освоения внутренней жизни героя. К ним В. Е. Хализев относит «описания его впечатлений от окружающего, и компактные обозначения того, что творится в душе героя, и пространные характеристики его переживаний, и внутренние монологи персонажей, и, наконец, изображение сновидений и галлюцинаций, которые выявляют бессознательное в человеке, его подсознание – то, что прячется в глубинах психики и неведомо ему самому» (4, 112). Обращаясь к рассказу, обратим внимание на то, что Вахит с детства одинок. Потеря матери, тяжелая работа отца, жизнь вдали от села – все это, как отмечает Вахит впоследствии, лишило его детства. В произведении не раз делается акцент на том, что герой не может отличить сон от яви и наоборот. Так сон о том, как Вахит оказался в темном лесу, в глубоком погребе, из которого доносятся стоны старухи, оставляет неизгладимый след в его душе. В один из дней, когда сын-пастух вернулся к больному отцу, стоны отца вновь напомнили Вахиту о страшном сновидении. Таким образом, темный лес, глубокий погреб, стоны и взгляд смерти вписываются в подсознание героя. Хотя старик ни разу не обмолвился о смерти, Вахит после этих видений отмечает, что вновь уже не смог вернуть образ отца в действительность. Здесь возможно сделать вывод о том, что смерть устрашает героя, образ смерти – это и образ отца. То, что Вахит покинул поселок, объясняется просто – это бегство от страха увидеть смерть отца, которою он вписал в своей памяти рядом с образом смерти. Причем за этот поступок он не несет ответственности. Уместно подчеркнуть, что герою рассказа повезло: он встретил Сару, которая преобразила его жизнь. Следует отметить, что именно Сарой воспринимает ее Вахит. Истинное имя спасительницы читателю не раскрыто. Свою спутницу жизни Вахит ассоциирует с симпатичной девочкой Сарой, с которой играл в детстве. Первые впечатления и переживания детства, таким образом, оставили свой след в душе Вахита.

В рассказе «Пастухи» стоит обратить внимание и на отношение главного героя повествования к религии, что также играет немаловажную роль в эмоционально-психическом состоянии Вахита. Как видно из содержания произведения, из лексики употребляемых выражений, отец Вахита мусульманин и придерживается основных устоев своей религии. Его сын тоже воспитан на этих традициях, но бегство из села и общение с Сарой приобщили его к другой религии. Сара знакомит Вахита с Иисусом, рассказывает о том, как он любил и заботился о бедных, униженных. Образ Иисуса побуждает героя на мысль о том, что, безусловно, должны найтись люди, которые помогут и его отцу. Вахит начинает верить в добро по отношению к людям. Эта вера приукрашает его, однако он не способен на мысль о том, что сам в состоянии творить добро. В какой-то степени это говорит об эгоизме Вахита. Однако и этот образ для него лишь утешение, успокоение для души. В конечном счете и Иисус превращается в его глазах в ответственного за столь ничтожную смерть отца. И здесь переживания Сары за психическое состояние Вахита становятся совершенно оправданными.

Рассказ Г. Ибрагимова «Пастухи» можно анализировать с различных точек зрения. Неизменной же останется сила эмоционального воздействия произведения на читателя, воплощенная автором в душевных переживаниях героя повествования. Рассказ писателя не только раскрывает мир нищеты, униженных, но и передает глубокие психологические переживания, что еще раз подчеркивает талант художника слова.

ЛИТЕРАТУРА

1. Есин А. Б. Принципы и приемы анализа литературного произведения: учеб. пособие / А. Б. Есин. – М.: Флинта: Наука, 2005. – 248 с.

2. Заһидуллина Д. Ф. Әдәби әсәргә анализ ясау: Урта гомуми белем бирү мәктәбе укучылары, укытучылар, педагогика колледжлары һәм югары уку йортлары студентлары өчен кулланма / Д. Ф. Заһидуллина, М. И. Ибраһимов, В. Р. Әминева. – Казан: Мәгариф, 2005. – 111 б.

3. Ибраһимов Г. Сайланма әсәрләр. – Казан: ТаРИХ, 2002. – 543 б.

4. Хализев В. Е. Теория литературы: Учебник / В. Е. Хализев. – М.: Высш. шк., 2002. – 437 с.

5. Хәсәнов М. Галимҗан Ибраһимов: Тормышы һәм иҗаты турында очерк. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1967. – 27 б.

# Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ БАЛАЛАР ӘДӘБИЯТЫН ҮСТЕРҮДӘГЕ ӨЛЕШЕ

*Г. Г. Мулласалихова (Саба районы, Шәмәрдән)*

Данная статья рассматривает вклад Г. Ибрагимова в развитие татарской детской литературы.

Әдәбиятыбыз тарихында бай мирас калдырган талантлы балалар язучысы, тәрҗемәче, мөгаллим, дәреслек-хрестоматияләр авторы, тәнкыйтьче, тарихчы Г. Ибраһимовның татар балалар әдәбияты

өлкәсендәге эшчәнлеге дә гаҗәп дәрәҗәдә күпкырлы, әһәмиятле.

Г. Ибраһимов – балалар әдәбиятының гаять дәрәҗәдә ярлы булуын күреп, аңа «хәл дәрәҗәсендә» ярдәм итү, баету, хезмәтләре һәм әдәби әсәрләре аша дөрес юнәлеш бирү омтылышы белән яшәгән шәхес.

Әсәрләрендә ул пейзажга бик еш мөрәҗәгать итә. Эстетик яктан тәрбиягә зур игътибар биреп, табигать матурлыгы аша бала күңеленә үтеп керергә омтыла. Балалар һәм яшүсмерләр өчен «Яз башы», «Көтүчеләр», «Карт ялчы», «Алмачуар» һ. б. әсәрләрен иҗат итә. Г. Ибраһимовның һәр хикәясе татар балалар әдәбияты өчен яңалык була.

Балалар әдәбияты – тәрбия өлкәсендә куәтле чараларның берсе. Әдипнең «Яз башы» хикәясендә табигать хозурына бирелеп, рәхәт чигәргә уйлаган бала образы бирелә. Куркыныч аждаһа, әлбәттә, ул аның хыялында туа, Салихны аңсыз калдыра. Малай савыга, газиз әнкәсенә, көләч табигать кочагына кайта, шулай тормыш җиңә. Әсәрдә халык иҗатының экият тылсымнары сизелә. «Яз башы» хикәясендә Г. Ибраһимов мондый экиятләрнең, тәрбия чарасы буларак, зарарлы булуын, шәхесне куркак итеп үстерүен күрсәтә. Моның өчен ул табигатьнең үзгәрешләргә гаять бай булган хәвефле минутларын ала. Хәвефле минутлар куркыныч экиятләр белән тәрбияләнгән шәкертне хафага сала, һушыннан яздыра. «Хыялдан нинди бәлаләр туа бит», – дип нәтиҗә ясый хикәянең ахырында автор. Хикәя оста пейзажчы каләме белән язылган. Туганнарының истәлекләренә караганда, Ибраһимов монда үзләренең Кондызлы күлен тасвирлаган булса кирәк.

Физик хезмәт тәрбиясен дә читләтеп үтмәгән әдип. «Карт ялчы» хикәясендә төп герой – яшүсмер малай Сәфәр. Көлтә алырга килгән җирендә Шаһибәк картның авыр язмышы белән таныша. 10 яшеннән байга ялланып хезмәт иткән Шаһибәк картлык көнендә бәхетсез. Әсәрдәге төп герой – Сәфәр, Шаһи картны чын күңелдән җәлли, аңа булышырга омтыла. Димәк, ул кешелекле, ярдәмчел, намуслы. Эшләгән кеше үз бәхетен таба дигән принциптан чыгып яшәүче. «Карт ялчы» хикәясендәге үсмер Сәфәр дөньяның ямен, яшәүнең тәмен хезмәттә күрә. «Көн-төн эшлисең, җаның рәхәтләнә, аруның нәрсә икәнен дә белмисең», – дип уйлый малай. Аның иң изге хисләре дә хезмәт кешесенә карата уяна. «Шаһи бабай, син безгә кучәр идең, безнең эткәй – картларга йомшак күңелле кеше», – ди ул карт ялчыны кызганып.

«Алмачуар» – әдипнең иң яратып укыла торган хикәясе. Хикәя психологик тирәнлеге белән яңалык буларак кабул ителә. Автор әсәрдә гореф-гадәтләрне, йолаларны да тасвирлый. Авыл кешесенең, җир кебек үк, яшәү һәм хезмәт символы булган атка сабый бала мәхәббәте аркылы язучы туган җиргә, аның табигатенә һәм кешеләренә, андагы яшәешкә дан җырлый, яшь буынны патриотизм рухында тәрбияләргә омтыла.

Әсәрдә гаделлек темасы да зур урын алып тора. Закирның рухын изгән, бар нәрсәдән күңелен кайтарган нәрсә – гаделсезлек. Әсәрнең төп кыйммәте дә шунда – сабыйның кешеләргә, тормышка булган ышанычы югалмаска тиеш.

«Алмачуар» 1961 елда Г. Кәримова тарафыннан рус теленә дә тәрҗемә ителгән.

«Көтүчеләр» хикәясе белән Г. Ибраһимов татар балалар әдәбиятына яңалык алып килә. Әсәрдә бала һәм сыйнфый каршылык проблемасы калкып чыга. «Көтүчеләр» хикәясенең төп герое Әптерәш карт гомере буе ярлылыкта газап чигә. Бәхетне көтеп-көтеп тә, хайваннар абзарында җан биргән Әптерәшнең фаҗигасе коточкыч.

Хикәядә Әптерәш картның улы Вахит образы да бар. Әсәрне уку барышында Вахитның бик күп тискәре сыйфатлары ачыла. Бердән, ул эш яратмый, икенчедән, сыерларның тиресен чыбыркы белән ярудан тәм таба, өченчедән, кеше кәҗәсенең сөтен савып эчүне дә тиешле, гадәти хәл дип саный. Хайваннарны интектерүе аның бик үк әйбәт малай түгеллеген исбатлый.

Вакыйгалар моның белән генә бетми әле. Әтисе ярдәмгә аеруча мохтаҗ вакытта Вахит аны ташлап китә. Ә бит әтисенең аңардан башка бер якын кешесе дә булмый. Үзе өйләнеп бик әйбәт урнашкач, ул әтисе турында борчылып, башкаларны гаепләп бик күп сөйли, ләкин бер генә мәртәбә дә әтисен кайтып күрми. Табигать күренешләре дә әсәргә оста гына кертеп җибәрелә, фәлсәфәлек тә юк түгел.

Үткен каләм остасы һәм тирән фикерләргә ия булган Галимҗан Ибраһимов карт ялчы Шаһи, Вахит образлары аша милләт язмышы өчен борчылуын, тормышны яхшы якка үзгәртергә теләвен күрсәтә.

Әсәрләрендә «тормыш төбендә» яшәүчеләрнең образларын сурәтләгәндә, тормыштагы чын вакыйгаларга, образларга таянган Г. Ибраһимов татар әдәбияты үсешенә үзенең хикәяләре белән төрлелек керткән әдипләребезнең берсе булып кала.

ӘДӘБИЯТ


1. Балалар әдәбияты. Хрестоматия. – Казан: Мәгариф, 2004.
2. Ибраһимов Г. Әсәрләр: Сигез томда. V т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978; VI т., 1986; VIII т., 1987.
3. Ибраһимов Г. Хикәяләр, повесть, роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007.


# Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ «КЫЗЫЛ ЧӘЧӘКЛӘР» ХИКӘЯСЕНДӘ ПЕЙЗАЖ


***Г. Ф. Сабирҗанова (Буа районы, Аксу)***



В статье рассматривается изображение пейзажа в произведении Г. Ибрагимова «Кызыл чәчәкләр» («Красные цветы»). Автор акцентирует внимание на том, что явления природы и их отражение в произведении позволяют раскрыть душевные переживания человека и события в масштабах страны.


Г. Ибраһимов – татар әдәбиятының төрлелеген, үсеш-үзгәрешен, заман проблемаларын чагылдырган авторларыбызның берсе. Язучы иҗтимагый-сәяси, җитди әхлакый мәсьәләләр, заман үзгәрешләре кебек

мөһим проблемалар күтәрә. Ул әсәрләрендә заман кешеләрен, чорга хас үзенчәлекләрне сурәтли. Язучы иҗатында кешенең эчке дөньясын, ил күләмендә барган вакыйгаларны сурәтләү үзәктә тора. Чорның катлаулылыгы исә тормышның каршылыклы булуы, конфликтлар һ.б. олы, гыйбрәтле язмышлы шәхесләрнең психологиясе аша тасвирлана. Психологик процессның бер үзенчәлеге исә – пейзаж, табигать образларын сурәтләү ярдәмендә яңа сыйфатлар табу (2, 95) ул.

«Һәр язучы иҗатында пейзажның вазифасы, әсәр структурасына ул сала торган мәгънә төрле. Татар әдәбиятында пейзаж сурәтләре үзенчәлекле әдәби-эстетик вазифа башкара: алар кешене сурәтләүдә катнаша, аның холык-фигыле белән янәшә, ниндидер “чиктәш” халәтне ача» (1, 135–136). Әдипләр табигатьне үзләре кабул иткәнчә, үз күңелләре аша уздырып сурәтлиләр, ә геройларын шул табигать тасвирлары эчендә ачалар.

Башлангыч чор иҗатында романтизм концепциясен һәрьяклап чагылдырган «Яз башы», «Диңгездә», «Сөю – сәгадәт» кебек хикәяләрендә табигать белән кеше мөнәсәбәтен чагылдырган Г. Ибраһимов совет дәверендә язган әсәрләрендә дә әлеге мөнәсәбәтләрне читтә калдырмый, аларга мөрәҗәгать итәргә тырыша. Табигать күренешләре аша дөньяга карашын, тормыш фәлсәфәсен чагылдыра. Әсәрдә пейзаж геройларның эчке кичерешләре янәшә яки капма-каршы куеп сурәтләнә. Һәр ике очракта да ул аларның эчке дөньясын тирәнрәк ачарга ярдәм итә. Автор әсәрләрендә табигать тасвирлары баш геройларның язмышына һәм әсәрдә сурәтләнгән вакыйгаларга барып тоташа. Мәкаләдә өйрәнү объекты итеп алынган «Кызыл чәчәкләр» әсәрендә образ-пейзажга мисаллар шактый күп. Повестьнең төп өлеше авыл күренешен тасвирлаудан башлана. Шулай да алар арасында күзгә иң ташланып торганы – Зәңгәр Чишмә образы. Язучы аны табигатьнең гүзәл бер почмагы итеп күрсәтә. Кечкенә күлен дә диңгезгә тиңләгән әдип, бакчада үскән чәчәкләрне, болыннарындагы печәннәрне яратып сурәтли: «...урманнарда меңәр еллык карт наратлар, чыршылар җәенкышын яшәреп, шаулашып утыралар; елгалар, күлләр буеннан сөзәк сырт булып җәелеп киткән киң басулары шундый бәрәкәтлеләр ки, вакытында җылы яңгыр яуса, кояшлы аяз көннәр булса, бу яланнарның мамык кебек йомшак, күзге төн болытлары кебек куе кара туфраклары ярты дөньяны туйдырырлык нигъмәтләр бирәләр» (3, 290). Шул рәвешле, язучы табигатьнең биниһая чиксез рухын, мәңгелеген, бетмәс-төкәнмәс матурлыгын, төсләр, исләр байлыгын укучысына җиткерергә омтыла.

Авылның табигатькә бәйле күренешен тасвирлаганнан соң, автор авыл халкының йорт төзелешләрен тасвирлауга күчә: «Авылның уртасында зур базар кайный: аның ике ягыннан биек матур сарайлар, зур тимер йозак белән бикләнә торган ак таш кибетләр тезелеп китәләр...» (3, 291). Г. Ибраһимов шуннан соң урта хәлле кешеләрнең өйләрен, аннан ярлы тормышлы кешеләрнең каралтыларын сурәтли. Шул рәвешле, әдип геройларның төрле социаль катламнан булуларын күрсәтә. Алга таба үз геройлары белән таныштыра. Аларга бәя бирә: «Мин менә шул чит өйләрнең берсендә тудым. Язмыш дулкыннары белән бер кавышып, бер аерылып яшәгән дүрт иптәшем дә шул авылның төрле урамнарында, байлыгы-төзеклеге төрлечә булган төрле өйләрдә туып-үстеләр. Арабыздан тик Шаһбазның гына кайда туганлыгын белмиләр» (3, 290), – ди ул бу хакта. Авыл кешеләренең тормышын күрсәтү исә социаль каршылыкларның нигезен ачу өчен кирәк. Әсәрдә табигать күренешләре конкрет субъектив кичерешләр белән янәшә куела. Зәңгәр Чишмә авылының матур табигате көрәш алып килгән олы хәсрәтне, кайгыны оныттыру белән бергә, геройларның, авторның күңел дөньясында барган хис-кичерешләр агымын ачуга да ярдәм итә. Биредә шунсын да әйтеп китү зарур, әсәрдә сурәтләнгән табигать күренешләре чынбарлыктагы сыйнфый көрәш мотивлары белән дә үрелеп бара. Повестьнең эпиграфында: «“Кызыл чәчәкләр” хикәясе якты, азат көннәр өчен көрәш юлында һәлак булган иптәшләргә багышлана» (3, 289), дип язылуы да шуңа ишарәли. Әсәрнең сюжеты, геройларның образлары да шул көрәшне күрсәтүгә, яңа тормышны төзү вакыйгаларын ачуга буйсындырыла. Әлеге эпиграфтан ук әдипнең яңа тормыш өчен көрәшүчеләрне кызыл чәчәкләргә тиңләве аңлашыла. Бу уңайдан Г. Ибраһимов әсәрнең тәэсирен көчәйтү максатыннан укучыга кечкенә бер хикәят сөйли.

Әсәр героена бала вакытта авыл аша узып баручы бер мосафир бер уч орлыклар бирә, аларны үстерергә киңәш итә. Шуның нәтиҗәсе буларак авыл кып-кызыл чәчәкләргә күмелә. Р. Харрасова билгеләвенчә, элекке вакытларда яхшылык таратып, һөнәр өйрәтеп, белем өләшеп йөрүче мәгърифәтчеләр булган. Карт әнә шундый бер кеше дип аңлашыла. Язучы бу очракта игелекле эшләрнең, булышлык итсәң, киң таралуын аңлатырга тели. Соңгы вакытта әсәрдәге кызыл чәчәкләрне ямьсезләп аңлатучылар да юк түгел. Анда үч тарату, үтерешләр билгесе күрәләр, ә бит әдип бу чәчәкләргә бары тик яхшы эшләр мәгънәсе генә салган һәм революцияне дә – изге гамәлдән, аның хакындагы фикерне таратучыларны да яхшы кешеләрдән санаган. Кызыл орлыкларны чәчүчеләрне дөньяны шакшыдан, чүптән арындыручылар, кешеләр күңеленә дәва алып килүчеләр, аларга ярдәм кулы сузучылар дип санаган ул (5, 49 ). Кызганыч ки, әдип хыялланган матур киләчәк урынына газаплы, аянычлы яшәеш башлана. Бер авыл, милләт кешеләре кан-дошманга әверелә, корал күтәрә. Үзара тату яшәгән халык арасында упкын барлыкка килә. Милли бердәмлек юкка чыга. Повестьта тасвирланган биш егет язмышы нәкъ менә шуларны раслап тора да инде. Димәк, бу чәчәкләр – символик мәгънәгә ия. Кызыл төс – кан, үлем, «кызыл» инкыйлаб тәртипләрен, билгеләрен белдерә (4, 131). Шулай итеп, кызыл чәчәкләр корбан бирү хакында искәртүче образга әйләнә. Иҗади гомумиләштерү чарасына әверелә. Гүзәллек билгесе булып килгән чәчәкләр бәхетле киләчәккә омтылган кешенең фаҗигасен белдерә. Тарихтагы канлы вакыйгаларның берсен ача. Бу пейзажда шул чорның социаль тәртипләренә читләтелгән протест яңгырый.

Нәтиҗә итеп әйткәндә, табигать образлары ярдәмендә, автор матурлык белән ямьсезлек, яхшылык белән яманлык хакындагы фикерләрен киң җәмәгатьчелек игътибарына җиткерә. Табигать күренеше (геройның табигатькә булган мөнәсәбәте, сыйнфый көрәш) ярдәмендә ул үз героеның яшәешен, күңел дөньясын күрсәтә, ил күләмендә барган канлы вакыйгаларны ачуга ирешә. Табигать күренешләрен символ буларак куллана. Алар ярдәмендә предмет, күренешләргә кешенең күңел дөньясы, хис-кичерешләре, иҗтимагый-сәяси мәсьәләләр белән аналогия үткәрә. Язучының гражданнар сугышыннан хезмәт мәйданына кайтучыларга багышланган

бу әсәре, әдипнең яңа чорның иҗтимагый-сәяси үзенчәлекләре турында җитди уйлануларын чагылдыра.

ӘДӘБИЯТ

1. Әдәбият белеме. Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.
2. Җәләлиева М. Ш. Әдәбиятта тойгы катламнары / М. Ш. Җәләлиева. – Казан: Мәгариф, 2005. –183 б.
3. Ибраһимов Г. Сайланма әсәрләр. – Казан: Хәтер, 2002. – 543 б.
4. Миңнуллина Ф. Х. Г. Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр» әсәрендә герой һәм милли бердәмлек концепциясе // Галимҗан Ибраһимов һәм XXI гасыр: Тууына 120 тулуга багышланган фәнни-гамәли конференция материаллары. – Казан: 2007. – Б. 129–131.
5. Рахман Р. Р. Дәреслектәге биремнәр һәм темалар буенча сочинениеләр. – Казан: Раннур, 2004. – 240 б.

# Г. ИБРАҺИМОВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ӘХЛАКЫЙ КЫЙММӘТЛӘР

*Л. Р. Зарипова (Алексеевский районы, Урта Тигәнәле)*

В статье делается обзор нравственных ценностей, которые нашли отражение в произведениях Г. Ибрагимова.

Г. Ибраһимов иҗаты, тематик яктан киңлеге, күтәрелгән мәсьәләләренең әһәмиятлелеге белән генә түгел, халкыбыз тарихына, аның гореф-гадәтләренә, әхлакый, мәдәни ягына гаять игътибарлы булуы, аларны бик оста куллана белүе белән дә аерылып тора. Аның әсәрләре вакыт, урын, вакыйгалар белән беррәттән, халкыбызның әхлакый кыйммәтләрен рухи яктан да тулысы белән чагылдыралар.

Г. Ибраһимовның башлангыч чор иҗатында ук инде кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр, табигать һәм кеше бердәмлеге, тормыш гаделсезлекләренә каршы чыгу, ирекле шәхес идеясен алга кую беренче планга куела. Әдипнең беренче әсәре – «Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы» хикәясе (1907) үк татар халкы өчен мөһим максатларның берсе булган, иң югары бәяләнә торган гыйлемлелек мәсьәләсен күтәрә. Мәдрәсәдәге шәкертләрнең гайре табигый хәлдә яшәве, аларга тиешле белем бирелмәве, белемнәре җитәрлек булмаган хәлфәләрнең яшь буынның вакытын юкка әрәм итүе әсәрдә куе буяулар белән тасвирлана. Яшь Галимҗан шул вакытта ук белемнең, тәрбиянең кеше тормышындагы әһәмиятен аңлап чыгыш ясый.

1907–1912 елларда язылган «Яз башы», «Диңгездә», «Сөю – сәгадәт», «Уты сүнгән җәһәннәм» кебек романтик рухлы хикәяләрендә дә гаделсезлеккә, кешене изүгә, кыерсытуга корылган җәмгыятькә каршы чыга, аның кара якларына табигый матурлыкны, кеше күңелендәге иң саф хисләрне каршы куя.

«Яз башы» хикәясендә бала күңелендәге саф хисләр, аның туган җире белән тыгыз мөнәсәбәттә булуы һәм ана белән бала арасындагы изге мөнәсәбәтләр, ихлас ярату, әнигә хөрмәт гәүдәләнеш ала. Мәдрәсәдә тугыз ай торып, туган өенә кайткан баланың үз уңышларын әнисе белән уртаклашуын, ананың аның тырышлыгына соклануын, ихлас хуплавын күрәбез.

Язучы үзе тудырган образларда халкыбыга хас сыйфатларны туплап бирергә омтыла. Аларның үзе яшәгән тормыштан канәгатьсезлеге, яңа мохит эзләүләре үк ирекkә, табигый хөрлеккә омтылуларын, көчле ихтыярлы булуларын күрсәтә. Алар үзләренең табигать баласы, бәхетле булырга яратылган камил затлар булуларын расларга алыналар. Бу сыйфатлар татар халкының төп милли характерын да гәүдәләндерәләр.

«Карт ялчы», «Көтүчеләр», «Кызыл чәчәкләр» әсәрләрендә Г. Ибраһимов кешеләр арасындагы социаль тигезсезлекне, үзара мөнәсәбәтләрдә матди байлык нәтиҗәсендә туган каршылыклар, шулардан килеп чыккан фаҗигане тасвирлый. Язучы кешеләрнең матди байлыкка карап бүленешен, кешелек сыйфатларын югалтып явызлануларын, бер-берсен рәнҗетүләрен сурәтли. Шул җирлектә гомер кичерүче аяныч язмышлы, бәхетле булыр өчен яратылып та, түбәнлеккә төшкән кешеләрне күрсәтә. «Татар хатыны ниләр күрми» повестенда һәм «Казакъ кызы» романында, хатын-кызның аянычлы язмышын тасвирлау аша, иске тәртипләргә, хатын-кызның хокуксызлыгына, кимсетелүенә каршы чыга.

«Яшь йөрәкләр» романындагы роматик образлар, бигрәк тә Зыя образы аша халыкка хезмәт итү идеалы яктыртыла. Зыя рухи байлыкны гәүдәләндерүче, яктылыкка, ирекле, матур тормышка әйдәүче зат буларак сурәтләнә. Зыя рухи матурлыкка сәҗдә кыла, аның белән яши, әмма тормыш аны кыса, идеалларын җимерә. Шуның аша автор җәмгыятькә бәя бирә.

Г. Ибраһимов үзенең әсәрләрендә халкыбыз күңелендә тирән урнашкан Коръәннән үк килә торган, ислам фәлсәфәсе белән бәйле рухи-әхлакый кыйммәтләргә дә зур урын бирә. Кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең ихласлыгы, белемгә омтылыш, ата-анага хөрмәт, бала хисләрен тәрбияләүгә игътибар, туганлык, ярдәмчеллек, дуслык, табигатне ярату һәм саклау кебек сыйфатларны олылый. Г. Ибраһимов элек-электән килгән гореф-гадәтләрне аеруча тәфсилләп, яратып тасвирлый.

Шул ук вакытта аның әсәрләрендә заман белән бәйле көрәш идеясе, кеше хокукларын богаулап торган иске карашларга каршы чыгу да гәүдәләнеш ала.

Шул максаттан ул геройларның эчке дөньясын, кичерешләрен тасвирлауга, аларның язмышын хикәяләүгә зур урын бирә. Психологик чигенешләр, геройларның уйларын, тойгыларын ачып салу, аларны төрле хәлләрдә сурәтләү авторга шәхесләрнең рухи якларын ачарга ярдәм итә. Ә аларның рухи дөньсында халкыбызга хас әхлакый сыйфатлар чагылыш таба.

Әсәрләрендә халкыбызның җаны, гомумәхлакый кыйммәтләре, бай тарихы чагылыш тапканга Г. Ибраһимов әсәрләре бүген дә үзенә җәлеп итә һәм тәрбияви әһәмиятләрен югалтмыйлар.

ӘДӘБИЯТ

1. Ибраһимов Галимҗан. Хикәяләр, повесть, роман / Төз. Р. Г. Фәйзуллин / Ибраһимов Г. – Казан: Татар. кит. нәшр, 2007. – 463 б.

# Г. ИБРАҺИМОВ ҺӘМ ТАТАР ТЕЛЕ, МӘГАРИФЕ, ТАРИХЫ

## ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ КАЙБЕР ТАРИХИ, ДИАЛЕКТАЛЬ СҮЗЛӘРНЕҢ ҺӘМ ЭТНОГРАФИЗМНАРНЫҢ КУЛЛАНЫЛЫШЫ

***А. Г. Шайхулов (Уфа)***

В статье рассматриваются некоторые аспекты системной характеристики лексики (исторической, диалектной, а также этнографизмов), встречающейся в произведениях известного татарского писателя Галимджана Ибрагимова. Автор, исходя из разрабатываемого им системного осмысления лексико-семантической структуры, исследуемые единицы анализирует в рамках следующих когнитивных сфер: I. Природа (неживая и живая). II. Человек (как физико-биологическое существо). III. Общество (человек как общественное существо). IV. Познание.

Г. Ибраһимов әсәрләрендә кулланылган тарихи, диалекталь сүзләрне күзәтүгә күчкәнче, гомумән алар турындагы кайбер карашларга тукталып узу урынлы булыр. Билгеле булганча, иске сүзләрнең кайберләре (диалекталь, тарихи сүзләр һәм этнографизмнар) сүзлек составыннан бөтенләйгә төшеп кала: мәсәлән, *шәкел (форма), сәяси (политик)* һ. б. Бу очракта шул үзенчәлекне дә искә алырга кирәктер: тел сүзләрен югалтуга карата бик сак, ә читтән кергән сүзләргә карата исә таләпчәнрәк. Хәзерге татар телендәге иске (архаик) сүзләрне алып карасаң, күбесе борынгы алтай, төрки чорлардан яки гарәп-фарсы, хәтта фин-угыр телләреннән кергән булып чыга. Аларны халык озак сыный. Ошатмаса, аның урынына икенче сүз сайлый. Мәсәлән, гарәп теленнән кергән *сәяси, иҗтимагый* сүзләре бер үк төрле яңгырый кебек. Ләкин *сәяси* сүзе сүзлек составыннан берара төшеп торды. Аны рус теле аша грек теленнән кергән *политика* сүзе алыштырды. Ә *иҗтимагый* үз урынын башка сүзгә бирергә бик ашыкмый. Ул рус теле аша кергән икенче сүз белән парлашып *(иҗтимагый-политик)* йөрде. Иске сүзләр йә пассивлашып, йә активлашып китәргә мөмкин. Шуңа да аларны югалтырга ашыкмаска кирәк.

Г. Ибраһимов әсәрләрендә очраган тарихи, диалекталь сүзләрне, этнографизмнарны кыскача түбәндәге когнитив сфералар төркемнәре эчендә карый алабыз. Тел гыйлеме бу төр классификацияләрне, тел тарафына (бу очракта – лексик берәмлекләргә) системалы карашны методологик нигез итеп ала.

I. **«Табигать» когнитив** сферасына караган тарихи, диалекталь сүзләр эчтәлекләре белән тагын да ваграк төркемнәрне тәшкил итәләр:

1. Җир: *түндәк* (2, 203) – *түмгәк, сүрелү* (2, 150) – *кибү, кору, коргаксу;* 2. Һава, күк: *таң килү белән* (2, 348) – *таң ату белән; дөнья бик караңгы* (2, 130) – *көн; сагыл* (1, 366) – *мираж;* 3. Су. *Су түбәненә... агып барган* (1, 119) – *су агымыннан* һ. б.

II. **«Кеше» когнитив** сферасына караган лексик берәмлекләрне семантик төркемнәргә бүлеп карарга мөмкин: 1. Кешенең акыл ягын характерлаучы диалекталь, тарихи лексик берәмлекләр: *ярты акыл, шаркылдык* (1, 189); *чакча баш нугайлыгы белән...* (2, 333); *бераз тилемсәрәк кебек күренсә дә* (1, 123) һ. б. 2. Мораль-әхлак сыйфатлар: *яманлыкка кул сузучыларга* (1, 130); *Пәкри белән юлыгуда гаепләнгән хатын* (1, 94) һ. б. 3. Кешенең психологик халәте: *арудан калгып утыра иде* (2, 385); *сабырын туплады* (2, 326) һ. б. 4. Тән әгъзалары: *куй күзле* (1, 159) һ. б. 5. Төс-кыяфәт: *күрек бирмәсә дә, акыллы бер иркәк биргән иде* (2, 390); *җитү кара чәчле* (2, 325); *кара туткыллы йөз* (2, 419); 6. Физик халәт: *мәгәр үзе арыган, чарчаган (2, 372); әлҗерәп беткән ... карт* (1, 153); 7. Характеры: а) уңай: *ул гаҗәп тере, уенчак иде* (1, 167); *чыпак телле шаян җегетләр бар* (1, 193); б) тискәре: *каенана бик әремтел нәрсә* (1, 322); *каты бавырлы* (2, 332); *боларда аумакайчылык көчле иде* (2, 456); 8. Чир, чирләү: *авыруын, кылтамак чирен тапканнар* (4, 85); 9. Эндәшү сүзе: *Амансыз, утагасы? – диде* (2, 377); 10. Яшь билгеләү сүзе: *чал* (2, 321); 11. Кешенең үлүе: *аны кабер алган* (1, 165); *үз-үзенә кул салган* (1, 394); *кабер чәчемлеге өчен дип* (1, 156).

III. **«Җәмгыять» когнитив** сферасы, югарыдагы төркемнәрдән аермалы буларак, үз эченә нигездә тормыш-көнкүреш, ягъни этнографизмнарга бәйле лексик берәмлекләрне ала. Алар, үз нәүбәтендә, түбәндәге тематик төркемчәләргә бүленеп карала: 1. Аш-су, өстәл әзерләү кирәк-яраклары: *кызыл киҗеле ашьяулык* (1, 263); *биш көре киҗеле салфетлар* (1, 373). 2 Аяк савыты: *яшел савырлы читекле карт* (4, 24). 3. Бизәнү әйберләре: *иннек сөртү* (1, 267); *кершән ягу* (1, 267). 4. Дини тәгъбирләргә бәйле: *куркулыклар коя* (1, 156); *хәерчелек вә тамгычылыкка алыштырдылар* (1, 417); *– Илаһым, хуҗам... үзең сакла – дип сагына башлыйлар* (1, 145); *бата кыйлу (2, 321);* комалакчы (2, 438); *указы киткән имеш* (1, 102). 5. Игенчелек эше: *иген тару җыелган булгач... туй иттек* (1, 204); *көлтәнең өсте үрә, төбе чери (*1, 147); 6. Ихата, өй кирәк-яраклары: *абзарда, бозаулар арасында* (1, 187); *кирәгә буенда*

(2, 337); *бакчаның текмәләренә сөялгән дә* (1, 299); *күләнкә ясадык* (1, 197); *җылы тотсын өчен, яхшылап эргә саласың* (1, 147) һ. б. 7. Туганлык-кардәшлек, якынлык мөнәсәбәтләренә караган: *араларында тамырлык барын сөйлиләр иде* (2, 327); *өлкән абза* (1, 367). 8. Киез-ката әзерләү: *нәгыз ак җоннар* (2, 351). 9. Кием-салым: *бөркәнчеген ташлап, битен юды* (1, 332); *күлмәк инече* (1, 390); *урамал очы белән күз яшен сөртте (2, 370); ука күкрәкле бишмәтләр* (2, 394); *ак җиңсәләр кигән* (1, 310) *кушьяулык ябынды* (2, 394). 10. Мал-туарга бәйле: *украсына чыдый алмаган кысыр бияләр* (2, 366); *асау айгыр өйрәткәнең бармы* (2, 380); *чыгымчы ат* (1, 378); *кара бия бик йөреmтәл нәрсә* (1, 153); *җәйлигә ... укытырга килә* (1, 125); *туклауда сөт кайната* (1, 169); *атлар өшәнгәннәр ахрысы* (1, 151); *тәҗе* (1, 125); *озын корык* (2, 343); *сакалдырыкны каты тартып бәйләделәр* (2, 379); *муендагы бугалак аның хәлен бетерде* (2, 379); *гомерендә нукта орылмаган, адәм кулы тимәгән, чәйлек бавы чияләнгән; ипләп имтекли башлады көшәнләү.* 11. Ризык төрләре: *кабул итү балдан, ләвәштән, куырдак ясалган иде* (2, 452); *туктының яхшысы асылган, бер табактан тамак җию дип күрәбез, иң симез локмаларны ... йоталар иде, егет тамак эшенә кереште, тыгына-тыгына туендылар*. 12. Савыт-саба: *зур җилпучы белән, сабадагы кымызны, күн турсык, көпе.* 13. Орышка, сугышка бәйле: *бер карачкыл күренде , бер атчабар килде.* 14. Төзелеш корылма: *тегермән бөясе аша.* 15. Туй хәстәрләре: *кызның өшәнчеге*. 16. Уен төрләре: *кич белән чиертке ... илә шөгыльләнә иде* һ. б.

Мисаллардан күренүенчә, бу төр когнитив төркемгә караган этнографизмнарның, нигездә, татар халкының яшәеше белән бәйле булса да, билгеле күләмдәгесе казакъ халкының дала тормышын чагылдыра. Аңлашыла ки, әдип үзе сурәтләгән тормышны барлык нечкәлекләре белән танып белгән очракта гына һәр укучы күңелендә тирән уй-хисләр, фикерләр уята ала. Югарыда карап узган мисаллар да әнә шуның дәлиле.

Г. Ибраһимовның, сүз остасы буларак, әдәби тел белән бик сак эш итүенә белгечләр күптән игътибар иткән инде. Әдип үзе дә бер мәкаләсендә: «телдә халыкның рухы, аның кайгы һәм шатлыгы, фикер вә хисләре тупланган. Ул бөек хәзинә», – дип язган иде. Иҗат практикасында әдип әнә шул бөек хәзинәдән файдаланып кына калмады, әдәби телне үзе дә осталарча эшкәртте һәм баетты, аңа матурлык, үткенлек һәм нәфислек өстәде. Г. Ибраһимов сүзләрнең мәгънә төсмерләрен арттырды, аларның эмоциональ-экспрессив мөмкинлекләрен киңәйтте. Ул татар теленең моңарчы файдаланылмаган резервларын хәрәкәткә китерде, аның сәнгатьчә фикерләү куәтен, кеше кичерешләрен тасвирлау байлыгын арттырды. Әдәби телгә сөйләм теле элементларын кертеп, Г. Ибраһимов аны тагын да баетты, халыкка якынайтты. Аның әсәрләрендә татар теленең барлык җирле сөйләшләре бергә кушылды, гомуми максатта хезмәткә җигелде.

ӘДӘБИЯТ


1. Поварисов С. Ш. Галимджан Ибрагимов и татарский литературный язык. Учебное пособие. – Уфа: Изд-во РИЦ БашГУ, 2009. – 398 с.

2. Поварисов С. Ш. Тел – күңелең көзгесе. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1982.

3. Поварисов С. Ш. Тел диңгезе // Казан утлары. – 1977. – №3.


# ФРАЗЕОЛОГИЯ В РОМАНЕ Г. ИБРАГИМОВА «ТИРӘН ТАМЫРЛАР» И ЕЁ ПЕРЕВОД НА РУССКИЙ ЯЗЫК

***Л. К. Байрамова (Казань)***

В соответствии со своей целевой установкой автор не только отбирает факты, но и даёт им определённое освещение. Так вырисовывается авторская языковая коммуникативная стратегия.

Классификация по семантическим полям использованных автором языковых единиц раскрывает, в каком объёме и с какой семантикой отбираются им эти единицы при развитии определённой темы, идеи, при описании той или иной ситуации, образа.

«Говоря о семантическом поле, мы обычно подразумеваем семантическую общность, т. е. некоторое инвариантное значение конституирующих его языковых единиц» (7, 98). Компоненты семантического поля объединяются семантической общностью и противопоставляются друг другу дифференциальными семантическими признаками. При этом принимаются во внимание следующие признаки, которыми характеризуется семантическое поле: 1) обширность, 2) смысловая аттракция, 3) целостность, 4) упорядоченность, 5) взаимоопределяемость (каждый элемент поля «прилегает» к соседям), 6) полнота, 7) произвольность и размытость границ, 8) непрерывность» (5, 127). Отнесение единицы к тому или иному полю осуществляется с помощью компонентного анализа значения фразеологизма и основывается на:

1) анализе словарных дефиниций единицы, поскольку они «в качестве условий своей истинности имеют ориентированность на тезаурус… и подчиняются в нём семантическим закономерностям» (6, 289–290);

2) анализе контекстного значения фразеологизма;

3) анализе парадигматической оппозиции.

Фразеологический фонд произведений Г. Ибрагимова пока ещё не изучен. В результате анализа фразеологии романа Г. Ибрагимова «Тирән тамырлар» («Глубокие корни») по вышеописанной методике было определено 600 фразеологизмов в 1100 употреблениях и выделено 83 семантических поля. Наиболее объёмными оказались семантические поля со значением эмоционального состояния человека и со значением речевой деятельности. И это не случайно: роман глубоко психологичен. В центре романа – человек с его переживаниями, волнениями в бурное время становления советской власти. Волнение, беспокойство, тревога, страх –

все эти чувства переживает почти каждый персонаж романа.

Так, по отношению к Нагыйме использованы фразеологизмы: *йөрәк яну* (1, 217), *коты очты: «Хатын куркып китте... Ире шуның өчен көнләшүдән яна, күрәсең, дип коты очты»* (1, 211). О волнениях и страхе бабушки Минзифы говорится: «*Карчыкның җаны бугазына килде*» (1, 255). «*Куркуыннан бая мич артына сыенган карчык иманын, догасын да әйтә алмады, револьвер тавышына һушыннан язып, идәнгә егылды»* (1, 255). Кроме того, использованы фразеологизмы: *җаны уч төбенә килде* (1, 262), *йөрәге каушады* (1, 265) и др.

Переживания Зифы-эби описываются и с помощью следующих фразеологизмов: *үлем ярык хәлендә, тик чыкмаган җаны бер иде, йөрәге дөрт-дөрт итә* и др. См.: «*Карчыкның коты очты. Җаны уч төбенә килде. Алтмыш ел буенча һәр сәгать укып килгән иманын онытты*» (1, 262).

Волнения, тревога у Марьям-бикә переданы так: «*Мәрьям-бикә бу хакта һәр көн, һәр кич-көндез, һәр таң-иртә уйлый иде. Бөтен йөрәге шул кайгы уты эчендә яна иде*» (1, 237).

О беспокойстве Ситдика Г. Ибрагимов пишет: «*Алпавыт баш күтәрә бит. Шуны бетерми торып җан да тынмас, дөнья да төзелмәс ахры...*» (1, 251).

При описании чувства страха у Жамали также использован фразеологизм: *«Милиционер киткәч, кәгазьне кат-кат карады. Арт ягын әйләндерде. Күңеленә бераз курку йөгерде*» (1, 294).

Разнообразны фразеологизмы со значением речи, использованные в романе Г. Ибрагимова для обозначения как самого процесса говорения: *телгә килү, телен ачу*, *авыз ачу*: *«Сиражи башын күтәрде. Үз яннарына чакырырга дип авызын ачты»* (1, 291), так и различных его фаз: начало говорения (*сүз кузгалу*), его диалогического продолжения *(сүз кайтару),* конца речевой деятельности *(ачкан авызын кире япты; тел очына килгән сүзләрен кабат йотты, телен тешләде, телен югалтты, авыз ачып сүз әйтмәде, авыз каплау).* Разнообразна и передача образа действия речи: *кырт кисү, сүзне икенчегә бору, сандугач кебек сайрау, түкми-чәчми әйтү, авызына иблис төкергән*: *«...Шәяхмәт дигән малайның, әйтерсең, авызына иблис төкергән инде»* (1, 264).

Особую группу составляют фразеологизмы со значением речевой деятельности – процесса ругани *(эт урынына сүкте; чат ябышты; әйтмәгән сүзен калдырмады);* в эту группу входят и бранные выражения: *эт нәрсә, кадалып кына тешсен, муены астына килсен, нәселе корсын, кәһәр төшкерләре, эт авыз нәрсә, маңка малай* и др. Например: *«Кадалып кына китсен! Муены астына килсен! Алланың каһәре төшсен! Бары да шунардан»* (1, 246).

Своей внешнесюжетной канвой роман Г. Ибрагимова похож на детектив с расследованием убийства и разоблачением лжи, раскрытием истины, изображением борьбы. Не случайны в романе и следующие фразеологизмы: 1) со значением лжи: *тузга язмаган сүз, әбиләр әкияте, яла ягу, яман телләр*, например: *«Гыймади җыен тузга язмаганны сөйләп йөри торган бәндә ул!»* (1, 171); 2) со значением истины *(туп-туры әйтеп салу, дөрескә чыгу): «Туп-туры әйт тә сал: болай эш чикмый диген ...»* (1, 269); 3) со значением борьбы: *«Акташлар, диген, сәвит өчен дә, кызыл Татарстан өчен дә менә шулай кан түккәннәр, диген...»* (1, 173–174).

Распределение фразеологизмов по семантическим полям раскрывает семантико-ситуационный параметр фразеологии романа Г. Ибрагимова. Этот параметр обуславливает и семантико-ситуативный принцип перевода, базирующийся на ситуативной и семантической теориях перевода.

В основе ситуативной теории перевода лежит допущение того, что адекватность перевода оригиналу заключается в тождестве описываемых ими ситуаций. Непосредственная замена фразеологизмов оригинала соответствующими фразеологизмами языка перевода оказывается возможной в результате использования эквивалентов разного типа (4, 161–163).

В русском переводе романа Г. Ибрагимова «Тирән тамырлар» (1987, перевод Г. Фаизовой) использованы фразеологические эквиваленты: абсолютно тождественные эквиваленты *(йөрәк яна – сердце горит),* полные *(теге дөнья – тот свет),* частичные *(ике ут өчендә – между двух огней),* аналоги *(астыртын ут йөртү – держать камень за пазухой),* тем самым раскрывается явление межъязыковой симметрии. Эквивалентная симметрия выражается и при использовании Г. Ибрагимовым фразеологизмов, которые являются кальками или полукальками русских фразеологизмов. Ср.: *мәсьәләне кабыргасы белән кую – ставить вопрос ребром, роль уйнау – играть роль.*

Однако в романе Г. Ибрагимова некоторые фразеологизмы являются лакунарными по отношению к русской фразеологии. Мы определяем лакунарную единицу как такую, которая в другом языке имеет пробел, пропуск, пустоту, т. е. лакуну – нулевой коррелят лакунарной единицы (3, 43). Лакунарные фразеологизмы – это фразеологизмы, для которых в переводимом языке отсутствуют эквивалентные фразеологизмы, т. е. фразеологическая лакунарность имеет место при отсутствии межъязыковых эквивалентов-фразеологизмов. Например, татарский фразеологизм *маңка малай* может быть передан на русский язык лексически *(сопляк),* а не фразеологизмом (в связи с отсутствием в русском языке соответствующего фразеологизма). Выражение *аллаһы әкбәр* и ему подобные мусульманские выражения, встречающиеся в романе Г. Ибрагимова, также не имеют эквивалентов в русском языке и, следовательно, являются лакунарными фразеологизмами.

В романе Г. Ибрагимова 8 фразеологизмов составляют фразеосемантическое поле «судьба»: *тәкъдирдә ни язган булса, шуны күрербез; алла ни язган булса, шуны күрербез*; *кара язмыш; язганын күрермен; алла язса; безнең чәчләребез тәкъдирдә бәйләнгәндер*, тогда как в русском языке им соответствуют необразные устойчивые сочетания: *предназначено судьбой, полагаться на Бога* и т. п. Например, нижеследующий перевод хотя и верный, но поэтически описанные чувства девушки в переводе звучат неадекватно, бедно из-за отсутствия фразеологической метафоры. Ср.:

*«Насыйбым шулдыр, язмышым шулдыр. Безнең чәчләребез тәкъдирдә бәйләнгәндер, – дип, бетмәс-төкәнмәс өметләр, хыяллар эчендә яна иде»* (1, 163).

*«Видно, суженый он мой, судьбой мне предназначенный, – говорила она себе»* (2, 177).

Лакунарными являются фразеологизмы семантического поля «религия»: *аллаһы әкбәр, лаилаһы иллалаһ, аллаһы тәгалә, истихарә кылу* и др. Адекватность в переводе фразеологизмов данного семантического поля

достигается путём ввода в русский текст транскрипционных фразеологических заимствований. Ср.:

*«Менә бервакыт бөтен авылны күтәреп, корбан гаетенә баргандагы кебек тәкбир әйтергә керештеләр:*

*– Аллаһы әкбәр, аллаһы әкбәр ...»* (1, 254).

*«Он вдруг начал во весь голос читать такбир. Ему стали вторить все остальные.*

*– Аллах акбэр, аллах акбэр... – понеслось над деревней, как в праздник Курбан-гаита»* (2, 255).

При этом в сноске даётся русский перевод и пояснение религиозных компонентов лакунарных фразеологизмов: т а к б и р – прославление аллаха; а л л а х а к б э р – слова такбира: «аллах велик»; к у р б а н - г а - и т – религиозный праздник жертвоприношений (2, 255).

Кроме того, следует отметить и контекстные лакунарные фразеологизмы, т. е. фазеологические единицы, которые в языке перевода имеют эквиваленты-фразеологизмы, но не использованы переводчиком и переведены не фразеологизмами, а лексемами или описательно (иногда вообще оставлены без перевода). Например:

«*Туры барып керсәң, ярамый. Хәзер яман телләргә эләгерсең. Берсе-берсе күреп калыр да гайбәт чәйни башлар ... »* (1, 214).

*«Заходить внутрь она не решалась, боялась попасться кому на глаза. Ещё начнутся пересуды… »* (2, 220).

Как видно, фразеологизм *телгә эләгү* неправильно переведён как *попасться на глаза* вместо *попадаться на язык,* а фразеологизм *гайбәт чәйнәү* переведён не фразеологизмом (например, *перемывать косточки*), а лексически – словом *пересуды.*

В заключение отметим, что в результате контекстных лакун в русских переводах романа Г. Ибрагимова «Тирән тамырлар» налицо и стилистическая потеря, и неполное отражение авторской коммуникативной стратегии. Переводы произведений Г. Ибрагимова на русский язык делают его знаменитым и в славянском мире.


ЛИТЕРАТУРА

1. Ибраһимов Г. Тирән тамырлар // Әсәрләр: сигез томда. – 3 т. / Г. Ибраһимов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. – Б. 135–386.

2. Ибрагимов Г. Глубокие корни / Г. Ибрагимов; пер. с тат. Р. Фаизовой. – М.: Советская Россия, 1987. – С. 153–364.

3. Байрамова Л. К. Введение в контрастивную лингвистику / Л. К. Байрамова. – Казань: КГУ, 2004. – 116 с.

4. Байрамова Л. К. О некоторых дискуссионных проблемах фразеологической эквивалентности / Л. К. Байрамова // Сопоставительная филология и полилингвизм: Материалы Международной научной конференции (Казань, 29 сентября – 1 октября 2010). – Казань: ИЯЛИ, 2010. – С. 160–164.

5.Денисов П. Н. Лексика русского языка и принципы её описания / П. Н. Денисов. – М.: Русский язык, 1980. – 253 с.

6. Караулов Ю. Н. Лингвистическое конструирование и тезаурус литературного языка / Ю. Н. Караулов. – М.: Наука, 1981. – 366 с.

7. Яцкина В. И. О некоторых подходах к теории семантического поля / В. И. Яцкина // Функционирование языковых единиц в контексте. – Воронеж, 1978. – С. 97–101.


# Г. ИБРАҺИМОВ ИҖАТЫ: БАШЛАНГЫЧ ЧОРЫ ӘСӘРЛӘРЕНЕҢ ТЕЛЕНӘ КҮЗӘТҮЛӘР


***Д. Б. Рамазанова (Казан)***



В статье рассматривается язык ранних рассказов Г. Ибрагимова, раскрывается целенаправленность и требовательность в выборе языковых средств, подчеркивается роль писателя в процессе создания современного татарского литературного языка.


Г. Ибраһимов әдәбиятка аяк басканда ук үзен киң карашлы, белемле, әзерлекле язучы итеп таныта. М. Хәсәнов «Аның исемен әйтү белән үк күзалдына күпкырлы талант иясенең мәһабәт образы килеп баса» дип яза (1, 7). Г. Ибраһимовның иҗат юлын тагын бер кабат күзаллап чыккач, аның «өйрәнчек хикәяләре»ндә үк инде әлеге «мәһабәт образ»ның чалымнары бик ачык күренүенә инанасың.

XX гасыр башында барган татар әдәби теленең тәгаенләнү процессына яшь язучы җитлеккән фикерле, өлгергән карашлы, теле бай булган автор буларак килеп керә, татар теленең бөтен байлыгын үзенең хикәяләвендә кулланып, укучыны үзенең карашлары, уй-хыяллары эченә алып кереп китә.

Биредә Г. Ибраһимовның башлангыч иҗатында иске татар язма әдәби теленә хас үзенчәлекләрнең чагылышына игътибар ителәчәк. Билгеле булганча, XX гасырның беренче 10–15 елларында иске татар язма әдәби тел нормаларыннан арыну, хәзерге татар язма әдәби телен формалаштыру процессы бара. Бу процесста Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Исхакый, Дәрдемәнд, М. Гафури һәм башка олы әдипләребез актив катнашалар, аңлы, ачык максатлы эшчәнлек алып баралар. Боларның иҗаты теленә гомуми караш ташласак, әлеге эшчәнлек бик үк шома үтми, төрле вариантларны кулланып карап, әкренләп билгеле бер фикергә килү рәвешендә бара.

Шушы аспектта күз салсак, Г. Ибраһимовның башлангыч иҗатында, әйтергә мөмкин, «Өйрәнчек хикәяләре»ндә иске татар язма әдәби теленә хас үзенчәлекләрнең шактый системалы рәвештә актив кулланылуы ачыклана: *вә* – һәм, *кеби* – кебек, *илә* – белән, *каюсы* кайсы, *бәгъзесе* – кайсы, *улдыгыннан* – булганга күрә, *улан* – булган һ. б.

1974 елда чыккан сайланма әсәрләренең I томында фон үзенчәлекләрдән түбәндәгеләр күзәтелә. Борынгы *г* саклану: *агырлык* (1, 403) (Алга таба бу томлыкның битләре генә күрсәтелеп барачак. – *Д. Р.*), *агыр* – авыр, *агыз* – авыз (409, 412, 419, 420, 428, 436 һ. б.), *тугры* – туры, *тугды* – туды (410 б.), *олуг* – олы, *аглыйсым килә* – еласым килә (168 б.), *агырсыну – авырсыну* (443 һ. б.), *саг сәламәт* – сау-сәламәт (401 б.) һ.б.

*Бүген, быел* сүзләрен тарихи чыгышын саклап язу: *бу көн* (52, 124 б.), *бу ел* (148 б.). Шул ук вакытта *бүген, быел* төрдәшләрен язу да күзәтелә.

Г. Ибраһимовның башланыч чор хикәяләрендә *-дык*/*-дек* кушымчалы фигыль актив кулланыла. Ул әдәби телдәге *-у*/*-ү* кушымчалы исем фигыльгә яисә *-ган*/*-гән* кушымчалы сыйфат фигыльгә туры килә. Бу форма, исемләшеп, төрле килешләрдә кулланыла һәм хәзерге әдәби телдәге «фигыль бәйлек яки бәйлек сүз» конструкциясен алыштыра. Мәсәлән: *икесе бер мәдрәсәнең шәкерте булдыгыннан* (булганга күрә), *гәпләре бик килеште* (402 б.). *Һәр шәкерт үзенең хәлфәсеннән генә дәрес уку лазем булдыгыннан* (тиеш булганга күрә) *Зәкинең хәлфәсенең шәкертләре бик күп улдыгыннан* (булганга күрә)*, тиз дәрес алырга чират җитми иде* (406 б.). *Юкарыда сөйләндеге кеби, безем Зәки дә ... инсад вә хәяны ташлады* (418 б.). *Моназарәгә мәхәббәт иттерә торган сүзләрне һәр дәрестә хәлфәсе сөйләп чыгардыгыннан... безем Зәки дә моназарә өчен соң дәрәҗәдә тырышты* (420 б.) һ. б.

Юклыкта: *Безнең Зәки мәхдүм җеназага бармадыгыннан* (бармаганга күрә)*, аның һәммә киемнәрене алдылар* (408 б.).

Төшем килешендә: *һәммәсе җеназа күтәрергә үзенең мөстәхикъ идекене* (хаклы икәнлеген) *исбат итмәктә иде* (407 б.).

Тупланган материаллар *-дык*/*-дек* формасы һәм шулай ук иске татар язма әдәби теленә хас башка күренешләрнең Г. Ибраһимовның башлангыч чор иҗатында билгеле дәрәҗәдә максатчан файдаланылуын күрсәтәләр. Беренчедән, алар автор сөйләшендә күбрәк күзәтеләләр. Икенчедән, аларның чикләнә барганлыгы күренә. Мәсәлән: *-дык*/*-дек* формасы, нигездә, тартым белән һәм чыгыш килешендә килә һәм ул хәзерге әдәби телдәге *-ганга күрә* формасына гына туры килә. Ягъни *-дык*/*-дек* формасы бер формада гына һәм бер мәгънәдә генә кулланыла. Бу исә әлеге форманың функциональ яктан чикләнгәнлеге турында сөйли.

Моңа охшаш күренеш «сорау алмашлыгы *-мак*/*-мәк* кирәк» төзелмәсенең кулланылышында да чагылыш тапкан. Мәсәлән, кайчандыр киң кулланышлы *-мак*/*-мәк* формасы татар теленең периферияда, бу очракта Урал төбәгендә формалашкан сөйләшләрдә генә һәм, нигездә, күрсәтелгән конструкциядә генә сакланып калган. Бу турыда диалектологларның хезмәтләреннән күбрәк мәгълүмат алырга мөмкин. Ә XX гасыр башында *-мак/-мәк* формасының кулланылыш функцияләре һичшиксез киңрәк булган. Моны Г. Тукай, Г. Исхакый һ. б. ларның иҗат әсәрләреннән күргән идек (2; 3; 4). Г. Ибраһимовта да шундый ук хәл. Анда *-мак* формасының мондый функцияләре табыла.

1. Урын-вакыт килешендә (*-макта/-мәктә*) эш яки хәлнең гадәттәгечә дәвам итүен белдерә: (балык) *каптыра торган җиребез күләнгәле һәм салкынча булып аерым бер рәхәтлек бирмәктә иде* (57 б.); *сандугачлар һаман өзлексез сайрамакталар иде* (64 б.) ...*Коръән чыгам», – сүзләре һәммә таләбәдән ишетелмәктә, «Иъзаэ вакугать» сүрәсене тәкрар-тәкрар укымакта иделәр* (410 б.). *Ник килгәненә үкенмәктә иде* (411 б.); *(мәчеттә шәкертләр) туры әүвәлге сафка яшен кеби атылмакталар иде* (411 б.). ...*аптырамакта иделәр... «башка көнне асла (бөтенләй) күренмиләр дә», – дип сукмәктә иделәр* (411 б.) һ. б.

Әлеге форма, *исә* теркәгече белән килгәндә, шарт фигыльгә туры килә: ...*хәтта кайбер вакыт «чукынган имеш» хәбәрләре дә чыкмакта исә дә* (чыкса да)*, ул, вакыйгдә* (чынлыкта)*, чын ихласлы бер мөэмин иде* (93 б.).

2. Юнәлеш килеш формасында килгәндә максатны белдерә: *Бу хәлдән истифадә итмәк булып* (файдаланып калмакчы булып)... (406 б.).

3. Дәвамлы үткән заман мәгънәсен белдерә: *Кечек бер авылдан бу кадәр адәм җыелуы «килми калган һичкем юктыр» фикерен искә төшермәктә иде* (төшерә иде) (95 б); *ташландык өй кеби күренмәктә* (күренә) *иде* (400 б.). Тагын кара: (410, 411, 419 һ. б.).

4. Исем фигыль функциясендә: *берәр стакан салкын чәй эчмәк илә* (эчү белән) *гомер үткәрде* (403 б.).

Шулай итеп, *-мак/-мәк* формасының мәгънә функцияләре әле XX гасыр башы әдәбиятында да шактый киң булганлыгы ачыклана.

Фигыльләрнең һәм модаль сүзләрнең исемләшүе *-лык/-лек* кушымчасы ярдәмендә дә башкарыла, аларның да төшем килеше *-ыны/-ене* кушымчасы белән ясала: *Кытрый хәзрәт үзенең (улын) укырга китергәнлегене* (китергәнен) *белдергәч, мөдәррис бик шатланды* (402 б.); *үзенә бәрабәр һичкем вә һич мәдрәсә юклыгыны (юк икәнен)... аңлатты* (403 б.).

Фигыльләрнең исемләшүе бернинди грамматик күрсәткечсез дә башкарылырга мөмкин: *Зәки тырышып укыса, ун сәнәдә беренче мөдәррис булачагыны да аңлатты* (403 б.). ...*анасының хәзерләгәнене* (хәзерләгәнен) *генә ашап йөргән...* (404 б.).

Исемләшкән һәм тартым кушымчасы алган фигыль формаларын төшем килешендә шушы рәвешне куллану Г. Ибраһимовның башлангыч чор иҗатында, шул чорның башка язучылары белән чагыштырганда, аеруча актив.

I, II зат кушымчалары да әсәрдә иске татар әдәби телендәгечә кулланыла: *тагын күренешермез* (күрешербез), *хуш килдеңез* (килдегез), *рәхим идеңез* (итегез) (402, 403 б.), *чәй эчмәдеңез?* (424 б.).

Исем һәм башка сүз төркемнәрендә дә шулай ук: *икемезгә* (әд. икебезгә) (408 б). *Сезнең һәммәңезне алып киттеләрме?* (413 б.); *атамыз үлсә дә...* (414 б.); *китеңез* (414 б.); *үземезә* (436 б.) һ. б.

Беренче зат күплек сандагы алмашлыкларның юнәлеш килеше кушымчасында *г/г* авазы төшү: *безнең үземезә бик кыенлык була...* (436 б.); *безем һәр сүземезә ышанучылыклары безем өчен файдалы да* (440 б.) һ. б.

Язучы әсәрләренең тел үзенчәлекләрен күзәткәндә, алардагы диалекталь күренешләргә дә игътибар итү әһәмиятле. Алар, берьяктан, язучының туган ягы сөйләшен чагылдырсалар, икенче яктан, язучының билгеле бер максат белән бәйле рәвештә (персонажны сурәтләү; әдәби телгә әлеге сүз яки форманы кертеп җибәрергә омтылу һ. б.) кулланылырга мөмкин. Г. Ибраһимов иҗатының башлангыч чорында алар авторның бала чагын, яшь вакытын («Яз башы», «Табигать балалары»), ул үскән тирәлектәге гореф-гадәтләрне («Татар хатыныниләр күрми») чагылдыруга багышланган әсәрләрдә ешрак күзәтеләләр.

Язучының туган ягы сөйләшеннән кергән диалекталь формалардан түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин:

Грамматика өлкәсендә: *җыярга башлау* – әд. җыя башлау (бу күренеш Урал төбәге татар сөйләшләренә хас).

*Башлау* сүзе белән инфинитивның башка формалары да шундый ук функциядәге конструкция оешырга мөмкин: *Шул зобанилар… дип һәммә халык сүкмәгә башлады* (сүгә башлады) (418 б.). Шулай итеп, *-мага/-мәгә* кушымчалы инфинитивның таралыш ареалы да, семантик функциясе XX гасыр башында киңрәк булган *ничек уздырмак кирәк* (414 б.) (бу конструкция аеруча урта диалект сөйләшләренә хас).

Иске татар язма әдәби телгә хас *-маенча/-мәенчә* формасы да Г. Ибраһимов әсәрләрендә, нигездә, даими характерда: *акшамга бармаенча* (бармыйча) *мәдрәсә капкасы төбендә көтеп тордылар да…* (410 б.)*; белмәенчә* (410 б.); *намазны бетермәенчә кайттыммы икән?* (413 б.).

Тартымлы исемнәрнең төшем килешен *-ыны/-ене* (хәзерге әдәби телдә *-ын/-ен*) кушымчалары белән ясау автор сөйләмендә даими төс ала: *Атасы үзенең шәхси эшләрене* (эшләрен) *вә Зәкинең кирәкләрене* (кирәкләрен) *бетерде дә… авылына китте* (403 б.). *Һаман ачлыктан эчләрене* (эчләрен) *шыкырдатып утырды; башыны* (башын) *киссәләр дә кулыннан һични килми* (405 б.); *ике кулыны җәеп* (406 б.); *вәхшәтләрнең һәммәсене* (һәммәсен) *дә күрде* (406 б.).

Исем сүз төркемнәреннән алмашлыкларның төрдәшлелеге һәм төрләнеше белән бәйле үзенчәлекләрне күрсәтергә кирәк. *Без* алмашлыгының иялек килешендә безем дип әйтелүе, язма әсәрләрдә генә түгел, җирле сөйләшләрдә дә күзәтелә (мәсәлән, Тау ягында, бәрәңге һ. б. сөйләшләрдә): *Безем* (безнең) *шәкертләр дә мәдрәсәгә кайттылар* (412 б.); *безем Зәки* (413 б.), *безем кебиләр аңламаслык идеп сөйләгәннәрме?* (430 б.); *безем сүземезә* (440 б.).

Билгеле булганча, *бу* алмашлыгы хәзерге татар әдәби телендә кыек килешләрдә килгәндә һәм төрле грамматик формалар ясалганда *м* авазына башланып языла. Иске татар язма әдәби телдә исә ул барлык очракларда да *б* авазына башлана. Г. Ибраһимовта да шулай ук. Мәсәлән: *буны* (92, 133, 136, 142 б. һ.б.), *боны* (194 б.), *боның* (190, 120 б.), *буңа* (102 б.), *буңар* (141 б.), *боңар* (118 б.), *бонда* (116 б.), *бунда* (133, 137 б.), *болар* (119 б.), *бунлар* (132, 134 б.), *бонлар* (110, 116, 118 б.), *бонлардан* (438, 439), *бунларның* (136, 142, 143, 145 б.), *бундый* (146 б.), *бондый* (112 б.), *боңарча* (114 б.) һ. б.

*Ул* алмашлыгының күплеге *анлар* (118, 132, 410, 420, 421 б.) рәвешендә кулланыла.

Бәйлекләрнең төрле борынгы төрдәшләре кулланыла: *илә, берлән* (400, 406, 407, 426, 440), *берлән* (400 б.), *илән* (409, 435), *кеби* (108, 114, 118, 136, 137, 400, 404 б.) һ. б.

Г. Ибраһимовта *миселле* чагыштыру бәйлеге күзәтелә. Мәсәлән: *«Угылым, саг бул, укы, тырыш, итагать ит!» – миселле вәгазьләр илә вәгазьләп авылына китте* (403 б.). *«…һәммәсене дә белеп, язып куярга кирәк!» – миселле сүзләр күп шәкертнең агызыннан ишетелмәктә иде* (412 б.). *Ничөн урынсыз золым идәсез? – миселле мөдафәгадә* (каршы) *булсалар да, файдасы булмады* (443 б.).

Бу бәйлекнең *мисале* (әд. мисаллы), төрдәше минзәлә сөйләшенең әгерҗе урынчылыгында теркәлгән һәм ул иске татар язма әдәби тел йогынтысы дип карала. Ягъни бу бәйлек хәзерге көндә җирле сөйләшләрдә генә кулланыла.

Күргәнебезчә, Г. Ибраһимовның башлангыч чор иҗатында иске татар язма әдәби теленә хас үзенчәлекләр шактый күп күзәтелә, алар диалекталь күренешләр белән бергә үрелеп әсәр тукымасын үзенчәлекле итеп оештыралар һәм XX гасыр башы әдәби әсәрләрнең теле нинди катлаулы икәнлеген күрсәтәләр.

Шул ук вакытта иске татар язма әдәби теленә хас үзенчәлекләр Г. Ибраһимов тарафыннан шәкертләр һәм муллалар тормышын чагылдырган әсәрләрендә активрак күзәтелә, дигән фикер туа. Хәтта муллалар сөйләшүен чагылдырган диалогларда да гади сөйләм теле элементлары өстенлек ала. Шулай итеп, әдип борынгы үзенчәлекләрне әсәрнең идея эчтәлегенә ярашлы рәвештә кулланган. Мәсәлән: *«Зәки шәкертнең мәдрәсәдән куылуы»* (1907), «*Йөз ел элек*» (1911 ел), «*Карак мулла*» (1911) һ. б.

Билгеле булганча, XX гасыр башы хәзерге татар әдәби теленең лексик составы формалашу процессында хәлиткеч адымнар ясала. шуларның аеруча әһәмиятле булган икесен күрсәтеп үтәргә кирәк.

1. Гарәп-фарсы чыгышлы сүзләр татар теленең үз сүзләре белән алмаштырыла. Мәсәлән, шундыйлардан *сәнә* – хәзер: *ел, шәһадәтнамә* – таныклык һ. б. Г. Ибраһимовта кулланыла әле.

2. Г. Ибраһимов иҗатында да кайбер рус сүзләре урынына татар теленең үз байлыгы нигезендә сүзләр ясарга омтылу үрнәкләре чагылыш таба: *ясама* – әд. ясалма, ясалган (әйбер) (139 б.), *эсселек үлчәве* (180 б.) – градусник, *кызма белән* (57, 58 б.) – хәзер: кызулык белән һ. б.

Бер төркем лексемалар әдипнең туган сөйләше өчен характерлы сүзләрне тәшкил итә, алар мишәр диалектына хас, чөнки Г. Ибраһимовның әтисе, чыгышы белән урта диалект вәкиле булса да, Солтанморат авылында муллалык итә. Бу авыл исә мишәр диалектына (стәрлетамак сөйләше) карый. Берничә мисал китерик: *карсак* – тәбәнәк, *йорт* – ишегалды, *алын* (193 б.) – ал, кишәрлек һ. б. Кайбер сүзләр көньяк-көнбатыш Башкортстан, Оренбург, Көньяк Урал төбәкләре өчен характерлы: *күтерлек* (62 б.) – сазламык, сазлык, баткаклык, *кибер* (109 б.) – тәкәббер*, җир* (147 б.): *ике җир бодай* – авылларда: электә җир үлчәү берәмлеге, *мәмерҗә* (62 б.) – җир убылып барлыкка килгән конус рәвешле төпсез чокыр һ.б.

Шулай итеп, олы әдибебез Г. Ибраһимовның иҗатында, күп төрле фәлсәфи-мәдәни, эстетик мәсьәләләр күтәрелеп чыгу белән бергә, аның телендә сурәтләү чаралары, образлы тел-стиль үзенчәлекләре, иске татар язма әдәби теле элементлары – барысы бергә катлаулы системаны тәшкил итә һәм бу система үзенең махсус тикшерүчесен көтә.

ӘДӘБИЯТ


1. Ибраһимов Г. Әсәрләр. 8 томда. I т.: Хикәяләр (1907–1929). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974.

2. Рамазанова Д. Б. Дәрдемәнд шигырьләре теленә бер караш // Дәрдемәнд мирасы һәм хәзерге заман. – Казан, 2009. – Б. 105–112.

3. Рамазанова Д. Б. Г.Исхакый әсәрләре лексикасының кайбер үзенчәлекләре // Гаяз Исхакый иҗаты: хәзерге караш. – Казан, 2008. – Б. 277–281.

4. Рамазанова Д. Б. Г. Тукай һәм XX гасыр башы мәдәни багланышлар // Г. Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар. – Казан, 2011. – Б. 104–107.

# ГАЛИМНЕҢ ТАТАР ТЕЛЕ ЛЕКСИКОЛОГИЯСЕ ӨЛКӘСЕНДӘГЕ ЭШЧӘНЛЕГЕНӘ БЕР КАРАШ

*Г. Р. Галиуллина (Казан)*

Статья посвящена рассмотрению деятельности Г. Ибрагимова в области татарской лексикологии, в частности татарской терминологии, и функционирования заимствованной лексики. Вся научная и литературно-творческая деятельность ученого, писателя и общественного деятеля направлена на пропаганду татарского национального языка. Основные принципы, разрабатываемые ученым в указанных областях, не теряют своей актуальности, значимости и в современной лингвистике.

Г. Ибраһимов татар милләтенең рухи тормышын, милли мәдәниятен, гуманитар фәнен баетуга алыштыргысыз өлеш керткән әдипләрнең беренче рәтендә йөри. Аның күпкырлы эшчәнлеге татар телен фәнни югарылыкка күтәрү, татар тел белеменең методологик нигезен эшләүгә юнәлгән. Татар тел белемендә кабатланмас эз калдырган әдипнең эшчәнлеге үз эченә татар грамматикасының теоретик һәм гамәли якларын, фонетика һәм орфография, тел тарихы, татар телен укыту методикасы, башка төрки телләрнең үсешенә бәйле мәсьәләләрне ала. Галимнең саналып киткән өлкәләрдәге эшчәнлеге бүген дә әһәмиятен югалтмаган, киресенчә, аларның күбесе хәзерге татар тел белеме фәне өлкәсендәге бәхәсле мәсьәләләрне хәл иткәндә кыйммәтле чыганак булып торырлык.

Бу хезмәтемдә Г. Ибраһимовның татар лексикологиясе өлкәсендәге эшчәнлегенә бәйле кайбер мәсьәләләргә аерым тукталырга булдым. Күренекле әдип үзенең һәм гыйльми, һәм публицистик, һәм әдәби-тәнкыйди мирасы аша татар теле лексикологиясен фәнни дәрәҗәгә күтәрү, татар теленең лексик байлыгын пропагандалау өлкәсендә өзлексез эшли. Әдәби әсәрләрендә ул татар теленең төрле лексик катламнарына караган сүзләрне, кабатланмас сурәтләү чараларын, халык авыз иҗаты ядкарьләрен уңышлы куллану белән татар халкының милли сыйфатларын, психологиясен, дөньяны күзаллау үзенчәлекләрен гаять дәрәҗәдә төгәл һәм тулы рәвештә ачып сала алган. Халыкның җанлы сөйләм телендә иҗат ителгән әдәби мирасы татар теле лексикасының чиксез байлыгын, мәгънә тирәнлеген чагылдыра.

Г. Ибраһимов үзенең төп кыйбласы итеп саф татар телен алга сөрүне сайлый. Әдәби мирасында бу образ, сурәт тудыру үзенчәлекләрендә чагылса, фәнни эшчәнлегендә исә XX гасыр башы татар тел белеменең көнүзәк мәсьәләләренә багышланган хезмәтләрендә ачык күренә. Татар милләтенең рухи, икътисади, иҗтимагый-сәяси тормышында кискен борылышлар чоры саналган XX гасырның беренче унъеллыгы татар гуманитар, шул исәптән тел белеме фәннәренең үсешендә билгеле чор санала. Татар әдәби теле үсеш юнәлешләренә бәйле фикерләр арасында Г. Ибраһимовның милли тел нигезендә халыкның җанлы сөйләм теле ятарга тиешлеген ассызыклавы аерылып тора. Ул галимнең татар теле лексикологиясенең бер тармагы саналган терминология өлкәсенә бәйле эшчәнлегендә ачык күренә. Мисал өчен, үзенең «Татар сарыфы» китабына язылган кереш сүздә ул болай дип язды: «...Минем бөтен мәнбәгым – саф татар теле булды. Кулымнан килгән чаклы, телемезнең эченә, төбе вә рухына керергә, андагы хасият вә мөнәсәбәтләрне табарга вә шундан алга алган нәтиҗәне мәйданга куярга тырыштым» (2,12). Г. Ибраһимовның бу өлкәгә караган төп принциплары хәзерге татар терминологиясен эшләүдә дә нигез булып торырлык. Аерым алганда, галим татар тел белеме терминологиясен эшләү барышында түбәндәгеләргә нигезләнә: 1) тел белеменең терминологик аппараты җиңел аңлашыла торган татар сүзләреннән торырга тиеш. Шул ук вакытта әдип телнең үз байлыгында теге яки бу терминны бирерлек сүз булмаганда, зарур урыннарда башка телләрдән термин алу мөмкинлеген кире какмый; 2) сүзнең лексик мәгънәсе белән терминологик мәгънәсе арасында бераз аерма булырга тиеш, ягъни термин ясаганда гомумкулланылыш сүзенең тышкы формасына үзгәреш кертү һәм лексик мәгънәнең бер семасын гына алга сөрү мөмкинлеге ассызыклана. «Фәнни терминологиянең милли тел кысаларында үсеше халыкның үз телен асыл итеп алып, мәҗбүрият булмаган урында чит сүзне кертмәүдән гыйбарәттер» (1, 88). Хәзерге татар телендәге терминнар системасына күз салсак, төгәл фәннәр өлкәсендә генә түгел, гуманитар фәннәр терминологиясе дә үзенең чуарлыгы, татар теленең табигый үсешенә зыянлы булуы белән аерылып тора. XX гасыр ахыры – XXI гасыр башында татар теленең лексик системасында барган кискен үзгәрешләр, телнең сүзлек составына уңай йогынты ясау белән бергә, телебезнең табигый агышына да шактый зыян китерде. Бернинди киртәләргә юлыкмыйча, телебезнең лексик составына килеп кереп, бик тиз арада актив кулланыла башлаган алынма сүзләрнең киң таралышы, иң башлап, телебезнең терминнар системасында күзәтелә. Кайбер галимнәрнең, әдипләрнең, татар теленең лексик байлыгына нигезләнеп, терминнар ясарга омтылышы да әлегәчә уңай нәтиҗәләргә китермәде. Моның төп сәбәбе – телебезнең үсеш закончалыкларын тиешенчә исәпкә алмау, термин буларак татар халкы арасында киң таралган, мәгънәсендә экспрессия көчле булган гомумкулланылыш яисә гади сөйләм сүзен тәкъдим итү. Терминология өлкәсендә булган төп проблемалар бары тик фәнни якын килеп, танылган әдипләребез, галимнәребез калдырган мирасны җентекле өйрәнелеп кенә хәл ителә ала.

Бу җәһәттән Г. Ибраһимовның тел сафлыгына карашы үзенчәлекле. 1910 елда «Йолдыз»да чыккан «Татар теле һәм татарча язу хакында бер-ике сүз» мәкаләсендә телебезгә үтеп кергән алынма сүзләргә карата фикерләре хәзерге татар теле лексикасы өчен дә бик актуаль. Аерым алганда, пуризм хәрәкәте тарафдарларының татар телендә кулланылып килә торган алынма сүзләрне татарчалаштыру юнәлешендәге эшчәнлеген тәнкыйтьләп, «...садә телдә язуның мәгънәсене һич бер чит лөгать кертмәү дип аңлау билкөлле хата идеке мәгълүм булса кирәк. .<...> Гыйльми вә фәнни нәрсәләр язганда, чит лөгатьсез бер эш тә чыгарып булмый. Бу фәкать бездә генә түгел, һәр милләттә шулайдыр. Бөтен әдәбиятны фәкать үз лөгатендә генә язу

һич бер милләткә мөяссәр дәгелдер. <...> Садә язу дип, бөтенләй татарчалашып беткән чит сүзләрне алыштырырга омтылу урынсыздыр» (1, 79–80).

Г. Ибраһимовның әлеге мәкаләсендә вакытлы матбугатта алынма сүзләрне урынсыз куллануны тәнкыйтьләгән фикерләре хәзерге татар матбугаты өчен дә бик урынлы. Бүгенге матбугат битләрендә күпләп кулланыла торган гарәп-фарсы, европа телләреннән кергән бер төркем алынмаларның киң җәмәгатьчелек өчен авыр яисә бөтенләй аңлаешсыз булуы мәгълүм.

Татар әдәби теленең халыкның җанлы сөйләм теле нигезендә үсәргә тиешлеге Г. Ибраһимовның 1924 елда сөйләгән «Татар телен җиңеләйтү турында тезислар»ында тагын да ачыграк чагыла. Әлеге докладта яңгыраган, татар теленең үз лексик байлыгын куллanышка киңрәк кертергә, татар теленең эчке ресурсларының барлык мөмкинлекләрен файдаланырга, аерым төшенчәләрне атау өчен телебездә сүз булмаган очракта башка төрки телләргә мөрәҗәгать итәргә, мәгънәләре аңлашылмаган алынма (гарәп-фарсы) сүзләрне кулланылышка алмаска, дигән принциплар хәзерге татар телен, аның лексик байлыгын һәм терминологиясен өйрәнү, системалаштыру һәм үсеш юнәлешләрен ачыклау барышында нигез булырлык.

ӘДӘБИЯТ

1. Ибраһимов Г. Г. Милләт. Тел. Әдәбият: Сайланма әсәрләр / Галимҗан Ибраһимов. – Казан: Мәгариф, 2007. – 239 б.

2. Ибраһимов Г. Татар сарыфы / Төз. Ф. С. Сафиуллина, Б. Э. Хәкимов. – Казан: Казан дәүләт университеты, 2009. – 118 б.

## ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ИҖАТЫНДА ТЕЛ-СУРӘТЛӘҮ ЧАРАЛАРЫ ҺӘМ ГЕОГРАФИК АТАМАЛАР КУЛЛАНЫЛЫШЫ

***Ф. Г. Гарипова (Казан)***

В статье речь ведется о том, как классик татарской литературы Г. Ибрагимов, используя географические названия, трогательно описывает природу и любовь к матери. При этом он удачно и к месту использует народное творчество: легенды, предания, поговорки и т. д.

Галимҗан Ибраһимов хикәяләре гамьле, мәгънәле һәм тәрбияви максатларны куеп язылганнар. Әдип психологик кичерешләрне гаҗәп дәрәҗәдә зур илтифат белән, нечкә һәм нәфис итеп, күңел кылларын тибрәндерерлек фалда көчле сурәтләп бирә.

«Яз башы» хикәясен укып чыкканнан соң, әниләрдәге балага карата булган мәхәббәтнең никадәр зур, никадәр илаһи икәнен аңлап, күңелләр әллә нишли. Әниләрдәге балага карата булган ярату хисләрен үлчәүләргә салып үлчәп булмаганны, чөнки әле галимнәрнең мондый таразу-үлчәүне уйлап чыгара алмаганнарын аңлыйсың. Ул мәхәббәтнең авырлыгы миллионлаган берәмлекләрне эченә аладыр.

Әдипнең табигатьне, аның матурлыгын тасвирлавы һәр кешене балачак елларына кайтара, тормыш агышы барышында йөрәккә кунган кунык-юшкынны юып юкка чыгара, аның табигать баласы булганлыгын исенә төшерә, ямьле хозурлыкны, матурлыкны күреп сокланырга мәҗбүр итә. Без – кешеләр һәммәбез дә табигать балалары. Г. Ибраһимов исә табигать белән бер булып яши белүе, әйләнә-тирәбезнең чагыштыргысыз ямьлелеген матур, чарланган тел белән күрсәтә алуы аның югары дәрәҗәдәге классик әдип, зыялы зат икәнлеген дәлилли. Табигатьтәге ямь, наз, камиллек берни белән чагыштырыла алмый торган нигъмәт. Аны күрә белү, аңа шатлану, аннан үз күңеленә, эчке дөньяңа, бөтен рухи халәтеңә чисталык, пакьлек җыюны, иманыңны яңарту хозурлыгын аңлау безгә бирелгән зур бүләк. Бу бүләктән дә зур тагын ни бар икән? Әдипнең тезелеп киткән энҗе бөртегедәй юллары сине табигать хәзинәсе эченә алып кереп китә һәм бөтен дөньяңны онытып шул юллар буенча барасың да барасың. Моның шулай икәне түбәндәге тасвирлаудан күренә:

«Инешнең ике ягына тезелгән таллар, яшел яфракка күмелеп, акрын гына, сак кына тавышлыйлар. Аның бөтен килешенә җәелеп яткан киң яшел тугай китә. Бу киң вә дулкынлы үлән диңгезенең нәкъ уртасыннан назлы кыз йөреше кеби боргаланып-боргаланып аккан елга үзенең көмештәй ялтыраган төсе белән бөтен тирә-якның күркен әллә ничә кат арттырып җибәрә.

Әнә ерак таулар, урманнар, әнә матур гына тулкынланып күренә торган уҗым басуы, әнә безнең юкәдән ясалган тубаллар белән җиләк җыйган уйсулармы, – болар бар да бизәнгән, бар да хәтфәдәй үләннәр белән түшәлеп, сары, кызыл, ал чәчәкләр белән матурланганнар».

Һәркем күңеленә үтә якын булган туган якны, аның табигате матурлыгын, әти-әнисен сагыну, Җирәнкәнең зәңгәр күзләре – чишмәләрнең челтерәп агу тавышлары халәткә кире кайта һәм, үзәкләрне өзеп, күңелләрне әллә нишләтә. Чын әдипләр каләме кешене тәрбияли, кешелек сыйфатларын үстерә, аны югары күтәрә. Бу матурлыкларның көче әти-әни тәрбиясе белән бергә үрелеп, сине зур тормышка әзерли, тормышны яратырга һәм аны мәгънәле итеп яшәргә өйрәтә. Табигать могҗизаларын карап, табигать баласы булып, әти-әни тәрбиясе күреп үсү, берни белән дә чагыштырыла алмый торган, бәһа куелырга мөмкин булмаган кыйммәтләр. Әдип иҗатын еллар үткәч тагын бер кат укып чыксаң, аның никадәр талантлы шәхес икәнлеген аңлыйсың. Аның әдәби сурәтләүләренең осталыгы җаныңны, күңелеңне айкый, тормыш мәгънәсен аңларга ярдәм итә, бөтен эчке дөньяңа бәйрәм ясый, аңлап җиткерелмәгәннәргә төшенергә булыша. Талант зур көчкә ия. Китап уку, андагы тәрбияви күренешләрне аңлау, сизү – аерым укучыга һәм һәркемгә җибәрелгән зур бәхет, халәткә салынган изге тойгыларны җанландырып җибәрә торган бер көч.

Әдип табигатьнең могҗизага тиң күренешләрен, бай әдәби буяуларга, сурәтләү чараларына төреп би-

рү белән бергә, аның биниһая зур көчкә ия булуын йөрәккә тиярлек гыйбарәләр, чарланган телнең энҗе бөртеге кебек ялтырап торган берәмлекләре ярдәмендә тасвирлаулары аша укучы күңеленә җиткерә белә. Бөтен халәтеңне «хәзер ни булыр?» дигән уй биләп ала һәм, фаҗига була күрмәсен, дигән шом сиңа тынгылык бирми. Бу очракта әдип табигатьнең көчен күл һәм күл янындагы камышлар үскән сазлык-күтер, халкыбыз хәтерендә сакланып калган фольклор персонажлары: елан, аждаһа, юха кебек куркыныч образлар, җил-давыл, күк күкрәү, яшен яшьнәү аша күрсәтә. Әдип бу табигать күренешләрен, еланнан, явызлыклары сәбәпле, юхага әйләнүчеләр белән бәйләнешле легенда-риваятьләрне оста куллана һәм теләгән фикеренең укучы күңеленә барып җитүенә ирешә. Әдип булуы ихтимал һәр күренешне оста тасвирлый һәм хикәянең герое кичерешен, психологиясен һәм рухи тәрбиясен тирән итеп ача. Хикәянең бөтен эчтәлеге, геройларының уй-кичерешләре, бер-берсенә мөнәсәбәтләре, хәтта бераз берберсеннән ак көнләшү белән көнләшү (балык тоту күренеше), ана белән баланың үзара бәйләнеш-мөнәсәбәтләре самими төстә, оста каләм белән матур итеп бәян ителә.

Аның «Яз башы» хикәясендә мифологик затларны тасвирлавы һәркемнең хушын алырлык.

«Аждаһа... аждаһа!.. Ух... нинди коточкыч нәрсә! Моның исемен генә ишетү белән, минем куркуым әллә ничә кат артып китә...

Тауларда йөри торган туз башлы еланнар бармы, әнә шулар, йөз яшәсә, аждаһага әйләнәләр, ди. Шуның өчен аны күргән берен үтерә барырга кирәк, ди. Аның өчен бер дә гөнаһ булмый, ди. Әгәр инде аны үтермәсәләр, йөзгә җитә дә, ди, аждаһа була, ди.

Ул камышлы һәм кеше керә алмый торган күтерлекләрдә була, ди. Аны минем бабам күргән: буе унбиш колач, калынлыгы ат чикле, ди. Шундый батыр, ди, сулышы-теше белән зур үгезләрне ерактан суырып аладыр, ди. Ул шул камышта ята бирә, ди. Әгәр дә тирә-якка зыяны булмаса, ята да ята, ди. Зыян итә башласа, маллар, адәмнәр, хайваннар алса, болыт килеп, җил-давыл белән күтәреп китә, ди.

Шуннан алып китә, китә, китә икән дә, ди, җиде диңгезне, җитмеш дәрьяны чыгып, Каф тауларына алып барып, гел еланнар, аждаһалар гына кайнап, ыжгырып ята торган бер төпсу мәмерҗәгә (тау-җир тишеге) ташлыйдыр, ди».

Бу мифик тасвирлау белән язылган өзекне укып чыккач, күңелгә шундый уйлар килә: татар халкының тамырлары борынгы буларак, фольклоры бик бай. Әдипләребез аларның һәр төрен әсәрләрендә еш кулланалар һәм телебезнең, рухи дөньябызның никадәр бай булганлыгын күрсәтәләр. Шушы өзектә генә дә хәзер телебездә һәрдаим яисә бөтенләй кулланылмый торган лексик берәмлекләр бар. Әйтик, *күтерлек* сүзе. Бу лексик берәмлек «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә һәм «Миллият сүзлеге»ндә юк. Ә диалектларда ул «сазлыклы, сулы юеш урын» мәгънәсен аңлата. Бу сүз татар топонимиясендә очрый. Актаныш районында йөргәндә (1979 ел), Сөн суы буенда балык тотып утыручы бабай бу тирәдә *Күтер урыннар, Күтер-сазлыклар* очрый иде, дип сөйләгән иде. *Күтер* лексик компоненты башка телләрдә дә очрый: монгол, бурят, коми, калмык телләрендә – *кужир, кудыр, куду-гур, кудук, куду, гуджир, гудыр* («тозлы саз, тозлы сулы инеш, тозлы туфрак, тозлык» мәгънәсендә).

*Мәмерҗә* – «тау-җир тишеге» мәгънәсендә йөргән сүз. Димәк, бу лексик берәмлек Г. Ибраһимов заманасында кулланылган. Татар диалектларында ул тирән чокыр мәгънәсендә сакланган. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә бу лексик берәмлек бирелмәгән.

«Диңгездә» хикәясендә Г. Ибраһимовның диңгезне, күкне, караңгылык-яктылыкны һ. б. табигать күренешләрен, күк җисемнәрен илаһилык дәрәҗәсенә күтәреп тасвирлавы йөрәкне сулкылдата һәм халәтне, җанны нииндидер таныш булып та бетмәгән гүзәллек тантанасына күмә. Шул кадәр матур әдәби буяулар, алымнар белән сурәтләнгән күренешләрне укыганда күңелдәге гаҗәпләнү галәмәтен сүзләр белән генә аңлатып бетереп булмый.

«Гүя күк белән диңгез беренче сөю – сәгадәтләрен кичерәләр, гүя күк үзенең нурлы күзләре белән диңгезнең йөрәгенә карый да, бусы аңа миллионнардан күп, вак зиннәтле, сөйкемле карап елмая, гүя бер-берен оныталар, тын кичәдә бер-берсенә ташланалар, кушылалар.

Диңгезгә кереп югалу белән, үзеңдә акрын, ләкин тирән бер рәхәтлек сизенә башлыйсың. Тән басыла, рух җиңеләя, күңел киңәя, йөрәкне әрнеткән авыр кайгылар үзеннән-үзе эриләр, таралып, каядыр югалалар».

Бу матур тасвирлаулар Г. Ибраһимов талантының биниһая зур икәнлеген күрсәтәләр.

Г. Ибраһимов иҗатының зур әһәмияткә ия булган үзенчәлекләренең тагын берсе – телебез байлыгын оста куллану. Аның иҗатында ныгып калган аерым сүзләрне хәзерге татар әдәби теленә яңадан кайтару лязем булыр иде. Сүз *күләнкә, күләнкәлек* лексик берәмлеге турында бара. «Без аны (Саткайны) суга якынрак китердек тә, астына яңа гына чапкан печән түшәп, өстенә *күләнкәлек* ясадык» («Табигать балалары»). Бу сүз Г. Ибраһимов иҗатында кулланылган, димәк, ул әдип заманасында әдәби тел берәмлеге булып исәпләнгән. Бу сүз «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә диалекталь сүз буларак теркәлгән һәм аңа түбәндәге аңлатма бирелгән: «Кояштан, кояш нурларыннан нәрсә белән булса да ышыкланган урын, күләгәләнгән пространство». «[Вәли] тазартылган орлыкны, аннан күләнкәдә торган аксыл тимер тракторны күрсәтте» (Г. Ибраһимов). *Байтак себергәч, хәл алыр өчен, ... койма буендагы эскәмиягә барып, күләнкәгә утырды* (Шакир Мөхәммәдев) (6, 295). Мисалдан күренгәнчә, Шакир Мөхәммәдев иҗатында да *күләнкә* сүзе кулланылган. Бу лексик берәмлек хәзерге әдәби телгә кире кайтарылса, сүзнең синонимик рәтләре баер, тулыланыр иде. Һәм әдәби тел дә төшеп калган бер берәмлеген үз эченә яңадан алыр иде.

Әдип иҗатында әһәмияткә ия булган үзенчәлекләрнең берсе – халык авыз иҗатыннан оста файдалану. Хикәяләрендә әдип «Әйткән сүз – аткан ук», «Ир ике сөйләмәс», «Көндәш көне – эт көне», «Алдыннан арты яхшы», «Кара халык – кара сарык» һ. б. шундый гыйбарәләрне байтак куллана.

Г. Ибраһимов иҗатында географик атамаларны да шактый куллана. Урал, Алатау, Караюрга һ. б. атамалар белән ул Үзән елга географик берәмлеген теркәп калдырган. Аның «Татар хатыны ниләр күрми» дигән повестенда Үзән елга болай сыйфатлана. «Үзән елга якты кояш астында көньяктан төньякка таба ялтырап ага-ага да алдына каршы чыккан ташлы тауларга барып бәрелә; бу киң биек ташларны үтеп чыга алмагач, кинәт кояш баешы ягына таба борыла да китә. Агым

буенча сул ягында киң сазлыклар, тугайлар, болыннар, бай печәнлекләр тудыра, алар эчендә таллар үстерә, киң, зур, якты күлләр ясый; уң ягыннан баскычланып-баскычланып тауның биек ак ярлары йөгерәләр-йөгерәләр дә, бу ак ташлар, елганың тирән ятуларыннан берсе турында кинәт тукталып, текә стена белән су өстенә асылалар. Моны үткәч, ташлар бетә, зур тау елгадан эчкә таба, сөзәкләнеп кереп, менә-менә дә куе урманга барып терәлә».

*Үзән* лексик берәмлеге аерым игътибарга лаек. «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә үзән сүзенең ике мәгънәсе бирелгән. 1. Елга яры буендагы уйсу җир. *Кояшның беренче нурлары үрләргә, томанлы үзәннәргә, күлләргә төште* (Г. Әпсәләмов). 2. Су юлы, су аккан эз. *Йомшак йонлы кара постау киеп, ята әле чиксез басулар, Үзәннәрдә әле, шау-гөр килеп, җемелдиләр язгы ташулар* (Ә. Исхак) (6, 726).

В. В. Радлов *өзен* сүзенең казакъ, бараба татарларында, кара-кыргызларда *өзөн, үзен, өсән, өсендүнең* «елга, елгачык, агым, тиз ага торган» төшенчәләрендә йөрүен теркәгән (3, 1293, 1303, 1893). Э. В. Севортян сүзлегендә бу термин: 1) агым; 2) елга юлы; 3) уйсулык, уйсу җир, тар сай чокыр, ялпылык; 4) кечкенә тарлавык; 5) елга уртасындагы коры җир берәмлеге; 6) дала мәгънәләрендә кулланыла (5, 510–511).

Югарыда әйтелгәнчә, *үзән* сүзе элек «елга» мәгънәсендә кулланылган, ә «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә ул «су юлы, су аккан эз» дип бирелә, димәк, бу сүз әле дә «елга»ны аңлата. *Үзән* түбәндәге елга атамалары составында кулланыла: Олы үзән елгасы – Саба районында Мичән елгасы кушылдыгы; Мәмәтәй үзәне – Балтач районында Арбаш елгасы; Билле үзән – Апас районында Чирмешән елгасы; Үзән (елга) – Апас районы Бола елгасы кушылдыклары һ. б. Үзән сүзе Татарстан микротопонимнары арасында да шактый очрый: Үзән тавы, Үзән тугае, Үзән каенлыгы, Үзән урманы һ. б.

Көнбатыш диалектның темников, кузнецк, хвалын сөйләшләрендә дә үзән һәм тарлавыклар «елга» дип йөртеләләр (7, 178).

Г. Ф. Саттаров *өзән – үзән* сүзенең *«җан + җан»* тезмәсеннән торуын күрсәтә. «Елга» төшенчәсе берсендә *өз – үз,* икенчесендә *өн – ән* сүзе белән билгеләнгән ике кардәш кабиләнең бергә кушылуыннан барлыкка килгән контаминацион тополексема, ди. Татар антропонимиясендә очрый торган *Өзәнбай* исеме *Елгабай* дип аңлатыла. Борынгы заманда ул, өзән~үзән (елга) буенда туган ир балага йола белән нисбәтле рәвештә кушылган исем буларак кулланылып, казан татарларында *Өзәнбаев* фамилиясендә сакланган (4, 54–55).

*Үзән* сүзе шагыйрьләр иҗатында да кулланыла. Халык шагыйре Сибгат ага Хәким *үзәнне, кырларны* болай искә ала:

Бу кырлар, бу үзәннәрдә минем
Эзләрем бик иртә салынган.
Кайтам, кайтам туган якларыма,
Талларыма хәтле сагынган.

Төрки халыкларда, мәсәлән, кыргызлардагы *өзөн,* казакъча *өзен,* уйгур телендәге *өзән* – «кушылдык», якутча – *үрех* һәм кумыклардагы *өзен* – «елга», урянхай телендәге *озан* «елга дуены» мәгънәләренә ия.

*Үзән* сүзе кергән географик атамалар Татарстаннан читтәге төбәкләрдә дә шактый күп очрый. *Башкортстанда* яши торган татарлар гидронимиясендә: Белорец, Бөрҗән районнарында Үзән – Агыйделнең сул кушылдыгы; Ерүзән, Салават, Дуван, Караидел районнары җирләреннән агып, Уфа елгасына сул яктан килеп кушыла. Чиләбе өлкәсе җирләреннән Ерүзән елгасы агып уза.

Башкортстанда *үзән* сүзе түбәндәге авыл атамаларында кулланыла: Караидел районында – Юрүзән бистәсе (поселогы), Бүздәк һәм Белорецк районнарында – Үзәнбаш авылы һәм бистәсе, Авыргазы районындагы Үзәнбаш авылының икенче исеме Ибрай авылы һ. б. Пенза өлкәсендә Ерүзән һәм Әләзән авыллары бар. Шунысы игътибарга лаек, элек төрки халыклар Днепр елгасын *Özü, Üzü* дип атаганнар.

Урта Идел буендагы *Олы Үзән* һәм *Кече Үзән* елгалары Саратов һәм Урал өлкәләренең җирләре аша ага. В. Семенов Самара җирләрендә Яңа Үзән өязен һәм шул ук исемдә өяз үзәген билгеләгән, бу өяз җирләренең борынгы татар истәлекләренә бик бай булуы хакында язган. 1627 елда төзелгән «Книга к Большому чертежу» хезмәтендә Идел бассейнында Самара тирәләрендә Үзән, Кече Үзән, Агач Үзән (Узень Деревянная) елгалары теркәлгән (2, 143, 144). Казакъстандагы Мангышлак өлкәсенең *Яңа Үзән* шәһәр хакимиятенә керә торган *Үзән бистәсе* барлыгы мәгълүм.

Госманлы төрекләре дәверендә *Днепр* (ә ул, югарыда күрсәтелгәнчә, төркиләр тарафыннан *Özü (Үзән)* дип аталган) ярында *Озю (Үзән)* кальгасы төзелгән. Ул шул ук исемдәге вилаятьнең башкаласы булып торган. Үзән елгасының *Азуглы (Узуглы)* Үзән дип аталган кушылдыгы да бар. П. Семенов фикеренчә, Днепр елгасындагы Березань утравы атамасы Бүре Үзән ада сүзеннән килеп чыккан. Ука суы бассейнында очрый торган Березань атамасы да шушы нисбәттә карала ала. *Үзән* сүзе Украинадагы елга атамалары составында да очрый. Украина топонимистлары аны төрки *үзән* сүзе белән бәйләп карыйлар. Э. М. Мурзаев мәгълүматларына караганда «үзән» термины кергән атамаларның таралыш даирәсе бик киң.

Шулай итеп, әдипләр кулланган атамаларның ерак тарихлары бар.

Шуны ассызыкларга кирәк, татар халкының зыялы шәхесләре сафында без Галимҗан Ибраһимов исемен дә горур атыйбыз. Ул халкыбызның рухи тормышы локомотивы булган дип әйтсәк тә, һич арттыру булмас. Язучы, тәнкыйтьче, җәмәгать эшлеклесе, әйбәт җитәкче. Яманаты чыккан еллар чолганышына эләкмәсә, татар халкына ул тагын да күп хезмәт иткән булыр иде.

## ӘДӘБИЯТ


1. Ибраһимов Г. Әсәрләр. Сигез томда. I т.: Хикәяләр (1907–1929). – Казан. Татар. кит. нәшр., 1974.

2. Книга к Большому чертежу / Под ред. К. Н. Сербиной. – М.-Л., 1950.

3. Радлов В. В. Опыт словаря тюркских наречий. – СПб., 1893.

4. Саттаров Г. Ф. Татар теле тарихында «җан» төшенчәсен белдерүче сүзләр һәм алар белән мөнәсәбәтле кеше исемнәре // Татар тел белеме мәсьәләләре. – 4 нче кит. – Казан, 1972.

5. Севортян Э. В. Этимологический словарь тюрских языков. – М., 1974.

6. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. Өч томда. II т.: К–С. – Казан: Татар. кит. нәрш., 1979.

7. Татар теленең диалектологик сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәрш., 1969.

# АРХАИЧНАЯ ЛЕКСИКА В РОМАНЕ Г. ИБРАГИМОВА «КАЗАКЪ КЫЗЫ» И ОСОБЕННОСТИ ЯЗЫКА ТАТАРСКОЙ ДИАСПОРЫ КНР

***А. Ш. Юсупова (Казань)***

Творческая деятельность Г. Ибрагимова была многогранной: писатель, публицист, ученый-востоковед, лингвист и литературовед, редактор, педагог, автор и составитель многочисленных учебников для татарских школ, исследователь истории революционного движения и т. д. – порой трудно бывает решить, какой стороне отдать предпочтение, как, впрочем, трудно и определить, в какой области им сделано больше, что из проделанного важнее.

Г. Ибрагимов удачно сочетал в себе черты талантливого художника, большого ученого-теоретика и блестящего организатора-практика. Он обладал характером борца-преобразователя и запомнился своим современникам как подвижник, человек, не боящийся и не избегавший никаких трудностей. При этом не внешние обстоятельства и не какие-либо привходящие причины, а высокое чувство патриотизма, горячая любовь к народу, страстное желание принести ему как можно больше пользы побуждали Ибрагимова браться за самые различные дела, вдохновляли его на самоотверженную деятельность, героизм и самопожертвование в работе.

В молодые годы он учительствовал в казахских аулах. Вероятно, уже тогда возник замысел будущего романа «Казакъ кызы». Позже Г. Ибрагимов преподавал в уфимском медресе «Галия». В этот период там обучались Магжан Жумабаев, Беимбет Майлин и другие казахские шакирды.

«Казакъ кызы» («Дочь степи», 1923) – этапное произведение для татарской литературы 1920-х гг. В нем реалистически достоверно отражена жизнь казахов конца XIX – начала XX века. Особенности художественного мира романа определили его лексический строй. Особые идейно-художественные функции выполняет зафиксированная в романе «Казакъ кызы» лексика, которая считается устаревшей в современном татарском языке, но активно употребляется в речи татарской диаспоры современного Китая.

Устаревшие слова в современном татарском языке используются прежде всего для воссоздания картины прошлых событий и выражения авторской позиции. Один и тот же текст может звучать, восприниматься и трактоваться по-разному в зависимости от той идейно-художественной функции, которую выполняют архаизмы.

Большое место в романе «Казакъ кызы» в составе языковых средств исторической стилизации занимают лексические архаизмы. Некоторые из них свободно проникают в разные речевые контексты, способствуя созданию общего языкового колорита эпохи. Однако следует отметить, что граница между авторской речью и речью персонажей оказывается в ряде случаев стертой. В речи автора встречаются такие лексические архаизмы, как: *ләкап, күҗә, амал, гуй, лазем, аял, әкә, чал* и т. д.

В романе Г. Ибрагимова «Казакъ кызы», наряду с татарскими лексемами, встречаются казахские слова. Разумеется, это явление лишний раз убеждает нас, насколько близок был Г. Ибрагимов к реальной действительности, языку, обычаям и культурным традициям народов, среди которых он жил и работал. Например, ***Чалның*** *тапкырлы кинаясе мәҗлеснең хушына китте. Ил агасы өлкән аксакал Биремҗан* ***әкә*** *моны куәтләп алды. Илнең арасына зур гауга ташлыйм дип торганыңмы бу синең, сәүләм?! – диде. Ул гайбәтче* ***кимперләрдән*** *кайбер нәрсә ишеткән иде. – Сәүләм Рокыя! – диде. –* ***Аяллыгыңа*** *барма, күп гомер эчендә яманын да, яхшысын да күрми амал юк!* ***Кимперләр,*** *өлкән хатыннар килеп аркасыннан сөйделәр («Казакъ кызы»).* Слова *әкә, чал, кимпер, аял* активно употребляются в речи татар, проживающих в Китае.

Фонетические варианты *ака/әкә* «старший брат, брат, старший родственник» активно употребляются в уйгурском, казахском, киргизском, каракалпакском языках. Слово *ака* относится к «лепетным» выражениям, как и почти все названия старших родственников. Г. Рамстедт относил их к общему тюрко-монгольскому фонду (1, 292).

Слово *чал* в значении «старик» является общеупотребительной лексемой, а этимологически оно связано с прилагательным *чал,* которое обозначает «потерявший цвет, белый, серебристый». Также в толковом словаре татарского языка зафиксировано устаревшее значение этой лексемы «старик, взрослый человек» (2, 403).

Слова *аял и кимпер* выступают в качестве синонимов и используются в значении «жена, женщина». Слово *аял* – фонетический вариант арабского заимствования *yajal «женщина»*, который присущ среднеазиатскому ареалу. В каракалпакском, казахском, киргизском, узбекском, уйгурском языках данное слово является активной единицей (1, 297).

В романе «Казакъ кызы» встречаются такие слова, которые вошли в казахский язык из восточных языков. В татарском языке их употребление не наблюдается. Например, *Малларга бу җирнең тозлы* ***икълиме*** *ошамады. Акылы,* ***менәзе*** *белән ил агасы була торган яхшы бер адәм иде. Җылкы кайтуы белән бөтен җәйләүдә уенлы, шау-шулы* ***хәят*** *тагы да көчәя төшә(«Казакъ кызы»).* Слово **икълим** в значении «климат» в татарском языке функционировало до начала XX века. Оно зафиксировано в двуязычных словарях татарского языка XIX века. В речи татар, проживающих в Китае, до сегодняшнего дня это слово является активной лексической единицей.

Слово **менәз** также не употребляется в современном татарском языке, а в речи наших соотечественников оно активно функционирует в значении «характер». Данное слово употребляется в кахзахском, киргизском языках в том же значении.

С современном татарском языке слово **хәят** перешло в ряд устаревшей лексики. Это слово нам знакомо по повести Ф. Амирхана «Хаят» (Х**әят –** имя главной героини), в нарицательном значении используется слово *тормыш.*

Слова **ләкап, күҗә, амал, гуй, лазем** являются активными лексическими единицами как в языке казахов, в основном проживающих на территории современного СУАР Китая, так и в языке татарской диаспоры КНР. Сохранению некоторых из них в активном словоупотреблении способствовал и тот факт, что они имеются в родственном казахском и уйгурском языках.

Слово *ләкап* активно употребляется во многих тюркских языках. В турецком, казахском, уйгурском, в говорах татарского языка оно употребляется в значении «прозвище». В современном татарском языке это слово перешло в разряд устаревших, а в языке активно функционирует сложная лексическая единица *кушамат*.

В двуязычном словаре Л. Будагова (1871) зафиксировано слово *күҗә* в значении «крупа». В современном татарском языке оно считается этнографизмом и употребляется в разных фонетических вариантах. Как отмечает Р. Ахметьянов, параллели этого слова имеются в казахском, уйгурском, тувинском, монгольском языках. В китайском языке слово *ку цзу* – это сорт пшена. Во времена кочевничества *күҗә* была основным продуктом питания после молока и мясо. А в жизни оседлых народов эта каша считается ритуальной и готовится к празднику Науруз (3,126).

Еще одно интересное наблюдение: в татарском языке для утверждения своего мнения, мысли пользуются такими вводными словами, как *чыннан да, дөрестән дә.* В речи татар, проживающих в Китае, очень активно употребляется персидское слово *рас*. Данный корень встречается и в современном татарском языке в таких словах, как *расларга, раслау,* а употребление данного слова как самостоятельной лексической единицы устарело, забылось.

Слово *арзу* в татарском языке встречается очень редко, только в диалектах. Оно вошло в татарский язык из персидского и употреблялось в значении «желание». В уйгурсом, казахском языках оно претерпело фонетическое изменение и функционирует в варианте *арыз*. В такой же форме оно употребляется и в речи татар, проживающих в Китае.

Глагол *чарчарга*/*чәрчергә* в значении «устать, уставать» активен в казахском, уйгурском, киргизском языках. Также татарам, проживающим в Китае, не знаком глагол *арырга*, потому что в их речи данного слова нет, а значение этого действия передается глаголом *чарчарга*.

Аналитические глаголы активно употребляются во всех тюркских языках. Особенностью казахского, уйгурского языков является образование таких глаголов с помощью лексемы *кылырга* во вспомогательной функции. Это явление ярко отражается и в речи татар, проживающих в Китае. Например, *тамак кылу, кунак кылу, илтимаз кылу* и т. д.

Примеры с вышеуказанными словами были зафиксированы и в романе Г. Ибрагимова «Казакъ кызы». Например, *Бу – «җылкычы ата»* ***ләкабе*** *белән йөртелә торган Юныс карт иде. Мәгәр үзе арыган,* ***чарчаган****, күңеле бозылган иде.* ***Туктының*** *симезен чалып, кымызны мул куеп* ***кунак кылдым.*** *Бу сүз* ***рас*** *булса, мин сезгә тагын бер* ***рас*** *сүз сөйләп бирим. Бирем әкәгә сәламемне тапшыр,* ***арызымны*** *әйт, Найман, Дүрткара* ***илләренең*** *кунагы булуыңны көтәбез, диген! Ләкин чит йортта моңа каршы берни кылырга да* ***амал юк*** *иде; агач савыт белән бирелгән куе* ***күҗә;*** *Биремҗан дигән ул исәр* ***чал*** *– йортның барына да билгеле адәм* ***гуй****! кода булуны* ***лазем итмәгән*** *булсалар* и («Казакъ кызы»). Эти слова своими корнями уходят в далекое прошлое и являются достоянием многих тюркских народов и языков.

Татары, живущие в Китае, не потеряли свою исконную лексику и до сих пор активно употребляют ее в своей речи. Сохранению некоторых из них в активном употреблении способствовал и тот факт, что они имеются в родственных казахском и уйгурском языках. Например, нан – хлеб, нарын – овощной суп, инәк – корова, йарык – светло, кәйен – потом, кәптәр – голубь, пакта – хлопок, клит – ключ, кулуп – замок, бакали – бакалея, чөмәк – гвоздь, кат-кат – пирог, бал прәннек – пряник, чыраг – свет, табанча – пистолет, чапан – куртка, мумай – бабушка, мөшек – кот, пайпак – носки, юллык – гостиница и т. д. Таким образом, понятие «устарелость» относительно: многие лексические единицы, грамматические формы и синтаксические конструкции, орфоэпические и орфографические нормы занимали разное положение, имели разный статус в языке метрополии и в языке восточного зарубежья в один и тот же период.

Сравнительное изучение особенностей языка романа Г. Ибрагимова, функционирования лексики татарского языка в Китае в среде изолированных от метрополии носителей языка весьма ценно в научном плане. Язык татарской эмиграции в Синьцзяне приобретал свои структурно-семантические особенности, обусловленные различными факторами, как собственно лингвистического, что доказывают произведения Г. Ибрагимова, так и социолингвистического свойства.

ЛИТЕРАТУРА

1. Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Лексика. – М.: Наука, 2001. – 822 с.

2. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге: 3 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1981. – Т. 3. – 832 б.

3. Әхмәтьянов Р. Г. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге / Р. Г. Әхмәтьянов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 272 б.

*Статья выполнена в рамках гранта РГНФ 11-04-00074 а.*

## Г. ИБРАҺИМОВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ АШ-СУ ТРАДИЦИЯЛӘРЕ ЛЕКСИКАСЫ

***Ф. С. Баязитова, А. Ф. Гайниева (Казан)***

Г. Ибрагимов оставил многогранное творческое наследие. Он глубоко знал и уважал народный язык, его местные особенности, духовную и материальную культуру не только татарского, но и соседних тюркских народов. Например, в его произведениях находят отражение в языковом и этнографическом отношении такие тонкости, как народные обряды, обрядовая пища и гостеприимство татар, башкир и казахов.

Г. Ибраһимовның әдәби мирасы бай һәм күпкырлы. Аның әсәрләрендә иҗтимагый тормыш төрле яктан яктыртыла.

Г. Ибраһимов үзенең иҗатында сөйләмнең гадилегенә, ачыклыгына һәм матурлыгына зур игътибар итә, образлылыкны көчәйтү өчен әледән-әле халык теленә

мөрәҗәгать итә. Халык теле, халык иҗаты аның өчен бай чыганак булып тора. «Болар милли тел һәм милли лөгатьнең бердәнбер хәзинәләредер», – ди Г. Ибраһимов.

Г. Ибраһимов тумышы белән авыл кешесе. Ул элекке Урал губернасы Стәрлетамак өязендә (хәзерге Башкортстанның Авыргазы районы, Солтанморат авылында) туып үскән. Бу төбәктә татар теленең минзәлә сөйләше һәм мишәр диалектына караган стәрлетамак сөйләше таралган, гомумән, төрле этнографик төркемнәр (типтәрләр, казан кешеләре, мишәрләр) бергә аралашып яшәгәннәр. Шуның өчен Г. Ибраһимов әсәрләрендә дә шул төбәкнең җирле традицияләре, тормыш-көнкүреше, аларга караган сүзләр, тәгъбирләр, тел үзенчәлекләре чагылыш таба

Г. Ибраһимовның «Татар хатыны ниләр күрми» әсәрендә авыл кызы Гөлбануның кичерешләре, аның фаҗигале язмышы, шулай ук бик җентекләп туй күренеше, туй йоласы, туй ашлары, кыз бирү, килен төшерү, туйдан соңгы яшь киленнең тормышы сурәтләнгән. Аш-су йолалары, аларның атамалары, мәҗлесләр, кунак сыйлаулар да халык традицияләре белән бәйләнештә үрелеп бара.

**Аш-су** – гомумән ашамлык, ашау-эчү әйберләре. Әсәрдә туй мәҗлесе өчен аш-суны бик мулдан, тырышып әзерләү турында сүз бара.

*«Берүк оятка калырлык булмасын, аш-суыңны карап әзерлә»* (226 б.). *«Бу вакыт Гөлбану кунаклар өчен казан, мич тирәсендә аш-су хәзерләшеп йөри иде»* (318 б.).

**Аш өе** – аш-су әзерләү өчен махсус эшләнгән кечкенә өй. ... *«Гөлбану сикереп торды, ... аш өенә таба чыгып китте»* (234 б.). *«Зур җилпуч белән йөгереп келәткә барды, өсәктән тутырып арыш оны алды да аш өенә керде»* (322 б.).

Аш-су табынын кулдан сугылган ашъяулыклар җәеп, кунаклар алдына салырга тастымаллар биреп хәстәрләгәннәр. Әсәрдә: *«Зур кызыл ашъяулык җәйде»* (256 б.). *«Кызыл киҗеле ашъяулык чыгарды»* (263 б.). Кунаклар алдына кую өчен әзерләнгән озын тастымал әлеге әсәрдә *салфит* сүзе белән бирелгән: *«Ишектән түргә сузылган тоташ салфитны болар таратты»* (256 б.). *«... биш көре киҗеле салфитларны табаксавыт сөртеп йөртте»* (373 б.). *«Ширбәт алынуга ике табынга ике салфит җәелде»* (257 б.).

**Салфит** сүзе тастымал яки сөлге мәгънәсендә урал алды һәм урал сөйләшләрендә еш кулланыла, ул шулай ук мишәр диалектының чистай сөйләшендә дә бар (тастымал мәгънәсендә). Салфит – рус телендә салфетка. Ул рус теленә итальян *(salvietta)*, немец *(salvette)* телләреннән кергән дип күрсәтелә (Фасмер, III, 551), димәк, шактый борынгыдан килгән алынма сүз.

Табынга иң беренче итеп токмачлы шулпа чыгарылган, аны зур табак белән уртага куйганнар: *«Иң элек зур агач табакта өсте май белән капланган токмачлы шулпа чыгардылар»* (256 б.). Ит шулай ук табак белән мул итеп чыгарылган: *«Токмач артыннан йомшарып пешкән симез билдәмәләре килде»* (256 б.).

Икмәк һәм камыр ашларының кулланылышы, аларның табынга бирелешендә дә барлык татар халкына хас йолалар һәм тел байлыгы чагылдырыла: *«искергән арыш икмәге»* (238 б.), *«майлы күмәч, бик зур бодай икмәге»* (263 б.). **Бәлеш**: *«Анда үги килен Мәрхәбә бәлеш майлап маташа»* (257 б.). **Пәрәмәч**: «... *каймактан, майдан, пәрәмәчтән җитешегез»* (248 б.).

Әсәрдә татар халкының туй йолаларында электән кулланылып килгән йола атрибуты буларак билгеле **ширбәт** сүзе дә кулланылган: *«Иң ахырдан никах ширбәте килде»* (256 б.). *Ширбәт* – гарәп теленнән кергән сүз: җиләк-җимештән махсус әзерләнгән татлы су яки шикәр салып болгатылган су. Җирле сөйләшләрдә *шәрбәт* варианты да бар (себ., к.-уф., перм. һ. б.). Кайбер төбәкләрдә ул түбәндәге сүз тезмәләрендә бүгенге көндә дә бик актив кулланылышта йөри: **ширбәт суwы** (хвл.) баллы су; **ширбәт ыртлау** (кузн.) баллы су йоту; **ширбәт каптыру** (кузн.) киленгә баллы су каптыру; **ширбәт бөркү** (кузн., хвл.) киленгә баллы су бөркү; **ширбәткә салу** (каз. ар.) туй мәҗлесендә бүләк салу һ. б. **Җимеш суы** – кунак табынында чәйдән дә алдан бирелә торган эчемлек: *«Тик болар артыннан Фәтхия карчыкның көяз кодалар, кодагыйлар алдында мактанычлы җимеш суы бирелде дә гөҗләп кайнап торган зур көмеш самавыр китерелде...»* (285 б.). Чәй яны ашлары арасында шул төбәк өчен хас булган ашамлык – төеп майга катыштырылган шомырт та искә алынган: *«чәй янына атланмай, кәрәзле ак юкә балы, төеп майга катыштырылган шомырт, вак бәлеш, эссе коймак белән каймак чыгарылды, шуннан башка нәрсә өстәлмәде»* (285 б.). Киптереп төелгән шомыртны, шулай ук кырда үскән вак чияне май белән болгатып кую, кышка саклау минзәлә, пермь һәм красноуфим татарлары сөйләшендә дә билгеле.

Әсәрдә туй мәҗлесендә кодалар алып килгән туй ашларын табынга бирү бик җентекләп язылган: «*Иң элек кодаларның ашларын, туй күчтәнәчләрен мәҗлескә чыгарып күрсәттеләр, табынга сыйдыра алмыйча аптырадылар. Аның майлары тулышып торган ике симез казы белән симез күркәсе, өсләренә каклар, җимешләр сибеп пешерелгән дүрт зур ләвеш күмәче, кечкенә дүрткел тау кебек торган, өсте-читләре кәнфит белән чәчәкләнгән зур ике баллы бавырсагы тагы әллә ничаклы оста әзерләнгән аш бүләкләре мәҗлеснең күзләрен уйнаттылар. Болар тирәсендәге бер батман ак кәрәзле бал, бер пот май, катлауланып пешкән симез билдәмә, кадаклы яхшы чәй кебекләр инде бөтенләй югалып калдылар»* (225 б.)

*«– Менә бусы өлкән кода Шиһабетдиннеке.*

*– Менә бусы Әфтәх коданыкы.*

*– Менә бусы Алтынбай коданыкы, – дип, атыйатый, чыгарылган әйберләр мәҗлес халкы алдында тау-тау булып өелде. Аннан инде мәҗлесне сыйлау өчен йорт хуҗасы Нурый картның ашларын бирә башладылар»* (225 б.).

Туй вакытында кодалар алып килгән күчтәнәчләрне «кода ашы» дип зурлап, олылап кунаклар утырган табынга алып чыгып күрсәтү татар халкы яшәгән бик күп төбәкләр өчен хас (керәшеннәрдә ул *кода ипиен чыгару* дип атала). Бу йолалар әле хәзер дә сакланалар һәм ул бик күп җирле сөйләш текстларында чагылыш таба.

Туй үткәннән соң кунакларны озату көнендә шулай ук зурлап табын ясалган. Биредә ул **озату ашы** дип аталган мәҗлесне белдерә: *«Төш авуга озату ашына утырдылар. Майлы шулпа белән токмач, симез билдәмә, зур кисәкләрдә китерелгән суык каз, сары май эчендә йөзеп пешкән өлкән бәлеш – бүгенге сый барлыгы менә шулар иде» (*284 б.). Биредә тагын бер бик матур йола – **бүләк чәе** турында да сүз бара: *«Туй үткәч тә Гөлбану үзенең иптәш кызларын бүләк чәенә чакырачак, һәммәсенә, дәрәҗәсенә карап, исле*

*сабыннар, хушбуйлар, иннекләр, кершәннәр өләшәчәк»* (274 б.).

Киленнең кайнана йортына төшкәч беренче хезмәте – *суга баруы* һәм аңа *су юлы күрсәтү*, шулай ук аш-суга караган йола – *токмач кисү* бу әсәрдә татар халкының традицион йолалары буларак чагылыш тапкан: *«Гөлбану үзенең чигүле алсу алъяпкычын чыгарды да җиңел, уңган кул белән тиз-тиз бәләкләде, каршыларга килгән каенсеңелләр ярдәме белән чиләк-көянтә алды, кушъяулык (бөркәнчек) ябынды, алты кыз белән бергә, якындагы чишмәгә суга китте. Бу кызлар яңа төшкән киленгә су юлы күрсәтеп кайттылар. Аннан кергәч, аш өендә, беләк сызганып камыр басты, бик нечкәләп токмач кисте, чиләк сыярлык зур самаварга су салып ут кабызды, шулай бер-бер артлы өй хезмәтләре ялганып китте»* (280 б.).

Көнкүреш һәм йола үзенчәлекләренә бай булган «Казакъ кызы» романында Г. Ибраһимов тугандаш казакъ халкының революциягә кадәрге дала тормышын сурәтли, аларның теленә хас сүзләрне кулланып, әсәрнең милли колоритын тагын да арттыра. Борынгы төрки аш-су атамалары *бавырсак, казылык, күҗә* һ. б. әсәрдә шулай ук тарих һәм этнография, тел ягыннан игътибарга лаек. Чөнки җирле сөйләшләрдә алар әле хәзерге чорда да сакланып киләләр. *«Берничә бавырсак салган бер тәрилкә алып, боларны кунак алдына китереп куйды, куе каймак салып, чәй ясый башлады»* (339 б.). *«Ни күрсен, ана белән кыз, акрын гына сөйләшеп, сай табактан майлы итне, казылыкны ашап утыралар»* (445 б.).

**Күҗә** – ярманы киледә төеп ваклаганнан соң казанда яки чуенда кайнатып пешерелгән сыек ботка. Бу сүз кардәш казакъ халкының тормышы белән яхшы таныш булган И. Салахов әсәрләрендә дә очрый: *«Сәет күҗәне бер-ике йотым тәмләп карады»*. «Казакъ кызы»нда: *«Карт, кулына бер-ике тамчы су салып, керле сөлгегә сөртте дә, агач савыт белән бирелгән куе күҗәне, пешереп киптерелгән тары ярмасын ашап, кечкенә күн турсыкка салынган әйрәнне алып, йортка чыкты»* (348 б.).

*Күҗә* сүзе Акмулла иҗатында да кулланылган:
*Катыксыз кара күҗә – эчкән асы.*
*Эчкәндә тамчылайды күзең ясы.*

Әстерхан сөйләшендә *көҗә // күҗе* ярмадан пешерелгән итсез аш, себер диалектларында *күҗә // күцә* – сыек ботка. Мәсәлән, әстерхан сөйләшендә *төй күҗе* – тары ярмасыннан пешерелгән аш яки ботка. *«Сары төй салады күҗегә, тарыны әйтәләр төй тип. Төй күҗәне ашайбыз аны».*

Бу борынгы атама төрле фонетик вариантларда башка төрки телләрдә, мәсәлән, карачай-балкар, кыргыз, казакъ, үзбәк һ. б. да билгеле. Урта диалект сөйләшләрендә *җарма кузәү* – тары яки башка берәр бөртекле ашлыкны килегә салып төеп ваклау: *Дары (тары) җармасын күдәйләр ийе* (минзәлә). Димәк, *кузәү, күҗе, күҗә* һ. б. ш. сүзләр төрки халыкларның тормыш-көнкүрешенә караган борынгы урталыклар һәм алар Г. Ибраһимов иҗатына да бик урынлы булып килеп кергәннәр.

Йомгак ясап әйткәндә, Г. Ибраһимов әдәби телне дә, җирле үзенчәлекләрне дә, халык традицияләрен дә тирәнтен белеп, шуларны үзенең иҗатында тиешле дәрәҗәдә файдалана белгән. Алай гына да түгел, ул тугандаш башкорт, казакъ халкын, аларның тел һәм йолаларын, гореф-гадәтләрен дә барлык нечкәлекләре белән төшенеп тасвирлаган, онытылмый торган тарихи-этнографик күренешләр һәм әдәби образлар иҗат итеп калдырган. Шуның өчен аның әсәрләре бүгенге көн укучылары өчен дә кызыклы һәм бик зур мәгълүмат чыганагы булып кала.

ӘДӘБИЯТ

Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. I т. – Казан, 1974. – 510 б.; II т. – 1975. – 455 б.; III т. – 1975. – 477 б.

# Г. ИБРАҺИМОВ ХЕЗМӘТЛӘРЕНДӘ ТАТАР ТЕЛ БЕЛЕМЕ ТЕРМИНОЛОГИЯСЕ

***Р. Р. Шәмсетдинова (Казан)***

В статье выявляется вклад Г. Ибрагимова в развитие терминологии татарского языкознания.

Г. Ибраһимов татар теленең иҗтимагый функциясен киңәйтү, фәннең һәр тармагы өчен атамалар – терминнар булдыруны үз чорының иң мөһим мәсьәләләреннән саный. Терминология өлкәсендә ул түбәндәге нигезләмәгә таяна: «аерым бер милләт булып яшәү әмәле булган халыклар үз телләрен дә фән вөҗүдкә китерергә тиешлеләр. Боңа ирешү өчен, фәнни истиляхны – булдыра алган чаклы – үз телләрендә ясап, җитмәгән, ләкин зарур булган урынларда гыйлемдә остаз итеп торткан икенче милләтләрдәге истиляхларны алырга мәҗбүр булалар. Бу һәм һәр халыкта шулай була килә (2).

Г. Ибраһимов татар теленең фән өлкәсендә үз урынын алу процессының шактый катлаулы һәм акрын баруын яхшы аңлап, үзенең «Татар сарыфы» һәм «Татар нәхүе» китапларында тел белеме терминнарын мөмкин кадәр татар теленең үз чаралары ярдәмендә ясарга тырыша. Ул яңа терминны телдә булган сүзгә яңа мәгънә биреп, яки телнең сүз ясый алу мөмкинлекләреннән файдаланып кертеп җибәрергә мөмкин дип саный.

Галимнең лингвистика өлкәсенә караган хезмәтләрендә татар теленең үз чараларыннан файдаланып ясалган терминнар шактый актив кулланыла һәм алар төрле ысулларга нигезләнгән. Шулар арасында иң активы – әзер сүзне терминлаштыру юлы белән ясалган терминнар: *боерык, иярту, сөйләүче (I), сүз, тамыр, тыңлаучы (II зат), урын, үзгәреш, үзәк (сүзнең тамыры), ярашу*. Г. Ибраһимов кушымчалау ысулы белән терминнар ясауның продуктив булуын ассызыклый һәм шул ысул белән ясалган уңышлы гына терминнар тәкъдим итә, аларның шактый өлеше тел белеменә кереп китә, урнашып кала. Мәсәлән: *аергыч, аерылмыш, аталма (атама), барлык-юклык, бәйлек, искәрмә, саналмыш, сөйләгеч (I зат), тезем, теркәләгеч (изафә бәйләнешендә булган сүзләрнең беренчесе), теркәләнмеш (изафә бәйләнешендә булган сүзләрнең икенчесе), төрдәш (сыйфат фигыль), эндәшелгеч (II зат), ярдәмлек, ясалыш.*

*Аерым алмаш* (аерым язылa торган алмашлыклар), *билгеләү алмашлары, бүлем ярдәмлекләре* (бүлү-

че теркәгечләр), *җыю ярдәмлекләре* (җыючы теркәгечләр), *зат алмашлары* (зат алмашлыклары), *иярчен кисәкләр, иярчен сүзләр* (ярдәмлек сүз төркемнәре), *кереш сүз, каеру ярдәмлекләре* (каршы куючы теркәгечләр), *охшату ярдәмлекләре* (чагыштыру мәгънәсен белдерүче бәйлекләр) кебек бүгенге дәреслекләрдә кулланыла торган, лингвистик *төп сан, чама саны* терминнар-сүзтезмәләр дә Г. Ибраһимов тарафыннан кертеп җибәрелә.

Г. Ибраһимов үзенә кадәр язылган фәнни хезмәтләрнең теленә дә гаять игътибарлы, аларны өйрәнеп, уңышлы дип сайлаган терминнарны үзенең фәнни хезмәтләрендә куллана, мисал итеп *берлек-күплек* (Ш. Иманаев), *иҗек* (К. Насыйри), *тынышлар* (М. Өметбаев), *ымлык* (Г. Нугайбәк), *сан, өлеш саны, бүлем саны* (Г. Фәезханов), *сүз төре* (Һ. Макъсуди) һ. б. ларны китерергә мөмкин.

Дөрес, татар теленең үз мөмкинлекләренә нигезләнеп ясалган терминнарның бүгенге көндә телдә урнашып китүләре төрлечә була. Бер төркем терминнар галим кертеп җибәргән хәлдә телебезгә кереп китәләр һәм актив кулланылып киләләр, мәсәлән: *искәрмә, кереш сүз, аваз, аергыч, барлык-юклык, сан, саналмыш, сүз, тамыр* һ. б. Кайбер терминнар бүгенге телдә беркадәр морфологик үзгәрешләр кичергән хәлдә кулланылалар: *зат алмашлары, күрсәтү алмашлары, аталма, җыю ярдәмлекләре, тынышлар, эндәш* һ. б. Терминнарның бер өлеше тел гыйлемендәге күренешләргә караш үзгәрү барышында, алар белдергән төшенчәләр юкка чыгу сәбәпле, пассивлашып, кулланылыштан төшеп калган: *сүз җилеме, юлдаш, кире өтер, тоташ алмаш, аерым алмаш, юлдаш сүзләр, явыз теләк* һ. б.; кайберләре урынына хәзерге тел белемендә башка терминнар кулланыла: *каеру ярдәмлекләре, иярчен сүзләр, төрдәш, эндәшелгеч* һ. б.

Галим татар телендәге алынма терминнарга карата да үз мөнәсәбәтен белдерә. Телгә кереп урнашкан һәм күп еллар дәвамында кулланылышта йөргән гарәп һәм фарсы чыгышлы алынма терминнар Г. Ибраһимовның тел гыйлеменә караган хезмәтләрендә мөһим урын алып торалар, шундыйлардан *изафә, җөмлә, замир* (алмашлык), *имля, нәху, истилях, назария, сарыф, шивә, асыл, вакыт, заман, исем, мәгънә, сыйфат, фигыль, хәреф* һ. б. Бу терминнарның кайберләре хәзерге вакытта традицион гарәп тел белемендә кулланыла, ә кайберләренең бераз үзгәртелеп, ләкин галим биргән эчке формасы, төшенчә белән атама арасында бәйләнеш табигате сакланган хәлдә, кулланылышта йөрүләре күзәтелә. Шулай ук аның тел белеменә караган хезмәтләрендә, гарәп-фарсы алынмаларын нигез итеп, татар теленең үз чаралары ярдәмендә төзелгән катнаш составлы яңа төр, нигездә, ике составлы терминнар булу күзәтелә: *исемлек галәмәтләре, сыйфатлык галәмәтләре, фигыльлек галәмәтләре, хәзерге заман, гамәлдәш бабы, хәзерге хәл, теләк бабы, төп исем, ялгыз исем, ким җөмлә, тавыш хәреф* һ. б. Мондый төр катнаш терминнарда алынма сүзләр күпчелек очракта ыру төшенчәләрне, ә татар теленең үз сүзләре төр төшенчәләрне белдерүләрен дә билгеләп китәргә кирәк. Ыру төшенчә белдергән терминнарның, гадәттә, күпчелек телләр өчен уртак булган универсаль категорияләрне белдерүләрен исәпкә алсак, Г. Ибраһимовның терминологик фондтагы алынмаларга карата мөнәсәбәтен билгеләү кыен түгел. Галим тарафыннан кертеп җибәрелгән, активлаштырылган терминнарның телдә урнашып калуларының да төрлечә булуы күзәтелә. Ул терминологик берәмлекләрнең бер төркеме хәзерге тел белеме өлкәсендә:

а) үзгәрешсез кулланыла: *кушма җөмлә, сәбәп җөмлә, баш җөмлә, вакыт җөмлә, киләчәк заман, үткән заман, хәзерге заман, кушма исем, ясалма исем, ялгызлык исеме, хәл фигыльләр, сыйфат дәрәҗәләре* һ. б.;

б) тезмә термин составындагы ыру төшенчәне белдерүче компонент үзгәртелеп кулланыла: *йөкләтү бабы, кайтым бабы, барлык-юклык галәмәтләре, иркәләү-кечерәйтү галәмәтләре;*

в) төшенчәсе юкка чыгу аркасында кулланылыштан төшеп калган терминнар: *калым бабы, үтем бабы, оешкан җөмлә, исме масдар, фигыль масдар, шарт ярдәмлекләре.*

Г. Ибраһимовның татар теле лингвистик терминологиясен камилләштерү юнәлешендә алып барган гамәли эшчәнлеге татарча яңа лингвистик терминнар иҗат итү, үз дәреслекләре аша аларны гамәлгә кертү, үзенә кадәр эшләнгән терминнарга анализ ясау һәм уңышлы дип саналганнарын активлаштыру, телдә кулланылып килгән гарәп-фарсы чыгышлы кайбер терминнарны, мәгънә – эчтәлекләрен конкретлаштырып, яңа термин составына кертеп җибәрүдә чагылыш табуы күзәтелде.

Билгеле булганча, «ясалыш ысулы – сүзне динамик яктан, төзелеш тибы – статик яктан характерлый...» (13, 122). Г. Ибраһимов ясалыш ысулы төзелеш калыбы белән үзара тыгыз бәйләнгән булуны яхшы аңлый, лингвистик терминнарны төрле ысуллар ярдәмендә ясый һәм төрле төзелеш калыпларына нигезләнә (3).

Шулай итеп, Г. Ибраһимовның татар тел белеме терминнарын эшләүдә гамәли эшчәнлеге татарча яңа лингвистик терминнар иҗат итүдә, үз дәреслекләре аша аларны гамәлгә кертүдә, башка телче галимнәр тарафыннан тәкъдим ителгән терминнарны кулланылышка кертүдә, терминология мәсьәләсенә кагылышлы бәхәсләрдә катнашып (матбугат битләрендә), татар тел белеменең терминологик системасын оештыруда катнашуында чагылыш таба.

## ӘДӘБИЯТ


1. Вәлиди Җ. Галимҗан Ибраһимовның тел мәйданындагы хезмәтләре // Г. Ибраһимов. Юбилей җыентыгы. – Казан: Татиздат, 1928. – Б. 131–142.

2. Ибраһимов Г. Истиляхлар һәйәтендән // Эшче. – 1920. – 20 декабрь. – №126.

3. Ибраһимов Г. Фәнни истиляхлар // Аң. –1913. – № 24.

4. Ибраһимов Г. Яңа әдәби татар теленең беренче баскычларында // К. Насыйри мәҗмугасы. – Казан, 1922. – Б. 150–160.

5 Ибраһимов Г. Татар телен җиңеләйтү мәсьәләсен чишәргә кирәк // Кызыл Татарстан. – 1924. –14 сент.

6. Ибраһимов Г. Татар телен җиңеләйтү турында тезислар // Мәгариф. – 1924. – №3/4. – Б. 169–172.

7. Ибраһимов Г. Тел һәм атамалар турысында инструкция // Кызыл Татарстан. – 1926. – 22 янв. – № 28.

8. Ибраһимов Г. Тел-әдәбият мәсьәләләренең кирәкле бер тармагы // Г. Ибраһимов. Әсәрләр: сигез томда. – Казан, 1978. – V т. – Б. 490–491.

9. Ибраһимов Г. Татар сарыфы / Г. Ибраһимов. – Казан, 2003.

10. Кириллова З. Н. Татар телен дәүләт теле буларак гамәлгә кую (20–30 нчы еллар) / З. Н. Кириллова. – Казан: Мастер-Лайн, 2000.

11. Хаков В. Х. Татар әдәби теле тарихы / В. Х. Хаков. – Казан, 1993. – Б. 313–323.

12. Хәерби. Татар сарыфы вә нәхүе // Йолдыз. – 1911. – № 751.

13. Фасеев Ф. С. Татар телендә терминолдогия нигезләре / Ф. С. Фасеев. – Казан: Таткнигоиздат, 1969. – 200 б.

# ТАТАР ТЕЛЕН ДӘҮЛӘТ ТЕЛЕ ИТҮДӘ Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ РОЛЕ (XX гасырның 20–30 нчы еллары)

*З. Н. Кириллова (Казан)*

Статья посвящена исследованию процесса реализации татарского языка как государственного в 20–30-е годы XX века и деятельности в этой области видного писателя, публициста, ученого и общественного деятеля Г. Ибрагимова. Особое внимание уделяется исследованию работы Академического центра и Научного общества татароведения, в деятельности которых активное участие принимал Г. Ибрагимов.

1921 елда татар теле беренче тапкыр рәсми рәвештә рус теле белән тигез дәрәҗәдәге дәүләт теле дип игълан ителә, һәм аны иҗтимагый тормышның барлык өлкәләрендә дә гамәлгә кертү буенча киң эш җәелеп китә. Әлеге эш белән Татар телен гамәлгә кую үзәк комиссиясе җитәкчелек итә.

Татар телен гамәли яктан тормышка ашыручы ролен Мәгариф комиссариаты үти. Аның карамагындагы төрле тип уку йортларында татар телен укыту һәм татарларны күбрәк җәлеп итү буенча зур эш башкарыла.

1918 елның май аенда Казанда үткәрелгән Бөтенроссия мөселман укытучыларының өченче съездында Татарстанда беренче гыйльми оешма – Гыйльми һәйәт сайланып, аның каршында төрле бүлекләр (теләдәбият, тарих бүлеге, музей, театр һәм нәфис сәнгать бүлеге, мәктәпләр өчен программалар төзү бүлеге, матбугат бүлеге һ. б.) оеша. Соңрак Гыйльми һәйәт, исемен аз гына үзгәртеп, Гыйльми мәркәз яки Гыйльми үзәк дип йөртелә башлый. 1921 елда, күп үзгәртүләр соңында, ТАССР халык мәгарифе комиссары һәм сәркятибе тарафыннан төзелгән гомуми нигезләр кабул ителә. Бу нигезләр буенча, Гыйльми үзәк Мәгариф комиссариатының фәнни, уку-укыту, агарту эшләре һәм әдәби эшчәнлек белән гомуми җитәкчелек итә, аның составына 4 комиссия керә: 1) фәнни-сәяси; 2) фәннитехник; 3) фәнни-педагогик һәм 4) сәнгать комиссиясе. Гыйльми үзәк 5 кешедән торган коллегия тарафыннан идарә ителә (1, 389).

Гыйльми үзәк 1922 елга кадәр оештырылу дәверен кичерә. 1922 елның 10 февралендә аның рәисе итеп Гаяз Максуд билгеләнә (2, 109). Гыйльми үзәк президиумы составына бу елларда Г. Максуд, фәнни-педагогик комиссия рәисе Г. Гобәйдуллин һәм гыйльми сәркатип Заһидулла Норкин (Нуркай) керәләр. 1925 елның 16 февраленнән алып, Гыйльми үзәк рәисе вазифасын Г. Ибраһимов башкара (3, 1). 1925 елның 7 апрелендә булган Гыйльми үзәк президиумы утырышында М. Корбангалиевкә фәнни-педагогик комиссия һәм нәшрият буенча эш алып барырга, Г. Ибраһимов булмаган вакытта, Гыйльми үзәк рәисе вазифаларын үтәп торырга тәкъдим ителә, һәм бу хакта карар да чыгарыла (3, 24).

Гыйльми үзәкнең эшчәнлеге дәвамында аның составында күп төрле комиссияләр төзелә. Аларның саны күп булуга да карамастан, үзәкнең эшчәнлеге нигездә 3 төп юнәлештә алып барыла: фәнни-педагогик, редакция-нәшрият эшчәнлеге һәм туган якны өйрәнү эше.

Фәнни-педагогик комиссия тарафыннан төрле тип уку йортлары, курслар өчен уку планнары, программалар һәм дәреслекләр төзелә, аларга күләмле аңлатмалар языла; мәгариф бүлекләрендә методик бюролар оештырыла; күп санлы методик кулланмалар, аңлатма язулары, методик хатлар күбәйтелеп таратыла һ. б.

1920 елның 12 ноябрендә үк Татгосиздатның нәшрият бүлеге киңәйтелгән утырышында татар телендәге дәреслекләр төзү буенча коллектив оештырыла. Аның составына күренекле 6 галим: Г. Ибраһимов, М. Корбангалиев, Ф. Сәйфи, Г. Шәрәф, Х. Бәдигый һәм Г. Сәйфуллиннар кертелә. Аларның бурычы итеп булган дәреслекләр белән исәпләшмичә, бөтенләй яңа дәреслекләр төзү, моның өчен төп принцип итеп коммунистик хезмәт принцибын алу, ә милли һәм дини тенденцияләрне катгый рәвештә булдырмау куела (4, 118–119). Шул вакыттан алып, әкренләп коллективлар яки аерым авторлар тарафыннан татар теле буенча дәреслекләр төзеп бастырыла башлый.

Татарстан республикасында чыгарыла торган барлык китаплар, дәреслек-кулланмалар, уку-укыту характерындагы һәм фәнни хезмәтләр Гыйльми үзәк карап чыгып, раслаганнан соң гына бастырылалар, бары вакытлы матбугат, өлкә комитеты, Халык комиссарлары советы һәм комиссариатларның махсус басмалары өчен генә Гыйльми үзәк рөхсәте таләп ителми (5, 79). Гыйльми үзәккә килгән барлык хезмәтләрне дә карап чыгу өчен, башта 2, аннары 3 редакция коллегиясе төзелә (татар, рус һәм милли азчылык телләрендәге китапларны карау өчен). Бу хезмәтләрнең күпчелеген татар телендәге китаплар тәшкил итә.

Кульязмалар тикшерү, редакцияләү, бастырырга рөхсәт бирү эшеннән тыш, Гыйльми үзәк тарафыннан журналлар да нәшер ителә. Аларның беренчесе – 1918 елдан бирле татар телендә чыгып килгән «Мәгариф» фәнни-педагогик журналы. Педагогика һәм методиканың теоретик һәм гамәли мәсьәләләре, татар теле һәм туган якны өйрәнү проблемаларын яктыртучы журнал 1938 елдан «Совет мәктәбе» исеме астында чыга башлый.

20 нче елларда Гыйльми үзәк кул астында чыгарылучы икенче басма – рус телендәге «Вестник просвещения» журналы. Шулай ук бу елларда татар телендә иҗтимагый-сәяси һәм әдәби характердагы «Безнең юл» журналы да үзенең эшчәнлеген җәелдерә. Билгеле булганча, журналның төп җитәкчесе Г. Ибраһимов була.

Гыйльми үзәк тарафыннан нәшер ителүче әлеге журналлар Татарстан республикасында гына түгел, СССР территориясендә яшәүче барлык төрки халыкларга да таратыла (6, 211).

Татар телендә бастыру өчен, төрле характердагы әдәбият әзерләгәндә, шулай ук, гомумән, татар телен дәүләт теленә яраклаштыру процессында, Гыйльми үзәк башта ук татар шрифты, орфографиясе, татар телендә фәнни терминология эшләү мәсьәләләре алдына килеп баса. Гыйльми үзәктә терминнар төзү буенча махсус комиссия оештырыла, аның кул астында «Татарстан» газетасы редакциясендә һәм Җир эшләре комиссариатының нәшрият бүлегендә дә комиссияләр эшли (7, 20). Татар телендә терминнар төзү өчен кабул ителгән карарлар нигезендә, Гыйльми үзәк тарафыннан бик күп фәннәрнең атамалары төзелә һәм шул атамалар

буенча дәреслекләр, гыйльми хезмәтләр һәм фәнни-популяр китаплар мәйданга чыгарыла. Билгеле булганча, Г. Ибраһимов – бу өлкәдә дә күп эшләгән галим, Гыйльми үзәк тарафыннан 1925 елда кабул ителгән «Тел һәм атамалар турысында инструкция» авторы.

Татар теле орфографиясенә реформа ясау мәсьәләсе буенча 10 елдан артык барган бәхәсләр дә 20 нче еллар башында күренерлек нәтиҗәгә китерә: 6 сузык аваздан торган орфография нигез итеп алына һәм бу татар халкы өчен шактый зур адым була (7, 20). 1920 елның 1 декабрендә Мәгариф комиссариатының фәнни бүлеге коллегиясе утырышында орфография төзү буенча комиссия составы игълан ителә. Әлеге комиссиягә «Эшче», «Татарстан», «Кызыл Шәрекъ», «Кызыл армия» редакторлары, Татрост, Госиздат вәкилләре һәм 9 белгеч (М. Корбангалиев, Г. Ибраһимов, Г. Шәрәф, Х. Бәдигый, Г. Максуд, Г. Рәхим, Г. Динмөхәммәтов, К. Сәгыйтов, Г. Хәбидов) кертелә (8, 14). Яңа орфография 1922 елда Татарстан республикасы буенча тулысынча урнашып бетә һәм әкренләп республикадан читтә булган татар вакытлы матбугатына да керә башлый (7, 20).

Ләкин, билгеле булганча, 20 нче елларда күп кенә халыклар латин алфавитына күчәләр. 1926 елның февралендә Бакуда төрки телле халыкларның язуын латинлаштыру мәсьәләләренә багышланган I Бөтенсоюз тюркологлар съезды үткәрелә. Съезд эшендә Азәрбайҗан һәм Урта Азиянең союздаш республикалары делегацияләреннән тыш, автоном республика һәм өлкәләрнең вәкилләре, Мәскәү, Ленинград һ. б. шәһәрләрдән күренекле рус тел галимнәре һәм ориенталистлары катнаша. Барлык төрки халыкларның да делегацияләре гарәп графикасын латинга күчерү тәкъдимен керткәч, Г. Ибраһимов, Татарстан делегациясенең башлыгы буларак, моңа каршы чыга, латинга күчмәскә, гарәп хәрефләрен реформалау белән чикләнергә тәкъдим итә: «Без, Татарстан вәкилләре, гарәп хәрефләренә реформа ясау, шуның белән аны хәзерге заман техникасына ярату юлында булдык, – дип яза ул съезддан кайткач. – ... Башкаларның тәҗрибәсеннән ни нәрсә чыгар, аны киләчәк күрсәтер» (9, 274–275). Тюркологлар съездындагы доклады матбугатта чыккач, Г. Ибраһимов позицияләрен тәнкыйть итеп язылган мәкаләләр һәм җыелышларда чыгышлар шактый күп була. Шуларга җавап итеп, әдип күләмле генә өч мәкалә белән чыга һәм үзенең графика өлкәсендәге позициясен тагын да ачыклый, башкаларның һәм читләтеп кенә тюркологлар съездының принципиаль ялгышын ачып сала. Ул, графика алыштыру элекке мирастан аерылу куркынычы белән бәйләнгән, халыкның иҗтимагый үсешен артта калдырырга мөмкин, ди (9, 348). Күренгәнчә, Г. Ибраһимов административ чаралар куллану, латинлаштыруны ясалма тизләтү ягында булмый, халыкның бу яңалыкны аңлы рәвештә, өстән басым ясалмыйча кабул итүен тели.

Гыйльми үзәк эшчәнлегенең өченче юнәлеше – туган якны өйрәнү эше – Татар дөньясын өйрәнү фәнни җәмгыяте эшчәнлегендә ачык чагыла. Бу җәмгыять татар халкының телен, тарихын, мәдәниятен төрле яклап өйрәнү буенча зур хезмәт күрсәтә, үзенең тирәсенә танылган галимнәрне, шул исәптән татарлар арасыннан күренекле белгечләрне туплый.

Җәмгыятьнең максаты итеп түбәндәгеләр куела: татарларны һәм татар мәдәниятен төрле яклап фәнни өйрәнү эше белән шөгыльләнүче белгечләрне бергә туплау, шулай ук бу өлкәгә кагылышлы мәсьәләләрне фәнни эшкәртү. Бу максатларны күздә тотып, җәмгыять үзенең бөтен халык алдында үткәрелә торган гомуми җыелышларында фәнни докладлар һәм белдерүләр тыңларга, экспедицияләр оештырырга һәм хезмәтләрен махсус журналда бастырырга тиеш була. Ул үзенең эшчәнлеген татар халкының матди һәм рухи мәдәниятен төрле яклап өйрәнү нигезендә алып бара (10, 201).

Кызганыч, шундый зур максатлар куйган җәмгыять озын гомерле булып чыкмый: 1929 елның 3 ноябрендә ул Татарстанны өйрәнү җәмгыятенә кушыла (10, 213). Алты ел ярым эшләү дәверендә җәмгыятьтә 4 идарә алмашына. Аларга төрле вакытта түбәндәге әгъзалар керә: Г. Рәхим, Җ. Вәлиди, Г. Гобәйдуллин, Г. Ибраһимов, М. Корбангалиев, Г. Максуд, Г. Шәрәф, Г. Сәгъди, М. Таһиров, М. Худяков, Н. Фирсов, Н. Воробьев һ. б.

Җәмгыятьнең аеруча актив эшчәнлеге 1925 елдан башлана. Нәкъ шул вакытта гомуми җыелышларның саны шактый арта, җәмгыять үзенең махсус басма органын чыгара башлый һәм фәнни экспедицияләр оештыра.

Үзенең барлык яшәеше дәверендә җәмгыять тарафыннан идарәнең 39 утырышы һәм шулай ук 39 гомуми җыелыш уздырыла, шуларның 7 се Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте (рәисе – Н. Фирсов) белән берлектә үткәрелә. Гомуми җыелышларда 65 фәнни доклад һәм чыгыш укыла. Докладлар белән 28 әгъза чыгыш ясый (10, 202). Докладлар татар тарихы, этнографиясе, әдәбияты, теле һәм башка бик күп проблемалар буенча күренекле галимнәр тарафыннан ясала. Мәсәлән, алар арасыннан В. А. Богородицкийның «Төрки-татар фонетикасы», «Төрки телләрдә сингармонизм законы», Г. Ибраһимовның Бакудагы I тюркология съезды хакындагы чыгышы, Җ. Вәлидинең «Казан татарлары диалектлары», Н. Ашмаринның «Казан татарлары телендә исем җөмләләр», «Татар телендә сүз тәртибе», Г. Сәгъдинең «Татар әдәбияты үсешенең төп моментлары», Самойловичның «Татарстан республикасында туган якны өйрәнүнең бурычлары» кебек докладларны аерым күрсәтергә мөмкин. Чыгышларның кайберләре җанлы фикер алышулар һәм бәхәсләр дә китереп чыгара.

Җәмгыять эшчәнлегенең соңгы 4 елында аның махсус органы – «Вестник научного общества Татароведения» (ВНОТ) журналы чыгарыла. Журнал битләрендә җәмгыятьнең гомуми җыелышларында укылган әһәмиятле фәнни докладлар, шулай ук тикшеренү характерындагы аерым хезмәтләр дә урын ала. Журналның чыгып өлгергән 10 санында барлыгы 70 фәнни мәкалә һәм 75 вак материал, рецензия һ. б. бастырыла.

Татар дөньясын өйрәнү фәнни җәмгыяте, үзенең басма органы ярдәмендә, СССР территориясендәге һәм чит илләрдәге (Берлин, Гамбург, Лондон, Рим, Харбин, Нью-Йорк һ. б. шәһәрләрдәге) 120 фәнни, укыту, гыйльми оешмалар һәм җәмгыятьләр белән даими бәйләнеш урнаштыра (10, 206–207).

Гыйльми үзәк карамагында 5 ел эшләгән, ә соңгы 2 ел эшчәнлеген Татар мәдәнияте йорты каршында үткәргән Татар дөньясын өйрәнү фәнни җәмгыяте татар халкын төрле яклап өйрәнү буенча зур эш башкара, үзенең тирәсенә танылган галимнәрне, шул исәптән татарлар арасыннан күренекле белгечләрне туплый. Татар дөньясын өйрәнү җәмгыяте генә түгел, гомумән, Гыйльми үзәк тә үз тирәсенә татар хезмәткәрләрен туплау

эшенә зур әһәмият бирә. Татарстан республикасыннан тыш, Башкортостан, Кыргызстан, Төркестан, Себер һ. б. өлкәләрдә яшәүче татар белгечләре дәреслекләр, брошюралар төзү эшенә, Казан вакытлы матбугатына актив катнаша башлыйлар (5, 212). Г. Сәгъди, Г. Алпаров, Г. Шнаси, Н. Надиев кебек күренекле галимнәр чит өлкәләрдән Казанга чакыртып алыналар һәм Гыйльми үзәктә, шулай ук Казан уку йортларында уңышлы гына эшли башлыйлар (11, 27). Истәлекләрдән күренгәнчә, Г. Ибраһимов Гыйльми үзәк эшенә төрле шәһәрләрдә яшәүче тәҗрибәле татар гыйльми көчләрен дә, рус һәм башка милләт галимнәрен дә, үсеп килгән яшь көчләрне дә җәлеп итүгә ирешә (13, 237).

Г. Ибраһимовның татар милләте, аның теле, мәдәнияте һәм киләчәге турындагы фикерләре 1927 елда язылган «Татар мәдәнияте нинди юлдан барачак?» мәкаләсендә ачык чагылыш таба. Г. Ибраһимов телне мәдәниятнең «чишмә башы һәм аның асылын билгеләүче фактор» дип саный. Шуңа бәйле рәвештә, ул бу хезмәтендә тел мәсьәләсенә кабат-кабат әйләнеп кайта. Милли мәдәниятнең үсешен тәэмин итү максатында, һәр татар баласын башлангыч мәктәптән башлап югары уку йортына кадәр ана телендә укыту кирәклегенә, татар телен, әдәбиятын, гореф-гадәтен, тарихын-тормышын яхшы белгән хезмәткәрләр таләп ителүгә басым ясый; ул вакытта ук кайбер даирәләрдә тарала башлаган урыслашу идеясенә бик кискен рәвештә каршы чыгып, әлеге фикер тарафдарларын көчле тәнкыйть утына тота (12, 207–238).

Йомгак ясап әйткәндә, XX гасырның 20–30 нчы елларында татар теленең дәүләт теле сыйфатында нигезләре салынуда Г. Ибраһимовның да роле гаять зур булган. Ул, әдәби әсәрләр язу, иҗтимагый-сәяси эшчәнлек алып барудан тыш, татар тел гыйлемен үстерү, аның терминологиясен, шрифтын һәм язуын камилләштерү кебек мәсьәләләр белән дә тирәнтен шөгыльләнгән һәм, гомумән, татар теленең язмышы һәм киләчәге өчен чын күңеленнән борчылып, урыслаштыру хәрәкәтенә каршы көрәш алып барган.

ӘДӘБИЯТ


1. НА РТ, ф. 3682, оп. 1, д. 59. Протоколы заседаний Президиума, Коллегии и подотделов Наркомпроса ТАССР и материалы к ним. Подлинники (4 января – 30 декабря 1921 г.). – 437 л.

2. НА РТ, ф. 3682, оп. 1, д. 76. Текстовые отчеты о деятельности Наркомпроса ТАССР за 1921 г. и июнь 1922 г. – 232 л.

3. НА РТ, ф. 3682, оп. 1, д. 690. Академический Центр. Протоколы заседаний Президиума отдела (25 сентября 1924 г. – 30 сентября 1926 г.). – 41 л.

4. НА РТ, ф. 3682, оп. 1, д. 5. Протоколы заседаний Коллегии Наркомпроса ТАССР и его отделов (15 октября – 7 декабря 1920 г.). – 133 л.

5. НА РТ, ф. 3682, оп. 1, д. 501. Текстовой отчет о деятельности Наркомпроса ТАССР за 1922/23 гг. – 100 л.

6. Отчет ЦИК и СНК за время с 3-го по 4-й съезд Советов. – Казань: тип. «Красн. Печатн.», 1923. – 304 с.

7. НА РТ, ф. 732, оп. 1, д. 154. Обзор деятельности ТатЦИКа и его комиссии. Докладные записки о деятельности кантисполкомов (11 января – 16 декабря 1922 г.). – 347 л.

8. НА РТ, ф. 3682, оп. 1, д. 7. Протоколы заседаний Коллегии Наркомпроса ТАССР и его отделов, положение об отделе Снабжения и список инструкторов Наркомпроса по кантонам ТАССР (24 ноября – 20 декабря 1920 г.). – 114 л.

9. Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. VIII т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. – 430 б.

10. Вестник научного общества Татароведения. – 1930. – № 9–10.

11. НА РТ, ф. 3682, оп. 1, д. 1148. Текстовые отчеты о деятельности Наркомпроса ТАССР за 1925/26 учебный год (27–30 сентября 1925 г.). – 261 л.

12. Ибраһимов Г. Г. Милләт. Тел. Әдәбият: Сайланма хезмәтләр. – Казан: Мәгариф, 2007. – 237 б.

13. Галимҗан Ибраһимов: мәкаләләр, истәлек-хатирәләр / Төз. Р. Акъегет. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 544 б.


# ӘДИПНЕҢ ПЕДАГОГИК ЭШЧӘНЛЕГЕ


***Ф. И. Шәкүрова (Казан)***



Ибрагимов Галимджан Гирфанович – классик татарской литературы, критик, общественный деятель, ученый, педагог. Его педагогическая и методическая деятельность заслуживает особого внимания. Галимджан Ибрагимов имеет большие заслуги в области татарского литературного языка. Он обогатил татарский язык, ввел много оборотов и слов из всех говоров и наречий татарского языка, способствуя созданию единого татарского литературного языка. Среди научных работ – «Татарская грамматика» (1911), «Теория литературы» (1916), «Методика преподавания родного языка» (1918).


Галимҗан Ибраһимов – классик язучы, тәнкыйтьче, публицист, җәмәгать эшлеклесе, педагог, күпкырлы галим.

Мин эшли торган Казан шәһәрендәге 52 нче гимназия – педагогик профильле гимназия. Педагогик сыйныф укучылары белән без күренекле педагогларның тормыш һәм иҗат юлларын, эшчәнлекләрен өйрәнәбез. Галимҗан Ибраһимовның мәгариф өлкәсендәге гыйльми хезмәтләре һәм нәтиҗәле практик эшчәнлеге педагогик сыйныф җитәкчеләрендә генә түгел, укучыларда да зур кызыксыну уятты.

Г. Ибраһимов тел галиме, педагог-методист буларак, тел-әдәбиятны укытуны камилләштерү буенча җитди хезмәтләр калдырган шәхес. Алар, татар теле һәм әдәбиятын укыту методикасы башлангычы булу белән беррәттән, тел белеменә һәм әдәбият теориясенә дә нигез салалар. Шуңа күрә кат-кат басылалар, озак еллар мәктәпләрдә дәреслек-кулланма булып хезмәт итәләр.

Галим мәктәптә ана теле укытуның максатын һәм бурычларын билгеләү мәсьәләсен тарихи планда куя. Мәдәни халыкларның мәктәпләрендә әһәмият бирелеп укытыла һәм кирәкле санала торган фәннәрнең иң беренчесе – милли тел һәм әдәбият, ди ул. Ул чорда милли мәсьәләдәге ике тенденция (милләтләрнең тууы, үсүе һәм милләтләрнең үзара якынаюы) империалистик юнәлеш ала, ягъни милләтләрнең якынаюы процессы аларның бер-берсен йоту, юкка чыгару сәясәте аша хәл ителергә тиеш була. Әнә шундый шартларда әдипнең: «Бер халыкның яшәргә теләве белән икенчеләренең

аны йотарга уйлавыннан туган көрәшләрнең иң төплесе – мәктәптән, мәктәптә ана теле укытып-укытмаудан башлана», – дип язуы аның иҗтимагый һәм милли мөнәсәбәтләрне тирәнтен аңлап эш итүен күрсәтә.

Галимҗан Ибраһимов, иҗади эшләүче укытучы һәм методист буларак, мәктәпне ана теле дәреслекләре белән тәэмин итү проблемасын хәл итүдә дә катнаша. Төрле әлифба һәм кулланмаларга нигезле рецензияләр яза, орфография буенча кулланмалар төзи.

Ул ана теле укыту методикасына әдәбият укыту методикасы белән органик бәйләнештә карый. 1913 елда «Мәктәп» журналында басылган «Мәктәптә әдәбият» дигән мәкаләсендә ул үзенең бу фикерен тел һәм әдәбият фәннәренең өйрәнү объектын берләштерү юлы белән дәлилли. 1916 елда язылып, беренче мәртәбә 1918 елда басылып чыккан методик хезмәтендә әдип үзенең бу карашын киңәйтә, телне тормышның барлык өлкәләрендә кулланыла торган уй йөртү коралы итеп саный.

Ана телен мәктәптә укытуның теоретик максат-бурычларыннан тыш, әдип аның практик бурычларын, ягъни тел укытуның практик нәтиҗәләрен дә ачык итеп санап күрсәтә: «Ана теле дәресләре балага:

1) уку-язу белдерә;

2) күңелендәге уйларын ачык вә яхшы рәвештә язып аңлату куәтен бирә;

3) төзек итеп сөйли алу куәтен арттыра;

4) укыганын аңларга өйрәтә;

5) китап укырга гадәтләндерә;

6) гыйлемгә, китап вә әдәбиятка дәрт вә мәхәббәт салдыра», – ди.

Г. Ибраһимов әдәби тел тарихы буенча да җуелмас эз калдыра.

Билгеле булганча, татар әдәби теле үзенең нормалары белән гомуми төрки язма әдәби телгә барып тоташа. Соңгысы берничә үсеш баскычын кичерә: гомуми борынгы төрки язма әдәби тел чоры V–X йөзләр; гомуми иске төрки язма әдәби тел чоры – XI–XV йөзләр; XV–XVI йөзләрдә инде гомуми иске төрки әдәби тел үзенең гомумилеген шактый югалта, төрле урыннарда, җирле үзенчәлекләр билгеле дәрәҗәдә өстенлек алып, аерым әдәби телләр формалаша башлый.

Бу тарихи процессны аңлатуда, милләт һәм милли тел проблемаларын хәл итүдә галим актив катнаша.

Ул, иске язма телне ташлап, яңа халыкчан милли әдәби телгә күчүне хуплап чыкса да, хәтта соңгысын төзүнең, камилләштерүнең юлларын эзләүдә турыдан-туры катнашса да, искесен бөтенләй оныту ягында тормый, аны гыйльми өйрәнергә кирәклекне һәрьяклап дәлилли. Иске әдәби телне һәм анда язылганнарны өйрәнү тарих өчен бик кирәк, дип таныса да, әдип аны куллanудан туктауның тарихи бер мәҗбүрият булуын исбатлап күрсәтә. Яңа милли телнең формалашу процессын тизләтү өстендә армый-талмый эш алып бара.

Г. Ибраһимовны атаклы тел галиме итеп таныткан тагын бер юнәлеш – аның татар теле төзелешен тикшерү буенча эшчәнлеге – сарыф (морфология), нәхү (синтаксис) **һәм** билгеле дәрәҗәдә стилистика өлкәсендәге эшчәнлеге.

Г. Ибраһимов телче-галим буларак, турыдан-туры әдәби телнең фонетик, орфографик, лексик, грамматик нормаларын чагылдырган, тел белемено караган хезмәтләр яза, шул рәвешчә татар тел гыйлеменә үзеннән зур өлеш кертә. Икенчедән, Г. Ибраһимов, телнең эчке мөмкинлекләреннән, халыкның җанлы сөйләменнән киң файдаланып, әдәби тел нормаларын халыкка җиткерү өлкәсендә зур эш алып бара.

Тел мәсьәләләренә ул 1910–1911 елларда игътибар итә башлый. 1911 елда «Шура» журналында басылып чыккан «Без – татармыз» дигән мәкаләсендә болай язды: «Эшләремезне татар эше дип атыймыз; үземез – татар, телемез – татар теле; әдәбиятымыз – татар әдәбияты; эшләгән һәммә эшемез – татар эшләре; туачак мәдәниятемез татар мәдәнияте булачак».

1911 елда аның бер-бер артлы «Татар имлясы», «Татар сарыфы», «Татар нәхүе» дигән китаплары дөнья күрә. «Йолдыз» газетасында 1910 елда басылган «Татар теле һәм татарча язу хакында бер-ике сүз» исемле мәкаләсендә һәм «Татар имлясы» дигән дәреслек-кулланмасында ул яшәп килгән татар язуына кайбер үзгәртүләр кертергә кирәклекне күтәреп чыга.

Күренекле шәхеснең хезмәтләрендә татар теленең фонетик закончалыкларына нык игътибар ителә. Ул бу өлкәдә элегрәк чыккан хезмәтләрне өйрәнә, фонетикага тел белеменең махсус тармагы итеп карый һәм андагы кануннарны дөрес чагылдырырга тырыша, аваз һәм хәреф арасындагы мөнәсәбәтне ачыклап, сузык авазлар системасы, тартык авазлар, иҗек һәм телдәге сингармонизм мәсьәләләренә шактый урын бирә, авазларның кулланылу үзенчәлекләрен тикшерә.

Г. Ибраһимов татар сөйләменең үзенчәлекләрен, аның синтаксик төзелешен, җөмлә, җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен, җөмлә төрләрен өйрәнү өлкәсендә дә зур эш башкара. Кушма җөмлә төрләрен һәм алардагы бәйләнеш юлларын ачыклап бирә. Үзенең «Татар нәхүе»ндә татар телендәге иярчен җөмләләрнең эчтәлеген аңлатып, ул үз карашын ышандырырлык дәлилләр белән раслый, иярчен җөмләләрнең табигатен шактый тулы ача. Аларның бүленешен беренче башлап Г. Ибраһимов хезмәтләре белән бәйләп карарга кирәк. Вакыт, сәбәп, тәмамлык, аергыч, рәвеш, шарт, кире җөмләләргә караган материаллар шуны күрсәтә. Синтаксиста тезем төшенчәсенә аңлатма да Г. Ибраһимовтан башлана.

Галимнең стилистикага багышланган «Әдәбият кануннары» дигән китабында (1918) күп мәсьәләләр лексик категорияләр һәм матур әдәбият әсәрләре телендәге сурәтләү алымнары белән тыгыз бәйләнештә карала. Мәсәлән: сыйфатлау (хәзерге телдә *эпитет* дип тә әйтәбез), охшату (чагыштыру), истигарә (метафора), киная (читләтеп әйтү), миҗаз (метонимия), хитап (риторик өндәү), тәкрар (кабатлау), җанландыру (сынландыру), капма-каршы мәгънәле сүзләрне яки фразаларны янәшә китерү (антоним, антитеза) һ. б.

Г. Ибраһимовны татар әдәби теленең үсеш мәсьәләләре дә кызыксындыра. Аның татар халкының бөек мәгърифәтчесе Каюм Насыйри хезмәтләренә игътибар итүе дә юкка гына түгел. Ул тел белеменә караган хезмәтләрендә К. Насыйри традицияләрен дәвам иттерә һәм олы мәгърифәтченең эшчәнлегенә югары бәя бирә. Г. Ибраһимовның «Башлангыч», «Каюм бабаның йөз еллыгы», «Яңа татар әдәби теленең беренче баскычларында» һ. б. хезмәтләре шуны ачык күрсәтә. Ул хәзерге татар халкының тарихын борынгы болгарлар һәм аларның теле белән якын мөнәсәбәттә өйрәнгәндә дә К. Насыйри фикерләренә таяна.

Яшь буынның язмышы, аны тәрбияләү, укыту мәсьәләләре һәрвакыт Г. Ибраһимовның игътибар үзәгендә булды.

Галим педагогика мәсьәләләре белән, беренче чиратта, халык язмышын хәл итүдә зур роль уйный торган фактор буларак кызыксынды

Г. Ибраһимов бу чорда тәрбиянең һәм укытуның максатын, бурычларын ачыклауга яңа позицияләрдән чыгып якын килә: «Мәктәпнең баш максаты укучыларны шәхси вә иҗтимагый хәятка хәзерләмәк һәм аларга тормыш көрәшендә егылып тапталмас өчен зарур булган куәтне бирмәктер», – ди ул «Мәктәптә әдәбият» исемле мәкаләсендә. Күренә ки, әдип укыту һәм тәрбия процессының социаль шартлар белән турыдан-туры бәйле булуын күз алдына китерә. Шуңа күрә дә педагогик фикер үсешен җәмгыятьтәге төрле иҗтимагый үзгәрешләр белән бәйләнештә карый. Ул шулай ук тәрбия һәм укытуның да, шәхеснең табигый сәләтеннән тыш, тагын күп кенә иҗтимагый-икътисадый сәбәпләр белән дә бәйле булуына игътибар итә. Бу чорда инде әдип капиталистик җәмгыятьтә табигый сәләт һәм талантны үстерергә бернинди мөмкинлекләр дә юклыгын ачык аңлый.

Г. Ибраһимов фикеренчә, тәрбиядә иң мөһим шартларның берсе – гармониялелек. Ә аның төп компонентларына тукталып: «Тән саулыгы, гакыл сәләте, хыял белән гакылның вә башка куәтләрнең мотавази рәвештә тәкәммеллеге, эш сөяргә өйрәнү…» ди («Тәрбиядә хөррият һәм шәхсият нигезләре»).

Галимнең педагогик темага язылган хезмәтләрендә укыту һәм тәрбия эшенең төп юнәлеше аңлы фикер йөртү һәм мөстәкыйльлекне үстерү булырга тиешлегенә дә басым ясала. Ә моны тормышка ашыру өчен мәдрәсәләрдә, иң беренче чиратта, шәкертләрнең кешелек дәрәҗәсен кимсетә торган чараларны бетерергә кирәк була. XX гасыр башында татар мәдрәсәләре өчен бу мәсьәлә гаять мөһим санала. Дөрес, ул вакытта инде мәктәп-мәдрәсәләр тормышына кайбер үзгәрешләр кертелә. Әйтик, «хәлфәнең кулындагы тал чыбыгын тартып алды, бер яктан сугып, икенче яктан ут чыгару хокукын да инкарь кылды: шуның аркасында тән җәзалары куәтеннән төшерелде. Ләкин болар белән генә чын тәрбиягә кердек дияргә ерак әле», ди әдип. Чөнки әле бу чорда, аның сүзләре белән әйткәндә, «олуглар алдында баш ию, үзеңне түбәнсетү, ягъни бер шәхес үзенең кыйммәтен икенчеләр аягы астына салу, ирекле кол булу» кебек күренешләр тәрбиянең асылын билгели. Шуңа күрә Г. Ибраһимов «тәрбиябез киләчәк нәселне аталар коллыгыннан, бабалар тәзәллегеннән, тарихи шәхсиятсезлектән коткарсын», дип өндәде.

Г. Ибраһимовның педагогик фикерләре биредә китерелгәннәр белән генә чикләнми. Шунысы әһәмиятле: галим тәрбиянең асылын гражданин, халык бәхете өчен көрәшүче актив шәхес тәрбияләүдә күрә.

Казакъ далаларында мөгаллим булып балалар укытып йөрү, Киевта мөселман студентларына дәресләр бирү, алдынгы уку йортларыннан берсе булган «Галия» мәдрәсәсендә мөгаллимлек итү, әлбәттә, Галимҗан Ибраһимовка бай педагогик тәҗрибә тупларга мөмкинлек биргән. Шуның нәтиҗәсе буларак, тәрбия һәм укыту мәсьәләләренә багышланган хезмәтләреннән галимнең мәгариф өлкәсендәге проблемаларны бөтен тирәнлеге белән аңлавы күренә.

ӘДӘБИЯТ

Ибраһимов Г. Г. Сайланма әсәрләр. – 1 т. – Казан: Таткнигоиздат, 1957.

Ибраһимов Г. Г. Әдәбият кануннары. – Казан, 1918.

Нуруллин И. З. Татар әдәбияты. Урта мәктәпнең 10 нчы классы өчен дәреслек. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – Б. 136–170.

Татар әдәбияты тарихы. III том. XX гасыр башы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – Б. 338–357.

Хәсәнов М. Х. Әдәбият (XX йөз башы һәм 20 нче еллар татар әдәбияты). – Казан: Мәгариф, 1994. – Б. 273–304.

# МӘКТӘПТӘ ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ИҖАТЫН ӨЙРӘНҮ

***Ә. Н. Нәҗипова-Зиннәтуллина (Казан)***

В этой статье отражаются методы и способы изучения биографии и некоторые произведении Г. Ибрагимова в десятом классе татарских школ по программе А. Ахмадуллина. Рассказывая о жизни Г. Ибрагимова, следует отметить такие качества писателя, как трудолюбие, талант, связь со своим временем, с народом, приобщение к революционным событиям, любовь к татарскому языку и литературе и духовным ценностям своего народа. На уроках жизнь и творчество Г. Ибрагимова освещается в связи с его творческим, педагогическим, научным путем, движением к художественной зрелости, вкладом в родную литературу, науку и образование. В каждом последующем уроке сведения углубляются и расширяются. Рекомендуются примерные цели, задачи, планы и ход уроков.

X сыйныфның әдәбият программасында (2010 елгы яңа басма, төзүчесе – А. Әхмәдуллин) Галимҗан Ибраһимов иҗатын өйрәнүгә 6 сәгать вакыт каралган. Бу вакыт эчендә укучыларга әдипнең иҗат үзенчәлеге, иҗатының татар әдәбияты тарихында тоткан урыны, язучының шәхси сыйфатлары турында тирән мәгълүмат бирү күздә тотыла.

Билгеле булганча, язучы, кеше буларак, теге яки бу тарихи, иҗтимагый, сәяси вакыйгалар тәэсирендә формалаша, һәм бу вакыйгалар аның иҗатына да юнәлеш бирәләр. Шуңа күрә дә аның тормыш юлын тарихи чорга, үзе яшәгән тирәлеккә бәйләп бирү мөһим. Әлбәттә, программа таләпләре нигезендә күренекле әдип иҗатын өйрәнү максатыннан дәреслектә (авторлары – М. Х. Хәсәнов, А. Г. Әхмәдуллин, Ф. Г. Галимуллин, И. З. Нуруллин) шактый күп һәм бай материал бирелгән. Ләкин программа нигезендә каралган вакыт эчендә дәреслектә тәкъдим ителгәннәрнең барысын да тирәнтен өйрәнү мөмкин түгел, язучының иҗатын тулаем күз алдына китерү өчен, аларны төшереп калдырып та булмый. Укытучы алдына, программада тәкъдим ителгән бөтен әсәрләрне дә тирәнтен өйрәнү өчен, дәресне һәм темага бәйле мөстәкыйль эшләрне методик яктан дөрес, уйлап оештыру бурычы килеп баса.

Әдипнең биографиясен, башлангыч чорда иҗат ителгән әсәрләрен күзәтү характерында өйрәнү тәкъдим ителә. Монда, әлбәттә, укучының яшь һәм белем үзенчәлеген истә тотып, күбрәк аларның үзләрен мөстәкыйль эшләтергә туры килә. (Мондый мөстәкыйль эш төрләренә өйдә әсәрләрне үзлегеңнән уку, алдан бирелгән сорауларга җаваплар әзерләү, язма эшләр – докладлар, рефератлар язу һ. б. керә.)

Әдипнең иҗатын монографик планда өйрәнү буенча методик системаның түбәндәге аспектларына тукталу мөһим:

– Галимҗан Ибраһимов шәхесе һәм иҗаты белән киң планда танышу, тарихи чорга, иҗтимагый фикергә бәйле рәвештә әдипнең карашлары үсешен күзәтү;

– дәреслектәге әсәрләренең язылу тарихы, әсәрләре белән беренчел танышу;

– әдәби текстка тулы анализ ясау;

– әсәрләрен гомумкешелек кыйммәтләре белән бәйлелектә тикшерү, бәйләү ярдәмендә әдип иҗатының әдәбият дөньясында тоткан урынын билгеләү.

Бу төр дәреснең һәр этабында язучы иҗатын өйрәнү буенча төп максат – бурычларны тормышка ашыру өчен укытучы тиешле методик алымнарны сайлап ала белергә, язучы иҗатына кагылышлы материаллар белән киң күләмдә таныш булырга тиеш. Әдәбият укытучысына бу тема буенча дәрескә әзерләнгәндә дәреслектәге материаллар белән генә канәгатьләнеп калмыйча, өстәмә фәнни әдәбиятны да өйрәнү һәм аны дәрестә уңышлы файдалана белү зарур. Г.Ибраһимов эшчәнлеге буенча соңгы елларда алып барылган күп төрле фәнни эзләнүләр, тикшеренүләр, басылып чыккан хезмәтләр бу эшкә мөмкинлек тудыра. Заманыбыз мәктәпләренә куелган бүгенге таләпләр, укытыла торган дәреслектәге материалларга гына таянып, әдипнең иҗатын монографик планда өйрәнү мөмкин түгеллеген уйларга нигез тудыра.

Дәрес барышында Г. Ибраһимовның тормышына, иҗатына бәйле тәнкыйди һәм фәнни-методик хезмәтләрнең исемлеге бирелә, әдәбият дәресләрендә өйрәнелә торган әсәрләрнең исемлеге тәкъдим ителә. Өйрәнелә торган теманың, материалның шактый катлаулы, күләмле булуын истә тотып дәресләрнең бүленеш схемасы белән дә танышырга мөмкин.

1 нче дәрес. Г. Ибраһимовның тормыш юлы, педагогик, методик эшчәнлеге. 1917 елга кадәр әдәби иҗаты.

2 нче дәрес. Г.Ибраһимовның әдәби-публицистик эшчәнлеге. Әдипнең совет чорындагы иҗтимагый эшчәнлеге

3 нче дәрес. Язучының совет чорындагы әдәби иҗаты.

4, 5 нче дәресләр. «Казакъ кызы» романына анализ.

6 нчы дәрес. Язма контроль эш.

Беренче дәрестә түбәндәге максатлар куела:

– Г. Ибраһимовның тормыш юлы, шәхесе белән таныштыру. XX йөз башы татар мәгърифәте тарихындагы үзгәрешләр нәтиҗәсендә әдипнең дөньяга карашын билгеләү;

– зур язучы, күренекле педагог, методист, журналист, сәясәтче, милләтпәрвәр, җәмәгать эшлеклесе булып китүенең төп факторларын билгеләү;

– Г. Ибраһимовның күп төрле эшчәнлеген, мирасын өйрәнү, аның татар дөньясында тоткан урынын ачыклау.

Өйрәнелә торган материалның эчтәлегеннән чыгып, дәресне укытучының лекциясе нигезендә оештыру уңышлы. Укучыларның чыгышларын тыңлау, истәлекләр, тәнкыйди әдәбият белән таныштыру кебек алымнар куллану да әһәмиятле. Мондый материаллар язучы яшәгән һәм иҗат иткән дәверне, әдипнең рухи дөньясын, карашларын һ. б.ны күзалларга ярдәм итә.

Укытучы лекциясен түбәндәге план нигезендә оештыра ала:

1. XX йөз татар тарихы, мәдәнияте, әдәбияты, милли мәгариф эшенең торышы.

2. Г. Ибраһимовның биографиясе, аның мәгариф, әдәбият, сәясәт, мәдәният өлкәсендә мәшһүр шәхес булып китүенә китергән төп факторлар.

3. Г. Ибраһимов – педагог-методист.

4. Г. Ибраһимов – журналист.

5. Г. Ибраһимовның башлангыч чор иҗаты, аның үзенчәлекләре.

Үткән дәресләрдә тарих һәм әдәбият фәненнән алган белемнәргә нигезләнеп, XX гасырның үзенчәлеге, сәяси вакыйгалар, аның татар халкына тәэсире, матбугат, театр, уку-укыту өлкәсендәге үсеш-үзгәрешләр турында укучыларга сораулар биреп, укытучы лекциясен башлап җибәрә.

Г.Ибраһимов әдәбият мәйданына милли әдәбиятның ныклап үсеп килүе чорында, тәнкыйди реализмның, прогрессив романтизмның һәм төрле әдәби жанрларның формалашуы чорында килеп керде.

Укытучы Г. Ибраһимовның әти-әнисе, балалык еллары, төрле уку йортларында укуы турында мәгълүмат бирә, мәшһүр шәхес булып китүенә этәргән төп факторларны билгели:

а) белемле, эшчән, акыллы гаиләдә тәрбияләнгән Галимҗанның сабый чакта ук күңелендә табигатькә, туган җиргә мәхәббәт уянуы;

б) татар мәктәп-мәдрәсәләрендәге уку-укытуның торышы, куелган тәртипләрнең табигый талантка ия булган, эзләнүчән табигатьле яшь Галимҗанга тәэсире. Төрле дәрәҗәдәге белем баскычларын үткән Г. Ибраһимовның педагогик һәм методик сыйфатлары ачылу;

в) 1917 елгы инкыйлаб нәтиҗәсендә башланып киткән милли азатлык хәрәкәтенең Г. Ибраһимовның җәмәгать эшлеклесе, сәясәтче, язучы булып китүенә тәэсире.

X сыйныф дәреслегендә Г. Ибраһимовның биографиясе, аның сәяси һәм әдәби эшчәнлеге эзлекле бирелеп, шактый тулы яктыртылган. Укытучы дәреслек материалларына таянып укучыларга белешмә бирә.

Әдипнең катлаулы тормыш юлын төгәлрәк күз алдына китерү өчен, укытучы презентацияле видеоматериал әзерли, йә булмаса, төзелгән синхрон таблицаны күрсәтмә материал буларак куллана ала.

Укытучы, укучыларның тарихтан, әдәбияттан алган белемнәренә таянып, Мулланур Вахитов, Мирсәет Солтангалиев, Йосыф Акчура, Гаяз Исхакый, Садри Максудиларның эшчәнлегенә һәм язмышларына кыскача тукталып китә. Татар халкының шушы күренекле уллары арасында Г. Ибраһимовка да урын бирелә.

1917 елгы инкыйлабка кадәр Г. Ибраһимов үзен таланты педагог, методист һәм журналист итеп таныта. Аның «Татар имлясы», «Яңа әдәбият» (1914), «Әдәбият дәресләре» (1916), «Әдәбият кануннары»(1918), «Татар телен ничек укытырга?» китаплары басылып чыга һәм бу хезмәтләр шәкертләрне дәрес материалын аңлап, фикер, иҗат көченә таянып эш итәргә өйрәтәләр.

Укытучы Г. Ибраһимовның сәяси-милли эшчәнлегенә тукталып киткәннән соң, аның башлангыч чор иҗаты турында мәгълүмат бирә. 1907–1912 елларда язган «Яз башы», «Диңгездә», «Сөю – сәгадәт», «Уты сүнгән җәһәннәм», «Татар хатыны ниләр күрми?» һ. б. хикәяләрендә искелеккә каршы көрәшүче, социаль-сәяси тәртипләрне үзгәртеп корырга теләүче романтик геройлар бирелүен ассызыклап китә. Укытучы бер хикәягә киңрәк тукталып, аннан өзекләр китереп, геройларның реаль тормышка романтик хыял аша карауларын, көрәшү юлларын реаль тормыштан эзләмәүләрен аңлатырга тиеш.

Иҗатның икенче этабына тукталып (1912–1917), укытучы, язучы әсәрләрендә («Карт ялчы», «Көтүчеләр» һ. б.) гаделлекне табу юлларын эзләвен, социаль тигезсезлек, реаль тормыш күренешләре чагылдырылуын билгели.

Алдагы дәрестә Г. Ибраһимовның XX йөз башы татар әдәби тәнкыйте һәм публицистикасы үсешенә зур өлеш кертүе һәм әдип хезмәтләренең 1917 ел инкыйлабына кадәрге татар тәнкыйте һәм эстетик фикер үсешендә югары роль уйнавы дәреслектәге материалга таянып ачыклана. Әдипнең совет чорындагы иҗтимагый эшчәнлеген аңлатканда укытучы түбәндәге планнан файдалана ала:

1. Уфадагы «Милләт мәҗлесе» утырышлары һәм Г. Ибраһимов эшчәнлеге.
2. Петроград, Мәскәүдәге сәяси тормыш һәм Г. Ибраһимов.
3. Г. Ибраһимовның татар газетасы чыгару буенча эшчәнлеге.
4. Г. Ибраһимовның 1919 елдагы сәяси эшчәнлеге.
5. Г. Ибраһимовның милли мәгариф эшен оештырудагы роле.
6. Г. Ибраһимов – зур галим, фәнни-тикшеренү эшен оештыручы.
7. Г. Ибраһимов – Сталин режимы корбаны.

Бу план нигезендә укучылардан рефератлар яздырырга да мөмкин. Г. Ибраһимовның иҗтимагый эшчәнлеген ачыклагач, укытучы әдипнең совет чорында язылган «Кызыл чәчәкләр» хикәясенә тукталып китә. Хикәя – уку өчен кызыклы, мавыктыргыч. Шуңа, хикәяне өйдә укып чыгу өчен алдан биреп җибәрергә кирәк. 1917 ел инкыйлабы, гражданнар сугышының Агыйдел буенда туып-үскән биш татар егетенә нинди фаҗига алып килүен укучылар аңлап калырга тиешләр.

Дәреслардән күренгәнчә, биографик дәрес лекция калыбына гына сыеп бетми. Моннан тыш укытучы сөйләгәндә укучылардан план төзетү, төп фикерләрне дәфтәрләргә яздыру да уңай нәтиҗә бирә. Әгәр сыйныф яхшы әзерлекле икән, бу дәресне семинар-дәрес формасында да оештырырга мөмкин. Мондый очракта инде укытучы алдан ук балаларга мөстәкыйль эшләр (конспект язу, алдан бирелгән сорауларга җавап табу, хронологик таблица төзү һ. б.) башкарырга кушып җибәрә.

Гомумән алганда, бу дәрестә укучылар язучы белән тирәнтен танышырга, алдагы дәресләрдә өйрәнеләсе әдәби әсәрне тикшерүгә әзерләнергә тиешләр.

Өй эше итеп, әдипнең «Казакъ кызы» романын искә төшереп килергә (әсәр инде укылган булырга тиеш) бирелә. Роман буенча язма эш (теге яки бу вакыйгага, йә геройларга бәяләмә, йә булмаса, аерым сорауларга җавап) язып килергә кушыла.

Әсәрне анализлау проблемаларны ачыклауга карап башкарыла. Ике сызыкка: мәхәббәт сызыгына (Карлыгач, Арысланбай, Калтай образларына) һәм сәясәт сызыгына (Байтүрә, Биремҗан, Сарсымбай, Азым әкә) бәйләп, сораулар кую ярдәмендә романдагы проблемалар ачыклана.

Монографик тема, гадәттә, инша язу белән тәмамлана. Укытучы темаларны алдан берничә вариантта тәкъдим итә. Укучылар белән берлектә план төзи.

Программада, әдипнең иҗатын монографик планда өйрәнүгә керешкәнче, аның тагын бер әсәрен – «Яшь йөрәкләр» романын күзәтү характерында дәрестә өйрәнү каралган.

Беренче дәрестә романның эчтәлеге, сюжет-композициясе игътибарга алына. Түбәндәге мәсьәләләр ачыклана: 1. Әсәрдә нинди иҗат методлары өстенлек итә? (Җавап: романтизм. Реалистик сурәтләү алымнары белән.) 2. «Яшь йөрәкләр» нинди жанрга карый һәм ни өчен? (Җавап: әсәр жанры буенча психологик роман, чөнки геройлар тирән, психологик кичерешләр аша сурәтләнгәннәр.)

Алдагы дәресләрдә мисаллар ярдәмендә җаваплар тулыландырыла.

Икенче дәрестә характерлар бирелеше тикшерелә. Сәнгатьлелек чарасы булган портретның характер бирүдә роле ачыклана Әсәрдән портретлар эзләп табарга кушыла. Аларны чагыштыру, бер-берсенә каршы кую аша укучылар төрле нәтиҗәләр ясыйлар. Мәсәлән: Җәләш, Сабир, Зыя һәм Мәрьям характерларына хас сыйфатларны тикшерү. Укытучы балалар игътибарын портреттагы әһәмиятле роль уйнаган кайсы да булса бер детальгә (бу очракта күз карашларына) юнәлтергә мөмкин.

Бер гаиләдә үсеп, бер төрле тәрбия алган Зыя һәм Сабир портретларын сурәтләгән өзекне укытып (йә дәфтәргә яздырып, таблица төзетеп), әсәрнең идеясен ачуда аның ролен билгеләтү әһәмиятле. Зыя һәм Сабир образларына бәйләп нәтиҗә ясала: бер гаиләдә үссәләр дә, тышкы кыяфәтләре, холык-фигыльләре буенча ике төрле сурәтләнгән егетләр киләчәккә баруның ике төрле юлын күрсәтәләр.

Геройларның характерын күрсәтүдә төш күрүнең роле билгеләнә. Әсәрдән өзекләр укытып, бу төшнең геройлар язмышында, киләчәкнең нинди булуын күрсәтүдә роле ачыклана. Мәсәлән, әсәр Мәрьямнең төш күрүе белән башланып китә. Укучылар, әсәрне анализлау барышында, бу төшләрнең вакыйгаларга нинди бәйләнеше барлыгын ачыклый баралар.

Жанры буенча психологик романга караган «Яшь йөрәкләр» романын тикшергәндә психологизмның бу әсәрдә ни дәрәҗәдә һәм ничек чагылуына аерым бер дәресне багышлау урынлы. Психологизм төшенчәсен теоретик нигезләгәннән соң, текст белән тирәнтен эшләүгә күчелә. Укытучы төп игътибарны авторның хикәя кылуы, күңел монологы, лирик пейзажы, психологик портреты, төш күрү кебек психологик анализ чараларына игътибарны юнәлткәндә, сораулар биреп, таблицалар төзетеп, өзекләр укытып, текст өстендә тирәнтен эшләгәндә генә куелган максат-бурычларын тормышка ашыра ала.

Җыеп кына әйткәндә, 10 нчы сыйныфта Г. Ибраһимов иҗатын җентекләп өйрәнү барышында, укучылар күренекле әдипнең зур талант иясе, милли әдәбиятның нигезен салучыларның берсе икәнлеген, милли

прозаның идея тематикасын киңәйткән, лиризм, романтик рух, реалистик сурәтләү чаралары белән баеткан киң колачлы язучы, татар мәгарифен үстерүдә үзеннән лаеклы өлеш керткән талантлы педагог, галим булуын, татар халкының социаль, милли үсеше өчен көрәшкән шәхес икәнлеген аңлап калырга тиешләр.

ӘДӘБИЯТ

1. Әдәбият теориясенә кереш. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. – Б. 190–195.

2. Әдәбият (XX йөз башы һәм 20 нче еллар татар әдәбияты): Унберьеллык урта мәктәпнең 10 сыйныфы өчен дәреслек / М. Х. Хәсәнов, А. Г. Әхмәдуллин, Ф. Г. Галимуллин, И. З. Нуруллин. – Казан: Мәгариф, 1994. – 273–305 б.

3. Закирҗанов Ә. М. Мәктәптә татар әдәбиятын укыту мәсьәләләре (әдәбият укытучылары өчен методик кулланма). – Казан: 1997. – 5–30 б.

4. Татар әдәбияты: Теория. Тарих / Д. Ф. Заһидуллина, Ә. М. Закирҗанов, Т. Ш. Гыйләҗев. – Казан: Мәгариф, 2004. – 175–179 б.

5. Заһидуллина Д. Ф. Мәктәптә татар әдәбиятын укыту методикасы. – Казан: Мәгариф, 2004. – 277–294 б.

# Г. ИБРАГИМОВ И НОВЫЙ ЛИТЕРАТУРНЫЙ ЯЗЫК

***Б. К. Миннуллин (Казань)***

Начало XX века является одновременно сложным и наиболее плодотворным этапом в формировании взглядов национального самосознания народов России. Именно после революции 1905–1907 годов в России появляется татарская периодика, поднимается языковой вопрос. Немалую роль в развитии и становлении татарского литературного языка, которого мы придерживаемся на сегодняшний день, сыграла социальная и научная активность К. Насыри, Ш. Марджани, а позже – Г. Тукая, Ф. Амирхана и других представителей татарской национальной интеллигенции рубежа XIX–XX вв. Особенно следует выделить труды, записки и высказывания известного писателя, языковеда, общественного деятеля Галимджана Ибрагимова, посвященные реформированию и развитию татарского языка.

Как известно, еще к середине XIX в. классический старотатарский письменный литературный язык включал в себя языковые элементы арабского, персидского, чагатайского, османско-турецкого и татарского языков. Поэтому литература, написанная на старотатарском литературном языке того времени, не была доступна всем слоям татарского общества. Понятный всем слоям общества разговорный вариант татарского языка негласно становился языком простонародья, который нельзя было использовать ни в литературе, ни в науке. Более или менее грамотный человек старался писать и читать на арабском языке. В этих условиях катастрофически мало времени и внимания уделялось научному изучению и разработке татарского языка.

Время требовало реформирования и научной разработки татарского литературного языка. На этапе перехода от средневековья к новому времени с такими проблемами сталкивались многие народы. К примеру, у народов Западной Европы этот переход был связан с преодолением господства латинского языка, у русских – с переходом от церковнославянского языка к живой русской речи. Причем этот переход сопровождался лексической, стилистической и грамматической обработкой русского литературного языка (1, 219). Во второй половине XIX в., отмеченной расширением капиталистических отношений, а следовательно, и социально-экономическими изменениями, вопрос о реформировании языка ставится ребром и перед татарами. Преобладающее большинство национальной интеллигенции решительно настаивало на пригодности татарского языка к использованию на самых высоких уровнях – в науке и литературе. По их мнению, по грамматическому и лексическому строю татарский язык не уступает другим языкам, но в то же время имели место и опасения за него: татарский язык не отвечал запросам времени и требовал совершенствования.

На необходимости реформирования татарского литературного языка настаивал и Г. Ибрагимов. Как известно, работу по реформированию татарского литературного языка рассматриваемого периода он пытался вести в комплексном плане, охватывая историю языка, графо-фонетику, морфологию, лексику и стилистику. Однако для достижения положительных результатов в реформе языка нужно было определиться, что брать за основу, и обозначить векторы его развития.

На рубеже XIX–XX вв. существовало как минимум три наиболее точно определенных варианта татарского языка: литературный язык (продолжение классического письменного старотатарского литературного языка, изобилующего арабской, персидской лексикой и соответствующими грамматическими формами), джадидо-османский вариант (близкий к языку газеты «Тарджеман») и вариант языка, обогащенный словами и формами татарского разговорного языка (2, 12). В национальной общественно-политической реальности это привело к условному расколу тюрко-татарского населения России на туркистов, тюркистов и татаристов. Под влиянием могущества единственного на тот момент независимого тюрко-мусульманского государства – Османской империи некоторые из татар, отказавшись от своего этнонима, прибегают к использованию этнонима «турок».

Именно противостоянию понятий «татарин – турок» Г. Ибрагимов посвятил ряд своих статей, опубликованных в 1911–1912 годах в журнале «Шура». В частности, в статье «Без – татармыз» («Мы – татары») Г. Ибрагимов удивляется, что будучи татарами, мы стремимся к самоназванию «турок», в отличие от русских, которые, несмотря на то, что являются славянским народом, отчего-то не отказываются от своего этнонима в пользу самоназвания «славянин». По мнению Г. Ибрагимова, решение поменять свое самоназвание на тот или иной вариант в глобальном мировом плане не даст никакого результата, нас все равно будут называть татарами, как это было в прошлом и будет в будущем,

потому что мы – татары. А в причинах выбора в качестве этнонима именно данного конкретного термина должна разбираться только историческая наука (3, 11–14).

Особо следует отметить работу Г. Ибрагимова по усовершенствованию письма татарского языка. Как известно, в начале XX века поднимается вопрос о реформировании письма и вырисовываются два пути развития: доработка имеющегося алфавита на основе арабской графики и переход на латиницу. Г. Ибрагимов, будучи ярым сторонником доработки имеющегося письма, объясняет свою позицию следующим образом. По его мнению, неподготовленный переход на латинскую графику мог привести к потере народом всего своего культурно-исторического, духовного и литературного богатства, накопленного столетиями и оформленного при помощи арабской графики. Свои мысли по поводу реформирования письма Г. Ибрагимов излагает в серии статей, из которых наиболее яркой является «Революцияме, реформамы?» («Революция или реформа?»), опубликованная в газете «Кызыл Татарстан» («Красный Татарстан») (4). В 1928 году, когда Татарстан уже год как использует в качестве письма алфавит на основе латинской графики, в редакцию газеты «Кызыл Татарстан» поступает письмо-обращение Г. Ибрагимова, в котором автор признает ошибочность своих взглядов по поводу латиницы и призывает к дальнейшим конструктивным практическим действиям. Однако, справедливости ради, следует отметить, что в технологическом и идеологическом плане Г. Ибрагимов никогда не был противником перехода на латиницу, он всего лишь опасался болезненного для всего народа процесса и отрицательного конечного результата.

Огромное внимание Г. Ибрагимов в своих трудах уделял также вопросам лексического развития «нового литературного языка», сформировавшегося на основе народной речи в конце XIX – начале XX в. Как мы подчеркивали выше, старотатарский письменный язык был весьма неоднородным, включал в себя много заимствований из арабского, персидского, османско-турецкого и других языков. По данному вопросу у филологов были различные мнения. Характеризуя старописьменный литературный язык, Г. Ибрагимов говорил следующее: «Под влиянием джагатайской и османской литературы выросла и существовала древняя татарская литература, которая заимствовала не только содержание, но и жанры, стиль и термины. В результате у нас образовался такой пестрый тюркский язык, который был наполовину чагатайским и османским» (5, 16). Он выделял несколько условий, присутствие которых в процессе реформирования языка считал обязательным:

– основной материал для строительства языка должен браться из нашего родного татарского языка. Ситуация, когда, несмотря на наличие словарных запасов в родном языке, используются заимствования, недопустима;

– в тех случаях, когда невозможно подобрать слово на татарском языке, следует, отталкиваясь от ситуации: 1) получать производные слова от основ из татарского языка (в данном случае следует обратить особое внимание на достоверность этимологии и соответствие значения); 2) использовать устаревшие слова либо заимствовать слова, понятные татарскому народу, у других тюркских народов России;

– начать активные действия по очищению языка от арабо-персидских заимствований, которые затрудняли восприятие литературных, публицистических и научных текстов всеми слоями общества. Если во времена русского феодального самодержавия арабо-персидская лексика служила оружием для сохранения религии и нации в борьбе против русификации татарского народа, то после пролетарской революции это оружие стало ненужным, лишним предметом, заставляющим делать шаг назад в развитии нации и ее культуры. Однако существует несколько пластов, составляющих исключение в данном отношении: 1) арабо-персидские слова, находящиеся в активном употреблении, несмотря на веяние времени (каләм – ручка, китап – книга, дин – религия и т. д.); 2) арабо-персидская лексика, использующаяся в литературе и воспринимающаяся как родная лексика (әсәр – произведение, әдәбият – литература, гыйлем – наука и т. д.); 3) арабо-персидская лексика, относящаяся к исламской терминологии и не имеющая аналогов татарского происхождения (хаҗ – паломничество, пәйгамбәр – пророк, иман – вера в бога и т. д.);

– международные слова не должны заменяться на аналоги из арабского или персидского языков, их следует употреблять без каких-либо изменений (интернационал, психология, техника, типография и т. д.);

– если подобрать слова, удовлетворяющие вышеуказанным условиям будет невозможно, следует, отказавшись от арабо-персидской лексики, использовать слова из русского языка, которые уже находятся в обиходе и воспринимаются легко, как будто это были бы слова из родного языка (товар, станция, шахта, совет и т. д.) (3, 93–94).

Как мы можем наблюдать, на фоне множественных и разнообразных позиций и взглядов национальной общественно-политической реальности, образовавшейся в начале XX века, в реформировании и развитии языка Г. Ибрагимов старался придерживаться максимально возможной условной золотой середины. Будучи сторонником доминирования национальной почвы при строительстве нового татарского языка, он не исключал наличия в новом языке и сложившихся столетиями иноязычных арабо-персидских, русских и западноевропейских элементов. Такая твердая и дальновидная позиция Г. Ибрагимова не могла не повлиять на дальнейшее плодотворное развитие научного, художественного и публицистического стилей нового татарского литературного языка, а в результате – и на общее богатство всего словарного состава татарского языка.

ЛИТЕРАТУРА

1. Абдуллин Я. Г. Татарская просветительская мысль / Я. Г. Абдуллин. – Казань: Таткнигоиздат, 1976. – 320 с.

2. Бәширова И. Б. Татар әдәби теле тарихы: XIX гасыр ахыры – XX йөз башы / И. Б. Бәширова. – Казан: Казан дәүләт технология университеты нәшрияты, 1999. – 528 б.

3. Ибраһимов Г. Милләт. Тел. Әдәбият. Сайланма хезмәтләр / Г. Ибраһимов. – Казан: Мәгариф, 2007. – 239 б.

4. Ибраһимов Г. Тюркология съездында тикшерелеп үтелгән мәсьәләләр: Революцияме, реформамы? / Г. Ибраһимов // Кызыл Татарстан. – 1926. – 20 март.

5. История татарского литературного языка (XIII – первая четверть XX в.). – Казань: Фикер, 2003. – 472 с.

# Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ ЯҢА ТЕРМИНОЛОГИЯ ЯСАУДАГЫ РОЛЕ

*М. К. Юматова (Яр Чаллы)*

В статье рассматриваются структурные и словообразовательные особенности новых терминов, представленных в научно-теоретических трудах Г. Ибрагимова; выявляются основные процессы развития терминологии татарского литературного языка в начале XX века.

Татар теле өчен яңа атамалар системасын, фәнни стильнең сүзлек базасын төзү – XX гасыр башында кискен торган мәсьәләләрнең берсе санала. Шул сәбәпле, күпкырлы галим буларак, Г. Ибраһимов үз чоры өчен бик әһәмиятле булган орфография һәм терминология мәсьәләләренә битараф кала алмый.

Ибраһимов яңа терминологияне барлыкка китерүдә ысуллар төрлелегә тарафдары була (3, 5). Ул кулланган терминнар гадәттә түбәндәге юллар белән ясала:

I. **Бер компоненттан гына торган** терминнарны ясау юллары.

1. Әзер сүзне терминлаштыру: боерык, ияртү, кереш сүз, мәртәбә, сан, тамыр, тыңлаучы, үзәк, урын.

2. Кушымчалау ысулы ярдәмендә яңа сүз ясау: аталма, аергыч, аерылмыш, барлык-юклык, бәйлек, искәрмә, кушылмачылык, кушымта, саналмыш, тәмамлык, тезем, теркәләгеч, теркәләнмеш, төрдәш, ымлык, эндәш, ярашу, ярдәмлек, ясалыш.

3. Алынма сүзне термин буларак куллану. Бу вакытта түбәндәге очраклар була: а) әдәби телдә актив кулланышлы булган алынмалар терминлаштырыла: исем, сыйфат, сәбәп, рәвеш; б) әзер алынма терминнар кабул ителә: баб, галәмәт, җөмлә, каед, масдар, фигыль.

II. **Күп компонентлы** калыплар буенча ясалган тезмә терминнар ясалышында түбәндәге очракларны күрсәтергә мөмкин:

1. Татар әдәби телендәге бер әзер сүз икенче әзер сүз белән тезмә термин ясый: сүз җилеме, сүз сөреше, юлдаш сүзләр, иярчен сүзләр, төп сан, чама саны.

2. Тезмә термин ыру төшенчәсен белдергән әзер сүздән һәм яңа сүздән ясала: бүлем саны, кушма сан, кушылмалы телләр.

3. Ыру төшенчәсен – әзер сүз, төр төшенчәсен алынма сүз белдерә: дәрәҗә саны; иштыйкаклы телләр, гөман саны.

4. Ыру төшенчәсен яңа ясалган сүз, төр төшенчәсен телдәге әзер сүз белдерә: аерым алмаш, тоташ алмашлар, билгеләү алмашлары, күргәзү алмашлары.

5. Тезмә термин ике яңа сүздән ясала: бергәлек тәмамлыгы, төшем тәмамлыгы, бүлем ярдәмлекләре.

6. Яңа сүз белән белдерелгән ыру төшенчәсенең төр төшенчәсен алынма сүз белдерә: зат алмашлары, сәбәп ярдәмлекләре, шарт ярдәмлекләре; сөаль алмашлары, рәвеш алмашлары.

7. Ыру төшенчәсен гарәп-фарсы алынмасы белдерә, аны татар телендә булган сүз җәенкеләндерә: иркәлек исемләре, иркәлек вә кечерәйтү исемләре, уртак исем, ялгыз исем, ялгызлык исме, алдагы хәл; нигез баб, иркәләү-кечерәйтү галәмәтләре, бөтен җөмлә, иярчен җөмлә, ким җөмлә, эстәү җөмләсе, куәтләү каедләре, чикләү каеде, булмыш фигыль, булачак фигыль, ярдәмче фигыль.

8. Ыру төшенчәсен белдергән гарәп-фарсы алынмасын яңа сүз җәенкеләндерә: күмәклек исме, ясалма исем, кушма исем (сыйфат); кайтым бабы, калым бабы, үтем бабы, барлык-юклык галәмәтләре.

9. Тезмә термин ике алынма сүздән ясала: вакыт җөмлә, исем масдар, асыл фигыль, хәбәр фигыльләре, хәзер фигыль, хәл фигыльләре; әүвәлге хәл; нисбәт галәмәтләре, фигыль масдар. Мондый терминнарның бер өлеше гарәп грамматикасында кулланылган вариантны татар теле кагыйдәләре буенча грамматик яктан оештыру юлы белән ясалган. Мәсәлән, мәгънәи мөстәләх – истилях мәгънәсе (2, 29).

Г. Ибраһимов хезмәтләрендә файдаланылган лингвистик терминнар төрле ысуллар ярдәмендә ясалган һәм төрле килеш калыплары буенча төзелгән.

I. **Тамыр терминнар**. Бу төр терминнар семантик ысул белән ясалган – әзер сүзгә яңа (терминологик) мәгънә йөкләнгән. Г. Ибраһимов фәнни атама итеп файдалану өчен төрле сүзләрне ала. Галим тарафыннан терминлаштырылган лексик берәмлекләр арасында түбәндәге төркемчәләрне күрсәтергә мөмкин:

1. Татар теленең үз сүзләре: аваз, иҗек, калып, сан, сүз, тамыр, төр, урын. Бу терминнар хәзерге вакытта да татар тел белемендә кулланыла. Аларның кайберләре беркадәр грамматик үзгәреш кичергән: алмаш – алмашлык, эндәш – эндәш сүз, урын – урын хәле. Сүзнең тамыры мәгънәсендә йөргән үзәк термины исә искергән һәм кулланылыштан төшеп калган.

2. Алынма сүзләр: а) хәзерге вакытта да кулланыла торган гарәп-фарсы сүзләре: асыл, вакыт, заман, изафә, исем, мәгънә, рәвеш, сәбәп, сыйфат, фигыль, хәреф. Бу терминнарның да бер өлеше грамматик үзгәрешләргә дучар булган: вакыт – вакыт хәле, рәвеш – рәвеш хәле, сәбәп – сәбәп хәле; б) хәзерге вакытта кулланылыштан төшеп калган алынма терминнар: гаиб, гөруһ, имля, истилях, каед, калкалә, ләфыз, масдар.

Г. Ибраһимовның термин ясалышында конверсия ысулы да катнаша. Аның хезмәтләрендә алар күп түгел һәм, башлыча, фигыль формаларыннан исемгә күчкәннәр: алмаш, тоташ (алмаш), эндәш, сөйләүче, тыңлаучы (3,31).

Яңа ясалган терминнар гадәттә «төзелмә терминнар» дип атала. Чарага бәйле рәвештә морфологик, морфологик-синтаксик һәм синтаксик ясалыш ысуллары аерыла.

II. **Ясалма терминнар**. Бу төр терминнар морфологик ысул – кушымчалау ярдәмендә ясалган. Г. Ибраһимов хезмәтләрендә кулланылган мондый терминнар ясалышында түбәндәге кушымчалар катнаша:

Исем ясагыч кушымчалар: а) -лык/-лек: алмашлык, барлык-юклык, бәйлек, берлек-күплек, вакытлык, тәмамлык, урынлык, ымлык, ярдәмлек; артыклык (сыйфаты), исемлек (галәмәтләре), иркәлек (исемләре); б) -ым/-ем: тезем; бүлем (саны, ярдәмлекләре, җөмлә), кайтым (бабы), күчем(тәмамлыгы); в) -мыш/-меш: аерылмыш, саналмыш, сыйфатланмыш, теркәләнмеш; г) -гыч/-геч: аергыч, сөйләгеч, теркәләгеч; д) -ма/-мә: аталма, искәрмә, кушылма; е) -ыш/-еш: тыныш(лар), үзгәреш, ясалыш; ж) -даш/-дәш: төрдәш, гамәлдәш (бабы); з) -ымта/-емтә: кушымта.

Сыйфат ясагыч кушымчалар: а) -лы/-ле: ияле, кушылмалы, иштыйкаклы; б) -ма/-мә: кушма, ясалма; в) -ым/-ем: аерым; г) -сыз/-сез: иясез.

Фигыль ясагыч кушымчалар: а) -ла/-лә: теркәләгеч, билгеләү; б) -лан/-лән: теркәләнмеш, сыйфатланмыш; в) -ай/-әй: (иркәләү)-кечерәйтү (галәмәтләре); д) төрле фигыль юнәлешләре формалары: йөкләтү, ярашу, эндәшелгеч.

Галимҗан Ибраһимов терминологиясе ясалышына бер үзенчәлек хас: исем ясагыч -лык/-лек һәм -ым/-ем кушымчалары ярдәмендә аерым терминнар да, тезмә термин составына кергән компонентлар да ясала (4, 282).

III. **Кушма термин**: исемфигыль. Терминны ике нигезне бергә кушу юлы белән ясау Г. Ибраһимов өчен хас түгел. Күрсәтелгән сүз бу төр ясалышка бердәнбер мисал булып тора.

IV. **Парлы терминнар:** иркәләү-кечерәйтү (галәмәтләре); берлек-күплек (галәмәтләре). Соңгы ике терминның парлы булуы аларның мәгънәсе, төшенчәләре белән билгеләнә. Бу терминнар капма-каршылыкка корылган категорияләрне белдерәләр һәм аларның компонентлары да антонимик мөнәсәбәттә тора.

V. **Тезмә терминнар**. Терминологиядә тезмә терминнар бик зур урын били, яки күпчелек терминнар нинди дә булса төшенчәне состав өлешләренә аерып, төр төшенчәләрен билгеләү нәтиҗәсендә барлыкка килә (2, 27). Г. Ибраһимовның терминологик системасын да , нигездә, төрле ыру һәм төр төшенчәләрен һәм алар арасындагы бәйләнешләрне белдергән тезмә терминнар тәшкил итә һәм алар түбәндәге төркемнәргә бүленә: а) компонентлары аергыч белән аерылмыш мөнәсәбәтендә булган сыйфатлы терминнар: аерым алмаш, изге теләк, кире өтер, кушма сан, булачак фигыль, баш җөмлә, булачак фигыль; б) компонентлары I төр изафә бәйләнешендә торган тезмә терминнар: аергыч җөмлә, кереш сүз, асыл фигыль, вакыт җөмлә; в) компонентлары II төр изафә бәйләнешендә торган тезмә терминнар: бергәлек ярдәмлеге, зат алмашлыклары, өлеш саны, сүз җилеме, юлдаш ярдәмлеге, азсыту сыйфаты, күргәзү алмашлары; г) бәйлекле конструкцияләр: баб белән үзгәреш, мәртәбә белән үзгәреш, сөйләүче өчен; д) күп компонентлы тасвирлама конструкцияләр: гатыф өчен булган «дә», саналган әйбернең исме.

Г. Ибраһимов, тел белеме терминнарын саф татарча куллануга каршы булмаса да, терминнар ясаганда кулланыла торган ысулларның төрлелеген телне баету чарасы итеп күрсәтә.

ӘДӘБИЯТ


1. Газизова Ф. М. Язык и стиль прозы Галимджана Ибрагимова: Автореф. дис. … канд. филол. наук. – Уфа, 1975. – 34 с.

2. Ибраһимов Г. Татар нәхүе: бишенче басмасы. – Казан: Сабах, 1919. – 52 б.

3. Ибраһимов Г. Татар сарыфы. – Казан: Сабах ширкәте, 1917. – 52 б.

4. Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда. VIII т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. – 432 б.


# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ҺӘМ XX ЙӨЗ БАШЫ ТАТАР ӘДӘБИ ТЕЛЕ


***Э. Ф. Җаббарова (Казан)***



В истории каждой области знаний есть имена ученых, с деятельностью которых связаны целые эпохи в развитии того или иного направления в науке и труды которых стали прочным фундаментом здания современной науки. Есть такое имя в тюркологии – Г. Ибрагимов. Статья посвящена вопросу исследования татарского литературного языка начала XX века и вкладу ученого, общественного деятеля Г. Ибрагимова в развитие норм, лексических пластов национального языка, чье наследие играет огромное значение в развитии гуманитарных знаний как у татар, так и у тюркских народов.


Галимҗан Ибраһимов – татар халкы тарихында уникаль шәхесләрнең берсе. Ул бөек әдип, тәнкыйтьче, публицист, җәмәгать эшлеклесе, күпкырлы галим буларак танылган. Аның мирасы татарларда һәм, гомумән, төрки халыкларда гуманитар белемнәр үсеше өчен зур әһәмияткә ия. 1905 ел революциясеннән соңгы гомуми күтәрелеш елларында әдәбият мәйданына чыккан бу язучы Бөек Октябрь революциясенә кадәр үк, үзенең әдәби әсәрләре һәм тәнкыйть мәкаләләре белән әдәби процесска көчле йогынты ясый. «Татарның мәдәни ярлы чагында мәйданга чыкканга, бөтен көчне әдәбиятка гына бирә алмадык. Минем төп эшем әдәбият булса да, моңа янәшә тагын ике тармак 1) лингвистика, филология, 2) революцион хәрәкәт тарихы кушылды. Шулай итеп каләм җимеше өч ботакта үсә барды», – ди ул (3, 209).

Әлеге мәкаләдә без Г. Ибраһимовның XX йөз башы татар әдәби теленә керткән өлешен беркадәр күзаллярбыз. Билгеле булганча, XX йөз башы – татар әдәби теле тарихында зур үзгәрешләр чоры һәм тел тирәсендә барган көрәшнең иң кызган вакыты. Чөнки «...берничә йөз еллар буена кулланылып киленгән иске татар әдәби теле бу чорда инде, халыкның җанлы сөйләменнән шактый нык ераклашкан һәм киң массаларга авыр аңлашылганга күрә, гомуммилләт әдәби теле функциясен үти алмый, җәмгыятьнең тар бер катламы өчен генә хезмәт итә башлый. Шуның нәтиҗәсендә, әдәби тел белән халыкның җанлы сөйләме арасында зур аерма барлыкка килә» (1, 10). Бу чорда әдәби телнең тулысынча җанлы сөйләмгә нигезләнеп үсеп китүе өчен яңа иҗтимагый-тарихи шартлар барлыкка килә. XIX йөз башында ук әдәби телне халыкның җанлы сөйләменә якынайту һәм һәрьяклап аны шул нигездә формалаштыру мәсьәләсе көн тәртибенә куелган була.

Милли телнең халыкчанлыгы һәм мөстәкыйльлеге өчен көрәш Г. Ибраһимовның эшчәнлегендә ачык чагылыш таба. Бу көрәш, беренчедән, әдәби тел телнең үз ресурслары хисабына үсәргә һәм баерга тиеш дигән фикерне алга сөрү юнәлешендә бара. «Татар әдәби теленең иң төп нигез материалы үзебезнең ана

телебездән алынырга тиешле. Татарчада сүзләр була торып, болар урынына башка һичбер телдән һичбер сүз кертелмәсен», – ди ул (2, 93).

Икенче яктан, әдәби телне, шул ук вакытта матур әдәбият телен, гарәп-фарсы һәм төрекчәлек йогынтысыннан сафландыру рухында бара: «...моңарчы әдәбият-матбугат дөньябызны каплап, әдәби, гыйльми әсәрләрне хезмәт халкына аңланмаслык ясауга сәбәп булган гарәбизмга каршы көрәш башларга, боларны чыгарып ташларга кирәк... Революциягә чаклы рус феодал самодержавиесе астында динне, милләтне саклау, руслаштыру сәясәтенә каршы бер калкан итеп тоту хыялы белән, мәгълүм шартлар эчендә, бик табигый булып килгән гарәпчәлек һәм аның безнең телдәге көчле урыны пролетариат революциясендән соң бөтенләй үз рольләрен югалттылар, кирәксез нәрсә булып калдылар. Безнең тормыш ягыннан әһәмияте калмаган гарәп, фарси(дан) сүзләр, аталмалар эзләп маташу – бер адым артка китүдер. Шуңа күрә гарәби, фарси сүзләрдән матбугатны тазарту тиешле» (2, 93–94).

XIX йөзнең икенче яртысында татарлар арасында барлыкка килгән мәгърифәтчелек хәрәкәте, XX йөз башындагы иҗтимагый-тарихи вакыйгалар, 1905–1907 еллардагы революцион күтәрелеш, иҗтимагый-сәяси төшенчәләрне белдергән сүзләрнең киң рәвештә үсеп, бу катламның ныклап урнашып һәм нормалашып китүе өчен зарури шартларны тудырды (4, 258–259). Г. Ибраһимов та бу катлам сүзләр телебездә ничек бар шулай ныгып калсын, аларны гомумкулланылыштагы сүзләр итеп карарга кирәклеген әйтә, аларны татарчага тәрҗемә итмәскә, дигән фикерне алга сөрә (2, 93).

Әдәби тел үсеше язма тел белән сөйләү теленең үзара һәрьяклап тәэсир итешү күренешеннән гыйбарәт булырга тиешлеген тирән аңлап, Г. Ибраһимов үз әсәрләрендә җанлы сөйләмдәге бай лексик, фразеологик, синтаксик һәм интонацион чараларны киң һәм иркен файдалана. Шулай итеп, әдипнең эшчәнлеге татар әдәби теле нормаларының камилләшүенә, телнең яңа синтаксик-стилистик мөмкинлекләре ачылуына, матур әдәбият теле җанлы сөйләү теленә якынайтылуына, милли әдәби тел азатлык өчен көрәшнең көчле идеологик коралы булып әверелүенә зур йогынты ясый.


ӘДӘБИЯТ

1. Абдуллин И. А. Г. Камал драмаларының теле / И. А. Абдуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1968. – 198б.

2. Ибраһимов Г. Милләт. Тел. Әдәбият: Сайланма әсәрләр / Г. Ибраһимов. – Казан: Мәгариф, 2007.– 239 б.

3. Ибраһимов Г. Әдәбият мәсьәләләре / Г. Ибраһимов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1960.– 262 б.

4. Хаков В. Х. Татар әдәби теле тарихы / В. Х. Хаков. – Казан: Казан университеты нәшрияты, 1993. – 310 б.


## ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫҢ ТӨРКИ ТЕЛЛӘР ҮСЕШЕ КОНЦЕПЦИЯСЕ


***Б. Э. Хәкимов (Казан)***



В статье рассматриваются взгляды Г. Ибрагимова на проблемы исторического и социального развития тюркских языков. Анализ трудов ученого, посвященных данной проблеме, показывает, что в его концепции основным фактором развития тюркских языков являются объективно сложившиеся общественно-исторические условия. Наследие Г. Ибрагимова в этом аспекте представляет большую ценность для татарского и тюркского языкознания.


Галимҗан Ибраһимовның лингвистик мирасы татарларда һәм, гомумән, төрки халыкларда гуманитар белемнәр үсеше өчен зур кыйммәткә ия, аны өйрәнү татар филологиясе алдында торган әһәмиятле бурычларның берсен тәшкил итә. Бүгенге көндә бөек галимнең мирасын һәрьяклап тикшерә торган махсус бер гыйлем өлкәсе формалашып килә дип әйтергә мөмкин.

Кыска гына вакыт дәвамында ул үзен көчле теоретик буларак кына түгел, ә бәлки гамәл кешесе, фәнни эшләрне нәтиҗәле итеп оештыручы, фәнни табышларны тормышка ашыручы буларак та күрсәтте, тел белеменең татарларда чын мәгънәсендәге фән булып формалашуында зур роль уйнады.

Г. Ибраһимовның лингвистик эшчәнлеге җәмгыять таләпләренә җавап булып тора, иҗтимагый мәнфәгатьләр шушы эшчәнлекнең юнәлешен билгели, бу – XX йөз башы төрки җәмгыятьләрдә барган катлаулы процесслар йогынтысында барлыкка килгән күренеш. XX йөз башында төрки милләтләрнең идентификациясе-үзбилгеләнүе, этносларның чикләре, үзара бәйләнеше һәм мөнәсәбәтләре мәсьәләсе кискен тора. Татар җәмгыятендә әлеге мәсьәләләрне чишүдә төрле тенденцияләр – гомумтөркичелек һәм татарчылык юнәлешләре көрәшә. Шушы мәсьәләләр тел белән тыгыз бәйләнештә карала һәм тел яссылыгында чишелә.

Г. Ибраһимовның 1916 елда басылып чыккан «Тел-әдәбият мәсьәләләренең кирәкле бер тармагы» мәкаләсендә телне тикшерүнең төп максатлары түбәндәгечә игълан кылына: «*...Телгә җиңеллек, телгә байлык, телгә саклык, телгә төзеклек, телгә дөрестлек...*» (3, 490). Бу актуаль мәсьәләләрне чишү өчен, Галимҗан Ибраһимов халыкның һәм телнең тарихына мөрәҗәгать итә, эзлекле рәвештә тарихилык принцибын куллана.

Галим фикеренчә, телләрнең үсеше нигезендә матди (географик һәм икътисади-сәяси) факторлар ята: *«Бик күптән инде, җәгърафи һәм икътисади-сәяси гамилләр тәэсире белән, төрек кабиләләре дөньяның төрле җирләрендә бер-берендән аерым, мөстәкыйль коллективлар булып оештылар»* (3, 330). Икенче яктан, тел өлкәсендәге бердәмлек тә матди һәм иҗтимагый якынлык җирлегендә барлыкка килә: *«Җәгърафи, тарихи, сәяси, икътисади, дини рәсмият вә башка күп сәбәпләр бу кабиләләрне бергә оештырып, бер әдәбият астында җыелырга зәмин хәзерләгән»* (3, 225).

Әлеге нигез фикердән чыгып, Г. Ибраһимов шундый нәтиҗә дә ясый: милли телләрнең аерылып чыгуы – табигый тарихи үсеш нәтиҗәсе: «*Без "татарлык" димез, телемезне "татар теле" дип, әдәбиятымызны "татар әдәбияты" дип атыймыз – моңа кемләрнең булса да хезмәтләре, фикерләре сәбәп түгел, моның*

*сәбәбе тирәндә, тарихи куәтләрнең шул юлга сөрүендәдер*» (3, 225).

Г. Ибраһимовның 1917 елга кадәрге хезмәтләрендә телләр үсеше процессларын хәрәкәткә китерүче факторлар абстракт-объектив яссылыкта карала: «*язмыш иҗбаре* (боеруы. – *Б. Х.*) *белән...*» (3, 225). Революциядән соңгы елларда исә галимнең телләр үсеше мәсьәләләрендә абстракт материализмы марксистик юнәлештә конкретлаша. Шулай итеп, революциягә кадәр аерым милли телләр формалашуның сәбәпләрен аңлатуда тарихи-иҗтимагый детерминизм төп принцип булып торса, 1920 нче елларда язылган мәкаләләрдә сыйнфыйлык принцибы, марксистик аңлау өстәлә. Г. Ибраһимов тел үсешенең юнәлеше хакимлек итүче сыйныф тарафыннан билгеләнә дигән фикерне кабул итә: «*Телнең сүзләренә килсәк тә, әдәбият, идеология эшләрендә үзен активист итеп сизгән пролетариатның безгә “приказлары” булмады түгел... Әле без моны эшләп җиткерә алмадык. Ләкин шуңа барабыз, чөнки яңа сыйныфларның хәле шуны безгә боера*» (3, 420).

Г. Ибраһимов алга киткән халыкларның телләре аерым тарихи чорларда башка кардәш халыклар өчен күп мәсьәләләрдә чыганак ролен үтәвен, «остаз» булуын да таный: «*Без бервакыт госманлы әдәбиятына шәкерт идек. Ул вакыт бездә госманлы тәэсире бар иде. Казакълар да беразгача татар мәдәниятенә вә татар әдәбиятына шәкерт булырлар*» (3, 225). Ләкин ХХ йөз башында ситуация инде үзгәргән була, галим казакъ (1910 нчы елларда) һәм башкорт телләренең (1920 нче еллар башында) мөстәкыйль әдәби тел булып оешуына комачауларга ярамый, кардәш халыклар белән тигез хокуклы дуслык мөнәсәбәтләре урнаштырырга кирәк дип саный: «*башка төрки кабиләләрнең һичберенә охшамаган алты-җиде миллионлы бер халыкны “татар теле вә әдәбияты” астына кертү фикере – бу хәяттагы табигый куәтне аңламаудан башка нәрсә түгелдер*» (3, 225). Бу мәсьәләдә галимнең девизы булып түбәндәге сүзләр яңгырый: «*Һичбер халыкның авызына һичбер вакытта, аның табигый телен тартып алып, үзең теләгән яңа бер тел куяр хәл юк*» (3, 225).

Аерым төрки телләрнең мөстәкыйль үсеше Г. Ибраһимов тарафыннан дәвам итүче процесс буларак күрсәтелә. Ул үз чорында ук инде формалашып җиткән берничә зур мөстәкыйль төрки телне атый (госманлы, азәрбайҗан, чыгътай, татар, казакъ) (3, 225). Ул алга таба да бу «макротелләр»дән кайбер яңа мөстәкыйль телләрнең аерылып чыгу мөмкинлеген таный (башкорт, кырым татарлары теле һ. б.), ләкин моңа киләчәктәге икътисади-иҗтимагый ситуация тәэсир итәчәк дигән фикердә тора (3, 225).

Күренекле телче эшчәнлегенең гомумтюркологик аспекты бигрәк тә 1926 елда Бакуда Беренче тюркология корылтаен үткәрү чорында язылган хезмәтләрендә чагылыш таба. Беренче тюркология корылтае вакытында Г. Ибраһимов телләр тарихы һәм үсеше мәсьәләсен чишү өлкәсендә бик актив эшли, әлеге мәсьәлә корылтайның көн тәртибендә төп мәсьәләләрнең берсе була.

«Төрек халыклары арасында әдәби-мәдәни федерация нигезләре» (1926) мәкаләсендә, тюркология корылтаена һәм аның карарларына бәйле рәвештә, Г. Ибраһимовның гомумтюркологик характердагы иң әһәмиятле фикерләре урын алган. Шул мәкаләдә телләрнең мөстәкыйль үсеше турындагы тезис тагын да конкретлаша: аерым телләр, үзләренең үзенчәлекле яклары булганга, бер-берсеннән автоном рәвештә үсәләр, ләкин төп юнәлешләрдә универсаль билгеләргә дә ия: «*...бу әдәби телләр... ераклашуга таба түгел, бәлки үскән саен якынлашуга баралар. Шуңа күрә имляда, аталмаларда, әдәби тел төзүдә бу телләр арасындагы гомуми булган уртак хасиятләр күз алдында тотылырга тиешледер*» (4, 289).

Моңа кадәрге мәкаләләрендә булган фикерләрен дәвам итеп һәм тагын да үстереп, Г. Ибраһимов аерым телләр формалашуда географик, тарихи, икътисади һәм иҗтимагый факторларның хәлиткеч ролен ассызыклый: «*...Тарихи-җәгъръфи, мәдәни-икътисади хәлләрнең башкалыгы, аерымлыгы сәбәбендән төрек халыклары аерым әдәби телләр, җирле тормыш белән сугарылган әдәбиятлар, гыйлемнәр, санагатьләр тудыру чарасына керештеләр*» (4, 288).

Г. Ибраһимов төрки телләрнең мөстәкыйль әдәби телләр булып үсеше, үзара мөнәсәбәтләре мәсьәләсенә дә кагыла. Аның сүзләре буенча, ХХ йөз башында бу мәсьәләдә ике агым көрәшә (бу карашларны ике капма-каршы чик дип атау дөресрәк булыр):

1) бер гомуми әдәби телне яклау агымы;

2) аерым «шивәләр»нең һәрберсен «бөтенләй мөстәкыйль» тел дип карау агымы («сепаратизм юлы») (4, 288).

Галим сүзләренә караганда, тюркология корылтае бу ике чик арасыннан, уртадан бара торган юлны сайлый (4, 287–289). Димәк, бу мәсьәлә тирәсендәге фикерләрне өч агым итеп тә карарга мөмкин.

Г. Ибраһимов «урта агым»ның җиңүен әйтә һәм шуны хуплый. Аның фикеренчә, әлеге реалистик, «уртадан баручы» агым беренчесен, табигый җирлеге нык булу сәбәпле, җиңә. Шул сәбәпле татарларда яңа милли әдәби тел төзү мәсьәләсе 1910 ел тирәсендә чишелгән санала: «*...Без, татарлар, аерым татар әдәбиятын, аерым әдәби татар телен тудыру мәсьәләсен боннан 15 еллар элек назариядә дә, гамәлдә дә чишеп беткән идек*» (4, 288).

Югарыда күрсәтелгән мәкаләдә шушы мәсьәлә тирәсендә булган фикерләр үсеше тасвирлана. Беренче агымга башлангыч бирүче итеп – И. Гаспралы күрсәтелә. Төрки халыкларның табигый үсеш закончалыкларыннан килеп чыккан, шушы табигый үсешкә җавап итеп һәм аның нәтиҗәсе буларак формалашкан «урта» агымга нигез салучылар – татарларда К. Насыйри, азәрбайҗанларда Ф. Ахундов, казакъларда Абай (Ибраһим Кунанбаев) (4, 287–288). Галим үзе төрки телләр үсеше мәсьәләсендәге ике капма-каршы агымны югарыдагыча билгеләп күрсәтсә дә, чынлыкта, объектив сәбәпләр җирлегендә оешкан мөстәкыйль әдәби телләр яшәвен яклау агымын икенче агым итеп атарга кирәк. «Сепаратистик» юнәлеш исә, безнеңчә, шул агымның чиктән узган бер формасы итеп каралырга тиеш.

«Төрек телләре арасында әдәби-мәдәни федерация нигезләре» мәкаләсендә иң мөһим аспектларның берсе булып аерым төрки әдәби телләрнең универсаль билгеләре һәм аларның алга таба үсешләрендә булырга тиешле уртак юнәлешләр проблемасы тора. Г. Ибраһимов бу хакта болай ди: «*...Аерым һәм уртак... хасиятләр безнең төрки әдәби телләрнең бер-беренә мөнәсәбәтләрендә нигез ташы булып алынырга тиешләр*» (4, 291).

Кардәш телләрнең дифференциаль һәм интеграль билгеләре чагыштырмасы Г. Ибраһимов тарафыннан

түбәндәгечә билгеләнә: «...*Төрки әдәби телләрнең... фонетикасында, морфологиясендә, синтаксисында тик үзләренә генә караган хасиятләре булган кебек, бу әдәби телләрнең һәммәсенә уртак булган хасиятләр, нигезләр дә бардыр*» (4, 291).

Конкрет алганда, аерым төрки телләрнең уртак, универсаль билгеләре Г. Ибраһимов тарафыннан гамәли-функциональ яссылыкта яктыртыла, кардәш төрки телләр өчен үзенә күрә бер унификация принциплары буларак тәкъдим ителә. Мәсәлән, төрки телләрнең орфографияләре өчен түбәндәге төп уртак нигезләр тәкъдим ителә: «*Сингармонизм, агглютинация (кушылмачылык), фонетика белән морфологияне игътибарга алу, һәр әдәби тел эчендә кабиләчелек белән көрәш, имля теләвенчә яңа хәрефләр, яңа галәмәтләр арттырырга туры килсә, һәммә төрек халыкларында бертөрле гомуми шәкелләр алу*» (4, 289).

Терминологиядә исә түбәндәге нигезләр күрсәтелә: «*Төп нигез үз ана телләрендән алыну, гарәп-фарсыны мөмкин кадәр чыгарып ташлау, әлбәттә, яңадан кертмәү, җитмәгән урында Аурупа атамалары материалыннан файдалану, югарыланган саен гомумирәк сүзләрне ала бару*» (4, 289).

Г. Ибраһимов фикеренчә, бу уртак билгеләр, юнәлешләр төрки телләргә гомуми принциплар буенча төзелгән, һәрберсе мөстәкыйль эчтәлекле телләр гаиләсе булып үсәргә мөмкинлек бирә: «*Һәрбер әдәби тел тик үзенә генә караган эчке аерым хасиятләре, шартлары нигезендә мохтар-автоном рәвештә төзелә, ләкин башка әдәби төрки телләр белән булган уртак хасиятләр, гомуми нигезләр буенча алар белән якын бәйләныш ясый... бу аерылу һәм бәрелешү мөнәсәбәтен әдәби-мәдәни федерация дип атарга мөмкин булыр иде. Әдәби төрки телләрнең бер-берсенә мөнәсәбәтләре, бер федерация эченә кергән мохтар-автоном бүлекләрнең бер-берсенә һәм гомумгә мөнәсәбәтләренә охшаш рәвештә булыр*» (4, 291).

Г. Ибраһимовның төрки телләр үсеше концепциясенең татар һәм төрки тел белеме өчен әһәмияте – телләр үсеше процессларын беренче тапкыр объектив төшенчәләргә һәм принципларга нигезләнеп тасвирлауда. Бөек галимебезнең бу өлкәдәге мирасын алга таба да тирәнтен өйрәнү – фән алдында торган мөһим бурычларның берсе.

ӘДӘБИЯТ


1. Беренче тюркология корылтае һәм аның тикшергән мәсьәләләре / төз. Г. Рәхим. – Казан: Татарстан Халык Мәгариф комиссариаты, 1926. – 96 б.
2. Ибраһимов Г. Имля, тел, әдәбият мәсьәләләре / Г. Ибраһимов. – Казан: Татарстан матбугат һәм нәшрият комбинаты, 1924. – 143 б.
3. Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда / Г. Ибраһимов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – V т. – 615 б.
4. Ибраһимов Г. Әсәрләр: сигез томда / Г. Ибраһимов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1987. – VIII т. – 432 б.


# ӘДИПНЕҢ «ТАТАР ХАТЫНЫ НИЛӘР КҮРМИ» ӘСӘРЕНДӘГЕ ФРАЗЕОЛОГИК ӘЙТЕЛМӘЛӘРНЕҢ ЛЕКСИК-СЕМАНТИК ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ


***З. С. Кәримова (Уфа)***



Статья посвящена анализу лексико-семантических особенностей фразеологических единиц. Рассматриваются синонимичность, антонимичность, омонимичность фразеологизмов. Эти фразеологизмы Г. Ибрагимов, как и другие писатели, в основном использует для избежания тавтологии в тексте.

Мастерское владение всеми этими возможностями, чутье в выборе стилистических и семантических оттенков являются характерными чертами стиля Г. Ибрагимова.


Г. Ибраһимов үзен туган телнең эчке мөмкинлекләрен, грамматик законнарын, стилистик характерын тирән аңлаучы классик язучы, зур галим итеп танытты.

Фразеологик әйтелмәләр язучылар телендә алтын фонд булып санала. Матур әдәбият стилендә фразеологик әйтелмәләрне эшкәртүгә һәр әдип үз өлешен кертте. Бигрәк тә Г. Камал, Ш. Камал, Г. Тукай, Г. Ибраһимов һ. б. фразеологик әйтелмәләрне төрле стилистик максатта иҗади куллануда матур үрнәк күрсәттеләр. Г. Ибраһимов иҗатында туган телнең зур фразеологик арсеналы тупланган.

Фразеологик әйтелмәләрдән оста файдалану язучының уңышлы һәм отышлы ягы: ул образларны, вакыйгаларны сиземлерәк итеп сурәтли, аларга үзенчәлекле төс кертә, әсәр теленең халыкчанлыгын, гадилеген тәэмин итә. Шуңа күрә язучының фразеологик әйтелмәләрен тикшерү аның поэтик стилен ачыклаучы чара булып тора. Бу хакта А. И. Ефимов болай ди: «Фразеологик байлык сурәтләү чаралары арасында поэтик стильнең кирәкле өлешләренең берсенә керә. Шуның өчен аларның теге яки бу язучы тарафыннан кулланылуын тикшерү язучының индивидуаль иҗат методы үзенчәлекләрен ачу өчен мөмкинлек бирә» (2).

Фразеологик әйтелмәләрдәге стилистик үзенчәлекләрнең эмоциональ-экспрессив характерларын тирәнрәк ачыклау өчен, аларны составы ягыннан да, лексик-семантик үзенчәлекләре ягыннан да тикшерергә мөмкин. Гадәттә аларны түбәндәгечә бүләләр:

1. Фразеологик синонимнар;
2. Фразеологик омонимнар;
3. Фразеологик антонимнар;
4. Фразеологик гиперболалар.

Бу төр фразеологик әйтелмәләр Г. Ибраһимов әсәрләрендә актив кулланыла. Аларның кайберләренә тукталып үтү урынлы булыр.

**Фразеологик синонимнар.** Кабатлау, тавталогия кебек күңелсез хәл килеп чыкмасын өчен, бер үк мәгънәне автор төрле лексик-грамматик чаралар ярдәмендә төзи. Мәсәлән, *«Ул башта моңа аптырап карады, азып-тузып китмәсен, яман телгә эләкмәсен, атычабы чыга күрмәсен, ходаем, дип борчылды»* (3, 446).

Автор тарафыннан бер җөмлә эчендә бик уңышлы кулланылган бу фразеологик әйтелмәләр бер мәгънәне аңлата (халык арасында начар яктан даны чыкмасын). Бу әсәрдә тагын шундый синонимик оялар табып була – *«күз йоммау»* (3, 446), *«бер тамчы йокламау»* (3, 501), *«күзгә йокы кермәү»* (3, 551–559) – йоклау мөмкинлеге булмау мәгънәсендә. Яисә тагын берничә мисал: *«йөрәк урыныннан кузгалу»* (3, 438), *«кот очу»* (3, 601) – курку мәгънәсендә. *«Берне әйткәнче, унны өлгертү»* (3, 445), *«авыз ачырмау»* (3, 536) – кешегә сүз әйтергә ирек бирмәү мәгънәсендә. Болар төрле формадагы лексик берәмлекләр белән тәгъбир ителсәләр дә, мәгънәләре, эчтәлекләре белән бер-берсенә бик якын торалар.

**Фразеологик антонимнар** капма-каршы идеяләрне, фикер, төшенчә, күренеш, факторларны тасвирлауга ярдәм итәләр. Фразеологизмнарның антонимик төшенчәдә булулары, аларны аерым-аерым караганда, сизелмәскә дә мөмкин. Моны контекстта, җөмлә эчендә, фикер йөрешендә генә белеп була. Мәсәлән, «Татар хатыны ниләр күрми» повестенда «кайгы» төшенчәсен белдергән бик күп фразеологик әйтелмәләр бар: *«Шулай икән, гөлкәем, хатын башына бер бәхет күләгәсе тими икән»* (3, 443), *«Аның башын караңгылык каплады»* (3, 444), *«Йөрәге, нindидер авырлык белән кысылып, кайгы дулкыны күкрәгеннән бугазына табан омтылды»* (3, 444). Г. Ибраһимов бу фразеологик әйтелмәләргә антонимик мөнәсәбәттә булган шатлык мәгънәсендәге *«түбәсе күккә тиде»* дигән фразеологик әйтелмәне кулланып, бик күп вакыйга һәм күренешләрне образлы итеп сурәтли. *«Сабираның шулай сүзсез җиңелүенә Мәрфуга киленнең түбәсе күккә тиде»* (3, 529). Галимҗан Ибраһимовта капма-каршы мәгънәләр белдергән фразеологик әйтелмәләр бик күп очрый. Алар вакыйга һәм күренешләрне контраст яки антонимик формада куеп сурәтләргә ярдәм итәләр.

Бер үк төрле лексик-грамматик чаралар ярдәмендә ясалган фразеологик әйтелмәләр контекст эчендә, стиль, әдәби әсәрнең идея-эчтәлеге таләп итүе буенча әсәр барышында төрле экспрессив-эмоциональ мәгънә белән эчтәлекләнергә мөмкин. Боларга **фразеологик омонимнар** диләр. Алар күчерелмә мәгънәдә була. Ләкин биредә күптөрле лексик мәгънә аңлату сәләте бик киң түгел. Болар стилистик яктан гына аерылалар яки, контекстка карап, фразеологизмның эчтәлеге берникадәр үзгәрә. Мәсәлән, *«Хатын, хайран булган кебек, ике кулын ике якка җәеп җибәрде»* (3, 491). *«Бикъярлар, Шибай кантун йортындагы вакыйгалар турында ни уйларга белмичә, хәйран булып калдылар»* (3, 568). Ике җөмләдә дә образлылык *«хәйран калу»* белән бирелгән. Ләкин беренчесеннән – якынча, ә икенчесендә нык хәйран калу аңлашыла. Аның шулай булуы фразеологик әйтелмәнең стилистик йөкләнешен башка лексик мәгънәдәге сүзләр ачыклауга бәйләнгән. Димәк, бер үк төрле фразеологик әйтелмәнең стилистик-семантик үзенчәлеге контекстка, вакыйгага, шартларга карап билгеләнә.

Образ тудыруда, персонажларның психологик кичерешләрен, кискен хәлләрен сурәтләүдә **фразеологик гиперболаларның** әһәмияте тагын да калкурак. Алар шул ук фразеологик синонимнар, антонимнар эчендә яшиләр. Г. Ибраһимов болары белән дә бик иркен эш итә. Фразеологиянең бу төре халык телендә дә күп очрый. Ләкин Г. Ибраһимов бервакытта да халыктагы әзер формалар белән генә тынычланмый, образны көчәйтү максатында, стилистик таләпләрдән чыгып, үзе дә фразеологик әйтелмәләр төзи. Мәсәлән, халык «уйлары чуалды», «башы томаланды» дисә, Г. Ибраһимов тагы да уңышлырак итеп *«Аның башын караңгылык каплады»* (3, 444) дигән фразеологик әйтелмә төзи. Халык телендә «батырып карау» дигән фразеологик әйтелмә дә бар, автор аны түбәндәгечә үзгәртә: *«Шул арада Гөлбану сикереп торды, ишектән кергән атасына, күз яшьләрен аз гына да яшермичә, елаган күзләре белән батырып карады да, җиңе белән битен сөртәсөртә, аш өенә таба чыгып китте»* (3, 444).

Галимҗан Ибраһимов үзенең «Татар хатыны ниләр күрми» әсәрендә фразеологик синонимнардан, антонимнардан, фразеологик гиперболалардан шактый уңышлы куллана, алар әсәрнең сәнгатьлелек дәрәҗәсен күтәрүдә, фикерне тулырак ачуда гаять әһәмиятле роль уйныйлар.

ӘДӘБИЯТ

1. Әхәтов Г. Х. Татар теленең лексикасы – Казан: Татар. кит. нәшр., 1965.
2. Ефимов Л.И. Стилистика художественной речи. – М.: Изд-во МГУ, 1967.
3. Ибраһимов Г. Сайланма әсәрләр: 3 томда. III т. – Казан: Таткнигоиздат, 1956.
4. Поварисов С. Ш. Система образных средств в художественной прозе Г. Ибрагимова. – Уфа: Изд-во БГУ, 1980.

*Работа выполнена при финансовой поддержке РГНФ РБ: «Урал – история, экономика, культура в рамках грантов научно-исследовательского проекта “Лингвокультурологические и лингводидактические аспекты изучения слова в языке и речи (на материале татарского языка)”». № 12–14 – 02011 а/У.*

## Г. ИБРАҺИМОВ ИҖАТЫНДА ДИНИ ЛЕКСИКА

***М. Р. Саттарова (Казан)***

Статья посвящается изучению одной из лексических особенностей языка произведений Г. Ибрагимова, а именно употребления религиозной лексики в произведении «Казакъ кызы» («Дочь степи»). Религиозная лексика служит источником изучения особенностей как духовной, так и материальной культуры. Избранное произведение интересно тем, что в нем находят отражение культура, религия и быт двух родственных народов, для которых ислам, будучи основным образом жизни, включающим в себя древние обычаи и традиции, имеет свой местный колорит.

Татар теле, әдәбияты үсешенә үзеннән зур өлеш керткән күренекле шәхес Галимҗан Ибраһимов әсәрләре теленең байлыгы, сюжетларының кызыклы булуы белән игътибарны җәлеп итә. Әлеге мәкалә әдипнең

«Казакъ кызы» романында кулланылган дини сүзләрне әсәрнең лексик спецификасы буларак анализлауга багышлана. Нәкъ менә әлеге әсәрне сайлау очраклы түгел, автор биредә татар халкының рухи үсешен бәяләү мөмкинлеген тудырырлык итеп, шул чор атмосферасын, кардәш казакъ халкы телендәге дини лексиканың кулланылыш үзенчәлекләрен дә теркәп калдырган.

Халык телендә дин белән бәйле сүзләр бер үк вакытта рухи мәдәниятне дә, матди мәдәниятне дә тасвирлау өчен кулланыла. Рухи аспект беренчел булып, идеяләрне көнкүрештә гамәлгә ашыру өчен матди элементлар буларак кием-салым, күпсанлы предметлар кулланылышка керүгә китергән. Сайлап алынган әсәрдә дә бу ачык күренә. Гомумән, лингвокультурологик күзлектән караганда, әлеге әсәр өйрәнү өчен кызыклы. Биредә ике кардәш халык мәдәнияте, теле очраша. Ислам дине ике халык өчен дә төп яшәү рәвеше булып тора. Әмма шул ук вакытта борынгыдан калган гореф-гадәт, йола-традицияләр дә сакланып, дини күзаллауларга милли, җирле төсмер бирә.

Аерым урыннарда лексик берәмлекләрнең казакъ телендәге вариантлары кулланылган. Дала халкының телен, көнкүрешен тасвирлауда ислам дине йолаларының электән сакланып калган гореф-гадәтләр белән үрелеп баруы ачык аңлашыла. Артык зур күләмле булмаган әлеге әсәрдә шактый күпсанлы дини сүзләр кулланылган. Аларны мәгънә ягыннан төрле төркемнәргә берләштерү түбәндәге нәтиҗәләрне бирде:

1) илаһи зат, Аллаһ Тәгаләне белдерү өчен кулланылган берәмлекләр: *Алла, Илаһи, Кодай, Тәңре, Ходай, ясаган ия*. Болардан тыш *яратучы (яралтучы), әлхәмдулла (әлхәмдүлилләһи), биргәнеңә шөкер* кебек сүзләр дә Аллаһ Тәгаләне күз алдында тотып кулланылган;

2) дингә бәйле кешеләр, затларны белдерә торган махсус атамалар да әсәрдә киң кулланылган: *адәм, әүлия, бәдәлче, дәверче, дин әһеле, динче, иблис, имам, ишан, молда/молдака, мулла, пигамбәр (пәйгамбәр), суфи, фидияче, хаҗи, хәлфә, шәкерт*;

3) ислам диненең нигез төшенчәләре буларак кулланыла торган түбәндәге абстракт мәгънәле сүзләр бар: *Аллаһу әкбәр, вәҗиб, гөнаһ, дин, дога, ислам, җан, кыямәт, саламалайкем (әссәләмегаләйкүм), обал (гөнаһ), оҗмах, тәкъдир, фарыз, ялган (бу вакытлы дөнья)*;

4) дини күзаллаулар белән бәйле булган йола атамаларыннан түбәндәгеләр очрады: *Аллага хәмед әйтү, бата кылу (искә алу, еллыгын укыту), бәдәл (кеше өчен ялланып хаҗга бару), дәвер (үлгән кешенең гөнаһларын кичерү йоласы), дәфен, дәфен-җиназа, дога кылу, җиназа, җиназа уку, имамга ою, комалак ачу, кыйблага юнәлү, кыяміттә җавап (бирү), ләхеткә төшерү, мәет-җиназа, мәкам (белән Коръән уку), мәхшәр (көне), ният кылу, рөкугка китү, сәҗдәгә яту, тәкбир (әйтү)*. Әсәрдә *дөлдел (дөлдөл)* атамасы да кулланылган;

5) дини текстларны белдерә торган сүзләр: *Коръән, мәкърәэ (Коръәннән өзек), тәбарәк, ясин;*

6) гомумән алганда дини кешеләр кия торган кием буларак кабул ителгән кием-салым атамалары: *җилән, җөббә, кәләпүш, чалма, чапан;*

7) дини ритуаллар, ышанулар белән бәйле предмет атамалары: *кәфен, комган, тәсбих*;

8) матди байлык, акча буларак аңлашыла торган лексик берәмлекләргә *корбан, сәдака, фидия, фидиялек* кебек сүзләр керә;

9) дин белән бәйле географик төшенчә – *кыйбла*.

Тематик яктан тасвирланган әлеге дини лексика, нигездә, татар теленең аңлатмалы сүзлегендә теркәлгән мәгънәләрдә кулланыла. Шулай да, үзенчәлекле, бүгенге татар әдәби теле күзлегеннән караганда специфик саналган очракларга аерым тукталу кирәк дип саналды. Алга таба нәкъ менә шундый лексик берәмлекләр тасвирлана.

***Алла*** – Ислам динендә «бар һәм бер» итеп танылган затның исеме; мәҗүсилек чорында төрле өлкәләргә караган илаһи көчне белдерә (6, 35). Әсәрдә ул бар һәм бер булган илаһи зат мәгънәсендә кулланылган: *Карт тагы зәһәрләнеп дөньяга, Аллага, байга үч итеп, сүгенеп йөри торган булды.* ***Аллага хәмед әйтү, Аллаһу әкбәр*** берәмлекләре дә шуны раслый: – *Илаһи ният кылдым җиназа намазы укымага, Аллага хәмед өчен, пигамбәргә друд өчен, мәеткә дога өчен, йөземне юнәлдердем кыйблага, оедым ошбу хәзер иманга, Аллаһе әкбәр!*

Моннан тыш, Аллаһ Тәгалә сүзенең синонимы буларак, текстта ***кодай/ходай, тәңре, ясаган ия, ясаган тәңрем*** сүзләре дә актив кулланылган. Мәсәлән, *Байдан чыгып үз тирмәсенә атлау белән, аның җаны әрнеп китте: ул алтмыш ел дөнья куды, Ходайга: «Мал да бирче, бак та бирче!» – дип моңлык кылды. Аның урынын кем ала белер – Кодай үзе юл күрсәтсен! – диде. – Ай Кодаем, ау, шуның йөздән берсен миңа бирсәң, синең кай җирең җимереләчәк иде?! Телемне алмадың, ау, Тәңрем! – Ясаган тәңрем мондый җылкыларны Байтүрәләргә биреп бетереп, безне мәхрүм калдырды. Мин карт инде, ясаган иямнән әҗәл көтәм, миңа ике адымнан артык тупрак кирәкмәс, – диде.*

Әлеге тематик төркемдәге сүзләрнең кулланылыш ешлыгы игътибарны җәлеп итә. Арада иң еш кулланылганы – *Тәңре, ясаган иям, ясаган тәңрем. Ходай* һәм *Алла* сүзләре иң аз кулланылганы. Үз чиратында, бу факт казакъ халкы сөйләмендә аерым гарәп-фарсы сүзләренең шул ук мәгънәдә кулланыла торган борынгы төрки эквивалентларын тулысынча кысрыклап чыгара алмавын күрсәтә.

***Бата кылу*** әсәрдә автор искәрмәсе белән «искә алу, еллыгын укыту» мәгънәсендә кулланылган. *Көннәрнең берендә, Тынычбай атаның елы тулганда, бата кылырга дип илнең өлкәннәре җыелган зур бер кымыз мәҗлесендә, күп уен-көлкедән соң, заманның авыраюыннан, дошманның җәфасыннан зарланып, әңгәмә ачылды.* «Фатиха, изге теләк; бәрәкәт, кот» дигәнне белдерә торган бу сүз хәзерге татар телендә актив кулланылмый (6, 74). Сүз русча «благословение» мәгънәсендә чуваш, кыргыз, каракалпак телләрендә дә очрый, ул гарәп телендәге фатыйха сүзеннән борынгы алынма буларак карала (2, 37). Кыргыз телендә түбәндәге мәгънәләре бар: 1) Коръәннең беренче сүрәсе; 2) этн. салават, хәер-дога (ризык белән сыйланганнан соң, нинди дә булса зур эш башкарылганнан соң кылына) (5).

***Бәдәл*** – гарәп теленнән кабул ителгән сүз һәм кеше өчен ялланып хаҗга бару һәм шуның өчен бирелгән акчаны; ***бәдәлче*** – бүтән кеше савабына ялланып, хаҗга баручыны белдерә (6, 101). Әсәрдә әлеге ике сүз шул ук мәгънәләрдә кулланылган: *Мәдрәсәдә укыган казакъ җегетләре, далада муллалыкта торган татар шәкертләре, вак ишаннар, суфилар, бәдәлчеләр, төрле яктан йөгерешеп, Байтүрәнең мәете яткан өлкән ак тирмәгә агылдылар. ... күкрәккә медаль таккан калын*

*биләр, бәдәл эзләп йөргән, тар, нечкә чалмалы, сырган кызыл җөббәле гарәп хәерче хаҗилары ...*

***Дәвер*** сүзе әсәрдә җеназа белән бәйле кулланыла һәм автор искәрмәсендә үлгән кешенең гөнаһларын кичерү йоласы буларак аңлатыла. Бу – варис тарафыннан бирелгән сәдаканың бирүче белән алучы арасында, мәрхүмнең 12 яшьтән соң яшәгән еллары санынча әйләнеп йөрүе (6, 152). ***Дәверче*** исә шул йоланы башкаручы кеше буларак аңлашыла. Мәсәлән, *Молдалар, теләгәнегез дәвергә керегез! Мәетнең сул ягы буйлап, ишектән түргәчә ике рәт булып, дин әһеле – дәверчеләр, фидиячеләр сафланганнар*.

Әлеге йола атамасы казакъча-русча сүзлектә «дәуір» этнографик берәмлеге буларак теркәлгән. Мәетне өйдән алып чыкканчы, мулла аның гөнаһларын үзенә ала һәм шуның бәрабәренә бүләкләр кабул итә торган «гөнаһлардан арындыру» йоласы; дәуір айналдыру – дәвер әйләндерү – гөнаһлардан арындыру йоласын уздыру (4). «Дәвер әйләндерү» йоласының килеп чыгышы Ислам дине кануннарына бәйле булмыйча, җирле халыкта электән сакланып калган традицияләрнең «исламлашуы» яисә башка сәбәпләр белән бәйле булырга мөмкин. Дини күзаллауларга нигезләнеп аңлатканда, кешенең үз гомере дәвамында кылган гөнаһлары мулла дога укып, сәдака алу хисабына кичерелә алмый.

Татар теленең урта диалекты бәрәңге сөйләшендә бу берәмлек «дәвер сөрү» буларак аңлашыла һәм «мәетне югач, ике мулланың кара-каршы утырып җеназа укуы» (отпевать, читать за упокойную) дигән мәгънәне белдерә, дәвер сөреп бетергәннән соң сәдака бирелгәнлеге искәртелә (7, 165). Бүгенге көндә дә татар халкында әлеге йола очрый. Әмма аның эчтәлеге әсәрдә тасвирланганча түгел, мәетне өйдән алып чыкканнан соң, зиратка алып китәр алдыннан тагын бер кат дога укудан гыйбарәт. Ә моның өчен сәдака бирү муллага хөрмәт йөзеннән эшләнә булса кирәк, чөнки дога кылу сәдака алу өчен башкарылмый. Килеп чыгышы белән *дәвер* сүзе гарәп теленә карый һәм, русча әйткәндә, «оборот, период» мәгънәсендә кулланыла (1, 256).

***Дәфен*** – мәет күмү йоласын аңлата (6, 153). Гарәп телендә *дәфәнә* фигыле «күмәргә» дигәнне белдерә (1, 246). ***Дәфен-җиназа*** сүзе дә шуны ук аңлата. Көндәлек сөйләмдә *дәфен кылу*, *дәфен-җиназа* төшенчәләре актив кулланылышта йөрмәсә дә, дини текстларда очрый.

***Дөлдел*** (дөлдөл) – гарәп теленнән кабул ителгән сүз. Ул бүгенге татар телендә хәзрәте Гали атланып йөргән качырның исеме һәм экиятләрдәге канатлы ат буларак билгеле (6, 154). Әсәрдә әлеге сүз бай атының кушаматы буларак кулланылган: *Байның үзе менә торган күк Дөлделен иярләп куйган ялчы аны бераз көлеп каршы алды: – Асыл киендең, җылкының толпарына мендең ... Юлың ак булсын, Азым әкә, – диде.*

***Җилән, җөббә, чалма, чапан*** сүзләре әсәрдә берничә урында кулланылган һәм ул чорда әлеге киемнәрнең популяр булуы хакында сөйли. Бер гасыр чамасы вакыт үтү белән әлеге атамаларның актив кулланылыштан чыга баруы һәм кием-салымнарның үзләренең дә тар кулланылышка ия булуы татар халкының киенү культурасы үзгәрүгә бәйле. Мәсәлән, *Болар арасында чалма, җилән киган татар муллалары, каракүл бүрекле, казаки, читек-кәвешле төрле татар сәүдәгәрләре, студент, семинарист киемендәге казакъ җегетләре, кысыкча кара күзләре, карасу киң йөзләре белән кай халыкның баласы икәнен күрсәтеп торган берничә офицер, бөтенләй европача киенгән, өлкән ак сакаллы карт казакъ адвокаты, күкрәккә медаль таккан калын биләр, бәдәл эзләп йөргән, тар, нечкә чалмалы, сырган кызыл җөббәле гарәп хәерче хаҗилары, нәселе, киеме мәгълүм булмаган тагы әллә кемнәр – һәммәсе, һәммәсе шул мәхшәр кебек җәмәгать эчендә бер яктан икенче якка тулганалар*.

***Кәләпүш*** сүзе бүгенге көндә татар телендә милли һәм дини күзаллауны берләштергән, нигездә ир-атлар баш киеме буларак аңлашыла. Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә кәләпүш – хәтфәдән тегелгән, түбәтәйгә охшаган баш киеме диелгән (6, 316). Ә түбәтәй турында «кәләпүш түгел» дип искәртелә (6, 600). Әсәрдә ул «татар кәләпүше» буларак ир-ат киеме сыйфатында тасвирланган: *Ияге очланып килгән, яңак сөякләренең югары ягы тышка бәреп тора, берничә генә бөртек чал сакалы җилберди; аягында иске читек-кәвеш, өстендә начар камзул, такыр башында татарның белен кебек җәелгән, каешланган иске кәләпүше иде. Малай елавыннан туктамады, әллә нинди бер иске кәләпүш ертыгына салган йомыркаларын бирмәс өчен бот араларына тыкты, үзе кызганычлы елау белән: – Мин аныкын алмадым, күл буеннан, камыш арасыннан үзем җыйдым, – дип, дөнья куптарып акыра иде.* Ә берничә урында ул хатын-кыз киеме итеп бирелә: *[Карлыгач-Сылу] Яшьрәк вакыттагы кечкенә кара кәләпүшне башының бер ягынарак салды да, көннең эсселеге белән, хатын-кызның, малның шау-шуы белән кайнап торган далага чыкты. Ике тирмә арасында җылтыр күзле, кайбер калку күкрәкле киленчәкләр белән, җефәктәй кара чәчләрен җилкәләрендә тулкынландырып, башларына кечкенә кызыл кәләпүшләр кигән сылу кызлар ачык һавада җырлый-җырлый киез басалар ...*

***Комалак ачу*** – комалаклар ярдәмендә фал ачу (6, 270). Ислам дине күзлегеннән нинди дә булса багучылык, күрәзәчелек итү эшләре катгый кире кагылса да, татарларда, шул исәптән, казакъларда да бу йола электән сакланып калган булган. Моңа түбәндәге җөмләне мисал итеп китерергә мөмкин: *Тактамны җәйдем, әүлиягә күңелемне куйдым да, комалак ачтым... Мәгәр, Ходаем каһәрләде, комалагым һичбер сүз ачык әйтмәде...*

Әсәрдә гөнаһ сүзенең казакъ телендәге варианты кулланылган. Бу – ***обал*** сүзе: *Ул яман җегет үз кылганының обалын табар, мәгәр илнең өлкәннәре акылга салсыннар, озын чәчле бер аял өчен талаш кузгалып кан түксәк, дусларыбыз җылар, мәңгелек дошманнарыбыз – ак, симез найманнар бәйрәм итәрләр, безгә рәхмәт әйтерләр, ашыкмагыз, уйлап эшләң, диде*.

***Ялган*** әсәрдә бер генә тапкыр кулланылган, автор аңлатмасы белән бирелгән һәм ул «вакытлы (фани) дөнья» дигәнне белдерә: *– Бу ялганда, – диде, – яхшылыгым күп булды, мәгәр яманлыгым да аз имәс. Дөньяныкы дөньяда бетсен...*

Карап үтелгән мисаллардагы төрлелек, специфик кулланылыш казакъ халкының милли менталитеты, Ислам диненең җирле колориты, төрки халыкларда электән сакланып калган тәңречелек элементлары белән үрелеп барудан бәйле. Шул ук вакытта авторның үз күзаллаулары да, субъектив фикер буларак, әсәр телендә чагылыш тапкан.

Нәтиҗә ясап әйткәндә, авторның үз дөньясы, кардәш булса да, икенче милләтнең мәдәни, дини

үзенчәлекләренең тел материалында чагылуы татар телендә дини лексика кулланылышын өйрәнү өчен кызыклы. Татар халкының укымышлы, зыялы шәхесләреннән берсе булган Г. Ибраһимовның халык тарихында, аның милли үзаңы, мәдәнияте формалашуда аерым урын алып торуы бәхәссез. Аның әсәрләрендәге дини сүзләрне туплау, өйрәнү халкыбызның рухи һәм матди мәдәнияте үзенчәлекләрен өйрәнү юнәлешендәге эзләнүләрнең тулы картинасын булдырырга ярдәм итәчәк.

ӘДӘБИЯТ

1. Арабско-русский словарь. В 2-х т. Т. 1.– Ташкент: Камалак, 1994. – 456 с.

2. Әхмәтьянов Р. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 272 б.

3. Ибраһимов Г. Казакъ кызы. – [Электронный ресурс]. – Режим доступа: www.kitap.net

4. Русско-казахский и казахско-русский словарь. – [Электронный ресурс]. – Режим доступа: http://sozdik.kz

5. Кыргызско-русский словарь. – [Электронный ресурс]. – Режим доступа: www.kyrgyz.ru

6. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Матбугат йорты, 2005. – 848 б.

7. Татар теленең зур диалектологик сүзлеге / Д. Б. Рамазанова һ. б. – Казан: Мәгариф, 2009. – 839 б.

*Мәкалә 11-14-16029а/В номерлы РГНФ гранты кысаларында язылды.*

# Г. ИБРАҺИМОВ ХИКӘЯЛӘРЕНДӘ ТӨСЛӘР

***Г. Р. Мөгътәсимова (Казан)***

В произведениях Г. Ибрагимова прилагательные со значением цвета прежде всего выступают в прямом значении. При этом они обозначают цвет разнообразных предметов быта, окружающей среды, явлений природы. Помимо прямого значения цвета большую роль в творчестве Г. Ибрагимова играет переносное и символическое значения цветообозначений. Цветообозначения помогают создавать автору яркие красочные образы и картины.

Һәр сүзнең нинди дә булса төп төшенчәсе була. Шул төшенчә, башка сүзләрнең төшенчәләре белән бәйләнешкә кереп, төрле күзаллаулар барлыкка китерә. Тирә-як табигатькә, халыкның көнкүреш үзенчәлекләренә бәйләнешле сүзләр текстка аеруча сурәтлелек бирәләр, тормышчан күренешне күз алдына китерәләр. Лексик берәмлек яки сүз номинатив мәгънәгә ия төп тел берәмлеге булып кала бирә. Сүз менталитет, дөнья тел сурәте, дөньяны күрә белү, халыкның күзаллаулары турында фикер йөртергә мөмкинлек бирә.

Бу мәкаләдә мин төсләрне белдергән сыйфатларга мөрәҗәгать итәргә булдым. Төсләрне белдерә торган сүзләр, минемчә, гап-гади лексик-семантик төркемне тәшкил итәләр. Аларның шигърияттә һәм прозада урын алуы исә, күп кенә кызыклы ачышлар ясарга, автор хакында, ул яшәгән чор, аның иҗаты турында фикер йөртергә мөмкинлек бирә. Галимҗан Ибраһимов та төсләрне белдергән сыйфатларны кулланып иҗат иткән. Язучының үзе турында белергә теләсәгез, аның әсәрләрен укыгыз. Чыннан да, язучы кулланган сүзләр аның уй-кичерешләрен, теләкләрен, иҗатындагы хисләрне тулырак ачып бирә.

Төс атамалары автор иҗат иткән дөнья сурәтенең аерылгысыз бер өлеше булып торалар. Дөньяны фәлсәфи һәм эстетик аңлау белән тыгыз бәйләнгәнлектән, төс кешелек мәдәниятендә һәрвакыт мөһим мәгънәгә ия. Төс атамалары, тел формасында матди билгеләнеп, билгеле бер тел моделе дә булып торалар.

Г. Ибраһимов әсәрләренең төсләр палитрасына ак, кара, яшел, сары, күк, кызыл сыйфатлары керүе билгеле булды. Галимҗан Ибраһимов ак һәм кара сыйфатларын бигрәк тә яратып куллана. Мәсәлән,

*Кояш болыт эчендә югалып, **ак** вә якты дөнья берьюлы караңгы, күңелсез хәлгә керде* («Яз башы»).

*Мин исем җыеп, күземне ачу белән, иң элек, әнине күрдем: аның күзләре яшьле һәм кызарган, **йөзе көлдәй ак** һәм тирән бер борчулы иде* («Яз башы»).

*Йокыдан яңа гына торып, олы **ак канатларын** мәгърур бер сыйфатта югары каерган җилкән...* («Диңгездә»).

*...аның йөрәге тыныч түгел, күзендә бик еш куркыну чыга, **йөзе агарына** иде* («Диңгездә»).

*Бу түрә – озын буйлы, калынрак гәүдәле, **ак сакаллы**...* («Йөз ел элек»).

*...**ак сакалым** белән әйтәм, ул мукшының биясен бөтенләй оялтыр* («Карак мулла»).

Г. Ибраһимов иҗатында диңгез, томан, бия күбрәк күк төскә буялган. Шуның белән әдип ясый торган сурәт тагын да матурланып, ачылып китә сыман. Мәсәлән:

*Җилкәннәрен зур кош канатлары кебек югары күтәреп каерган көймәбез, **күгелҗем шома диңгез** өстеннән көнбатыш ягына таба карап, акрын гына кузгала* («Диңгездә»). *...көймәбезнең киң **күгелҗем су өстеннән** җил астына таба бераз ава төшеп...* («Диңгездә»).

*...аларның өстенә чыккан **кара күк томан**, без диңгезнең эченәрәк киткән саен, калыная, ярны, андагы карачкыларны үзенә йота бара* («Диңгездә»).

*...акбуз **күк биядән** алга чыгарлык мал таба алмый...* («Карак мулла»).

Әсәрләренә бизәк өсти торган сыйфатлар арасында кызыл да бар. Автор байрак, утны тасвирлаганда, әлеге сүзне актив куллана. Мәсәлән:

*Без алга киткән саен, артыбыздагы шәһәр, лиман, андагы кораблар, манаралар, еpактан җилбердәп торган **аклы-кызыллы байраклар** җиргә бата баралар...* («Диңгездә»).

*Су өсте кояш баеганда була торган **кызыл ут** төсеннән...* («Диңгездә»).

Г. Ибраһимов яратып куллана торган төсләр арасында яшел дә бар. Яшел лексик берәмлеге үсемлекләр йә табигать образын тудырганда файдаланылгын. Мәсәлән:

*Инешнең ике ягына тезелгән таллар, **яшел яфракка** күмелеп, акрын гына, сак кына тавышлыйлар* («Яз башы»).

*Әнә, безнең алдыбызда – барачак юлыбызда киң **яшел ялан** белән биек һәм урманлы тау уртасында зур, түгәрәк сихерле күл ялтырый...* («Яз башы»).

*Дөнья әүвәлгечә матур, таулар, кырлар, урманнар элеккечә **яшел**, сандугачлар һаман өзлексез сайрамак-талар иде* («Яз башы»).

Үзенең хисләрен тагын да тирәнрәк ачу өчен, автор сары сыйфатын файдалана. Мәсәлән,

*Менә бер ягы **сары алтын төсенә** манылган зур күл* («Сөю – сәгадәт»).

*Шәрекъ ягы **кызгылт сары төсе** белән яна* («Диңгездә»).

*Бөтен тирә-ягын **кызыл сары утка** күмеп, су төбеннән олы кояш чыга* («Диңгездә»). Шунысы да игъ-тибарга лаек: автор саф сары төсне түгел, ә аның төс-мерләрен сайлаган.

Галимҗан Ибраһимовның яраткан төсе – кара.

*Кыш буена мәктәпнең тар бүлмәсендә, китаплар, **кара такталар** эчендә генә көн уздырган адәмгә, миңа, бу – яшьтән үк өсләрендә аунаган кырлар, яланнар, таулар аерым бер якынлык белән каршы алган кеби тоелалар* («Яз башы»).

*Кояш баешы ягыннан **кара куе болыт** чыгуы безне тагы борчый башлады* («Яз башы»).

*Бая ук кайтырга омтылган Гали: яхшы чакта кай-тып калыйк, малайлар, инеш ягыннан **кап-кара болыт** та күтәрелде, дип сөйләнә башлады; башкалар да: кайтыйк, малайлар, кайтыйк, дип, моны куәтләделәр* («Яз башы»).

*Аның күгендә заһир булган бу **кара болыт**, һаман зурая, зурая барып, ниһаять, Тимринең урлаша башла-вы ачык сөйләнә – шуның артыннан барып, мәсьәлә аның «указын алырга» тирәсенә җыела* («Карак мулла»).

*Тагы ныграк калыная да, **карала да төшеп**, безгә якына бара иде: җил чыгуы аңа тагы зур куәт бул-ды* («Яз башы»).

*...алар урынына адәмнең йөрәген еракка, төпкә, тирәнгә алып китә торган **куе караңгы, серле бер хәл** килә* («Диңгездә»).

***Һәммә нәрсә кара, караңгы**, җәйге, көзге төн-нәрдә генә була торган **калын, куе караңгылык** бөтен тирә-якны йоткан, диңгез, су, бөтен дөнья үзе шул гәү-дәләнгән **караңгылык төсле тоелалар*** («Диңгездә»).

*...**кара-сарыга**, бара торгач, **томанлы карага** әй-ләнде* («Диңгездә»).

*...үтә дә куркыныч **кара төн** булган усал кыш килә* («Уты сүнгән җәһәннәм»).

Әдип соры, җирән, шәмәхә, зәңгәр, ал төсләрен бер дә яратмый, шуңа күрә әлеге сыйфатлар иҗатында бик сирәк күзәтелә.

Шулай итеп, һәрбер телнең төсләрне сайлауда үз юлы булган кебек, әдипләрнең дә үз юлы, рухына, пси-хологиясенә, халәтенә туры китереп, төсләрне белдер-гән сыйфатларны файдалану ысулы бар. Әлеге катлау-лы процессларны аңлау, төшенү иҗат кешеләренең психологиясен аңларга, шуның белән милләтебезнең лингвомәдәни кыйммәтләрен ачыкларга, дөнья сурәтен тасвирларга ярдәм итәчәк.

ӘДӘБИЯТ

1. Ибраһимов Г. Сайланма әсәрләр / Г. Ибраһимов. – Казан: Таткнигоиздат, 1957. – 526 б.

2. Хаков В.Х. Тел һәм стиль мәсьәләләре / В. Х. Хаков. – Ка-зан: КДУ, 1961. – 160 б.

## Г. ИБРАҺИМОВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ РИЗЫК АТАМАЛАРЫ

***Р. С. Нурмөхәммәтова (Казан)***

В своих произведениях каждый писатель отражает определенную эпоху. Для этого он использует лексику, отражающую материальную и духовную культуру народа. Лексика материальной культуры татарского языка включает такие жизненно-важные лексико-тематические группы, как жилище, одежда, еда, орудия труда и т. д. Статья посвящается изучению названий еды и напитков в произведениях Г. Ибрагимова. Исследование проводится в русле новой лингвистической науки – лингвокультурологии.

Г. Ибраһимов үзеннән соң зур мирас калдырып киткән шәхес. Әдипнең әсәрләре әдәбият белгечләренең игътибарын үзенә күптәннән җәлеп итүе табигый: аның иҗатын өйрәнүгә күп кенә галимнәр өлеш керткән, шактый фәнни хезмәтләр язылган.

Г. Ибраһимов әсәрләре тел белгечләренең тикшере-нүләре өчен дә бай материал бирә, шунлыктан тел-челәрнең дә аның иҗатына әледән-әле әйләнеп кайтуы гаҗәп хәл түгел. Соңгы елларда тел белемендә бар-лыкка килгән һәм бүгенге көндә инде шактый уңыш-ларга ирешкән лингвокультурология фәне өчен дә Г. Ибраһимов әсәрләре кызыклы тикшеренү объектын тәшкил итә. Бу нисбәттән әлеге әсәрләрдә кулланылган ризык атамаларын барлау гыйбрәтле нәтиҗәләр ясарга мөмкинлек бирә.

Һәрбер язучы үзе яшәгән чорны тасвирлый, шун-лыктан әсәр тукымасына шул чорның колоритын, ул вакыттагы тәртипләрне, халыкның яшәү рәвешен, мат-ди хәлен, рухи дөньясын ачык чагылдырган күренеш-ләрнең, предметларның, вакыйгаларның кереп китүе гайре табигый саналмый. Г. Ибраһимов әсәрләрендә дә ул яшәгән заманның матди мәдәният лексикасы зур урын алып тора: халыкның көнкүрешен, гореф-гадәт-ләрен, яңа җәмгыять алып килгән үзгәрешләрне, яңача хуҗалык тәртибен һ. б. сурәтләгәндә ул телнең лексик байлыгын бөтен тулылыгы белән файдалана.

Ашау, ризык темасы теләсә кайсы тарихи үсеш этабында һәркем өчен актуаль тема санала, чөнки ул кешенең беренчел биологик ихтыяҗларын тәшкил итә. Шулай булуга карамастан, Г. Ибраһимов әсәрләрендә бу тематик төркемгә караган лексиканы артык күпсанлы дип әйтеп булмый. Бу аңлашыла да. XX йөз башы – әдипнең актив иҗат иткән чоры – Россия халкы өчен дә, татарлар өчен дә сынауларга шактый бай була.

Ашау-эчү әйберләренең байлыгы күзлегеннән карағанда да бу искиткеч авыр еллар: сугышлар, революцияләр, ачлык, җимереклек... Мондый шартларда ризык төрлелеге турында фикер йөртү мөмкин дә түгел. Димәк, Г. Ибраһимов, реалист-язучы буларак, моңа күз йома алмаган һәм аның әсәрләрендә ашамлык-эчемлек атамаларына ярлылык үзен аклый да. Язучы әсәрләрендә ризык атамалары күп булмауның сәбәбе тирәнрәк тә яшеренгән булырга мөмкин. Ач халыкка хыялдагы нигъмәтләр, сыйлар турында язу миһербансызлык, рәхимсезлек булыр иде. Шуңа күрә ул бу тематикага караган сүзләрдән аңлы рәвештә баш тарткандыр, аларны текстны матурлау, чынбарлыкның дөреслеген күрсәтү өчен генә берникадәр күләмдә куллануны кирәк тапкандыр.

Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы», «Кызыл чәчәкләр», «Тирән тамырлар» әсәрләрендә очраган ризык атамаларын барлап чыкканнан соң, аларны түбәндәге семантик төркемнәргә бүлеп карадык.

1. Азык-төлекне гомумиләштереп атаучы сүзләр: *аш, аш-су, нигъмәт, ризык, сый.* ***Аш*** сүзен Г. Ибраһимов гомумән ризык, ашау вакыты мәгънәләрендә куллана: Шуны ишеткәч, ашаганым *аш*, эчкәнем су булмады... («Кызыл чәчәкләр»). Көндезге *аш*ка таралып, кичке алтыда яңадан хөкем ачылгач, гаепләнүчеләрнең актык сүзләре башланды («Тирән тамырлар»).

***Аш-су*** табынга кую өчен хәзерләнгән ашамлык, сыйны белдерә: Яңа күрше Гайниәләр *аш-су* белән ярдәм иттеләр («Кызыл чәчәкләр»). Бергә гомер иткән, яхшылыгын, яманлыгын бергә кичергән, бергә *аш-су* күргән кешеләр онытыламыни? («Тирән тамырлар»).

***Сый*** – кунаклар чакырылганда, бәйрәмнәрдә әзерләнә торган затлырак ашамлык-эчемлек (2, 491): Ике коданың катнашы күп, *сый*лары уртак, уен-көлкеләре бергә бара («Казакъ кызы»).

***Нигъмәт*** һәм ***ризык*** – һәртөрле ашамлык, ризыклар җыелмасы: Ара-тирә байның кымызын эчәм, итен ашыйм икән – казакъ йорты үзенең бу *нигъмәт*ләрен далада каңгырып йөргән бичара нугай хәерчегә дә бирә түгелме?! («Казакъ кызы»). Үз бәхетеңне ашавың җитмәгән, инде минем балаларым *ризыг*ына тотынгансың икән!» – дип каһәрләп, мич буендагы кайчыны алып, Шаһбаз башына бәрә («Кызыл чәчәкләр»). Ашыйсы *ризыгы* бетмәс, башы исән булса, адәм баласы бер кайта икән... («Казакъ кызы»).

2. Итле ризык атамалары: *бөер, бөйрәк, җылкы казылыгы, ит, кабырга, казылык, куй башы, куырдак, тукты, ял.* ***Казылык*** – атның түш ите; эчәккә яки ясалма элпәгә тутырылып махсус эшләнгән ит фаршы (2, 222). Бу сүзнең «Казакъ кызы» әсәрендә аңлатмалы сүзлеккә теркәлгән ике мәгънәсе дә күзәтелә: Таныш булмасалар да, хөрмәтләп каршы алдылар, хуҗаның янына утыртып, туктының симезе, *җылкы казылыгы*ның майлысы белән кунак кылдылар (монда атның түш ите булырга мөмкин. – *Н. Р.*). Туктының симезен суйдырып, *казылык*ның, *ял*ның майлысын салсаң кирәк, – диде. Йортта кунак булгач, ит пешкәндер, *тукты*дан, *казылык*тан бер согынып килим, дип уйлады (соңгы мисалларда эчәккә тутырылган итне аңлатуы мөмкин. – *Н. Р.*). Әлеге мисалларда очраган *ял* һәм *тукты* сүзләренә дә тукталып китү урынлы булыр. Бу сүзләр «Казакъ кызы» әсәрендә еш очрый. Казакъ милли ризык атамасы буларак, «җал» ат муенының яллы җиренең өске өлешендәрәк тире астындагы майлы озынча кисәген аңлата, һәм ул хайванның әгъзалары арасында иң затлысы санала икән (1). Контекст буенча ***ял***ның шуңа туры килүен аңлыйбыз. ***Тукты*** – туудан алты айдан артыграк вакыт узган куй (сарык) бәрәне, безнең мисалда ул әлеге бәрәннең ите мәгънәсендә килгән.

«Казакъ кызы» әсәрендә ***ит*** сүзе дә күп очрый, чөнки далаларда яшәү рәвеше күчмә терлекчелек белән шөгыльләнер өчен җайлы булган, ит мондагы халыкның төп ризыгын тәшкил иткән: Казан янында азапланучы тукал табак тутырып *ит*не өлкән өйгә алып керде. Казакъның борынгы гадәте буенча, ул кунакка хөрмәт кылу тик кымыз һәм *ит* белән генә була дип карый...

3. Сөт-йомырка ризыклары: *йомырка, каймак, катык, корт, май, сөт, эремчек.* Бу сүзләрнең күбесе далада яшәүчеләрнең тормышын яктырткан «Казакъ кызы» әсәреннән табылды. Г. Ибраһимов ***йомырка*** сүзен нәкъ ризык атамасы буларак кулланмаган, контексттан күренгәнчә, ул әзер ашамлыкны аңлатмый: Куйчы карт Күчәрбай миңа үрдәк *йомырка*лары алып кайткан иде. Гөлчәчәк күз яше аша көлеп, шатланып, *йомырка*ларны алды да, кәләпүш ертыгын бармак очы белән генә тотып, ачык ишектән далага ыргытты. Бала теге *йомырка*лар белән булган иртәнге талашын сөйли башлады («Казакъ кызы»).

***Каймак*** – сөтнең өстенә җыела торган куе, майлы өлеше (2, 222): Тирмәнең сул ягында торган тәбәнәк шкафтан керле ашъяулык, сабы сынган чәйнек, ямаулы чынаяклар, берничә бавырсак салган бер тәрилкә алып, боларны кунак алдына китереп куйды, куе *каймак* салып, чәй ясый башлады. Вакыт соң булса да, килен коедан су китереп самавыр куйды, шүрлектән *каймак*, бавырсак алды, чынаяклар чыгарды («Казакъ кызы»).

***Май*** – хайван сөтеннән (сөт өстен, каймакны язып) алына торган туклыклы матдә: Ятим бозау асрасаң, авызың-борының *май* итәр, ятим бала асрасаң, авызың-борының кан итәр, дигән борынгылар... («Кызыл чәчәкләр»). Мин әнинең хәлен сорашып бетерергә өлгерә алмадым, яшьләр каяндыр *май*, *йомырка*, *сөт*, икмәк тә табып китерделәр («Кызыл чәчәкләр»).

***Эремчек, корт*** – сөттән әзерләнә торган ризык атамалары: Сарсымбайның казан янында *эремчек* кайнатып маташкан Айбалага йомшак тавыш белән: «Киленчәгем! Карлыгач-Сылуың тормаган булса кирәк, барып уятсаңчы!» – дигән сүзен ишеткәч, кызның йөрәге дерелдәп китте. Тукалның кушуы буенча, тирмәдән әле кибеп бетмәгән *корт*ларны кояшка чыгарды, элеккеләре белән янәшә өченче казанны куеп, астына тизәк ягып, берничә көн буенча җыелган сөттән *эремчек* кайната башлады («Казакъ кызы»).

4. Камыр һәм ипи-күмәч ризыклары: *бавырсак, бәлеш, җәймә, икмәк, клиндер, күмәч, нан, прәннек, сохари.* ***Бавырсак*** – чикләвек зурлыгында ваклап, майда кайнатып пешерелә торган милли камыр ризыгы (2, 64): Ул <…> самавыр, чәй, *бавырсак* кебек начар бидгатьләрне эшкә санамый иде («Казакъ кызы»).

***Бәлеш*** – эченә төрле ашамлыклар (ит, яшелчә, җиләк-җимеш һ.б.) салып, мичтә табада пешерелгән камыр ашы (2, 102): Бер көнне шулай кечкенә *бәлеш*ләр пешергән дә ике баласына икене тоттырган. Гали белән Фазыйл өйләреннән ак күмәч кисәкләре, *бәлеш* калдыклары чыгарып бирделәр («Кызыл чәчәкләр»).

***Икмәк катысы*** аңлатмалы сүзлектә «икмәкнең тышындагы каты катлавы» дип бирелә (2, 178). Әсәрдә ул каткан ипи мәгънәсендә кулланылган: Юынмадым, чәй-фәлән сорап тормадым, бер сынык *икмәк катысы* белән санап куйган чылгыйларымны алдым да тышка йөгердем («Кызыл чәчәкләр»).

***Сохари*** – махсус киптерелгән икмәк кисәкләре: Мин исән-сау, ди; *сохари* җибәрегез, ди; үзем балта эшенә керештем, ди («Кызыл чәчәкләр»).

***Күмәч*** – май, йомырка, шикәр кушып, камыр басып пешерелгән ашамлык; ак оннан пешерелгән икмәк (2, 331): Бу вакыт теге базарчылар симез ит пешертәләрдер, *ак күмәч* ашыйлардыр, – ә безгә нәрсә? («Кызыл чәчәкләр»). Кәрәзле бал белән *ак күмәч* куйды («Тирән тамырлар»).

***Прәннек*** – балга, бәрәңге балына яки шикәр сиробына катырылган һәм төрле аш тәмләткечләр салып пешерелгән баллы вак күмәч (2, 556); ***клиндер*** – гадәттә төче камырдан боҗрасыман итеп пешерелгән күмәч (2, 263): Без һәммәсенә капка ачабыз; күбесе безгә ярты конфетмы, *прәннек*ме, каткан *клиндер* кисәгеме ташлап китә («Кызыл чәчәкләр»).

5. Чәй ризыклары: *бал, кәрәзле бал, конфет, шикәр.* ***Бал*** – бал кортлары чәчәк нектарыннан җыеп ясаган куе, татлы, авыр сыеклык (2, 68): *Бал*-май үземдә күп була... («Кызыл чәчәкләр»). ***Кәрәзле бал*** – кәрәзе белән алынган бал (2, 317): *Кәрәзле бал* белән ак күмәч куйды («Тирән тамырлар»).

***Конфет*** – кечерәк шарчык, мендәрчек, озынча һ. б. формалардагы баллы-шикәрле кондитер ашамлыгы (2, 278): Аның күз төбе шешеп чыкты, күп *конфет* ашаудан черегән тешләреннән кан китте («Кызыл чәчәкләр»). Арыслан аның башыннан сыйпап йөзеннән сөйде дә, кулындагы ашыкларын карап, кайдан алуын сорашып, ике *конфет* бирде («Казакъ кызы»).

***Шикәр*** – чөгендер яки камышның махсус төрләреннән алына торган ак төстәге вак кристаллардан гыйбарәт татлы азык продукты (2, 683): Көндездән калган ике бәрәңгене тозлап ашыйм, сөтсез, *шикәр*сез бер чынаяк чәй эчәм дә, читән өебезнең ишегалдына чыгып, әткәйнең чикмәненә уралып, җир идәнгә йокларга ятам («Кызыл чәчәкләр»).

6. Яшелчә, җиләк-җимеш: *бәрәңге, җиләк, җимеш, кавын, карбыз, кәбестә, кишер, кыяр, суган, торма, чөгендер.* Түбәндәге мисаллар барысы да «Кызыл чәчәкләр» әсәреннән алынды: Әнкәй аңа бер *бәрәңге*, бер сынык икмәк бирде, кем икәнен сорашты. Гайния җыеп кайткан *җиләк*ләр белән тәмләп чәй эчтек... Өй буенда бакча: анда *җимеш*ләр пешә... Ындырда бәрәңге бакчасы, анда *кыяр, карбыз, кавын, торма, чөгендер, кишер, кәбестә* – җаныңа ни кирәк, һәммәсе бар... Күп вакыт үтмәде, тегеннән, чаршау астыннан, Гайниякәйнең ак кулы безгә зур бер тәлинкә белән әйбәтләп киселгән икмәк, әрчеп туралган *суган*, байтак ук салкын ит суzды.

7. Ярмадан әзерләнгән ашамлыклар Г. Ибраһимовның карап үтелгән әсәрләрендә күп түгел: «Казакъ кызы» әсәрендә *кужә* сүзе очрады. Татар телендә ул киптергән бодайны киледә төеп яки башка юл белән ваклап, ваклаганнан соң казанда яки чуенда кайнатып пешерелгән сыек ботка атамасы. Ә әсәрдәге мәгънәсе берникадәр аерыла: Карт, кулына бер-ике тамчы су салып, керле сөлгегә сөртте дә, агач савыт белән бирелгән куе *кужә*не – пешереп киптерелгән тары ярмасын ашап, кечкенә күн турсыкка салынган әйрәнне алып, йортка чыкты.

8. Эчемлек исемнәре: *әйрән, кымыз, чәй, кызылбаш, аракы, сыра.* Бу атамалар арасында исерткеч һәм исерткеч булмаган эчемлекләр бар. Иң элек алкогольсез эчемлекләрне карап үтик. ***Әйрән*** – катыкны суга болгатып ясалган эчемлек (2, 745), ул сусаганда әйбәт, шуңа күрә аны күбрәк җәен әзерләгәннәр һәм салкын килеш эчкәннәр: Әбкәем, бик харап сусадым. Бозлы *әйрән*ең юкмы? («Кызыл чәчәкләр»).

***Чәй***не татарлар бик күптәннән куллана башлаганнар. Кайчак чәй янына төрле ризыклар куелган һәм ул аерым ашауны алыштырган. Әсәрләрдә бу үзенчәлекләр ачык күренә: Ул кергәндә Сарсымбай түгәрәк тирмәнең түрендә *чәй* эчеп утыра иде («Казакъ кызы»). Гайшә самавыры, табасы тирәсендә маташа биреп, өстәлгә *чәй* әзерли-әзерли, каланы сөйли башлады («Тирән тамырлар»). Аннан соң бер чынаяк бик каты *чәй* бирәләр дә, Гыйлаҗи аны тышка, һавага алып чыгып кирә («Кызыл чәчәкләр»).

***Кымыз*** – бия, дөя яки кәҗә сөтеннән әчетеп ясалган эчемлек (2, 306). Кымызны казакъ һәм монгол далаларында яшәүче борынгы кабиләләр иң беренче ясый башлаган. Күчмә халыклар аны ясау технологиясен сер итеп саклаганнар. Ул казакъ, кыргыз халкында аеруча популяр эчемлек саналган. Шуңа күрә бу сүз «Казакъ кызы» әсәрендә бик күп очрый (80 чамасы): *Кымыз*ның мул чагы, туктыларның симез заманы, йөгерекләрнең дә дер кайнап йөрәк суккан вакытлары иде. Зиннәтле зур, бай тирмәнең ишеге төбендәге сабадагы *кымыз*ны пешкәк белән шапырып тора иде. Борынгы кодагыз гаепләп китмәсен: туктының симезен суегыз, *кымыз*ны мул китерегез, – диде. Ишек ачылды, зур чаган табак белән *кымыз* күтәреп тукал керде («Казакъ кызы»).

***Аракы*** – спиртлы исерткеч эчемлек (2, 44): Аңа *аракы* дип су эчерәләр («Кызыл чәчәкләр»). ***Кызылбаш*** сүзе әсәрдә шулай ук исерткечне белдерә: Менә сезгә алтын шахтасы янында ясалганнан бер *кызылбаш!* («Кызыл чәчәкләр»). ***Сыра*** – арпа салатыннан ясала торган җиңелчә исерткеч эчемлек (2, 494): Кооператив тапшырган эшләреннән бушаган араларда, Җамали абзый: «Бусы *сыра*лык булыр!» – дип, иске киемнәрне ямый, өр-яңа кебек иткәнче өтели дә сатарга алып чыга иде («Тирән тамырлар»)

Г. Ибраһимов әсәрләрен тикшереп чыкканнан соң, түбәндәге нәтиҗәне ясарга мөмкин: башка матди мәдәният элементлары (кием-салым, торак һ. б.) белән чагыштырганда, аларда ризык атамалары әллә ни күп түгел. Шулай да бу сүзләр буенча әсәрләрдә сурәтләнгән чорда, төбәктә халыкның нинди ризыкларга өстенлек бирүен ачыкларга була. Бу исә этнографик, лингвокультурологик эзләнүләр өчен нигезле мәгълүмат бирә.

## ӘДӘБИЯТ


1. Ахметова Ш. К. Пища казахов Западной Сибири: традиции и новации. – [Электронный ресурс]. – Режим доступа: kyrgyz.ru

2. ТТАС – Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Матбугат йорты, 2005. – 848 б.

3. kitap.net.ru



*Мәкалә 11-14-16029а/В номерлы РГНФ гранты кысаларында язылды.*

# Г. ИБРАҺИМОВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ САВЫТ-САБА АТАМАЛАРЫ

***Г. Хөснуллина (Казан)***

Данная статья посвящена рассмотрению употребления лексики кухонной утвари (посуды) в произведениях Г. Ибрагимова.

Г. Ибраһимовның 1907 елда беренче хикәясе басылгач ук, Ф. Әмирхан: «Менә бу – безнең татар әдәбиятының киләчәге! Менә монда талант чаткылары күренеп тора. Менә бу безгә әле калын-калын милли романнар да бирәчәк», – дигән. Күргәнебезчә, ул ялгышмаган, әдипкә дөрес бәя биргән, чөнки Г. Ибраһимов – гомере белән дә, иҗаты белән дә үрнәк, зирәк акыллы кеше, киң колачлы язучы. Гасырлар узгач та, ул иҗат иткән әсәрләрнең популярлыгы кимеми, әдипнең сөйләм матурлыгы көннән-көн шаккаттыра, әсәрләрнең теле төрле сурәтләү чараларына, төрле катлам сүзләренә бай булуын күрергә була.

Г. Ибраһимов әсәрләрендәге лексик байлыкны берьюлы колачлау мөмкин түгел. Бу мәкаләдә язучы әсәрләрендә кулланылган савыт-саба атамаларын тикшерү күздә тотыла. Моның өчен Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы» романы һәм берничә хикәясе каралды.

Г. Ибраһимов әсәрләреннән алынган мисаллардагы савыт-саба атамаларын түбәндәгечә төркемләп була:

1) аш-су әзерләү һәм аны саклау, йөртү-ташу өчен кулланыла торган савыт-саба атамалары;

2) ризыкны табынга бирү өчен кулланыла торган савыт-саба атамалары.

Аш-су әзерләү һәм аны саклау, йөртү-ташу өчен кулланыла торган савыт-саба атамалары: *казан, пешкәк, кисмәк, табагач, пычак, пәке* һ. б.

*Шуның алдында гына тукалның ак урамал сарган башы, **казан** астындагы утның ялкыны күренә. Казан* – аш пешерү, су кайнату өчен кулланыла торган төбе ярым түгәрәк яки башка шәкелдәге металл савыт (3, 221). Р. Әхмәтьянов исә әлеге сүзнең килеп чыгышын болайрак аңлата: «казан (котел), түгәрәк чокыр» сүзеннән, каргь тамырыннан (тамыр мәгънәсе ачык түгел), ди (2, 86).

*Зиннәтле, зур, бай тирмәнең ишеге төбендәге **саба**дагы кымызны **пешкәк** белән шапырып тора иде. Саба* – тире яки күннән кечкенә капчыкка охшатып эшләгән савыт; турсык (су, кымыз кебек нәрсә салып йөртелә) (3, 456). Р. Әхмәтьянов *саба* атамасының «тире капчык, тырыс, мичкә, савыт, чүлмәк, тәлинкә» мәгънәләрен дә үз эченә алуын күрсәтә (2, 165). *Пешкәк* – таяк башына беркетелгән тишекле түгәрәк такта кисәгеннән гыйбарәт, гөбедә май атлый торган корал (3, 415).

*Ялчы хатын **чиләге**н **мичкә**нең авызына тыкты да атлар-атламас барган үгезне куалый-куалый күлгә китте. Чиләк* – су яки башка сыек яки бөртекле нәрсәләр салу өчен асылма тоткалы озынча савыт (3, 653). Әлеге сүзнең башка телләрдәге мәгънәләре аның башта куыш агачны белдергәнлегенә ишарә ясыйлар, дип аңлата Р. Әхмәтьянов (2, 234). *Мичкә* – ике башы да яссы төпле, цилиндр формасындагы яки кабарынкы корсаклы тимердән яки тар гына такталарны коршаулап эшләнгән зур савыт, кисмәк (3, 368). *Мичкә* (бочка) – рус теленә дә татар теленнән кергән сүз булырга мөмкин (2, 145).

*Юныс карт, алдына табак килүгә, кесәсеннән бер каеш тартма чыгарды, аннан агач саплы кечкенә **пычак** алып, тимер табакның читенә берничә ышкыды да, биргәненә шөкер дип, иткә тотынды. Пычак* – кисү, турау өчен бер башына сап куелган, үткен яссы металл кисәге (3, 435). Р. Әхмәтьянов сүзне гомумтөркиләрнең пычак // бычак, ә борынгы төркиләрдә *быччак* «кисә торган нәрсә» дигәннән килеп чыккан дип билгели (2, 165).

*Байның икенче ягындагы чәчле сәүдәгәр җегет тә кесәсеннән **пәке** чыгарып турарга тотынды, башкалар тураганны ашарга керештеләр. Пәке* – сабына бөкләнеп кертелә торган кечкенә пычак (3, 436).

*Шуңардан ерак түгел бик зур бер **кисмәк** янында, буй-буй ялтырап торган кыйммәтле бохара бикасабы киеп, бер хатын алачык янындагы зур казанда сары май кайната. Кисмәк* – такта кисәкләреннән коршаулап яки агачтан кисеп (уеп) ясалган савыт (3, 257). Р. Әхмәтьянов исә әлеге сүзне «*кис-у* сүзеннән булса кирәк» дип кенә аңлата (2, 108).

*Болай кинәт кагылсак, башкорт агай **табагач**ын алыр да: «Сез әллә ниткән намәләр икәнсез», – дип куып чыгарыр. Табагач* – 1) Кызган табаны горизонталь хәлдә тотып күчереп йөртү өчен әсбап; гадәттә, агач саплы тимер эләктергеч; 2) Савыт-сабаның озын агач тоткасы, сабы (3, 503).

*Биш минут эчендә читәне белән бөтен **кәрзин**не өстерәп кайтты. **Самовар (самавыр*** варианты да шактый күп очрады***)**, чәй, бушаган кымыз **уҗау**лары алынып, алар урынына ачылган пиво бутылкалары белән стаканнар килде. Кәрзин* – берәр нәрсәне салып йөртү яки саклау өчен чыбыктан, камыштан, юка дранчадан һ.б.ш. үреп ясалган савыт (3, 317). Этимологик сүзлектә «борынгы рус теленнән корзать “үрү, ишү” дән алынган» дип әйтелә (2, 99). *Самавыр* – үзәктәге утлыгына күмер яки йомычка ягып чәй кайната торган чиләк сыман ябык металл савыт (3, 462). *Уҗау – диал.* Аш чүмече (3, 617).

Мисал итеп китерелгән савыт-сабаларның кайберләре үзенчәлекле атамалары белән, ә кайберләре куллану ешлыгы белән аерылалар. Мәсәлән, бериш савыт-саба атамалары әсәр дәвамында бер генә очраса, икенчеләре исә еш очрый. Боларга *самавыр, казан, пычак* кебекләрне кертергә була.

Икенче төркемне тәшкил иткән – ризыкны табынга бирү өчен кулланыла торган савыт-саба атамаларын карап китик.

*Өлкән өйдә, **табак** күренү белән булса кирәк, тавышлар, көлкеләр берьюлы басылды. Табак* – зур түгәрәк һәм чагыштырмача сай савыт (3, 503). Этимологик сүзлектә дә «гарәп-фарсы теленнән чыккан сүз, «табак (савыт)» мәгънәсен белдерә» дип бирелгән (2, 186).

*Азымбай чал, кымызны эчеп, **савыт**ны бикәгә бирде... Савыт* – 1) Чәчелә яки түгелә торган һ. б. ш. нәрсәләрне салып саклау-йөртү әсбабы, әйбере; 2) Ашсу салып йөртә торган тәлинкә (3, 457). Р. Әхмәтьянов «савыт, кием, кипрән (оболочка)» сүзеннән дип тә, «металлдан коелган нәрсә» сүзенең күплек формасы дип тә аңлата (2, 166).

*...сабы сынган **чәйнек**, ямаулы **чынаяк**лар, берничә бавырсак салган бер **тәрилкә** алып, боларны кунак алдына китереп куйды, куе каймак салып, чәй ясый башлады. Чәйнек* – чәй пешерү, парлау өчен махсус ясалган тоткалы борынлы савыт (3, 667). *Чынаяк* – фарфор яки фаянс савыт (3, 664). Борынгы татар телендәге чини айак «кытай савыты» сүзеннән диелгән (2, 244). *Тәрилкә* – (рус теленнән кергән тәлинкә сүзенең сөйләмдәге формасы) кырыйлары бераз күтәрелеп торган җәйпәк савыт (3, 580).

*Карлыгач, теге өйдән **аяк**ларны алырга дип чыгып, тукалны күрде. Аяк (иск.)* – чәй чынаягы яки шуңа охшашлы савыт, касә; гомумән, савыт (3, 62). Р. Әхмәтьянов сүзне гомумтөркиләрнең айак «савыт, чиләк, чүлмәк», ә борынгы төркиләрдә аҥак «авыз, тишек, кушлык, чүлмәк» дигәннән килә дип билгели (2, 25).

*Бикә кечкенә **турсык**ка кымыз салдырды... Турсык* – сөт, кымыз һ. б. ш. сыеклыклар өчен тар авызлы капчык сыман зур күн савыт (3, 567). Борынгыдан торс, торус «агач орысы, шуннан ясалган савыт, ат аягы тиресеннән ясалган савыт» сүзеннән (2, 213).

***Стакан**нар туктаусыз шыкылдыйлар, **бутылка**лар кәрзиннән сәкегә менә, тиз арада бушап, мич астына тәгәри торалар. Стакан* – чәй, су эчү, сыеклык алу-салу өчен кулланыла торган, нигездә, цилиндр формалы, сапсыз, үтә күренмәле пыяла, бәллүр һ. б. ш. материалдан эшләнгән савыт (3, 481). *Бутылка* – шешә сүзенең сөйләм телендәге атамасы. Шешә дигәндә пыяла савыт кына күз уңында тотылса, бутылка атамасы эченә пыяладан булмаганнары да кертеп карала.

*Гөнаһ шомлыгына каршы, юлдашым уянды да, кызарган күзләре белән бер миңа, бер бушаган **шешә**ләргә карап... Шешә* – сыекчалар салу өчен тар бугазлы пыяла савыт (3, 682). Фарсы теленнән шиша, шуша «шешә, стакан, пыяла» сүзеннән таралган сүз (2, 249).

Савыт-саба атамалары ризык атамалары белән һәрвакыт диярлек янәшә йөриләр, шуңа күрә савыт-саба атамалары да әсәрләргә еш килеп керә дияргә мөмкин. Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы» романында төрле йолалар белән бәйле ризыклар күп очрый, шуңа күрә алар янәшәсендә савыт-саба атамалары да шактый урын алган.

Г. Ибраһимов иҗаты милли әдәбиятыбызның, мәдәниятебезнең барлык тармакларына диярлек көчле, тирән йогынты ясый. Илебездәге төрки телле халыкларның әдәбиятын үстерүдә дә тирән, нәтиҗәле, бәрәкәтле эз калдыра.

ӘДӘБИЯТ

1. Ибраһимов Г. Г. Хикәяләр, повесть, роман / Галимҗан Ибраһимов; төз. Р. Акъегет. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 463 б.

2. Әхмәтьянов Р. Г. Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге / Р. Г. Әхмәтьянов. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – 272 б.

3. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге. – Казан: Матбугат йорты, 2005. – 848 б.

## Г. ИБРАҺИМОВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ЭКСПРЕССИВЛЫКНЫ БЕЛДЕРҮЧЕ ЧАРА БУЛАРАК КУЛЛАНЫЛГАН ӨСТӘЛМӘЛӘРНЕҢ МӘГЪНӘ ТӨСМЕРЛӘРЕ

***Л. Р. Мирсиапова (Алабуга )***

В данной статье проводится анализ некоторых смысловых разновидностей, а также экспрессивных функций присоединительных конструкций в произведениях Г. Ибрагимова. В начале XX века именно Г. Ибрагимов начал использовать разнообразные смысловые виды этих конструкций, хотя в это время эти явления в синтаксисе еще не упоминались. Поэтому в настоящее время изучение первоначальных форм присоединительных конструкций очень актуально.

Күренекле әдип, галим һәм җәмәгать эшлеклесе Г. Ибраһимов телдән файдалануга, андагы чараларны куллануга бик таләпчән була. Аның әсәрләрендә нәфис сөйләм тиешле эмоциональ югарылыкта. Һәр язучы тел хәзинәсеннән үзенчә файдалана. Ул сүзләрне сайлап алуда, тел сурәтләү чараларын үзенчәлекле итеп куллануда һәм җөмлә төзелешенең бирелешендә күренә. Г. Ибраһимов, мәсәлән, бер үк мәгънәне бирү өчен төрле лексик-стилистик һәм фразеологик чараларны эшкә җигә, халыкның җанлы сөйләмен әдәби калыпка салып, күңелгә үтеп керерлек, тирән тойгылар уятырлык әдәби әсәрләр тудыра. Әдип әзер җөмләгә хәзерге вакытта синтаксиста өстәлмәләр дип аталучы яңа бер сүз яисә сүзләр тезмәсен китереп өстәп, сөйләм яңалыгын барлыкка китерүдә зур уңыш казана. Мондый төзелмәләрне кулланып ул җанлы сөйләмнең табигыйлеген, самимилеген, тәэсир көчен арттыра.

Сөйләм телен әдәби әсәргә бөтен үзенчәлекләре белән алып керүдә Г. Ибраһимов бу алымны яратып куллана. Аның синтаксисында ул характерлы үзенчәлек буларак аерылып тормаса да, нәкъ менә шушы әдиптә аның активлашу мөмкинлекләре күренә башлый (1, 112): Коридорда унсигез камера бар. Дүртесе Баязитныкы кебек тар, кечкенәләр. *Ялгыз утыручылар өчен* («Безнең көннәр»).

Г. Ибраһимов әсәрләрендә кулланылган өстәлмәләрне, җөмләдә нинди мәгънә төсмере белдерүенә карап, түбәндәге төрләргә бүлеп карарга мөмкин.

1. Беренче җөмләдәге яисә үткәндә өзелеп калган фикер дәвам иттерелә: Аяксыз, кулсыз булып кайтсаң да, син минеке. Башкаларга күзем дә төшми. *Күңелем дә* («Кызыл чәчәкләр»); Яратам мин үзебезнең авылны. Авылның төньягын каплаган зур тауларны («Алмачуар».

2. Әйтелгән фикернең билгесен ачыклау нияте белән кулланылган өстәлмәләр: Гаҗәеп бай бүлмә. *Китаплар, гәзитләр белән тулы* («Кызыл чәчәкләр»); Утыз сумга Садыйк байның бер келәтен алдык. Зур гына, *иркен генә* («Кызыл чәчәкләр»).

Кайвакыт теге яки бу фикернең билгесен ачыклаучы мондый өстәлмәләр бер-бер артлы килеп исемлә-

шәләр: Бүген сабан туе. Андый-мондый гына түгел. *Тирә-якта бик сирәк була торган. Бик зурысы, бик шәбе* («Алмачуар»).

Өстәлмә конструкцияләр үзара тиңдәшләнеп тә киләләр: Явыз киленем көчләгәч, авылга икмәккә барганымны да әйтермен. *Акташ фетнәсен дә, мужикларның котырганын да* («Тирән тамырлар»).

3. Өстәлмәдәге сүзләр тагын да ныграк ышандыру өчен кулланылалар: Менә монысы чын дөресе! *Чыннан да* («Кызыл чәчәкләр»).

4. Нинди дә булса бер фикергә каршы мәгънәдәге өстәлмәләр. Әлеге өстәлмәләр еш кына антоним сүзләр һәм каршы куючы теркәгечләр белән белдереләләр: Сафа картның да биш кенә бәбкәле бер казы бар икән. Аларның бәбкәләре зуррак. *Ләкин ямьсезрәк* («Алмачуар»); атасы Акташта крестьян. Ярлы. *Ләкин каты йөрәкле* («Тирән тамырлар»).

5. Охшату-чагыштыру мәгънәсен белдерүче өстәлмәләр: Охшыйлар шул, балам... бар да охшыйлар. *Ике тамчы су кебек*. Хәзрәт тә охшый. Коеп куйган кебек («Тирән тамырлар»).

6. Киләчәккә ышаныч, өмет белән карауны белдерүче өстәлмәләр: Сентябрьдә китәм. Язгы сабанга кайтып җитәрмен. *Насыйп булса* («Кызыл чәчәкләр»).

7. Теге яки бу әйбернең күләменә игътибар юнәлдерү кирәк булганда, еш кына бу сүзләр өстәлмә составына кертеп карала: Әткәйнең күздән чыгарып калдырган ташы бар икән! *Алты сажень*! («Кызыл чәчәкләр»); Мылтыклы кеше атның камытын кисеп җибәргәч, Николай патша акчалары коелып төшкәнен дә сөйләрмен. *Барын-барын да. Инәсеннән җебенәчә* («Тирән тамырлар»).

8. Өстәмә хәбәр биреп, хәбәрне тагын да конкретлаштыру максатыннан кулланылган өстәлмәләр: Ләкин ул бирешми, һаман дулый. *Тыпырчына, кизәнә* («Казакъ кызы»); Шулай да аңардан куркалар. *Карулашмыйлар* («Тирән тамырлар»).

9. Кире хәл мәгънәсен белдерүче өстәлмәләр: Ул Мөгаллим Хәбип – эт ул! *Коммун булмаса да* («Тирән тамырлар»).

Шуны да онытмаска кирәк: XX йөз башларында нәкъ менә Г. Ибраһимов тарафыннан актив кулланыла башлаган, сөйләмнең экспрессивлыгын арттыручы, мәгънәне калкуландыручы әлеге өстәлмәләр хәзерге вакытта матур әдәбият, публицистика телендә әһәмиятле стилистик чарага әйләнделәр. Бу алым инде хәзер язучылар, шагыйрьләр, журналистлар тарафыннан аңлы рәвештә, синтаксик экспрессия чарасы буларак кулланыла. Ә бу исә Г. Ибраһимовның чын әдәби тел остасы булу белән бергә, татар тел гыйлемен үстерүдә зур сәләтле, киң эрудицияле галим икәнлегенә тагын бер тапкыр ышандыра.

ӘДӘБИЯТ

1. Сафиуллина Ф. С. Татар телендә сүз тәртибе. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. – Б. 109–112.

## Г. ИБРАҺИМОВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ АТАУ ҖӨМЛӘЛӘР

***Г. Ә. Нәбиуллина (Казан)***

В статье рассматриваются стилистические особенности номинативных предложений в языке произведений Г. Ибрагимова. Писатель был новатором в использовании отдельных языковых средств, впервые показавшим таящиеся в них богатейшие возможности в передаче впечатлений об окружающем мире.

Г. Ибраһимов, бер яктан, милли прозаның идея-тематик колачын киңәйтеп, аңа яңа сулыш бирсә, икенче яктан, әдәби телне яңадан-яңа сурәтләү чаралары, поэтик-синтаксик алымнар, стилистик фигуралар белән баетып, татар теленең мөмкинлекләрен, байлыгын проза өлкәсендә яңа биеклеккә күтәрә.

Г. Ибраһимов прозасына хас аһәңлелек, камиллек, нәфислек, лиризм һәм романтик рух, иң беренче чиратта, язучының хикәяләү осталыгына бәйле. Г. Ибраһимовның теле, әсәрләренең тел-стиль үзенчәлекләре, әдип буларак осталыгы турында фәнни әдәбиятта күп язылды. Безнең максат Г. Ибраһимов әсәрләренең структур-синтаксик оешуында, пейзаж, портрет микротекстларының формалашуында мөһим роль уйнаган атау җөмләләрнең кулланылыш үзенчәлекләрен ачарга омтылыш ясаудан гыйбарәт.

Г. Ибраһимов әсәрләрендә бер составлы җөмләләрнең гаять бай структур-семантик төрләре кулланыла. Язучы бигрәк тә атау җөмләләрнең стилистик мөмкинлекләрен гаять урынлы файдалана.

Г. Ибраһимов әсәрләрендә пейзаж, портрет, психологизм микротекстлары еш кына атау җөмләләләрдән торган хикәяләү нигезендә туа. Язучы атау җөмләләрне аеруча пейзаж тасвирлауда яратып куллана. Мәсәлән, *Җылы яңгыр. Якты кояш. Ни күрим: бер атнадан матур сабаклар, яшел яфраклар чыкты; җәй көне аллы-гөлле кызыл чәчәкләр бөтен бакчама ямь бирде; көз көне энҗе-мәрҗән бөртекләре кебек тигез, матур кызыл орлыклар җыеп алдым* (VI том). Күренгәнчә, пейзаж текстының атау җөмләләр белән башланып китүе әсәргә тәэсирле башлангыч бирәләр. Бу төр башлам җөмләләрдә төп мәгънә туплана, аның артыннан килгән җөмләләр атау җөмләләрдә бирелгән фикерне, күренешне төрле яклап ачыклыйлар.

Г. Ибраһимов әсәрләрендә атау җөмләләр сурәт, образ тудыралар, предмет-күренешләрне атыйлар, хикәяләүгә яңа күренешләр, затлар, предметлар кертәләр. Алар хис-тойгылар, эмоцияләр белән үрелеп баралар, хикәяләүне җанландырып, аны тагын да ачыграк итәләр, сурәтләргә, төсләргә баеталар.

Автор билгеле бер обстановканы төгәл, җыйнак, аһәңле итеп укучыга җиткерүдә дә еш кына атау җөмләләрдән файдалана. Обстановканы нечкәлек белән тасвирлауда атау җөмләләр еш кына *әнә*, *менә* сүзләре белән баетыла. Мәсәлән, *Менә нинди әйбәт ак бина... Көндезге кояш вакытында аның эче җылы йомшак нур белән тула...* (V том). *Әнә урамга ике яклап тезелгән кечкенә авыл... Менә салам түбәле өйләр... Әнә капка*

*төбендә куелган урак машинасы канатларын күтәреп тора* (VI том). Биредә *әнә*, *менә* сүзләре төбәп әйтү, күрсәтү төсмере өстиләр. Автор, әйтерсең, сөйләү моментында күз алдында тотылган, каршыда булган предмет-күренешләрне күрсәтеп сөйли.

Г. Ибраһимов геройларның портретын тасвирлауда, һәркайсын кабатланмас итеп сурәтләүдә атау җөмләләр чылбырыннан файдалана. Портретның бөтен барлыгын, тулылыгын нечкәләп, детальләп сурәтләүдә, әһәмиятле күренешне ассызыклауда атау җөмләләр уңышлы файдаланыла. Атау җөмләләрнең кыска, җыйнак булуы мәгънәне тыгыз итеп бирергә ярдәм итә, сөйләмне, хикәяләүне бизәкләргә, төсләргә баета. *Кыска буйлы, ябык гәүдәле, кәҗә сакаллы, азрак кылый күзле бер карт иде. Өстендә иске җилән, аны билдән буган. Башында чите камалы мескен бүрек, аягында оекчабата* (VIII том); *Аягында зур итек. Өстендә кара чикмән. Башында кара эшләпә. Кулында ике телле шәп гармун. Менә Шәйхел шулай юньсезләнеп кайтып төште* (V том ). *Ябык, чандыр гәүдәле, эчке хәйләкәр күзле, җиңел кузгалышлы бер карт иде. Ияге очланып килгән, яңак сөякләренең югары ягы тышка бәреп тора, берничә бөртек чал сакалы җемелди. Үзе ничек җитез* (VI том). Күренгәнчә, тулы бер абзац атау җөмләләр чылбырыннан тора. Сегментланган кисәкләр, аерым сүз-сурәтләр аша укучының күз алдына тирән мәгънә, образ, хәрәкәт килеп баса. Портретны сурәтләүче атау җөмләләр укучының фикерләү, күзаллау сәләтен арттыралар, төсләргә, фантазиягә баеталар.

Атау җөмләләр, составында бәяләү төсмерен белдерүче *нинди*, *ничаклы*, *шулкадәр* сүзләре килеп, психологик портрет тудыруга хезмәт итәләр. Мәсәлән, *Караңгылана. Тирә-якта тын. Шулкадәр рәхәт!* (VI том); *Күтәрелеп, диңгезгә бер каравым белән, күңелем ачылып, җаным канатланып ук китте. Йа ходам! Һава ни дәрәҗәдә саф! Ничаклы матурлык!* (V том). Табигатьнең аерым күренешләре детальләп сурәтләнә. Мондый җөмләләр геройның рухи халәтен, эмоциональ кичерешләрен белдерү чарасына әвереләләр, табигать күренешләре аша психологизм тудырыла.

ӘДӘБИЯТ

1. Ибраһимов Г. Әсәрләр: 8 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974–1987.

# Г. ИБРАҺИМОВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ПАРЛЫ ИСЕМНӘР
## («Диңгездә» һәм «Яз башы» хикәяләре мисалында)

***И. И. Сабитова (Казан)***

В статье рассматриваются пути образования и структура парных имён существительных в произведениях Г. Ибрагимова. Среди парных слов в лексике Г. Ибрагимова по численности преобладают парные имена. Они образованы по типу *существительное + существительное,* по моделям *существительное в основной форме + существительное в основной форме* и *притяжательная форма существительного на -е + существительное на -е.* Особенно продуктивной оказалась модель *существительное в основной форме + существительное в основной форме*. По семантической структуре парные слова образуют шесть групп.

Татар тел белемендә парлы сүзләр турында беренче мәгълүмат К. Насыйри хезмәтләрендә күренә. Ул аларның берничә төрен күрсәтә һәм шактый тулы исемләгән бирә. Г. Алпаров кушма сүзләр белән беррәттән парлы сүзләргә дә игътибар итә. Ул аларны семантик һәм фонетик принциплардан чыгып төркемли. Кабатлаулы парлы сүзләрне «кабатлау кушмалар» дип атап, аларның үзенчәлекләрен дә күрсәтә. Татар телендә әлеге мәсьәләнең кайбер аспектларына Ш. А. Рамазанов, Ф. С. Фасеев һәм башка кайбер тел галимнәре дә тукталып уза. В. Н. Хангилдин һәм Д. Г. Тумашева грамматикаларында парлы сүзләр турында шактый тулы мәгълүмат бирелә һәм аларның структур үзенчәлекләре күрсәтелә. Ф. Ә. Ганиев – парлы исемнәрне өйрәнүгә зур өлеш керткән галим. Аның тарафыннан бу мәсьәлә аерым монографик планда тирәнтен һәм һәр яклап өйрәнелгән. Кушма сүзләрнең бер төре булган парлы сүзләрнең үзенчәлекләренә тирән анализ ясаган Ф. И. Таһированың хезмәте дә телчеләрдә зур кызыксыну уятты.

Г. Ибраһимов күренекле язучы гына түгел, татар теленең морфологик төзелешен өйрәнүгә шактый өлеш керткән галим дә. Ул үзенең грамматикасында *тау-таш*, *килем-китем*, *алыш-биреш*, *ир-ат* кебек парлы сүзләрне «юлдаш сүзләр» дип, *карт-коры* кебек сүзләрне сүз җилемнәре дип атый.

Бүгенге көндә Г. Ибраһимов әсәрләре шактый тирәнтен өйрәнелгән. Аның иҗатының милли асылын, кабатланмас бизәкләрен ачуга юнәлтелгән яңадан-яңа хезмәтләр языла һәм киләчәктә дә язылачак.

Г. Ибраһимов әсәрләренең лексикасын анализлагач, аларның искиткеч бай икәнлеге һәм анда кушма сүзләр (*коточкыч, коточыргыч, бераз, бердәнбер, бервакыт, һичнәрсә, бервакыт, бераз, һичбер, гөнаһшомлык, һичнәрсә, гыйбадәтханә, шәһадәтнамә, бертоташтан, һәрвакыт, карабалык, кызылканат, берничә, һәркем* һ. б.) белән беррәттән, аларның бер төре булган парлы сүзләр дә еш очраганлыгы күренде. Парлы сүзләр арасында сыйфатлар да *(тау-тау, исән-сау),* рәвешләр дә *(ава-түнә, берәм-берәм, иректе-ирексез, иртәле-кичле, үзеннән-үзе, еш-еш, як-якка, арлы-бирле, кисәк-кисәк),* саннар да *(бер-ике, ике-өч),* ияртемнәр дә *(шалт-шолт),* фигыльләр дә *(ашау-эчү, улү-нитү),* алмашлыклар да *(бер-бере),* ымлыклар да *(ай-вай),* хәбәрлек сүзләр дә *(әлҗе-мөлҗе)* бар. Материалдан күренгәнчә, сан ягыннан парлы исемнәр өстенлек итә. Алар компонентлары тезүле бәйләнеш нигезендә кушылып ясалганнар. Ясалышлары ягыннан бер генә тип очрый:

**1. Исем + исем тибы.**

1) ***Төп формадагы исем + төп формадагы исем*** моделе: **тавыш-тын, тау-таш, җил-давыл, аһ-зар,**

**кул-аяк, аш-чәй, тирә-як, ялан-урман** һ. б. *Картым намазлык өстендә катты, **тавышы-тыны** калмады. Бервакыт, ди, балыкчылар ... **аш-чәй** кайнату өчен, җирне бераз казып, зур гына ут ягалар. Соңра язмыш аңа үзенең рәхимен сала: ул бер хәзрәтнең йортына* **хатын-кыз** *йомышына йөрергә алына. **Җил-давыл** һаман көчәя, **тау-таш** җимерелгәндәй булып күк күкрәве һаман арта бара, ... Арада елау, **аһ-зар**, нәзерләр, тәүбәләр башлана. Бөтен **тирә-ягын** кызыл, сары утка күмеп, су төбеннән олы кояш чыга.*

2) ***Тартымлы исем + тартымлы исем*** моделе: **иге-чиге.** *Бөтен дөньяда **иге-чиге** күренмәгән диңгез белән иң җитез хыяллар да чигенә барып чыга алмаячак күктән башка һичнәрсә калмады. ... бу таллар өстендә нәфис һәм матур кошлар үзләренең диңгез артыннан алып килгән моңнарын, шатлыклы көйләрен, сандугач үзенең **иге-чиге** булмаган мәхәббәтен сайрый.*

Анализ күрсәткәнчә, парлы исемнәр, нигездә, *төп формадагы исем + төп формадагы исем моделе* буенча ясалган.

Г. Ибраһимов әсәрләрендә очраган парлы исемнәрне семантик бәйләнеш ягыннан түбәндәге төркемнәргә бүләргә мөмкин:

1) якын мәгънәле яки синоним исемнәрдән торган, ягъни үзара синонимик мөнәсәбәттә булган парлы исемнәр: **тирә-як, исәнлек-саулык, аһ-ваһ, аһ-зар, ай-вай.** *Иптәшләр исә күлнең, **тирә-якның** матурлыгыннан, танышлыгыннан бигрәк, җил булмауга куаныштылар... Бик еш **исәнлек-саулыгын**, хатын, балачагасының хәлен сорашкан. Я ходай! Һава ни дәрәҗәдә саф, бөтен **тирә-якта** ничаклы матурлык! Фәрештә аны [аждаһаны] тимер чылбырлар белән авызлыклаган булганга, ай-ваена карамыйча, тарта бирә...*

2) Капма-каршы мәгънәле исемнәрдән – антонимнардан торган, ягъни үзара антонимик мөнәсәбәттә булган парлы исемнәр: **тавыш-тын.** *Картым намазлык өстендә катты,* **тавышы-тыны** *калмады.*

3) Компонентлары бер-берсенә бөтенгә өлеш караган кебек төзелгән парлы исемнәр: **тау-таш, җил-давыл, ялан-урман.** *Аяз матур көннең кинәт коточкыч караңгы бер күренешкә әйләнеп, **җил-давыл** вә яшеннәрнең кузгалуы теге тискәре иптәшләребезне дә яхшы ук каушатты булса кирәк. Күк, **тау-ташлар** җимергән, дөньяның астын өскә китергән кебек, куәт белән күкри. Авылдан байтак читтә, **ялан-урман** уртасында булган Кондызлы күлгә юнәлдек.*

4) Компонентлары бер-беренә якын булган төшенчәләрне белдергән парлы исемнәр: **хатын-кыз, аш-чәй, аяк-кул.** *Соңра язмыш аңа үзенең рәхимен сала: ул бер хәзрәтнең йортына **хатын-кыз** йомышына йөрергә алына. Бервакыт, ди, балыкчылар ... **аш-чәй** кайнату өчен, җирне бераз казып, зур гына ут ягалар. ... икенчеләре [Габдулла хаҗи] кәгъбәгә тәваф кылып та, пигамбәребезнең зиратына бармаганлыгы сәбәбеннән* **кулы-аягы** *тартышкан, шуннан вафат булган, диләр икән.*

5) Беренче компоненты реаль мәгънәгә ия булып, икенчесе искергән, пассивлашкан парлы исемнәр: **бала-чага.** *Бик еш исәнлек-саулыгын, хатын, **балачагасының** хәлен сорашкан.*

6) Лексик мәгънәләре тулысынча тәңгәл килгән, ягъни бер үк сүзнең кабатлануы белән ясалган парлы исемнәр: **ат-ат** (уен). *Нинди уеннар башлап ташлаганбыздыр, анысын ачык хәтерли алмыйм. Шулай да үзебезгә мәгълүм: «Туп», «Кыекбаш», «**Ат-ат**»ларның берсе дә калмады ....*

Күргәнебезчә, Г. Ибраһимов әсәрләре теле гаҗәеп дәрәҗәдә бай. Аның бер өлешен ясалышлары ягыннан бер типка караган парлы исемнәр тәшкил итә һәм аларның һәрберсе ясалышы ягыннан җентекләп өйрәнүне сорый.

ӘДӘБИЯТ


1. Алпаров Г. Сайланма хезмәтләр (Татар грамматикасы һәм гомуми тел белеме мәсьәләләре) / Г. Алпаров. – Казан, 1945. – 180 б.
2. Ганиев Ф. Ә. Хәзерге татар әдәби теле: Сүзьясалышы / Ф. Ә. Ганиев. – Казан: Мәгариф, 2000. – 271 б.
3. Ибраһимов Г. Татар сарфы / Г. Ибраһимов. – Казан, 1911. – 82 б. (на арабской графике).
4. Ибраһимов Г. Сайланма әсәрләр. I т. / Г. Ибраһимов. – Казан: Таткнигоиздат, 1957. – 526 б.
5. Насыри К. Краткая татарская грамматика / К. Насыри. – Казань, 1860. – 80 с.
6. Рамазанов Ш. А. Татар теле буенча очерклар / Ш. А. Рамазанов. – Казан: Татгосиздат, 1954. – 200 б.
7. Тагирова Ф. И. Лексикографирование и орфографирование сложных слов татарского языка / Ф. И. Тагирова. – Казань, 2005. – 128 с.
8. Татар грамматикасы. I т. – М.: Инсан; Казан: Фикер, 1998. – 510 с.
9. Тумашева Д. Г. Хәзерге татар әдәби теле. Морфология: Югары уку йорты студентлары өчен дәреслек-кулланма / Д. Г. Тумашева. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 1978. – 221 б.
10. Фасеев Ф. С. Татар телендә терминология / Ф. С. Фасеев. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1969. – 200 б.
11. Хангилдин В. Н. Татар теле грамматикасы (Морфология һәм синтаксис) / В. Н. Хангилдин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. – 644 б.


# «БАШКОРТ КЫЗЫ ГӨЛБИКӘ» ХИКӘЯСЕНЕҢ КАЙБЕР ТЕЛ-СТИЛЬ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ


***Р. Х. Мөхиярова (Яр Чаллы)***



Статья посвящена лингвостилистическим особенностям рассказа Г. Ибрагимова «Башкирка Гульбикэ». Анализируются использованные в рассказе поговорки, фразеологизмы, сравнения, эпитеты, просторечные слова и диалектизмы, выявляется их роль в достижении художественной выразительности.


Галимҗан Ибраһимов күренекле язучы гына түгел, мәшһүр тел галиме, методист та булган. Әдипнең «Татар сарыфы», «Татар нәхүе», «Татар телен ничек укытырга?» кебек фәнни хезмәтләре хәзерге чорда да әһәмиятен югалтмаган.

Билгеле, язучы үз әсәрләренең телен дә мөмкин булган кадәр камил итәргә тырышкан. Бу «Башкорт кызы Гөлбикә» хикәясе мисалында ачык күренә. Әсәрдә төрле тел-стиль чаралары бик мул һәм оста кулланылган.

Автор аеруча халык мәкаль-әйтемнәре белән оста эш итә, еш кына аларны бераз үзгәртеп, образлылыкны көчәйтеп, иҗади куллана.

*Сәфәрнең бөтен җавабы минем өстә, юлдашка **җил дә, яңгыр да булмаячак*** (170 б.). (Җил-яңгыр тидермәү).

***Атын урлаткач капкасын бикләгән** адәм шул булды инде, – ди* (169 б.).

(Атны урлаткач, абзарны бикләмиләр).

***Мал иясенә охшый,** диләр. Ләкин башкортның эте һичбер вакыт үзе кебек ялкау булмый* (160).

Югарыдагы өзектә мәкальгә нигезләнгән үзенчәлекле алогизм фикерне ирония белән үткенрәк белдерүгә хезмәт итә.

Әсәр геройларының халәте бөтенләй үк өметсез түгеллеген дә автор мәкаль ярдәмендә бик кыска аңлата:

*Әбиләр, **илдә чыпчык үлми,** дигәннәр* (170 б.).

Язучы фразеологик әйтелмәләрне дә хикәянең эчтәлегенә, стиленә тәңгәл китереп, образлылыкны арттыру максатында оста файдаланган:

*...мин, йә Ходай, өзгәләп ыргыталар, күрәсең, дип **котым очты*** (172 б.).

*...тамак туйдыра алудан **өмид өзүемә** каршы, әллә кайдан майлы күмәч тә, йомшак корт белән куе каймак та чыкты* (161 б.).

*Ерак күк безнең аһ-зарларга **колак салмый*** (172 б.).

Галимҗан Ибраһимов бу хикәясендә чагыштыруларны да күп кулланган. Ясалыш формасы ягыннан алар күп төрле, иң активлары – -дай/-дәй кушымчасы белән ясалганнары.

Кыргый хайван белән чагыштыру:

*Үзе һаман, бөтенләй котылуына ышанып җитә алмаган кебек, **капканнан ычкынган куяндай** як-ягына карана* (158 б.).

Кош белән чагыштыру:

*Минем кесәдән акча чыкканны сабырсызлык белән көтеп, **карчыгадай** эләктерде дә, йөгерә-йөгерә чыгып ук китте* (164 б.).

Чагыштырулар ясау өчен, әдип дини чыганакларга да мөрәҗәгать иткән:

*Көтү-көтү этләрне өрдереп, башкорт хатын-кызларының безне **дәҗҗәл күргәндәй** бер ис китү белән, хәйранлык белән, әллә кая чаклы карап калган күзләреннән котылып, авыл читендәге кечкенә бер өйгә барып туктадык* (159 б.).

***...Мөхәммәдкә вәхи белән килгән Җәбраилдәй,** минем хыял күгем ачылып, анда гаҗәеп бер нур тулды* (171 б.).

*Кебек* бәйлеген кулланып ясалган чагыштырулар бер предмет белән икенче предметны, абстракт һәм конкрет предметларны янәшә куеп чагыштыру ярдәмендә барлыкка килгән.Тасвирлау объекты күз алдына чагыштырган предмет аша килеп баса:

*Идәннәре, ди, **күзге кебек шома**, ялтырап тора, ди, таеп егылып, башымны яра яздым, ди* (162 б.).

Икенче бер чагыштыруда объектның халәте тасвирлана:

*Тиздән безнең өй дә тынды, ишек бикләнде, ут сүнде, юлдашым **үлек кебек йоклый*** (167 б.).

Сирәк кенә чагыштырулар *төсле* бәйлеге белән дә ясалган:

*Кыяфәтендә башкортлык юк: иякка таба очланып килгән тар йөз, **су төсле күз,** ул да эчкә баткан* (161 б.).

*Гүя* теркәгече бәйлек функциясендә килеп, үзенчәлекле чагыштыру ясый:

*Ире чыгып югалды, шуның белән **гүя аның өстеннән авыр йөк төште**...* (166 б.).

Язучы кулланган барлык чагыштырулар да күзаллауны конкретлаштыру, образлылыкны көчәйтү вазифасын башкаралар.

Күренешләргә мөнәсәбәтне, экспрессив төсмер белдерү өчен, язучы эпитетлардан да файдалана.

***«Керле күлмәк»*** (165 б.), ***«кара тышлы мендәр»*** (160 б.), ***«сары шадра»*** (161 б.) кебек традицион эпитетларга тукталып тормыйча, Г. Ибраһимов кулланган кайбер үзенчәлекле индивидуаль эпитетларны карап үтәрбез. Язучы күбрәк берничә сүзле эпитетка өстенлек бирә:

*Сезгә мин җырламыйм, сезгә башкорт кызы булып тууга башка гөнаһасы булмаган **фаҗигый язмышлы** Гөлбикә моңлана... – диясем килгән иде* (172 б.).

*Фаҗигый* эпитеты икенче бер урында «матур» сүзе белән бергә килеп, «фаҗигый матур йөзе» дигән каршылыклы гыйбарә, ягъни оксюморон барлыкка китергән:

*Шул мең төрле халык белән тулган олы театрда, шул шау-шулар эчендә минем хыялымда Гөлбикәнең **фаҗигый матур йөзе,** колагымда аның **авыр моңлы музыкасы** иде* (172 б.).

Югарыдагы җөмләдә «авыр моңлы музыка»сы эпитеты Гөлбикәнең авыр да, моңлы да тормышын оста тасвирлый. Эпитетлар, бер-бер артлы тезелеп, градация дә ясый:

*Шул **авыр, моңлы, бетмәс караңгы кайгы белән тулы гомеремдә** сиңа очравым һәм синең **ихлас иркәң, җылы кочагың** эчендә үткәргән сәгатьләрем минем **боек күңелемне** күтәрде, **яралы йөрәгемә** шифалы бер тамчы булды* (172 б.).

Язучы, әсәрнең стиленә ярашлы рәвештә, башка бик күп чаралардан да файдаланган. Мәсәлән, хикәядәге геройларның күпчелеге башкорт булганлыктан, язучы аларны өлешчә «әсәй» телләрендә дә сөйләткән:

*– Күрмәгән кая!... Күргән, әллә **нисә** рәт күргән... Патша хәзрәтенең туры үзенә алып баралар, ди... Патшаның **һарае,** ди, үзе бер **кала саклы** бар, ди* (162 б.).

Жаргон һәм гади сөйләм сүзләре әсәрдә нindidер бер халәтне яхшырак тасвирлауга хезмәт итә. Мәсәлән, арып, «ач бүредән яман ачыккан» геройларның ашаулары түбәндәгечә күрсәтелә:

*Сәкегә, юрганнар, мендәрләр өстенә тәмам җәелеп, аякларны бөкләп утырдык та башкортта гына табыла торган тәмле ашамлыкларны **бөгә башладык*** (161 б.).

Җомагылның тупаслыгын, явызлыгын, әшәкелеген күрсәтү өчен, язучы шундый сүз сайлаган:

*– Эшең түгел, **ырылдама!** – дип кенә куйды* (162 б.).

Кондукторларның штраф түләтеп, яңадан билет алдыруларын тасвирлаганда , әдип «тунадылар» дигән гади сөйләм сүзен уңышлы файдалана:

*Түләп, рәхәтләнеп барасы урында ике кабат **тунадылар...*** (158 б.).

Әсәрдә диалекталь, ягъни Башкортостан татарлары сөйләменә генә хас булган сүзләр дә очрый:

*Анда берничә кара тышлы мендәр ауный, шулар янында кыйммәтле атластан, бөтен түше алтынга манылган тәңкәләр белән тулы хатыннар киеме* ***тәпәрләнеп*** *ята* (160 б.).

Гомумән алганда, Галимҗан Ибраһимов «Башкорт кызы Гөлбикә» әсәрен язганда, халкыбызның электэлектән кулланган мәкаль-әйтемнәрен дә, фразеологик әйтелмәләрне дә, төрледән-төрле чагыштыруларны да, индивидуаль эпитетларны да, жаргон, гади сөйләм сүзләрен, диалектизмнар һәм башкортча сүзләрне дә оста файдаланган, алар ярдәмендә образларны тулысынча ачуга, шул чор башкорт халкының тормыш колорит-төсмерләрен тулы күрсәтүгә ирешкән.

ӘДӘБИЯТ

Ибраһимов Г. Хикәяләр, повесть, роман. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. – 463 б. (Мәкаләдәге мисаллар шушы җыентык буенча җәяләр эчендә битен күрсәтеп бирелде).

# Г. ИБРАҺИМОВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ ДЕЗИДЕРАТИВ ИСЕМНӘРНЕҢ КУЛЛАНЫЛЫШЫ

***М. З. Вәлиева (Казан)***

В данной статье рассматривается употребление дезидеративных имен в творчестве Г. Ибрагимова. Дезидеративные имена в художественном тексте помимо своих основных функций имеют дополнительные смысловые оттенки.

Әдәби әсәр тукымасына килеп кергән кеше исемнәренең кулланылыш үзенчәлекләре галимнәр тарафыннан соңгы елларда шактый җентекле тикшерелә башлады. Бу аңлашыла да, чөнки әдәби текст эчендәге һәрбер сүз, шул исәптән кеше исемнәре дә, үз функцияләрен башкарудан тыш, өстәмә мәгънәви төсмерләргә дә ия булалар, «эчтәлек белән форманы бергә бәйләп тора торган сүз-сурәткә әвереләләр» (1, 6). Башка тел чаралары кебек үк, кеше исемнәре дә образлар системасын тудыруда, әсәрнең төп тема һәм мотивларын ачып бирүдә әһәмиятле роль башкара. Тел-сурәтләү чаралары кебек үк, кеше исемнәренең кулланылышы ягыннан да һәрбер әдипнең үзенә генә хас үзенчәлекләре була. Бу җәһәттән Г. Ибраһимов иҗаты аеруча зур игътибарга лаек. Әдип үзенең һәрбер персонажына аларның төс-кыяфәтен, холкын ачып бирердәй, хәтта шул чорның үзенчәлекләрен дә чагылдырырдай исемнәр бирергә тырышкан. Мин бу хезмәтемдә Г. Ибраһимов иҗатында кулланылган хатын-кыз исемнәренә, аларның дезидератив төренә, ягъни теләк исемнәргә тукталырга булдым. Теләк исемнәргә килгәндә, аларның нигезендә баланың саулык, бәхет, муллык-байлык, матурлык, гүзәллек, сафлык, тынычлык һәм башка бик күп яхшы сыйфатларга ия булуын теләү ята. Г. Ибраһимов иҗатында аларның түбәндәге төрләре кулланылган:

1. Баланың сау-сәламәт булып үсүен теләп бирегән исемнәр.

Мондый төр исемнәрдән татар телендә гарәп теленнән кергән Хәят (яшәеш), Сәлимә (исән-сау, сәламәт), Гайшә (тере, яшәп торучы) һ. б. исемнәр һәм шул исем компонентлары катнашында ясалган антропонимнар киң таралган. Галимҗан Ибраһимов иҗатында шулар арасыннан аеруча *Гайшә* дигәне киң кулланылган. Мәсәлән:

*Гайшәнең күзләренә йокы кермәде* (4, 93).

2. Баланың бәхетле, мул тормышта яшәвен теләп бирелгән хатын-кыз исемнәре.

Татар антропонимиясендә төрки-татар сүзе *миңле* антрополексемасы катнашында ясалган исемнәр аерым бер урын алып тора. Борынгы бабаларыбыз миңле бала бәхетле була дип ышанганнар һәм яңа туган сабыйның тәнендә миң булса, аңа *миң, миңле* сүзләре кергән исемнәр бирергә тырышканнар (7, 70). Г. Ибраһимов иҗатында шундый антропонимнардан *Миңҗамал* исеме белән очрашабыз. Чыннан да, исеме җисеменә туры килә дигәндә, бу яшь кызга бәхетле булу өчен барлык шартлар да бар кебек. Матурлыгы, чаялыгы, илдә тынычлык урнашу, якыннарының саулыгы – болар барысы да әдипнең шушы геройга карата чын-чынлап теләктәш булуын күрсәтә:

*Хәзер таныйм: сез Сафа бабай кызы Миңҗамал бит* (2, 100).

3. Баланың бай, мул тормышлы булуын теләп бирелгән антропонимнар.

Бу төр берәмлекләрдән *нәгыйм* (бәхет, ләззәт; нигъмәт) антрополексемасы катнашында ясалган Нәгыймә исеме язучының «Тирән тамырлар» романында урын алган. Әсәрдәге вакыйгалардан күренгәнчә, әлеге герой автор тарафыннан бәхетле мул тормышта яшәргә тиешле киң күңелле образ буларак яктыртылган:

*Шәяхмәт белән бергә кайткан озынча буйлы, ябыграк, ләкин нык гәүдәле, маңгаенда тирән яралы кеше – Нәгыймәнең ире Садыйк иде* (4, 98).

4. Баланың матур, чибәр булуын теләп бирелгән исемнәр.

Шушы төркемгә керә торган антропонимнар татар хатын-кыз исемнәре арасында күпчелекне тәшкил итә. Кыз баланың матур, нурлы йөзле; сылу, зифа гәүдәле; якты, саф күңелле, кыскасы, чын мәгънәсендә гүзәллек иясе булуын теләп, шундый мәгънә белдергән исемнәр бирү традициясе гасырлар буе дәвам итә. Андый исемнәр төрки-татар чыгышлы *күрекле, күркәм, сылу, йарык (якты), багду (яктылык, нур), гүзәл* антрополексемалары катнашында барлыкка килгәннәр. Еш кына татар халык иҗатында, җырларда киң кулланылган кош, хайван атамалары да кеше исеме буларак кулланылган. Бу җәһәттән, мисал итеп Г. Ибраһимовның «Казакъ кызы» романындагы Карлыгач-Сылу исемен китерергә мөмкин. Кызның үз исеме Карлыгач булса да, халык, аның гүзәллегенә таң калып, исеменә Сылу сүзен дә өстәп атый башлаган. Һәм әсәрдә бу исем дә

баш хәрефтән бирелә, еш кына кызның үз исеме буларак та аңлашыла:

*Карлыгач сахраның матуры булып пешеп өлгерде* (3, 272).

*Ил эчендә дә коры исеме белән әйтмичә, Карлыгач-Сылу дип атыйлар иде* (2, 272).

Кыз баланың матур, сылу булуын теләп бирелгән исемнәрнең кайберләре *зифа* компоненты белән ясалган. Г. Ибраһимов иҗатында без андый исемнәрнең *Миңзифа, Зифа* кебек төрләре белән очрашабыз:

*Миңзифа әбинең теңкәсенә тиеп бетте бит шул каһәр төшкерләре!* (4, 110)

*Зифа карчык «Хезмәт»кә килеп төште* (5, 110).

Кыз баланың чибәр, гүзәл булуын теләп бирелгән исемнәр арасында гарәби чыгышлы *җамал, вәсим, нәфис, җәмил, әҗме* сүзләре ярдәмендә барлыкка килгәннәре дә татар халкы тарафыннан теләп кулланылган. Г. Ибраһимов үзенең иҗатында шуларның *җамал, нәфис* компонентлары катнашында ясалганнарын кулланган:

*Фәтхия. Нихәлең бар, Гөлҗамал килен*? (6, 32).

*Аның кечкенә сеңлесе Нәфисә коты очып елап җибәрде* (4, 125).

Кыз баланың матур, чибәр, нәфис, гүзәл булуын теләп биргән исемнәрнең бер өлеше гөл-чәчәк, асылташ атамаларына нигезләнеп барлыкка килгән. Аеруча фарсы чыгышлы *гөл* компоненты катнашында ясалганнары халкыбыз тарафыннан яртып кулланыла. Гомумән, «гөл» сүзе татар телендә генә түгел, башка бик күп төрки халыкларда да исем ясауда катнаша һәм ул компонент исемгә, үзенең туры мәгънәсеннән тыш, наз, нәфислек, хисчәнлек төсмерләрен дә өсти. Г. Ибраһимов яратып кулланган Гөлҗиһан, Гөлчәчәк исемнәренең геройларына да шушы сыйфатлар хас:

*Исеме Гөлҗиһан иде* (5, 105).

*Гөлчәчәк ... тышка атылды* (3, 298).

*Алтын* һәм *көмеш* кебек затлы металл атамалары белән дә хатын-кыз исемнәре барлыкка килгән. Алтын, көмеш сүзләре катнашында ясалган исемнәр, бер яктан, баланың гаилә өчен кадерле, кыйммәтле булуына, мул тормышта яшәргә тиешлегенә ишарә итсә, икенче яктан, алтын, көмеш сүзе кергән хатын-кыз исемнәрендә баланың якты, нурлы йөзле, чибәр булуын теләү дә чагылыш тапкан:

*Хәл шулай булганда, бу хәбәрне Алтынчәч бикәгә әйтсәң, ул шелтәләп чыгарыр* (3, 276).

*Җегетнең анасы мәрхүм Гөлсем бикә белән Алтынчәч якын дуслар иде* (3, 298).

Асылташ атамалары кергән хатын-кыз исемнәре арасыннан әдип Гәүһәр антропонимына мөрәҗәгать иткән. Язучы әлеге исем ярдәмендә аның иясенә хас булган затлылык, нәзәкатьлелек, серлелек кебек сыйфатларны тагын да тулырак итеп ачып бирүгә ирешкән дисәк тә ялгышмабыз:

*Аның сөйгәне Гәүһәр туташны җанлы көенчә күз алдына китереп бастырып* ... (2, 64).

Болгар-татарларда изге, илаһи булып саналган күк җисемен белдерә торган *ай* астрологик термины да, туры мәгънәсеннән тыш, сылулык, матурлык, нәфислек; пакьлек-сафлык; якты, нурлы кебек күчерелмә мәгънәләргә дә ия булган. Г. Ибраһимовның Айбала исемле герое да чын мәгънәсендәге нәфислек, сафлык, серлелек чагылышы булып тора:

*Айбала аз гына да тартынмады, кыенсынмады, сөйкемле күзләре белән көлеп: «Ир-җегет үзенең ярын сагынмасмы?» – дип җавап кайтарып, тиз-тиз чыгып китте* (3, 272).

Хатын-кыз исемнәре арасында яктылык, матурлык, гүзәллек, сафлык символы булып исәпләнгән күк җисемен белдергән *йолдыз* термины катнашында ясалганнары да бар.Таң йолдызын белдерә торган Чулпан исеме, гарәпләрдән кергән шул ук мәгънәдәге Зөһрә, латин чыгышлы Венера, гарәби чыгышлы «йолдыз, җемелдәүче» мәгънәләренә ия Сафура антропонимнарын халкыбыз гына түгел, Г. Ибраһимов та яратып кулланган. Шушы исемнәр аша әдип әлеге геройларның матур, чибәр булуларын гына түгел, якыннарының күңелләрен даими җылытып торучы серле яктылык чыганагы булуларын да чагылдыра алган:

*Кызым Чулпан исән торса, киявем булачак идең* ... (3, 286).

*Хәйри бай. Зөһрә! Вәли! Сез кайда?* (6, 22).

*Җамали куркудан шашкан бичара Сафураның бу мәшәкатьләренә күз салмады* (5, 116).

Мәгълүм булганча, ислам динен кабул иткәннән соң, төрки-татар телендә *кояш, ай, йолдыз* компонентлары белән ясалган антропонимнарның *шәмсе* /г./ (кояш), *бәдри ~ бәдәр* /г./ (ай), *камәр* /г./ (ай), *маһи* /ф./ (ай) кебек синонимнары барлыкка килә һәм алар татар язучылары тарафыннан киң кулланылышка кереп китә. Мәсәлән, Г. Ибраһимов үзенең иҗатында *Камәр* исеменә еш мөрәҗәгать итә. Әсәр эчтәлегеннән күренгәнчә, әлеге исем иясе үзе дә ай кебек якты, чибәр һәм ниндидер серлелеккә, илаһилыкка ия:

*Әхтәм Банаев. Камәр туташ, сез тирә-яктагы атаклы мөгаллимә* (6, 28).

Кыз баланың матур, чибәр, затлы булуын теләп кушылган исемнәрнең бик күп өлеше гарәп-фарсы телләреннән кергән. Шулар арасында Г. Ибраһимов әсәрләрендә кулланылган Зәйния исеме аерым игътибарга лаек:

*Батырхан. Боларны ишеткәч, Зәйния, хурлыгыннан, көн-төн акырып елый башлады* (6, 24).

5. Баланың акыллы, гыйлемле, дан-шөһрәтле һәм башка шундый югары әхлакый сыйфатларга ия булуын теләп бирелгән исемнәр. Г. Ибраһимов мондый төр исемнәрнең *гыйлем-гыйльме* компонентлары катнашында ясалганнарына өстенлек бирә:

*Карасам, Гыйльминур җиңги икән* (2, 67).

Чыннан да, әдип кулланган исемнәрнең байтагы җисемнәренә туры килә. Мәсәлән, «иң асылы, сайлап алынганы» мәгънәсендәге Гайния исеме бирелгән персонаж үзе дә әсәр тукымасында нәкъ шул үзенчәлекләргә ия образ буларак тасвирланган. Ул гомере буена сөйгән ярының иң асылы, сайлап алынганы булып кала:

*Их, бәгырем, Гайниям, ничек онытыйм инде* (2, 76).

Гарәби чыгышлы, шулай ук «сайлап алынган асыл зат» мәгънәсендә йөри торган Зәбидә антропонимы да әсәрдә ниндидер бер яктылык булып тора. Сабый баланың иң авыр минутларында Зәбидә карчык белән саташуы аның нәкъ менә бала тарафыннан сайлап алынган асыл зат булуы хакында сөйли дә инде:

*Бу бала берничә көннән бирле Зәбидә карчык белән саташа* (4, 122).

Шул рәвешчә, Г. Ибраһимов иҗатында кулланылган хатын-кыз исемнәренең һәрберсе җентекле уйлап сайланган һәм алар, башка тел чаралары белән беррәттән, язучының үзенә генә хас стиль калыбын

формалаштыруда зур роль башкаралар, дисәк һич тә ялгышмабыз.

Гомумән, Г. Ибраһимов иҗатында кеше исемнәре, номинатив функция башкарудан тыш, әдәби геройларның катлаулы рухи дөньяларын, хисләр тирәнлеген ачып бирергә, геройларның яшәү, эш-хәрәкәт мәйданы турында тулырак күзаллау булдырырга ярдәм итәләр.

ӘДӘБИЯТ


1. Бәширова И. Б. Сүз белән сурәт ясау. – Казан: Татар. кит. нәшр, 1974. – 176 б.

2. Ибраһимов Г. Адәмнәр. – Казан: Татар. кит.нәшр, 1998. – 157 б.

3. Ибраһимов Г. Казакъ кызы // Татар әдәбиятыннан хрестоматия: Унберьеллык мәктәпнең 10 нчы сыйныфы өчен / Төзүчеләре: А. Г. Әхмәдуллин, Ф. Г. Галимуллин. – Казан: Мәгариф, 1995. – Б. 270–343.

4. Ибраһимов Г. Кызыл чәчәкләр // Ибраһимов Г. Адәмнәр. – Казан: Татар. кит. нәшр, 1998. – Б. 116–157.

5. Ибраһимов Г. Тирән тамырлар // Яхин А. Г. Әдәбият: Унберьеллык мәктәпнең 10 нчы сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия. – Казан: Мәгариф, 1995. – Б. 24–45.

6. Ибраһимов Г. Яңа кешеләр // Яхин А. Г. Әдәбият: Унберьеллык мәктәпнең 10 нчы сыйныфы өчен дәреслек-хрестоматия. – Казан: Мәгариф, 1995. – Б. 92–124.

7. Саттаров Г.Ф. Исемең матур, кемнәр куйган? – Казан: Татар. кит. нәшр, 1989. – 255 б.


# СИНОНИМЫ В ПРОИЗВЕДЕНИЯХ Г. ИБРАГИМОВА


***Э. Н. Денмухаметова (Казань)***


Чтобы расскрыть многогранную личность Галимджана Ибрагимова, нужны огромные знания в области духовной истории татарского народа. Художник, воплотивший в своих произведениях основополагающие принципы социалистического реализма, крупный критик и теоретик литературы, выдающийся учёный, государственный и общественный деятель, он был пионером новой национальной культуры. В своих бессмертных произведениях через языковые особенности татарской речи Г. Ибрагимов смог создать такую ауру, которая передает яркость художественной мысли татарского народа, силу словесных красок, динамичность и лаконичность лексической системы классической татарской литературы начала XX в. Эти шедевры языковой культуры являются вместе с тем и картинами развернутой в широком плане истории татарской лингвокультуры данного периода.

Язык художественной литературы всегда был предметом внимания лингвистов, и язык произведений Г. Ибрагимова тоже был неоднократно изучен. Несмотря на это, существуют еще многие аспекты пополнения лингвистических учений относительно стиля и языковых особенностей великого классика татарской литературы. Одной из таких областей можно назвать синонимию, где через синтез обобщений относительно расположения синонимических единиц в прозе Г. Ибрагимова выявляется то, что анализ и правильность выбранного писателем семантического тона и умелая их комбинация, мотивированность соединения различных семантических оттенков синонимов, определение для синонимизируемого слова соответствующего пространства в контексте, пространства, устанавливаемого рациональной комбинацией слов, ведущей к расширению круга ассоциаций, поэтическая гармония в употреблении синонимов создают особое функциональное поле выбора средств и способов выражения. Вданной работе рассматриваются вопросы синонимии в рассказах Г. Ибрагимова.

Анализ языковой природы синонимов, использованных Г. Ибрагимовом в своих рассказах, убеждает нас в том, что при классификации последних с точки зрения средств и способов их выражения выявляется, что стиль художественно-образных конструкций в его произведениях связан с приобретением языковыми единицами в контексте цельного художественного произведения эстетической значимости. И следует отметить, что позиция синонима при всей его потенциальной подвижности регулируется целенаправленностью лексической и семантической системы текста.

Синонимы в рассказах Г. Ибрагимова не только обладают сходством значения, но и имеют определенные различия. Наиболее распространенными отличительными классами синонимов являются абсолютные, парные, семантические, контекстуальные и близкие синонимы. Синонимы Г. Ибрагимова есть воплощение, своеобразная художественно-образная реализация системы языка, и они выполняют свое концептуальное назначение в определенной тональности.

Особую группу в текстах рассказов Г. Ибрагимова составляют так называемые абсолютные синонимы (иначе их называют полными или дублетными). Существование таких синонимов связано со способностью языковой системы его прозы иметь несколько означающих для одного означаемого (например, **бәян** [рассказ] – **сөйләү**; **кояш** [солнце] **– шамс; йөз** [лицо] – **бит, чәһрә, чырай; Илаһ** [бог] – **Аллаһ, Алла, Ходай; гыйлем** [знание] – **белем** һ. б.).

В рассказах Г. Ибрагимова семантика и стилистика в диапазоне абсолютных синонимов являются средствами номинации субъектов и объектов. Их системная синтаксическая функция – функция представления, наименования, обозначения качеств, оценок, признаков предмета, т. е. их литературная характеристика. Так, например, в возвышенном или торжественном стиле в случае употребления вместо лексической единицы **бәхет** слова **сәгадәт** или же в случае замены слова **сандугач** синонимом **былбыл** содержание текста не искажается; автор здесь делает акцент на стилистическую окраску описанного. Например, «Бу *вакытның хыялыңда да аерым бер тәм, бөтенләй башка булган бер ямь була; моны хис кыйлмаган адәмнәр зур бер* ***сәгадәт****тән мәхрүмнәрдер дип уйлыйсың, аларны кызганасың*» (Уты сүнгән җәһәннәм, б. 122) или «*Гүя ул безне, безнең күңелдәге ялкынны белә дә, адәм гомерендә бер генә килеп кичә торган мәсәлсез* ***бәхет*** *белән безне тәбрик кыйла, шуны бөтен дөньяга чәчә кеби хис кыйлына*» («Сөю – сәгадәт», б. 116); «*Тирә-яктагы барлык нәрсәләр, тәңренең бәхетле колы –* ***сандугач****ның*

*музыкасы тәэсиренә чумып, үлем тынлыгына бата һәм тыннарын әчтән алалар»* («Сөю – сәгадәт», б. 116). «*Беләмсең, ни ди **былбыл**?*» («Сөю – сәгадәт», б. 116).

В приведенных примерах между понятием **сәгадәт** и его лексическим синонимом **бәхет** или между **былбыл** и **сандугач** существует семантическое отличие, хотя в них наблюдается некая стилистическая окраска. Наличие таких стилевых черт не отражается в существовании синонимов, ибо в каждом данном состоянии синонимы все же находятся в динамическом равновесии.

Следующую группу синонимов в рассказах Г. Ибрагимова составляют парные синонимы, спецификой которых является своеобразный способ их образования посредством соединительных союзов или интонацией перечисления. Изменение их позиции в парных синонимах почти невозможно, поскольку место и статус каждого слова в них и их союзов являются определенными и конкретно стабильными, а их нарушение приводит порою к потере изящности и экспрессивной согласованности элементов парных синонимов. Например, «*Ләкин бик **нык**, бик **каты** китте*» («Яз башы», б. 57); «***Аһ-зар, фөрьяд** куба, тәүбәләр, догалар, авыр ыңгырашулы күз яше бөтен корабны каплый*». («Диңгездә», б. 78); «*Мин яшьтән үк **ямь вә матурлык** гашыйкы*» («Сөю – сәгадәт», б. 108) и др.

Соединительный союз **вә** или **һәм** играет весьма важную роль в образовании парных синонимов. Изучая особенности лексических синонимов Г. Ибрагимова, можно выявить специфическое структурное многообразие парных синонимов, которые использованы писателем в целях придания лексике своих произведений высокой экспрессии в необходимых позициях, оригинальных функциях, в различных ракурсах: в поэтическом выражении мысли, описании состояния персонажей, событий и явлений, при которых в конечном итоге один из их элементов способствует осмыслению значения непонятных читателю слов и определению стилистических особенностей. Источники возникновения парных синонимов в рассказах Г. Ибрагимова разные. Среди них есть лексика татарского литературного языка, в структуре синонима представляющая оба компонента и используемая в целях восполнения, комментирования смысла выше сказанного и воздействия через них на читателя: «*Шулар белән **борчылып**, җаныңны кая куярга **аптыравың** җитмәгән кебек, тагы бөтен нәрсәсе белән сиңа каршы төшә!*» («Карт ялчы», б. 148); «*Яшьлекнең бер дәверендә күп нәрсәгә ышагасың: алла диләр, **гадәләт, хакыйкать** диләр, һәммә кешеләрнең **сәгадәте** хакында сөйлиләр, мәгълүм бер шартлар буенча тезеленсә, **хәятта бәхет** булуын өмит итәләр – яшь һәрберсен саф җәүһәр дип кабул итә, һәм шуның белән аның **тормышы** мәгълүм бер дәвердә мәгънәле дә,матур да була.*» («Мәрхүмнең дәфтәреннән», б. 206) и т. д. Как видно из примеров, использованы такие синонимические пары, как *борчылып – аптырап* (волноваться); *гадәләт – хакыйкать* (справедливость, истина); *сәгадәт – бәхет* (счастье); *хаят – тормыш* (жизнь).

Встречаются и такие синонимы, один компонент которых состоит из слов тюркского происхождения, а другой – арабского или персидского; также есть пары где оба компонента являются заимствованными. Например, в татарском языке слово *язык* обозначается словом – тел, а в арабском **лугать** (лөгать); **кадер, хөрмәт** (арабизмы) – уважение; **яхуд** (перс.) – **яки** (тат.) – или; **мәдәни** (араб.)– **культуралы** – культурный и т. д.

Что касается семантических (идеографических) синонимов, то они в прозе Г. Ибрагимова отличаются оттенками значения. Одна из основных причин появления в его рассказах подобного класса синонимов – стремление автора способствовать наиболее полному осмыслению, изучению явлений литературной действительности, открыть новый оттенок синонима и дать ему определенное контекстуальное место в своих произведениях. С этой точки зрения указанный класс синонимов в творчестве Г. Ибрагимова занимает весьма важное положение. Например, «*Бераздан соң теге калын урманлы, зур **куәтле мөтәкәббир** тау артыннан тулган ай күтәрелә башлый. Дөнья вә табигатькә яңа **күрек**, яңа **матурлык** арта. Айның бу нуры һәр нәрсәгә хыялый, мөзссир, ләкин бик **мөлаем**, **гүзәл**, шигъри һәм серри төс бирә*» («Сөю – сәгадәт», б. 116).

Выше приведенные синонимические единицы **куәтле и мөтәкәббир; күрек и матурлык; мөлаем и гүзәл** имеют общие значения – сильный, большой; красота; красивы. Однако эти единицы различаются лексическими значениями и стилистической окраской. Так, слово *мөтәкәббир* имеет превосходную степень описания и может переводиться как **очень большой**; *куәтле* – с широкой семантикой как **сильный во всем;** а слово **күрек** используется как красивый, но в простом, разговорном стиле, в отличие от слова *матурлык* (красота). В лексеме **мөлаем** преобладает семантика красоты лица, а в слове *гүзәл* – всесторонняя красота. Следовательно, в рассказах Г. Ибрагимова обязательным условием семантической синонимии признается смысловое тождество.

В произведениях Г. Ибрагимова также можно увидеть близкие синонимы, т. е. слова, близкие по значению, которые употребляются для обозначения одного и того же понятия. Например, «*Мин дә, **хәят күгеннән югалып**, үлемнең караңгы кичәсе артына **батармын, югалырмы**н*» («Сөю – сәгадәт», б. 106); «*Бу садә тормыш фәкать бу авылда гына булмыйча, бөтен тирәякта гайн шул хәл **хөкем сөргәнгә**, төрле үзгәрүләргә вә чит якларга чыгып йөрергә иҗбар итәрлек эшләр булмаганга, алар күптән шулай **яшәп киләләр,** сату-алу, кәсеп вә һөнәргә кул сузмыйлар иде, чөнки мәҗбүрият юк иде*» («Йөз ел элек», б. 88) и др.

Некоторые контекстуальные синонимы, замещающие позицию «синтеза», обладают сложным идиолектным значением и являются смысловыми доминантами текста. Кроме того, контекстуальные синонимы в силу установления индивидуально-обусловленной смысловой близости способны порождать определенные ассоциации, ведущие к возникновению различных образно-смысловых планов в тексте. Таким образом, контекстуальные синонимы активно участвуют в смысловой организации текстового пространства рассказов Г. Ибрагимова, в реализации важнейших категорий текста: семантической и структурной целостности, композиционной завершенности, воспроизводимости и модальности, а следовательно, выполняют текстообразующую функцию.

Кроме того, можно отметить и эмоционально-экспрессивную функцию контекстуальных синонимов

в произведениях Г. Ибрагимова, так как при анализе языкового материала в большинстве случаев отмечалось наличие положительных и отрицательных коннотаций у лексем, замещающих позиции «тезиса» и «антитезиса». Выраженность и значимость эмоционально-экспрессивной функции связаны, во-первых, со спецификой «тезиса» и «антитезиса» как элементов когнитивной схемы, лежащей в основе логико-семантической организации контекстуальных рядов, во-вторых, с тем, что в синонимическом ряду каждый член вносит свой уникальный семантико-стилистический оттенок значения.

Таким образом, близкие синонимы широко используются автором, интерпретируя различные предметы и объекты, с целью избежания повтора одинаковых лексических единиц, обеспечения эмоционально-оценочных характеристик объектов описания и достаточно полного представления читателю событий, явлений, а также и личностные качества своих персонажей.

ЛИТЕРАТУРА


Брагина А. А. Синонимы в литературном языке / А. А. Брагина. – М.: Русский язык, 1954. – 127с.

Сафиуллина Ф. С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология. / Ф. С. Сафиуллина. – Казан: Хәтер, 1999. – Б. 36–51.

Сәгыйтов Р. Татар теле синонимиясендә гарәп-фарсы алынмалары / Р. Сәгыйтов // Мәгариф. – 1992. – № 10. – Б. 22–23.

Ханбикова Ш. С. Синонимнар сүзлеге / Ш. С. Ханбикова, Ф. С. Сафиуллина. – Казан: Хәтер, 1999. – 256 б.

Ханбикова Ш. Татар телендә синонимия һәм сүзлекләр / Ш. С. Ханбикова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – 280 б.

Ибраһимов Г. Әсәрләр. Сигез томда / Г. Ибраһимов. – Т. 1. Хикәяләр. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. – 510 б.


# ЯЗУЧЫНЫҢ «ДИҢГЕЗДӘ» ХИКӘЯСЕНДӘ *ДИҢГЕЗ* КОНЦЕПТЫНЫҢ ЧАГЫЛЫШЫ


***А. А. Ногманова (Уфа)***



В произведении Г. Ибрагимова «В море» концептуальными лексемами являются слова *море, волны, вода, лодка, остров* и т. д., образующие ярко выраженную индивидуально-авторскую концептосферу. Героя рассказа притягивают к себе покой, изменчивость и романтика моря. В статье также уделяется место анализу «небесной» лексики, так как эти две группы слов часто соприкасаются друг с другом в структуре художественного текста.


Теләсә кайсы матур әдәбият текстының структурасын конкрет темага караган лексик берәмлекләр тәшкил итә. Бу яктан караганда, Г. Ибраһимов әсәрләре татар әдәби телен революцион көрәш («Кызыл чәчәкләр»), ачлык («Адәмнәр»), ат («Алмачуар») темаларына караган лексика белән баетты. Язучының «Диңгездә» әсәре бу уңайдан телебезне «диңгез» лексикасы белән тулыландырды.

«Диңгез» концепты бөтен кешелек дөньясының менталитетын, аң-фикерләрен чагылдыра. Аның архетип билгеләре бар: су стихиясенең үзгәреп торучанлыгы, матурлык, тирәнлек, романтика. Әсәрдә «диңгез» индивидуаль-автор эчтәлеге буларак ачыла, конкрет чор, урынга, геройга бәйле рәвештә яңа мәгънә белән байый. Борынгы заманнардан бирле диңгезнең үзгәрүчән, серле образы кешене үзенә тартып торган, аның шомлылыгы, иксез-чиксезлеге, түземлеге, серле тынлыгы битараф калдырмаган.

Компаративные конструкции, реализуемые с помощью аффиксов сравнительной степени, имеют специфическую структуру и семантику в отличие от собственно сравнения: качественный признак одного и того же предмета сравнивается с самим собой с целью установления большей или меньшей степени его проявления; аффиксы сравнительной степени могут образовывать только свободные сравнения; в этих конструкциях обычно отсутствует образ сравнения.

Аффикс *-рак/-рәк* присоединяется к основам качественных прилагательных и усиливает степень наличия названного в них признака.

Превосходная степень выражает наибольшую интенсивность проявления признака по сравнению с другими предметами и не имеет единого показателя. В основном она образуется при помощи препозитивной частицы *иң* (самый), *бик* (очень): *Бу бит адәм түгелдер, фәрештәдер, фәрештәнең дә **иң** олысы, аллага **иң** якын булганыдыр...*(Көтүчеләр); *Ләкин ул хәлдә калмый: ул акрын, әмма туктаусыз рәвештә ерак вә югары күккә карап юл тота – ниһаясез фәзаның **иң** гали ноктасына, төшлеккә туры текәп, мөтәкәббиранә бара башлый* (Сөю – сәгадәт); *Яшьлекнең бу дәверен адәмнең хәятында **иң** гали вә **иң** кыйммәт бер заманы дип хисаплыйлар* (Сөю – сәгадәт); *Ул бондый кичәләрдә **бик** аз сүзле була; тик **бик** сирәк кенә, миңа **бик** гали вә **бик** тирән мәгънәле булып күренгән берәр сүз генә әйтеп куя* (Сөю – сәгадәт); *Айның бу нуры һәр нәрсәгә хыялый, мөәссир, ләкин **бик** мөлаем, гүзәл, шигъри һәм серри төс бирә* (Сөю – сәгадәт).

Рассматривая семантику степеней сравнения наречий в анализируемых произведениях, отметим, что они очень близки к степеням сравнения прилагательных. В форме положительной степени наречия признак представляют вне сопоставления, в форме сравнительной степени – как обнаруживающиеся в большей степени по сравнению с другими его проявлениями, в превосходной – как высшую степень качества. Морфологические показатели данной категории наречий аналогичны морфологическим показателям прилагательных: *Аяз көндә, димәк, һич көтмәгәндә яшен сугу ничек тәэсир итсә, патшаның бу фәрманы аңардан яман**рак** булды* (Кызыл чәчәкләр); *Алтын булгач, докторын да, алласын да, мулласын да, патшасын да сатып алып була икән шул: ике мең тотканнар, диләр... Бәлки, артыг**рак** та булыр – күпме чыкса чыккандыр, Гали «шәһәргә» барып каралды, – ахрысы бөтенләйгә котылды...* (Кызыл чәчәкләр); *Аннан соң бөтен тамырларым буенча биләмә, аякларыма төште – тагы хәлсезләндем, тагы артыг**рак** өзелдем...* (Кызыл чәчәкләр).

В то же время автором очень часто используются и метаслова сравнения. В татарском языке метаслова сравнения *охшаган, хәтерләткән, булып* и др. имеют свои лексико-семантические и стилистические свойства. Например: *Төшләрем өнгә **охшый**. Өнемдә булганнарны төштән аера алмыйм* (Көтүчеләр); *Ул, ятлаган сүрәләре булып, шуларны укый идеме, әллә жырлый идеме, һичбер вакыт белә алмадым; ләкин аның шул озын кышкы төннәрдә, тыштагы буранның ачы сызгыруына кушылып, өйнең караңгы почмагында ялгызы урнашып, нииндидер авыр кайгы белән моңаюлары – минем йөрәгемдә мәңге таралмаслык рәвештә агулы кан **булып** урнашып калганнар* (Көтүчеләр).

Глагол *охшаган* в сочетании с существительными и местоимениями в направительном падеже участвует в выражении уподобительности сравнения. Данный глагол может употребляться в различных грамматических формах: *охшашлы, охшаган, охшый.* Например:

*Бу шундый якты, шундый матур һәм мәсгудиятле ки, башка сәгадәтләр гомер күгендә ялтыраган берәр йолдыз булсалар, бусы үзенең зурлыгы, яктылыгы, күңел каршындагы куәте белән төшлек тугрысында мөтәкәббиранә торган олуг кояшка* ***охшый*** (Сөю – сәгадәт); *Агыйделнең киң болыннар, зур таулар арасыннан боргаланып-боргаланып аккан җирендә үзенең зурлыгы, йортларның төзеклеге белән кечерәк шәһәргә* ***охшашлы*** *бер авыл бар...* (Кызыл чәчәкләр).

Данные слова по частотности употребления уступают другим способам репрезентации семантики компаративности, но все же широко представлены в произведениях Г. Ибрагимова.

Различны и функции компаративных конструкций. Они используются автором как средство портретной характеристики человека: *Ул чакта таза имәндәй ир булган Кәримнең инде сакалына чал кергән, картлык үзен күрсәтә башлаган* (Табигать балалары).

Сравнения используются для характеристики психологического состояния героев, образной конкретизации эмоций: *Сугышка алалар, үлемгә куалар дип, хатынкыз шикелле елап торып булмый инде* (Кызыл чәчәкләр).

Сравнения используются автором и при изображении картин природы: *Таң сандугачлары сайраудан туктамаганнар иде әле; безне әллә кайдан кая җәелеп яткан киң тугай, чык суы белән энҗедәй ялтырап, каршы алды* (Табигать балалары).

Таким образом, рассмотрев средства репрезентации категории компаративности и их функционирование в произведениях Г. Ибрагимова, мы пришли к выводу, что компаративные конструкции являются средством создания точности высказывания и служат цели выражения авторского отношения к изображаемому.

ЛИТЕРАТУРА

1. Закиев М. З. Татарская грамматика. Синтаксис. – Казань, 1992. – 576 с.

# СЕМАНТИКА И РЕПРЕЗЕНТАЦИЯ КАУЗАЛЬНОСТИ В ЯЗЫКЕ ХУДОЖЕСТВЕННЫХ ПРОИЗВЕДЕНИЙ Г. ИБРАГИМОВА

***Л. Г. Валиева (Казань)***

Галимджан Ибрагимов – известный языковед, общественный деятель, классик татарской литературы, произведения которого составляют золотой фонд письменного наследия татарского народа. Язык его произведений отличается своей утонченностью, точностью структуры, образностью.

В данной статье мы рассмотрим семантику и репрезентацию значимой лингвистической категории каузальности в языке художественных произведений Г. Ибрагимова.

Причинность (каузальность) определяется как «генетическая связь явлений объективного мира в процессе их развития, состоящая в том, что одно явление (причина)… порождает другое (следствие)» (1, 457). *Причина* и *следствие* неразрывны, так как каждая причина имеет свое следствие, а любое следствие вызывается какой-либо причиной.

Взаимосвязь причины и следствия образует причинно-следственную цепь, в которой явления выступают и причиной, и следствием. Например, то, что является по отношению к предыдущему явлению следствием, служит причиной по отношению к последующему. Это наблюдается и в языковой структуре произведений Г. Ибрагимова. Рассмотрим это на конкретном примере: *Әткәйләр киткәндә, катык оеп җитмәгән, икмәк тә пешеп өлгермәгән; шуңа күрә азык алмый киткәннәр икән, аларга ашарга илтергә кирәк булды* (Г. Ибраһимов. Алмачуар). Когда отец уходил на работу, он не взял, оказывается, еды, потому что кислое молоко еще не отстоялось и хлеб не был еще готов; нужно было ему отнести обед.

В данном предложении образована следующая причинно-следственная цепь: *Катык оеп җитмәгән, икмәк тә пешеп өлгермәгән* (кислое молоко еще не отстоялось, и хлеб не был еще готов) – **причина**, *шуңа күрә азык алмый киткәннәр икән* (он не взял, оказывается, еды) – **следствие** => *азык алмый киткәннәр икән* (он не взял, оказывается, еды) – **причина**, *аларга ашарга илтергә кирәк булды* (нужно было ему отнести обед) – **следствие**.

Таким образом, часть *азык алмый киткәннәр икән* (он не взял, оказывается, еды) является следствием по отношению к предыдущей части (*катык оеп җитмәгән, икмәк тә пешеп өлгермәгән* – кислое молоко еще не отстоялось, и хлеб не был еще готов) и причиной – по отношению к последующей (*аларга ашарга илтергә кирәк булды* – нужно было ему отнести обед).

Каузальность в татарском языке устанавливается между членами предложения и между предложениями. Рассмотрим, какие средства используются для выражения причинно-следственных отношений между членами предложения и между предложениями в произведениях Г. Ибрагимова.

Семантика и репрезентация каузальности между членами предложения:

– Аффикс исходного падежа: *Туктаусыз чабу**дан**, йокысызлык**тан**, яңгыр**дан** бер дә кеше төсе калмады* (Г. Ибраһимов. Карт ялчы). От беспрерывной беготни, бессонницы и ненастья мы потеряли человеческий облик.

Отвлеченные имена существительные, образованные с помощью аффикса *-лык*/*-лек*, принимают форму исходного падежа *-дан*/*-дән, -тан*/*-тән, -нан*/*-нән* и отражают причину внутреннего характера. Эта причина связана с психическим, эмоциональным состоянием субъекта действия. Например: *Мин шат<u>лыг</u>ым**нан** кая сикерергә урын тапмыйм* (Г. Ибраһимов. Алмачуар). От радости я не нахожу себе места; *Шул минутларда ялгыз<u>лык</u>**тан** җаным әрни* (Г.Ибраһимов. Көтүчеләр). В эти минуты сердце сжимается от одиночества.

Существительные, выражающие эмоционально-психическое состояние, принимают форму исходного падежа и обозначают причину выполнения процесса. Например: *Куркуд**ан** йөрәгем купты…* (Г. Ибраһимов. Көтүчеләр). От страха сердце мое оборвалось…

Это же значение передают и имена действия. Например: *…Хурлануым**нан** башымны кая куярга җир тапмадым, ни әйтергә белмәдем* (Г. Ибраһимов. Көтүчеләр). …От стыда я не знал, куда деваться и что говорить.

– Послелоги и послеложные слова.

Для репрезентации каузальности в произведениях Г. Ибрагимова широко используются послелоги и послеложные слова *өчен, аркасында, сәбәпле*, которые передают разные оттенки причинно-следственного значения.

Послеложное слово *сәбәпле* указывает на причину основного действия. Например: *Ул бай белән безнең әти арасында, ниндидер бер җир талашы **сәбәбеннән**, әллә кайчаннан бирле дошманлык бара иде* (Г. Ибраһимов. Алмачуар). Из-за спора о земле между этим баем и моим отцом с давних пор шла вражда.

Послелог *өчен*:

а) выражает объект, являющийся причиной действия: *Буйга зурлыгы **өчен** аны Озын Хафиз дип йөртәләр* (Г. Ибраһимов. Алмачуар). За высокий рост его прозвали Длинный Хафиз;

б) указывает на причину основного действия: *Атларга бер солы көлтәсен артык биргән **өчен** дә дөнья чаклы тавыш куптара торган адәм* (Г. Ибраһимов. Карт ялчы). Такой человек поднимает шум из-за каждого снопа овса, отданного лошадям.

Послеложное слово *аркасында* подчеркивает следственный компонент каузальной конструкции и может выражать как положительное, так и отрицательное следствие. Как показал анализ собранных нами примеров, в произведениях Г. Ибрагимова это послеложное слово обычно употребляется, когда причина благоприятствует выполнению какого-либо действия: *Без бурлы бия **аркасында** аякка бастык* (Г. Ибраһимов. Алмачуар). Благодаря гнедой кобыле мы встали на ноги; *Көн-төн карау **аркасында** бер атна дигәндә минем Алмачуарым бөтенләй элекке хәленә кайта алды* (Г. Ибраһимов. Алмачуар). Благодаря неусыпным заботам мой Чубарый через неделю выздоровел и стал совсем как прежде.

– Причастие, присоединенное к глаголу с помощью направительного падежа, выражает причину процесса. Например: *Ләкин мин, моңа оста булма<u>ган</u>**га**, артык кызыгын тапмадым* (Г. Ибраһимов. Яз башы). Но я не счел это интересным, так как у меня не было на это особых способностей.

Семантика и репрезентация каузальности между предложениями:

Каузальная ситуация проявляется наиболее развернуто в сложных предложениях, так как в этом случае и причина, и следствие выражаются предикативными конструкциями (предложениями).

– Сказуемое синтетического придаточного предложения, выраженное причастием (форма *-ган/-гән, -кан/-кән*), принимает аффикс направительного падежа, и придаточное предложение обозначает причину действия главного. Например: *Кунарга дип чыкма<u>ган</u>**га**, минем тышавым да, кешәннәрем дә юк икән…* (Г. Ибраһимов. Карт ялчы). Я не собирался ночевать на поле, поэтому с собой у меня нет ни пут, ни веревки; *Ул бөтен авылда хыянәтсезлеге белән бик артык танылган бер әби бул<u>ган</u>**га**, байлар аны үзләренә алмакчы булалар* (Г. Ибраһимов. Карт ялчы). Она была известна всей деревне своей безукоризненной честностью, поэтому богачи предложили ей пойти на содержание к ним; *Малай юаш, акыллы күрен<u>гән</u>**гә**, аны кайтармыйлар, еллап хезмәткә яллыйлар* (Г. Ибраһимов. Карт ялчы). Благодаря тому, что мальчик был кротким и сообразительным, его не отпустили, а наняли на год работником; *Бу арада бурлы бия бик артык холыксызланып кит<u>кән</u>**гә**, мин аның янына барырга курыктым* (Г. Ибраһимов. Алмачуар). За последнее время гнедо-чалая была слишком раздражительная, поэтому я побоялся даже подойти к ней; *Тирмәнебез авылдан читтәрәк бул<u>ган</u>**га**, миңа анда барып йөрергә сирәк туры килә иде* (Г. Ибраһимов. Көтүчеләр). Мельница наша стояла в стороне от деревни, и бывать в деревне приходилось редко.

– Синтетическое придаточное предложение, сказуемое которого выражено деепричастием с аффиксом *-ып/-еп*, обозначает причину действия главного предложения: *Яшеннән ут чыг**ып**, тирмәнебез янып китте* (Г. Ибраһимов. Көтүчеләр). От грозовой молнии вспыхнул пожар, и наша мельница сгорела.

– Относительные (союзные) слова: *Иртә кайтсалар, аларны эшкә кушачаклар, **шуның өчен** алар булган чаклы соңга калырга тырышалар икән* (Г. Ибраһимов. Яз башы). Если они придут домой рано, их заставят работать, поэтому они стараются остаться на озере как можно дольше.

– Интонация ожидания. После следственной части делается определенная пауза, и далее следует часть, выражающая причину: *Гайни моңа риза булмый: кадерле карты, балалары белән гомер иткән балчык өйне ташлау – мәрхүмнәрнең күңеленә авыр тоелыр кебек була* (Г. Ибраһимов. Карт ялчы). Бабушка Гайни не согласилась на это: бросить глиняную лачугу, где она прожила жизнь со своим стариком и детьми, ей казалось оскорблением памяти дорогих людей.

Частицы, которые не имеют самостоятельного лексического значения, а лишь «придают отдельным словам, членам предложения или предложению в целом различные смысловые, эмоциональные и модально-экспрессивные оттенки» (2, 352), хотя и не выражают каузальность, способны усилить это значение или указывать на предположительный характер причины/следствия.

Частицы *-дыр/-дер, -тыр/-тер* могут находиться в составе следственной части и выражать предположительность следствия, тогда как причина в таких случаях является реальным фактом. Например: *Һичбер вакыт һичкем аның хәлен белергә, бергә кайгырышырга теләмәгәнгә, ул үзе дә йөрәгенең барлыгын, аның ярасын оныткан**дыр*** (Г. Ибраһимов. Карт ялчы). Оттого что никогда никто не интересовался им и не хотел разделить его горе, он, видимо, и сам забыл о своем сердце, забыл о ранах в нем.

Следует отметить, что глагол *бул* + формальный показатель глагола условного наклонения *-са/-сә*, употребляясь с предикативным словом *кирәк*, репрезентирует каузальность, причем указывает на предположительную причину. Например: *Йөзе чыннан да*

*ярылган **булса кирәк**: ак яулык белән бер күзе ашасыннан бәйләнгән* (Г. Ибраһимов. Алмачуар). Лицо, кажется, вправду разбито: один глаз перевязан белым платком.

Таким образом, для выражения каузальности между членами предложения и между предложениями Г. Ибрагимов использует многообразные средства, каждый способ репрезентации обладает своеобразной семантической особенностью.

ЛИТЕРАТУРА

1. Словарь русского языка / Под ред. А. П. Евгеньевой. – М.: Русский язык, 1985. – 1988 с.

2. Татарская грамматика. Т. II. Морфология. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1993. – 397 с.

# Г. ИБРАҺИМОВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ КЕРЕШМӘЛӘРНЕҢ КУЛЛАНЫЛУ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

***В. И. Гыймадиева (Алабуга)***

Наблюдения над языком произведений Г. Ибрагимова позволяют выделить различные семантические типы вставных конструкций вне предложения, не зависящие в своем значении от компонентов предыдущего предложения и зависящие от них. Вставное предложение представляет новое звено в цепи связанных между собой предложений авторского повествования, но звено, оторванное от этой цепи, включение которого в связный текст сложного синтаксического целого прерывает связи между предложениями, входящими в это синтаксическое целое. Вставочные конструкции, дополняют содержание основного предложения и вводятся в его рамки для экономичности, компактности сообщения. Они носят субъективно-авторский характер при введении авторского «я», выражении авторских эмоции, оценок, индивидуального восприятия действительности.

Татар телендә кереш сүзләр һәм керешмәләр телчеләрнең игътибарын күптәннән җәлеп иткән (2, 89–90; 4, 498). Ләкин әлеге хезмәтләрдә җөмләдән тыш килгән кереш җөмләләргә һәм керешмәләргә бөтенләй игътибар ителмәгән. Бары тик сүз тәртибенә мөнәсәбәтле рәвештә җөмлә ахырында килгән керешмәләрне Ф. С. Сафиуллина өстәлмәләргә мөнәсәбәттә карый (3, 129–130). Ул аларны өстәлмә конструкцияләр астында бик җентекләп өйрәнә һәм төп үзенчәлекләрен билгеләп чыга. Соңгы елларда татар синтаксисында, беренче тапкыр буларак, җөмләдән тыш керешмәләр күрсәтелә (1, 17–23). Г. Ибраһимов әсәрләрендә, тел үзенчәлекләренә игътибар итсәң, керешмәләрнең шактый актив булуы күзгә ташлана. Без әлеге мәкаләдә әдипнең «Адәмнәр», «Казакъ кызы», «Тирән тамырлар» һ. б. повесть һәм романнары, күп санлы хикәяләреннән тупланган мисаллар үрнәгендә бу синтаксик берәмлекләрнең үзенчәлекләрен күрсәтүне максат итеп куйдык. Болар, мөстәкыйль җөмләләр тәмамланганнан соң, җәяләр эчендә биреләләр. Керешмәләр тәгәлләнгәч, нокта куела һәм җәяләр ябыла. Җәядән соң тыныш билгесе куелмый, ә яңа җөмлә баш хәрефтән башлап языла. Керешмәләр Г. Ибраһимов әсәрләрендә җөмлә уртасында да, җөмлә ахырында да һәм җөмләдән тыш та кулланылганнар. Җөмлә уртасында килгән керешмәләр җөмләнең бер кисәген генә ачыклыйлар: Якында гына, кигәвеннәрдән үзен кая куярга белми дулап, арканына уралып дүрт аягы бергә килеп беткән соры бия бар икән, шуны тиз генә җиктек тә Өсманың энесе *(минем каенишем булыр, Ходай кушса!)* белән кайтарып җибәрдек («Табигать балалары»). Авылда бик-бик калын кое баганасы бар иде. Фәхринең атасы Тимершаны *(ул миңа бертуган эне була)* аягын югары шул баганага астылар («Тирән тамырлар»).

Җөмлә уртасында һәм җөмлә ахырында килгән керешмәләрнең түбәндәге төрләрен күрсәтергә мөмкин.

Вакыт төшенчәсен белдерүче керешмәләр: Хәзер биш олуг мәсҗетле, базарлы, мәктәп вә школалы вә ярыйсы ук мәгъмур булган авыл моннан бер гасыр элек *(югарыдагы вакыйга булган 1810 елларда)* илле-алтмыш йорттан гыйбарәт кечкенә вә ярым мәдәни булган бер карьячектән гыйбарәт иде («Йөз ел элек»).

Җөмлә ахырында каршы кую мөнәсәбәте була. Ул каршылык интонациясе һәм теркәгечләре, теркәгеч сүзләр ярдәмендә белдерелә. Җөмләләр үзара шушы чара ярдәмендә бәйләнәләр: Һәм сүзендә торды: шуннан соң сабан туйларына аяк та атламады. *(Тик телләрдә генә аның баһадирлыкларын әкият итеп сөйләргә калды)* («Алмачуар»).

Төзелеш ягыннан караганда, керешмәләрнең түбәндәге төрләрен күрсәтергә мөмкин:

1. Сүзнең мәгънәсенә аңлатма бирүче керешмәләр: Өлкән хатыны *(аның ике хатыны бар иде)*, сәке астыннан алып, бер аршын биеклегендә булган бернәрсәне идән уртасына китереп куйды («Йөз ел элек»). Шлемын тотты да, прокурорның *(дөресе: прокурор иптәшенең)* сүзен калдырып, залдан чыгып сызды («Тирән тамырлар»). Бу ярым түгәрәкнең уртасы кутан дип атала – бу инде һәммәгә уртак йорт эче *(уртак мәйдан)* хезмәтен үтәячәк («Казакъ кызы»). Авыл халкы бу эшкә башта аптырап калалар: ни сәбәптән бу тирә-якка усаллыгы, саранлыгы белән даны чыккан явыз Әлемгол тик торганда үзенең гомерлек дошманы Хафизга *(безнең әткәйгә)* бер бия китереп фатиха калдыра?! («Алмачуар»).

2. Сүзнең татарчадан русчага тәрҗемәсен тәшкил итүче керешмәләр: Бу коры, җилсез, тын эсселектән даланың төрле ягында, көмеш дулкыннары белән уйнаган диңгез кебек, сагым *(мираж)* ялтырый («Казакъ кызы»).

3. Татар сүзләре гарәп-фарсы сүзләре белән дөресләнә: Түрәнең килүе бөтенләй башка сәбәптән иде: моннан ун көннәр элек ат көтүчесе Салих картның яшь хатыны Камилә белән «урыс Пәкри» (Әбүбәкердән мөхәффәф) дигән бер егетне уйнаш кыйлуда *(хилафе шәрыг мөнәсәбәттә булу)* яла ягып, халык вә мулла бергә бик яхшы гына тукмаганнар, өстәвенә егетнең чәчен үтмәс пәке белән кырып азаплаганнар иде («Йөз ел элек»).

4. Гарәп-фарсы сүзләренә карата шул ук телдәге алынмалар керешмә ролен үти: Яңа фикерле, мөтәрәккый карилардан *(Коръәне хафизлардан)* берсе юлда туры килде («Габдрахман Салихов»).

Г. Ибраһимов әсәрләренең телен, аның синтаксик үзенчәлекләрен өйрәнеп, түбәндәге нәтиҗәләргә килергә мөмкин. Әдипнең әсәрләре, бигрәк тә прозасы керешмәләргә бай. Г. Ибраһимов, аларны бик урынлы файдаланып, фикерен төгәл, үтемле итеп бирүгә ирешкән. Аның әсәрләрендә җөмлә уртасында, җөмлә ахырында һәм җөмләдән тыш та кулланылган керешмәләрнең матур үрнәкләрен табып була.

ӘДӘБИЯТ


1. Галлямов Ф. Г. Татар телендә җөмләдән тыш килгән керешмә төзелмәләр // Милли мәдәният. – 2003. – № 4. – Б. 17–23.
2. Сабиров К. Татар телендә тыныш билгеләре. – Казан, 1956. – 184 б.
3. Сафиуллина Ф. С. Татар телендә сүз тәртибе. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1974. – 154 б.
4. Хангилдин В. Н. Татар теле грамматикасы: Морфология һәм синтаксис. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1959. – 642 б.


# ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВ ӘСӘРЛӘРЕНДӘ КҮЧЕРЕЛМӘ МӘГЪНӘЛЕ СҮЗЛӘР КУЛЛАНЫЛЫШЫ
## («Кызыл чәчәкләр» повесте буенча)


***Ә. К. Булатова (Казан)***



В данной статье рассматривается употребление переносных значений слов в произведениях великого татарского классика как один из способов образования лексической многозначности. Художественный стиль и язык Г. Ибрагимова очень красив и своеобразен, писатель умело оперирует всем богатством лексики татарского языка, наряду с общелитературными словами в речи персонажей выступают и яркие примеры разговорного стиля. Автор на основе общеязыковых, образных и индивидуальных метафор, метонимии и синекдохи повествует о конкретных событиях и отдельно взятых персонажах.


Татар филология фәнендә матур әдәбият әсәрләрен лингвистларның бары тик тел ягыннан, әдәбиятчыларның – әдәбият теориясе ягыннан, яисә комплекслы, ягъни әдәби әсәрнең тел һәм әдәби эшләнешен бергә каравы еш очрый. Матур әдәбиятның төрләре татар филологиясендә лингвистик яктан шактый нык өйрәнелде. Д. Г. Тумашева, Ш. Г. Рамазанов, В. Х. Хаков, И. Б. Бәширова, Х. Р. Курбатов, Р. С. Нуриев, Л. Г. Габдрахманова, З. Ф. Сәлахетдинова һ. б. ның хезмәтләрендә аерым язучы, яки аерым бер чор язучыларның әсәрләре, үзәккә алынып, тулаем стилистик планда лексик, грамматик яктан тикшерелә, тел күренешләренә тасвирлы анализ бирелә.

Г. Ибраһимов әсәрләренең телен һәм стиль үзенчәлекләрен күп кенә галимнәр өйрәнгәннәр. С. Ш. Поварисов аерым хезмәтләрендә Г. Ибраһимовның тел байлыгын лингвистик яктан анализлый, шулай ук И. Б. Бәширова, Ф. М. Газизова, М. Ә. Сәгыйтов кебек галимнәрнең мәкаләләре әлеге проблеманы берникадәр күләмдә өйрәнүнең мисалы булып торалар. С. Ш. Поварисов, мәсәлән, Г. Ибраһимовның урта мәктәп программасына кертелгән әсәрләрендә сүзләрнең стилистик яктан кулланылышын, күпмәгънәлелек күренешләрен, образлы сурәтләү чараларын тикшерә.

Бу мәкаләдә Галимҗан Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр» әсәрендәге күпмәгънәлелек күренешен тикшерү максат итеп куелды.

Г. Ибраһимов татар теленең сүзлек хәзинәсе белән оста эш итеп, аның лексик чараларының төрле үзенчәлекләреннән файдалана. Әдипнең дөньяга карашы, чынбарлыкны тасвирлавы, эстетик күзаллавы – аның сурәтләү чараларына бай булган образлы телендә чагыла. Бер үк сүз, төрле сүзләр белән бәйләнешкә кереп, мәгънә күчешләрен чагылдыруга ярдәм итә. Тел гыйлемендә күпмәгънәлелек (полисемия) дип йөртелгән мондый күренеш Г. Ибраһимов теле өчен аеруча характерлы.

Телдә күпмәгънәлелекнең билгеле бер семантик закончалыклар буенча үсеше, даими рәвештә яңадан-яңа тотрыклы төшенчәләр тууга, мәгънә берлеге килеп чыгуга китерә.

Күпмәгънәле сүзләрнең лексик-семантик вариантлары аерым бер төшенчәне күрсәткәндә, атап, башка сүзләр белән рәттән килгән вакытта, ягъни яңа контекстта туалар. Барлык кешеләргә дә таныш булган сүзләр полисемантик мәгънәдә матур әдәбиятта киң кулланылалар. Язучы, сүз остасы буларак, үзлекләре ягыннан төрле булган әйберләрнең, предметларның гомуми билгеләрен күреп ала һәм, шул рәвешле, сүзне башка бер сүз белән бәйләнешкә кертеп, яңа мәгънә берлеге барлыкка китерә. Әлеге мәгънә – сүз күчеше тел белемендә *күчмә мәгънә* дигән төшенчә белән билгеләнә.

Күпмәгънәлелек метафора, метонимия, синекдоха, функция берлеге буенча күчеш кебек төрләргә бүленә. Шулардан метафораларны карап үтик.

Метафора (грек. *metaphora* – күчү) – бер атаманың икенче атамага охшашлыгы нигезендә күчеше (5, 20).

«***Язмыш дулкыннары*** *белән бер кавышып, бер аерылып яшәгән дүрт иптәшем дә шул авылның төрле урамнарында, байлыгы-төзеклеге төрлечә булган төрле өйләрдә туып үстеләр*» җөмләсендә әдип төп геройның иптәшләренең тормышындагы үзгәрешләрен дулкыннарга тиңли һәм, шуны да әйтергә кирәк, алар диңгездәгеләргә караганда ачырак, аянычрак булып күзалланалар, *язмыш* сүзе белән бергә килеп образлы метафора хасил була.

«*Аның [Зөһрә апаның]* ***мәхәббәт җимеше*** *– үткен Шаһбаз, үз гомерен чабата тукып, аркан ишеп үткәрә торган ялгыз фәкыйрь бабасы Әхми карт кулына калган*» җөмләсендә Г. Ибраһимов *мәхәббәт җимеше* метафорасы аша, ассоциация нигезендә, көтелеп дөньяга килгән баланы күзаллый.

«*Моңарчы һичкая кузгалмаган Гыйлаҗи да* ***аякланды***» җөмләсендә *аякланды* ‘күчеп китте’ мәгънәсендә килә (бу торыш билгесе һәм процесс билгесе охшашлыгы нигезендәге күчеш), гомумән, әлеге сүз сөйләү телендә генә кулланыла.

«*Шахталарга бара торган юл менә шул* ***тау итәгеннән*** *үтә*», «*Таулар биек, агачлар матур, заводлар һәммәсе дә төрле тау араларыннан төшкән* ***елгаларның тамагында*** *буып ясалган зур матур күлләр тирәсендә утырганнар*». *Тау итәге, елга тамагы* – гомумтел метафоралары, алар объектларның урнашу ягыннан охшашлыгына нигезләнеп ясала.

«*Егет ниндидер бер* ***кара*** *пычрак* ***җинаятьтә*** *гаепләнә*», «*Бохарада, Фирганәдә булган* ***кара көчләр*** *өчен куркыныч кызыл батырларның берсе безнең Шаһбаз икәнен ул җирләрдән кайтучылар сөеп сөйлиләр иде*», «*Ниндидер бер бәйрәм – кайгылы бәйрәм, кара, бик* ***кара бәйрәм***», «*Ләкин Фазыл минем йөрәгемә* ***кара кан*** *сауарып китте*» җөмләләрендә *кара көч, кара җинаять, кара бәйрәм, кара кан* метафоралары аша вакыйгаларга негатив төсмер бирелә (эчке охшашлык һәм ассоциация охшашлыгы).

«***Бәхет ишекләре*** *бер ачылса, гаҗәп була икән ул*» – дип, автор гомумхалык телендә һәм поэтик сөйләмдә еш кулланыла торган *бәхет ишекләре* метафорасын куллана.

«*Дөньяның төрле* ***караңгы почмакларыннан кара туфан*** *булып безне батырырга, юк итәргә килгән барлык кара көчләр бер селтәүдә үзләре йөзтүбән китте*», «***Революция кылычы*** *контрларны юкка чыгарды*» мисалларында инкыйлаби көрәшнең кискенлеге *караңгы почмаклардан кара туфан булып батырырга, революция кылычы, кара көчләр* кебек метафоралар белән бирелгән. Түбәндәге юлларда исә әлеге каршылык тагын да катлаулы һәм эстетик көчләре зур булган чаралар белән күрсәтелгән иҗтимагый-сәяси күренешләр чагылыш таба: «*Җирнең төбеннән күтәрелде, диңгезләр кичте, кан дәрьяларын үтеп чыкты, дөньяның кара көчләрен үз кулы белән бугазлады, ерак күкләргә менеп, андагы аллаларны, фәрештәне карага, пычракка буяп, богаулап ыргытты, арыслан, лачын күзләре белән алдагы көннәргә бер караш ташлап, бу үлемнәр, каннар эченә, бер газап дөньясына, каяндыр, тәрәзә ачты, аннан кояш күренде, нур ага башлады, тирә як чәчәкләр белән тулды… Болар барысы да кызыллар иде*».

Төп геройның ихтыярлы, физик һәм рухи яхтан көчле булуын: «*Башкаларга буйсынмаган авыр* ***ташлар*** *минем кулда* ***уйнап йөриләр***» җөмләсендә *ташлар уйнап йөриләр* метафорасы күрсәтә. Геройның күп уйлану, борчылу, икеләнү минутларын чагылдырганда язучы *«хәсрәт болыты үтеп киткән»* кебек метафора куллана (эчке охшашлык һәм ассоциация охшашлыгы нигезендә ясалган): «*Фазылның күзләреннән тирән* ***хәсрәт болыты*** *үтеп киткән кебек булды, авыр хәсрәтле бер тавыш белән дәвам итте*».

Әсәрдә метонимия күренешенең мисаллары да шактый очрый. Ике әйбернең янәшә булуы нигезендә барлыкка килгән күчерелмә мәгънә метонимия (*metonimia* – яңадан атау) дип атала (5, 22). Әсәрдә форма һәм аның эчтәлеге ягыннан бәйләнешле метонимияләр очрый.

«*Авылның уртасында зур* ***базар*** *кайный*», дигәндә, кешеләр җыелмасы күздә тотыла.

«*Бу баланың гомереннән беренче сәгатьләрен һичбер* ***өй*** *үзенә алырга теләми*», дигәндә исә, *өй* гаилә, кеше мәгънәсендә килә.

«*Безнең* ***ярты җир солы*** *бар*» җөмләсендә *җир* дигәндә җир үлчәме, имана җире, мәйдан күздә тотыла.

«*Гыйлаҗи тутырып бер* ***чокыр*** *эчте*» – бу очракта чокырга салынган эчемлек истә тотыла.

«*Фазыл* ***кымызда*** *икән*» җөмләсендә исә кымыз эчеп сәламәтләнү урыны күзаллана.

«***Үзбәкне, казакны*** *солдатка алмыйлар икән*», дигән юлларда әлеге халык вәкилләреннән булган ир-атлар истә тотыла.

Шулай итеп, Г. Ибраһимов әсәрләренең лексик-семантик системасында күпмәгънәле сүзләр мөһим йөкләмәне үти. Күпмәгънәле сүзләр куллану белән бергә, әдип аларның катлаулы семантикасы, бай мәгънә төсмерләре һәм стилистик үзенчәлекләргә ия булуын дәлилли, үзенең осталыгын, әдәби зәвыгын чагылдыра. Шул ук вакытта телебезнең бетмәс-төкәнмәс сүзлек хәзинәсенең байлыгын һәм гүзәллеген ачып бирә.

ӘДӘБИЯТ

1. Газизова Ф. М. Галимҗан Ибраһимов әсәрләрендә чагыштыру, эпитет һәм метафора // Татар теле һәм әдәбияты. – 5 нче кит. – Казан, 1976. – 296 б.

2. Ибраһимов Г. Сайланма әсәрләр: сигез томда, III т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1975. – 616 б.

3. Поварисов С. Ш. Мәктәптә әдәби әсәрнең телен өйрәнү. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1976. – 128 б.

4. Сәгыйтов М. Ә. Г. Ибраһимов әсәрләрендә сүз сәнгате / М. Ә. Сәгыйтов // Татар әдәбияты мәсьәләләре. – 6 нчы җыентык. – Казан: КДПИ, 1974. – 280 б.

5. Сафиуллина Ф. С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология. – Казан: Хәтер, 1999. – 288 б.

# БЕССОЮЗНЫЕ СЛОЖНЫЕ ПРЕДЛОЖЕНИЯ ОДНОРОДНОГО СОСТАВА В КАРАКАЛПАКСКОМ И ТАТАРСКОМ ЯЗЫКАХ

***Г. А. Альниязова (Нукус)***

Бессоюзные сложные предложения (БСП) однородного состава – это такие предложения, части которых однородны по отношению к единой для них тождественной теме сообщения, грамматически оформленной единством целеустановки и эмоциональной окраски.

Части БСП могут осознаваться однородными по отношению к той вещественной семантике, которая вы-

ражается в общем для них контексте. Например: 1. *Тек еки мәрте ғана ол өзи ушын ҳеш нәрсе умытылмағанын ескертти. Бир мәрте перзенти оны қатты қапа қылды, екиншисинде Едигей еебетейсиз ҳәзиллести (Ш. Айтматов).* 2. *Дөньяны шулай корып бетәм дә, сезнең дүртегезне бер вакытта хатыннарыгыз белән парлап кунакка чакырам... Елга ике мәртәбә: берсе — чана юлы төшкәч тә, авылда казлар, сугымнар суйган, кыз биргән, туй уздырган чорларда... икенчесе—җәй көне, печәнгә төшәр алдыннан, яшь тәкәләр өлгергәч, авылда кыз озату, килен төшерү көннәрендә...* (Г. Ибраһимов. Кызыл чәчәкләр).

Части БСП могут осознаваться однородными по отношению к вещественной семантике, выраженной общей предикативной частью, соотносимой с главной частью сложноподчиненного предложения: 3. *Жаслар ҳәмме нәрсеге жеткенше асығады: балалар тезирек мурт шығыўын күсейди, қызлар барлық көзлердиң тезирек нышанасы болыўын әрман етеди* (Т. Қайыпбергенов).

Таким же образом составные части бессоюзных предложений могут быть однородны по отношению к семантике, выражаемой общим придаточным предложением: 4. *Шаһбаз җиде яшькә җиткәч, чабатачы Әхми карт та үлә; шул зур авылда минем киләчәктәге дүрт дусымның берсе булган бу бала бөтенләй ятим, ялгыз кала* (Г. Ибраһимов. Кызыл чәчәкләр).

Как однородные, части БСП могут осознаваться и по отношению к семантике, выражаемой общими членами предложения. Например: 5. ***Ул арада** тыштан аяк тавышы ишетелде, буяулы нечкә ишек ике якка ачылды.* (Г. Ибраһимов.Кызыл чәчәкләр). 6. ***Аннан соңгы елларда** дөнья кайнады, моңарчы гел бертөсле генә, тыныч кына агып торган тормыш диңгез кебек дулкынлана башлады* (Г. Ибраһимов. Кызыл чәчәкләр). Общий член может использоваться в одной из частей, как в данном примере. Но он может повторяться в частях: 7. ***Бул жер** ҳәмме ушын қәдирли, **бул жер** муқәддес ата-бабалар мәканы (из газеты).* 8. *Куәт **миндә** иде, илнең топкасы **миндә** иде...*(Г. Ибраһимов. Казакъ кызы).

Можно полагать, что общая семантика в таких случаях способна выражаться и другими средствами – общим главным предложением, вводными и служебными словами, общими обособленными оборотами.

Однородность частей в приведенных примерах выражается в том, что в приведенных выше примерах содержание частей подается однородным, одинаковым в том плане, что каждое из них является элементом, раскрывающим содержание общей вещественной семантики. В четвертом примере части однородны в силу того, что каждая из них одинаково отнесена ко времени реализации того явления, о котором говорится в придаточной части. В пятом и шестом примерах, кроме того, части однородны в том плане, что каждая из них «снабжена» одной и той же обстоятельственной характеристикой («ул арада», «аннан соңгы елларда»).

Отмеченные способы выражения общей семантики можно назвать эксплицитными. Они являются свидетельством сходства принципа организации однородности в простом и сложном предложении: несколько компонентов являются однородными, если они одновременно относятся к общему для них и противопоставленному им компоненту.

Следует отметить, что в БСП однородность организуется только на отмеченной выше основе. Так, если в приведенных примерах опустить общие компоненты, БСП останутся однородными. Значит, в самом БСП содержатся элементы, благодаря которым и создается однородность.

Для организации однородности в БСП могут быть использованы средства семантической и структурной организации самих частей (помимо внешних – общего контекста, общих придаточных, главных предложений и др. средств). Среди БСП однородного состава выделяется группа предложений, в которых акцентируется внимание на различии более конкретных элементов семантики основных частей (несмотря на наличие более общего значения однородности, тождественности). В них обнаруживается тенденция к структурносмысловому разложению частей на два состава, каждый из которых симметрично соотносителен и семантически сопоставим с соответствующим составом другой. Например: 9. *Үпкә – дошман, гакыл – дус* (посл.). 10. *Белемле үлмәс, белемсез күрмәс* (посл). 11. *Сен муаллим, мен укучы.* 12. *Атлы атын мактар, юләр – хатынын* (посл.). На письме разделение частей на составы обозначается средствами пунктуации. Акцент на различие семантики частей обнаруживается различными способами. В одном случае все симметрично соотносящиеся составы отчетливо антонимичны (пример 9). В другом случае одни составы отчетливо антонимичны, остальные же можно понять антонимичными лишь в соотношении с первыми – только контекстуально (пример 10). В третьем случае акцент на различие может обнаруживаться только в контекстуально понимаемой антонимии составов (пример 11), в четвертом случае внимание акцентируется на общем различии составов по семантике, не связанной с антонимией (пример 12).

Таким образом, предложения данного типа по более конкретной семантике являются сопоставительно-противительными и связаны с выражением отношений тождественности, которые по своему значению не совпадают с более абстрактной семантикой однородности, по содержанию соотносительной с отношениями тождественности.

В следующих примерах на более конкретном уровне между частями обнаруживается причинно-следственная семантика, хотя общая семантика однородности и общая отрицательная оценка налицо: 13. *Чәчкән орлыкларым өстенә үзем юкта тирес түккәннәр, нindидер бер явыз кара таш белән бастырып киткән, – орлыкларым вакытында чыга алмый калганнар, кайберләре, томаланып, бөтенләй черегәннәр* (Г. Ибраһимов. Кызыл чәчәкләр). 14. *Бу җәйләү картның күңеленә ошамады: туфрагы начар, саргылт; үләне сирәк, сыек, күле чыннан да корып бетеп бара, аның тирә-ягы әллә каян-кая кызыл вак үлән белән капланган, сахрада көтү-көтү йөргән малларның да чырае юк* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы).

В БСП однородного состава другого типа акцентируется внимание на сходстве элементов семантики в составных частях. Наиболее характерными особенностями предложений данного типа являются невозможность членения частей на два противопоставленных состава, семантическое отождествление или сближение отдельных элементов, семантическая несопоставимость

составов в случае возможности их выделения. Например: 15. *Башында әфисәр фуражкасы, аякта шпорлы ялтыр итек, беләктә ак тасма, кулында менә дигән маузер!* (Г. Ибраһимов. Кызыл чәчәкләр). 16. *Көнетөне кар ява, жил ыжгыра, туктаусыз буран уйный* (Г. Ибраһимов. Казакъ кызы).

В предложениях данного типа обнаруживается тенденция к организации соответствия конкретной семантики тождества и более общей семантики однородности средствами лексического и грамматического наполнения частей. В них используются средства эксплицитного выражения общей для частей семантики, чтобы акцентировать их тождество.

Наличие общей эксплицитно выраженной вещественной семантики акцентирует тождество семантики составных частей в оценочном плане: положительное, отрицательное, нейтральное. Так, части подаются в каждом конкретном предложении или только как положительные, или только как отрицательные, или только как нейтральные.

Таким образом, как показывает наш материал, бессоюзные сложные предложения рассмотренного типа характеризуется отношениями тождественности, которые можно квалифицировать как соединительные. Эти предложения антонимически противопоставлены предложениям сопоставительно-противительным и вместе с ними образуют наиболее общую категорию бессоюзных сложных предложений однородного состава.

## «КАЗАКЪ КЫЗЫ» РОМАНЫНЫҢ ЛЕКСИКАСЫНА КЫСКАЧА КҮЗӘТҮ

***В. М. Әгълиуллина (Баулы)***

Данная статья посвящена краткому обзору лексики романа Г. Ибрагимова «Казакъ кызы».

Татар телендәге сүзләрне җыеп теркәү эше, татар лексикографиясенең башлангыч тарихы бик күптәннән килсә дә, татар лексикографиясе тарихында беренче тапкыр сүзлек төзү эшен фәнни лексикографик принципларга нигезләп башлап җибәрүче автор Ж. Вәлиди була. Сүзлекләр чыгарылып, тел нормалары үзләштерелгәннән соң да әле әдәбиятны үстерүгә күп көч куярга туры килә. Бу нисбәттән Галимҗан Ибраһимов хезмәтләре аерым игътибарга лаек.

Шуңа күрә дә ул татар телендә каләм тибрәтүчеләр өчен, хәтта тугандаш төрки халыклар өчен дә остаз булып санала. Язучы сыйнфый көрәш, әхлакый таләпләр, дуслык һәм милләт бердәмлеге мәсьәләләрен күтәрә. Әсәрләрендә кеше һәм табигать мөнәсәбәтен; үткән тарих һәм яңа хакимияткә мөнәсәбәтне күтәрә; хатын-кыз язмышын һәм милли азатлык мәсьәләсен милли җирлектә ача; ачлык фаҗигасен натуралистик алымнар белән сурәтли. Аның иҗаты реализмга нигезләнә, романтизм элементлары да күзәтелә. Г. Ибраһимовның совет чоры иҗатына (1917–1938) күзәтү ясаганда «Алмачуар», «Яңа кешеләр», «Адәмнәр», «Казакъ кызы» һ. б. әсәрләрен кертергә кирәк.

Аның иҗаты жанрларга бай: драмалар, романнар, повестьлар, хикәяләр. «Тирән тамырлар», «Кызыл чәчәкләр», «Яңа кешеләр» һәм «Алмачуар» кебек әсәрләре татар әдәбиятында лаеклы урын тота. «Казакъ кызы» романында язучы сыйнфый көрәш һәм әхлак, колониаль изү, дуслык һәм милләт бердәмлеге мәсьәләләрен күтәрә. Аның иҗаты традицион реализмга нигезләнә, романтизм элементлары да күзәтелә, чөнки Г. Ибраһимов казакъларның көндәлек тормышларын яхшы белә. Аңа яшь чагында Кустанай белән Төньяк Казакъстанда укытучы булып эшләргә туры килә, шуңа күрә ул казакь телен дә, анда яшәүчеләрнең гореф-гадәтләрен дә бик яхшы белә.

«Казакъ кызы» романының жанры эпик төргә карый, кешеләр язмышы хикәяләп бирелә, характерлар формалашу процессы эзлекле күрсәтелә; ул берничә сюжет сызыгына ия булган, чагыштырмача зур күләмле әсәр. Әлеге хезмәттә бәян ителгән вакыйга-күренешләр революциягә кадәрге чорны сурәтли.

Әсәрдә текст эчендә текст формасы урын ала, бер вакыйга икенчесенә үрелеп, халык тормышы сурәтләнә. Һәр бәйрәм, һәр йола үтәлешендә халыкның барлык тирән тамырлары чагыла. Мәсәлән, туй барышын гына анализлап та романның тел-стиль үзенчәлеген ачып була.

Язучы казакъларның Кара-айгыр һәм Кызылкортлар ыругларына караган яшьләренең зур туйда үзләрен ничек тотуларын, гореф-гадәтләрен тасвирлый алган. Зур туйлардагы уен-көлке, кымыз эчү, тапкыр сүзләр көрәштерү дә казакъ кабиләләрендә аерылгысыз гадәт.

Карлыгач-Сылу белән Арысланбайның бер-берсенә карашлары, мөнәсәбәтләре, яшьләрнең уен-көлкеләре аларның характерларын да, тормышка мөнәсәбәтләрен дә, чынбарлыкны да ачык чагылдыра. Аларның аралашуы текстның үзеген тәшкил итә дә инде.

**Әсәрнең лексик составы.** Әсәрнең төп лексикасын төрки-татар чыгышлы сүзләр тәшкил итә, шулай да казакъ теленнән алынмалар аз түгел, чөнки сүз казакъ халкының тормышы турында бара, шуңа күрә алынмаларның күбесе казакъ сүзләре: *думбра, зөрнә* – казакъ халкының музыка кораллары; *үләң* – казакъча җыр; *мәгәр* – ләкин; *кәмәре* – билбау; *җегет* – егет дигән сүзнең казакъ халкына хас әйтелеше; *бүз балалар* – яшүсмер балалар; *калымлыгы* – әйттерелгән кыз йә ир бала; *аз имәс* – аз түгел; *гуй* – казакъ теленә хас сүзгә, яки җөмлә ахырына өстәлә торган кушымча; *кимперләр* – карчыклар; *чаң кузгатып* – тузан туздырып; *әкә* (өлкән яштәге кешегә әйтелә торган сүз) – ага. Казакъ теленең сөйләмен биргәндә Галимҗан Ибраһимов, кайчакта, татар теленең сүз әйтелешен куллана: «Юл булсын!» (юл, бу сүз казакъ телендә ***«жол»*** дип әйтелсә дә, язучы әсәрендә татарча яза).

Галимҗан Ибраһимов сәнгатьле сурәтләүгә матур үрнәкләр тәкъдим итә. Мондый төр текстлар гадәттә

синонимнарга бай булалар, язучыда ***контекстуаль синонимнар*** күп:

Җегетнең мактавына *каршы каты чәнчеп*, *үләң белән җавап кайтара*. Яшь йөрәккә *ут төшә*, *кан кайный*, мәгәр танымады, кем дип сорарга кыймады, сүз әйтергә теле бармады... *Картлар, өлкәннәр, хатыннар һәммәсе* арбаларга *утырганнар*, кайберләре дөягә *менгәннәр*. Кызларның *сылулары*, җегетләрнең *асыллары* кара-каршы килгән икән...

***Антропонимнар*:** Магҗан хаҗи, Азымбай, Карлыгач-Сылу, Сарсымбай;

***Топонимнар:*** Җылкы-Баткан авылы, Яшел-Сырт, Танабуга, Алтын-Күл җәйләве.

Матур әдәбиятта ***антонимнар*** бик әһәмиятле урын тоталар, чөнки алар ярдәмендә образлы сурәтләү палитрасы тудырыла, язучы төрле төсләр белән бирелгән картиналарны хәтта ике сүз белән ясап бирә ала. Чөнки алар бер үк күренешнең ике чиген билгелиләр, әлеге чикләр арасындагы образларның тирәнлеген инде укучы үзе бәяли. Мәсәлән, саф антонимнар: *бүз балалар – яшь сылулар; кызларның сылулары*, *җегетләрнең асыллары* кара-каршы килгән икән, бер уенсыз үтеп китәргә ярамас... *Алышмы*, *бирешме*?

Әсәрнең теле бик үтемле: гади сөйләм теленә зур урын бирелсә дә, әдәби яктан югары дәрәҗәдә иҗат ителгән. Әсәрнең теле-стиле байлыгына ***фразеологик берәмлекләр*** дә зур өлеш керткән. Мәсәлән: *буйга җитү; дәрт уяну; күңеле бармау; кайнашып йөрү; күз ташлау; йөрәккә ут төшү, кан кайнау; күңеленңне сузмау; үз чаманы карау; көлке кылу; авыз йомылганчы; рәт җитү.*

***Эпитетлар:*** *бүз* балалар; *асыл* киенгән; *укалы* бүреге; *алтынлы* кәмәре; *төз* буй; *куе кара* мыек; *акыллы* йөз; *яшь* йөрәк; *сылу* кыз; *яшь* күңел; *асыл* айгырлар; кызларның *сылулары;* җегетләрнең *асыллары;якты* кояш; *ачык* дала; *яман* уе; *елдам* ат; *яман* камчы.

***Метафоралар*** ярдәмендә охшаш яки каршылыкка нигезләнгән чагыштырулар бирелә: думбрасы, зөрнәсе белән *шау килеп*; тезгеннәр тартыла, камчылар *уйный*, өзәңгеләр *селкенә башлый* , егетнең мактавына каршы *каты чәнчеп,* үләң белән җавап кайтара.

Икенче бер охшаш күренеш белән ***чагыштырулар*** урынлы кулланылган: *айдай* йөзле, *камыштай* буйлы; лачын *коштай* тизлек белән аның тезгенен тартып җибәрә; сүз әйтеп авыз йомылганчы; бөркет *коштай* кагына биреп...

***Морфологик төзелеш үзенчәлекләре*** аша авторның фикерләрен җиткерү рәвеше аныклана һәм укучының кабул итеп алу мөмкинлекләре ачыла. Тиңдәш кисәкләрне еш очратырга була, парлы сүзләрнең еш кулланылуы игътибарны җәлеп итә. Чагыштыру *-дай*/*-дәй* кушымчалары, *сыман* бәйлеге белән бирелә. *Диделәр* сүзе актив кулланыла, бигрәк тә парлы сүзләр еш кулланыла: *кара-каршы*; *уен-көлке* кылалар, *үләң-җыр* әйтешәләр; *Карлыгач-Сылу; алыш-биреш* һ. б.

***Синтаксик үзенчәлекләр.*** Функциональ яктан бу – хикәяләүле текст. Текстта кыска, ким җөмләләр күп кулланылган, шуның белән аның халыкчанлыгы ачык чагылдырылган. Галимҗан Ибраһимовның төп максаты – матур, шул ук вакытта күзаллау өчен җиңел сурәт тудыру булганга, ул казакъ халкының сүзгә тапкырлыгын, сөйләү осталыгын, үзенчәлекле сөйләүләрен, фикерләрен турыдан-туры, ачыктан-ачык әйттермичә, оста итеп метафоралар аша бирә. Әдипнең таланты, тоемлау мөмкинлекләре аның тыныш билгеләрен оста файдалануында да күренә. Мәсәлән: *– Юл булсын!*

Әсәр татар халык әкиятләре стилендә язылган: эпик киңлек күзгә ташлана, мавыктыргыч, укырга җиңел. Зур булмаган вакыйгаларда «тукталышлы хикәяләү» алымы белән тулы бер халыкның язмышы бирелә. Еш кулланылган алымнардан лирик чигенешләр, эчке монологлар, символик образлар, кабатлаулар әсәрне яңгырашлы итәләр. «Казакъ кызы» романы, XX гасыр башы татар әдәбиятын тирәнтен өйрәнү белән бергә, телебездәге лексик үзенчәлекләрне дә тикшереп-карап үтү, тарихи-мәдәни белешмә алу мөмкинлеген дә ача. Әдипнең үзенә кадәрге бай мирас белән тирәнтен таныш булуын, татар теле үзенчәлекләрен бик нечкә сиземләвен, телгә хас булган закончалыкларны билгеле бер системага салып, гаять оста итеп укучыга җиткерә алуын күрсәтүче бу әсәрне «зур фәнни хезмәт булып саналырга хаклы» дип әйтә алабыз.

## НОВОМЕТОДНЫЕ ПРЕОБРАЗОВАНИЯ КАК РЕАКЦИЯ ТАТАРСКОГО СОЦИУМА НА ГЛОБАЛИЗАЦИОННЫЕ ПРОЦЕССЫ В ЭКОНОМИКЕ КОНЦА XIX – НАЧАЛА XX В.

***Б. Ю. Хайрутдинов (Казань)***

